*Российский исламский институт (Казань)*

Каюм Насыри – ученый-просветитель, внесший бесценный вклад в развитие татарской лексикографии. Его словари являются одним из самых передовых работ своего времени. Кроме вышедших в свет лексикографических трудов, в архиве хранится также и фрагмент рукописного «Татарско-русского словаря» ученого. До сегодняшнего дня данная работа Каюма Насыри не переведена на кириллицу и не издана. В представленной статье делается обзор особенностей рукописного словаря в лексико-грамматическом аспекте. Анализируются основные приемы в работе автора, проводится историко-лингвистический анализ лексикона словника.

**Ключевые слова:** Каюм Насыри, лексикография татарского языка, татарский литературный язык, лексика, словник, рукописный словарь.

Kayum Nasyri is a scientist and educator who has made an invaluable contribution to the development of Tatar lexicography. His dictionaries are one of the most advanced works of his time. In addition to the published lexicographical works, the archive also contains a fragment of the scientist's handwritten "Tatar-Russian Dictionary". To date, this work by Kayum Nasyri has not been translated into Cyrillic and has not been published. The article provides an overview of the features of the handwritten dictionary in the lexico-grammatical aspect. The main techniques in the author's work are analyzed, and a historical and linguistic analysis of the dictionary's vocabulary is carried out.
**Keywords:** Kayum Nasyri, lexicography of the Tatar language, Tatar literary language, vocabulary, dictionary, handwritten dictionary.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ КУЛЪЯЗМА СҮЗЛЕГЕ

***Г.Г. Батыршина, В.М. Гарипова-Хәсәншина***
*Россия ислам институты (Казан)*

Бөек татар мәгърифәтчесе К. Насыйри – халкыбыз мәдәнияте тарихында тирән эз калдырган, аның милли үзаңы һәм рухи үсешенә зур өлеш керткән күренекле галим. Киңкырлы энциклопедик эшчәнлек алып барган, шул юнәлештә «Көнчыгышны Көнбатыш белән тоташтыручы күпер» [1: 9] булып торган К. Насыйриның үзе исән чагында ук матур әдәбият, фольклор, педагогика һәм төрле фән тармаклары буенча 40 ка якын китабы (Г. Рәхим исәпләүләренә караганда, «аның язган әсәрләренең басылганнарының гына бит хисабы 4000 биттән артыграк, календарьлары үзе 1228 бит җыела») [4: 78] басылып чыга. Алар арасында галимнең тел белеме, шул исәптән лексикография өлкәсенә караган хезмәтләре аерым урын алып тора.

XIX гасырның икенче яртысында басылган сүзлекләр арасында К. Насыйри хезмәтләре иң күренеклеләре булып исәпләнә. Бу чорда галимнең «Татарча-русча лөгать китабы» (1878), «Рус хоруфе һәҗас үзә мөрәттиб лөгать китабы» (1892) (алар исә туган телдә язылган беренче сүзлекләр була [1: 261]), терминологик сүзлекләре, шулай ук татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге «Ләһҗәи татари» (1895–1896) дөнья күрә. В. Хангилдин галимнең бу өлкәдәге эшчәнлегенең төп юнәлеш-максатларын күрсәтеп, хаклы рәвештә болай яза: «1 – русларга татар теле, татарларга рус телен өйрәтү; 2 – татарларга һәм башка кызыксынучыларга шул чор татар әдәби телен өйрәтү һәм татар әдәби телен лексик-стилистик яктан баету; 3 – татар әдәби телен лексик яктан нормалаштыру максатын куеп, терминологик сүзлекләр төзү» [5: 79 ].

К. Насыйриның югарыда әйтелгән хезмәтләре белән беррәттән, ТР милли архивында саклана торган кулъязма сүзлегенә дә игътибар итәсе килә [2]. Ул – А4 форматындагы ике яклап язылган 24 биттән гыйбарәт «Татарча-русча сүзлек»нең бер өлеше. Битләр бергә төпләнгән. Елы күрсәтелмәгән. Сүзлектә бары «А» хәрефенә башланган беоәмлекләрләр генә урын алган. Димәк, ниндидер сәбәпләр аркасында төгәлләнмичә калган яки аның шушы өлеше генә сакланган.

1878 елда дөнья күргән «Татарча-русча лөгать»тән аермалы буларак, биредә сүзләр аңлату юлы белән тәрҗемә ителә. Кайбер сүзләрнең этимологиясе, чыганаклары, семантик үзенчәлекләре күрсәтелә. Ягъни

К. Насыйри бу сүзлеген билгеле бер теоретик максатларны да күздә тотып, татарча-русча тулы сүзлек итеп төзи башлаган дияргә җирлек бар.

«А» хәрефеннән генә башланган сүзләрне үз эченә алса да, лөгатьлеккә меңгә якын (төгәлрәк 895) берәмлек теркәлгән. Алар гарәп шрифтында бирелеп, тәрҗемә өлеше кириллицада язылган.

Югарыда әйтелгәнчә, сүзләрне тәрҗемә итүнең төп принцибы булып аңлату алымы тора. Мәсәлән: *араламак* – сделать промежуток между двумя предметами, прежде соединенными, отделить один предмет от другого, разнимать, раздвинуть; *эзләмәк* – (по следу идти) искать какой-нибудь предмет, обыскивать, эзләп тапмак – отыскать; *апара* – опара, закваска для пшеничного хлеба һ. б.

Бер төркем сүзләргә автор төгәл эквивалентын бирә яки аны синонимнары белән тәрҗемә итә: *адым* – шаг, *ачыгу* – голодность, *адашу* – заблуждение, *арулык* – чистота, опрятность; *арата* – перекладина, балка; *ызгыш* – ссора, брань, распря; *азап* – мука, мучение, страдание, тяжкий труд, пытка; *ату* – кидание, бросание һ. б. Мисаллардан күренгәнчә, төгәл аңлатмалар исем һәм исем фигыльгә караган сүзләргә бирелгән.

*Асламчы* сүзе катнаш юл белән (синонимнар һәм аңлату юлы бергә килү) тәрҗемә ителгән: *асламчы* – барышник, разносщик (продающий товар на толчок или по домам).

*Асмак* сүзенә автор этнографик характердагы аңлатма биргән: *асмак* – казан асмак (=аш асмак), подвесить котел (выражение сие сохранившееся от кочевого народа – они подвешивают котел на таганы, т. е. в трех палках, соединенных вверху, а теперь в татарских домах вставится к печке, прислужить к приготовлению пищи, варить кушанье).

Бер төркем сүзләр (орфографик варинтлар, традицион формалар, сирәк кулланылган сүзләр) телдә ешрак кулланылган вариантларына кайтарып тәрҗемә ителгән. Мәсәлән: *абагы* см. җабагы; *абалана* см. тубалана; *абынучан* см. сөртенүчән (моннан, димәк, сүзлекнең башка өлешләре дә булуы яисә автор аны, һичшиксез, төгәлләргә тиешлеге күренә); اطا (ата) см. آتا; آغر (агыр) см. اوْر (авыр) һ. б.

Иллюстрация ярдәмендә генә тәрҗемә ителгән очраклар бар: *атынмак* – качаться на качелях (таган атунмак); *эз* – кеше эзе, куян эзе, ат эзе; *аталы* – аталы-угыллы, аталы-кызлы, аталы-аналы күгәрчен (голубь с голубкой) һ. б.

Сүзлектә һәр берәмлеккә диярлек мисаллар, ягъни иллюстрация бирелгән. Алар, нигездә, җанлы сөйләмнән алынса да, К. Насыйри халык иҗатыннан да матур үрнәкләр китерә. Аеруча ул күпмәгънәле сүзләрнең мәгънәсен тулырак ачу, күчерелмә мәгънә яисә мәгънә төсмерләрен ачыклау өчен иллюстратив материалдан файдалана. Мисаллар. *Аяк* – нога (у человека), *лапа* (у птиц) (бу сүзнең кулланылыш үзенчәлегенә дә игътибар итә) преимущественно от колена до подошвы. Чашка, посуда (җама аяк), чайная чашка – бер аяк чәй, чашка чаю (чәй аягы = чынаяк), *таш аяк* – каменная посуда, чаша (= таш савыт). Так же называется в Казани ярмарка небольшая на Булаке, в которой торгуют каменными посудами; *тимер аяк* – коньки, привязываемые к ногам; *актык чана аягы* – последний зимний путь; *юл аягы* тагы берне эч – на дорожку выпей еще, *аягын сузды* – ногу протянул (т. е. умер), *аягыңның туфрагы булам* (буду прахом твоей

ноги) – всепокорнейше прошу, *аяк* – ножка (у мебели), өстәл аягы, *аякчу* – портянка.

*Атмак* – кидать (ыргытмак), бросать (ташламак), стрелять. *Таш атмак* – бросить камень (рукой), *ук атмак* – стрелу пустить из лука, *мылтык атмак*, *туп атмак, агач чәчәк аттты* – дерево расцвело, *таң атты* – расцветало. Гомумән, автор бу сүзлегендә сүзләрнең күпмәгънәлелегенә игътибар итә. Мәсәлән, *айкамак* сүзенең ул 7 мәгънәсен күрсәтә: *баш айкамак* – качать головой; *кул айкамак* – широко и многократно разводить руки, когда издали призывать кого-то; *кырмыска бүкәнен таяк белән айкау* – ворочать палкой муравейную кучу; *мичне кисәү белән айкамак* – шеверять в печи кочергой; *айкый-чайкый кер юа* – полоскать в воде (как полощат белье); күч. *халык айкамак* – производить волнение, распря, ссору в народе; күч. *китабларны актарыб-айкаб бетерде* – приводить в сильное движение (хәзерге «Татарча-русча сүзлек»тә әлеге сүзнең 4 мәгънәсе бирелә). Хәзерге татар әдәби телендә, гадәттә, ‘мич айкау’ урынына *мич бутау*, ‘баш айкау’ урынына *баш чайкау* тезмәләре кулланыла. *Асыл* лексик берәмлегенең ике мәгънәсе*: асыл кеше* – важный человек; *асыл таш* – драгоценный камень (хәзерге сүзлектә 4 мәгънә бирелә); *абдырамак* сүзенең 5 мәгънәсе күрсәтелә (хәзерге “Татарча-русча сүзлек”тә шулай ук 7 мәгънәсе теркәлгән) [7]. *Ыспай* лексик берәмлегенең хәзерге сүзлектә ике мәгънәсе теркәлсә, К. Насыйри тагын ‘стройный’ (о росте), ‘хорошенький’ (о лошади), ‘чистый’, ‘светлый’, ‘чудный’ һәм ‘со вкусом украшенный’ (о доме) кебек мәгънәләрен дә бирә һ. б.

Бер төркем сүзләрнең автор чыганак телен күрсәтә, этимологиясен ачыклый. Мәсәлән: *абыз* – от араб. хафиз, наизусть знающий, ученый, образованный человек, абыз кеше – почтенный человек, абзый – абый, братец, абзый – господин. Шунда *абызта = абыз тута* (почтенная, старшая сестра), *абызтай* (госпожа, сударыня) сүзе дә бар. “Бүгенге көндә ‘абыстай’ сүзе татар һәм башкорт телләрендә ‘мулла хатыны’ мәгънәсендә кулланыла [3: 220], этимологик сүзлектә дә шушы мәгънәдә килә [6]; *абруй* – персид. аб – вода, руй – лицо – достоинство, честь, слава; *алка, азаб* сүзләрене; шулай ук гарәп теленнән икәнлеген, *арыш* берәмлегенең рус сүзе икәнлеген әйтеп үтә.

Лексик-грамматик яктан караганда, лөгатьлектә барлык сүз төркемнәре дә урын алган. Фигыльләр *-мак//-мәк* кушымчалы инфинитив формасында теркәлгән. Кайбер фигыльләрнең юнәлеш формалары күрсәтелеп, аннан соң исем фигыль бирелгән.

Хезмәтнең бер өлеше генә булуга карамастан, биредә сүзләрнең лексик-семантик яктан берничә төркемен күзәтергә мөмкин. Болар: көнкүреш атамалары: *аркан, арба, ахак, алтагач, аякчу, астар* һ. б.; туганлык терминнары: *аба – абый, абзый, абыз тута – абызтай, ата, ага, ана, әби, ир;* үсемлек исемнәре*: абага, артыш, алма, әрем* һ. б.; кош-корт, хайван атамалары: *акчарлак, әтәч, арыслан, ат, алабуга, эт* һ. б.

Татар лексикографиясе тарихында мәгърифәтче галим К. Насыйриның эшчәнлеге зур әһәмияткә ия. Аның сүзлекләрендә туган телебез – татар теленең XIX гасыр ахырындагы, шулай ук хәзерге татар әдәби телендә дә кулланыла торган бай лексик хәзинә тупланган. Галимнең татарча-русча кульязма сүзлеге төзелеше, тәрҗемә принциплары белән бу өлкәдәге басылган

хезмәтләреннән аерылып тора. Әлеге кулъязма хезмәт тулысынча төгәлләнеп басылып чыккан булса, үз чоры өчен генә түгел, бүгенге көн өчен дә кыйммәтле чыганак, татар лексикографиясенең гүзәл бер үрнәге булыр иде.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Загидуллин И.К.* Великий татарский просветитель Каюм Насыри: монография. Казань: Татар. кн. изд-во, 2024. 319 с.

2. *Насыйри К.* Татарча-русча сүзлек. Кулъязма. ТР Милли архивы, 970 ф., 1 тасв., 5 эш.

3. *Рамазанова Д.Б.* Гаиләдә традицион этика һәм никах туганлыгы терминнары // Межэтнические и межконфессиональные отношения в Республике Татарстан. Ч. 2. Казань, 1993. С. 218–221.

4. *Рәхим Г.* Насыйриның тәрҗемәи хәле // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар / редкол.: И.Г. Гомәров, З.З. Рәмиев, А.М. Ахунов; төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова. Казан: ТӘһСИ, 2020, 9 нчы чыг. Б. 81–88.

5. *Хангилдин В.Н.* Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе // Каюм Насыйри – 1825–1945. Казан, 1948. Б. 78–91.

6. URL: https://suzlek.antat.ru/fullartR.php?id=11917

7. URL: https://suzlek.antat.ru/fullartR.php?id=99494

УДК 81`28

# ТЕОРЕТИЧЕСКИЕ АСПЕКТЫ АРЕАЛЬНОЙ ЛИНГВИСТИКИ

***А.А. Бадртдинова***

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье описываются теоретические аспекты ареальной лингвистики. Раскрываются понятия центра, перефирии и диффузии ареала. Изложен метод географической лингвистики – основной метод ареальной лингвистики. Перечислены также другие методы общей лингвистики.

**Ключевые слова:** Ареальная лингвистика, географическая лингвистика, ареал, центр, перефирия, диффузия.

The article describes the theoretical aspects of areal linguistics. The concepts of center, periphery, and area diffusion are revealed. The method of geographical linguistics, the main method of areal linguistics, is described. Other methods of areal linguistics are also listed.

**Keywords:** areal linguistics, geographical linguistics, area, center, periphery, diffusion.

# АРЕАЛЬ ЛИНГВИСТИКАНЫҢ ТЕОРЕТИК АСПЕКТЛАРЫ

***А.Ә. Бәдртдинова***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

Ареаль лингвистика – лингвистик география методларын кулланып, лингвистик ареалларны өйрәнә торган тел белеме тармагы [1: 18]. Ареаль лингвистика (лат. area ‘мәйдан’, ‘киңлек’) – лингвистик география методлары ярдәмендә телләрнең һәм диалектларның пространство озынлыгында һәм үзара бәйләнештә таралуын өйрәнүче лингвистик фән.

Ареаль лингвистика – тел үзенчәлекләренең төрле территорияләрдә таралуын тикшерә. Ул лингвистик география һәм диалектология белән тыгыз

бәйләнгән. Ареаль лингвистиканың төп нәтиҗәләре – уртак билгеләргә ия урынчылыклар.

Ареаль тел белеменең төп методларыннан берсе – лингвистик география методы. Карталарда изогласслар билгеләнеп, тел бәйләнешләре, тел күренешләренең «туу» үзәкләре ачыклана. Тел күренешләренең таралу яки тукталу сәбәпләре анализлана.

Ареаль лингвистика телнең эчендәге үзенчәлекләрен, характеры буенча бертөрле процессларны ачыклаучы, бертөрле нәтиҗәләр бирүче һәм дөньяның төрле телләрендә шактый югары дәрәҗәдә ешлык белән чагылучы үзенчәлекләрне ачырга, аларның картада тасвирланывын күрергә ярдәм итә.

Ареаль лингвистиканың максаты һәм объекты бер дисәң дә була – телләр арасында охшашлыкларны һәм аларны китереп чыгаручы сәбәпләрне өйрәнү.

Ареаль лингвистика диалектология фәне нигезендә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында барлыкка килә.

Әйтеп үткәнчә, ареаль лингвистикада төп тикшеренү ысулы – лингвистик география методы.

Лингвистик география тел күренешләренең территориаль таралышын өйрәнә торган, ареаль лингвистика белән тыгыз бәйләнгән тел белеменең бер бүлеге [1: 82].

Әлеге метод белән эшләгәндә төп этаплар түбәндәгедән гыйбарәт:

1) тел материалын җыеп, әзерләү;

2) картага төшерү;

3) карталарны интерпретацияләү.

Картага төшергәнче сораштырулар үткәрелә. Информантларны яше, социаль хәле, туган урыны, шушы урында яшәү вакытына карап сайлап алып, алдан төзелгән анкета белән эш алып барыла. Иң еше очрый торган грамматик, лексик үзенчәлекләрне керткән сораулыклар алдан төзелгән була. Мәсәлән татар телендә «йорт» сүзе берничә төрле вариантта әйтелә, кайбер сөйләшләрдә «ызба» [3: 795], кайберләрендә «өй» дип әйтү таралган. Информантка рус телендә фраза әйтелә һәм шул фразаны татарчага тәрҗемә итергә кушыла: «Он остался дома», информантлар үзләре гадәтләнгәнчә җавап бирә, мәсәлән: «Ул үдә калды». Картага билгеләр куелгач, ареаллар ачыклана.

Ареаль лингвистикада тасвирлама метод – телнең билгеле бер чорда иҗтимагый яшәеш рәвешен сурәтли, тел механизмының элементларын, кисәкләрен тасвирлау һәм анализлау, шулай ук фонемаларга, морфемаларга, сүзләргә, грамматик формаларга һәм категорияләргә билгеләмәләр бирү методы; чагыштырма-тарихи метод – кардәш телләрнең үсеш тарихын билгеләгән законнарны ачу өчен хезмәт итә торган метод, кардәш телләрдәге кардәш күренешләр җыелмасын һәм бу күренешләрдә сакланган борынгы закончалыкларны өйрәнүгә нигезләнгән метод һәм башка ысуллар кулланыла [1: 112, 173].

Телдәге яңа күренешләрнең барлыкка килү сәбәпләрен, үсеш тарихын, таралу юнәлешләрен өйрәнгәндә, архаизмнарның сакланып калган урыннарын тапканда тикшеренүче өчен ареалдагы үзәкне, периферияне, диффузия (вибрация) зоналарын эзләү мөһим урын алып тора. Диалект

континуумының өч төп зонасын аерып күрсәтү кабул ителгән: үзәк, маргиналь (күзәтелгән изоглосслар азрак сизелерлек характерда булган ерак зона) һәм күчеш зонасы.

Мәсәлән, минзәлә сөйләшендә «карагат» сүзе сакланып калган [2], сүзне куллану үзәккә – Казан тирәсенә якынайган саен кими, «карлыган» сүзенә күчә. Әлеге сүз сергач (Түбән Новогород), байкыбаш (Башкортостан) сөйләшләрендә дә очрый [3: 274]. Бу сүз кайбер төрки телләрдә сакланып калган, мәсәлән, казах телендә [4]. Шул ук вакытта XX гасыр азагы белән чагыштырганда бүген әлеге сүзне минзәлә сөйләшендә куллану кими. Ул архаизмга әйләнеп бара. Аны диалектизм дип тә тасвирлыйлар. «Карагат» сүзен куллану зонасы – күчеш зонасы була. Ә аның үзәге дип төгәл генә кайсы як икәнен өйтеп булмый, чөнки таралу ареалы бик киң. Картадан караганда кайсы урында иң киң таралыш тапкан, шул территорияне үзәк дип әйтергә була. «Карагат» сүзе Себердәге төрки халыкларда да очрый.

Шулай итеп, ареаль лингвистика фәне география белән тыгыз бәйләнгән һәм телнең үсешен, тарихын төрле яклап ачыкларга ярдәм итә.

СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1. Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов / под ред. Ф.И. Тагировой и Ф.Ф. Гаффаровой Казан: ИЯЛИ, 2016. 248 с.

2. *Бадртдинова А.А.* Говор села Актаныш Республики Татарстан Российской Федерации // Мир науки. Социология, филология, культурология. 2021. Т. 12. № 3.

3. Татар теленең зүр диалектологик сүзлеге: ок. 40 000 единиц / сост.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыкова, Т.Х. Хайрутдинова [и др.]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. 839 с.

4. Русско-казахский словарь [Электронный ресурс]. URL: https://sozdik.kz/ru/ (дата обращения: 16.05.2025.)

УДК 811.512.145

# ЧЕПЕЦКИЕ ТАТАРЫ (нукратский говор татарского языка и образцы народных традиций)

***М.Р. Булатова***

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Статья посвящена этнолингвистической характеристике нукратского говора среднего диалекта татарского языка. Нукратский говор – это говор чепецких татар, т. е. группы татар Урало-Поволжья, живущих в бассейне реки Чепцы (левый приток Вятки) на северо-западе современной Удмуртии и Слободского района Кировской области. В историографии они известны как чепецкие татары, потомки арских князей. В данной работе рассматриваются история формирования татар указываемых регионов и их лингвистические особенности. Приводятся примеры народных традиций чепецких татар. Статья написана на основе материалов, собранных автором во время комплексных экспедиций, предпринятых Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан по татарским населенным пунктам Удмуртской Республики и Кировской области РФ.

**Ключевые слова:** чепецкие татары, Удмуртия, Кировская область, средний диалект татарского языка, нукратский говор, ареальная лингвистика, комплексная экспедиция, традиционная культура.

The article is devoted to the ethnolinguistic characteristics of the nukrat subdialect of the middle dialect of the Tatar language. The nukrat subdialect is the subdialect of the Chepetsk Tatars, i.e. a group of Tatars from the Ural-Volga region living in the Cheptsa River basin (left tributary of the Vyatka) in the northwest of modern Udmurtia and the Slobodskoy district of the Kirov region. In historiography they are known as the Chepetsk Tatars, descendants of the Arsk princes. This work examines the history of the formation of the Tatars of the indicated regions and their linguistic features. Examples of folk traditions of the Chepetsk Tatars are given. The article is based on materials collected by the author during complex expeditions undertaken by the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan to Tatar settlements of the Udmurt Republic and the Kirov Region of the Russian Federation.

**Keywords:** Chepet Tatars, Udmurtia, Kirov region, middle dialect of the Tatar language, nukrat subdialect, areal linguistics, complex expedition, traditional culture.

# ЧЕПЦА БУЕ ТАТАРЛАРЫ
## (татар теленең нократ сөйләше һәм халык традицияләре үрнәкләре)

***М.Р. Булатова***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

Татар теле урта диалектының нократ сөйләше Вятка (тат. Нократ) елгасының бер тармагы булган Чепца елгасы бассейнында таралган. Шуңа күрә сөйләш вәкилләрен *Чепца буе татарлары* дип тә атыйлар. Административ бүленеш буенча бу территория Киров өлкәсеенең Слободской районына һәм Удмуртия республикасының Юкамен, Глазов, Балезино районнарына карый.

Киров өлкәсенең Слободской районындагы Нократ (русча: Карино) авылы элек бик зур булган, үзе берничә авылны – Олы Ил яки Югары авыл (Югары Карино), Түбән авыл (Түбән Нократ), Ильяс авылларын берләштереп торган. Югары авыл үзе дә Митюк һәм Дәүләтьяр авылларына, Түбән авыл исә Арслан, Абаш, Касыйм, Юач авылларына бүленгән булган.

Сөйләш вәкилләренең бер өлеше – Чепца елгасының югары агымында, Удмуртиядәге авылларда яшиләр. Бу сөйләшкә караган авыллар арасында иң зурысы – Балезино районының Кистем авылы. Тарихи материаллардан күренгәнчә, Кистем авылының халкы, җир аз булу сәбәпле, Киров өлкәсендәге Нократ авылыннан аерылып чыгып, әлеге урынга килеп утырган. Бу авылның сөйләше дә шул ук Нократ авылы сөйләшеннән аерылмый диярлек. Шуңа күрә, фәндә сөйләш *нократ-кистем* сөйләше дигән исем белән дә билгеле [1: 4].

Нократ татарларының килеп чыгышы турында бер-берсенә капма-каршы берничә гипотеза яшәп килә. Берәүләр аларны көнчыгыштан Вятка елгасы буйларына беренчеләрдән булып үтеп кергән төрки

кабиләләрнең, икенчеләре исә Идел болгарларының варислары дип саный. Бу төркемнәрнең килеп чыгышын болгарлар һәм Алтын Урда татарлары белән бәйләп караучылар да бар.

Болгар дәүләте җимерелгәннән соң, Чепца елгасы бассейнындагы җирләр Казан ханлыгы составына керә. 1489 елгы тарихи документларда Чепца буенда Казан ханлыгына буйсынучы «арча кенәзләре» турында әйтелә. Арча кенәзләренең Чепца елгасы янында беренче яшәү урыннары булып Нократ авылы санала. Авыл исеме Вятка елгасы (Нократ иле) атамасыннан килеп чыккан [4: 39–40]. Д.М. Исхаков кыпчак кабиләсеннән Кара(ча) би токымы вәкилләре булган «арча кенәзләре»нең Арча «даруга»сына ия булуларын ассызыклый [4: 31].

XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендә һәм риваятьләрдә Чепца елгасы буйларына килеп чыккан иң беренче кенәз дип Кара хан (Кара би) санала. Кара би үзенең гаскәре белән Мәскәү кенәзенә хезмәткә алына һәм 1337–1381 елларда Чепца елгасы башыннан алып Вятка елгасына койган арадагы җирләр белән идарә иткәне өчен махсус грамота белән бүләкләнә. Галимнәр фикеренчә, Кара бинең Касыйм, Арслан, Дәүләт, Дүнәш, Абашид исемле улларыннан ишәйгән нәселе Чепца елгасы буйлап урнашкан авылларга гына түгел, бәлки хәзерге Татарстанның Әгерҗе, Актаныш, Арча, Башкортстанның Балтач районнарындагы, шулай ук Оренбург губернасының кайбер авылларына нигез салалар [7: 20].

XIX гасырда арча кенәзләре тарихын махсус өйрәнгән П.М. Сорокин аларның килеп чыгышын Идел Болгарлары белән бәйли. Галим әйтүенчә, «арча» сүзе бу этник төркемнең атамасы белән түгел, ә бәлки Чепца һәм Вятка елгалары арасындагы алар яшәгән борынгы ил исеме белән бәйле. П.М. Сорокин аларны «арча кенәзләре» дип атауны Болгар дәүләтенең төньягында урнашкан Арча шәһәре белән бәйләп аңлата [6: 61]. Әбү Хәмит әл-Гарнатый Идел болгарларының Ару дигән өлкәсе булуы турында әйтә. Аның үзәге булып сәүдә факториясеннән үсеп чыккан Казаннан 60 чакрым ераклыкта гына урнашкан Арча (Арск) шәһәре саналган. Казансу буена урнашкан Арча «даруга»сы (даруг – салым җыя торган үзәк) әкренләп киңәйгән һәм тора-бара Кама елгасының урта һәм түбән өлешләрен дә үз эченә алган. Соңыннан Арча юлы буйлап бу экономик зонаны даими күзәтү астында торган калалар барлыкка килгән. Шундый калаларның берсе Чепца елгасының уңъяк ярына урнашкан Гурья-Кала булган. Бу даруга тирәсендә һәм Арча юлы буйлап яшәгән халыкларны *арлар* дип йөртү кабул ителгән. Элек төрки телле кавемнәр бу атама белән удмуртларны гына атасалар, тора-бара арлар дип атау бу өлкәнең барлык халкына да, шул исәптән нократ татарларына да карый башлаган [8: 118; 4: 128].

Чепца буе татарлары казан татарларының мөстәкыйль төркемен тәшкил итәләр. Татар диалектологиясе фәнендә нократ сөйләшенең нократ, кистем, глазов (юкамен), бисермән-керәшеннәр урынчылыклары билгеләнгән [1: 3]. Киров өлкәсенең Слободской районы татар авыллары нократ урынчылыгына карый. Удмуртия республикасының Юкамен, Глазов, Балезино районнарында – кистем, глазов (юкамен), бисермән-керәшен урынчылыклары.

Нократ сөйләшенең үзенчәлекләре XX гасыр башында Җ. Вәлиди, XX гасыр урталарында Н.Б. Борһанова [3] тарафыннан өйрәнелгән. Диалектологлар Ф.С. Баязитова, Ф.Ю. Йосыпов, Д.Б. Рамазановаларның да бу сөйләшкә багышланган хезмәтләре бар.

ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең Удмуртия республикасына оештырган 2012 елгы комплекслы экспедиция вакытында нократ сөйләшенең кистем, глазов урынчылыклары диалектолог М.Р. Булатова (мәкалә авторы) тарафыннан да өйрәнелә. 2018 елда Киров өлкәсенә уздырылган фәнни экспедициядә автор нократ урынчылыгын да тикшерә. М.Р. Булатованың ике төбәк вәкилләренә хас тел үзенчәлекләрен яктырткан һәм гореф-гадәт, көнкүрешен материалларын туплаган кайбер хезмәтләре коллектив китапларда басылып чыга [2: 54–80; 5: 98–149].

Борынгылыкны аеруча яхшы саклаган кайбер сөйләшләр татар халкының теле, аның тарихи формалашуы турында гаять әһәмиятле булган фактларны үзләрендә саклап киләләр. Нократ сөйләше – менә шундыйларның берсе.

Фонетик үзенчәлекләр. Болгар дәүләте һәм аның дәвамчысы Алтын Урда чорларындагы төрки тел авазлар составы ягыннан сузыкларның кулланылышы белән борынгы төрки телдән аз аерылган. Нократ сөйләше вәкилләренең бабалары шушы борынгы чорга хас телне үзләре белән алып китәләр. Башка телләр чолганышында, төп татар халкыннан аерылган хәлдә яшәү нәтиҗәсендә, әлеге борынгы телгә хас авазлар системасы аларның телендә хәзергә кадәр сакланып килә. Идел буе төрки теле исә фонетик яктан шактый зур үзгәрешләр кичерә. Мәсәлән, [*а*] авазы иренләшү төсмере ала, [*о*]–[*ө*], [*у*]–[*ү*] авазлары үзара алмашыну кичерәләр. Борынгы төрки телдәге [*о*], [*ө*] авазлары урынына [*у*], [*ү*], ә [*у*]–[*ү*] урынына [*о*], [*ө*] әйтелә башлый: борынгы *кол* сүзе – хәзер *кул* ‘рука’, *көл* – хәзер *күл* ‘озеро’, *күл* – хәзер *көл* ‘зола’ һ. б. Борынгы төрки телдә хәзерге [э] авазына охшаш аваз хәзерге татар телендә [*ә*] яки [*и*] авазына, ә борынгы [*и*] авазы хәзерге телдә [*е(э)*] авазына күчә: *кәлін* – әд. килен, *бәрі* – бире һ. б.

Нократ сөйләшендә [*а*] авазы, барлык позицияләрдә дә урта (казан татарлары) диалектның дөбьяз, нагайбәк, касыйм, пермь, керәшен сөйләшләрендәге кебек, иренләшү төсмере булмаган, ачык аваз булып әйтелә (мәсәлән, қатын – әд. ха°тын, орф. хатын). Бу үзенчәлеге белән көнбатыш (мишәр) диалект сөйләшләре белән дә уртаклык күрсәтә.

[ә] авазы ике вариантта: а) татар әдәби телендәгечә киң әйтелешле (*сәгәт* – әд. сәгать, *қәгәз* – кәгазь, *Сәлимә);* б) тар әйтелешле [*ә*] – яңгырашы белән рус телендәге [э] авазына якын тора (*чэчкэ* – әд. чәчкә, *килэлэр* – киләләр). Бу үзенчәлек белән нократ сөйләше казан арты керәшеннәре сөйләшенең мишә һәм кама буе урынчылыклары, шулай ук касыйм, пермь, мордва-каратай сөйләшләренә якын тора.

[э(*е*)] авазының нократ сөйләшендә шулай ук ике варианты бар: а) тар әйтелешле [э(е)], гомумтатар сүзләрендәге кебек, тамыр һәм кушымчаларда, сүз башында һәм сүз ахырында килә ала (эшче, беренче); сөйләштә ул әдәби телдәге [ө] авазы урынына да кулланыла (кен – әд. көн, тетен – төтен һ. б.); б) киң әйтелешле [э(е)] авазы әдәби телдәге [*и*] авазы урынына килергә мөмкин (эт – әд. ит ‘мясо’, эке – ике һ. б.).

Шулай итеп, нократ сөйләшендә [*и*], [*ә*], [э(*е*)] сузык авазларының төрле вариантлары күзәтелә һәм бу күренеш татар телендә сузыкларның эволюциясе һәм үсү юллары тарихы белән аңлатыла.

Морфологик яктан, мәсәлән, нократ сөйләшендә *-нан/-нән/-дан/-дән* чыгыш килеше кушымчалары *-дин/-дэн* рәвешендә дә әйтелә (*синдин* – әд. синнән, *кешедин* – кешедән): *Мынау таулар эстендин йердэн су килэ.*

Исем-исем сүзтезмәләре сөйләштә күп очракта кушымчасыз гына кулланыла: *қазан кеше* – әд. казан кешесе, *ураза бәрйэм* – ураза бәйрәме. Бу күренеш урта диалектның пермь һәм көнчыгыш диалект сөйләшләренә дә хас.

Хәзерге заман хикәя фигыльнең кушымчасы киң вариантта, ягъни *-ай/-әй* дип әйтелә: *син йасайсын* – әд. йасыйсың, орф. ясыйсың, *кәрәксенмәйләр* – кирәксенмиләр. Чагыштыр, *-ай/-әй* вариантларын кулланып сөйләү Башкортстан, Себер, Әстерхан, Чиләбе һ. б. өлкә татарларында да сакланган. Әлеге форма татар әдәби телендә XIX гасыр ахырына кадәр кулланылган.

Фигыльнең *-ма/-мә* формасы актив күренеш: *Буләкне китермә* (китерергә) *тийеш.* Бу форма касыйм, пермь, әстерхан, бастан, нурлат сөйләшләренә, минзәлә сөйләшенең әгерҗе урынчылыгына хас. Сирәк кенә *-ма кели* формасында көнбатыш диалектта да очрый.

Сөйләштә иске татар әдәби телендәге *-мага/-мәгә* инфинитив формасы да сакланган: *Сезне тыңнамаға керәйем әле, дидем.* Бу форма әлеге көндә урта диалектның касыйм, бәрәңге, пермь, бастан, эчкен, әстерхан һәм өлешчә тагын башка сөйләшләрендә сакланган.

Нократ сөйләше лексик-семантик системасының нигезен гомумтатар сүзләре тәшкил итә. Әдәби телдә булмаган сүзләр дә табыла. Аларның күпчелеге төрки-татар; шулай ук, күрше халыклар белән аралашу нәтиҗәсендә, сөйләштә алынмалар (рус, удмурт) да урын алган (сирик – әд. почмак, олан – бала, хуҗам – ирем, пәтери – чорма; бидрә – чиләк, гүлпич – идән асты; пүкән – урындык, қучақ – тәрәзә, угриҗ – кыяр, папа – күбәләк, зыпка – бишек һ. б.).

Түбәндә фәнни экспедиция вакытында информанттан диктофонга язып алынып транскрипцияләнгән, тел үзенчәлекләрен һәм халык традицияләрен чагылдырган сөйләү үрнәкләре китерелә:

**Бәйрәмнәр.** [Ийүндә сабантуй уздырма уйлайбыз. Конкурс булма тийеш: күэндэлэр белэн сулар ташып, мешоклар белән қыйнашып, қапчықларда йүᵒгереп, күчтэнэчлэрне кискэлэп арқандан, бағанаға менү. Элекке калхузда арлар да бар эделәр. Урыслар да, бисерманнар. Анын күрә ’атыш (*катыш*) булғачын, аларнын бэрйэмнәрен (*бәйрәмнәрен*) туже уздырғаннар. Арларнын «Николин ден′» булғалай. Ул кез кен (*көз көне*) була, уборка беткәчен. Қыш кен аларға «Масленица»ны уздырма булышқалайбыз. Арларнын бэрйэмнэре бар – «Выл′ Ӝук» (*Яңа ботка*). Ул сабантуй формасында: уйыннары да булғалай, торговл′а да, канциртлары да. Безнен дә – татар, ар халықнын – ансамбл′ләребез йэри чығыш йасамаға. Сабантуйларны уздырғанда без қатнаштырабыз татар номерлар да, арлар номерларын да. Патамушто бэтенебез бер аwылда торабыз] *(Киров өлкәсе Слободской районының Нократ авылында Н. Дәүләтьяровтан (1950 елгы) Миңнира Булатова язып алды. 2018 ел).*

**Аш-су.** [Қыймақ, күзикмәк, қабарчи (*кош теле*) бешерер, зур-зур ипи, күмәч салыр иде әни. Пирәмәч ачы қамырдан була, эстегә йералма бытқа (*бәрәңге боткасы*) йаққалағанда. Тәбәғый (*зур кекс*), чепчигине (*чәкчәк*) бешермә була. Безди дә пилмин тыталар, аш шулпа йасайлар, йарма булса, йармалы аш. Балиш, кул'аш – итле бәрәңге, бэккэн (*бөккән*), қал'ағалы беккэн – эченә шалқан салып бешергән беккэн. Безди кушман (*ачы торма*) субырнысы (*төнәтмә*) булған] *(Удмуртия Республикасы Юкамен районы Дасис авылында Т. Балтачевадан (1933 елгы) Миңнира Булатова язып алды. 2012 ел).*

**Кияүгә чыгу.** [Кийәүгә чыққанда, ийгә кергәндә бәләкәй (*мендәр*) салдылар. Бийатам, бийемем бачқычны менгәндә йәшел печин йәйделәр, топсасын басасын икән, бәләкәй салалар. «Әйдәгез, текле айақларығыз белин», дилэр. Бал, май да қаптыралар. Кич кәбен салдылар (*никах укыттылар*). Кизүлейләр (*аш-су әзерлиләр*): шанги (*пәрәмәч*), қабарчи, беккэн, тәбәкмәк (*табада пешкән затлы камыр ашы*), эт (*ит*) бешерделәр. Безди башта чәй эчәләр, анан ары аш қуйалар] *(Удмуртия Республикасы Глазов районы Кистем авылында З. Касыймовадан (1934 елгы) Миңнира Булатова язып алды. 2012 ел).*

Йомгаклап әйткәндә, Удмуртия һәм Киров өлкәсе территориясендәге Вятка (тат. Нократ) елгасының бер тармагы булган Чепца елгасы бассейнында татар теле урта диалектының нократ сөйләше таралган. Бу сөйләштә тарихның тирән катламнарын ачарга ярдәм итә торган, иске татар язма әдәби теленә хас булган лингвистик үзенчәлекләр, халык традицияләре ныграк сакланып калган. Гореф-гадәт, йолаларга, тормыш-көнкүрешкә караган сүзләр әлеге сөйләшнең урта диалектның казан арты, пермь, керәшен, касыйм сөйләшләре белән, шулай ук көнбатыш диалект сөйләшләре белән дә зур уртаклыгы булуын күрсәтә. Тарихи сәбәпләр аркасында, татар халкының төп өлешеннән территориаль яктан аерымланып, удмуртлар һәм руслар арасында яшәп калганлыктан, нократ сөйләше вәкилләренең гореф-гадәтләрендә әлеге халыклар белән уртаклыклар барлыкка килгән.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Баязитова Ф.С.* Нократ сөйләше. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе, фольклор. Казан, 2006. 240 б.

2. *Булатова М.Р.* Татар теле урта диалектының нократ сөйләше // Милли-мәдәни мирасыбыз: Киров өлкәсе татарлары. Казан, 2022. Б. 54–80.

3. *Бурганова Н.Б.* Языковые особенности каринских и глазовских татар: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1953. 16 с.

4. *Исхаков Д.М.* Арские князья и нукратские татары (Историко-этнографические сведения, генеологии, клановая принадлежность, место в социально-политической структуре Казанского ханства и Русского государства). Казань: Фэн, 2010. 224 с.

5. *Рамазанова Д.Б., Булатова М.Р.* Тел – милләтнең җаны (Татар теле урта диалектының нократ сөйләше) // Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары. Казан, 2021. 2 нче басма. Б. 98–149.

6. *Сорокин П.М.* Арские князья в Карино // Календарь и памятная книга Вятской губернии на 1895 г. Вятка, 1894. С. 45–70.

7. *Сыркина И.А., Касимова Д.Г.* Загадки незагадочного народа: историко-этнографический очерк о чепецких татарах. Глазов: ГГПИ, 1994. 175 с.

8. *Юсупов Ф.Ю.* Татар теленең диалектлары: Урал сөйләшләре. Казан: Мәгариф, 2003. 351 б.

УДК 811.512.145

# РИТОРИЧЕСКИЙ ВОПРОС И РИТОРИЧЕСКОЕ ВОСКЛИЦАНИЕ В СТАРОТАТАРСКИХ ПИСЬМЕННЫХ ИСТОЧНИКАХ XVII–XVIII вв.

***М.З. Валиева***

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Статья посвящена изучению функционирования риторического вопроса и риторического восклицания в старотатарских письменных источниках XVII–XVIII вв. Риторический вопрос и риторическое восклицание в художественных текстах аявляется одним из выразительных средств придания эмоционально-экспрессивного оттенка и повышения выразительности текста. Автором сделан вывод о том, что риторический вопрос и риторическое восклицание в старотатарских письменных текстах выполняют стилистические функции и усиливают образность высказывания.
**Ключевые слова:** Старотатарский язык, письменный источник, риторический вопрос, риторическое восклицание.

The article is devoted to the study of the functioning of the rhetorical question and the rhetorical exclamation in the Old Tatar written sources of the XVII–XVIII centuries. The rhetorical question and the rhetorical exclamation in literary texts are one of the expressive means of giving an emotionally expressive shade and increasing the expressiveness of the text. The author concludes that the rhetorical question and the rhetorical exclamation in the Old Tatar written texts perform stylistic functions and enhance the imagery of the utterance.
**Keywords:** Old Tatar language, written source, rhetorical question, rhetorical exclamation.

# XVII–XVIII ГАСЫР ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ РИТОРИК СОРАУ ҺӘМ РИТОРИК ӨНДӘҮ ҖӨМЛӘЛӘР

***М.З. Вәлиева***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

Риторик сорау яки риторик өндәү җөмләләр эмоциональ-экспрессив яктан күпкырлы мәгънә төсмерләрен җиткерә ала торган стилистик чараларның берсе булып тора. Риторик сорау җөмләләр авторның, лирик герой яисә персонажның карашларын, уй-фикерләрен сорау рәвешендә чагылдырып кына калмый, ә көчле экспрессия аша җиткерә, шулай ук анда ниндидер фикерләр расланырга яисә кире кагылырга да мөмкин [4: 429].

XVII–XVIII гасырлар иске татар язма истәлекләрендә риторик сорау, риторик өндәү кебек стиль чаралары авторлар тарафыннан яратып кулланыла. Сәнгати сөйләм чарасы буларак, алар жанр үзенчәлекләреннән һәм әсәрнең эчтәлегеннән чыгып, төрле фунция башкара. Әлеге чаралар ярдәмендә авторның төрле кичерешләре бирелә, чынбарлыктағы вакыйгаларга мөнәсәбәте белдерелә, әсәрдә образлылык көчәйтеп күрсәтелә. Аеруча риторик сораулар аша шагыйрьләр үзләренең дөньяга карашлары, җәмгыять, кешелек турында үзләрен борчыган фикер-сораулары белән

уртаклаша, «теге дөнья» хакында уйланып борчыла. Бу алымга суфи шагыйрьләр еш мөрәҗәгать итә, шушы стилистик чара ярдәмендә алар үзләренең уй-кичерешләрен генә җиткереп калмыйлар, ә укучы белән лирик герой герой арасында җылы мөнәсәбәт урнаштыралар, аны да уйланырга этәрәләр: *Монда ғыйззәт үкүш күрдек, / Анда хәлемез нә ула?* [3: 25]. *Килдек – дөнйадин китәсе,/ Фәсад эшләрне нитәсе?* [5: 125]. *Җөрм-у-ғысйан әйләде чуķ , нәйләйүр йәүме-л-хисаб?* [2: 30].

XVII–XVIII гасырларда иҗат иткән шагыйрьләрдән Габди заманага кагылышлы фикерләрен, чордашларының укымышлы кешеләргә, галимнәргә карата булган мөнәсәбәтләре турындагы уйлануларын, күңеленнән ургылып чыккан борчуларын көчле тойгыга уралган риторик сорау аша җиткерә: *Ғалимләрнең хәлен сорғыл / Адинәдә һәрбер айда. / Хәлен сорап хәйер иткән, / Бу заманда – монда кайда?!* [3: 23].

Автор уйланып, үз эш-гамәлләренең максат-ниятен, барасы юлларын белергә, киләчәген күзалларга теләгәндәй үз-үзе белән сөйләшкән рәвештә дә риторик сорауны кулланырга мөмкин. Лирик герой шул рәвешчә үзенең чуалган фикерләрен тәртипкә сала, укучыны да битараф булмаска, киләчәге турында уйланырга өнди: *Шуны күреп бу күңелем ни теләр, / Бу дөнйада бармы миндәй биһөнәр?* [5: 134]. *Мәндан ата баласы, вафат аға-атасы, / Һәм үтептер анасы, ғыйбрәт кайдин аласы?* [5: 126].

Риторик сорауларда гадәттә заман таләпләренә кагылышлы мөһим мәсьәләләргә игътибар ителә, сораулар шәхескә яки объектка эндәшү, мөрәҗәгать итү рәвешендә бер-бер артлы куеп барылырга да мөмкин. Мәсәлән, Габдерәхим Утыз Имәни үзенең иҗатында риторик сорау кебек стилистик алымга еш мөрәҗәгать итә, әлеге чара ярдәмендә киләчәге, үткән тормышы турындагы уйлары белән уртаклаша. Риторик сорауларның бер-бер арты төзелеп килүе шагыйрьнең үткәне өчен үкенү, аны сагыну, хәтта төшенкелеккә бирелү кебек хис-тойгыларын тагын да көчәйтеп чагылдыра: *Ķәни ул фәрх-ү-сәйран итдеки көн, / Мәгаше хуш эчендә үтдеки көн? / Ķәни ул чуķ тәнәггым, шади дилләр? / Ķәни ул дошманы юк сафи хальләр? / Ķәни ул дил фәрағ мөстәķбәлемдин, / Замане халь дәхи мазый көнемдин? Ķәни ул хане-сөхбәт иртә wә кич?..* [2: 73]. Шагыйрьнең шигырьләрендә үзенең үткәне өчен генә түгел, ә замандашлары өчен дә борчыла. Мәсәлән, автор чордашы Суфи Аллаһияр хакындагы уйллануларын «бу җиһаннан җир астына китеп баргач» та «хисап көнендә» ничек җавап бирер дип борчылып, фикерен риторик сорау ярдәмендә җиткерә: *Җөрм-у-ғыйсйан әйләде чуķ, нәйләйүр йәүме-л-хисаб?* [2: 30].

Риторик сорау еш кына авторның сөйгән ярына хис-тойгыларын, мәхәббәтен белдерү, шулай ук шагыйрьнең серле уйлануларын аңлату, лирик геройның үз хис-кичерешләренең сәбәбен аңларга тырышу максатыннан да әсәр тукымасына килеп керергә мөмкин. Мәсәлән, әлеге очракта авторның хискә-хыялга бирелүе, үзенең бу халәтенә күпмедер дәрәҗәдә аптыраошта калуы да чагылыш таба: *Хилафдин чығубән йөредем иртә, Кем билеңдин ķочтым төн уртасында?* [1: 66]. *Кичләрдә даим бәнем уйķу килмәз күземә, / Йимәк-эчмәк арзу ķылмаз – ни улды бәнем үземә?* [1: 69].

Шулай ук тезмә әсәрләрдә лирик геройның хис-кичерешләре риторик сорау җөмләләр ярдәмендә генә түгел, ә көчле тойгы белән әйтелеп, өндәү җөмләләр аша да җиткерелергә мөмкин: *Ғазраил үлем кәдәхдин тотып*

*торыр, – / Кизү тигәр: шул кәдәхдин эчәрбез, аһ!* [6: 34]. *Килер безгә қыл-дин нечкә сират күпрек, / Ни хәл белән шул сиратдин кучәрбез, аһ!* [6: 34]. Мисалларда күренгәнчә, лирик геройны уйга салган сораулар, киләчәге өчен курку, сират күперен үтә алмавы өчен борчылу, уфтану, гаҗизлек һ. б. шагыйрьнең күңеленнән ниндидер бер хис ташкыны булып ургылып чыга. Биредә *аһ* кисәкчәсенең дә кулланылуы бу хисләрнең бирелешен тагын да көчәйтә, укучыныэң күңленә үтеп керү, аңа тәэсир итү көчен арттыра, әсәрнең теленә теленә җан өрә.

Түбәндәге очракта авторның Аллаһ белән сөйләшүен, аңа мөрәҗәгатен риторик өндәү ярдәмендә җиткерү әсәрне эмоциональ-экспрессив төсмер-ләр белән баета. Һәм мондый җөмләләрнең һәрбер куплет ахырында ка-батланып баруы касыйдәнең үзенә бер стилен булдыра, максатын аерып күрсәтә, аның көчле интонация белән укылырга тиешлегенә басым ясый: *Сән шәфәгать әйләгел бу / Мөбтәлайә, йа шәфиг!* [7: 31]. *Син мәдәд әйлә бу мескин / Мөбтәлайә, йа шәфиг* [7: 33].

Гомумән, суфи шагыйрьләр иҗатында Аллаһка мөрәҗәгать, ялвару вакытында риторик өндәү яки сорауны стилистик чара буларак куллану киң таралган күренеш булып тора. Биредә риторик өндәүгә теләк төсмер-ләре дә өстә: *Хак Тәгалә ләтыйф белән / Озын гомер вирсәйде!* [1: 55].

Авторны яисә персонажны борчыган сорау көчле тойгы белән, кискен хисләргә уралып әйтелгән очраклар да, сирәк булса да, күзәтелә. Бу аеруча суфи шагыйрь Габди иҗатында еш күзәтелә. Шагыйрь ялкынланып укучы-га мөрәҗәгать итә, күңелендә туган хис-кичерешләрен көчле тойгы белән җиткерә. Бу очракта риторик сорау җөмләләргә өндәү билгесе дә өстәлә: *Хәлен сора хәйер иткән, / Бу заманда – монда қайда?!* [3: 23].

Шул рәвешчә, язма истәлекләрдә риторик сорау җөмләләрнең күбрәк урын алуын, шагыйрьләр тарафыннан яратып кулланыла торган, киң таралган, стилистик чара булуын искәртергә кирәк. Аеруча суфи ша-гыйрьләр, мәсәлән, Мәүлә Колый, Габдессәлам дөньяви яшәешкә, дөрес яшәүгә, яки гөнаһлы үткәнгә бәйле уйлану, үкенү-борчылуларын, шулай ук сөйгән ярга бәйле хисләрен укучыга үтемле итеп җиткерү, чордашла-рын үз чоры, киләчәге, дөрес яшәве турында уйланырга этәрү максатын-нан риторик сорау һәм риторик өндәү кебек чараларны киң куллана. Го-мумән, XVII–XVIII гасыр иске татар әдәбиятында авторның чынбарлыкка мөнәсәбәтен, тирән кичерешләрен чагылдыруда, тормыш-көнкүрешне сурәтләүдә риторик сорау һәм өндәү җөмләләр зур роль уйный.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Габдессәлам // XVIII гасыр әдәбияты. Поэзия. Казан: Дом печати, 2006. Б. 41–73.

2. *Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари.* Шигырьләр, поэмалар / төз. Ә. Шәрипов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 397 б.

3. Габди // XVIII гасыр әдәбияты. Поэзия. Казан: Дом печати, 2006. Б. 41–73.

4. *Голуб И.Б., Стародубец С.Н.* Стилистика русского языка и культура речи. М.: Юрайт, 2023. 456 с.

5. Мөслимов Габделмәннан // XVIII гасыр әдәбияты. Поэзия. Казан: Дом печати, 2006. Б. 41–73.

6. *Мәүлә Колый.* Хикмәтләр. Казан: Иман, 2001. 135 б.

7. Тайсугани Габдерахман бине Туймөхәммәд // XVIII гасыр әдәбияты. Поэзия. Казан: Дом печати. Б. 31–40.

УДК94(470.41)

# КУЛЬТУРА ПИТАНИЯ ТАТАР РУБЕЖА XIX–XX ВВ. В ТРУДАХ КАЮМА НАСЫРИ

***Л.Р. Габдрафикова***
*Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ (Казань)*

В публикации анализируется культура питания городских татар рубежа XIX–XX вв. В качестве источника выбраны труды Каюма Насыри по этой теме: исследование по этнографии казанских татар и кулинарная книга. Автор выделяет, что эти работы были рассчитаны на разного читателя: «внешнего» и «внутреннего». Труды К. Насыри сыграли большую роль в формировании новой татарской кухни рубежа XIX–XX вв.
**Ключевые слова:** история повседневности, татарская кухня, история татар, Казань, кулинарные книги.

The publication analyzes the food culture of urban Tatars at the turn of the 19th–20th centuries. The sources of the study are a work on the ethnography of the Kazan Tatars and a cookbook by Kayum Nasyri. These works were intended for different readers: “external” and “internal”. The works of Kayum Nasyri became the basis for the new Tatar cuisine at the turn of the 19th-20th centuries.
**Keywords:** history of everyday life, Tatar cuisine, history of Tatars, Kazan, cookbooks.

Каюм Насыри отличался многогранностью творчества, живым интересом к новшествам своего времени. Являясь преподавателем миссионерского учебного заведения, среди волго-уральских мусульман он был одним из первых адептов европейской культуры, и на протяжении всей жизни ему приходилось выслушивать негативные оценки единоверцев, не понимавших ни его мотивов, ни образа жизни, ни сферы профессиональной реализации. Тем не менее, К. Насыри с завидным энтузиазмом и преданностью делу просвещения, продолжал свою деятельность. Его труды различной направленности: по медицине, педагогике и другим областям знаний, изданные отдельными брошюрами, а также на страницах его татарских календарей в конце XIX в., представляют несомненный интерес для раскрытия отдельных сфер повседневности татар того времени [1].

Еще одним из направлений деятельности К. Насыри было внимание к культуре питания. Эти записи и публикации являются важными источниками для изучения повседневности татар рубежа XIX–XX вв. Однако при обращении к этим трудам нужно учитывать и исторический контекст, и цели их создания.

Во-первых, вопросов пищи татар ученый касался в этнографических исследованиях. Данная работа была ориентирована, скорее, на «внешнего» читателя, однако при его жизни она не была опубликована. «Материалы по татарской этнографии», в итоге, увидели свет только в 1926 г. в сборнике «Неопубликованные произведения Каюма Насыри» («Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре»). Книга была издана по случаю 100-летия ученого, которое прошло накануне. Материал к печати

подготовили Гали Рахим и Галимджан Ибрагимов [2: 252]. Впоследствии фрагменты этого труда использовались и в работе Н.И. Воробьева о казанских татарах [3], и в коллективном труде по истории татар Среднего Поволжья и Приуралья [4]. В этих материалах были зафиксированы наблюдения К. Насыри по повседневной культуре питания татар его эпохи, т. е. второй половины XIX в.

Здесь обозначены многие традиционные блюда. Главными составляющими («самой необходимой пищей») татарской кухни К. Насыри называет хлеб (муку), мясо и бульон *(икмәк, ит, шурпа).* Все остальное – это уже вариации на этой базе. Ориентиром для этнографического описания для него выступали состоятельные семейства. В таких домах имелся следующий продуктовый набор для приготовления пищи: мясо, масло, вода, соль, рис, крупа, мука, ягоды, мясо птицы (гусь, утка, курица), яблоки, яйца, морковь, тыква. Интересно, что К. Насыри выделял просто мясо (говядина, баранина, конина) и мясо птицы. Кроме того, он подчеркивал, что татары «из рыбы готовят очень мало». Есть у него и свое деление круп – рис и остальные крупы. На наш взгляд, это указывало и на наиболее частое употребление риса, по крайней мере, в семьях состоятельных татар. Как самые повседневные блюда, из указанных выше продуктов, К. Насыри выделял вареное мясо и бульоны с различными видами лапши *(салма, токмач),* а также пельмени. Более праздничной едой считался плов, причем он выделял два его вида. Если «сартский плов» *(сарт пылавы)* напоминал традиционный плов, когда мясо сразу жарили в казане, то казанский вариант *(казан халкының пылавы)* готовился немного иначе. Мясо сначала отваривали и лишь потом жарили в казане с морковью и луком, а потом добавляли рис, изюм и оставляли томиться на несколько часов. Информация об этих блюдах даны максимально кратко, т. к., по словам К. Насыри, «они известны каждому» [5: 239].

Вероятно, именно эти обозначенные выше блюда входили и в его повседневный рацион. Так его двоюродный племянник А. Хусаинов вспоминал, что К. Насыри хорошо готовил плов, «шакирдскую лапшу» и кулламу [6: 505].

Также в этнографических записках ученого встречаются описания таких традиционных блюд как балеш *(бәлеш)* и губадия *(гөбәдия).* Но они немного отличаются от современных вариаций. Так, основными компонентами балеша К. Насыри указывает тесто, мясо и рис, что можно объяснить с еще незначительным распространением картофеля в татарской среде в середине XIX в. Губадия тоже готовилась с мясом. Помимо мяса добавлялся еще *корт*, мелко порубленные сваренные яйца и масло.

Кроме этих блюд, К. Насыри отмечает также фаршированную рисом утку, а также круглые и полукруглые пироги с различными начинками (с рисом и тыквой, морковью, яйцами). Их он называет *бөккән* (букен), они были как печеные, так и жареные. Последний вариант обозначен еще словом «самса» [5: 240].

В качестве сладкого блюда просветитель приводил балеш с яблоком *(алма бәлеше)* с добавлением сахара. Вероятно, эти блюда являются уже более поздними. Они иллюстрируют и частое употребление татарами

в печеном виде овощей, и более широкое применение сахара. Паштеты-пироги из ягодной или яблочной пастилы, упоминаемые К. Насыри, тоже своим названием отсылают к новому времени, когда в русском языке было в употреблении название слоенных мясных пирогов (paste), завезенных иностранцами-немцами и французами. Постепенно слово «паштет» начали применять только по отношению к начинкам таких пирогов, однако в татарской культуре паштет стал названием сладких пирогов. Помимо этого, из татарских десертов К. Насыри называет мучные блюда: *как-төш* или *бавырсак* с медом, а также *кош теле*. Первое блюдо по размеру напоминал современный вариант чак-чака – «не больше кедрового ореха» *(эрбет чикләвегеннән артык зур булмый)* [5: 241].

Второй труд К. Насыри о культуре питания – это «Иршад-әл-әтбиха ила истихзар әл-әтгамә» 1893 г. Название этой книги переводили на русский язык и как «Наука о приготовлении различной пищи» [7: 15], а также «Правило приготовления пищи» *(«Ашамлык әзерләү буенча кагыйдә»)* [2: 171] и «Наставления повару» [8]. Сюда он включил 87 рецептов. Этот кулинарный труд можно обозначить как познавательную книгу для «внутреннего» читателя. Она носила просветительский характер и знакомила татар, прежде всего, с новыми блюдами. Кроме того, его можно считать попыткой просветителя нивелировать социально-культурные границы между разными слоями общества: например, купеческой кухней и крестьянской, русской и татарской, и т. д. Поэтому, этот труд нельзя воспринимать исключительно как иллюстрацию татарской повседневности рубежа XIX–XX вв. Это скорее образ будущей культуры питания татар, устремлений образованной части татарского сообщества к новшествам, в том числе в питании. К. Насыри стремился переосмыслить привычный быт и ввести новое понимание пользы ряда продуктов питания или их вреда. Например, «самое лучшее – совмещать мясо и овощи», – писал он. Кроме того, он советовал делать перерывы между приемами пищи от четырех до пяти часов [1: 92]. Также ученый рассуждал о сбалансированном рационе и калорийности пищи. К. Насыри подчеркивал, что еда имеет большое значение для здоровья человека, поэтому должна соответствовать степени тяжести выполняемой работы, т. к. злоупотребление едой вредно отражается на самочувствии [9: 112].

Эту же работу по просвещению читателей и знакомству с новыми блюдами он проводил и с помощью своих календарей, где тоже печатались и разные рецепты. Например, в календаре 1888 г. им был помещен рецепт изготовления пастилы и варенья из яблок и рябины [2: 221]. Кстати, и для собственного пользования просветитель готовил своеобразное «варенье» из шиповника. По словам его племянника, он собирал эти плоды в лесу, а потом смешивал с сахаром и хранил в стеклянной банке. Называл он эту сладкую смесь «вареньем» и угощал ею в зимнее время лишь своих дорогих гостей [6: 507]. Книга «Наставления повару» отражает частный мир лишь небольшой прослойки татарского сообщества. В основном, это были городские жители, находившиеся, иногда вынужденно, в культурном пограничье. Это было характерно и для повседневности самого К. Насыри. Например, один из его знакомых вспоминал, что в Казани он ел обычно в харчевне, а чай пил у себя дома [6: 495]. Неслучайно и в его кулинарной

книге периодически встречались примечания вроде «русский плов», «русское блюдо» и т. д. Тут можно увидеть такие традиционные блюда русской кухни – щи, борщ, солянка, рассольник, свекольник и другие супы. К. Насыри знакомил татарского читателя с непривычными для него блюдами и пытался таким образом адаптировать новые рецепты в татарской среде. Новые рецепты требовали расширения и кухонного инвентаря. Так, в некоторых случаях К. Насыри рекомендует читателям уже другую посуду (например, медную кастрюлю вместо казана).

Кулинарный труд К. Насыри предлагал также много жареных блюд из мяса (в их числе различные котлеты), а также соусы, десерты, напитки (кисель, квас, компот и т. д.). Есть в жареном виде он рекомендовал и картофель – имелись рецепты картофельных оладий и котлет [8: 20, 27]. Все это можно связать с развитием городского общепита и влиянием на татарский быт ресторанов, трактиров (в том числе харчевень) и других мест общественного питания.

Книга К. Насыри является также иллюстрацией все большего проникновения в быт городских татар сахара: 23 рецепта из 87 – это различные лакомства с сахаром (варенья, пудинги, печенья, цукаты и другие десерты). Сахар добавлялся и в различные рецепты яблочных пирогов, компоты и сиропы.

Кроме элементов русской кухни в работе К. Насыри можно усмотреть и османское влияние. Например, жареные мясные блюда он называет именно характерными для османской культуры питания обозначениями (кебаб, кёфте, хариса). При этом они не всегда соответствуют османскому аналогу. Например, при обозначении фруктового варенья К. Насыри употреблял и слово арабского происхождения мурраба *(мөрәбба)*, а компотов – *хушаб* [8: 24, 39]. При этом *хушаф* – это молочный напиток с финиками, т. е. К. Насыри в этом отношении создавал собственные смыслы на пограничье разных культур. Также он называет *һәрисә* (хариса) блюда напоминавшее по технологии приготовления котлеты. А вот на территории бывшей Османской империи под блюдом хариса понимают кашу с мясом. Любопытно, что в более поздних татарских кулинарных книгах («Ашсу остасы» 1909 г.) котлеты обозначены как *кәтлит*. Кроме того, тексты К. Насыри говорят и о том, что в татарской повседневности не были широко распространены жареные блюда, поэтому в качестве глагола жарить он часто писал *кебаб ит*, *кебаб кыл* [8: 18, 27].

Обращает на себя внимание, что в кулинарной книге довольно много блюд из риса. Помимо похлебок с рисом *(өйрә),* молочного супа с рисом, фаршированной рисом индейки просветитель приводит 12 рецептов плова. Кроме классических варинатов плова, в том числе с сухофруктами, это различные вариации риса с овощами (например, с баклажанами). Гораздо меньше блюд, где основной компонент – картофель. Иногда автор предлагал картофель к жареному мясу в качестве гарнира.

В данной работе К. Насыри важны и такие детали повседневности, как элементы интерьера и кухонный инвентарь татарского дома второй половины XIX в. Например, практически каждый рецепт просветителя заканчивается рекомендацией «поставь на дастархан». Здесь мы видим, что в татарской лексике еще нет слова «стол» (өстәл). Очевидно, и автор

кулинарной книги имел ввиду скатерть или сервированное место на сяке. В этом направлении «Наставления повару» можно анализировать и дальше.

Безусловно, труд К. Насыри оказал влияние на дальнейшее становление татарской кухни. Измения в культуре питания городских татар к началу XX в. были довольно ощутимыми [10: 74–95]. Кулинарная книга К. Насыри 1893 г. была переиздана второй раз в 1901 г. при материальной поддержке Исмагила Шамсетдинова [2: 172]. Этот интерес к новым блюдам нашел отражение и в татарских календарях начала XX в. (например, Ф. Халиди), и в татарской периодической печати (журналы «Иктисад», «Сөембикә» и т. д.), а также в отдельной кулинарной книге «Аш-су остасы» Фаузии Ибрагимовой 1909 г. Последняя книга переиздавалась еще раз. Конечно, применялись новые рецепты в большей степени в городской среде, где был доступ и к различным ингредиентам, и к разнообразной посуде, а самое главное готовность к кулинарным экспериментам. Неслучайно этнограф Н.И. Воробьев в конце 1920-х гг. замечал, что «лучше, конечно, готовят горожанки, а затем крестьянки Заказанья и это, по-видимому, является также следствием длительного влияния на этот район городской культуры» [3: 145]. Просветитель Каюм Насыри со своей книгой о правилах приготовления пищи был, безусловно, первопроходцем этого движения к новой татарской кухне рубежа XIX–XX вв.

## СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1. *Насыйри К.* Сайланма әсәрләр. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 318 б.

2. Каюм Насыйри: иллюстрацияле персональ энциклопедия / төз.-авт. Р.В. Шайдуллин һ. б. Казан: ТЭТӨИ, 2025. 500 б.

3. *Воробьев Н.И.* Материальная культура казанских татар (Опыт этнографич. исследования). Казань: Дом татарской культуры и Академический центр ТНКП, 1930. 464 с.

4. Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М.: Наука, 1967. 540 с.

5. *Насыйри К.* Сайланма әсәрләр. Т. 3. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 384 б.

6. Каюм Насыри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / төз. Р.Ф. Исламов. Казан: Җыен, 2017. 816 б.

7. *Гайнуллин М.Х.* Каюм Насыри. Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. 47 с.

8. *Насыйри К.* Иршад-әл-Әтбиха. Казан: Икътисад, идарә һәм хокук институтының «Познание» нәшрияты, 2015. 48 б.

9. *Мухамедьяров Ф.Г.* Каюм Насыри как популяризатор медико-санитарных знаний среди татар // Каюм Насыри. Материалы науч. сессий, посвящ. 120-летию со дня рождения. – Казань, 1948. – С. 109–115.

10. *Габдрафикова Л.* Татарское буржуазное общество: стиль жизни в эпоху перемен» (вторая половина XIX – начало XX века). Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 367 с.

УДК 821.512.145

# ТЕМА ВОЙНЫ В ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ 1960–1980-х ГОДОВ: ПРОБЛЕМАТИКА И ПОЭТИКА

***Ф.И. Габидуллина***
*Елабужский институт КФУ (Елабуга)*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению Кабинета Министров РТ № 565 от 16.07.2024*

В статье рассматриваются особенности отражения темы войны в татарской литературе 1960–1980-х годов. В центре внимания автора находятся вопросы проблематики и поэтики. В этом аспекте анализируются и оцениваются произведения М. Магдеева, М. Юнуса, А. Гилязова. Качественные изменения в них выражается в философском подходе к военным ситуациям, в концепции героя, в раскрытии понятия героизма, в отражении войны в реальных ее проявлениях.
**Ключевые слова:** татарская литература, новое осмысление войны, конфликт, герой, поэтика.

The article examines the peculiarities of reflecting the theme of war in the Tatar literature of the 1960s and 80s. The author focuses on issues of problematics and poetics. For this purpose, the works of M. Magdeev, M. Yunus, and A. Gilyazov are analyzed and evaluated. Qualitative changes in them are expressed in the philosophical approach to military situations, in the concept of a hero, in the disclosure of the concept of heroism, in the reflection of war in its real manifestations.
**Keywords:** Tatar literature, new understanding of war, conflict, hero, poetics.

# 1960–1980 ЕЛЛАР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА СУГЫШ ТЕМАСЫ: ПРОБЛЕМАТИКА ҺӘМ ПОЭТИКА

***Ф.И. Габидуллина***
*КФУның Алабуга институты (Алабуга)*

XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятында сугыш темасы иң актуальләрдән саналып, әлеге гаять катлаулы мәсьәләне әдәби сурәтләүдә ул берничә этап аша үтә. Бөек Ватан сугышы елларында әдәбиятта ил-халыкны көрәшкә чакыру, ватанны саклау, фашизмга нәфрәт, фронттагы солдат язмышы, җиңүгә ышаныч кебек темалар өстенлек итеп, әдипләр нигездә солдат батырлыгы, хезмәт фидакарьлеге мисалларына мөрәҗәгать итәләр. Шуның белән ватанны сакларга ант итү, азатлык сугышына чакыру, дошманга нәфрәт, хезмәт фронтында җиңүгә өлеш кертүнең һәркем алдындагы изге бурыч булуын укучыга җиткерәләр. Сугыштан соңгы елларда исә тема-мотивлар киңәя төшә. Язучылар фронт хәлләрен һәм тылдагы тормышны сурәтләгәндә геройларның күңел халәтен, уй-фикерләрен ачуга игътибарны арттыралар, «батырлыкның чыганакларын эзләү белән кызыксыналар» [5: 99], фронт һәм тыл бердәмлеген, дошман әсирлегендәге михнәтләрне тасвирлыйлар. Ә инде 1960–1980 елларда сугыш темасын

чагылдыруда җитди сыйфат үзгәрешләре күзәтелә. Мәкаләдә әлеге чор әдәбиятында урын алган сугыш турындагы әсәрләрне идея-проблематика һәм сәнгатьчә эшләнеш ягыннан тикшереп бәяләү максат итеп куела. Шуннан чыгып, әлеге еллар әдәбияты үзенчәлекләре, фронт һәм тыл хәлләрен сәнгатьчә ачу, геройлык күренешләрен бәяләү, авторлар файдаланган алымнар кебек мәсьәләләр тикшерелә.

Прозада бу темага Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Ә. Еники, А. Расих, Г. Галиев, Х. Камалов, И. Гази һ. б. күпләр мөрәҗәгать итә, без исә тикшеренү объекты итеп М. Мәһдиев, М. Юныс, А. Гыйләҗев әсәрләрен алдык. Аларда сугыш темасын сурәтләүгә яңа яктан килү омтылышы, яңа герой типлары һәм сәнгать чаралары төрлелеге күзәтелә.

Татар әдәбиятының 1960–1980 еллардагы үсеш-үзгәреше илленче еллар ахырында җәмгыятьтә урын алган «Хрущев җепшеклеге» күренеше белән тыгыз бәйле булып, «әдәби процесс катлаулы, каршылыклы булуы белән характерлана» [1: 218]. Белгәнебезчә, Сталинның «шәхес культы» фаш ителгәннән соң, илдә билгеле бер демократик үзгәрешләр башлана, сүз һәм матбугат ирекге күзәтелә, ил җитәкчелегенең үткәндәге сәясәте тәнкыйтьләнә, гаепсез хөкем ителгәннәр аклана. Болар исә әдипләрне яшәеш хакыйкатен эзләүгә, үткәндәге һәм бүгенге вакыйгаларны гаделлек төшенчәсенә нисбәтле тасвирлауга этәрә. Әдәбиятта, Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, милли нигезләргә кайту, яшәеш кыйммәтләрен туган җир, халык яшәеше, традицияләр бәйләнешендә бәяләүгә китерә. Әдәби барыш җитди үзгәрешләр юлына чыга һәм анда тәнкыйди, лирик-психологик, фәлсәфи юнәлешләрдә эзләнүләр башлана [3: 368]. Социалистик реализм иҗат методы үзенең башлангыч формадагы эчтәлеген югалта һәм «кешегә йөз белән борылу» дип аталган формага килә. Ул исә, тарихилык һәм реальлек принципларын саклаган хәлдә, кеше шәхесен алгы планга чыгару, аны билгеле бер милләт вәкиле итеп, һәрнәрсәгә үз карашы булган шәхес итеп чагылдыруны яклый.

Әдәби барышта күзәтелгән яңалыклар сугышка бәйле вакыйгаларны сурәтләүдә дә җитди үзгәрешләргә китерә. Бу турыда сүз алып барырга мөмкинлек биргән әсәрләрне иҗат итүчеләрнең берсе – М. Мәһдиев. Аның «Без – 41 ел балалары» (1968), «Фронтовиклар» (1970), «Ут чәчәге» (1980), «Бәхилләшү» (1988) кебек повесть-романнарын белмәгән татар кешесе юктыр. Әдип үзе сугышта булмаган, әмма яшьлеге сугыш елларына туры килүе, гомере буе сугыш афәтен күргән авылдашлары белән аралашып яшәве, аңа тыл тормышын, элекке солдатлар язмышын, кабатланмас геройларны мәйданга чыгару мөмкинлеге бирә. «Без – 41 ел балалары» повесте сугыш чорында Арча педагогика училищесында укучы малайлар турында булып, сурәтләнгән һәр күренеш сугыш сөреме, аның ерак тылга килеп җиткән кайтавазы белән сугарылган. Ф. Миңнуллин язганча, «яшь аралаш көлеп язылган, көлке белән фаҗига чиратлашкан, якты моң белән сугарылган әсәр» [6: 220]. Повестьтагы Әлтафи, Әркәшә кебек малайлар яисә Хәлил абый, Исмәгыйль абый кебек укытучылар – һәрберсе үз йөзе белән аерылып торган һәм үз чорының бөтенлекле образын күз алдына бастырырга ярдәм иткән образлар. Гомумән, «...моңсу-лирик, матур тел-сөйләме һәм эмоциональ тәэсирлелеге белән шигърияткә тартым, тормыш-яшәештәге асыл кыйммәтләрне барлауга йөз тоткан гаять үзенчәлекле текст хасил

була» [4: 48–49]. М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы сугыш утын үтүчеләргә үзгә бер якын мөнәсәбәт, аларны ярату, хөрмәт итү, гади һәм гадәтилекләре алдында баш ию рухы белән язылган. Бу әсәр геройлары Рушад, Гата турында укып, күпсанлы яшьләрнең укытучы һөнәрен сайлавына шикләнмәскә мөмкин. Автор бер деталь, бер күренеш аша героеның иң мөһим сыйфатларын ачу осталыгын күрсәтә. Матур, сурәтле һәм афоризмнарга бай теле белән ул укучыны үзеннән җибәрми, геройлары язмышы белән яшәргә мәҗбүр итә. Әдипнең «Кеше китә – җыры кала»сында Тимерхан, «Ут чәчәге»ндәге Асаф Рәимов кебек геройлары да фронттагы ут-суларны кичкән чын ир-егетләр итеп бирелә. Ә инде аларның дәвамчысы – «Бәхилләшү» повестендагы Исламгали, зур булмаган штрихлар аша бирелсә дә, кабатланмас шәхес буларак күз алдына баса. «Әлеге сугыш батыры – чын мәгънәсендә милли образ. Татар халкына хас булган сабырлык, рухи ныклык кебек сыйфатларны Ходай Тәгалә аңа мулдан биргән. Ике кулын сугышта калдырып кайткан, төннәрен сызланып интегүче Исламгали агайга капка төбенә җыелган күршеләренә мәзәк хәлләр генә сөйләү нинди кыенлык белән бирелүен үзе дә хатыны гына белә. Шуңа да ул безне үзенең оптимизмы, яшәү көче, горурлыгы белән сокландыра» [2: 319].

Сугыш чоры татар авылын кешенең уй-фикере, хис-кичереше, җан хәрәкәте аша сурәтләгән әсәрләрнең берсе булып А. Гыйләҗевның «Язгы кәрваннәр» (1972) повесте тора. Автор әлеге афәткә беренче чиратта балалар һәм яшүсмерләр тормышы аша карый. Авыр тормыш шартлары, ачлык, иртә таңнан кичке караңгыга кадәр авыр физик хезмәт төшә алар җилкәсенә. Кешеләр кичергән михнәт-җәфаларга җан әрни, күңел сыкрана. Шулай да әлеге вакыйгалар катламы кеше күңелен, рухи көчен ачуга фон гына булып хезмәт итә. Автор сугыш чоры яшүсмерләренең гаҗәеп матур, үзенчәлекле образларын тудыра. Әйе, авырлыклар һәр өйдә тулып ята: сугыш борчуы, тамак кайгысы, ятимлек һ. б. Бу аларны бер-берсенә якынайта. Шул ук вакытта һәрберсе үз йөзе, җан хәрәкәте белән ачыла. Бу яктан Ибраһим һәм Әдилә образлары аерылып тора. Автор үзенең геройларын, беренче чиратта, әхлак сафлыгы, кешелеклелек, намус, гаделлек белән сыный. Шуңа да әлеге сыйфатларны үзләрендә тәрбияләгән геройларның мәхәббәте дә сокландыра. Текстта бу бөек хис гадәти тормыш вакыйгаларында бирелә, әмма алардагы ихласлык, күңел җылылыгы, бер-берсенә булган беренче, саф хисләрнең самимилеге, сафлыгы укучының да җанын биләп ала. «Ибраһим, Дамир һәм Әдилә мисалында кешедәге әхлакый сыйфатларның алдагы буыннардан килә торган кыйммәтләр һәм идеаллар нигезендә формалашуын күрсәтә. Тик моның өчен шәхес алдагы буыннарның рухи кыйммәтләрен үзе теләп үзләштерергә тиеш. Буыннар «кәрванының» нигезе исә, автор фикеренчә, – милли рухи мәдәниятебез. А. Гыйләҗев бу әсәрендә кәрвандагы һәр кешенең уникальлеген, кабатланмаслыгын, кыйммәтен күрсәтә алган» [9: 170]. Повесть чор образын, шул шартларда кешелек сыйфатын югары күтәргән заман типларын чагылдыруы белән сугыш чоры татар авылы турындагы иң яхшы әсәрләрдән санала.

1960–1980 еллар татар әдәбиятында, сугыш вакыйгаларын үз эченә алып, аны тарихи-фәлсәфи яссылыкта бәяләүгә китергән авторлар булып Х. Камалов һәм М. Юныс тора. Сугыштан авыр яралар белән кайткан Х. Камалов «Һәркемнең гомере бер генә» (1975) романы белән татар

әдәбиятында сугышны яңача – кырыс реализм ноктасыннан карап, бөтен авырлык-михнәтләре, үлем-фаҗигалары белән сурәтләүне башлап җибәрә. Бу яктан ул рус әдәбиятында киң яңгыраш алган «лейтенант прозасы» рухында булуы һәм Ю. Бондаревның «Батальоны просят огня», «Последние залпы», Г. Баклановның «Пядь земли», «Июль 41 года», К. Воробьевның «Это мы, Господи!», «Убиты под Москвой» кебек әсәрләре белән аваздашлыгы, типологик охшашлыгы ягыннан киң яңгыраш алды. Әдип алдагы елларда «Безне өйдә көтәләр» (1982), «Үлгәннәм соң яздым» (1989) романнарын иҗат итеп, ачы сугыш фаҗигасын чагылдырган трилогия бастырып чыгара. Бу әсәрләр татар әдипләренең йөз аклыгы, әдәбиятыбызның зурлыгы һәм сугыш ветераннары алдындагы изге бурычны үтәү чагылышы булып тарихта калды.

М. Юнысның бөтен иҗатын туган якка, туган җиргә, халыкка, табигатькә, гореф-гадәтләргә җылы мөнәсәбәт хисе иңләп. Чит илләр, җирләр, андагы халык тормышы турында язарга яратучы әдип иҗатында «Биектә калу» («Шәмдәлләрдә генә утлар яна...», 1981) повесте үзгә урын алып тора. Сугыш темасына язылган әсәрләр арасында иң уңышлыларының берсе ул. Автор сугыш вакыйгаларын һәм тыл тормышын сурәтләү аша яшәү һәм үлем, мәхәббәт һәм нәфрәт турында гаять гыйбрәтле, фәлсәфи эчтәлекле итеп яза. «Ул – барыннан да бигрәк фәлсәфи тирәнлеге, эмоциональ тәэсир көченең зурлыгы белән аерылып тора» [7: 330]. Әсәрнең сюжеты Бөек Ватан сугышы бетәргә бик аз калганлыкны хәбәр итүдән башлана. Солдатларның, туган якларына кайтып, сөйгәннәре белән кушыласы, җиңү шатлыгын алар белән бергә уртаклашасы килә. Әлеге теләк-омтылышлары шулкадәр көчле, укучы күңелендә аның тормышка ашачагына шик туа. Сәйрин экипажы соңгы сугышта, рухи биеклек үрнәге күрсәтеп, һәлак була. Төп герой Сәйрин Сәләхов – авыл егете, ул бөтен барлыгы белән татар кешесенә хас сыйфатларда ачыла. Гаять тырыш, булдыклы, максатчан һәм ышанычлы егетне барысы да хөрмәт итә. Автор беренчеләрдән булып илдә рус булмаган халыкларга үзгә караш булуны, моның хәтта сугыш шартларында да ачык чагылуын әрнеп сурәтли. Татар егете Сәйрин Сәләхов, якут егете Максим Майнагышев, кырым татары Марсель Ялчинский кебекләргә булган караш, хәтта аларның үлеме дә әлеге сәясәтнең бер чагылышы булып тора. Вакыйга-күренешләрдә Сәйриннең кешелеклелек, миһербанлылык сыйфатлары аеруча киң ачыла. Болар аңа туган җиреннән, туган анасыннан килә. Кешеләр өчен яшәүне сайлаган егет, дуслары белән бергә, самолетта шартлап һәлак була. Әсәрнең бөтен геройлары да рухи биеклек ноктасыннан бәяләнә. Сөйгәне, кешеләр өчен яшәгән Разыя, баласы өчен соңгы онын саклаган ана, аның исәнлегенә дога укыган авылдашлары, һөҗүмгә барган дуслары – барысы да рухи биеклек үрнәге күрсәтә. Әсәрдә аерым милләтләр, бигрәк тә азчылык саналган халыкларның рухи биеклегенә басым ясала. Р. Рахмани язганча, М. Юныс «арзанлы, мавыктыргыч сюжет сызыклары белән бизәп, укучынын күзенә төтен җибәрми, тормыш дөреслеген йомып калдырып аны шомартмый. милли язмышының андый такыр, шома юлдан йөрмәгәнлеген ул яхшы белә һәм шуңа да анын үзенчәлекләрен ачканда реаль тормыштан чыгып фикер йөртергә тырыша. Бу очракта да ул иман-кыйбласын җуймаган ышанычлы әдип исеменә тугры кала» [8: 181]. Гомумән, әсәр батырлык, туган җир, ватан өчен көрәшү

кебек изге төшенчәләрне фәлсәфи планда, яшәү-үлем аша яктыртуы белән җитди яңалык алып килә.

Шулай итеп, 1960–1980 еллар татар әдәбиятында сугыш темасының чагылышы яшәү һәм үлем, батырлык мәгънәсе, солдат һәм туган җир кебек җитди мәсьәләләрне алгы планга чыгара. Сугыш вакыйгаларын үз эченә алган әсәрләрдә ул дошманга нәфрәт, яшәүгә омтылышны фәлсәфи ноктадан чагылдыру аша бирелсә, тылдагы яшәеш кешенең әхлакый сыйфатлары, милли яшәештә чагылдан кыйммәтләргә нигезләнүендә чагыла.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Закирзянов А.М.* Татар әдәбият белеме: традицияләр һәм үсеш тенденцияләре (XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы). Казан: ИЯЛИ, 2018. 350 б.

2. *Закирҗанов Ә.М.* Мөхәммәт Мәһдиев // Татар әдәбияты: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 11 нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия (татар балалары өчен). Яңадан эшләнгән өченче басма / Ф.М. Мусин, З.Н. Хәбибуллина, Ә.М. Закирҗанов. Казан: Мәгариф, 2006. Б. 287–320.

3. *Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

4. *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда: 6 т: 1960–1980 еллар / ф. мөх-рләр: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. Б. 10–34.

5. *Миңнуллин Ф.М.* Безнең прозада сугыш темасы // Балта явызлар кулында: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Т. Галиуллин кереш сүзе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 97–107.

6. *Миңнуллин Ф.М.* Яшьлекне сагыну // Балта явызлар кулында: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Т. Галиуллин кереш сүзе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 218–230.

7. *Миңнуллин Ф.М.* Биектә калу // Балта явызлар кулында: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Т. Галиуллин кереш сүзе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 328–332.

8. *Рахмани Р.* Кыйблабызга тугрылык // Казан утлары. 2002. № 4. Б. 170–184.

9. *Хәбетдинова М.М.* Аяз Гыйләҗев // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда: 6 т: 1960–1980 еллар / ф. мөх-рләр: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. Б. 159–182.

УДК 821.161.1

# ОБЗОР ТРУДА ИЗВЕСТНОГО ТАТАРСКОГО ПРОСВЕТИТЕЛЯ КАЮМА НАСЫРИ «МИФТАХ АЛЬ-КУР’АН»

***Г.Р. Гайнуллина, Р.М. Миннегулова***
*Казанский федеральный университет (Казань)*

*Статья написана и опубликована при финансовой поддержке РНФ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта «Проведение фундаментальных научных исследований и поисковых научных исследований малыми отдельными научными группами» (региональный конкурс)» № 24-28-20211*

Данная статья посвящена анализу известных религиозных трудов выдающегося татарского просветителя XIX века Каюма Насыри. В статье рассматриваются ключевые богословские работы ученого и раскрывается их содержание, основные идеи и значение для развития татарской религиозной мысли.

Статья адресована исследователям истории татарской культуры, религии и всем, кто интересуется наследием Каюма Насыри.
**Ключевые слова:** научное наследие Каюма Насыри, татарское просветительство, татаро-мусульманская система образования.

This article is devoted to the analysis of famous religious works of the outstanding Tatar enlightener of the XIX century Kayum Nasyri. The article considers the key theological works of the scientist and reveals their content, main ideas and significance for the development of Tatar religious thought. The article is addressed to researchers of the history of Tatar culture, religion and all those who are interested in the heritage of Kayum Nasiri.
**Keywords:** scientific heritage of Kayum Nasyri, Tatar enlightenment, Tatar-Muslim education system.

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ МӘГЪРИФӘТЧЕСЕ КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ «МИФТАХ ӘЛ-КОРЪӘН» ХЕЗМӘТЕНӘ КҮЗӘТҮ

***Г.Р. Гайнуллина, Р.М. Миннегулова***
*Казан федераль университеты (Казан)*

Мәшһүр Каюм Насыйри киң җәмәгатьчелеккә хәзерге татар әдәби, фәнни теленә нигез салучы, мәгърифәтче, тарихчы, этнограф, тел белгече, әдип һәм, шуның өстәвенә, дин галиме, дини эчтәлектәге хезмәтләр, уку әсбаплары авторы буларак та билгеле. Каюм Насыйри ислам динен өйрәнүгә зур өлеш кертә. Дин өлкәсендәге эшчәнлеген ул «иҗтиһадымның иң олысы» дип билгели [2: 37].

Татарларның дөньяга карашын, үзаңын һәм менталитетын дин билгеләгәнлектән, Каюм Насыйри халыкны агарту эшенә дини аспект та җәлеп итә. «Аңа, танылган дин эшлеклеләре династиясенең дәвамчысы буларак, ислам дине мәсьәләләре, ислам дине гыйлеме, Корьәнне өйрәнүче фәнни дисциплана һәрвакыт мөһим була» [3: 32].

Каюм Насыйри кулы белән язылган дини һәм әдәби әсәрләр, уку ярдәмлекләре форма һәм эчтәлек ягыннан мөселман китап традициясе таләпләренә туры китереп төзелә. Мондый әсәрләр исемлегенә «Мөхтәсар тәварих әнбия» (Пәйгамбәрләрнең кыскача тарихы, 1884); «Мәҗмәгыль әхбар» (Пәйгамбәребез галәйһиссәлам тормышы, 1891); «Гакаиде Исламия» (Ислам дине, 1895); «Китаб эттәрбия» (Тәрбия китабы, 1891); «Әхлак дөләсе» (Әхлак турында матәм, 1884) һ. б. керә. Галим ислам дине буенча язылган хезмәтләрендә укучыларны исламның югары әхлакый һәм гуманистик кыйммәтләре белән таныштыра. Кеше акылын һәм хөр фикер йөртүне зурлаучы, хуплаучы әдәби әсәрләр, шулай ук, укыту-методик кулланмалары идея-эчтәлек ягыннан Корьән тәгълиматына һәм диннең рухи-әхлакый кануннарына таянып языла. Галим исламның рационалистик рухын практикада гәүдәләндерә һәм дин тәгълиматының беренче чиратта югары акылга, инсанның фикер йөртү сәләтенә, рухи үсеш мөмкинлекләренә юнәлгәнлеген исбатлый.

Каюм Насыйриның әдәби һәм фәнни хезмәтләр исемлегендә «Мифтах әл-Корьән» («Корьән ачкычы») дип аталган сүзлеге аерым урынны алып тора. Бу мөселманнарның Изге китабының асылын ача торган хикәяләр

җыелмасын тәшкил итә. Үз эченә якынча 46 200 Коръән сүзләрен алган конкорданс өстендә эш дүрт ел дәвам итә һәм 1886 елның 13 декабрендә тәмамлана. Кульязма брошюралардан торган дәфтәрне хәтерләтә. Киңлеге буенча тышлык күләме 190 мм, биеклеге буенча 275 мм тәшкил итә. Сүзлекнең бит күләме тышлык зурлыгына туры килә. Китап 4 битлек форзацларга ия. Тутырылмаган битләрне исәпкә алып, барлыгы китапның күләмен 424 бит тәшкил итә. Хезмәтнең битләрендә автор нумерациясе юк, бары сул якның өске өлешендә заманча гарәп цифрлары белән китапханә номеры сугылган. Барлыгы 212 номерны күрергә була. Сүзлек структурасы галимнең кереш сүзен һәм төп текстын үз эченә ала. Титуль бите рәсмиләштерелмәгән. Китапның исеме авторның кереш сүзендә генә телгә алына. К. Насыйриның кереш сүзе иске татар телендә гарәп графикасы белән язылган һәм, китапханә номеры нигезендә, 9 һәм 10 кульязма борылышларында урнаштырылган. Моннан тыш, форзацның 3 нче битендә зур булмаган, баш элементларның санын исәпкә алып эшләнелгән, татар телендә язма бар. Кульязманың төп тексты 14 нче номерлы борылыштан сүзтезмәләр, фразалар һәм тулы җөмләләр белән башлана. Бүлекләрнең исемнәре тиешле колонкалар чикләрендә аерым юллар белән язылган. Шулай ук, автор аларны битләр өстенә чыгарырга мәҗбүр булган. Кульязманың төп тексты кара каләм белән башкарылган, ә бүлек һәм аларның исемнәре кызыл кара белән язылган. Әлеге хезмәттә Коръән сурәләре өстендәге кыска дулкынлы горизонталь формадагы тамгалар сүзлек белән эшләүне җиңеләйтәләр. Кульязмада сүз берәмлекләре рәвешендә өстәмәләрнең саны күп. Аларның кайберләре автор тарафыннан махсус кушымчаларда, 43, 131, 179 нчы борылышларда ябыштырылган кечкенә кәгазь битләрендә язылган. Кульязманың төп тексты бүлек – бабларга бүленгән. Каюм Насыйри тарафыннан барлыгы 28 бүлек бирелгән. Аларның атамалары теге яки бу гарәп хәрефләреннән алынып («хәмзә» хәрефеннән тыш, башка хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртипләрен саклап) язылган. Мәсәлән: бāб әл-хамзати әл-истифāмийа (Сорау «хәмзә» бүлеге), бāб әл-бā («ба» бүлеге), бāб ат-тā («та» бүлеге ), бāб аç-ā’ («са» бүлеге, бāб әлджӣм («джим» бүлеге). Һәр бүлек тәкъдим итүче бүлекчәләрдән тора, алар Коръән сүзләре башлана торган хәрефләр тезмәсеннән гыйбарәт. Ә аларның саны 160 ка җитә. Сүзлекнең баш берәмлекләренең эчтәлегенә килгәндә, алар автор тарафыннан түбәндәге 3 элементлы схема буенча төзелгән:

1 элемент: Коръәндәге тотрыклы гыйбарәләр гарәпчә диакритик билгеләр кулланмыйча язылган.

2 элемент: Сүрәнең исеме диакритик билгеләрсез һәм аның аерым сүзеннән башка язылган.

3 элемент: Бит номеры 1861 елгы Коръән басмасында чыгарылган.

«Бу китапны укыган кеше үзен Коръән хафизы дип атый ала», – ди галим [2: 37]. Сүзлек иң элек Коръәнне җитди белүче затлар: дин әһелләре, казыйлар, имамнар, дин фәннәре укытучылары, дин таратучыларга атап нәшир ителә. Әлеге кульязма рәвешендәге китап университет фәнни китапханәсендә 130 ел дәвамында саклана, ә исә 2015 елда 100 нөсхә тиражы белән басылып чыга. Басма 2 томда тәкъдим ителә: беренчесе – «Каләм Шәриф» – конкорданс төзегәндә Каюм Насыйри тарафыннан нигез буларак алынган Коръәннең 1861 елгы Казан басмасы факсимилесы, икен-

чесе «Мифтах әл-Коръән» кулъязмасы факсимелесыннан гыйбарәт. Әлеге хезмәт алдынгы көнбатыш методологиясенең көнчыгыш материалга дөрес ярашуы һәм куллану нәтиҗәсе, ике фәнни парадигм синтезлау үрнәге булып тора. «Мифтах әл-Коръән» конкордансының үзенчәлеге Коръәндәге Аллаһ сүзләрен тарату ысулыннан гыйбарәт. Кулъязманы тикшерү барышында автор аятьләрнең номерларын түгел, ә Коръән типография басмасы битләренең номерларын күрсәткәнлеге ачыклана.

Татар галиме хезмәте Коръәннең асылын тышкы инструментлардан, кеше фикере, инанулары, фаразлаулары, уйдырмаларынан, азат булган аңлату үрнәге булып тора.

Әлеге хезмәтнең әһәмияте гаять зур, чөнки ул ислам дөньясында беренче Коръән сүзлеге булып тора. «Мифтах әл-Коръән» – Изге Китап буенча күрсәткеч, маршрут буларак хезмәт итә дияргә мөмкин. Каюм Насыйри Коръәндәге гарәп сүзләренең мәгънәләрен тәфсилләп, аларның контекстын аятьләр кысаларында аңлата, бу исә конкрет фразаларның мәгънәсен һәм әһәмиятен тирәнрәк аңларга булыша. Сүзлек тарихи һәм мәдәни аспектларның сылтамаларын үз эченә ала, бу укучыларга төрле тарихи чорларда сүзләрнең һәм фразаларның ничек кулланылуын күрергә ярдәм итә. Шулай ук, К. Насыйри хезмәте Коръән теле турындагы белемнәрне системалаштыра, бу аны галимнәр, гарәп телен һәм Ислам теологиясен өйрәнүче студентлар өчен дә файдалы итә.

К. Насыйриның «Мифтах әл-Коръән» сүзлегеннән тыш, 1867 елда нәшер ителгән «Гакаид рисаләсе»н (икенче тапкыр бастырылганда «Гакаид исламия» исеме астында) телгә алмыйча мөмкин түгел. Әлеге хезмәтне татар телендә дини гыйлем алу буенча ярдәмлекләр төзүнең беренче омтылышына кертергә була. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, татар мәдрәсәләрендә ул киң таралыш алмый. Бу Каюм Насыйриның төп теологик хезмәтләреннән берсе, анда мәгърифәтче Аллаһка ышану, Аллаһны исем һәм сыйфатлары аша тану, пәйгамбәрләргә ышану, соңгы пәйгамбәр, Мөхәммәдкә инану һәм аның тормыш юлы, шәҗәрәсе кебек мәсьәләләрне күтәрә.

«Гакаид рисалә»дә галим гыйбадәт кылу сәбәпләре турындагы мәсьәләне күтәрә. Насыйри, уку әсбапларын укыганнан соң, мөселман халкы дин турында уйлана башлар, үз акылы һәм йөрәге белән бердәм Аллага ышаныр һәм алга таба белемнәр, дөньяви һәм дини, рухи-әхлакый үсеш алу өчен үз көчен куяр, дип ышана.

Мәгърифәтче фикеренчә, ике иман чыганагы бар: Аллаһы Тәгаләнең барлыгын исбатлый алырлык акыл һәм дәлилләр. «Гакаид исламия» хезмәте ислам дине мәсьәләләрен бәян итүче чыганак булып тора, ул ислам диненең хәнәфи мәзхәбенә нигезләнеп язылган. Галим киләчәк буыннарны рухи-әхлакый тәрбияләү турында кайгырта, дини белем нигезләрен бирергә омтыла. Мәгърифәтче үз хезмәтләрен язганда Изге китапка – Коръәнгә таянган.

«Кыйссасәл-Әнбия» Каюм Насыйриның иң танылган әсәре булып тора. Әсәрнең эчтәлеге Изге Язмалардагы пәйгамбәрләр турындагы хикәяләрне үз эченә ала. Ләкин, ул турыдан-туры тәрҗемә түгел, ә автор тарафыннан эшкәртелеп үзгәртелгән вариантны хәтерләтә. Кыйссас әл-Әнбия эчтәлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала:

Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнгән Адәмнан башлап Мөхәммәт пәйгамбәргә кадәрге пәйгамбәрләрнең тормыш юллары, гамәлләре һәм вәгазьләре сурәтләнә. Һәр пәйгамбәрнең үзенчәлекле тарихы һәм вазыйфасы бар. Хезмәттә Аллаһы Тәгалә белән пәйгамбәрләр арасындагы бәйләнешкә, аларның вәгазьләренә һәм халыкларга тәэсир итүләренә зур игътибар бирелә.

Пәйгамбәрләрнең сынаулары һәм авырлыклар аша үткән юллары сүрәтләнә. Күп кенә пәйгамбәрләр үз халыклары тарафыннан кабул ителмәгән, эзәрлекләнгән һәм җәфа чиккән. Пәйгамбәрләрнең сабырлыгы, ныклыгы һәм Аллаһы Тәгаләгә ышануларына басым ясала.

Изге китап хикәяләренең үзгәртелгән варианты: К. Насыйри Изге Язмалардагы хикәяләрне үз стиле, татар халкының гореф-гадәтләренә һәм тормышына яраклаштырып, үзгәртеп яза. Ул хикәяләрнең дидактик ягын ныгыта, аларны татар халкы өчен аңлаешлырак һәм кызыклырак итә.

Мораль-дидактик элементлар: «Кыйссасәл-Әнбия» – хикәяләр җыентыгы гына түгел, ә мөселманнар өчен тәрбияле әсәр. Автор үзенең хикәяләре аша Аллаһы Тәгаләгә ышану, изге гамәлләр кылу, яхшылыкка омтылу кебек мөһим әхлакый кагыйдәләрне тәкъдим итә. Кыскасы, «Кыйссасәл-Әнбия» – татар халкы өчен мөһим әсәр, ул дини белем бирү белән бергә, әхлакый тәрбия бирү ролен дә үти. Әсәрдәге хикәяләрнең кызыклылыгы һәм гадилеге аны бүгенге көнгә кадәр популяр китаплар рәтенә кертә.

«Мәҗмәгыль әхбар. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам тормышы»нда рәсүлебезнең язмышына бәйле вакыйгалар белән беррәттән, К. Насыйри әлеге хезмәтендә милләттәшләренең исенә әдәп-әхлак кагыйдәләрен төшерә. Галим әхлакый битарафлыкны үгет-нәсыйхәт биреп кенә түгел, ә гыйбрәт күрсәтү юлы аша хәл итүне мөһимрәк күрә.

Шулай ук, К. Насыйри дини хезмәтләр, уку әсбаплары чыгарудан тыш, календарьләр төзү эшен алып бара. Ул 1871 елдан башлап беренче мәртәбә календарь сүзен кулланып, еллык өстәл календаре чыгара башлый. 1877 елга хәтле галим басмаларын «Казан календаре» дип, ә 1878 елдан «Календарь» дип кенә атый. Ул аларны елга бер тапкыр бастыра, соңгысы 1897 елда дөнья күрә. Ул төзегән календарьлар берничә төргә бүленә:

Дивар календарьлары: Һәр ел өчен аерым нәшер ителгән, диварга эләр өчен ясалган календарьлар. Аларда айлар, көннәр, мөһим дини бәйрәмнәр күрсәтелгән.

Кесә календарьлары: Кечкенә форматтагы, кесәдә йөртер өчен уңайлы календарьлар.

«Мөхтәсәр тәкъвим» (Кыскача календарь): Бу календарьда мөселман айлары, көннәре белән бергә, кояш чыгу һәм баю вакытлары, намаз вакытлары да күрсәтелгән. К. Насыйриның 1888 елгы календаренда мөселманнарның мөбарәк айлары бәян ителә. Мәсәлән, Җөмәдәл-ахыр – Әбү Бәкер радыяллаһү ганһе вә хәлифә хәзрәти Гомәр радыяллаһү ганһе ошбу айда вафат. Раҗәб – әүвәлге җомга кичәсе – Рәгаиб бәйрәмедер. Пәйгамбәр галәйһиссәламнең әнисе ошбу кичәдә йөкле булган. Шәгъбан – 15 нче кичәсе – Бәраәт бәйрәмедер. Кыйбла юнәлешенең үзгәрүе шәгъбан аенда булды. Хәсән бине Гали радыяллаһү ганһе шәгъбанда вафат. Рамазан – бөтен ай шатлык вә бәйрәмдер. 27 нче кичәсе – Кадер кичәседер. 19 нда хәзрәти Расүл галәйһиссәламгә Хира тавында вәхи килгән, «Әл-Галәкъ»

сүрәсе иңгән. 28 ендә зәкят вә фитр садакасы вәҗиб булган. 12 сендә бәдер сугышы булган. 17 сендә хәзрәти Гали вафат булган. 25 ендә Мәккә-и Мөкәррәмә фәтех кылынган. Шәввәл – берендә Гыйд әл-Фитрдыр. Рамазанның үтүенә хәсрәтләнеп, киләчәк Рамазанга сәламәт җитсәк иде дип Аллаһы Тәгаләдән сорый торган көндер. 12 сендә Өхед сугышы булган. Зөлхиҗҗә – 10 нчы көнендә Корбан гаетедер, шатлык көнедер. 11, 12, 13 нче көннәре – тәкбир тәшрикъ көннәредер. 18 ендә хәзрәти Госман радыяллаһү ганһе, ә 22 сендә Гомәр радыяллаһү ганһе вафат. Пәйгамбәр галәйһиссәлам хәзрәти Гайшә радыяллаһү ганһе белән ошбу айда никахлашкан. Мөхәррам – әүвәл көне һиҗри ел башыдыр. 10 сында – Гашура бәйрәмедер. Хәзрәти Хөсәен ошбу көндә шәһит булган. Сафәр – 28 ендә Пәйгамбәр галәйһиссәлам хәзрәти Әбү Бәкер илә Мәдинәгә һиҗрәт кылу максаты белән Мәккәдән чыккан. Рабигыль-әүвәл – 10 сында Пәйгамбәр галәйһиссәлам Мәккәдән һиҗрәт кылып, Мәдинәгә кергән. 12 сендә Пәйгамбәр галәйһиссәлам бу дөньядан кичкән. 20 сендә хәзрәти Әбү Бәкергә бәйгать бирелгән, ул «хәлифә Расүлуллаһ» дип аталган.

Шуңа өстәп, Каюм Насыйри календарьларында астрономик мәгълүматларның төгәллегенә зур игътибар биргән. Ул үзенең астрономик белемнәрен һәм исәпләүләрен кулланып, календарьларны мөмкин кадәр дөрес итеп төзегән. Бу календарьлар халык арасында киң таралган һәм гамәли тормышта кулланылган. Аларның тарихи әһәмияте дә зур, чөнки алар аша без ул чорның вакыт исәпләү системасы һәм астрономик белемнәре турында мәгълүмат ала алабыз.

Каюм Насыйриның дини хезмәтләре татар халкының рухи тормышында зур әһәмияткә ия. Аның хезмәтләре үз заманындагы җәмгыятьтәге төрле мәсьәләләргә җавап бирүгә юнәлтелгән һәм бүген дә актуальлеген югалтмый. Мәшһүр мәгърифәтче гади халыкка аңлаешлы телдә ислам диненең нигезләрен аңлата. Ул катлаулы дини мәсьәләләрне гадиләштереп, халыкка җиткерә. Аның хезмәтләре татар халкының милли үзаңын формалаштыруда мөһим роль уйный. Ул дини кыйммәтләрне милли мәдәният белән бәйләп, татар халкының рухи байлыгын саклап калырга өндәгән, кешеләрне намуслы, гадел, мәрхәмәтле булырга өйрәткән. К. Насыйри үзенең дини карашларын фәнни белемнәр белән бәйләргә тырышкан. Ул астрономия, математика кебек фәннәрне өйрәнеп, дини мәсьәләләрне аңлатуга куллану юлларын эзләгән. Ул дини терминнарны татар теленә тәрҗемә итеп, дини белемнәрне халыкка аңлаешлы иткән. Кыскасы, Каюм Насыйриның дини хезмәтләре татар халкының мәдәни һәм рухи мирасының аерылгысыз өлеше булып тора.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Маннанова Р.* Мәшһүр мәгърифәтче Каюм Насыйри тууына 200 ел // Дин вә мәгыйшәт., 2025, гыйнвар. № 1 (354). Б. 12.

2. *Насыри К.* Мифтах аль-Кур’ан: в 2 т. Т. 2: Насыри К. Мифтах аль-Кур’ан. Казань, 2015. 452 с.

3. *Хайрутдинов А.Г.* «Мифтах аль-Кур’ан» Каюма Насыри: Первый в мусульманском мире конкорданс Корана // Ислам в современном мире. 2016. № 12 (1). С. 57–76.

4. *Шафигуллина Р.Ф.* «Вершина моего иджтихада…» // Насыри К. Мифтах аль-Кур’ан: в 2 т. Т. 2: Насыри К. Мифтах аль-Кур’ан. Казань, 2015. 452 с.

5. *Юзеев А.Н.* Просветительская мысль татарского народа (XIX – нач. XX в.): монография. Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. 415 с.

УДК 821.512.145

# ТРАНСФОРМАЦИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА В МОЛОДЕЖНОЙ ИНТЕРНЕТ-СРЕДЕ

***Г.У. Гайнуллина***
*УУНиТ (Уфа)*

Данная статья посвящена исследованию функционирования татарского языка в молодежной Внтернет-среде. Анализируются проблемы, связанные с исследованием такого сложного и многомерного явления, как Интернет. Здесь также ставится вопрос о соотношении понятий «Интернет» и «культура». Материалом для исследования послужили открытые молодежные группы социальной сети Вконтакте. Пользователями этих сайтов являются молодые люди в возрасте от 14 до 30 лет. Особое внимание в статье уделяется изучению заимствований и жаргонизмов, которые являются спецификой молодежной Интернет-среды. Изучение языка массовой коммуникации – актуальная задача для филологов, которые призваны рассматривать СМИ в широком контексте, позволяющем понять и объяснить влияние социально-психологических, политических и культурных факторов на функционирование языка в обществе.
**Ключевые слова:** татарский язык, заимствования, язык Интернета, Интернет-среда, массовая коммуникация, культура речи.

This article is devoted to the study of the functioning of the Tatar language in the youth Internet environment. The problems associated with the study of such a complex and multidimensional phenomenon as the Internet are analyzed. It also raises the question of the relationship between the concepts of “Internet” and “culture”. The material for the study was the open youth groups of the social network Vkontakte. The users of these sites are young people between the ages of 14 and 30. Special attention is paid in the article to the study of borrowings and jargonisms, which are the specifics of the youth Internet environment. Studying the language of mass communication is an urgent task for philologists who are called upon to consider the media in a broad context that allows them to understand and explain the influence of socio–psychological, political and cultural factors on the functioning of language in society.
**Keywords:** Tatar language, borrowings, Internet language, Internet environment, mass communication, culture of speech.

Жизнь человека неразрывно связана с обществом. Под влиянием общественного сознания формируется массовая культура, коллективное мышление. Язык является средством выражения коллективного сознания. Наблюдая за изменениями, происходящими в языке, можно судить о развитии и изменении культуры и образа мышления человека.

Каждое поколение имеет своих кумиров, развивается и формируется под влиянием ценностей, которые возникают в тот или иной исторический период. Наиболее активный слой общества, в который входит молодежь, является носителем и двигателем этих ценностей. Наблюдать за динамикой и культурным состоянием «мира» молодежи мы можем, анализируя их речь, письменную и устную.

Жизнь молодежи XXI века неразрывно связана с Интернетом. Современные технологии позволяют молодым людям постоянно находиться в виртуальной разговорной среде. Большую часть времени молодежь

проводит в социальных сетях, где происходит основной процесс общения, обмена информации. Общение происходит сиюминутно, в режиме реального времени, что сближает данный вид речи с разговорной.

«Массовая коммуникация – это система социального взаимодействия особого рода. Общезначимость данной коммуникативной сферы обусловлена тем, что в центре ее внимания находится человеческое общество, которое выступает как ограниченное социальное пространство со специфическими внутренними процессами и культурными характеристиками. Массовая коммуникация – это систематическое распространение сообщений среди численно больших, рассредоточенных аудиторий с целью воздействия на оценки, мнения и поведения людей» [3: 13].

Научный анализ такого сложного и многомерного явления, как Интернет, предполагает сопряжение различных областей гуманитарного знания, с одной стороны, и знания информационных технологий – с другой стороны. В то же время Интернет – это феномен культуры, прежде всего медийной.

В связи с этим правомерно поставить вопрос о соотношении понятий «Интернет» и «культура». Культура в целом исходит из принципа закрытости. Средства массовой информации, наоборот, – из принципа открытости и прозрачности. Создание произведений культуры предполагает и требует затраты определенного времени. Продолжительной и углубленной работы. СМИ, прежде всего Интернет, базируется на принципе высочайшей степени оперативности, актуальности. Возможности быстрой смены или замены информации, мгновенного распространения, тотального охвата.

Интернет – это паутина, в сетях которой находится громадное количество информации. Здесь можно найти практически любые ответы на вопросы, дистанционно обучаться, вести переписку с интересными для тебя людьми.

При помощи Интернета люди делятся впечатлениями, постоянно находятся на связи, общаются. В виртуальном мире люди чувствуют себя более раскрепощено, увереннее, что позволяет людям снимать психологические барьеры, высвобождают свое «я».

В просторах социальной сети люди сиюминутно обмениваются информацией, используя письменную разговорную речь. Язык не стоит на месте, он постоянно терпит какие-то изменения, развивается. У каждого поколения свои особенности разговорной речи. В мире Интернета возникают новые языковые средства коммуникации, происходит трансформация старых.

С появлением Интернета существенно меняется судьба текста в обществе, так как в Интернет-сообществе человек-образ равен тексту, что особенно ярко проявляется в чатах, где реализуется базовое стремление человека к творческому самовыражению.

Для эмоциональной насыщенности речи были введены смайлики (от англ. smile – улыбка), в большем количестве используются знаки препинания. Сегодня смайлики являются своего рода «передатчиком» эмоций.

Существование Интернет-общения создает условия для формирования нового стиля – стиля Интернет-общения.

В виртуальном мире возникает свой специфический язык – язык общения Интернет-пользователей, «массы», со своими лексическими

особенностями. Стиль данного языка вобрал в себя черты разговорной речи, такие, как спонтанность, линейный непосредственный характер речевого акта.

Так возникает своеобразная разговорно-письменная речь. Письменный ее характер позволят нам наблюдать за изменениями, происходящими в разговорной речи, наблюдать за динамикой развития языка в современном обществе и культуры в целом. Сравнивая ее с нормами литературной речи, можно увидеть, что она изобилует жаргонами, словами ненормированной лексики и др.

В нашей работе рассматриваются языковые особенности молодежной Интернет-среды на материалах русского и татарского языков. Материалом для исследования послужили следующие открытые молодежные группы социальной сети Вконтакте: число пользователей одной страницы составляет более 300 тысяч человек. Пользователями этих сайтов являются молодые люди в возрасте от 14 до 25 лет.

Основная деятельность этих групп Вконтакте заключается в отправке на страницу сайта разных интересных картинок с надписями и их комментировании. Целью нашего исследования является анализ лексико-семантических и грамматических особенностей данных надписей. В ходе исследования выяснилось, что на страницах популярных для молодежи сайтов чаще всего встречаются следующие лексико-семантические особенности:

В большом количестве подростки употребляют неологизмы, образованные от заимствованных из других языков слов: *троллинг* (англ. *trolling* означает «ловлю рыбы на блесну», создание конфликтных ситуаций), *лайк* (англ. like – нравиться), *фэйспалм* (англ. face – лицо, palm – ладонь) – популярное онлайн-выражение в виде физического жеста, которое является проявлением разочарования, стыда), *имхо* (англ. IMHO – In My Humble Opinion – по моему скромному мнению), *селфи* (self – себя, себе, в значении автопортрета, фотографирования самим себя) и многие другие, связанные с популярными онлайн-играми (*Assassin's Creed Unity* (рус. *Кредо ассасина: Единство*, в русской локализации Assassin's Creed Единство) – компьютерная мультиплатформенная игра). Все это связано с тем, что в сети Интернет-игры, программы (популярные у молодежи) на английском языке, придуманы зарубежными авторами. Да и сам язык программирования составлен на английском. Стремление к европеизации ведет к тому, что наш язык наполняется, иногда и засоряется английскими выражениями, словами. Вместо «привет» употребляют форму «хай», вместо «пока» – «бай» и т. д.

В татарском языке также много неологизмов, образованных путем «схватывания» слов, форм слов, морфем из русской лексики:

– *Үтери**ческий** Көлдер**чинский***
– ***Негри**бәрәңге*
– ***Спрашивай**га кердем. Сорагыз инде мине дә...*
– *Синең дә **загрузка** белән шулай уйнаганың бармы?*
– *Син миңа **сбщ** язам. Ә син миңа юк???*
– *Обама, син контактта **зарегался**мы?*
– *Минем **головам** (процессор) тупить итә.*

Молодые люди также используют переделанные, иногда и с отрицательной семантической окраской фразеологизмы. Такого рода «выражения» также можно рассматривать как ненормативную лексику.

*Авызыңны северим! (в значении закрой рот)*
*Арышыңны урыйм (форма угрозы)*
*Җаныңны северим! (форма угрозы)*
*Бук чәйнәмә әле... (в значении «Не мели ерунды»)*
*Ычкын моннан! (в значении «Вали отсюда»)*

Омнимами называются слова, разные по значению, но совпадающие по звучанию. Например, *лук – овощ, лук – оружие*. Помимо лексических омонимов выделяют и другие разновидности омонимии: омофоны – слова одинаковые по звучанию, но разные по написанию; омографы – слова, имеющие ударения на разных слогах, но пишущиеся одинаково; омоформы – слова, совпадающие по написанию и звучанию в какой-либо грамматической форме или формах.

При помощи игры слов передаются новые значения. Часто их используют для создания каламбуров. В рассматриваемой нами молодежной Интернет-среде также можно увидеть такого рода примеры:

*– Һәр басудан төркемнең бюджеты арта бара*
*– Сөйлә миңа интернет, кая яши бай бабай.*
*– Интернетны аердылар. Комптагы бөтен уеннарны унап чыктым.*
*– Интернетны куштылар.*
*– Башың белән селкеп кара.*

В приведенных выше примерах омонимы образованы за счет калькирования из русского языка и поэтому с точки зрения семантики не совсем правильны и понятны. «Калька (от фр. calque – копия) или калькирование в лингвистике – заимствование иноязычных слов, выражений, фраз буквальным переводом соответствующей языковой единицы, а также результат этих заимствований: слова, выражения и фразы» [1]. Например, предложение «Интернетны куштылар» образовано за счет прямого перевода предложения «Соединили Интернет». В татарском языке слово «куштылар» употребляется в значении «присоединить», «дать имя», а также в форме прошедшего времени 3-го лица глагола велеть, приказать; поэтому данное предложение звучит как «Присоединили (приказали) Интернет».

*– Һәр басудан төркемнең бюджеты арта бара.(С каждого нажатия (поля) численность группы возрастает)*

*– Сөйлә миңа интернет, кая яши бай бабай. (Расскажи мне Интернет, где (куда) живет богатый дедушка)*

*– Интернетны аердылар. Комптагы бөтен уеннарны унап чыктым. (Интернет отсоединили (развели). Переиграл все игры на компьютере)*

*– Башың белән селкеп кара. (Попробуй помотать (здесь в значении «снять и потрясти») головой)*

В просторах сети Интернет «язык молодежи» стал модным. В связи с этим многие слова-жаргоны, употребляемые молодежью, в быстрые сроки становятся популярными. Умение пользоватья жаргонизмами делает челвека «своим крутым чуваком». Сленг как вид жаргона – это частое явление как в русском, так и татарском языках:

*Сәлам, **брат**!*

*Малайны успех көтә иде... Булып чыкмады. **Не фортануло**.*

*Ошаса. **Лайк** куй!*

*Ния **сбщ** язмайсың?!*

*Мин **офлайнга** киттем, югалтма.*

*Мин сине **черный списокка** тыктым!!!*

*Нинди текә **чувак**!*

*Шәп **чувиха**!!!*

*Тридцати кошкам своим потом будешь скриншоты показывать, как ты подкатывающих к тебе парней остроумно **обламывала**.*

*Считать себя «**типичным ниггером**».*

***Баян**! (в значении неудачной шутки)*

Язык Интернета нельзя представить себе без вульгаризмов. В татарской Интернет-лексике их очень много, чаще они взяты из русского языка:

*– Тортны **жалко***

*– **Даже** ул хезмәт иткән*

*– **Пивы** алган идем*

*– **Причем тут** баш?*

*– **Пожалуйста**, көт мине!*

*– **Мужиклар** көне белән!*

*– Тор, бу **ограбление**!*

*– **Обычный** кешеләр ничек менә. Мин ничек менәм.*

*– **Американский** комедия караганда реакция. **Русский** комедия караганда реакция.*

*– Байлар **карты** уйный.*

*– Бөтен безнең **подписчыклар**!*

*– Симезләрне **обижать** итмәгез – алар сезне саклап кала ала.*

*– **Слышь**, кызый, **крышаң** китеп бара бугай.*

*– Барасың **такой** дустың белән... и **вдруг такой** песи...*

*– Керми генә кара, **убью**!*

*– Син, **да да**, сиңа әйтәм мин... **подписаться** га бас син! Ишеттеңме?*

*– Сөймәгән мине көтә, сөйгән **тормозить** итә!*

*– Җаным, мин монда бер күлмәк алган идем. Тик аны кияргә **повод** кына юк. – Ә, нинди күлмәк? – Туй күлмәге, матурым.*

*– **Веришь**, менә мондый балык эләктердем!*

*– **Лябуфф ызла**! Син кәҗәне яратсаң, ул да сине ярата*

*– Минем **статус – активный поиск**!!!*

*– Мин – **татарочка**.*

*– **Полюбому** трамвай гаепле.*

*– Кошлар **общагасы***

*– **Семычкылар** ничә сум.*

Слова-заимствования – результат взаимодействия, сотрудничества народов, наций. Усиление взаимодействия языков при возрастающей роли культурных и экономических связей между народами приводит к образованию особого фонда интернациональной лексики, имеющейся как в родственных, так и в неродственных языках.

«В настоящее время наблюдается возрастание интернациональной лексики английского происхождения, это объясняется его глобальной ролью. Основную массу интернациональных элементов английского происхождения составляют корневые морфемы, проникающие в мировые языки и обладающие способностью комбинироваться с национальными аффиксами» [6: 134]. В своем исследовании А.Э. Рыцарева под интернационализмами понимает «лексические единицы, функционирующие в нескольких (не менее чем в трех) мировых языках, близкие по звуковой, графической и семантической форме, являющиеся следствием языкового контакта и выражающие общие для многих культур понятия из областей науки, техники, бизнеса, политики, искусства, средств коммуникации». Безусловно, «язык» Интернета нельзя представить без интернациональных слов, как русские, так и татары активно пользуются такимим словами, как*: Интернет, веб-сайт, смс, e-mail, рамблер, гугл, юзер, медиа, браузер, файл, программа, админ, модератор, логин, пароль, шрифт, Wi-Fi, геймер, хакер, вирус, антивирус, 1С, XP, яндекс.*

Итак, рассмотрев вопрос о существовании татарского Интернет-языка, мы приходим к выводу о том, что как такого национального татарского Интернет-языка не существует. Все языковые особенности молодежной Интернет-среды идентичны как для русского, так и татарского языков. Отсюда можно сделать вывод о возможности становления особой формы языка – языка общения Интернет-пользователей. Этот «язык», безусловно, будет иметь и национальные черты, так как на нем будут общаться представители разных наций, базируясь на свой родной язык.

Сегодня особенно остро встает вопрос о формировании высокой информационно-языковой культуры в обществе, о сохранении национальных языковых традиций и культуры речи. Изучение языка массовой коммуникации – актуальная задача для филологов, которые призваны рассматривать СМИ в широком контексте, позволяющем понять и объяснить влияние социально-психологических, политических и культурных факторов на функционирование языка в обществе. Решение задачи возможно только в тесном сотрудничестве с представителями других областей знания, т. е. на междисциплинарном уровне.

СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1. *Бергельсон М.Б.* Языковые аспекты виртуальной коммуникации // Вестник МГУ. Лингвистика и межкультурная коммуникация. 2002. № 1. С. 55–67.

2. *Виноградова Т.Ю.* Специфика общения в Интернете // Русская и сопоставительная филология: Лингвокультурологический аспект. 2004. № 11. С. 63–67.

3. *Володина М.Н.* Язык средств массовой информации. М.: Академический Проект; Альма Матер, 2008. 760 с.

4. *Гольцова Н.Г.* Русский язык. 10-11 классы: учебник для общеобразовательных учреждений / Н.Г. Гольцова и др. 8-е изд. М.: ООО «Русское слово – учебник», 2011. 448 с.

5. *Дубенец Э.М.* Лингвистические изменения в языке. М.: Глосса-Пресс, 2003. 256 с.

6. Язык Интернет: характеристика, особенности и влияние // http://xreferat.ru/31/1320-1-yazyk-internet-harakteristika-osobennosti-i-vliyanie.html.

УДК 373.24

# РОЛЬ ХУДОЖЕСТВЕННОЙ ЛИТЕРАТУРЫ В ФОРМИРОВАНИИ НАВЫКОВ ВЛАДЕНИЯ РОДНЫМ ЯЗЫКОМ У ДЕТЕЙ ДОШКОЛЬНОГО ВОЗРАСТА

***М.Ф. Гайфуллина***

*Стерлитамакский филиал СФ УУНиТ (г. Стерлитамак)*

В статье рассматриваются возможности художественной литературы в формировании навыков владения родным языком у детей старшего дошкольного возраста. Значимость литературы велика по своей образовательной, воспитательной и художественной ценности. Расширение знаний о мире вокруг ребенка способствует развитию его индивидуальности и формированию навыка тонкого восприятия формы родного языка. Развитие способности дошкольников к восприятию лучших образцов литературных произведений, включая осознание основных элементов их выразительности, требует целенаправленной работы с детьми с самых первых лет жизни. Под руководством опытного педагога, детям старшего дошкольного возраста удается не только прочувствовать атмосферу художественного произведения, осмыслить его ключевые идеи и особенности стиля, но и познать тонкости родной речи.

**Ключевые слова:** дети дошкольного возраста, развитие речи, навыки владения родным языком, дошкольная образовательная организация, художественная литература.

The article examines the possibilities of fiction in the formation of native language skills in older preschool children. The importance of literature is great in its educational, educational and artistic value. The expansion of knowledge about the world around a child contributes to the development of his personality and the formation of the skill of subtle perception of the form of his native language. Developing the ability of preschoolers to perceive the best examples of literary works, including awareness of the basic elements of their expressiveness, requires purposeful work with children from the very first years of life. Under the guidance of an experienced teacher, older preschool children manage not only to experience the atmosphere of an artistic work, comprehend its key ideas and style features, but also to learn the subtleties of their native speech.

**Keywords:** preschool children, speech development, native language skills, preschool educational organization, fiction.

Роль художественной литературы в процессе освоения родного языка, родной культуры неоценима, поэтому уже в дошкольных образовательных организациях особое внимание уделяется знакомству детей с литературными произведениями.

Процесс восприятия художественной литературы детьми дошкольного возраста представляет собой активную и самостоятельную деятельность, предполагающую не просто поглощение информации, а включение в процесс внутреннего взаимодействия, эмпатии к персонажам произведения, воображаемого переноса сюжета на свою жизнь, что позволяет ребенку ощутить себя непосредственным участником и свидетелем событий в художественном произведении. По мнению О.С. Ушаковой, художественная литература способна раскрыть перед старшим дошкольником полноту жизни нашего общества, окружающей среды, а также вселенную эмоций и

межличностных связей. Старший дошкольник обретает богатый эмоциональный опыт и совершенствует свои мыслительные способности благодаря знакомству с произведениями художественной литературы, которые также стимулируют его воображение. Значимость литературы велика по своей образовательной, воспитательной и художественной ценности, поскольку расширение знаний о мире вокруг ребенка способствует развитию его индивидуальности и формированию навыка тонкого восприятия формы родного языка. С самого начала своей жизни человек окружён произведениями художественной литературы. Для того чтобы дошкольники могли полноценно воспринимать художественную литературу, их необходимо тщательно подготовить, что может осуществляться благодаря усилиям педагогов детских садов [3: 97].

В старшем дошкольном возрасте особенно ярко проявляется процесс восприятия искусства. Старшие дошкольники проявляют чувствительную эмпатию по отношению к основным персонажам в художественной литературе. В этом возрасте детям удается представить себя в роли главного персонажа, активно участвующего в придуманных ими ситуациях. Старшие дошкольники обожают народные волшебные сказки за их удивительные выдумки, невероятную фантазию, богатые конфликты, трудности, разнообразие сюжета, множество драматических поворотов и ярких, смелых персонажей художественной литературы.

В.В. Гербова подчеркивает роль художественной литературы в формировании навыков владения родным языком у детей старшего дошкольного возраста, указывая на то, что благодаря художественным произведениям дети могут овладеть всеми ключевыми грамматическими аспектами и словарем еще до начала школьного образования и изучения грамматических правил. В процессе чтения художественных книг детям дошкольного возраста открывается возможность познакомиться со множеством новых терминов, ярких метафорических оборотов, что способствует развитию их речевых навыков и расширению словарного запаса эмоционально окрашенной лексики. В процессе ознакомления с литературным творением очевидна взаимосвязь между развитием речевых навыков и эстетическим воспитанием ребенка дошкольного возраста, когда язык осваивается через его художественное применение [1: 19–20].

Литература для детей должна служить инструментом формирования гуманизма, основанного на принципах справедливости, доброты и патриотизма. При выборе литературы для чтения в дошкольной образовательной организации педагогу следует проявить осмотрительность. Старший дошкольник привлекается художественным произведением благодаря его образным формам, яркости и значимости содержания. Воспитание формирует определенные критерии поведения, которыми дети старшего дошкольного возраста руководствуются при оценке персонажей художественных произведений, давая осмысленную и мотивированную характеристику. Развитие способности сопереживать персонажам, отслеживания сюжетной линии и сравнения событий в книге с жизненным опытом ребенка облегчает ему быстрое и правильное восприятие реалистических сказок, историй, а к завершению дошкольного периода – даже волшебных историй и невероятных рассказов.

В связи с ограниченным развитием мыслительных способностей дошкольников, они испытывают трудности в осмыслении ключевых литературных форм, включая поговорки, пословицы, загадки и басни, что делает необходимым участие взрослых в их обучении. Под руководством педагогов детского сада старшие дошкольники могут осознавать полноту содержания литературного произведения и его основную художественную форму, находить ключевые образные слова и крылатые выражения, ощущать рифму и ритм стихотворения, а также запоминать художественные приемы, используемые другими авторами детской литературы [2: 195].

Таким образом, развитие и совершенствование восприятия художественных произведений на родном языке у детей старшего дошкольного возраста происходит на протяжении всего этого периода. Развитие способности дошкольников к восприятию лучших образцов литературных произведений, включая осознание основных элементов их выразительности, требует целенаправленной работы с детьми с самых первых лет жизни. Под руководством опытного педагога, детям старшего дошкольного возраста удается не только прочувствовать атмосферу художественного произведения, осмыслить его ключевые идеи и особенности стиля, но и познать тонкости родной речи.

СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1. *Гербова В.В.* Занятия по развитию речи в средней группе детского сада. М.: МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2011. 80 с.

2. *Ёлкина Н.В.* Формирование связной речи у детей дошкольного возраста: Учеб. пособие. Ярославль: Изд-во ЯГПУ им. К.Д. Ушинского, 2006. С. 227.

3. *Ушакова О.С* Методика развития речи детей дошкольного возраста: Учеб.-метод. пособие для воспитателей дошк. образовательных учреждений / О.С. Ушакова, Е.М. Струнина. М.: ВЛАДОС, 2018. 288 с.

УДК 821.512.145

# КАЮМ НАСЫРИ В ТВОРЧЕСКОМ НАСЛЕДИИ ГАЯЗА ИСХАКИ

***Л.Ш. Галиева***

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Данная статья посвящена исследованию роли личности и деятельности выдающегося татарского просветителя Каюма Насыри в творческом наследии классика татарской литературы Гаяза Исхаки. Г. Исхаки посвятил К. Насыйри несколько статей, которые были опубликованы на страницах периодических изданий. Первая из них является некрологом и увидела свет в общетюркской газете «Тарджиман». Вторая публикация была написана по случаю 100-летнего юбилея К. Насыри. Третья и самая объемная статья писателя была опубликована в 1937 году в журнале «Яңа милли юл» («Новый национальный путь»), во время пребывания писателя в эмиграции. Также имя К. Насыри можно встретить в произведениях писателя, его публицистике. Г. Исхаки высоко оценивает деятельность К. Насыри для татарского народа, вносит свой вклад на пути популяризации его имени и творческого наследия среди других тюркских народов.

**Ключевые слова:** история татарской литературы, Гаяз Исхаки, Каюм Насыри, татарская публицистика, журналистика, юбилей.

This article is devoted to the study of the role of the personality and activities of the outstanding Tatar educator Kayum Nasyri in the creative heritage of the classic of Tatar literature Gayaz Iskhaki. G. Iskhaki dedicated several articles to K. Nasyri, which were published in periodicals. The first of them is an obituary and was published in the pan-Turkic newspaper "Tardzhiman". The second publication was written on the occasion of the 100th anniversary of K. Nasyri. The third and most voluminous article of the writer was published in 1937 in the magazine "Yana milli yul" ("New National Path"), during the writer's stay in exile. Also, the name of K. Nasyri can be found in the writer's works, his journalism. G. Iskhaki highly appreciates the activities of K. Nasyri for the Tatar people, makes his contribution to the popularization of his name and creative heritage among other Turkic peoples.
**Keywords:** history of Tatar literature, Gayaz Iskhaki, Kayum Nasyri, Tatar journalism, journalism, anniversary.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ЯЗМА МИРАСЫНДА КАЮМ НАСЫЙРИ

***Л.Ш. Галиева***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

XX гасырның күренекле язучысы, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның язма мирасында замандашлары, иҗатташлары, татар халкының күренекле вәкилләре хакында язылган мәкаләләр шактый күп. Шулар арасында танылган мәгърифәтче, тарихчы-этнограф, тел, әдәбият, фольклор белгече Каюм Насыйрига багышлап язылган берничә язма да бар. Әлеге мәкалә кысаларында шул публикацияләргә игътибарны юнәлтеп, Г. Исхакый иҗатында К. Насыйри шәхесенә, иҗатына бәйле аерым фактларны барлау да төп максат итеп куелды.

Тарихчы Р. Әмирхан язганча: «Исхакыйның публицистик һәм журналистик эшчәнлегенең башы, безгә билгеле мәгълүматларга караганда, 1902 елда башланган. Бу эшчәнлеккә этәргечне татарның олуг мәгърифәтчесе К. Насыйриның вафаты биргән булса кирәк. Мәгърифәтченең үлеменнән тетрәгән яшь әдип "бер сулыш белән" җеназа мәрасиме (некролог) язып чыга һәм "Мәшһүр мөхәррир" дигән исем белән "Тәрҗеман" гэзитендә бастырып чыгара» [1: 298]. Г. Исхакыйның мәгърифәтче галим вафатына карата язылган некрологы «Тәрҗемән» газетасының 1902 елгы 15 сентябрь санында «Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый» имзасы белән басылган [4: 388]. Г. Исхакыйның 15 томлык «Әсәрләр»енең 6 нчы томына ул «Габделкаюм әфәнденең вафаты (Казаннан мәктүб)» дип кертелгән [4: 6–7]. Некрологтан соң түбәндәге искәрмә урнаштырылган: «Мәрхүм Габделкаюм әфәнде гомерендә ляземгә кадере беленмәеп, бәгъдәи вафат (вафатыннан соң) заман кәгдекчә (үткәннән соң) наме вә шөһрәте артачак вә рухына догалар җәмегъ идәчәк адәмләрең бередер (Рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән!)» [4: 388–389]. Газетаның рус телендә басылып чыккан «Переводчик» дигән өлешендә некрологның тәрҗемәсе урнаштырылган. Г. Исхакый үзе язганча, аның әлеге язмасы берничә көннән соң Төркиянең «Икъдам» газетасында да дөнья күрә [7: 162].

Некрологның күләме зур түгел. К. Насыйрины мәшһүр мөхәррирләр рәтенә кертеп, Г. Исхакый аның татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү юнәле-

шендәге эшчәнлегенә басым ясый, 38 фәнни хезмәт бастырып чыгаруы турында язып чыга. Шулар арасында «Ләһҗәи татари» сүзлеген аерым билгеләп үтә. Галимнең татар теленең «гүзәл бер дил ула булачагыны мәйданә куймыш мәрхүм Габделкаюм әфәндедер», – дип белдерә [4: 6–7]. Мәкаләдә шулай ук К. Насыйриның мөгаллимлек эше, календарьлар чыгаруы да искә алына. Д.Ә. Хәбибуллина билгеләп үткәнчә, Г. Исхакый беренчеләрдән булып мәгърифәтченең православие дини белем бирү системасындагы хезмәтен факт буларак терки һәм әлеге чорны галимнең фәнни эшчәнлегендә уңышлы дәвер дип саный [10: 46].

Г. Исхакыйның К. Насыйрига багышланган икенче мәкаләсе 1925 елда «Төрек йорты» журналының 11 нче август санында «Гаяз Исхакый» имзасы белән төрек телендә басылган. Ул галимнең 100 еллыгы уңаеннан язылган. «Габделкаюм Насыйри» дип исемләнгән әлеге мәкаләне язучы татарларның дәүләтләрен югалту чорыннан башлап җибәрә һәм мөшкел хәлгә төшкән халкын коткару өчен К. Насыйри алып барган эшчәнлеккә игътибарны юнәлтә. «Бүген тууына 100 ел тулу мөнәсәбәте илә телгә алынган Габделкаюм әл-Насыйри русларның “милли юл эзләнешләреннән” тиешле гыйбрәт алган һәм бу фикерне Идел-Урал буе халкына төшендереп, милләте өчен дөрес юнәлешле тынычлыкка куйгандыр», – дип яза Г. Исхакый [6: 305]. Фикерен дәвам итеп, әдип К. Насыйри тоткан юлны да ачыклап бирә: «Ул да – миллиятне саклап, Аурупа мәдәниятен кабул итеп, Аурупа рәвешендәге фикерләүне кабул иттерү» [6: 306].

Некрологта Г. Исхакый мәгърифәтченең эшчәнлегенә кыскача гына тукталса, биредә инде аның һәрбер юнәлешен аерып чыгарырга тырыша: 1) астрономия фәненә нигезләнгән мәгълүматларны эченә алган календарьлар бастырып чыгару; 2) гәзитә нәшер итәргә омтылыш; 3) мәктәп һәм мәдрәсәләрнең үзгәртеп кору эшен башлау; 4) Аурупа мәктәпләрендә укытылган фәннәрнең (математика, медицина, тарих, география һ.б.) дәреслекләрен җирле төрек шивәсенә тәрҗемә итү; 5) русча грамматика һәм русча-татарча сүзлек төзү [6: 306–307]. Галимнең хезмәтләре арасыннан «Ләһҗәи татари»дан тыш биредә шулай ук «Фөвакиһел җөләсә» «зур әдәби әсәре» дә билгеләп үтелә. Некрологта К. Насыйриның 38 хезмәте барлыгы турында хәбәр ителсә, әлеге мәкаләдә Г. Исхакый: «Каюм Насыйри кырык ике китап белән берничә тәмамланмаган кульязмалар калдыргандыр», – дип яза [6: 307].

Г. Исхакыйның К. Насыйри турында язылган иң күләмле мәкаләсе «Гаяз» имзасы белән 1937 елда «Яңа милли юл» журналының 10 нчы санында дөнья күрә [7: 394]. Мәкалә Г. Исхакыйның галим турындагы истәлекләре белән башланып китә: «Габделкаюм Насыйрины мин шәхсән таный идем. ... Шул вакытларда, тәхминән 1895–1896 елларда, мин Габделкаюм Насыйриның шактый күп әсәрләре берлә дә танышкан идем вә берничә мәртәбә Печән базары тирәсендә камчат бүрекле, иске модалы киң җиләнле, читек-кәвешле, урта буйлы Сукыр Каюмны очратканымны да хәтерләтәм. Аның хакында мәдрәсәдә төрле-төрле хикәяләр дә сөйләнә иде» [7: 160–161].

Г. Исхакый К. Насыйри янына өч тапкыр килгәнен тәфсилләп язып чыга. Беренчесендә ул галим торган йортка иптәше белән килә: «Ниләр хакында сөйләвебезне хәзер онытттым. Ләкин аның кыяфәте күз уңымда

тора: ул кыска казакидан, ялан аягына башмак кигән көтнчә безне каршы алды. Күзе зәгыйфьлеге бик ачык күренә иде. Өенең бер тарафында бик күп шүрлекләргә бик күп китаплар тезелгән иде, алдына бик күп кәгазьләр берлә тулган гаять гади бер өстәл куелган иде» [7: 161]. Икенче тапкыр Г. Исхакый мәгърифәтче янына ялгызы бара. Бу очрашуда К. Насыйри аңа русча укуның кирәклеге хакында сөйли, әсәрләрен күрсәтә һәм аш белән сыйлый. Өченче тапкыр Г. Исхакый галим янына «Русча-татарча лөгать» китабы сатып алу максатыннан килә [7: 161].

Г. Исхакый мәкаләсенең зур өлешен К. Насыйри холкы-табигате, гамәлләре турында уйланулары тәшкил итә. Шунысы мөһим: әлеге язганнар чор мохитен, укымышлы татар даирәсендә хөкем сөргән вәзгыятьне күзалларга мөмкинлек бирә. Биредә җәмгыятьтә К. Насыйрига карата урнашкан мөнәсәбәт тә ачык сиземләнә.

Мәкаләдә Г. Исхакый галим турында үзе язганнарны да барлап чыга. Мәсәлән, некрологтан тан соң ул К. Насыйри шәхесенә үзенең танылган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә мөрәҗәгать итүен ассызыклый: «Мәрхүм хакында ул вакытларда минем икенче язуым, үземнең “Инкыйраз” исемле әсәремдә иде. Анда мин аны милләтне сакларга тырышучы, милләтнең үзлеген мөхафәзә итүгә үзен корбан итүче бер галим кеби язып, бераз хыялый сыйфатлар да кушкаладым. Безнең үз кешеләребез, үз милли хезмәтчеләребезне күтәрүне, аларны зурайтуны рус хөкүмәте яратмаганга, Петербург цензоры Габделкаюм Насыйри хакында язганнарымның өчтән икесен кызыл каләм берлә бозып җибәрде» [7: 162]. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә К. Насыйри ике урында атап үтелә. Аның беренчесе пароходның «Габделкаюм әл-Насыйри» исеме белән аталуына бәйле. Икенчесендә исә Җәгъфәр К. Насыйрины Ш. Мәрҗани белән бергә хәтереннән кичерә. Г. Исхакый «Әсәрләр»енең 12 нче томын төзүче, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче текстолог галим З. Мөхәммәтшин сүзләренә таянып фикер йөртсәк, әлеге мәкаләсендә Г. Исхакый «әсәрнең төп һәм бердәнбер герое Җәгъфәргә К. Насыйриның прототибы салынуын ачыклап уза» [7: 396].

К. Насыйри исеме әдипнең башка әсәрләренә дә килеп керә. Мәсәлән, Г. Исхакыйның «Теләнче кызы» романында Мансур исемле герой уйлана: «...Каюм әл-Насыйриның кырык ел әдәби хезмәте өчен татар галәменең бойкоты астында бөтен гомерене ялгызлыкта үткәреп, ачлыктан үлүе хәтеренә килә...» [2: 154]. «Мөгаллимә» драмасында Фатыйма «Сукыр Каюм»ны телгә ала [3: 296].

1915 елда басылган «Кизүдәге мәсьәләләремез» мәкаләсендә Г. Исхакый К. Насыйрины Ш. Мәрҗани, И. Гаспралылар белән бергә «татарның элгәреге мәдәният каһаманнары» рәтенә кертә [5: 69]. 1910 елда Төркиядә татар әдәбияты турында яңгыраткан докладында Г. Исхакый К. Насыйрины «хәзерге әдәбиятымызның тәүге хезмәтчесе» дип атап, түбәндәгеләрне җиткерә: «Әфәнделәр, саф Казан татарчасы китап язган Габделкаюм әфәнде эн-Насыйри булгандыр. Бу затка кадәр шималь төркиләре Шәрык төркисе илә, ягъни чыгтайча яза иделәр. Габделкаюм әфәнде хәзерге татар әдәбиятының бабасы, димәктер. Габделкаюм әфәнде исән вакытта аңа замандашлар тарафыннан тиешле дәрәҗәдә бәя бирелмәгән иде. Әмма хәзерге татар мөхәррирләре якты фикерле татарлар исемен иң зур хөрмәт белән

искә алган бер зат – ул да булса мәрхүм Габделкаюм эн-Насыйридыр. Габделкаюм әфәнде татар әдәбиятына нигез корды һәм шималь кышының тәэсиритенә каршы торырлык ныклы бер нигез корды. Габделкаюм эн-Насыйри заманында башланган милли уяну Казан татарларының әдәбиятына гына кагылмыйча, бөтен хәятларын да үз эченә алды» [4: 195]. Шушы ук мәкаләдә язучы К. Насыйриның мөхәррирлек эшенә, татар теле, әдәбияты тарихына, календарьлар нәшер итү, дәреслекләр төзүгә керткән өлешенә дә туктала [4: 196]. «Тюрки в СССР» мәкаләсендә исә Г. Исхакый, К. Насыйрины Исмәгыйль Гаспралы белән бер рәткә куеп, аларны төркиләрнең хәзерге милли хәрәкәтенең беренче идеологлары рәтенә кертә, аларның бер үк мәсьәләләрне чишү юнәлешендә милли тел, әдәбият, сәнгать, тарих, милли мәктәп турында уйланулары, икесенең дә татар телендә газета бастырырга омтылышларын билгеләп уза [8: 209].

Күренекле галим, журналист һәм нашир, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе Габделбари Баттал К. Насыйриның Г. Исхакый иҗатына тәэсире хакында түбәндәгеләрне язып чыга: «Каюм Насыйри тәэсире белән тугры юлга төшеп киткән вә тәхрир теле хакында икенче бер агым ясаган кешеләрнең мәшһүрләре: Заһир Бигиев («Гүзәл кыз Хәдичә», «Мөртәд», «Катыйлә»ләрне язучы), Муса Акъегет («Хисам мелла»), Һади әфәнде Максуди, Садри Максуди («Мәгыйшәт»), Гаяз Исхакый (башлап «Тәгаллемдә сәгадәт»не татарча язучы), Галиәсгар Камал вә башкалар», – дип язып чыга [9: 117].

Нәтиҗә ясап шуны билгеләп узарга мөмкин: К. Насыйри шәхесе, аның киңкырлы эшчәнлеге, күпсанлы хезмәтләре күренекле язучы Г. Исхакый иҗатына да йогынты ясаган. Мәгърифәтче галимне ул әдәби әсәрләрендә искә ала, аңа багышлап аерым мәкаләләр бастыра. Г. Исхакый К. Насыйрины татар дөньясының иң мөхтәрәм затларыннан санап, аны башка төрки халыкларга таныту юлында да үзеннән саллы өлеш кертә.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Әмирхан Р.* Гаяз Исхакый – журналист һәм публицист // Әмирхан Р. Иманга тугрылык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. Б. 298–312.

2. *Исхакый Г.* Теләнче кызы // Әсәрләр. 15 томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Б. 5–220.

3. *Исхакый Г.* Әсәрләр. 15 томда. 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 496 б.

4. *Исхакый Г.* Әсәрләр. 15 томда. 6 т.: публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 447 б.

5. *Исхакый Г.* Әсәрләр. 15 томда. 7 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 366 б.

6. *Исхакый Г.* Әсәрләр. 15 томда. 9 т.: публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 415 б.

7. *Исхакый Г.* Әсәрләр. 15 томда. 12 т.: публицистика / [томны төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл. Зөфәр Мөхәммәтшин]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 471 б.

8. *Исхакый Г.* Тюрки в СССР / Әсәрләр. 15 томда. 13 т.: публицистика / [томны төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл. Зөфәр Мөхәммәтшин]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. Б. 206–221.

9. Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Габделбари Баттал. Сайланма әсәрләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Габдулбари Баттал. Избранные сочинения / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Ш. Гарипова, А.Н. Хәсәнова, Г.М. Ханнанова; кереш сүз авторы А.Н. Хәсәнова. Т. 1. Казан: ТәһСИ, 2023. 20 нче чыг. 256 б.

10. *Хабибуллина Д.А.* Деятельность Каюма Насыри в православных религиозных учебных заведениях Казани // Гасырлар авазы=Эхо веков. 2023. № 1. С. 45–54.

УДК 811.512.145

# «ПОЛНЫЙ РУССКО-ТАТАРСКОМ СЛОВАРЬ, С ДОПОЛНЕНИЕМ ИЗ ИНОСТРАННЫХ СЛОВ, УПОТРЕБЛЯЕМЫХ В РУССКОМ ЯЗЫКЕ КАК НАУЧНЫЕ ТЕРМИНЫ» К. НАСЫЙРИ В ТЕРМИНОГРАФИЧЕСКОМ АСПЕКТЕ

***О.Н. Галимова***
*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье впервые в терминографическом аспекте исследуется часть «Иностранные слова» «Полного русско-татарского словаря, с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины» К. Насыри, который первым поднимает проблему фиксации терминов в специальном словаре и показывает возможности их представления. Рассматриваются словник словаря, особенности фиксации терминов. Анализируются созданные автором определения. Установлено, что семантика заглавного слова эксплицируется посредством эквивалентных соответствий, посредством определений, посредством определений и эквивалентных соответствий. Основная часть определений относится к родовым.
**Ключевые слова:** татарский язык, терминография, терминологический словарь, словари К. Насыри, фиксация терминов в словарях

The article for the first time examines the part «Foreign Words» of the «Complete Russian-Tatar Dictionary, with an addition of foreign words used in Russian as scientific terms» by K. Nasyri, who was the first to raise the problem of fixing terms in a special dictionary and show the possibilities of their presentation. Vocabulary of dictionary, peculiarities of terms fixation are considered. The definitions created by the author are analyzed. It has been established that the semantics of a header word are exploited by equivalent correspondences, by definitions, by definitions and equivalent correspondences. Most definitions are generic.
**Keywords:** Tatar language, terminology, terminology dictionary, dictionaries of K. Nasyri, fixation of terms in dictionaries

# К. НАСЫЙРИНЫҢ «РУС ХОРУФЫ ҺИҖАСЫ ҮЗРӨ МӨРӘТТӘБ ЛӨГАТЬ КИТАБЫ» ТЕРМИНОГРАФИК АСПЕКТТА

***О.Н. Галимова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

К. Насыйриның татар терминологиясен үстерүгә керткән өлеше галимнәр тарафыннан җентекләп өйрәнелә: төрле фәннәргә караган махсус хезмәтләре һәм сүзлекләре анализлана. Татарча беренче терминологик сүзлекнең К. Насыйри каләменә каравы күп кенә хезмәтләрдә билгеләп үтелә [7: 181]. Галимнәр К. Насыйри эшчәнлеген, нигездә терминологик аспектта карыйлар һәм «аерым тармакларга караган терминологияне татар телендә булдыру мәсьәләсен беренче булып күтәрүен», «татар сүзләрен термин буларак беркетүен, гарәп терминнарына татарча конкурентлар тудыруын» әйтәләр [8: 271]. Г.Г. Батыршина К. Насыйриның сүзлекләр төзү

өлкәсендәге эшчәнлеген дә өйрәнә: төп игътибарны «Ләһҗәи татари» (1895) сүзлегенә юнәлтеп, кайбер лексикографик мәсьәләләрне карый. Мәсәлән, сүзләрнең мәгънәләрен аңлату ысулларын җентекләп анализлый. К. Насыйриның синонимнар аша аңлату ысулын киң куллануын, антонимик, тасвири (җәелдерелгән һәм кыска), катнаш аңлатмаларның булуын әйтә. Аңлатмаларда икенче сүзгә җибәрү алымына игътибар итә. Омонимнарны һәм күпмәгънәле сүзләрне теркәүне карый. Теркәлгән терминнарның фән һәм профессиональ эшчәнлекнең кайсы тармакларына каравын күрсәтә. [3: 52–123].

Тәкъдим ителгән мәкаләдә К. Насыйриның «Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы» беренче тапкыр терминографик аспектта тикшерелә, бу исә татар терминографиясе тарихын өйрәнүдә, татар телендә терминологик сүзлекләр төзү һәм терминнарны сүзлекләргә теркәү ысулларын камилләштерүдә зур әһәмияткә ия.

Татар лексикографиясендә сан буенча русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр беренче урында тора. Махсус лексика да башта нәкъ менә шул сүзлекләргә теркәлә [9: 111]. Беренче терминологик сүзлек тә русча-татарча сүзлек белән бәйле. К. Насыйри «Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы»нда (1892) «Әлфаз әҗнәбия», ягъни «Чит сүзләр» исеме астында рус телендә термин буларак кулланыла торган алынмаларны терки. Галимнәр әйтүенчә, әлеге сүзлек XIX гасырның икенче яртысында эшләнгән сүзлекләрнең күренеклеләреннән берсе санала [8: 79]. Сүзлек 1904, 1911 елларда яңадан басылып чыга. Әлеге басмалар, тикшеренүчеләр күрсәтүенчә, беренче басмадан аерылмый [8: 93–94].

Сүзлекнең «Чит сүзләр» өлеше мөстәкыйль булмау, ә төп өлешкә өстәмә булу (ул хезмәтнең исемендә үк чагыла) сәбәпле, «Чит сүзләр» структур яктан төп өлешнең дәвамы булып тора. Аңа махсус кереш сүз бирелми. Шулай да сүзлекнең титул битендә автор болай ди: «Янә рус кәлимәләреннән башка рус телендә мөстәгъмәл булучы әҗнәби лөгатьләр (чит тел сүзләре), рус телендәге фөнүне шәтта истилахлары (төрле фәннәргә караган атамалар) – күбрәк чит тел сүзләредер, зикер кылынды» [6].

Сүзлекнең лөгатьлегенә килгәндә, анда, хезмәтнең исеменнән үк күренгәнчә, рус телендә термин буларак кулланылган сүзләр туплап бирелгән, барлыгы 1695 (+5) термин һәм терминологик сүтезмә. Сүзлекнең «Чит сүзләр» өлешен төп өлеш белән чагыштыру ике өлештә дә кулланылган сүзләр барлыгын күрсәтә. Мәсәлән, *гвоздика, клюква, лёнъ, майъс, яхонтъ, экзаменъ, экономія* сүзлек мәкаләләре ике өлештә дә тәңгәл [6: 29, 234; 65, 242; 73, 245; 76, 247; 226, 263; 224, 263]. «Чит сүзләр» өлешендә *айва* мәкаләсендә татар телендәге эквивалентларның урыны алмашынган, *крапива, лимонъ, магазинъ* мәкаләләренең татар өлешендә дублет (триплет), *камфара, анисъ, нарцисъ* мәкаләләрендә аңлатмалар өстәлгән [6: 5, 228; 69, 244; 73, 245; 76, 246; 63, 241; 6, 229; 89, 251]. *Ежевика, извѣстнякъ* мәкаләләрендә татар телендәге эквивалентлар үзгәргән. *Барсъ* мәкаләсендә аңлатма да өстәлгән, татар телендәге атамасы да алмаштырылган [6: 42, 238; 57, 239; 7, 231]. Күзәтелгән аерымлыклар К. Насыйриның терминнар өлешен махсус өстәмә сүзлек итеп эшләвен дәлилли.

Атамаларның тематикасы буенча сүзлек күп тармак сүзлеге булып тора. Монда биология (*зебра, зебу, дельфин*), медицина (*наркотизм*, *нерв, подагра*), сәяси-иҗтимагый (*император, губерния, нейтралитет*), хәрби (*артиллерия, кавалерия, иррегулярное войско*), транспорт (*кабриолет, каботажное судно*), метеорология (*изотермы*), астрономия (*Гершелев телескоп, метеорный камень, полярная звезда*), минералогия (*изумруд, корунд, опал*), лингвистика (*синоним, синтаксис, термин*) һ. б. ш. өлкәләрнең терминнары бар. Сүзлеккә күп кенә фән һәм фән тармакларының атамасы теркәлгән. Мәсәлән, *антропология*, *инсектология, терминология, фармакология, филология*. Сүз төркемнәре ягыннан караганда, теркәлгән атамаларның күпчелеген исем сүз төркеменә караган атамалар тәшкил итә. Моннан тыш сыйфат (*фактический, фальшивый, элементарный* и др.), фигыль (*бланшировать, гравировать, конвоировать*) һәм рәвеш (*аккуратно, оптом*) белән белдерелгән терминнар да бар.

Атамалар сүзлектә рус алфавиты тәртибендә урнаштырылган. Терминологик сүтезмәләр беренче компонент буенча теркәлгән. К. Насыйри аларны һәм туры, һәм кире сүз тәртибендә бирә. Бу исә терминологик сүтезмәләрне теркәүдә, бер яктан, бертөрлелек сакланмавын күрсәтсә, икенчедән, аларны теркәү мөмкинлекләрен ача:

*Исландский мох* ایسلان موکی / *ислан мүге*;

*Губка древесная* آغاچ کومبەسی / *агач гөмбәсе* [6: 237, 240].

Термин ачыклаучы компоненттан тыш киң кулланылганда, ул җәяләр эчендә дә бирелергә мөмкин:

*Блекота (черная)* قارا تیلبران / *кара тилбәрән* [6: 232].

Терминологик сүтезмәләр ыруг атамасыннан соң да, аңа кадәр дә бирелә:

*Фіалка трёхлистный* اوچ یافراق میلاوشه / өч яфраклы миләүшә;

*Фіалка* مغرو فقر چچکیدر خوش ایسلی قزلت زنکار چچکلی (میلاوشه) – منکشه / (*миләүшә*) мәгъруф кыр чәчәгедер, хуш исле кызгылт зәңгәр чәчәкле – *мәнәкшә*;

*Экономія* مصرفنی پخته توتو – مصرفنی صاقلاب توتو / мәсрафны пөхтә тоту – мәсрафны саклап тоту;

*Экономія политическая* (مملکتننك مصر فنی حقنده بر فندر) / мәмләкәтнең мәсрафы хакында бер фәндер [6: 263].

Сул якта, сүзлекнең рус өлешендә өтер аша, я җәяләр эчендә дублетлар китерелә:

*Гиппопотамь, бегемоть* قالون تیریلی حیوانلار جملەسندن بر حیواندر / калын тиреле хайваннар җөмләсеннән бер хайвандыр;

*Бадъянъ* (*китайскій анисъ*) بادیان / *бадыян* [6: 231, 236].

Бер үк мәгънәдәге терминнар шулай ук аерым баш сүзләр итеп тә бирелә, аннан алар махсус тамга белән берләштерелә:

Метерография } هواده ظهور ایتکان نرسهلر حقندا بر فندر / һавада зоһур ител-
Метеорология } гән нәрсәләр хакында бер фәндер [6: 249].

Сүзлекнең рус өлешендә рус телендә махсус хезмәтләрдә күзәтелә торган кыскартылмаларны күрергә мөмкин:

*Балдырьянъ (апт.)* سنبل جبلی / *сөнбел җәбәли*;

*Касатик болотн.* قلچ اوطی دیرلر بر نباتدر / *кылыч уты* диерләр бер нәбаттыр [6: 231, 242].

Сүзлек мәкаләләре төрле структурада. Билгеле булганча, сүзлек мәкаләсенең структурасы сүзлекнең тибына бәйле. Бертелле һәм икетелле сүзлекләрдә ул аерыла [5: 83]. Карала торган хезмәттә сул якта рус атамасы бирелә, уң якта аның татар телендәге эквиваленты китерелә. Иң гади сүзлек мәкаләләре шундый төзелештә. Мондый төзелеш, билгеле булганча, икетелле сүзлекләргә хас:

*жирафъ* زرافه / *зәрәфә*

*страусъ* توه قوش / *төя кош* [6: 258, 239].

Сүзлек мәкаләсенең уң ягы татар телендәге дублетлардан да тора. Андый сүзлек мәкаләләре шулай ук икетелле сүзлекләр өчен хас. Бер үк мәгънәдәге терминнар сызыкча аша да, яки теркәгече белән дә теркәлә:

*Мальва* ابه كوماچى – ماچى بور چاغى / *әбә күмәче – мәче борчагы;*

*Ленъ кукушкинъ* كوكو جيتونى ياكه كوكو توشاكى / *күке җитене* яки *күке түшәге* [6: 247, 245].

«Чит сүзләр» өлешендә теркәлгән сүзләрнең күпчелеге, гадәттә, яңа сүз булганга, К. Насыйри аларга аңлатмалар бирә. Мәсәлән, *акула, вигонь, гидра, гиена, дельфин, зебу, зебра* кебек хайван атамаларының мәгънәсе аңлату юлы белән ачылган. Мондый сүзлек мәкаләләре бертелле сүзлекләрне хәтерләтә.

Сүзлекнең татар өлеше еш кына аңлатма һәм татар эквивалентыннан оеша, ягъни катнаш структурада була. Аңлатма һәм эквивалентның урнашуына карап, сүзлек мәкаләләренең түбәндәге ике төрен күрсәтеп була: «баш рус сүзе – татар телендә аңлатма – эквивалент» и «баш рус сүзе – татар телендәге эквивалент – аңлатма»:

*Барсъ* معروق يرتقچ حيواندر – يولبارص / мәгъруф ерткыч хайван – *юлбарс*;

*Шакалъ* (چقال) بورى بلاب تولكى آراسندراق / (*чакал*) бүре белән төлке арасындарак [6: 231, 262].

Дублет атамалар булганда, сүзлек мәкаләләре әлеге модельләрнең «рус сүзе – эквивалент – эквивалент – аңлатма», «рус сүзе – аңлатма – эквивалент – эквивалент» асмодельләрендә оеша:

*Нарцизъ* (نرجس – نركس) خوش ايسلى چچكدر توبنده صوغانى بولور / (*нәрҗис – нәркис*) хуш исле чәчәктер, түбәндә суганы булыр;

*Амарантъ* / بر اولن اسميدر قطفه كلى ديرلر ياكه اتچ كيكريكى ياكه ماچى قويروغى / бер үлән исемедер, *катфә гөле* диерләр яки *этәч кикриге* яки *мачы койрыгы* [6: 251, 229].

Сүзлек мәкаләсенең «баш рус сүзе – татар телендәге эквивалент – аңлатма» моделе соңрак татар телендә тәрҗемәле-аңлатмалы терминологик сүзлекләр төзүдә нигез булып китә.

Терминография фәнендә сүзлекләрдә аңлатма бирү, ягъни семантизацияләү үзәк мәсьәләләрнең берсе булып тора. Терминны семантизацияләү ул предметның асыл һәм аерып торган билгеләрен ачу, предмет турындагы төшенчәнең, башка төшенчәләр белән мөнәсәбәтләрен ачыклап, махсус төшенчәләр системасында урынын күрсәтү дигән сүз [1: 40]. В.В. Дубичинский аны кардиналь проблема дип билгели [4: 552], чөнки терминнар билгеләмәсез була алмый [2: 11].

Тикшерә торган сүзлектә аңлатмалар күләм ягыннан бер-берсеннән нык аерыла: К. Насыйри аңлатмаларның бик кыскаларын да, озын, энциклопедик характердагыларын да иҗат иткән. Түбәндә кайбер биология

терминнарына бирелгән аңлатмаларны карап үтик, чөнки нәкъ менә әлеге атамаларга бирелгән аңлатмалар төрлелекләре белән аерылып тора. Кыска аңлатмалар ким эчтәлекле, аз мәгълүматлы. Аларда, гадәттә, ыруг-төр бәйләнешләре генә чагылыш таба. Үзенчәлекле билгеләр күрсәтелми. Бу сүзлекчедә мәгълүматның тиешле күләмдә булмавына бәйле булса кирәк, чөнки таныш үсемлекләр, хайваннарның атамалары тәфсиллерәк аңлатыла.

*Бекасъ* نوع اورداق / нәүгъ үрдәк;

*Саламандра* (سمندر) بر معروف حيواندر / (*сәмәндәр*) бер мәгърүф хайвандыр [6: 231, 257].

Гомумән алганда, К. Насыйри аңлатмаларда ыруг-төр бәйләнешләрен эзлекле чагылдырып бара: хайван атамалары аңлатмаларында ыруг төшенчәсен белдергән *хайван, кош, үрдәк, балык, маймыл*, үсемлек аңлатмаларында *агач, нәбат, үлән, чәчәк, җимеш* кебек сүзләрне куллана. Шунысын да әйтергә кирәк, автор аңлатмаларда ыруг төшенчәсен белдергән сүзләрдән мөмкин кадәр якынрак баскычтагысын алырга омтыла:

*Обезьяна* (مايمول) سوت حيوانلارى جملەسندن دورت قوللى حيواندر / (*маймыл*) сөт хайваннары җөмләсеннән дүрт куллы хайвандыр;

*Орангутангъ* اورمان كشيسى يغنى آدمكا بيك اوخشاغان مايمولدر / *урман кешесе* ягъни адәмгә бик охшаган маймылдыр [6: 251, 252].

Җәяләр эчендә объектның кайсы өлкәгә каравы әйтелгән кыска гына мәгълүматлы сүзлек мәкаләләрен дә ыруг-төр бәйләнешләре чагылган сүзлек мәкаләләре рәтендә карала:

*Бузина (черная)* (نباتاتدان) قارا بوزون / (*нәбататтат*) кара бузин [6: 232].

Шулай да кайбер аңлатмаларда ыруг-төр бәйләнешләре чагылыш тапмый. К. Насыйри терминнарның мәгънәсен ачуда практик якка игътибар итә: хайван һәм үсемлекләрнең шул вакытта актуаль булган кулланылыш үзенчәлеген күрсәтү белән чикләнә. Мондый аңлатмалар фәнни яктан информатив түгел, шулай да терминнарга аңлатмаларда өстәмә мәгълүмат буларак игътибарга лаек:

*Барсукъ* (بورصق) يونوندان نقاشلار قلم ياصارلار / (*бурсык*) йонынnан нәкашлар каләм ясарлар;

*Кампешевое дерево* كوك صاندال آغاچى بوياو عملنه استعمال قيلنور / *күк сандал агачы* буяу гамәленә истигъмал киленер [6: 231, 240].

Икенче төркем аңлатмаларда ыруг-төр бәйләнешләрен чагылдырган өлеш төрле өстәмә мәгълүмат белән баетылган. Ул, мәсәлән, объектларның тышкы күренешләрендәге таныш, күзгә бәрелеп торган билгеләрен күрсәтү, таралышы, яшәү үзенчәлекләрен әйтү, башка хайваннар, үсемлекләр белән чагыштыру рәвешендә бирелә. Мондый аңлатмалар эчтәлеге белән хәзерге чорда аңлатмалы сүзлекләрдәге аңлатмаларга якын торалар. Мәсәлән:

*Фазан* (معروف قوش) طاوق جنسندن جونى بيك ماتور / (*мәгърүф кош*) тавык җенесеннән, җоны бик матур;

*Казуаръ* (قازوار) هندستانده بر قوشدر توه قوش كبك / (*казуар*) Һиндстанда бер коштыр, төя кош кебек;

*Мамонтъ* فيل جنسندن قديم بر حيوندر حالا سوياكلرى موكوزلرى ير آستوندان و دينكز ايچنده تابولادر غايت اولوغ حيوان بولوب طوفانده نسلى كيسولمشدر / фил җенесеннән кадим

бер хайвандыр, халя сөякләре, мөгезләре йер астыннан вә диңгез эчендә табыладыр, гаять олуг хайван булып, туфанда нәселе киселмештер;

*Инфузорія* شول قدر واق جيواندر صوده بولور كه قورالسز كوز بلان كورمك ممكن توكل مكر خرده بين آرقلى قاراسنك كورنور / шулкадәр вак хайвандыр, суда булыр ки, коралсыз күз белән күрмәк мөмкин түгел, мәгәр хәрдәбин аркылы карасаң, күренер [6: 260, 241, 247, 240].

Аерым очракларда өстәмә мәгълүмат фәнни булмаган, ә бәлки халык арасында таралган хәбәр, имеш-мимеш рәвешендә булырга мөмкин:

*Гиена* بر يرتقچ حيواندر قبردن ميتلرنى الا ايمش / бер ерткыч хайвандыр, кабердән мәетләрне ала имеш [6: 236].

Кайбер сүзлек мәкаләләрендә мәгънәне тулырак ачу максатыннан чит тел терминнары да кулланыла. Мондый алымның тагын бер өстенлеге шунда: ул яңа сүзне инде билгеле мәгънәгә беркетә.

*Мимоза* افريقه نباتلارندان بر نباتدر آدمننك قولى تيسه شينكوب توشەدر شول جهتدن روسچه (بى طرون مينه) آتالور / Африка нәбатларыннан бер нәбаттыр, адәмнең кулы тисә, шиңеп төшәдер, шул җәһәттән русча «не тронь меня» аталыр [6: 250].

Шунысын да әйтергә кирәк: терминның мәгънәсен рус терминын да күрсәтеп тулырак ачу соңрак татар теленең аңлатмалы сүзлекләрдә киң кулланыла башлый.

Шулай итеп «Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы»нда бирелгән «Чит сүзләр» – аңлатма элементлары булган тәрҗемәле терминологик сүзлек. К. Насыйри терминнарны беренче тапкыр махсус сүзлеккә теркәү кирәклеген һәм мөмкинлеген күрсәтә, терминнарны сүзлеккә теркәү ысулларын тәкъдим итә, аларга аңлатмалар эшли. Бу сүзлек шуннан соң чыккан терминологик сүзлекләр өчен үрнәк булып китә.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Анохина Т.Я., Зайцева Т.Н.* Об одном из способов описания научной терминологии в специальных словарях // Известия МГТУ «МАМИ». 2013. № 1(15), Т. 6. С. 36–43.

2. *Бархударов С.Г.* Актуальные задачи лексикографии в области терминов // Проблематика определений терминов в словарях разных типов. Л.: Наука, 1976. С. 5–12.

3. *Батыршина Г.Г.* Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге. Казан: КДАТУ нәшр., 2007. 171 б.

4. *Дубичинский В.В.* Некоторые современные вопросы лексикографии. Rasprave: Časopis Instituta za hrvatski jezik i jezikoslovlje, Вып. 46, 2020. С. 547–566.

5. *Моисеев М.В.* Лексикография английского языка: учеб.-метод. пособ. Для студентов языковых специальностей. Омск: Изд-во ОмГУ, 2006. 92 с.

6. *Насыйри К.* Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы. Казан: Ун-т тип., 1892. 263 б.

7. Татар лексикологиясе: өч томда. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 392 б.

8. Татар лексикологиясе: өч томда. Казан: ТӘһСИ, 2018. Т. III. 2 кис. 464 б.

9. *Фасеев Ф.С.* Татар телендә терминология нигезләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 200 б.

УДК 821.512.145

# МӨХӘММӘТ ГАЛИ ИҖАТЫНДА КАЮМ НАСЫЙРИ ШӘХЕСЕ

**_Ф.Г. Галимуллин_**
_Казанский федеральный университет (Казань)_

В статье анализируется повесть Мухаммата Гали «Детство Каюма Насыйри» («Каюмның балалык чагы» на татарском языке), главный герой которой впоследствии стал видным просветителем, энциклопедическим ученым, писателем, фольклористом, издателем… Рассматриваются художественные средства, использованные писателем в создании художественного образа юного Каюма, а также его ближайшее окружение.
**Ключевые слова:** Каюм Насыйри, А. Пушкин, К. Фукс, Маскаринское медресе, Габденнасыйр Курсави.

The article analyzes the story of Mukhammad Gali "Childhood of Kayum Nasyiri" (in the Tatar language), the main character of which later became a prominent educator, encyclopedic scholar, writer, folklorist, publisher... The artistic means used by the writer in creating the artistic image of young Kayum, as well as his immediate environment are considered.
**Keywords:** Kayum Nasyiri, A. Pushkin, K. Fuchs, Maskarinsky madrasah, Gabdennasyr Kursavi

# ЛИЧНОСТЬ КАЮМА НАСЫРИ В ТВОРЧЕСТВЕ МУХАММЕТА ГАЛИ

**_Ф.Г. Галимуллин_**
_Казан федераль университеты (Казан)_

Балык Бистәсе ягы әдәбиятыбызга элек-электән талантлы иҗат кешеләрен бирә килгән. Миргазиз Укмасый, Яков Емельянов, Зәйнәп Бәширова, Фәрит Ибраһимов кебекләрнең исемнәрен искә төшерү дә күп нәрсә турында сөйли. Олы Елга авылы мулласы улы Мөхәммәт Гали каләм әһелләре даирәсенә Сатыш, Казанның Күл буе, Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәләрендә белем алып, Беренче бөтендөнья сугышларында катнашып, тимер рудникларында, балык промыселларында да эшләп, шактый белем һәм тормыш тәҗрибәсе туплап килә. «Аң» журналының 1914 елдагы саннарында басылган хикәяләре М. Гали дигән автор пәйда булуын хәбәр итә. Шуннан соң бу әдибебезнең әсәрләре бары тик шушы имза белән дөнья күрә. Хәтта 1956 елда вафатыннан соң бастырылган сайланма әсәрләр җыентыгын да «М. Гали» дип кенә исемләгәннәр. Күрәсең, Мөхәммәт дип әйтү атеизм хакимлек иткән еларда пәйгамбәребезне тагын бер тапкыр искә төшерү була дип тә уйлаганнардыр. Динебезгә һәм сыйнфыйлыкка кагылышлы нәрсәләр белән өркетелү беренче нәүбәттә язучыларның күңел халәтләренә, аннан инде иҗатларына да көчле йогынты ясаган. Андый тетрәнүләр М. Гали тормышында да була торган. Әйтик, утызынчы елларның икенче яртысында Казан дәүләт педагогия институтында әйбәт кенә эшләп килгән җиреннән ул әлеге уку йортын ташлап китәргә мәҗбүр була. Чөнки көн саен институттагы хезмәттәшләреннән кемнеңдер кулга алынуы

турында хәбәр ишетеп тетрәнергә туры килә. Милли кадрлар җитештерүче бу югары уку йорты аерым игътибар үзәгендә булган. Мондый шартларда үзенә нәүбәт җиткәнен кем генә салкын кан белән күтәреп тора алыр икән? Бу хәл аның тикшеренүләренең дә тематикасын билгели. Ягъни ул да совет хакимияте идеологиясе әлегә дошман итеп әверелдерергә өлгермәгән каләм әһелләре иҗатларын гына тикшерергә мәҗбүр. Без аның хезмәтләрендә шундыйлардан аеруча Г. Камал иҗатының төрле яклап, әйтергә кирәк, шактый тирән тикшерелгәнен күрәбез. Кызганыч, педагогия институтыннан китәргә мәҗбүр булу сәбәпле, ул хәтта хезмәтләрен кандидатлык диссертациясен яклауга куярга да җөрьәт итми. Тел-әдәбият институтында кече фәнни хезмәткәр булып эшләү белән генә канәгать итәргә тиеш була.

Бу очракта аның әдәби һәм фәнни эшчәнлегенең төрле тармакларына тукталмыйча, бары тик Каюм Насыйрига багышланган повестена гына игътибар юнәлтәсе килә. Бөек мәгърифәтченең тууына ике гасыр тулган бу елда бу табигый дә.

Әйе, М. Гали Каюм Насыйриның тормыш юлы, иҗаты, мәгърифәтчелек эшчәнлеге белән күп еллар кызыксынып яши, мавыгып өйрәнә. М. Гайнуллин раславынча, «кульъязмаларын җентекләп тикшерә, 1945, 1952 елларда әсәрләрен җыеп бастыруда катнаша, К. Насыйриның үзе һәм замандашлары (Гали Мәхмүдов һәм башкалар) турында мәкаләләр бастыра. Ахырда, шул чорны вәземләп өйрәнү нәтиҗәсендә «Каюм Насыйри» (яки «Бөек мәгърифәтче») исеме белән роман язу уена килә [2: 11]. Ул аны өч кисәктән язарга уйлый: «Каюмның балачагы», «Каюмның яшьлеге», «Каюмның фәнни-иҗади эшчәнлеге». Әмма, ни кызганыч, бары тик сиксән битлек беренче кисәген генә язып өлгерә. Гомере җитми. 1956 елда Хисам Мөхәмматов тарафыннан төзелгән «Сайланма әсәрләр» җыентыгында урын ала. 1958 елда аерым китап итеп тә басыла. Шуннан соң аның укучыларга тәкъдим ителгәне юк әле.

Әлеге әсәрне укып утырганда, хикәяләү кинәт кенә өзелеп калгач, ирексездән «их» дип сискәнеп куясың. Чөнки автор киләчәктә олуг галим булып үсәчәк, татарның рухи үсеше юлында фидакарьләрчә эш итәчәк Каюмның бу олы юлга ничек килеп чыгуын бик тә мавыктыргыч итеп сурәтләү барышында тукталып кала. Монда, әлбәттә, М. Галинең хикәяләү осталыгы, теленең гаять тә бай, образлы, йомшак һәм җанга ятышлы булуы да мөһим роль уйный.

Безнең уебызча, бу әсәрне язарга ниятләгәндә, М. Гали үз алдына мондый төп сорауны куйгандыр:

– Габделкаюм динебезне нечкәләп белгән, шәригать кануннары белән көн итүче гаиләдә туган, шул даирәдә тәрбияләнгән. Димәк, зирәк акыллы бу малайга дин әһеле булырга да бөтен шартлар булган. Әмма ни өчен ул халкыбызны мәгърифәтле итү юлыннан киткән?

Бу сорауга, сүз дә юк, бер-ике җөмлә белән генә җавап биреп булмавы көн кебек ачык. Шуңа күрә М. Гали роман язарга була. Иң мөһиме, ул үз әсәренең героен аз да түгел, күп тә түгел, халкыбызның бөекләре рәтендә күрә. Гап-гади авыл малаеның әнә шулай югары бәяләнерлек олпат шәхес булып өлгерү барышын укучыларга күрсәтеп бирүне максат итә. Ә бу исә җиңел эш түгел. Моның өчен Габделкаюмның нәсел-нәсәп, гаилә даирәсен генә түгел, заманның тулаем мохитен дә күз алдына яхшылап китерергә,

ягъни аны үз вакыты мохитендә яшәтергә кирәк. М. Гали исә аның замандашы түгел. Ул аңардан алтмыш сигез ел соңрак туган, ягъни герое белән үзе арасында ике буын гомерен эченә алган еллар аермасы ята. Романны язарга алынганда исә бу аерма йөз елдан да артып киткән, ягъни егерменче йөзнең дә уртасына җитеп киленә. Тарихи чыганаклардан билгеле булганча, әлеге бер гасырга караган елларда илебез гаять катлаулы үзгәрешләр кичерде. Аларның барлыкка килүенә К. Насыйри яшәгән 1825–1902 еллар арасындагы үзгәрешләрнең роле дә бик сизелерек булды.

М. Гали сурәтләвенчә, Габделкаюм туып үскән гаилә дә ул заман татар мохите өчен гадәти түгел. Аларның бабалары үз чорының укымышлыларыннан. Әтисенең мөселман дөньясында танылган акыл иясе, татар иҗтимагый фикере үсешенә билгеле бер юнәлеш бирүче Габденнасыйр Курсави (1776–1812) белән аралашып яшәгәнлеге үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Аның үз улына Габденнасыйр дигән исем кушуы да Г. Курсавига карата булган олы ихтирамын күрсәтә. Димәк, мәгърифәтче галим Габделкаюмның Насыйри тәхәллүсен алуының сәбәбе Г. Курсавина барып тоташа икән. Юкса, аның, бабасының исеме буенча, Каюм Хөсәен булып йөрү ихтималы да булган. Габделкаюмның әбисе (Хөсәеннең хатыны) Бибигамбәр дә Курсавины күреп калган икән. Ул аны болайрак тасвирлый: «Кечерәк кенә буйлы, чандыр гәүдәле, ач яңаклы, ияк очында сары сакаллы, уйчан йөзле, салмак кына сүзле». Шуны да әйтергә кирәк, Г. Курсавиның хатыны да Шырданныкы булган икән.

Хөсәен мулла улы Габденнасыйрга зур өметләр баглый. Әмма аны үзе теләгәнчә тәрбия кылып өлгерә алмый, шактый иртә вафат була. Малайны Зөядә сәүдәгәрлек итүче бертуган энесе Хәсән тәрбиягә ала. Ул вакытта әлеге бистәдә күбесенчә руслар яши. Шуңа күрә анда малайны үзебезчә укыту һәм тәрбияләү өчен мәдрәсә булмый. Уку яшенә җиткән малайны белем алудан мәхрүм итеп булмый бит. Сәүдә белән төрле төбәкләр белән бәйләнеш тотып яшәгән Хәсән абыйсы Россия шартларында рус телен белүнең дә кирәклеген яхшы белә. Шуңа күрә ул Габденнасыйрны, башлангыч әзерлек алу өчен, рус мәктәбенә бирә. Малай анда өч ел укый, ныклап рус телендә укырга-язарга, сөйләшергә өйрәнә. Укуын тагын да дәвам иттерер иде, әмма әнисе Бибигамбәр аны тәрбиягә алган Хәсәнгә болай ди:

– Балабыз мөселманча укый алмый кала бит, алай булмасын инде.

Әлбәттә, Хәсән бу хакта үзе дә уйлый. Ул малайны укыту өчен мәдрәсә сайлый. Казанда да әйбәт мәдрәсәләр бар барын. Әмма ул абыйсының зур өметләр баглаган улына Мәчкәрә мәдрәсәсен сайлый. Чыннан да, унтугызынчы гасырның утызынчы-кырыгынчы елларында бу уку йортының абруе еракларга таралган була. Габденнасыйр, дөрестән дә, биредә шактый әйбәт әзерлек ала. Йөрергә ераграк булгач, аны тора-бара Бәрәскә мәдрәсәсенә күчерәләр. Егет монда да биш ел белем эсти. Яшәү һәм дөнья көтү өчен җитәрлек белем алды дип санап, Хәсән абыйсы аны сәүдә эшенә якынайта. Үзе белән төрле ярминкәләргә, шәһәрләргә йөртә, хәтта Мәскәүдә дә еш булалар. Егет исәп-хисапка да әйбәт, русчаны да йөгерек сөйләшә. Ихтимал, шушы юнәлештән дәвамлырак барса, үзен дә шул кәсепкә багышлар иде. Әмма Хәсән абыйсының үлеп китүе аның тормыш барышын үзгәртеп җибәрә. Ул әнисе янына – Шырданга кайта. Аңа

муллалык вазифасын тәкъдим итәләр. Әмма ул моннан баш тарта. Юкса, авылда аның турында «указлы муллалардан да аңа чыкканы юк», диләр. Ул авылдашларының балаларын укытырга алына. Бу шөгыль аңа җан рәхәте бирә. Үз балаларына да, шул исәптән Габделкаюмга да башлангыч белемне үзе бирә.

Габденнасыйрның рус мәктәбендә бергә укыган дусты Иван Никитович һаман да Зөядә яши икән. М. Гали Габденнасыйрны шушы кешегә бәйләнешле рәвештә ачуга шактый кызыклы сәхифәләр багышлый. Әлеге рус кешесе Казан-Зөя, Зөя-Чабаксар арасында почта йөртә. Билгеле булганча, 1833 елда А.С. Пушкин Казанга килә. Аны Чабаксардан Казанга шушы Иван почта аты белән үзе илтә. Шагыйрьгә үз өендә дә хөрмәт күрсәтә. А.С. Пушкин белән бергә Казанда университет профессоры К.Ф. Фукста кунакта була. Әлеге Иван Никитович ярдәмендә Габденнасыйр К.Ф. Фукс белән таныша. Олы улы Габделхәй авырып киткәч, әлеге алман галименә мөрәҗәгать итә. Габденнасыйр белән К.Ф. Фукс арасында чын мәгънәсендә дуслык урнаша. Хәтта ул профессорга татарларның яшәү рәвеше, гадәт-йолалары турында мәгълүматлар җыярга булыша, гаиләсе белән җыен бәйрәменә дә алып кайта.

Инде алдарак әйтелгәнчә, Габденнасыйр ислам дине тәгълиматы буенча да нык әзерлекле була. Аның изге китабыбыз Коръәнне дистәләрчә данәдә күчереп язганлыгы мәгълүм. М. Гали дә сүз бара торган әсәрендә аның Г. Курсави тарафыннан иҗат ителгән «Әл-Иршад лил-гыйбад» («Кешеләрне туры юлга күндерү») дигән китапны күчереп язу эше белән мәшгуль булуын әйтеп уза. Бу китап ул елларда зыялыларыбыз арасында киң мәгълүм була, ул татар иҗтимагый фикере үсешендә билгеле хезмәт үти. Г. Курсави әсәренең тәнкыйди рухта икәнлеген заманында Г. Сәгъди дә билгеләп үткән. «Г. Курсави – ди Г. Сәгъди, – халык мәнфәгатьләрен күз алдында тотып эш итте һәм үзенең чыгышларында аның киләчәге тәрәккыять һәм мәгърифәт юлына басу, фәнни белемнәр һәм мәдәният казанышларын тарату белән бәйләнгән дип басым ясап күрсәтте» [3: 80].

Габденнасыйр үзе күчереп язган китаплар белән балаларын да таныштыргандыр, алардагы фикерләрне аңнарына җиткерә баргандыр дип уйларга кирәк. Әлбәттә, болар Габделкаюмның аңына да керә баргандыр. Нәтиҗә ачык: атаклы мәдрәсәләрдә белем алган, гарәп-фарсы, төрек телләрен үзләштергән, рус теленә дә чит-ят итеп карамаган гаиләдә Габдекаюмның халыкны мәгърифәтле итеп күрү теләге уяну, шул изге эшкә бөтен гомерен багышлавы бер дә гаҗәп түгел. Автор шулай ук Габделкаюмның дөньяга карашы формалашу барышына җәмгыятьтәге хәл-әхвәлләрнең дә йогынты ясап торганлыгын күрсәтергә дә онытмый. Тик бу әле башлангыч хәлдә генә кала. Күрәсең, ул бу якларны алдагы кисәкләрдә тагын да киңрәк ачарга тиеш булгандыр. Шулай да Казандагы агач эше остасына өйрәнчелеккә бирелгән Габделкаюмның – паштa хакимиятенең эшчеләргә карата рәхимсез мөнәсәбәтен күргән малайның – үзе өчен тиешле гыйбрәт алганын сурәтләргә өлгерә. Сукно фабрикасы эшчеләренең эш шартларын бераз гына булса да җиңеләйтүләрен сораган үтенечкә кул куйганнары өчен генә дә йөзләрчә тапкыр камчы белән суктыруларына шаһит булу яшүсмер күңелендә нинди хисләр уятуы әйтмәсәң дә аңлашыла. «Бу күңелсез вакыйга, – ди М. Гали, – 1837 елның 29 январь көнендә булды. Шуннан

берничә көн узгач, суконщиклар җәзаланган шул көнне русның бөек шагыйре А.С. Пушкинның да фаҗигалы рәвештә һәлак булуы турында Казанга хәбәр алынды. Габделкаюм бу көнне гомергә хәтереннән чыгармады»,– дип, хикәяләү өзелеп кала [1: 289].

Әмма укучы Мөхәммәт ага Галигә, олуг мәгърифәтчебез хакында мондый әсәр язып калдырганы өчен, бик рәхмәтле. Чөнки ул Каюм бабабызның галимлек, мәгърифәтчелек һәм тагын башка күп кенә игелеклеле юнәлешләрдә халкыбызга хезмәт итүгә килүенең сәбәпләрен аңларга ярдәм итә. Әсәрне бүгенге укучыларга да җиткерергә кирәклеге үзеннән-үзе аңлашыла.


ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Гали М.* Каюмның балалык чагы // Сайланма әсәрләр. Казан: Таткнигоиздат, 1956. С. 199–289.
2. *Гали М.* Сайланма әсәрләр. Казан: Таткнигоиздат, 1956. 374 с.
3. *Сагди Г.* Курсави Әбунасыйр // Ислам: белешмә-сүзлек. 1993. Б. 79–81.



УДК 821.161.1


# РЕЦЕПЦИЯ ТВОРЧЕСТВА КАЮМА НАСЫРИ В СОВРЕМЕННОЙ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ


*Исследование выполнено при финансовой поддержке гранта РНФ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта «Проведение фундаментальных научных исследований и поисковых научных исследований малыми отдельными научными группами» (региональный конкурс)» № 24-28-20211*



***А.Ф. Галимуллина***

*Казанский федеральный университет (Казань)*



В статье рассматривается рецепция творчества Каюма Насыри в современной татарской литературе. В поэме «Каюм коесы» («Колодец Каюма») Эльмира Шарифуллина, используя символику образов колодца, родника обращается к теме памяти и бережного обращения к духовно-нравственным традициям татарских просветителей. К каждой из семи частям поэмы предпосланы эпиграфы из высказываний Каюма Насыри о татарском языке, об обучении детей, с которыми автор вступает в поэтический диалог в данной части. В поэме создается символический образ колодца Каюма Насыри, который сохранился на протяжении двух веков, который вселяет надежду на дальнейшее сохранение татарского языка, татарской литературы и культуры, несмотря на грустные размышления об их современном состоянии. Равиль Бухараев в произведениях разных жанров художественно осмысливает образ Каюма Насыри. В драматической пьесе-сказке «Железная горошина», написанной по мотивам татарских народных поверий Р.Р. Бухараев создает образ Насыра-бабая, чудаковатого деревенского ученого, который знает латынь, собирает фольклор и посвящает пьесу Каюму Насыри и Габдулле Тукаю.



**Ключевые слова:** художественная рецепция, современная татарская литература, Эльмира Шарифуллина, Равиль Бухараев, Каюм Насыри.



The article examines the reception of Kayum Nasyri’s work in modern Tatar literature. In the poem “Kayum koesy” (“Kayum’s Well”), Elmira Sharifullina, using

the symbolism of the images of a well and a spring, addresses the theme of memory and careful treatment of the spiritual and moral traditions of Tatar educators. Each of the seven parts of the poem is preceded by epigraphs from Kayum Nasyri's statements about the Tatar language, about teaching children, with whom the author enters into a poetic dialogue in this part. The poem creates a symbolic image of Kayum Nasyri's well, which has survived for two centuries, which instills hope for the further preservation of the Tatar language, Tatar literature and culture, despite the sad thoughts about their current state. Ravil Bukharaev artistically comprehends the image of Kayum Nasyri in works of different genres. In the dramatic fairy tale play "The Iron Pea", written based on Tatar folk beliefs by R.R. Bukharaev creates the image of Nasyr-babai, an eccentric village scientist who knows Latin, collects folklore and dedicates the play to Kayum Nasyri and Gabdulla Tukai.
**Keywords:** artistic reception, modern Tatar literature, Elmira Sharifullina, Ravil Bukharaev, Kayum Nasyri.

Личность и творчество выдающегося татарского писателя, ученого, философа, педагога Габделькаюма Насырова – Каюма Насыри (14 (2) февраля 1825 – 20 августа (2 сентября 1902 года) в разное время привлекает внимание писателей Республики Татарстан. Отметим, что образ Каюма Насыри воплощается в произведениях разных жанров. Например, пьесы Мухаммеда Гали и Хусаина Уразикова «Каюм Насыри» (спектакль Татарского академического театра им. Г. Камала), Равиля Бухараева «Улица Каюма Насыри» (снят телевизионный спектакль в 1989 году), повести Мухаммата Гали «Детство Каюма Насыйри» («Каюмның балалык чагы» на татарском языке), Рафиса Ахметова «Звезда татарской зари», Нур Ахмадиев «Каюм Насыри», поэтесса Эльмира Шарифуллина написала поэму «Каюм коесы» (1997) [5; 6; 8]. В ряде произведений Каюм Насыри упоминается в связи с характеристикой главного героя или для создания исторического фона в произведении. Такой прием рецепции часто использует в своих произведениях Равиль Бухараев, создававший свои произведения на русском языке.

Так, например, в пьесе «Железная горошина», по которой в 2005 году был поставлен спектакль в Татарском академическом театре им. Г. Камала, Каюм Насыри выведен в образе чудаковатого деревенского ученого, знающего латынь, собирателя фольклора, а сама пьеса имеет посвящение: «Высокой памяти светочей тысячелетней культуры КАЮМА НАСЫРИ, записавшего народные поверья и обряды, и ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ, увидевшего в Заказанье голубую корову ПОСВЯЩАЕТСЯ» [2: 28] (Отметим, что мы воспроизвели авторское оформление текста прописными буквами). В поэме «Вокруг Тукая. Комментарии к любви» (1983) [1; 3; 4]. Заметим, что автор обозначил жанр этого произведения как роман в стихах. В поэме действие происходит в двух временных пластах: в 1912 и 1983 году: *«Два времени, два мира ощущая, / терпя эпох трагический разрыв, / я слышу, как, пространство освящая, / звучит валторны и трубы надрыв…»* [4].

Каюм Насыри упоминается в этой поэме контекстно и служит для характеристики и описания улицы, ныне улицы Каюма Насыри. Показательно, что, сравнивая видных татарских просветителей XIX века, автор отдает предпочтение Каюму Насыри: *«Напомнив дни Алмушей, Утямышей, /*

*с угла Евангелической на треть, / зазеленев четырехскатной крышей, / явилась взору старая мечеть. / Не обликом барочного фасона / напомнила она былые дни, / а тем, что здесь муллой во время оно / служил историк Булгар – Марджани. / Он был в священном деле просвещенья / в ряду с самим Каюмом Насыри!»* [4].

Личность и творчество Каюма Насыри постоянно присутствует в поэтическом сознании Равиля Бухараева в виде цитат, аллюзий, реминисценций. В сказке-пьесе «Железная горошина» Насыр-бабай является носителем мудрости, именно ему Р.Р. Бухараев доверяет самые ответственные высказывания, которые выражают авторскую позицию. Насыр-бабаей жалуется Сарвар-аби на то, что иссякли все сказки, что они никому ненужны: *«А кому это нужно, в конце-то концов? / Поверья дедов, сказки отцов...»* [2: 36].

В современном прагматичном мире тяжело жить среди корысти и зависти, злобы, скупости, глупости. Больше всего не любят сказки прагматичные люди (Гали) и мифологические образы (в сказке – это Юха, Див), поэтому Насыр-бабай мечтает о чудесах, о встрече с Водяной, Шурале: *«Как в юности, скитаясь по земле, / мечтал я в чаще встретить Шурале! / Не испугался б я и Водяного»* [4: 37]. В пьесе-сказке Р.Р. Бухараева образ Насыра-бабая представлен как носитель народной мудрости, как собиратель и хранитель народных преданий, пословиц, традиций, которые помогают положительным героям справиться с мифологическим олицетворением зла – Юхой.

Завершает пьесу монолог Насыр-бабая о родине, о родной земле, в который добавляются реплики других персонажей: *«Край мой отчий! / печаль иль счастье в крови, / не оскудей силой веры, надежды, любви! / Боль иль радость даруй нам, / Сказанья храни... <...> Да, это чудо! / Заря над родимой землей...»* [4: 81]. Лейтмотивом пьесы Р.Р. Бухараева становятся народные песни «Тяфтиляу» и «Ал Зейнабым», мелодией «Ал Зейнабым» завершается пьеса.

Обращение к образу Каюма Насыри в современной пьесе-сказке воспринимается как продолжение традиции, которую заложил в своем творчестве Каюм Насыри, создав повесть «Повесть об Абу-али-Сине» (1872), посвященную таджикскому ученому Ибн-Сине, следует также отметить труды Каюма Насыри по татарскому фольклору: «Памятники народной литературы казанских татар», «Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов» (в соавторстве П. Поляковым).

В цикле «Старинные истории», состоящем из двух произведений разных жанров: рассказа «Раскрытие неопределенностей» и пьесы «Улица Каюма Насыри» Р.Р. Бухараев размышляет о судьбах родного языка, о вопросах литературного образования татар. Отметим, что Р.Р. Бухараев оригинально обозначает жанр пьесы-сценария телевизионного спектакля как исторические светотени в двух действиях

В этом цикле образ Каюма Насыри возникает в тесной связи с Казанским университетом и это неслучайно: известно, что татарский просветитель был вольнослушателем Казанского университета, состоял в «Обществе археологии, истории и этнографии». В цикле «Старинные истории» синтез художественного и документального обуславливается уже

самим автором в примечании о том, что диалоги исторических героев составлены с использованием их публикаций в периодической печати и их просветительских трудов.

Образ Каюма Насыри появляется уже в рассказе «Раскрытие неопределенности» (1989), в котором русско-татарская школа, открытая в Казани Каюмом Насыри, представлена через призму взгляда миссионера, инспектора В. Радлова и Каюма Насыри. Богатый внутренний мир Каюма Насыри противоречит его внешнему облику, его вынужденно скитальческой жизни, бытовой неустроенности. Финал рассказа Р.Р. Бухараева остается открытым, в нем появляется прямая авторская речь русскоязычного писателя, который «*думает*» по-русски (курсив автора рассказа): *«Я, бывший математик и сущий сочинитель, природный татарин, мог бы при легком усилии памяти изложить все вышесказанное на нескольких европейских языках, и пуще того, на татарском, но при этом думал бы я все равно по-русски, как повелось с детства, и не один я таков»* [5: 151]. Эта речь переносит читателя в современность и приглашает к размышлениям о судьбе татарского языка через математическую категорию «неопределенности».

В пьесе «Улица Каюма Насыри» Р.Р. Бухараев преобладает художественное начало над документальным. После чтения рассказа «Раскрытие неопределенности» читателю более понятны те, проблемы, которые волнуют Каюма Насыри, как просветителя XIX века, и автора, как представителя XX века. Фактически пьеса начинается с того, чем завершил рассказ Р.Р. Бухараев – с постановки проблемы незнания современной молодежью татарского языка, истории татарского народа, его выдающихся просветителей. Один из персонажей пьесы – Ахмет, молодой человек с университетским дипломом астронома не выдержал экзамена своего будущего тестя – простого таксиста. В возмущенной речи Ахмета типичные аргументы, которые приводят все, кто не знает своего родного языка: *«А кто сейчас знает из университетских моего возраста? По-настоящему – почти никто... Так мало ему этого! Я, говорит, живу на улице Насыри, что про Насыри знаешь? Я – то-се, просветитель, говорю, а больше-то и не знаю... А вот, опять спрашивает, почему мечеть Марджани на нашей улице так называется? А я вообще без понятия. Ну и что? Я же не татарскую школу кончал...»* [5: 153]. Жанр пьесы Р.Р. Бухараев обозначил как исторические светотени в 2-х действиях. Этому соответствуют декорации, описанные автором в афише: «Автору пьеса видится с минимумом декораций, но с использованием слайдов старой Казани. Действие происходит в наши дни, а также с 1866 по 1886 годы. Диалоги реальных персонажей основаны на подлинных документах эпохи» [5: 152].

В этой пьесе Р.Р. Бухараев использует свой любимый прием: вводит два временных пласта: современность – 1970–1980-е годы и прошлое – 1866–1886-е годы – время жизни Каюма Насыри, Шигабетдина Марджани. В пьесе «Улица Каюма Насыри» персонаж Ахмед открывает в себе дар видеть сквозь время. В пьесе три героя легко перемещаются во времени: Ахмет, линотипист, он же типографский работник, отец Зухры (возлюбленная Ахмеда в современных главах, она же жена Каюма Насыри) Мусагит, который предстает в современных действиях таксистом, а в прошлом – извозчиком. Наиболее символично перевоплощение Ахмета в немого нищего,

слугу Ахметшу. В этом превращении символически представлен немым человек, который не знает родного языка.

В диалогах Насыри с наборщиком, с Марджани, Радловым отчетливо проявляется авторская позиция в оценке просветительской деятельности Каюма Насыри: его усилия по открытию газеты на татарском языке «Утренняя звезда», планы по изданию календарей, а также его деятельность по обучению детей русскому языку, его убежденность в необходимости просвещения татарского народа: «… В России живем: сколько мудрости, сколько науки – все на русском языке! Но по одному много ли учеников научишь? Нужна целая школа…» [5: 189]. Многие идеи, цитаты из трудов Каюма Насыри раскрываются в его диалогах с наборщиком, например, беседа о том, как преодолеть межнациональную рознь и об одиночестве ученого-просветителя. В финале пьесы «Улица Каюма Насыри» персонаж не ощущает себя одиноким, потому что много соратников, вышедших из татарского народа, активно занимаются просветительской деятельностью: *«Я часто встречаюсь с достойными людьми на заседаниях Общества, и в труде совсем – не одинок. Сколько людей теперь отдает время и силы делу просвещения? Марджани, Ильяси, Акмулла, многие, многие… Аитов, Шамсутдин Культяси… Стремления к знаниям, к изучению народной истории, культуры уже никого не остановит… Да и я еще могу работать, вопреки всем разочарованиям...»* [5: 224]. По убеждению Каюма Насыри, только знания народов друг о друге позволят преодолеть национальную рознь.

В финале Р.Р. Бухараев использует традиционный предмет – зеркало для перенесения Ахмета в современный мир. Ахмет, уже обогащенный историческими знаниями по-другому смотрит на современный мир, уже он задумывается о будущем, которое вызывает у него тревогу, поэтому пьеса завершается риторическим вопросом: «Я-то еще сумею прочитать. Я корни свои не забыл. А дети мои сумеют ли? Захотят?». Зухра отвечает: «Ну, об этом еще говорить рано!». Последняя многозначная реплика-вопрос Ахмета обращена к залу: «Рано? Вы думаете, что еще рано?!» [5: 228].

В пьесе личность и деятельность Каюма Насыри представлена в оценке различных героев: татарских святоши и торговца резко отрицательная, тесть Мусагит по-человечески сочувствует, но не понимает просветителя, его жена Зухра безоговорочно любит и верит ему, оценка исторических лиц имеет документальную основу, дается по их публикациям, так, в оценке миссионера Н.И. Ильминского акцентируется, что деятельность Каюма Насыри направлена на развитие национального духа татар, инспектор В.В. Радлов не понимает методов обучения, применяемых им в русско-татарской школе. В рассказе глубже раскрыты идеологические споры-противоречия Каюма Насыри с русскими миссионерами, четко выражена авторская позиция, то в пьесе через диалоги, взаимоотношения героев, а также другими сценическими приемами (декорации, различные места действия, множество сценок-эпизодов) автор непосредственно воздействует на читателя, позволяет «оживить» главного героя, дать множественную оценку его деятельности.

Поэма Эльмиры Мухаметовны Шарифуллиной «Каюм коесы» («Колодец Каюма», 1997) написана на татарском языке. Поэма состоит из семи

глав, каждая разделена на части и предваряется эпиграфами из трудов Каюма Насыри, цитатами из классиков и современных писателей и исследователей, что создает диалогичность текста, существенно расширяет содержание поэмы.

Уже во вступлении автор раскрывает реальное и символическое значения названия поэмы. Отталкиваясь от реального факта – на родине Каюма Насыри в селе Малые Ширданы Зеленодольского района РТ (современное название села) бережно сохраняется колодец, вырытый самим просветителем. Этот исторический факт позволяет поэтессе сделать обобщение, касающееся научного, художественного и научно-просветительского наследия Каюма Насыри: *Гасырларны кичеп исән калган, / Исән калган Каюм коесы, / Күпме чишмә юлын югалтканда, / Адашканда – иң мул сулысы, / Насыйрийлар нәсел агачының / Бер тылсымы булып, / Ядкяре, / Нуры булып изге гамәлләрнең, / Бер әдәбе булып, / Әхлагы – / Исән калган кое / Һәм бүген дә / Тибеп тора көчле чишмәсе. / Ничә килеп, Күпме мәртәбәләр / Сындырганнар булыр / Сиртмәсен...»* [8: 28]. Традиционная символика родника, колодца как символа знания, преемственности, чистоты закреплена как в татарской мифологии и литературе, так и русском фольклоре и литературе и в культуре народов мира. Как отмечает Е.В. Голубева, «колодец – это с одной стороны символ жизни (в силу того, что является источником воды), а с другой стороны, – символический вход в страну мертвых, в другой мир, и потому имеющий волшебные свойства. Колодец дает возможность исполнить желание, заглянуть в будущее, достичь нового чудесного перерождения в совершенно другом качестве. Недаром он является знаком инициации. Издавна люди приходили к колодцам в поисках исцеления и предсказания» [7].

В поэме Э.М. Шарифуллиной колодец также приобретает сакральный смысл, наделяется способностью само возрождаться, он наполнен святой водой знания. Эту же смысловую функцию выполняют два эпиграфа, предпосланные к первой главе поэмы: первое высказывание Каюма Насыйри о том, что его трудами воспользуются последующие поколения и цитата из статьи Г. Гайфуллиной о том, что в родном селе К. Насыйри в деревне Верхние Ширданы (Югары Шырдан) Зеленодольского района Татарстана сохранился колодец Каюма Насыйри.

Во второй главе поэмы автор, обыгрывая известную татарскую пословицу «учиться – это копать колодец иголкой» *(«Белем малу –/ Кое казу, диләр, / Энә белән казу – коены»)* [8: 29]. размышляет о сущности творчества, которое должно служить народу, быть полезным ему, а также обладать высокой художественности. Эталоном такого служения через литературное творчество выступает Каюм Насыри: *«Гыйлем сөйгән Каюм бабабызның / Таза булган нәсел-буыны! / Ничә гасыр яшәр гомер биреп, / Казыган ул үзенең коесын: // Якташлары, авыл кешеләре / Шифалы су белән туенсын! / Коены да казый белеп казу, / Урынын табып казу кирәктер. / Гыйлем коесына / Корал – энә, / Су коесы өчен – көрәктер»* [8: 29]. В этой главе образ колодца приобретает еще одно значение: колодец духа, колодец практики *(«Рухи кое! / Һәм гамәли кое!»)* [3: 30]. В поэме Э.М. Шарифуллина часто использует метафоричность татарских пословиц, помещая их в контекст своих размышлений о творчестве: *«Сүз сөйләсәң, / Белеп сөйләү кирәк, /*

*Дөреслеген тоеп уенның. / Коесының суы тәмсез, дип. / Иҗатында, әйткән фикерендә / Сүзе – тозсыз, / Үзе гамьсез, дип»* [8: 29].

Вторая глава посвящена осмыслению педагогической деятельности Каюма Насыри, показательно, что рефреном этой главы становится поговорка: «Не плюй в колодец» («Коега төкермәгез! / Коега төкермәгез!») [8: 32]. В эпиграфах ко второй главе цитата из Каюма насыри: «Балалар укыта башлап, капка өстенә вывеска куйгач, частька барып әйткәннәр... Хәтта бәгъзе адәмнәр Казан шәһәреннән кудырырга йөрделәр» и высказывание классика татарской литературы Габдрахима Утыз-Имени о необходимости изучения русского языка: «Татарларга урыс телен белү кырык беренче фарыз» [3: 30]. Высоко оценивая научную деятельность Каюма Насыри, поэтесса делает акцент на главной мысли татарского просветителя о необходимости сохранения высокой духовности (татарское – рухият) для просвещенной личности: *«Зарурлыгын телләр өйрәнүнең / Аңлатмакчы булып / Кылып ният – / Әкиятләр хәттә әйтмәгәнне / Сүз башлаган: / Кирәк ру-хи – ят!!!»* [8: 31].

Кульминацией поэмы является одическое посвящение родному, татарскому языку, данная во второй части третьей главы: *«Туган теле бер генә була, / Ул – минем татар телем. / Ул – минем газиз Әнкәем, / Газиз Әткәм теле! // Туган тел бер генә була, / Ул – чишмә суы кебек. / Ул якты Кояш сыман бит, / Нурларын тора сибеп. // Туган тел бер генә була, / Ул – минем тәмле телем. / Ул – минем баллы, ширбәтле, / Ул – минем назлы телем»* [8: 33].

Поэма имеет кольцевую композицию, завершается посвящением колодцу Каюма и устремленными в будущее призывом к сохранению родного языка, бережного отношения к своей истории и традициям: *«“Гыйбрәт алсын, / Гыйбадәтен кылсын, / Шифалы су белән туенсын...” – / Диеп, гуя ике гасыр буе / Яшәтә ул Каюм коесын. // Яшәтә ул, җыры үлмәсен, дип, / Җире иңмәсен, дип, татарның / Исбатлый күк Каюмнары белән / Бөеклеген илнең, Ватанның // урау юллар, / Гасырларга тиң еллар / Кайтавазлар булып эндәшә. / Энә белән казылса тик кое, / Каюм коесына тиңләшә»* [8: 45].

Э.М. Шарифуллина в поэме использует всю палитру символики образов чистой родниковой воды, образов родника и колодца, а в последней строфе связывает в единый символический образ чистую родлникову каплю с колодцем Каюма, как символа чистоты родного языка, любви к родине, упорства в своих научных исследованиях с будущим татарского народа, глубоко интимно прочувствованного автором. Так, лирическая героиня поэмы мечтает стать хотя бы одной лишь каплей, частью полноводного колодца Каюма: *«...Су бирегез, / Кирәк бер йотым су... / Кайчагында җитә бер тамы. / И туган җир! / Каюм коесында / Шул бер тамчы / Саф су булсамчы!»* [8: 45].

Таким образом, современнные писатели Равиль Бухараев и Эльмира Шарифуллина, создавая образ татарского просветителя Каюма Насыри в произведениях разных жанров (поэме, пьесе, рассказе, пьесе-сказке), дают высокую оценку личности и просветительского, научного наследия, воспринимают его как эталона высокой нравственности, самоотверженного ученого и патриота. Художественная рецепция личности и творчества

татарского классика в современной татарской литературе позволяет познакомить читателя с Каюмом Насыри и актуализировать его творчества, дать оценку его деятельности в контексте современного состояния татарской литературы и культуры.


СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1. *Бухараев Р.Р.* Вокруг Тукая: поэмы. Казань: Таткнигоиздат, 1986.

2. *Бухараев Р.Р.* Железная горошина // Бухараев Р.Р. Пьесы-сказки. Казань: Изд-во «Kazan-Казань», 2016. С. 28–81.

3. *Бухараев Р.Р.* Комментарии к любви. М.: Современник, 1985.

4. *Бухараев Р.Р.* Поэма Вокруг Тукая. Комментарии к любви // http://gabdullatukay.ru/rus/in-art/in-literature/stihi-o-tukae/ravil-buharaev-kommentarii-k-lyubvi/ (дата последнего обращения 12.05.2025).

5. *Бухараев Р.Р.* Улица Каюма Насыри // Бухараев Р.Р. Книга историй. Казань: Магариф-Вакыт, 2011. С. 152–230.

6. *Гали М.* Каюмның балалык чагы // Сайланма әсәрләр. Казан: Таткнигоиздат, 1956. С. 199–289.

7. *Голубева Е.В.* Колодцы как сакральный пространственный локус // Молодой ученый. 2009. № 10 (10). С. 222–225. URL: https://moluch.ru/archive/10/702/ (дата обращения: 12.05.2025).

8. *Шәрифуллина Э.М.* Каюм коесы [Текст]: поэмалар, автор иҗатына бәяләмәләр Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 253 с.



УДК 811.512.145


# МОТИВЫ ДЕОНИМИЗАЦИИ АНТРОПОНИМОВ В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ


***Г.Р. Галиуллина***

*Казанский федеральный университет (Казань)*



В татарском языкознании остается вне должного внимания изучение ономастической лексики вне прямой референции. В статье делается попытка анализа особенностей функционирования отдельных антропонимов в более широком контексте. Анализу подвергаются отдельные антропонимы, хорошо известные представителям татарского лингвокультурного пространства, которые являются актуальными в познавательном и эмоциональном аспектах и активно функционируют в фольклорных текстах, в литературных произведениях и в устной речи татар. Как показывает обзор материала, на переход онимов в разряд апеллятивной лексики влияют не только языковые, но и внеязыковые факторы. Антропоним, переходя в разряд апеллятива, наполняется дополнительным смысловым контекстом. Следует отметить, что смысловой объем исследуемых имен формируется не контекстом, они включаются в него уже «готовыми» семантическими оттенками.



**Ключевые слова:** татарский язык, онимы, деонимизация, антропонимия, прецедентное имя.



In Tatar linguistics, the study of onomastic lexicon beyond direct referents remains neglected. The article attempts to analyse the peculiarities of the functioning of individual anthroponyms in a wider context. The article analyses certain anthroponyms that are well known to representatives of the Tatar linguocultural space, which are relevant in cognitive and emotional aspects and actively function in folklore texts, in literary works and in the oral speech of Tatars. As the review of the material shows, not only linguistic but also extralinguistic factors influence the transition of onyms into the category of appellative lexicon.

An anthroponym, passing into the category of appellative, is filled with an additional semantic context. It should be noted that the semantic volume of the studied names is not formed by the context, they are included in it already ‘ready’ semantic shades.

**Keywords:** Tatar language, onyms, deonymisation, anthroponymy, precedent name.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ АНТРОПОНИМНАРНЫҢ КҮМӘКЛЕК СҮЗЛӘРГӘ КҮЧҮ МОТИВЛАРЫ

***Г.Р. Галиуллина***

*Казан федераль университеты (Казан)*

Телнең ономастик катламы милли мәдәниятне һәм тарихны, халыкның көнкүреш мәнфәгатьләрен, иҗтимагый тормышын чагылдырган гаять катлаулы һәм кызыклы берәмлекләрдән санала. Бу төр лексика белән кызыксыну, аның үзенчәлекләрен өйрәнү дә шактый бай тарихка ия. Аерым алганда, 1870 елларда Казан университеты каршында «Археология, Этнография һәм Тарих җәмгыяте» ачылу, әлеге җәмгыятьтә ономастик түгәрәк тә оешу һәм бу түгәрәктә В. Радлов, Н. Золотиницкий, И. Износков, В. Магницкий, татарлардан Г. Әхмәров, В. Тимофеев, К. Насыйри һ. б. актив фәнни эшчәнлекләре, XX гасырның 70 нче елларында күренекле галим Г.Ф. Саттаров җитәкчелегендә Казан төрки-татар ономастика мәктәбе оешу ономастик берәмлекләрне системалы өйрәнүдә хәлиткеч роль уйный [3: 52]. Шулай да ялгызлык исемнәренең үз функцияләреннән тыш кулланылу үзенчәлекләренә игътибар ныклап торып соңгы дистә елларда гына бирелә башлавын да искәртү зарур.

Ономастика фәнендә ялгызлык исемнәренең башка функциядә, башлыча күмәклек сүзләре рәтендә килүләре төрле термин белән атап йөртелә. Шулар арасында киң таралганы – *деонимлашу, деонимизация* күренеше дип атала. Әлеге төр күчеш барышында ялгызлык исеме үзенең югарыда саналган төп семантик үзенчәлекләрен югалтып, күмәклек сүзләренә хас билгеләр белән тулылана, ягъни уртак билгеләре булган бер төркем предмет, процесс, билге һ. б.ны атый башлый, гомумиләштерү сәләтенә ия була, төшенчә белән ныклы бәйләнеш хасил итә [6: 31] Гадәттә, мондый үзенчәлек исемнең окказиональ кулланылышы очрагында, ягъни туры референциядән тыш күзәтелә. Ялгызлык исемнәренең окказиональ кулланылышы дигәндә, исемнең семантик деривация өчен нигез буларак хезмәт итүен күзаллыйлар [5: 10].

Татар телендә күмәклек сүзгә күчкән берәмлекләр арасында антропонимнар зур урын били. Әлеге мәкаләдә без әлеге төр берәмлекләргә киңрәк тукталырбыз.

Телдә кулланылыш ситуацияләренә бәйле, кеше исеме күмәклек сүзләргә хас булган бер төркем предмет, күренешләрне атау сәләтенә ия була ала. Шул ук вакытта аның эчтәлеге коннотатив семалар белән тулыланырга мөмкин. Күмәклек сүзләр функциясендә йөргән исемнәр халыкның милли-мәдәни күзаллаулары белән турыдан-туры бәйләнгән була. Татар телендә туры референциядән тыш кулланыла торган күпсанлы исемнәрне табарга мөмкин, мәсәлән, *Мамай явы*, *Хуҗа Насретдин, Шәкүр карак, Мәҗнүн гыйшкы, Сафура бураны, Гобәй белән Хобәй булу; Рамазан агай килде; Бәдигъ мәзин күркәсе; Галигә дуслыктан түгел, Могавиягә дошманлыктан; Габдулла биясе; Тыр-тыр Зариф* һ. б. [2: 118].

Исем коннотатив эчтәлеккә ия булсын һәм бер төркем субъект яки предметларны атый башласын өчен, аның семантик эчтәлеген баета, сүзнең эчке формасын башка төр семалар белән тулылындыра алырлык мәгълүмати даирә булу кирәк. Төгәлрәк әйтсәк, ялгызлык исеме күмәклек сүзләр рәтенә күчсен өчен, тел факторлары булу гына җитми, бәлки экстралингвистик факторларның да тәэсир итүе мөһим. Нәкъ бу төр факторлар ялгызлык исеменең семантик мөмкинлекләрен киңәйтергә мөмкинлек бирә. Антропонимның үз функцияләреннән тыш кулланылуы узус белән тел системасы мөмкинлекләре арасындагы каршылыкка китерә. Моның нәтиҗәсендә антропоним үзенең төп мәгънәсендә табылмаган яңа семантик сыйфатларга ия була башлый.

Һәрбер мәдәният кысасында мондый төр ялгызлык исемнәр җыелмасын күпләп очратырга мөмкин. Аларның берише универсаль характерда булса, икенчеләре исә бары тик бер мәдәният җимеше буларак кына барлыкка килә һәм шул мәдәният вәкилләренә генә аңлашыла. Бу төр исемнәрнең күмәклек сүзләргә хас функциядә кулланылышы халык авыз иҗаты үрнәкләрендә, сөйләм телендә һәм матур әдәбият әсәрләрендә еш очрый. Татар мәдәниятендә яңа эчтәлек белән тулылынган берничә антропонимны карап үтик.

Татар кеше исемнәре системасына *Йосыф* исеме популярлыгы ягыннан аерым урын били. Аның татар халкы арасында популярлыгы ике факторга бәйле: беренчедән, ул пәйгамбәр исеме буларак билгеле, икенчедән, татар лингвокультур киңлекләрендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» шигъри әсәре киң популярлык казана. Йосыф пәйгамбәрнең гомерен тасвирлаган әлеге әсәр Идел буе Болгар дәүләте чорының иң атаклы, әһәмиятле рухи ядкяре санала. Бик күп тапкырлар күчереп язу, ятлау поэманың төп герое Йосыф исемен татар халкы арасында популярлаштырган. Халык телендә әлеге исем әкренләп ‘матур’, ‘гашыйк’ кебек семалар белән тулыланып, апеллятив берәмлек буларак та кабул ителә башлаган. Аның бу функциядә кулланылышын без *һәр Йосыф матур түгел / һәр Йосыф гүзәл булмас*; *Гыйшык тоту Йосыф-Зөләйхадан калган* һ. б. шундый гыйбарәләрдә күрәбез. Әдәби текстларда да очратабыз, мәсәлән, *Әллә соң авылда Йосыфлар, Таһирлар, Фәрхадлар, Мәҗнүннәр, Хәлилләр булмадымы? Миңнурга кызыгып, аңа күз атып, күңеле төшеп, аның белән хыялланып йөргән егетләр булмады түгел, булды* (З. Мәхмүди).

Аталган әсәр герое *Зөләйха* исеменең һәм башка хатын-кыз образларының дә татарлар арасында киңрәк мәгънәдә кулланылышы күзгә ташлана, мәсәлән, *Әйе, ул чорларда да җанын аямаган каһарманнар, ут эчендә һәр адым саен үлем көтеп йөргән сөйгәннәрен өзелеп көтүче Зөләйхалар, Зөһрәләр, Галиябанулар, Нәфисәләр байтак булгандыр* (Ә. Рәшит); *Зөләйхалар бетмәгән дөньяда* (https://tugantel.tatar/).

Тарихи антропонимиконда *Вәли* исеме популярлыгы белән аерылып тора. Ул *Вәлишаһ (Вәлиша), Вәлибәк, Мөхәммәтвәли, Вәлиулла, Миңлевәли, Әхмәтвәли, Габделвәли, Вәлиәхмәт, Вәлинур* кебек кушма төзелешле ир-ат исемнәре составында кулланыла. Әлеге антропонимнан бер генә хатын-кыз исеме дә ясалмавы игътибарны җәлеп итә. Бу, мөгаен, әлеге исемнең мәгънәсе белән бәйледер, чөнки *вәли* ‘әүлия, изге’, ‘яклаучы’, ‘Аллаһка якын дус’ кебек мәгънәләрне белдерә [4: 107]. Суфичылык тәгълиматында

вәлиләр роле зур була, алар суфичылык орденнарында югары урынны били [1: 151]. Моннан тыш, *Вәли* исеме татар халык авыз иҗаты үрнәкләрендә дә киң таралган. Ул, нигездә, *Гали* исеме белән кулланыла: *Гали үз эшендә, Вәли үз эшендә*; *Гали – Вәлигә, Вәли – Галигә* һ. б. Монда шуны ассызыкларга кирәк: фольклор текстларында антропонимның семантик потенциалы җуелган. Безнең фикеребезчә, мондый үзенчәлек исемнең гасырлар дәвамында бик актив кулланылышы белән бәйле. Татар мәдәниятендә бу исем киң таралышта булу аркасында, «гадиләшкән», ‘сала агае’ коннотатив мәгънәсен алган һәм беренчел мәгънә көчле абстрактлашуга дучар булган.

*Биби* исем компоненты гарәп-фарсы цивилизациясе йогынтысында яшәгән күп кенә көнчыгыш телләрендә актив кулланыла. Татарларда кеше исемнәре системасы ислам йогынтысында үзгәрә бару дәверендә әлеге хатын-кыз исем компонентының активлыгы да артканнан-арта бара. XX гасыр башында әлеге антропоформант катнашында бик күп хатын-кыз исемнәре барлыкка килә. Мәсәлән, 1900–1910 еллар хронологик аралыгында Казан шәһәре буенча 842 кыз балага кушылган 136 ике составлы кеше исеменең 122 се *биби* антропоформанты белән ясалган: *Бибигалия, Бибифатыйма, Бибисаим, Бибиразия* һәм башкалар. Әмма бу исемнәрнең зур күпчелеге 30–40 нчы еллар аралыгын узмаган. Архив мәгълүматлары нигезендә без 40 нчы еллар ахырына кадәр *Бибинур, Бибисара, Бибигөл* исемнәрен генә очраттык, алар да бераз соңрак кулланылыштан төшеп калды. Хәзер татарлар әлеге антропоформант ярдәмендә ясалган исемнәрне балаларга кушмыйлар диярлек. Бу, мөгаен, XX гасыр башында иң популяр булган хатын-кыз исемнәренең хәзерге исемлегебезгә «кайтмаган» берсенбер очрагыдыр. Моның сәбәбе исемнең коннотатив эчтәлегендә яшеренгән дип саныйбыз. *Биби* исеме титулдан барлыкка килгән һәм ‘югары даирә ханымы’ мәгънәсен белдерә. Шулай ук аның бик актив кулланылышы, аеруча түбән катлам кешеләре арасында киң таралыш табуы беренчел мәгънәнең җуела төшүенә китерә. Танылган татар драматургы Г. Камалның «Беренче театр» комедиясендәге беркатлы, бераз аңгыра асрау Биби образы да әлеге исемнең кулланылыш активлыгы кимүенә китерә. Хәзерге татар сөйләм телендә җиңел акыллы, интеллектуаль үсеше түбән хатын-кызны *биби* дип атыйлар. Шулай итеп, татарлар өчен *Биби* исеме тискәре коннотациясе белән билгеле исем буларак кабул ителә.

Татар мәдәниятендә *Шәкүр* исеме күмәклек сүзләр рәтенә күчкән антропонимнар арасында шулай ук үзенчәлекле урын били. Идел буе территориясендә яшәгән халыкларны үзенең җинаятьләре белән куркытып торган ат карагы Шәкүр Рәхимов исеме XX гасыр башында татарлар арасында киң таралыш тапкан була. Халык хәтерендә ул, беренче чиратта, атларны яратуы һәм караклыгы белән җуелып калган. Хәзерге татар телендә *Шәкүр карак* гыйбарәсе каракларга, хәйләкәр, тәвәккәл ир-атларга карата кулланыла. Бу исем түбәндәге коннотатив семалар белән тулылындырылган: беренчедән, ул тулы бер дәвер буларак күзаллана: *Авыл халкы ерак калган Шәкүр карак чорын да истә тота* (http://corpus.tatar/main.htm); аңа охшаган кешеләр төркемен атый: *Безнең төбәкнең үз «Шәкүр карагы» бар ахры: теге авылдан да атлар югалган, моннан да – хәбәрләр йөреп кенә торды* (http://corpus.tatar/main.htm) *Ни аяныч, безнең көннәрдә дә Шәкүр Карак эшен дәвам итүчеләр турында ишетелеп тора* (http://corpus.tatar/main.htm).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, ялгызлык исеменең күмәклек сүз рәтенә күчүе яки бу функциядә аерым контекст эчендә кулланылышы исемнең идентификацияләү, атау кебек төп сыйфатыннан тыш, эчтәлеге тулыланып, кемнәрнедер яки нәрсәнедер белдерә башлавын, күмәклек сүзләргә хас семалар белән баетылуын да күрсәтә.


ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Галиуллина Г.Р.* Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. 349 с.

2. *Галиуллина Г.Р.* Прецедентные имена в современном татарском языке // Ученые записки Крымского федерального университета им. В.И. Вернадского. Филологические науки. Т. 2(68). № 3. Симферополь, 2016. С. 117–122.

3. *Галиуллина Г.Р.* Казанская тюрко-татарская ономастическая научная школа: история и современность // Тюркская ономастика: от истоков до современности: материалы Междунар. науч.-практ. конф. (Казань, 11–14 октября 2018 г.) / под ред. Г.Р. Галиуллиной. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. С. 52–57.

4. *Саттаров Г.Ф.* Татар исемнәре: аңлатмалы сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 551 б.

5. *Суперанская А.В.* Апеллятив – онома // Имя нарицательное и собственное. М.: Наука, 1978. С. 5–33.

6. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2017. Т. III. 536 б.

7. Татар теленең язма корпусы. URL: http://corpus.tatar/main.htm (мөрәҗәгать итү вакыты: 22.04.2025).

8. Туган тел. Национальный корпус татарского языка. URL: https://tugantel.tatar/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 22.04.2025).



УДК 821.512.145


## ФОЛЬКЛОРНО-МИФОЛОГИЧЕСКИЕ МОТИВЫ В ТВОРЧЕСТВЕ Р. БАТУЛЛЫ


***А.Ф. Ганиева***

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань),*

***И.Ш. Ганиев***

*Казанский государственный институт культуры (Казань)*



Устное народное творчество способствует реалистическому изображению действительности и проникновению в психологию героев. В татарской литературе творчество Р. Батуллы выделяется тем, что он широко и плодотворно использует фольклорные и мифологические мотивы. Фольклор помогает писателю раскрыть представления народа о жизни, показать его духовный мир.


**Ключевые слова:** литература, фольклор, татарская проза, рассказ, сказка, Роберт Батулла.



Oral folk art promotes a realistic depiction of reality and insight into the psychology of the characters. In Tatar literature, R. Batulla’s work stands out because he makes extensive and fruitful use of folklore and mythological motifs. Folklore helps the writer to reveal the people’s ideas about life, to show their spiritual world.


**Keywords:** literature, folklore, Tatar prose, short story, fairy tale, Robert Batulla.

Одной из задач современной татарской литературоведческой науки является изучение обращения писателей к фольклору в разные периоды, раскрытие его сложных, своеобразных, исторических закономерностей, установление динамики этих связей, выявление конкретного содержания фольклоризма в творчестве писателей каждого периода развития татарской литературы.

Фольклорную традицию следует рассматривать не только как систему художественных приемов того или иного писателя, но и как философский взгляд на мир. Опора на фольклорные мотивы в творчестве, несомненно, оказывает влияние на формирование авторской концепции человека и действительности, на своеобразное понимание разными писателями принципа народности и специфики народного характера.

«Отличительными чертами национальных литератур на исследуемом этапе развития становятся повышенный интерес к этнической тематике, поиск нравственных ориентиров в своей исконной традиции, интенсивное использование притчеобразных, мифопоэтических, фантастических структур, синтез разных стилей и направлений, размывание жанровых границ, обращение к мифопоэтическим универсалиям и др. приёмы» [3: 3].

Одна из первых сказок Р. Батуллы «Длинноязычная птица», была написана в 1963 году. Сказка была опубликована в газете «Яшь ленинчы» в номере от 4 ноября 1965 года. В произведении одна ленивая птица ест все то, что принесли родственники, а сама не летает на поиски еды. Со временем родственники перестали давать ей еду, и прятали свою добычу в дуплах деревьев. Изголодавшись, эта безымянная ленивая птица стала долбить эти деревья и была вынуждена есть насекомых, спрятанных в них. Они расползались внутри стволов деревьев и становились лесными вредителями. Тогда общество птиц поручает этой безымянной птице, тюкая клювом ствол дерева, собирать вредителей. Ей дали имя Тукран, и с тех пор дятлы обязаны заниматься очисткой леса. Эта сказка написана как миф, легенда о том, откуда появляются такие названия.

Как видим, Батулла уже в первых произведениях опирается на образное мышление народа. Наличие же актёрского мастерства в сочетании с удивительно богатой фантазией показывает Батуллу как искусного сказочника. В качестве ведущего детских передач на телевидении он вырастил несколько поколений ребят, слушавших его сказки. Сказки Батуллы отличаются не только богатством увлекательных приключений, но и смысловым содержанием. Дидактика в них почти отсутствует, хотя они и написаны с воспитательной целью в качестве показательного примера для маленького читателя. Ребенок, душой погруженный в приключенческие события и содержание произведения, богатого эмоциями, начинает ощущать переживания героя всей душой и в конечном итоге делает выводы своим умом. Таким образом, Батулла своей фантазией не только учит детей мыслить и думать, но и развивает их мир мечты, обогащает их воображение.

«Дитя зайца Нуяк» (1966), «Сказка о звездах» (1969), «Мышкин ребенок Чикыл» (1970), «Мальчик играет на курае» (1970), «Бессмертный парень» (1970), «Мубарак», «Где спит радуга?», «Сак и Сок», «Алып-Батыр» – самые популярные сказки Батуллы. Многие из них созданы на основе народных легенд, сказок, в некоторых успешно использовались

восточные традиции и, конечно, писатель обогатил их своей нескончаемой фантазией. «Когда читаешь ее, чувствуешь себя как на празднике истории родного языка, нашего народа, – пишет о произведении “Алып-Батыр” Р. Шарипов, – в произведении найдется и поэтическая мелодия, философская высота. Все эти маленькие, исторические, национальные детали, эти стихи – все они, естественно, смешиваются в этой сказке и образуют прекрасный орнамент» [6: 185]. Эта оценка Р. Шарипова подходит и к другим сказкам Батуллы. Несмотря на разнообразие содержания, в них лежит общая философская мысль: как и в сказке в жизни происходит борьба зла с добром, испытание могут выдержать только доброжелательные люди с чистой душой – честные, находчивые и работящие.

Сказки Батуллы сложно классифицировать исходя из какого-то принципа. Их нельзя отнести к традиционным сказкам о зверях, волшебным и приключенческим, так как во многих сказках можно встретить признаки, присущие всем этим трем видам. Интересная картина бросается в глаза, если учитывать возрастные особенности читателя: в сказках, написанных для детей, и взрослые найдут поучительный смысл. К примеру, в сочинении «Ушастый Тафи» (1966) охотники, не стреляют в детеныша лисы, похожего на щенка, и берут с собой. Лиса превращается в собаку: во время охоты она начинает находить норы своих соплеменников. Люди за это вешают на шее Тафи жестяную медаль. Но под конец охотник застрелил и его самого, сделав из шкуры лисенка шапку-ушанку. Это произведение словно становится для молодого читателя предупреждением, что такая судьба ожидает и самого предателя своего родственника, а для более широко мыслящего читателя оно воспринимается как оценка обществу, общественному строю. Батулла назвал многие свои произведения «сказкой» или «кыйссой», но заметно, что это деление является достаточно условным. Например, произведение «Ушастый Тафи» с точки зрения жанра вполне можно считать и памфлетом.

«Как человек, погруженный в мир литературы, я слышал о Батулле, писавшем рассказы, но всегда был в затруднении, не в силах понять написанные им рассказы» [1], – пишет Х. Ашрафзянов. И действительно, читателю, привыкшему воспринимать освещение жизни только в плоскости реалистических и романтических художественных способов, творчество Батуллы может показаться странным. Впитывание образного представления народа с раннего детства, взросление с особой любовью к сказкам, мифам, легендам, оказывает в дальнейшем сильное влияние на детей. Проникновение в художественный мир сказок для детей проявлений политики, а сказочных мотивов в романы-повести, адресованные взрослым, свидетельствуют о том, что творчество Батуллы не укладывается в существующие до сих пор литературные стандарты.

Жанр произведения «Акбурэ» («Белый волк») (1972–1987) автор обозначил как сказку. Если Р. Назипов называет его «сказкой для взрослых» [4], то Ф. Хатипов использует термин «реальная сказка» [5: 125]. В основе произведения лежат реальные события: в них освещаются общественные преобразования, происходящие в татарской жизни с начала XX века до 1960-х годов и связанные с этим взаимоотношение человека и природы. При этом писатель использует нетипичный в реалистической литературе мифический мотив: там, как в татарских народных сказках и легендах,

превращение белого волка в юного парня, а джигита в молодого волка естественно вписывается в ткань произведения.

Повесть «Акбурэ» начинается описанием естественно-привычного существования деревни Буй-Турай, неподалеку от которой волки живут в лесу своей жизнью. В один из дней перед Сыртаком, прославившимся мастерством волчьей охоты, вышел волк, отличавшийся от других и цветом, и величиной. С этого дня знатный охотник заразился мечтой о поимке вождя рода волков Акбурэ. Батулла успешно использовал легенды тюркских народов о волке. Оказывается, и история деревни, и родовое начало Сыртака были напрямую связаны с волками. Охотник, хотя и знал, что ему запрещено стрелять, не мог сдержать охотничьего упрямства. С этого и начались все беды. И среди людей, и в волчьей стае исчезает естественный баланс. В связи с отношением с волками освещается история народа: изображая зловещие тридцатые годы, трагедии Великой Отечественной войны, ущерб, нанесенный природе, автор проводит параллели и сходства между жизнью волков и обществом. Хотя Сыртак, погибший от волчьих клыков, и оставил сыну Котлы завещание вырасти охотником на волков, но Котлы оказался умнее отца. Он понимает, что убийство белого волка, живущего в образе учителя Дивангари, приведет к катастрофе. Для большего воздействия на сознание читателя Батулла реанимирует мифическое мироощущение народа. Особо подчеркивается, что будущее человека зависит от его гармоничного сосуществования с природой. В дальнейшем в прозе Р. Батуллы часто встречается слияние реального мира с воображаемым. Многие из произведений, как в народных сказках, выстроены по схеме: нарушение традиции и наказание за содеянное. Совершенная ошибка прощается («Змеи», 2011), но в ряде случаев за преступление может быть вынесено и пожизненное наказание («Фарсия-демон», 2010; «Дочери», 2010 и др.).

мырдан кечкенә күмәчләр) пешереләә. Әмәлне балалар башлап җибәрә, алар һәр йорт янында туктап Әмәл бәйрәме белән котлыйлар. Һәр йорттан тукач яки көлчә тутырылган зур табаклар белән аларны каршы алып, ризыкларны балалар җыйсын өчен карга чөяләр. Авыл буенча йөреп чыкканнан соң, һәр бала күчтәнәчләр тулы букчасын алып өенә кайта, өйдә бәйрәм табынына ботен гаилә бергә утырып чәй эчә. Шушы җыелган тукачлар һәм көлчәләрне, ягъни ритуал ризыкны, *«Киләсе Әмәлләрне дә күрергә язсын, еллар имин булсын!»* дип һәр кеше авыз итә (информант: О.М. Мостафина). Томск өлкәсендә яши торган информантлар Әмәл өчен махсус ботка пешергәннәрен сөйлиләр: *«Әмәл бәйрәмен бөтен халык бәйрәм иткән. Әмәлгә башта орлык бүрттергәннәр, аннары бүрткән орлыкны киптергәннәр һәм тарттырганнар, шул онны казанда озак итеп болгатып ботка пешергәннәр. Ул ак төстәге сыек ботка була. Ул ботканы бөтен кеше ашый алган. Шушындый сүзләр әйткәннәр: Әмәл, Әмәл, бер аягыңа бер кәлцә, икенче аягыңа ике кәлцә* (информант: Ә.З. Абанеева).

Төмән өлкәсендә Әмәл бәйрәменә *тукач, көлчә, бавырсак* һәм *пәтер* пешергәннәр. *«Пәтер төрле размерда, кояш кебек түгәрәк була. Аның өстен бизиләр»* (информант: И.И. Садыкова), *«Элек паурсак пешергәннәр, аны чөйгәннәр. Кайбер авылларда паурсак, көлцән цөйгәннәр. Шуңа бу бәйрәмне паурсак, кулцән бәйрәме дип тә әйтәләр»* (информант: Ш.Т. Мурзаев).

Октябрь революциясенә кадәр, һәрбер татар авылында мәчет һәм мәдрәсәләр булганда, Нәүрүз әйтүчеләр шәкертләр булган. Соңгы елларда узган экспедицияләр вакытында Нәүрүз текстларының аерым фрагментларын гына язып алдык, аларны тулысында хәтерләүче информантлар очрамады. Мәсәлән, Новосибирск өлкәсендә түбәндәге текстлар язып алынды:

*Нәүрүз әйтеп без килдек,*
*Котлык җамалың күрдек,*
*Сезләргә дога кылдык,*
*Нәүрүз мөбарәкбад.*
*Нәүрүз әйттек без сезгә,*
*Хакын бирегез безгә,*
*Яшегез җитсен йөзгә,*
*Малыгыз артсын көзгә,*
*Нәүрүз мөбарәкбад*!
(информант: Г.З. Шаһабетдинова).

Соңгы вакытта Әмәл бәйрәменең тагын бер исеме әйләнешкә кергән. Аны *Садака бәйрәме* дип атыйлар. Бу исем бәйрәм вакытында йөргән балалар әйтә торган сүзләрдән алынган. Балалар хәзерге вакытта Нәүрүз текстлары урынына *«Әмәл, көлчән, садака»* дип кычкыралар. Новосибирск өлкәсендә информантлар бәйрәмне түбәндәгечә сурәтли: *«Сәдәка бәйрәмендә өйдә һәркем төрле ашлар пешерә дә инде, чәй эчә торганнар иде. Бавырсаклар, ашлар шулай пешерәләр иде. Йомырка буйый идек. Берберебезгә кунакка керә идек Садака бәйрәмендә яшьләр, балалар өй саен кереп йөри.*

*Садака, садака,*
*Акчаларын – кесәгә,*
*Муллаларын – оҗмахка*
*Шайтаннарын – тәмугка,*

*диләр инде, тиенле акча бирәләр иде, пешкән әйбер, йомырка да бирәләр. Зурлар йөрми, балалар йөри. Югырак вакыт иде. Нәрсә булса да бирәләр иде. Аннары күл буена бара идек менә, яшьләр бөтенесе. Анда бергәләп ашлар, бәрәңге пешерә идек.* (информант: З.З. Кунгулова).

Әмәл бәйрәмендә *тукач, көлчән* чөймәгән кешеләргә *«Әмәлегез бетсен!»* дип узалар. Теләсә кайсы йоланың кешеләрнең үзара бәйләнешләрен ныгытуга, табигать белән кешелек арасында гармония урнаштыруга юнәлтелүен истә тотсак, әлеге теләкнең мәгънәсе аңлашыла. Бәйрәмнән баш тарткан, аның ритуалларын башкармаган кешеләр гармониягә зыян китерә ала, бу үз чиратында табигать катаклизмнары, башка бәла-казаларга китерә алае дигән ышану ритуалларны төгәл үтәүне таләп итә. Әмәл, садака бәйрәменең хәзергә кадәр сакланып калуы, хәтта авыр елларда да онытылмавы да шуның белән аңлатыла.

Халык календарендә кечерәк масштабтагы, әмма халык тарафыннан игътибарсыз калмый торган даталар, шартлы рәвештә йола дип карарга мөмкин күренешләр дә бар. Алар да төрле ышанулар, гореф-гадәтләр белән бәйләнгән. Шундый шартлы йолаларның берсе Әмәлдән соң себер татарлары *Корткаяк бураны* дип атаган март аенда уза торган бураннар белән бәйле. Халык ышануы буенча Корткаяк Әмәлдән риза булса, буransыз да узарга мөмкин. Шуңа күрә Корткаякның күңеле булсын өчен Әмәлдә тукач, көлчән пешерергә кирәк дип ышаналар. Бу буран берничә көн эчендә, бер бер артлы ике тапкыр була, беренчесендә Корткаяк бураны салкын буран була, икенчесендә, берничә көннән соң, җепшек буран булып уза. *«Барганда усалланып, аләмәт (өермә) уза, кайтканда елап кайта»* (информант: Ш.Т. Мурзаев), *«Корткаяк сыктап кайтып барат, итәген бер якка сыпырып, икенче якка сыпырып»* (информант: М.С. Айдуллина). Язып алынган материаллардан күренгәнчә, *Корткаяк* шушы буранның иясе, рухы, яки шушы буран вакытында күренә торган яки буран чыгарып йөрүче явыз зат булып та аңлашыла. Аны икенче төрле *Әямәце*/*Әйәмәце*/*Әләмәце*/*Әләмәче* дип тә атыйлар. Корткаяк яки Әямәце/Әйямәце/ Әләмәце/Әләмәче бураны вакытында урамда йөрергә ярамый дигән ышану бар. *«Бүген Корткаяк бураны. Әйәмәце алып китәр, урамда йөрсәң дип куркыталар иде балачакта»* (информант: М.К. Туктасимова). *«Әямәче – буран иясе ул. Кыш көне генә була ул. Буран булып йөри. Күтәреп китә ул. Өереп алып китә. Куркыталар иде»* (информант: Г.Н. Ниязова), *«Әйәмәце балаларны ләгәнгә салып өереп алып китә. Әнә анда ләгәнен лаңгыр-лоңгыр китереп йөри»* (информант: О.М. Мостафина), *«Әләмәче ул кич йөри. Күзе ялтырак, ялтырап тора. Кош шикелле»* (информант: Е.Х. Туктасинова).

Корткаяк турында легендалар, ышанулар күп булып, Төмән өлкәсендә язып алынган легендадан Корткаякның тау куышында яшәгән карчык булып, ул чыккач, дулап давыл-буран чыгаруы турында сүз бара. Аның күңелен күрер өчен өйдә пешерелгән икмәк бирәләр: *«Корткаяк өчен көлчәне үзебезгә пешерергә кирәк. Садакага икмәк тә бирергә ярый. Кибет конфет-прәннеген яратмый. Буран башлангач, икмәк чыгарабыз»* (информант: О.М. Мостафина).

Буран иясенең кәефен күрергә омтылу, Корткаяк бураны белән бәйле ышанулар Себер территорияләрендә хәзергә кадәр яши.

Язгы йолаларның тагын берсе *Боз озату* йоласы. Әлеге йола хәзерге вакытта күп регионнарда фрагментлар рәвешендә генә сакланса да, Себер татарларында боз озату йоласы *Су-туй, Пос осату* исемнәре белән хәзер дә уздырыла. Елгаларда боз китү ел фасылларының алышынуын, кышның тәмамлануын, китүен белдерә. Боз кышны, салкынны гәүдәләндерә. Боз

китү, табигать уяну вакыты, бу вакытта табигатьтәге хаос кеше тормышына да йогынты ясый ала, аның аеруча сизгер һәм көчле вакыты санала. Боз китү белән бәйле ышанулар, гореф-гадәтләр дә формалашкан. Себердә елгаларда боз кузгалган көнне авылда бәйрәм рухы урнаша: аккан бозларга салам яндырып җибәрәләр, су буена яшьләр бергә җыелалар, шунда ук гармунчылар да була. Су буенда шау-шу, гармун тавышы төнгә кадәр тукталмый.

Омск өлкәсенең Иртеш буенда урнашкан авылларда «Боз озату» мифологик ышануларга нигезләнгән асылын саклаган хәлендә хәзергә кадәр уздырыла. Аны Тәвриз районы Козгын авылында «Су-туй» буларак, Иртеш елгасында боз кузгалгач уздырыла. Бу көнне авыл халкы елга буена җыела, үзләре белән самоварлар алып төшеп, чәй кайнаталар, милли камыр ризыклары алып барып, бөтен халык күңел ача, бәйрәм ясыйлар. Халык боз озатырга бәйрәмчә киенеп, иң яхшы киемнәрен кияләр: *«Боз бакканда иң матур күлмәгеңне киясең инде, яңа күлмәгең булса, яңа күлмәк киясең, яхшы шәлең булса, аны ябынып барасың». «Су туй була. Су бәйрәме дип тә әйтәләр иде. Иртеш буенда уздыра идек. Самаварлар куеп, Су туй ясый идек. Пешеренеп киләбез. Боз киткән вакытта бөтен авыл бәйрәме була идек. Төрле уеннар уйный идек. Бозга ипиләр ташлыйбыз. Хәер итеп. Теләкләр тели идек. Бәрәңге пешерә идек»* (информант: М.К. Туктасимова). Су буена төшкәч тә кешеләр үзләренә сәламәтлек, исәнлек теләп суга икмәк салганнар яки акча атканнар. Халык боз киткәндә бөтен авыруларны, күңелсезлекләрне алып киткәнгә ышана. Шуңа күрә боз киткән вакытта авыру кешеләр дә, аягына баса алган очракта, боз киткән вакытта елга буена ашыккан, боз өстенә авыру кешеләрнең киемнәрен салып җибәргәннәр. Шулай ук язгы боз киткәндә язгы су авыруларны, гонаһларны алып китә, кеше чистарынып, яшәреп кала дигән ышану белән тиз генә бозлы суга кереп чыгу, ташу суы белән юыну, бит-кулларны юу гадәте дә булган (информантлар: З.Ә. Хамитова, Ш.К. Хәмидуллина).

Халык ташу суына икмәк, акча салып Су ияләренең күңелен күрергә омтылалар. Бөтен гомерләре зур елга буенда узган халык шул рәвешле үзенең тормышын, эшчәнлеген җайларга тырыша. Су иясенең күңелен күрү аша, кеше үз дөньясына куркыныч тудырырга сәләтле булган икенче стихия – су стихиясен шәфкатьләндерергә, ягъни стихияләр аша дөньяда гармония булдырырга омтыла. Су иясенә сәдака бирелмәгән, аның күңелен күрмәгән елларда суда бәла-казалар күп була дигән ышану булган.

Омск өлкәсендә яшәүче татарларның язгы бозларга курчаклар куеп җибәрү традициясе да булган. Себер татарларында язып алынган материаллардан кешенең авыру-сырхауларын им-том белән курчакларга күчерүләре аңлашыла. *«Курчакны чүпрәккә утыртам да пөхтәләп төреп, боз өстенә утыртам да агызып җибәрәм. Булган авыру-сырхауларны, хәвеф-хәтәрләрне агызып алып кит дип»* (информант: Г.Н. Ниязова).

Себер авылларында Боз озату йоласы вакытында борынгылык эзләре сакланган бер күренеш сакланган: аккан бозлар аркылы киләчәккә яки мәңгелеккә сәлам әйтәләр. *«Мәңгәли бабайга – төньяк рухына сәлам әйтәбез. Аңа мөрәҗәгать итеп, акча атканда да әйтәбез – Мәңгәли бабай, безгә сәламәтлек бир!»* (информантлар: Омск өлкәсе Тәвриз районы, Тау авылы хатын-кызларыннан). *«Миңа әнием өйрәткән: Боз кузгалса,*

*Мәңкеләгә сәлам әйт, дип әйтергә. Мәңкелә – мәңге ята торган боз ул»* (информант: А.Х. Фәттахова).

Әшеван авылында боз киткәндә башка рухларга – Тәен-Вәенгә яки Әхәләй-Мәхәләйгә сәлам әйтәләр, Сәңке бабай рухына сәдака бирәләр. Эбаргүл авылында боз озатканда Мәңке бабайга, Мәңкелек бабайга сәлам юллыйлар. Мәңке бабайга, Мәңкелек бабай – Иртешнең хуҗасы дип ышаналар. Кучүм авылында боз киткәндә Әхәләй-Мәхәләйгә сәлам әйт дип аккан бозларга икмәк яки акча аталар. Бу йолаларда татар фольклоры өчен әлегә кадәр таныш булмаган мифологик образ – Мәңке, Мәңкелек, Мәңгәли турында сүз бара. Аны информантлар төрлечә аңлата. Ул Су иясе, Иртеш хуҗасы, Төньяк рухы, яки Төньяк боз океаны рухы буларак аңлатыла. Нигездә ул мәңгелек төшенчәсенә кайтып кала. Мәңгелек – ул икенче дөнья, яки үлеләр дөньясы. Евразиянең төньяк халыклары мифологиясендә Төньяк боз океаны үлеләр дөньясы, караңгылык дөньясы булып күзаллана. Себер татарлары мифологиясе буенча параллель дөньялар горизанталь буенча бүленә, алар бер яссылыкта урнашкан, төньяк, шул исәптән аның үзәге булып саналган Төньяк боз океаны да үлеләр дөньясы. Алдан карап узган материаллар буенча параллель дөньяларны елгалар бәйләп тора. Елга боздан ачылган вакыт, бу дөньялар арасындагы бәйләнеш аеруча көчәя.

Татар халкының язгы календарь йолаларның берсе булган «Боз озату» йоласы хәзерге вакытта онытыла бара торган йолалардан. Бары себер татарлары яшәгән Омск һәм Новосибирск өлкәләрендә генә бу йоланың борынгыдан килгән атрибутлары сакланып калган. Анализланган материаллардан боз озату йоласының кышны озату, язны каршы алу йоласы гына булмыйча, бу вакытта үлеләр һәм тереләр дөньясы арасындагы бәйләнеш көчәя торган табигатьнең аеруча сизгер бер мизгеле булуын күренә. Кешеләр аны үлеләр дөньясы капкалары, ягъни портал ачыла торган вакыт буларак кабул итәләр. Шул вакытта халык үзенә кирәкмәгән күренешләрдән – авырулардан, бәхетсезлекләрдән котылырга омтыла, аларны бозлар белән кире юлы булмаган дөньяга озата. Мәңке/Мәңге/Мәңгәли/Мәңкелә Себер татарлары мифологик ышанулары буенча үлеләр дөньясын символлаштырган Төньяк боз океаны хуҗасы буларак күзаллана. Бу образлар турында мәңгелек дөнья белән бәйле рух дигән фикергә килә барабыз.

Себер татарларының тамыры борынгы заманнарга киткән, мифологик ышануларга нигезләнгән календарь йолаларның тагын берсе язын кошлар кайткан вакытта уздырыла торган *Карга туе, Каргатуй, Карга боткасы, Карабакчар туе яки бакчар туе, сыерчык туе*. Исеменнән үк күренгәнчә бер төбәктә кара каргаларның кайтуын, икенчеләрендә сыерчыклар/карабакчарлар кайтуын бәйрәм итәләр. Бәйрәмнең асылында кара каргаларның яки карабакчарларның җиргә яз, җылы алып кайтуларына ышану ята.

Каргалар яки бакчарлар (сыерчыклар) килгәч, җир кардан ачыла төшкәч, карга туеның көне билгеләнгән. Язгы бәйрәмнәрнең барсында да булган кебек, бу көнне яшьләр, үсмерләр йортттан йортка кереп ботка пешерер өчен азык – төрле ярмалар, май, йомырка җыйган.Бу яшьләр беренчедән бәйрәм җитүен бөтен кешегә хәбәр итсә, икенчедән берәү дә бәйрәмнән читтә калырга тиеш булмаган. *«Карга туен сукмак төшә башлагач үткәргәннәр. Кошлар кайткач үткәргәннәр. Ботка пешергәннәр, үзләре ашаганнар, балалар уйнашып, сикерешеп, җырлап калган ботканы үләнгә*

*сипкәннәр. Өйдән өйгә йөрегәннәр»* (информант: Ә.З. Абанеева) *«Карга путкасына кем сөт, кем ярма китерә. Май алып баралар. Карга путкасын каргаларга да калдыралар. Каргалар ашасын дип, биек җирләргә кашык белән салалар»* (информант: И.И. Садыкова). Кара каргалар өчен дә биек җирләргә (киртә, лапас түбәләренә) ботка салганнар.

Себер татарларының сыерчык туе да карга туеннан аерылмый. Омск татарларында карабакчарлар килгәч «Карабакчар туе» уздырыла. Әлеге төбәккә оештырылган экспедиция вакытында «Карабакчар туе»ның ике варианты язып алынды. Йоланың беренче варианты «аулак өй» рәвешендә узган, яшьләрнең күңел ачу чарасы булып аңлашыла. Бу бәйрәмне кызлар берәр өйдә оештыра. Бәйрәмгә егетләрен дә чакыралар. Икенче вариантта йола боткасын өлкәннәр пешерә. Шулай ук коймак, әлбә, йомырка кебек ритуал ризыклар әзерләнгән. Балалар сарай түбәләренә менеп ботка ашаган. Калган ризыкларны кошларга салганнар. Соңыннан Иртеш буенда төрле уеннар уйнаганнар. Йоланың махсус текстлары да булган. Хәзер дә түбә башларында йомырка яки ботка ашый башлаганчы

*Карабакчар туй, туй,*
*Бер атыңны суй, суй, –*

*дигән юлларны әйтәләр* (информант: Е.Х. Туктасинова).

*«Бала чакта Карабакчар туен үткәрә идек. Әниләр ботка пешерә иде, оннан, сөтка ботка чала да, әлбә пешерә. Кура башына менеп Карабакчар туен үткәрәбез. Коймак пешерәләр»* (информант: Е.Х.).

Себер татарларының язгы циклы тулы булсын өчен тагын бер йоланы атап үтәбез. Бу язын, карлар эреп беткәч үтәлә торган йола – Цым, Чым үтү – бабалар культы белән бәйле барлык үлгәннәрне искә алу йоласы. Ул боз эрегәч, җирнең өсте каты эрегәч, май аенда үткәрелә. Цым үтмичә, җиргә көрәк тыкмыйлар, агач-чәчәк утыртмыйлар. Цым үтмичә киртә куймыйлар. Бу йола турында материал туплау дәвам итә. Язгы йолаларның соңгы этабы – яшьләр уеннары дип карарга мөмкин. Су буенда яшьләр уеннар уйный, гармун уйныйлар. Атна-ун көн дәвам иткән яшьләр уеннары җирләр кибә башлагач башланып китә.

Кешенең табигать белән мөнәсәбәте, гармониядә яшәве борынгы заманнарда ук йола-ритуал ярдәмендә җайга салынган. Әлеге йолаларның төп – функциясе табигатькә тәэсир итү, аллаларның һәм ияләрнең күңелен күрү, ритуал аша җәмгыять тормышында тотрыклылык булдыру, беренче чиратта, халыкның иминлеген һәм туклыгын тәэмин итү. Теләсә кайсы календарь бәйрәмнең нигезендә хуҗалык белән бәйле йолалар ята. Аучылык, терлек асрау, балыкчылык кебек эшләр беренче чиратта табигать шартларыннан бәйле булган. Язның вакытында килүе, карның вакытында эрүе, боз сугулар булмау, кирәк вакытында яңгыр һәм кар яву һәм киресенчә кирәкмәгән вакытта яумау – бу күренешләр белән аларның ияләренең яки аллаларының күңелен күрү аша идарә итәргә омтылу календарь бәйрәмнәрнең нигезендә ята. Йолалар, ритуаллар, гореф-гадәтләр, ягъни халыкның йолаларда гәүдәләнгән үз-үзен тотышы шул халыкның дөньяны танып-белүе турында информация саклый. Календарь йолаларның халык традицияләрен саклауда да әһәмияте зур. Шул ук вакытта туганнар, авылдашлар, туганнар, кешеләр бер берсенә якынаялар. Яшь буын милли

традицияләрне үзләштерә, рухи бягланышлар ныгый, гомүмкешелек кыйммәтләре барлана.

ИНФОРМАНТЛАР

Абанеева Әминә Закировна, 1948 елгы. Томск өлкәсе Томск районы Умавыл авылы.

Айдуллина Мөхлисә Сибгатулла кызы, 1961 елгы. Төмән өлкәсе Тубыл районы Ачир авылы.

Кунгулова Заһирә (Зайра) Закир кызы,1940 елгы. Новосибирск өлкәсе Каргат районы Тәрәнә авылы.

Мостафина Оркыя Мөхәммәтгали кызы, 1938 елгы. Төмән өлкәсе Тубыл районы Тубылтура авылы.

Мурзаев Шиабетдин Туктасон улы, 1949 елгы. Төмән өлкәсе Тубыл районы Ачир авылы.

Ниязова Гөлсинә Наил кызы, 1959 елгы. Омск өлкәсе Тәвриз районы Тау авылы

Мостафина Оркыя Мөхәммәтгали кызы, 1938 елгы. Төмән өлкәсе Тубыл районы Тубылтура авылы),

Садыкова Ирина Исмәгыйль кызы, 1941 елгы. Төмән өлкәсе Тубыл районы Олы Юршак авылы.

Туктасимова Маһинур Калимулла кызы, 1929 елгы. Омск өлкәсе Тәбриз районында Козгын авылы.

Туктасинова Екатерина Хафисовна. 1930 елгы. Омск өлкәсе Тәбриз районы, Козгын авылы).

Фәттахова Асия Хамидулла кызы, 1937 елгы. Омск өлкәсе Тәвриз районы Әйрә авылы

Хамитова Зәкия Әйтмөхәммәт кызы, 1938 елгы; Омск өлкәсе Усть-Ишем районы Әшеван авылы.

Хәмидуллина Шәмсия Касыйм кызы, 1925 елгы. Омск өлкәсе Усть-Ишем районы Әшеван авылы.

Шаһабетдинова Гөлҗиһан Зөлкарнәй кызы, 1928 елгы. Новосибирск өлкәсе Колыван районы Умар авылы.

УДК 811.512.145

# РОЛЬ ГЛАГОЛОВ С ИНКОРПОРИРОВАННЫМИ АКТАНТАМИ В СЛОВООБРАЗОВАНИИ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

***И.Ф. Зарипова***
*УУНиТ (Уфа)*

Данная статья посвящена исследованию роли глаголов с инкорпорированными актантами в образовании слов путем сложения. Предлагается классификация данных сложных слов по типу инкорпорированного актанта в современном татарском языке.
**Ключевые слова:** татарский язык, агглютинация, словообразование, глагол, валентность, актант, инкорпорация.

This article is devoted to the study of the role of verbs with incorporated actants in the formation of words by addition. The classification of these complex words by the type of incorporated actant in the modern Tatar language is proposed.
**Keywords:** татарский язык, агглютинация, словообразование, глагол, валентность, актант, инкорпорация.

# ИНКОРПОРАЦИЯЛӘНГӘН АКТАНТЛАР БЕЛӘН ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗ ЯСАЛЫШЫНДАГЫ РОЛЕ

***И.Ф. Зарипова***
*Уфа фән һәм технологияләр университеты (Уфа)*

Сүзләрне кушу – ул бер кушма сүзгә ике яки сирәк кенә берничә гади нигезне кушудан торган сүз ясалышы ысулы. Кушма сүзләрнең өлешләре бер-берсе белән бәйләнгән. Бу бәйләнеш һәр өлешнең грамматик формасы һәм мәгънәсе буенча сайлануында күренә. Мәсәлән, ике теләсә нинди сүзне генә алып кушып булмый, чөнки аларның мәгънәләре һәм грамматик үзенчәлекләре туры килмәскә мөмкин. Шуңа күрә, кушма сүз ясаганда, сүзләрнең лексик һәм грамматик ярашуы мөһим роль уйный [6: 210]. Бу ысул телне баету һәм яңа төшенчәләрне белдерү өчен бик әһәмиятле.

Кушма сүзләрнең компонентлары үзара тигез хокуклы һәм берсе икенчесенә буйсынган булырга мөмкин. Хәзерге татар телендә ияртүле мөнәсәбәттәге компонентларның кушылуын түбәндәге типларга бүләләр: 1) атрибутив мөнәсәбәттәге компонентларны кушу; 2) объект мөнәсәбәтендәге компонентларны кушу; 3) хәл мөнәсәбәтендәге компонентларны кушу [6: 211]. Моннан тыш, татар телендә сүз кушылуның тагын бер төрен – хәбәрлек мөнәсәбәтендә булган компонентларны кушуны күрсәтергә мөмкин [3: 55; 8: 37]. Мәсәлән: *минбеләмлек, үзбушаткыч, үзбилгеләнеш, көнбатыш, көнчыгыш, буйсыну, үзйөрешле.* Атрибутив мөнәсәбәттән тыш, башка очракларда кушма сүзнең төп компоненты булып инкорпорацияләнгән актантлар исәбенә семантик валентлыгын тормышка ашыручы фигыль тора.

Фигыль – теләсә кайсы телдә дә аерым урын алып торучы сүз төркеме. Чөнки нәкъ менә фигыль җөмләнең үзәге булып тора, ул ситуациядә катнашучыларның санын һәм аларның нинди роль башкаруын билгели. Фигыль үзен дә, аның тарафыннан сурәтләнгән бөтен ситуацияне дә күзалларга мөмкинлек бирә. Шуңа күрә дә фигыльне валентлыкның семантик теориясе кысаларында өйрәнү бүгенге көндә тел белеме, семантик синтаксис һәм функциональ грамматика өлкәсендә эшләүче галимнәрнең игътибарын җәлеп итә.

Фигыль актантларының инкорпорациясе (фигыльгә кушылуы) полисинтетик телләрдә генә түгел, ә башка телләрдә дә очрый. Моның сәбәбе гади: инкорпорант комплекслары мәгънәне тиз һәм нәтиҗәле итеп җиткерү мөмкинлеге бирә. Бу телнең экономияле булу омтылышы белән аңлатыла, ягъни тел мөмкин кадәр аз сүз кулланып, күбрәк мәгълүмат бирүгә юнәлгән. Шуңа күрә инкорпорацияне телнең экономия законының бер күренеше дип санарга була.

Заманча дөньяда, тормыш тизлеге арту сәбәпле, вакытны һәм көчне саклау ихтыяҗы телнең дә үзгәрүенә китерә. Кешеләрнең сөйләмдә азрак көч кулланырга омтылуы тел экономиясенең активлашуына этәргеч бирә.

Тел экономиясе берничә сәбәп аркасында барлыкка килә. Беренчедән, тел, социаль күренеш буларак, җәмгыятьтән, анда барган процесслардан аерылгысыз, шуңа күрә андагы үзгәрешләргә тиз җавап бирә. Икенчедән, тел кеше эшчәнлегенең продукты булып тора, телдә кешенең фикерләү

үзенчәлекләре, аерым алганда, фикерләрне белдерүнең төгәллегенә һәм кыскалыгына омтылу чагыла. Өченчедән, тел – үзгәрергә сәләтле катлаулы система, ул экономия принцибын кулланып камилләшә.

Шулай итеп, тел экономиясе лингвистикада телнең табигый яшәешенең мөһим принципларының берсе булып санала. Ул кешенең азрак көч куеп, азрак сүз кулланып, күбрәк мәгълүмат җиткерү омтылышыннан гыйбарәт.

Лингвистик экономия принцибы нигезендә тел билгесен тәшкил итүче ике өлешнең асимметриясе, ягъни ачыклаучы һәм ачыкланучы сүзләрнең мәгънә аермалылыгын үз эченә алган тел күренешләрендә чагыла. Бу полисемия, синонимия, омонимия, кыскарту һәм аббревиатура, диффузлык, эллипс, субституция, нейтральләшү, синкретизм һәм инкорпорация.

В.А. Плунгян фаразлавынча, фикер белдерүнең иң компактлы ысулының ачык мисалы булып «бер сүз-җөмләдә бөтен фикер берьюлы төрелгән» [4: 173] инкорпорация тора. Мондый җөмләләрне В.А. Плунгян куллануы уңайлы: «кыскарак та, тизрәк тә» [4: 174] булган аббревиатурлар белән чагыштыра.

Инкорпорация (латинча «incorporatio» сүзеннән, ягъни «үз эченә алу») – ике яки аннан да күбрәк мәгънәле кисәкләрнең бер морфологик берәмлеккә берләшүе. Әлеге кисәкләр аерым лексик мәгънәгә ия һәм хәрәкәтчән була. Аларның саны һәм тәртибе һәрвакыт фикернең эчтәлеге белән бәйле, ә алар арасындагы мөнәсәбәтләр синтаксик мөнәсәбәтләргә туры килә [9].

Инкорпорация күренеше телгә бик үзенчәлекле мөмкинлек бирә: сөйләмне кыскарту, аны төгәлрәк һәм образлырак итү. Бу аеруча инкорпоратив телләрдә ачык күренә, анда бер сүз берничә сүзтезмәне яки хәтта җөмләне дә алмаштыра ала. Әйтик, эскимос телләрендәге бер сүз, безнеңчә берничә сүз белән әйтелә торган хәбәрне белдерергә мөмкин. Инкорпорация шулай ук телнең грамматик төзелешенә дә йогынты ясый. Мәсәлән, инкорпоратив телләрдә исемнәр һәм фигыльләр арасындагы чикләр юка булырга мөмкин, чөнки исем, фигыль составына кереп, аның мәгънәсен үзгәртә ала. Бу күренеш телләрнең төрле типтагы классификациясенә дә бәйле, чөнки телнең инкорпоративлык дәрәҗәсе аның морфологик төзелешен характерлый. Инкорпорацияне өйрәнү телләрнең үсеш тарихын аңларга, аларның структурасын һәм грамматик үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә.

О.С. Ахманованың «Лингвистик терминнар сүзлеге»ндә инкорпорация – ул сүз ясалуның (яки синтагматик берәмлекнең аерым төренең) үзенчәлекле һәм нәтиҗәле ысулы. Бу ысул ярдәмендә бер-берсенә бәйле тамырлар, ярдәмче элементлар белән бергә, бербөтенгә әверелә [2: 177].

Зур энциклопедик сүзлектә инкорпорация «сүзтезмә компонентларының (өлешчә И) яки җөмләнең барлык кисәкләренең (тулы И) синтаксик бәйләнеш ысулы буларак билгеләнә, бу очракта компонентларның һәрберсе формаль күрсәткечләреннән башка бербөтенгә оеша» [9].

Әмма кайбер галимнәр әлеге төшенчәгә киңрәк мәгънә бирә. Аерым алганда, Л. Теньер инкорпорация күренешен агглютинациянең иң чик дәрәҗәсе буларак карый. Полисинтетик (инкорпорацияләнүче) телләрдә «агглютинация шулкадәр еракка керә ки, хәтта җөмләнең барлык элементларын да үз эченә ала: аларны агглютинацияләнгән бер олы сүз итеп

күзалларга була» [7: 43]. Шунысын да билгеләп үтү мөһим: агглютинация, димәк, инкорпорация дә теге яки бу дәрәҗәдә дөньяның барлык телләре өчен хас, бу тулысынча закончалыклы булып күренә, чөнки инкорпорация барлык телләргә кагыла торган тел экономиясе законының чагылышы булып тора [7: 43].

«Инкорпорация» төшенчәсенең асылына тикшеренүчеләрнең карашлары төрлечә. Кайбер галимнәр (Р.З. Гинзбург, И.А. Муравьева, Бейкер) фикеренчә, күп кенә һинд-европа телләрендә тышкы яктан инкорпорант комплексларга охшаган яңа фигыльләр барлыкка килүгә карамастан, аларны инкорпорация мисаллары дип санарга ярамый.

Мондый фикергә каршы позиция дә бар. М.А. Анохина, О.Ю. Афанасьева, Л.В. Мерзлякова, Л.Ф. Омельченко, М. Бэрри, Р. Холл кебек галимнәр фикеренчә, кайбер телләрдә фигыльләр үз эченә ситуациядә катнашучыларны (мәҗбүри һәм өстәмә) кертә ала. Бу күренеш инкорпорацияле телләргә хас. Мондый тел берәмлекләре инкорпорация мисалы булып тора ала, чөнки аларның семантик ягы фигыль белән бәйле булган, әмма мөстәкыйль синтаксик ролен саклаган актант белән охшаш. Димәк, фигыль үзенә башка сүзләрне «йотып», бербөтен мәгънә төзи [10].

Хәзерге вакытка кадәр андый фигыльләр күбрәк сүз ясалышы системасында сүз кушылу мисаллары буларак өйрәнелде. Ләкин, берничә сүздән торган берәмлекләр буларак, андый фигыльләр инкорпорациянең аерым бер очрагы булып тора, чөнки семантик планда алар фигыльнең нинди дә булса җөмлә кисәге белән бәйләнешенә тәңгәл [10]. Кайвакыт әлеге рольдәге катнашучыны белдерә торган җөмлә кисәге принципиаль рәвештә булмаска да мөмкин. Бу очракта без актантларның инкорпорациясе турында сөйлибез.

«Исем + фигыль» тибындагы кушма сүзләр полисинтетик булмаган һинд-европа телләренең төрле төркемнәрендә, аерым алганда рус һәм инглиз телләрендә билгеләнә. Мәсәлән: *to houseclean – убирать дом, квартиру; to fortune-tell – гадать, предсказывать будущее; рыболовствовать – ловить рыбу; престолонаследовать – наследовать престол; зубоскалить – скалить зубы* –туры тәмамлык белән фигыль сүзтезмәләренә; *to handweave – ткать вручную – to weave with hands; to finger-paint – рисовать пальцами – to paint with fingers; рукодельничать – делать что-то руками; рукоприкладствовать – прикладывать руки* – инструментны белдерүче исем белән фигыль сүзтезмәләренә; *to skydive – совершать затяжной прыжок с парашютом (букв. нырять в небо) – to dive into the shy; to air-drop – сбрасывать с самолета; домоседствовать – сидеть дома, казнокрадствовать – красть из казны* локатив мәгънәле исем белән фигыль бәйләнешендәге сүзтезмәләргә тәңгәл һ. б. [10].

Үзенең структур-типологик тибы буенча агглютинатив телләргә караган татар телендә дә кушма сүзләр мисалында фигыльләрнең инкорпорантлашкан актантлар белән бәйләнешен аерып күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән: *кулъюгыч (кул + юуу), елъязма (елны + язу), газүткәргеч (газ + үткәрү), сусаклагыч (су + саклау), тизәйткеч (тиз + әйтү)* һ. б.

Без инкорпорацияне киң мәгънәдә – семантик-синтаксик күренеш, ягъни фигыльнең үз эченә җөмләдәге башка сүзләрне, аеруча эш-хәлнең катнашучыларын (субъект, объект һ. б.) «алу»ы буларак карыйбыз.

Шулай итеп, инкорпорация, тел экономиясе законы чагылышы буларак, хәзерге татар телендә дә күзәтелә, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Мәсәлән: *атказану, үзбилгеләнү, радиотапшыру, буйсыну.* Нигездә, инкорпорацияләнгән актантлы фигыльләр кушма фигыль ясау өчен генә түгел, башка кушма сүз төркемнәре ясалышына да мотивлаштыручы нигез булып тора.

Хәзерге татар телендә инкорпорант комплексларның түбәндәге типларын аерып күрсәтергә мөмкин: «исем / алмашлык + фигыль», «рәвеш / сыйфат + фигыль» һәм «сан + фигыль» схемалары буенча төзелгән сүзләр.

Татар телендә төрле сүз төркемнәрен барлыкка китерүче, актанты ингерент рәвештә күрсәтелгән, «исем / алмашлык + фигыль» схемасы буенча төзелгән инкорпорант комплекслардан торган кушма сүзләр киң таралган. Актантларның төрләре буенча мондый фигыль бәйләнешләренең түбәндәге классификациясен китерергә мөмкин:

1. Эш-гамәлнең субъектын белдерүче актант белән фигыль бәйләнешләреннән исем: *минбеләмлек (мин + беләм), үзбушаткыч (үзе + бушату), үзбилгеләнеш (үзе + билгеләнә), көнбатыш (көн + бату), көнчыгыш (көн + чыгу)* я фигыль *буйсыну (буй + сыну), үзйөрешле (үзе + йөрү), үзбилгеләнү (үзе + билгеләнү)* ясала.

2. Эш-гамәлнең объектын белдерүче актант белән фигыль бәйләнешләреннән: 1) исемнәр: *урынбасар (урын + басу), эшкуар (эш + куу), эшсөяр (эш + сөю), алъяпкыч (ал + ябу), башваткыч (баш + вату)*; 2) сыйфатлар: *башимәс (баш + имәү), коточыргыч (кот + очыру), канечкеч (кан + эчү), канкойгыч (кан + кою)* ясалу өчен мотивлаштыручы нигез булып тора.

3. Актант-локатив белән фигыль бәйләнеше нигезендә исемнәр ясала: *атменәр (атка + менү),* прилагательное: *йорттума (йортта + туу), суүсем (суда + үсү).*

4. Актант-темпоратив белән фигыльләр бәйләнеше дә исемнәр ясау өчен мотивлаштыручы нигез ролен үти: *көньяшәр (көн + яшәү).*

«Рәвеш / сыйфат + фигыль» схемасы буенча төзелгән инкорпорант комплекслар, нигездә, исемнәр, сыйфатлар һәм рәвешләр ясалу өчен материал булып тора.

Эшнең үтәлү рәвешен белдерүче актант белән фигыль бәйләнеше нигезендә исемнәр: *тизәйткеч (тиз + әйтү), тикторыш (тик + тору);* сыйфатлар: *тизаткыч (тиз + ату), ярымүткәргеч (ярым + үткәрү), тиктормас (тик + тормау), тигезүзгәрешле (тигез + үзгәрү);* рәвешләр: *бертуктамый (бер + туктамый), кушучлап (куш + учлау)* ясала.

Күләм-чаманы белдерүче актант белән фигыль бәйләнеше исемнәр ясалу өчен хезмәт итә. Мәсәлән: *йөзьяшәр (йөз + яшәү), кырыгалдар (кырык + алдау)*. Бу сүзләр «сан + фигыль» структур схемасы буенча ясала.

Шулай итеп, актантлары белән кушылган фигыльләргә синкретизм күренешләре хас дип әйтә алабыз, алар, синтаксик күренеш буларак, сүз кушылу һәм төрле сүз төркемнәренең морфологик-синтаксик ысулы белән сүз ясалышының мотивлаштыручы нигезе булып хезмәт итә. Фигыльләр материалында актантларның инкорпорацияләнүен алга таба өйрәнү, бу кызыклы лингвистик күренешне тирәнтен аңларга һәм хәзерге татар теленең грамматик төзелешенә яңача карарга мөмкинлек бирәчәк.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Анохина М.А.* Явление инкорпорации в английской глагольной лексике: на материале адвербиальных глаголов английского языка: дис. ... канд. филол. наук. Барнаул, 2006.

2. *Ахманова О.С.* Словарь лингвистических терминов. М.: Сов. энцикл., 1969. 606 с.

3. *Җәләй Л.* Татар теленең тарихи морфологиясе. Казан: Фикер, 2000. 288 б.

4. *Плунгян В.А.* Почему языки такие разные. Популярная лингвистика. М.: АСТ-Пресс Книга, 2010. 274.

5. *Смирнова Е.А.* Функционирование глаголов с инкорпорированными актантами: автореф. дис. …канд. наук. Пермь, 2013. 24 с.

6. Татарская грамматика. Т. I. Казань, 1995. 582 с.

7. *Теньер Л.* Основы структурного синтаксиса. М.: Прогресс, 1988. 656 с.

8. *Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе. Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2006. 335 б.

9. Крупнейший сборник онлайн-словарей. URL: https://www.liveinternet.ru/users/4127920/post194042156/ (дата обращения: 27.04.2025).

10. Человек и наука. URL: http://cheloveknauka.com (дата обращения: 27.04.2025).

УДК 821.512.145

# ОБЩЕЕ В ПРОСВЕТИТЕЛЬСКИХ ВЗГЛЯДАХ ТВОРЧЕСТВА КУЛ МУХАММЕДА И КАЮМА НАСЫРИ

***Г.Н. Зайнеева***

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматриваются общие аспекты в просветительских взглядах поэта Кул Мухаммеда и ученого-энциклопедиста Каюма Насыри на примере поэм «Мухимма эс-сыйбьян», «Тагриф эл-вилдан» и труда «Книга о воспитании». Более детально сделан акцент на тему образования, получения знаний, роли ученых.

**Ключевые слова:** Кул Мухаммед, Каюм Насыри, просветительство, поэмы, знания, ученые.

The article examines common aspects in the enlightenment views of poet Kul Muhammad and encyclopedic scholar Kayum Nasyri using the example of the poems “Muhimma es-syibyan”, “Taghrif el-Vildan” and the work “The Book of Education”. The focus is on the topic of education, knowledge acquisition, and the role of scientists in more detail.

**Keywords:** Kul Mohammed, Qayum Nasiri, enlightenment, poems, knowledge, scientists.

# КОЛ МӨХӘММӘД ҺӘМ КАЮМ НАСЫЙРИ ИҖАТЛАРЫНДА МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК КАРАШЛАРЫ

***Г.Н. Зәйниева***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

XVIII–XIX гасырлардагы иҗтимагый-сәяси тенденцияләр татар мәгърифәтчеләре арасында зур роль уйный. Иң башта мәгърифәтчеләр дөньяга фәлсәфи караш һәм дини реформаторлык идеяләрен пропагандалау белән

чикләнсәләр, алга таба аларның эшчәнлеге әдәби хәрәкәт эченә үтә барды. Суфичылык әдәбиятының тәэсире дә зур роль уйный. Шәригать әһелләре дә хәдисләр, аятьләр, вәгазьләр аша яшәешнең, кешеләрдәге сыйфатларның уңай-тискәре якларына игътибар юнәлтәләр. Г. Курсави, Г. Утыз Имәни, Т. Ялчыгол, Ә. Каргалый, Кол Мөхәммәд, Һ. Салихов, Г. Кандалый һ. б. иҗатларында дини мәсьәләләр белән бергә, иҗтимагый, әхлакый карашлары да чагыла. Аларда гаделлек, кешелеклелек, ярдәмчеллек, гыйлемлелек уңай бәяләнеп, аның каршысы булган явызлык, байлык артыннан куу, наданлык сыйфатлары тәнкыйтьләнә. Әлеге чор әдипләренең фикерләре мәгърифәтчелек идеяләре көчәйгән хәлдә әдәбият мәйданына килеп чыга. И. Нуруллин фикеренчә: «Бүгенгедә үткәннең калдыклары һәм киләчәкнең яралгылары була. Чөнки җәмгыять туктаусыз үсеш-үзгәреш процессы кичерә. Төрле формациядә яшәгән кешеләр аң һәм карашлары ягыннан бер-берсеннән никадәр аерылмасыннар, барыбер кеше булып калалар, һәм күп кенә гомумкешелек сыйфатлары аларны берләштерә, бер-берсенә якынайта» [4: 12].

XVIII йөз ахыры – XIX йөз башында иҗат иткән шагыйрь Кол Мөхәммәд (1777–1849) «Мөһиммә әс-сыйбьян» («Сабыйларның бурычлары», 1810) һәм «Тәгъриф әл-вилдан» («Балаларга аңлатма», 1815) исемле шигъри әсәрләрендә әхлак мәсьәләләрен яктырта. Алар фәлсәфи-дидактик планда язылып, дин, шәригать, әхлак, мәгърифәт темалары белән бергә үрелеп бирелгән.

Мәшһүр тел галиме, мәгърифәтче, энциклопедист галим Каюм Насыйри да (1825–1902) әлеге темага «Балаларга тәгълим бирмәк», «Бала тәрбия кылучы хатыннарга нәсыйхәт» мәкаләләре, «Әхлак рисаләсе» (1881, 1890), «Китаб әт-тәрбия» (1891), «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» (1884) китапларын багышлый. «Китаб әт-тәрбия» («Тәрбия китабы») әсәрендә (1891) «тәрбия» төшенчәсенең төрле якларына мөрәҗәгать итә. Барлыгы 113 тәрбиядән гыйбарәт булган бу әсәр, кешелек арасында әдәплелек, хөрмәт, гыйлем, сабый чактан тәрбиялелек, юмартлык, дуслык кебек аспектларга тукталып, үгет-нәсыйхәт, вәгазь кебек кабул ителергә тиешле. Кол Мөхәммәд шигъри әсәрләрендә һәм К. Насыйринең «Китаб әт-тәрбия»сендә гыйлем-мәгърифәт белән бәйле моментларга тукталу мөһим. Алардагы әхлак-тәрбия-гыйлем темалары һәр чорда актуаль.

Билгеле булганча, Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) дә белемле булуга өндәүләре хәдисләр аша килеп җиткән: «Кытайга барып булса да белем алыгыз, чөнки белемгә өйрәнү һәр мөселман өчен фарыз», «Мөселман кеше белемгә өйрәнеп, белгәнен дин кардәшенә өйрәтсә, шул сәдаканың иң яхшысы булыр», «Белем гыйбадәттән өстен, ул диннең төп кисәге» [2].

Кол Мөхәммәднең «Мөһиммә әс-сыйбьян» поэмасында укый-яза белү, мәгърифәт – олылык, зурлык билгесе диелә:

Тарикъ әһле сөннәт сәвад *(укый-яза белү)* әгъзам,
Вә игътәсыйму әл-җәбәл Алла *(Аллаһы тавына тотыныгыз)* диде иляһым.

«Тәгъриф әл-вилдан» поэмасында мәгърифәт кешеләре котылу юлында булырлар, «гыйлем – хөрмәт» дип ассызыклый:

Әй, талиблар, гомер үтәр, гафил улмаң,
Форсат варда укымай надан калмаң.

Тәхсыйл куеп гыйлемлекдин коруг калмаң,
Гыйлем – шәрәф бик белең имди.

Каюм Насыйри да «гыйлемсез эш кылган кеше – юлсыз йөргән кеше белән бәрабәрдер» [1: 231], «гыйлем, әлбәттә, пәйгамбәр мирасыдыр (20 нче тәрбия)» [3: 21–22] дип, гыйлемнең әһәмиятлелегенә басым ясый.

Мондый чагыштырулар белән әдипләр укырга, белем алырга, мәгърифәткә өндиләр. Кол Мөхәммәд поэмаларында һәм Каюм Насыйри «Китаб әт-тәрбия»сендә балаларга, шәкертләргә турыдан-туры мөрәҗәгать итеп, татар халкының тәрбия тәҗрибәсенә таянып, төпле киңәшләре урын ала. Әдипләрнең икесе дә балаларга яратып, «угыл, әүляд, фәрзанд, сыйбьян» сүзләре белән эндәшә, яшь буынны рухи-әхлакый саф итеп тәрбияләргә тырышып, алдагы юлларында дөрес юнәлеш бирергә омтыла. Шәмсетдинова (Гарипова) Л.Ш. тикшеренүләрендә дә тәрбия мәсьәләләре игътибарга алынып, нәсыйхәт-гыйбрәтләр мисалында, халыкның педагогик мирасына өстенлек бирелә [5].

Каюм Насыйрида «белемле кеше уңай әхлаклы була, надан кеше – әхлакый нигездән ерагая; надан, тиле янында йөрсәң, үзең дә шуңа охшый барасың», дигән фикер уздырыла (6 нчы тәрбия)» [3: 9].

Белемне бала чактан ук өйрәнергә тиешле дип искәртәләр әдипләр, шул вакытта физиологик яктан да, рухи чисталык ягыннан да бар гыйлем җиңелрәк, тизрәк үзләштерелә дигән фикердә торалар. Хәзерге заман галимнәре бу фаразны фәнни исбатлап та бирәләр. Гыйлем исә һәрчак өстәлергә, арттырылырга тиешле.

К. Насыйри «Китаб әт-тәрбия»сендә: «Яшь чакта алган гыйлем ташка чокып ясалган бизәккә охшаш (34 нче тәрбия)», ди [3: 32]. Кол Мөхәммәд тә вакытны бушка уздырмаска, яшь чак тиз үтә, картлык тиз килеп җитә, гафил булма дип, кат-кат искәртә. Яшь чакны – җил белән, яшен яктыртуы белән чагыштыра. Г. Кандалыйның «Йакутлар табыладыр вакыт берлән, вакытлар табылмыйдыр йакут берлән» дигән бик тә мәгънәле сүзләре бар.

К. Насыйри 35 нче тәрбиясендә белем алуга сәләтле булуның кирәклеген дә ассызыклый, һәрбер кешегә, һәрбер балага бер үк тәрбия-тәгълим биреп тә, төрлечә кабулителергә мөмкин, бай – гавам балалары белән чагыштыру килешмәвен әйтә [3: 32–33].

Остаз белән шәкерт мөнәсәбәте аерым игътибарга лаек. Кол Мөхәммәд «Тәгъриф әл-вилдан» поэмасында бу мәсьәләгә берничә бүлек багышлаган: «Фи хак әл-остаз гали тәлямизә» (Остазлар хакы турында), «Фи бәяне зәм талибәтә замана» (Замана шәкертләрен шелтәләү бәянында), «Фи бәяне васыяти талибан» (Шәкертләргә васыять бәянында). Автор шәкертләргә остазларын хөрмәт итәргә тиешләр дигән фикердә торып, хәтта шуны таләп итә. Укучыларның белемле булуларында мөгаллимнәрнең өлеше чиксез зур:

Аның өчен остаз илә хакны белде,
Надан ирде, остазындин гыйлем алды.
Фарыз, ваҗиб остазындин ул үгрәнде,
Иман-ислам барын андин белде имди, ди.

Остаз олы яшьтә булса да, аны ташламаска, хөрмәтләргә, аның тәрбиясен хаклап яшәргә куша:

Остазының хөрмәтени саклаялар,
Остазына дошманлыкы кылмаялар.
Надан дию хәкарәти *(хурлау)* кылмаялар,
Чөнки сине золмәтдин *(наданлыктан)* чыкарыр имди.
Надан ирдең «Әлифба»ны һәм белмәгән,
Остазыңдин үгрәндең һәрнә белән.
Кани сәңа юк йиргә лаф оран,
Фикер кылсаң, андин күб сән надан имди.

К. Насыйрича шулай ук акыл ияләре – хөрмәткә лаек кешеләр: «Гакыл ияләре белән вә гыйлем әһле белән аралашу вә сер кыйлмак күңелләрне тергезер. Вә гыйлем вә мәгърифәт әһле белән сер кыйлмак ислемай сатучылар янында тормак белән бәрабәрдер ки, гәрчә сиңа ул ислемай бирмәсә дә, хуш исе борыныңа керәдер. Наданнар вә явызлар белән гәпләшү – тимерчеләр янында тормак белән бәрабәрдер: очкыннары сиңа килеп сачрар, шулай ук наданның наданлыгы әсәр итәдер (72 нче тәрбия)» [3: 52].

Кол Мөхәммәд һәрчак галимнәрне, остазларны, мөгаллимнәрне хөрмәтләп, олылап, алар өчен догада булып, мин-минлекне күрсәтмичә яшәргә куша. Киресен эшләгән шәкерт – наданлыгын күрсәткән, түбән зат. К. Насыйри да ахмак һәм надан адәм дуслыкка да, дошманлыкка да ярамас дигән фикердә: «Әй угыл, гадүе гакыйл хәер мин садыйки җаһил» *(«Акыллы дошман надан дустан яхшырак» мәгънәсендә).* Ахмак вә надан адәм дустлыкка вә дошманлыкка һәм ярамас. Вә һөнәрсез кеше дустлыкка ярамас. Саклан шул кешедән ки, үзе бернәрсә белмәс, үзен галим вә белекле санар. Бер эшне бер мәртәбә эшләп тугры килмәсә, икенче мәртәбә ул эшкә тотынма, вә кулыңнан килмәгән эшкә тотынма (82 нче тәрбия) [3: 59]; «Ахмак үз-үзенә кыйлган кадәр зарарны гакыллы адәм дошманына да кыйлмас (87 тәрбия)» [3: 61–62]. Кол Мөхәммәд тә, Каюм Насыйри да иҗатларында үзен галим, остаз дип санаган «белемсез» адәмнәрдән ераграк торырга, сакланырга тәкъдим итәләр.

Әлеге әсәрләр белән барлык әти-әниләргә, тәрбияче-укытучыларга танышып чыгу бик мөһим. Алар методик кулланма кебек тәрбиялелекнең барлык аспектларына тукталалар. Әлеге әдипләр иҗатлары хәзерге вакытта да актуаль булып кала. Әсәрләрдәге үгет-нәсыйхәт, тәрбия киңәшләре бик тә файдалы. Каюм Насыйри сүзләре белән мәкаләне тәмамлыйсы килә: «Вә дәхи олуглык вә игелеклелек дигән нәрсә гыйлем вә әдәп beләндер вә күркәм әхлак беләндер».

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Әдәбияттан хрестоматия-дәреслек: 8 нче класс өчен / төз. Л. Җәләй. Казан: Татгосиздат, 1947. 480 б.

2. Мең дә бер хәдис. Казан: Иман, 1992. 64 б.

3. *Насыйри К.* Китаб әт-тәрбия. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 143 б.

4. *Нуруллин И.З.* Әдәбият теориясе: Әдәби процесс. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 143 б.

5. *Шамсетдинова Л.Ш.* «Рисаләи Газиза» Таджетдина Ялчыгула (проблематика и поэтика): дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002.

УДК 070

# ПРОСВЕТИТЕЛЬСТВО НАСЛЕДИЯ КАЗАХСКИХ ЖЫРАУ

**_А.К. Ишанова_**
_Евразийский национальный университет им. Л.Н. Гумилева (Астана, Казахстан)_

В статье феномен наследия жырау рассматривается как одна из уникальных и ранних основ формирования тенденции общетюркских традиций просветительства, когда жырау всем свои творчеством и жизнью доказывал первостепенное значение таких констант, как любовь к Родине, знание, истина, справедливость, честь, долг, нравственное бытие.
**Ключевые слова:** жырау, феномен, просветительство, толгау, добро, зло, номадизм.

This article explores the phenomenon of zhyrau heritage as one of the unique and early foundations in shaping the pan-Turkic tradition of enlightenment. Through their creative works and way of life, zhyrau consistently affirmed the paramount importance of enduring values such as love for the homeland, knowledge, truth, justice, honor, duty, and moral existence.
**Keywords:** zhyrau, phenomenon, enlightenment, tolgau, good, evil, nomadism.

Феномен поэзии казахских жырау еще до конца не изучен и с течением времени притягательность их наследия только возрастает. Заслуживает особого внимания точка зрения Е. Турсынова о том, что корни поэзии жырау уходят в далекий, I век до нашей эры [1: 29].

В данной работе мы выделим лишь несколько аспектов исследования своеобразия жырауской поэтики, связанных с первыми тенденциями просветительства в общетюркском наследии.

Выделим общие, основные принципы жырауской поэтики, отличающие их от эпоса:

| Жырауская поэзия | Эпос |
|---|---|
| Наличие авторского, внутреннего голоса | Анонимность, безличность |
| Самоуважение, вечное самоутверждение, восславление себя и своего рода, наряду с культом предков | Воспевание предков |
| Акцент на настоящем | Ппоэтизация прошлого |
| Социальная маркировка добра и зла | Вневременные границы добра и зла |
| Разделяются слово и предмет | Еще есть единство слова и предмета |
| Порождение номадической реальности, где в особом почитании сила слова | Порождение военной магии |

Во многом уникальность и притягательность поэзии жырау в том, что здесь мы обнаруживаем идеальный образ степного номада, которому свойственны любовь и воспевание родной земли, почитание родителей, сильный дух воина, максимализм во всем, отрицание чуждого мировоззрения, четкое различение добра и зла, умение достойно встретить смертный жребий, любовь к жизни и стремление к просветительству родного народа.

Феномен поэзии жырау связан с особым переживанием пространства как неотъемлемой части себя, что не всегда встречается даже в современной литературе, скорее, наоборот, в современной поэзии и прозе есть распадение их на различные составляющие, что и вызывает дискомфорт человека.

В программном толгау Казтугана жырау все это прослеживается особенно четко. Поэтика самопредставления связана со стремлением не только дать яркий автопортрет, но и идеальный образ номада XIV–XV веков. Много черт, указующих на осознание исключительной роли, особого предназначения жырау на этой земле: «Мыслителя лоб, выступают виски», – в не очень точном переводе тем не менее указание на «двурогость» как особую примету яркой личности, предводителя, завоевателя, просветителя, победителя.

Казтуган воссоздал в знаменитых строках обобщенный портрет воина-жырау, в котором важную значимость приобретает лицо с приметами сакрального предназначения человека:

| | |
|---|---|
| «Бүдырайған екі шекелі<br>Мұздай үлкен көбелі<br>Қары ұнымы сұлтандын жүрісі»<br>[2: 21] | «С буграми висков, выпирающих в стынь,<br>В доспехах из плотных, блестящих пластин.<br>На вид как султан, покоряю собой»<br>[2: 59] |

Известна частая ссылка в древнетюркской традиции на выступающие виски как признак избранности, сакральности в плане особого предназначения вести и просвещать народ – подобная деталь есть в описании лица Искандера Двурогого, в поэме Джамбула об Утеген-батыре. Это подтверждается и финальной строкой:

«Ему путь особый судьбою был дан.
Он сын Суюниша, батыр Казтуган» [2: 29].

Для Казтугана – это, прежде всего, воплощение собственного особого предназначения. Жырау-воин – носитель идеальных героических черт победителя с открытым лицом, отвергающий какие-либо маски и знающий о том, что «нет страшнее смеха подленьких людей» [2: 29].

Поэтику жырау формирует особая стадия развития номадического мировоззрения, когда кочевник неразрывно связан с природой, отсюда изобилие таких сравнений, как «клык молодого верблюда-самца», «вороний коготь», «шелковая нить мощного лука». Огромная физическая мощь сочетается с невероятными способностями: «От туч он очистил небесный простор. / Он солнцу дорогу пробил сквозь туман / Средь многих неверных / И средь мусульман».

Особое чувство родового единства как источника духовной мощи человека – сквозной мотив многих толгау, не случайно почти в каждом толгау жырау стараются назвать имя матери и отца.

Здесь важно заметить, что казахские батыры не совершали подвиги для личного торжества и возвеличивания себя над толпой. Они служили народу и самим же народом и возносились. В этом толгау Казтуган – идеальный носитель таких архетипических качеств, как мощь, преодоление, сила, причем не только физическая, он способен покорить не только вра-

гов, но и природу, отвергая чуждую религию, утверждая ценности своего вольного, кочевого народа. В идеальном герое жырауской поэзии подчеркнута гармония физического и духовно-нравственного, где нравственность неотделима от качеств воина-защитника, человека сильного духом.

Откуда же эта гармония внешнего и внутреннего, становящаяся истоком невероятной духовной силы? Внимательное вчитывание в строки толгау позволяет предположить, что есть несколько истоков этой внутренней силы – культ предков, вера в аруахов и особое ощущение родства с пространством степи, слиянное ощущение себя как части природы со всеми ее обитателями – беркутами, воронами, волками, степью, облаками, небом, горами. Безусловно, жырау еще не утратили мифологически-тотемическое ощущение единства с природой, но это уже новый этап осмысления своего «я», в сравнении с фольклорным и мифологическим мирофоззрением, здесь присутствуют элементы субъективной эмоциональности, что еще более становится заметным при сравнении текстов разных жырау, даже живших в одну эпоху, к примеру, Казтуган и Асан Кайгы.

Именно это совпадение с самим собой, отсутствие ложных масок, «лисьей игры» позволяет жырау достойно встретить смерть, как это делает Доспамбет-жырау. Камча, жена, родной край, Ак-Жаик, воинская доблесть и честь человека – образы-константы его земной жизни. Заклинанием-повтором – «не жалею о том», Доспамбет-жырау запечатлевает милые сердцу образы в последний миг сознания – тугай, секиру, стрелу, тулпара, красавицу-жену:

| | |
|---|---|
| «Өкінбестей болғанмын.<br>Ер Мамайдың алдында<br>Шаһид кештім, өкінбен!..»<br>[3: 124]. | «Мне не о чем в жизни своей сожалеть<br>Я пал пред Мамаем самим храбрецом,<br>Я пал как герой – не жалею о том»<br>[2: 38]. |

Цельность личности, способного в последние мгновения жизни слагать толгау, не сетуя и не жалуясь на судьбу, а утверждая приятие смерти во имя жизни и народа, подобных примеров очень мало. Не имея возможности записать, кочевники на века запечатлели, передавая из уст в уста последнюю песнь жырау-батыра, осмысливающего всю свою жизнь, словно проматывая кинематографическую пленку.

В творчестве жырау XV века запечатлен идеал человека, не признающего двойственности ролей, двуличия. Эта честность, архаическая чистота и цельность – главная основа образа благородного батыра, способного отдать жизнь за свободу народа.

В творчестве Шалкииз-жырау впервые определенно зазвучал мотив иного человека – носителя маски, связанный с нравственным сознанием, на доминанту «жаман-жақсы» указывает и А. Кодар [4: 61] плохого и хорошего, добра и зла: «Жаманға сырыңды қосып сөз айтпа» [3: 127].

«Хорошие люди – гора, куда не взлетает слова.
А людям плохим – так я думать привык –
Самим же во вред их болтливый язык.
Пронырливость лисья – плохая игра,
Не может она довести до добра» [2: 45].

Жырау уверен, что хитрость, лесть, болтливость, прагма-игра всегда бывают разгаданы и влекут за собой ответную негативную реакцию.

В казахской классике есть мотив, варьирующийся в творчестве Жиембет-жырау, М. Жумабаева, Шакарима и связан он с поведенческими стереотипами прагма-игр. Самое известное произведение Жиембета-жырау связано с попыткой в поэтической форме объясниться с Есим-ханом. Существуют две версии причин разлада его взаимоотношений с Есим-ханом. По одной он навлек на себя гнев хана из-за стремления стать независимым, утверждая собственную власть и авторитет в Младшем жузе. По другой версии, его младший брат Жолымбет влюбился в калмычку, предназначенную хану. Именно об этом мы узнаем из поэтического наследия жырау и потому можем говорить лишь об этой, второй причине ссылки жырау в восточную часть ханства. Поэтическое наследие жырау позволяет нам сделать вывод о том, что он отверг поведенческий стереотип, прагма-игру, сулившую ему благополучное существование. Жырау осмелился противопоставить любовь, истину, свободу – власти. Это и было основой первых просветительских тенденций в самых первых образцах тюркского устного литературного наследия. Жиембет противопоставляет игре хана свое открытое мужество и отвагу воина:

«Меніменен, ханым, ойнаспа,
Менің ерлігімді сұрасаң,
Жолбарыс пенен аюдай» [3: 131].

Нетрудно заметить сходство этой коллизии с основной интригой знаменитой поэмы М. Жумабаева «Батыр Баян». Если батыр Баян вынужден был осудить своего юного брата и собственноручно свершить над ним скорый суд, урезав и собственную жизнь, то Жиембет жырау занимает сторону брата, не позволив разрушить любовь, поступившись своими привилегиями, саном, даже решившись на разлуку с родным краем. И та, и другая история имели под собой реальную основу. Но невольно мы обращаем внимание на прямо противоположную позицию двух известных в народе личностей в конфликте любви и власти, понятий чести, патриотизма, долга. Финал судеб батыра и жырау одинаково далек от довольства и покоя. И все-таки, выступивший за любовь против власти хана, Жиембет-жырау сохранил брата и любовь. Батыр Баян же лишился всего. Не пожелав больше жить, он сохранил сознание чести рода. Тем самым, в классической казахской литературе находит разноплановое воплощение тема прагма-игр дискурсами поведения. Слепое подчинение ритуалам-традициям рассматривается в аспекте трагедийного потрясения судьбы. Тем самым первые тенденции просветительства в ранних образцах тюркской поэзии жырау связаны с установлением традиции борьбы за истину и справделивость.

В знаменитом толгау «Одиночество» Махамбет Утемисов с горечью отмечает, что у многих благородство проявляется лишь на словах, а не на деле. Сам он не был человеком маски, как и Курмангазы.

Казахскую литературу XV – начала XX веков отличает отказ от двуличия, отказ от маски. Эта позиция характерна уже для многих жырау вплоть до поэтов и прозаиков начала XX века. Если в поэзии тюркских авторов X–XII веков преобладают мотивы игры, проявляющие тесную

связь природного и человеческого миров (М. Кашгари, Ю. Баласагуни), то в казахской классической литературе XIX века мотивы и образы игры уже больше тяготеют к темам социальным, просветительским и нравственно-психологическим.

В одном из толгау Казтуган жырау четко прослеживается особое ощущение связи времени и степного пространства:

«Степная земля бесконечна, как время…
Земля – черно-белой Орды поселенье.
Земля, на которой отец мой Суюниш
Сыграл свою свадьбу под пляски и пенье.
Где мать Бозтуган по старомуц чину
Невестою стала, где в злую годину
Родился я маленький, как вороненок.
Земля, где обрезали мне пуповину,
Земля, что обмыла меня, обстирала,
Земля, подарившая мне лук из тала,
Набившая стрелами густо колчаны,
Земля, что меня от врагов укрывала» [2: 29].

Бесконечность времени и земли для номада – знак бесконечности жизни. Впервые именно в поэзии жырау появляется социальный конфликт. И если даже Казтуган жырау, в отличие от Жиембета жырау, не проговаривает нам причину его ссылки и прощания с родной землей – именно эта мысль сквозная в его толгау «Степная земля бесконечна, как время…», мы можем предположить, что он также столкнулся с несправедливостью или предательством. Но даже оказавшись в западне, жырау могли утешать себя вечностью времени и родной земли, а значит, неуничтожимостью добра, истины, правда, в толгау более позднего времени, такое ощущение времени и пространства встречается все реже. Подобная позиция казахских жырау способствовала выработке сильных нравственно-социальных норм бытия, необходимых впоследствии для развития собственно просветительства в последующие века для всех тюркских народов.

В данном переводе на русский язык (переводчик Владимир Цыбин) допущена большая неточность, сравнение с вороном несет в себе изначально сакральную символику особого предназначения.

«Родился я маленький, как вороненок.
Земля, где обрезали мне пуповину…»

Финальные строки толгау – описание красоты степей и благословение остающимся у брегов родного Едиля, когда только и становится понятным, что это последний поклон-воспевание родной степи.

Однако в этом толгау есть одна строка, подтверждающая возможность возникновения социального конфликта жырау и ханской власти:

«Равны перед песней бедняк и богатый,
Стригун и лихой иноходец поджарый,
Холмы и лощины,
Песок и щебенка.
Здесь корень съедобный – размером с теленка» [2: 31].

Итак, в наследии жырау мы видим формирование уникальной основы тенденций формирования просветительства как утверждения таких ценностей, как любовь к родной земле, защита истины и справедливости, нравственно-философских основ национального бытия, формирующих национальное самосознание тюрков во все времена и эпохи. Поэтика пространства и личности в творчестве казахских жырау отличается уникальным ощущением единства с мирозданием, что позволяло черпать особую внутреннюю силу и гармонию мироощущения, почти утраченную современным человеком. В художественных текстах современных авторов мы наблюдаем как по-особенному, по-разному человек пытается вновь обрести это единство с окружающим пространством, проживая его уникальность в слиянии с собственными мыслями и поступками. И если современному автору для этого нужны чаще всего покой и уединение на лоне природы, то жырау не нужно было прилагать особых усилий для ощущения единства мироздания, для проживания пространства как части собственного бытия. Основными способами передачи этой идеи становится выдвижение на первый план природного мироздания, где каждая травинка, гора, река самоценны сами по себе, помимо этого жырау используют сравнения мифо-тотемического наполнения, что еще больше подчеркивает ощущение единство человека и степного пространства, не утраченное жырау, где он и черпает гармонию мироощущения и силу духа.

Тем самым, феномен наследия жырау является одной из основных и ранних основ формирования тенденции общетюркской традиции просветительства, когда жырау всем свои творчеством и жизнью доказывал первостепенное значение таких констант, как любовь к Родине, знание, истина, справедливость, честь, долг, нравственное бытие и счастье народа.

СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1. *Турсунов Е.* Возникновение баксы, акынов, сэри и жырау. Астана: Фолиант, 1999. 267 с.

2. Поэты пяти веков / под ред. М. Магауина. Алматы: Жазуши, 1993. 330 с.

3. Екімыңжылдық дала жыры. Алматы: Қазақ энциклопедиясы. 2000. 752 б.

4. *Кодар А.* Мировоззрение кочевников в свете степного знания // Культурные контексты Казахстана. Алматы: Ниса, 1998. С. 56–66.

УДК 811.512.145

# ФРАЗЕОЛОГИЗМЫ С КОМПОНЕНТОМ «ГЛАГОЛ ДВИЖЕНИЯ» В СТАРОТАТАРСКИХ ПИСЬМЕННЫХ ПАМЯТНИКАХ XV–XVI ВЕКОВ

***Э.Х. Кадирова***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казань)*

В статье дается информация о фразеологизмах с компонентами – глаголами движения в старотатарских письменных памятниках XV–XVI вв. Актуальность объясняется тем, что фразеология старотатарского языка малоизучена. Исследование показало, что устойчивые выражения с глаголами движения

широко распространены в данном периоде старотатарского языка. Самыми распространенными глаголами движения в составе фразеологизмов оказались глаголы төш- и кил-. Как показывают наблюдения, основной корпус фразеологизмов данного типа сохранился в активном фонде татарского языка и по сей день.
**Ключевые слова:** фразеологизм, татарский язык, старотатарский язык, глаголы движения.

The article provides information on phraseological units with components - verbs of motion in Old Tatar written monuments of the 15th–16th centuries. The relevance is explained by the fact that the phraseology of the Old Tatar language is poorly studied. The study showed that set expressions with verbs of motion are widespread in this period of the Old Tatar language. The most common verbs of motion in phraseological units were the verbs төш- and кил. As observations show, the main corpus of phraseological units of this type has been preserved in the active fund of the Tatar language to this day.
**Keywords:** phraseology, Tatar language, Old Tatar language, verbs of motion.

## XV–XVI ГАСЫР ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ ХӘРӘКӘТ ФИГЫЛЬЛӘРЕ ЯРДӘМЕНДӘ ЯСАЛГАН ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР

***Э.Х. Кадирова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

Билгеле булганча, хәрәкәт фигыльләре теләсә кайсы телдәге лексиканың мөһим һәм әһәмиятле катламын тәшкил итә. Өстәвенә, алар үзләренең төп мәгънәләрендә кулланылу белән генә чикләнмиләр, башка сүзләр белән бәйләнешкә кереп, күчерелмә мәгънәләр дә барлыкка китерәләр. Мәкаләдә Казан ханлыгы чорының иске татар теле язма истәлекләрендә хәрәкәт фигыльләре белән ясалган фразеологизмнарга күзәтү ясала. Куелган максатка ирешүдә түбәндәге бурычлар билгеләнә: XV–XVI гасыр язма истәлекләрендә хәрәкәт фигыльләре белән ясалган фразеологик берәмлекләрне барлау; аларны хәзерге татар телендәге шул төр фразеологизмнар белән чагыштырып, уртаклыкларын һәм аерымлыкларын күрсәтү. Хәрәкәт фигыльләре элек-электән күп кенә тел галимнәренең игътибарында булды. Алар төрки телләр, шул исәптән татар теле материалында төрле аспектларда өйрәнелде [Тенишев 1961; Хуснутдинов Д. Х., Сагдиева Р.К., Сибгатуллина И.К., 2018; Gilazetdinova G.Kh., Salakhova R.R.: 2018]. Иске татар телендә хәрәкәт фигыльләре белән бәйле тотрыклы гыйбарәләргә караган сораулар әлегә тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә кала. Бу хезмәтнең актуальлеген һәм фәнни яңалыгын билгели. Материалларны югары уку йортларында һәм көллиятләрдә татар әдәби теле тарихы фәнен укытуда, шулай ук иске татар теле сүзлекләрен төзегәндә кулланырга мөмкин.

Борынгы чорларда ук фразеология әдәби әсәрнең тел тукымасын оештыруда иң актив сурәтләү чараларыннан санала. Аларның төзелешен, семантикасын, кулланылыш үзенчәлекләрен, стилистик функцияләрен билгеләү авторларның иҗат методы үзенчәлекләрен ачарга мөмкинлек бирү белән беррәттән, иске татар әдәбиятының һәм теленең байлыгын,

төрлелегән бәяләргә, татар теленең фразеологик системасы тарихын ачыкларга ярдәм итә.

XV–XVI гасыр иске татар теле үрнәкләре булып, Мөхәммәдьярның поэмалары, Кол Шәриф иҗаты, «Кыз хикәяте», Өмми Камал әсәрләре, Максудиның «Могҗизнамә»се, «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» һәм «Сиражел-кулүб» истәлекләре тора.

Сүзләрне еш кына күчерелмә мәгънәдә кулланган, әсәрләрендә әйтергә теләгән фикерләрен һәрвакыт фразеологик әйтемнәр, тапкыр сүзләр, мәкаль-әйтемнәр белән күрсәтеп биргән шагыйрь Мөхәммәдьяр иҗатында без хәрәкәт фигыльләре белән бәйле тотрыклы гыйбарәләрнең матур үрнәкләрен күрәбез. Өмми Камал иҗатында, Максудиның «Могҗизнамә»сендә дә хәрәкәт фигыльләре белән ясалган фразеологизмнар күп. Кол Шәриф әсәрләре, «Кыз хикәяте»,«Зафәрнамә-и вилаяте Казан», «Сиражел-кулүб» истәлекләре аларга бай түгел.

Истәлекләрдә кил-, йөр-, чык-, кит-, төш-, кер-, кич-, дүн- фигыльләре белән ясалган тотрыклы сүзтезмәләр урын ала:

кил-: *башка килү* (Нә ки телдин чыкты – ул башка килүр) [3: 206]; *телдин килү* (Бәс, ни килсә башка, бел, телдин килүр) [3: 206]; *телгә ни килү* (Телгә ни кем килсә күңүлдин рәуан) [3: 225]; *элеңдин нимә килмәү* (Элеңдин нимә килмәс, – қылмагыл лаф) [3: 48]; *сүзне куа қилү* (Сүзне куа килдем уш, и мәрде пир) [3: 55]; *кулуңдин килгәнчә* (Кем қулуңдин килгәнчә қыл йахшылық) [3: 66 ]; *элкидин килгәнчә* (Элкидин килгәнчә изгү қылгайлар) [3: 67]; *йадга килү* (Бер хикайәт килде йадга уш нәзыйр) [3: 67]; *гакылга килү* (Гақлыңа килгел, фәқир, сән бер нәфәс [3: 73]); *туш килү* (Догаси хәқ хәзрәтендә түш килеб, һәлақ булды атаси қарны йарлыб) [3: 81]; *күңүлгә килү* (Бер хикәйәт килде күңлүмгә нәзыйр) [3: 55]; *күз йомуб ачгунчә килү* (Күз йомуб ачгунчә килдем эүгә хуш) [3: 196]; *хуш килү* (Шаһга хуш килди анын бу сүзләри) [3: 200]; *ләббәйкә кәлү* (Раббе тийү аңа бакса, кәлүр ләббәйкә йөз-мең йандин) [1: 340];

кит-: *йөзидин рәнге киту* (Сөфрасе қайнаб, йөзидин рәнге китте) [3: 48]; *гақлы киту* (Гақлы китеб башындин, йәшәрде күзи) [3 : 95]; (Гаклы китәр – һәркем күрсә йөзени) [2: 74] *усы киду* ʽһушы китү’ (Шу диклү мәдех сәналяр кыйлур кә усы кидәр) [6: 274];

төш-: *күзи төшу* (Бер йегеткә төште нагәһан күзи) [3 : 57]; *хатергә төшу* (Аны таңлаб ултурурда нагәһан Хатеремгә төшти фикрәт ул заман) [3: 224]; *фикер дөшу* (Бер фикер дөшде үгүмә) [2: 50]; *арайа сүз дөшу* (Өч көн улды, сүз дөште арайә) [2: 52]; *күңеле төшү* (könglüne tüşgendin ötrü merg vehmi nâ-gehân) [ЗВК : 335], *айагына дүшү* (төшү) (Кеми әлин үпәр кеми айагына дүшәр улды) [6: 281], (Килүб, атасының айакыга төшде, бере-бере берлә күрешделәр) [СК: 73]; *эндишә төшу* (Дәстүр бирсәңез, мәнем күңлүмгә сәфәр кылмак эндишәсе төшде [СК: 86];

чык-: *телдин чыку* (Нә ки телдин чыкты – ул башка килүр) [3: 206]; *сүздин чыкмау* (Ни бойурса, чыкма аның сүзедин) [3: 195]; *күңелдән чыкару* (Чүн чыкаруб сән күңелдән мөһерини эгъйарның) [6: 400]; *элдән чыкару* (Анлари чыкарма элдән белкә йар анлар дурур) 6: 421]; *башка чыгу* (Кемсә башына чыкмады бу кыз иллә, Нә гилме илә, нә худ коры сүз илә) [2: 56];

йөр-: *үзүңне үзүң қабартыб йөрү* (Йөрүрсән үзүңне үзүң қабартыб) [3: 46]; *телдә йөрү* (*Бер көн үзе вәгз эчендә нагәһан Кем телендә йөрүде бу сүз рәуан)* [3: 210]; *телләр үзә йөрү* (*Хан доғасы йөрүгәй телләр үзә, Важҗи ирүр дөнйада илләр үзә)* [3: 223]; *акча йөрү* (Пул йиренә анда йөрүр акчалар) [2: 54];

бар-: *тәфәккергә бару* (тәфәккергә барды, ул заман Җәбраил галәйһиссәлам хәзер булды) [5: 76];

кич-: *гомер кичү* (Кем кичди гомер дүшди кара сачмә агълар) [6: 369];

кер- : *төшкә керү* (Керде төшенә аның шаһи җәһан) [3: 210]; *йулга керү* (Әгәр дә тәүбәләнеп, заһид юлына керсә, Аллаһы Тәгалә аның тәүбәсен кабул кылырмы, гөнаһын ярлыкармы?» – дип сорады) [5: 61], (Иртәсе янә кәлде, мәликне иманга дәгъвәт кылды, андаг әйде: «Кем, әй, юл бетүрмеш, кил, кил, юлга кереп Хак Тәгаләнең берлегенгә инангыл) [5: 67]; *йөккә керү* (Әй, заһид. янә моның тик хат биреб, йөккә керсәң, янә анларны һәм ярлыкармын) [5: 63]; (Зөлкифелгә аның өчен Зөлкифел тимешләр, кем Тәңре Тәгаләнең фазылына инанып, карендәшегә нәсыйхәт биреб, йөккә кереб, бәтик бирмеш) [5: 63]; *сүзгә керү* (Сүзләйү уш сүзгә кердем мән фәқир, Бер хикайәт қылайым моңа нәзыйр) [3: 41]; *сүзә керү* (Тәңри ады берлә сүзә керәклүм) [6: 332].

Бу төр фразеологик өйтелмәләрнең семантикасына килсәк, алар кешенең холкын, рухи халәтен, физик халәтен, кешенең уйлау эшчәнлеген, кешенең тышкы кыяфәтен, гамәлләрен, шәхесара мөнәсәбәтләрне чагылдыралар.

Тикшеренү хәрәкәт фигыльләре белән төзелгән тотрыклы әйтелмәләр иске татар теленең шушы чорында киң таралган булуын күрсәтә. Алар еш кына трансформацияләнмәгән хәлдә киләләр, ягъни гомумтел фразеологизмы автор тарафыннан нинди дә булса структур-семантик үзгәрешләрсез кулланыла: *сүзгә керү* ʽсөйләшә башлауʼ [3: 41], *сүзне куа килү* ʽсүз куертуʼ [3: 55], *сүздин чыкмау* ʽсүздә торуʼ [3: 195].

Якынча күзәтүләр күрсәткәнчә, әлеге төр фразеологик берәмлекләрнең төп корпусы хәзерге көнгә кадәр татар теленең актив фондында саклана.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Кол Шәриф.* И күңел, бу дөньядыр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 94 б.

2. Кыз хикәяте / төз.-авт.: Р.Ф. Мәрданов. Казан: Милли китап, 2012. 184 б.

3. *Мөхәммәдьяр*. Нуры содур: Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.

4. *Мөхәммәт Әмин*. Могҗизнамә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 295 б.

5. Сираҗел-колүб. Казань: Типография Т-го Дома Братьевъ Каримовыхъ, 1903, 93 б.

6. *Фатхтдинов Ф.К.* Өмми Камал китабы. Казань: ИЯЛИ, 2022. 648 с.

7. *Хуснутдинов Д.Х., Сагдиева Р.К., Сибгатуллина И.К.* Глаголы движения в татарском языке // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота. 2018. № 4 (82). Ч. 2. С. 403–406.

8. *Melek Özjetgin A.* Astrahanlı Şerifnin 1550 tarihlı Zafer-namesi // Türkoloje dergisi. Ankara: Ankara universitesi basımevi. 1993. S. 321–413.

9. *Gilazetdinova G.Kh., Salakhova R.R.* Lexical-semantic groups of the verbs of motion in structurally different languages (on the material of the Russian and the Tatar languages) // XLinguae, Volume 11, Issue 4, October 2018.

УДК 82.091

# МЕЖКУЛЬТУРНЫЙ ДИАЛОГ ЛИТЕРАТУР В ПОЭТИЧЕСКИХ ПЕРЕВОДАХ НИКОЛАЯ БЕЛЯЕВА

***Ф.Г. Калимуллина***
*Институт Татарской энциклопедии и регионоведения им. М. Хасанова АН РТ (Казань)*

В статье исследуется значение диалога русской и татарской литератур на примере переводческой деятельности Николая Беляева – поэта и переводчика, чьи работы стали мостом между культурами. Анализируются его переводы стихов татарских авторов, таких как Дардменд, Хади Такташ и Хасан Туфан, демонстрирующие глубокое проникновение в оригинальные тексты и мастерское сохранение их образности и эмоционального заряда. Статья подчеркивает актуальность его наследия для современного изучения межкультурного взаимодействия. В заключении делается вывод о значимости переводов Беляева для расширения диалога литератур и взаимного обогащения культур.
**Ключевые слова:** Николай Беляев, поэтический перевод, межкультурная коммуникация, татарская поэзия, русская поэзия, литературный диалог.

The article explores the importance of dialogue between Russian and Tatar literatures using the example of the translation work of Nikolai Belyaev, a poet and translator whose works became a bridge between cultures. His translations of poems by Tatar authors such as Durdmand, Hadi Taktash and Hassan Tufan are analyzed, demonstrating a deep insight into the original texts and a masterful preservation of their imagery and emotional charge. The article highlights the relevance of his legacy for the modern study of intercultural interaction. In conclusion, it is concluded that Belyaev’s translations are important for expanding the dialogue of literatures and the mutual enrichment of cultures.
**Keywords:** Nikolay Belyaev, poetic translation, intercultural communication, Tatar poetry, Russian poetry, literary dialogue.

Поэтический перевод занимает особое место в пространстве межкультурной коммуникации, выступая не только как акт языкового преобразования, но и как сложный процесс художественного и смыслового переосмысления. В отличие от прозаических текстов, стихи требуют от переводчика не только точности в передаче содержания, но и сохранения ритма, образности, эмоциональной тональности, что делает переводческое искусство особенно ценным для диалога литератур.

В условиях глобализации и усиления межкультурных связей изучение поэтического перевода приобретает новую актуальность. Он становится мостом между различными культурными традициями, позволяя читателю одной языковой среды проникнуть в эстетический мир другой. При этом каждый перевод – это не просто воспроизведение оригинала, но и его интерпретация, в которой отражаются как индивидуальность переводчика, так и особенности восприятия иноязычной культуры.

Цель данной статьи – рассмотреть поэтический перевод в контексте межкультурного диалога в татарской и русской поэзиях на примере переводческой деятельности поэта Николая Николаевича Беляева. Актуальность исследования обусловлена необходимостью осмысления

переводческой практики как важного элемента культурного взаимодействия, а также потребностью в разработке методологических подходов, позволяющих оценить художественную и смысловую значимость переводов в контексте диалога литератур.

Поэт, переводчик, заслуженный работник культуры ТАССР Николай Беляев родился 23 сентября 1937 г. в городе Ярославль. В 1961 г. окончил геологический факультет Казанского университета, в 1975 г. – Высшие литературные курсы при Литературном институте имени М. Горького в Москве. 1967 г. вышла первая книга стихов Николая Беляева «Голоса расстояний», через два он стал членом Союза писателей СССР. В 1989–1992 гг. работал геологом, геофизиком, журналистом, литературным консультантом Союза писателей РТ. Многие годы Николай Беляев вел известное литературное объединение «АРС» при Казанском университете. С 1992 г. жил в селе Ворша Собинского района Владимирской области. В 2013 г. вернулся в Казань [9].

Николай Беляев также автор поэтических сборников «Голоса расстояний» (дополненный вариант, 1998 г.), «Ветер» (1969 г.), «Перекресток» (1972 г.), «Казанская тетрадь» (1980 г.), «Тысячелистник» (1984 г.), «Лирика» (1987 г.), «След ласточки» (2001 г.), «Поэма Солнца» (2011 г.) и др. Поэзии Беляева свойственна открытость, четкость нравственных ориентиров, бескомпромиссность в решении этических проблем, иногда – некоторая публицистичность [3]. Стихи обращены к современнику, одинаково живо воспринимающему как сугубо личные переживания поэта, так и его социальную настроенность. В основе его миропонимания лежат общечеловеческие ценности, любовь к людям, внимательное и бережное отношение к природе. Особое место в творчестве Беляева занимают темы, связанные с Казанью, Татарстаном [6]. Скончался поэт 24 декабря 2016 г. в Казани.

Отдельное важное направление в творчестве Николая Беляева – это переводы стихотворений татарских поэтов на русский язык. Поэт перевел стихи Дэрдменда, Х. Такташа, С. Хакима, Х. Туфана, С. Сулеймановой, Н. Арслана, А. Баяна, И. Юзеева, Ш. Галиева, Р. Хариса, Зульфата, Р. Ахметжанова, Ф. Яруллина, Р. Файзуллина, Р. Гаташа и др. Особые дружеские связи соединяли его с татарским поэтом Сибгатом Хакимом [12]. За книгу стихов и переводов с татарского «Помню. Слышу. Люблю…» в 2007 г. Николай Беляев получил Державинскую премию [2]. В одном из своих интервью поэт сказал, что основой рационального межкультурного диалога является братство, дружба народов [1].

Николай Беляев в своем творчестве обретает присущие только ему интонации в своеобразном сплаве разных поэтических культур – русской классической поэзии и поэзии Востока. Тема Востока выходит на передний план многих произведений поэта, например, стихотворения «Уроки Хайяма», «Монолог Дэрдменда». «Я – навек должник перед Востоком» – признается поэт. «Беляев строит в своем творчестве своеобразный мост между Западом и Востоком, а цемент в этом строительстве замешан на искреннем интересе и уважении к духовным ценностям других народов», – охарактеризовал его другой поэт Николай Алешков [4:22].

Именно изучение восточной литературы помогло Николаю Беляеву делать успешные переводы стихов татарского поэта Дардменда (1859–1921).

Переводить татарского поэта Дардменда крайне сложно, практически невозможно воссоздать все нюансы восточных приемов стихосложения, характерные для его стихов на языке перевода [7], однако, Николаю Беляеву это успешно удалось. Поэт проникает в переживания лирического героя татарского автора, и эти чувства воспроизводит через призму русскоязычных словестных форм. Например, короткое, но полное экспрессии стихотворение Дардменда в переводе Н. Беляева звучит так:

Солнца не жди...
Осень пришла – снег и дожди,
Сердце синей долины сковал ледок...
Высох цветок,
На тощем стебле – колючки остались.
Боль, боль...
Соловей!
Тебе острие иголки досталось [8].

Татарский вариант стихов:

Җәй үтте...
Кар-яңгырлы көз урнашты,
Күк тугайның баурына боз урнашты.
Гөл кипте,
Сабагында кинә калды.
Былбыл!
Сиңа бер бөртек инә калды [13].

Другой татарский автор с ярко выраженным художественным стилем – Хади Такташ (1901–1931), к поэзии которого также удалось найти ключи Николаю Беляеву [5]. Рассмотрим одно из стихотворений Такташа:

Течёт холодной мысли яд
По жилам высохшим, бескровным.
В душе – пустынной и огромной –
Лишь ветры чёрные свистят.
Пронзили сердце мне мечом,
Стрелой – добили, погасили.
О, злые джинны! – я ушёл,
Я умер – дальше вы бессильны! («В темные ночи») [4:23].

Оригинал стихотворения:

Уем зәкъкум булып агыла
Коры, кансыз тамырлардан;
Хыялым бер тирән сахра,–
Суык җилләр исә анда.
Йөрәгем мәңгегә сүнде
Кылыч, уклар ярасыннан;
Үләм мин дә китәм инде
Явыз «җеннәр» арасыннан [10].

При сравнении оригинала и перевода стихов сразу становится ясно, что Николай Беляев душой проникся к чувствам лирического героя Такта-

ша, легко и талантливо смог передать атмосферу произведения, не меняя структуру и подачу слов оригинала.

При переводе одного из стихотворений поэта Хасана Туфана (1900–1981) наблюдается, как для передачи полной экспересcии на русском языке, Николай Беляев использует свои приемы описания чувств главного героя. Отрывок из стихотворения Туфана «Кайсыгызның кулы җылы?» в оригинале:

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы?
Бәйлисе бар йөрәкне... [11].

В то время у Николая Беляева отрывок звучит так:

Да, жизнь научила меня понимать
многое. Слёзы – не нам проливать.
У кого из вас руки нежнее дыханья? –
надо сердце перевязать…[4: 23].

Как видим, у Туфана используется выражение «У кого руки теплые?», но с более глубоким эмоциональным посылом, для передачи этой глубокой эмоциональности Беляев использует выражение «У кого из вас руки нежнее дыханья?», что намного обогащает произведение.

Подводя итоги, можно сказать, что Николай Беляев в каждый перевод вносил свое душевное тепло, а точно подобранные слова делали эти переводческие поэтические произведения качественными. Бросается в глаза то, что Беляев выбирал для переводов философские стихи татарских поэтов о бытие, трудностях жизни и о надежде. Эти категории ясны и понятны для народов всех культур, переживания лирических героев сближают читателей. Благодаря его переводческой деятельности стихи татарских поэтов стали доступны русскоязычной аудитории. Николай Беляев не просто переводил тексты – он создавал мост между двумя языковыми мирами, сохраняя при этом глубину и самобытность оригинальных произведений. Его творчество остается значимым примером того, как переводческое искусство может объединять разные культуры, обогащая их и открывая новые горизонты для диалога.

## СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ


1. *Беляев Николай.* «Время свои обязанности выполнит…» [Электронный ресурс]. URL: https://history-kazan.ru/11065-1338 (дата обращения: 15.03.25).

2. *Беляев Николай*. Помню. Слышу. Люблю…: новые стихи, переводы с татарского. Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. 239 с.

3. *Беляев Николай.* «Я выпрыгнул из поезда...» // Дружба народов. 1998. № 10. С. 98–102.

4. Бенефис переводчика: Николай Беляев. Распахнул я окно // Аргамак. Татарстан. 2011. № 2 (7). С. 22–31.

5. Века и минуты: поэма / Х. Такташ; [пер. с тат. Н. Беляева]. Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. 128 с.

6. *Воздвиженский В.* «Как время катится в Казани золотое...» // Беляев Н.Н. Лирика. Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. С. 3.

7. *Нагуманова Э.Ф.* О переводах стихотворений Дардменда на русский язык // Вестник Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. 2010. № 2 (20). С. 169–171.
8. Переводы Беляева с татарских стихов Дардменда [Электронный ресурс]. URL:http://nb.arda.ru/transl/derdmend/ (дата обращения: 15.03.25)
9. *Скворцов А.Э.* Беляев Н.Н. // Татарская энциклопедия. Казань: Институт Татарской энциклопедии, 2002. Т. 1. С. 347–348.
10. *Такташ Һади.* Караңгы төннәрдә [Электронный ресурс]. URL: https://shigriyat.ru/authors/taktash/63 (дата обращения: 15.03.25).
11. *Туфан*. Кайсыгызның кулы җылы? [Электронный ресурс]. URL: https://shigriyat.ru/authors/tufan/36 (дата обращения: 15.03.25).
12. *Хаким С.* Об этой книге // Беляев Н.Н. Казанская тетрадь. Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. С. 3–4.
13. Шигъръият рубрикасы. Дәрдмәнд. Җәй үтте... [Электронный ресурс]. URL: https://t.me/InstitutTE/966 (дата обращения: 15.03.25).

УДК 82-991.2

# «КНИГА О ВОСПИТАНИИ» КАЮМА НАСЫРИ: ТЕМАТИЧЕСКОЕ СВОЕОБРАЗИЕ

***Г.И. Каюмова***
*Институт татарской энциклопедии и регионоведения им. М. Хасанова АН РТ (Казань)*

В данной публикации рассматривается один из фундаментальных трудов известного татарского просветителя, настоящего педагога Каюма Насыри «Книга о воспитании», которая состоит из 113 наставлений и является своеобразным кладезем мудрости. Наставления, пришедшие из глубины веков, не утратили своей актуальности и по сей день, напротив, некоторые даже обрели особую значимость. В этом труде ученого, который хотел видеть молодежь образованной и благовоспитанной, можно ознакомиться с важными советами по всестороннему воспитанию. В статье автор предпринял попытку собрать и распределить по различным тематическим группам наставления, основанные на разных воспитательных направлениях, и дать им пояснения.
**Ключевые слова:** Каюм Насыри, просветитель, педагог, «Китаб-әт-тәрбия», воспитание, наставления, молодежь.

The article examines one of the fundamental works of the famous Tatar educator, real pedagogue Kayum Nasyri, “The Book of Education”, which consists of 113 exhortations and is a kind of storehouse of wisdom. The exhortations that came from the depths of the centuries have not lost their relevance to this day, on the contrary, some have even gained special significance. In this work of the scientist who wanted to see young people educated and well-mannered, you can find important tips on comprehensive upbringing. The author has attempted to collect and distribute materials based on different upbringing directions into various thematic groups and provide explanations to them in the article.
**Keywords:** Kayum Nasyri, educator, pedagogue, “Kitab-at-tarbia” (“The Book of Education”), upbringing, exhortations, youth.

# КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ «КИТАБ-ӘТ-ТӘРБИЯ» ХЕЗМӘТЕ: ТЕМАТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР

***Г.И. Каюмова***
*ТР ФА М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты (Казан)*

Бөтен гомерен татар халкын рухи-мәдәни агартуга, аның милли үзаңын үстерүгә, аңа әхлакый тәрбия бирүгә багышлаган мәгърифәтче әдип, энциклопедист галим, педагог Каюм Насыйриның күпкырлы эшчәнлеге – «милләткә фидакарьләрчә хәзмәт итүнең бөек үрнәге. Аның хезмәтләре – татар халкын белемле, тәрбияле итүдә үзенә күрә бер мәктәп, университет» [4: 5]. Алар татар халкының тәрбия тәҗрибәсенә нигезләнеп иҗат ителә. Әдипнең «Балаларга тәгълим бирмәк» «Могайнеттен», «Бала тәрбия кылучы хатыннарга нәсыйхәт» мәкаләләре, «Әхлак рисаләсе» (1881, 1890), «Китаб-әт-тәрбия» (1891), «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» (1884) китаплары – әхлак-тәрбия тәҗрибәсенең матур үрнәкләре. Мәгърифәтче галим иҗатын төрле яклап өйрәнү-тикшерү эшләре әле дә дәвам итә. Аның хезмәтләренең тәрбияви әһәмияте Җ. Вәҗиева, И. Гыйләҗев, Ш. Җәләлиев, Р. Исламов, Ф. Исламов, Р. Сәләхова, Ә. Хуҗиәхмәтов, Л. Шәйдәева, Ф. Яруллина, Р. Сәхибгәрәева, Л. Танташева һәм башка галимнәр, педагоглар тарафыннан этрафлы һәм тәфсилле яктыртылган. Җ. Вәҗиева К. Насыйриның «көчле педагог» булуын, аның тәрбия мәсьәләсенә «аерым бер фән» буларак каравын ассызыклый [1]. Ш. Җәләлиев фикеренчә, мәгърифәтче «тәрбиядә халыкчанлыкка һәм гуманлылыкка зур өстенлек бирә һәм бу аның төп педагогик принцибы булып әверелә» [2]. К. Насыйриның югарыда күрсәтеп үтелгән хезмәтләре арасында 113 төрле тәрбиядән гыйбарәт «Китаб-әт-тәрбия»се («Тәрбия китабы») [3] аерым игътибарга лаек. Шагыйрә Э. Шәрифуллинаның мәгърифәтчегә, аның күпкырлы эшчәнлегенә багышланган «Каюм коесы» поэмасында да бу китап турында хөрмәт белән искә алына: «Иманлы сүз кайтты тәрбиягә, / «Эт-тәрбия» кайтты, / Мең шөкер!» [5: 511].

Әлеге мәкаләдә К. Насыйриның киң катлау укучыга җиткерергә теләгән әдәп-әхлак кагыйдәләре һәр тәрбиядә нинди дә булса гыйбрәтле хикәят, мисал-дәлилләр белән көчәйтелгән һәм вәгазь-нәсыйхәтләр белән ныгытылган «Китаб-әт-тәрбия» хезмәтендәге тәрбия мәсьәләләренә киңрәк тукталып үтәрбез. Аларны шартлы рәвештә унике тематик төркемгә берләштереп карарга мөмкин.

К. Насыйриның хезмәтләрендә, педагогик карашларында балаларга төпле белем бирү, һөнәргә өйрәтү кирәклеге хакындагы кызыл җеп булып сузылган фикерне үзәккә алган **беренче бүлекне** *Һөнәр өйрәнү, һөнәрле булу турындагы тәрбияләр* дип атарга була. Игътибар үзәгендәге китапта урын алган *беренче* тәрбиядә үк һөнәр өйрәнүнең мөһимлегенә басым ясала, аның «ышанычлы дәүләт» булуы ассызыклана. Әлеге бүлек *тугызынчы, сиксән, сиксән беренче* тәрбияләрне дә берләштерә. Мәсәлән, *тугызынчы* тәрбиядә «үз көчең белән тапкан бер тиенең кеше көче белән хасил булган мең тиеннән бәрәкәтлерәкдер», кешегә бил бөгеп, кимсетелеп яшәгәнче, үз һөнәрең белән үзеңә-үзең хуҗа булу күпкә яхшырактыр дигән

фикер үткәрелә. Соңгыларында һөнәрнең ниндие дә яхшы булу турында искәртелә, аеруча сату-алу эшендә ялган сөйләмәскә, ант итмәскә, намус белән сәүдә итәргә кирәклеге әйтелә.

*Гыйлемле вә мәгърифәтле булуның хикмәтләре, наданлыкның тискәре йогынтысы турындагы тәрбияләр* дип аталырга мөмкин **икенче бүлек** *өченче, алтынчы, уникенче, җитмеш бер, җитмеш ике, җитмеш өч, сиксән ике, сиксән җиденче* тәрбияләрне берләштерә. Күрсәтеп үтелгән тәрбияләрдә гыйлем үзләштерергә кирәклегенә төшендерелә; акылның буйга карап үлчәнмәвенә, гыйззәтлелек һәм олуглыкка килеш-килбәт, төс-кыяфәт белән генә ирешеп булмавына, бу сыйфатларның кешегә гыйлем, әдәп һәм күркәм әхлак белән генә килә алуына басым ясала: «Вә дәхи олуглык вә игелеклелек дигән нәрсә гыйлем вә әдәп беләндер вә күркәм әхлак беләндер». *Җитмеш өченче* тәрбиядә бик тә кызыклы һәм бер үк вакытта уйландырырлык фикерләр урын ала: кешенең эшендә яки сүзендә хата күрсәң, аны, бу кешенең үзенә күрсәтеп, «болай кирәк» дип төзәтмәскә кирәк, имеш; чөнки, беренчедән, ул кеше синең белгәнеңне үзләштерер, икенчедән, һич рәхмәт әйтмәс, киресенчә дошман күрер. «Бу эш үз башыма күп килгәне бар, вә ничә мәртәбә кешенең хатасын үгрәтеп үкенгәнем бар», – ди автор. *Сиксән икенче* тәрбиядә – ахмак, надан кеше дуслыкка да, дошманлыкка да ярамас, *сиксән җиденче* тәрбиядә «ахмак үз-үзенә кыйлган кадәр зарарны гакыллы адәм дошманына да кыйлмас» диелгән көчле фикерләр уздырыла; үзен галим, гыйлем иясе дип санаган наданнардан сакланырга кушыла.

*Аз сүзле булу, сүзне уйлап һәм үлчәп сөйләү, кеше рәнҗетмәү турындагы тәрбияләрне* берләштергән **өченче бүлек**, исеменнән аңлашылганча, урынлы-урынсыз сүз сөйләп йөргән, ахырын уйламыйча сүз йөрткән акылсызлардан гыйбрәт алырга кушылган, аз сүзле булырга, сүзне уйлап һәм үлчәп сөйләргә кирәклегенә басым ясалган *бишенче*, сөйләп торган кешене бүлдереп сүз сөйләүнең бик начар гадәт булуы искәртелгән, әйтәсе сүзеңне башкалар сөйләп бетергәч әйтергә кирәклегенә төшендерелгән *унынчы*, кешегә каты бәрелеп яки аның гаебен башкалар алдында йөзенә бәреп әйтеп, яисә кул астындагыларыңны рәнҗетерлек гамәлләр кылып, аларның күңелен яралаудан сакланырга киңәш ителгән, «тел җәрәхәте кылыч җәрәхәтеннән ачырактыр вә яманрактыр» диелгән *алтмыш дүртенче, җитмеш дүртенче, сиксән тугызынчы, туксан, туксан беренче* һ. б. тәрбияләрдән гыйбарәт. Сүзне уйламыйча яки махсус авырттырам дип әйтүнең, начар эш-гамәлләр кылуның залимлек билгесе булуына басым ясала (61 нче тәрбия); үз бәяңне күтәрәм дип, кемне дә булса кешеләр алдында сүксәң, аңа вәгазь һәм нәсыйхәт кылсаң, һичшиксез, аның дошманына әвереләчәксең, диелә (62 нче тәрбия). *Җитмеш дүртенче* тәрбиядәге киңәш аеруча гыйбрәтле: «Әй угыл, кешегә мәнфәгать итәргә кулыңнан килмәй икән, бары зарарыңны ирешдермә». Бу бүлекне *алтмыш дүртенче* тәрбиядәге «изге холык вә йомшаклык белән татлы сүзләр сөйләшмәк ризыкның ачкычыдыр» дигән хак сүзләр белән йомгаклыйк.

**Дүртенче бүлекне** *Кешелекле, иманлы, ярдәмчел, тәрбияле булу турындагы тәрбияләр* тәшкил итә. Бу бүлеккә караган тәрбияләрдә кешеләргә мөнәсәбәттә кешелекле (11 нче тәрбия), иманлы (13 нче тәрбия) булу фарызлыгы хакында үтемле әйтелә. Әйтик, кешене бары тик яхшы мөнәсәбәт

белән генә җиңәргә мөмкин; хуҗа кеше, үзенең кул астындагыларга яхшы мөнәсәбәт күрсәтсә, кешелекле һәм кечелекле булса гына, хөрмәткә ирешә ала, диелә. Иманлы булу мәсьәләсенә килгәндә, ахирәттә йөзеңә кызыл-лык китерерлек, оятлы итәрлек гамәлләр кылмаска киңәш ителә. *Ундүртенче* тәрбиядә – мөмкин булган кадәр фәкыйрьләргә, мохтаҗларга ярдәм күрсәтүнең савабы турында, *илле алтынчы* тәрбиядә исә мохтаҗларга үзе ярдәм сораганчы ук ярдәм итү кирәклеге хакында аңлатыла. *Икенче тәрбиядә,* халык мәкалендәгечә: «Таш белән атканга – аш белән ату» кирәклегенә төшендерелә; *илле бишенче* тәрбиядә дә шуңа охшаш фикер уздырыла: «Үч алырга вә җәза бирергә көч җитә торып, гафу белән мөгамәлә кыйлмак барча изге холыкларның күркәмерәгедер». *Кырык дүртенче, кырык тугызынчы* тәрбияләрдә, көчеңнән килгәндә, изге гамәлләр кылырга тырышырга кирәк диелә: «Әй угыл, сачкәнеңне урырсың, кыйлганыңны күрерсең, ягъни изге эш кыйлсаң, изге җәза алырсың вә явыз эш кыйлсаң, михнәткә вә газапка лаек булырсың». *Илле беренче* тәрбиядә явыз холыклы кешегә үзеңнең яхшы холкың, изге гамәлләрең белән үрнәк булу кирәклеге турында әйтелә, сүз белән түгел кылган гамәлләрең белән нәсыйхәт кылуның иң күркәм сыйфат булуы ассызыклана. Әмма кешегә кылган яхшылыкларың турында кычкырып йөрүнең гөнаһ булуы искәртелә (52 нче, 57 нче тәрбияләр). Автор «берәүгә бер яхшылыгың тисә – сөйләп йөрмә, берәүдән яхшылык күрсәң – фаш кыйл, онытма», ә синнән яхшылык күргән кеше, аны үзе дә онытмый дип әйтергә тели. *Йөз дә өченче* тәрбиядә, кешенең холык-фигыленә, социаль чыгышына, диненә карамастан, һәркемгә карата да ачык йөзле, йомшак телле булу, олыларны хөрмәтләү, кечкенәләргә мәрхәмәтле һәм шәфкатьле булу кирәклеге турында киңәш ителә.

*Юмартлык-саранлык турындагы тәрбияләрне* үз эченә алган **бишенче бүлектә** юмарт булу хупланыла (8 нче тәрбия), саран кешенең мескен булуы турында әйтелә (50 нче тәрбия), «тар холыклы кешенең ризкы да тар була», диелә (59 нчы тәрбия). «Халыкка икмәк-тоз күрсәтмәгән кешенең үлгәч тә исемен телгә алмаслар. Тереклеге белән сөендермәгән кешенең үлеменә дә бик кайгырмаслар» (46 нчы тәрбия) дигән гыйбрәтле фикер әйтелә.

**Алтынчы бүлектә** *Булганына шөкер итү, азга да канәгать булу турындагы тәрбияләр* урын ала. Биредә сүз *унтугыздан алып егерме икегә кадәрге* тәрбия, шулай ук *егерме җиденче, егерме сигезенче, йөз унберенче* һ. б. тәрбияләр турында бара. Аларда булганына шөкер итә белүнең мөһимлегенә мисал-дәлилләр белән үтемле итеп төшендерелә; кешенең мул, сый тормышка бик тиз ияләшүе, нәфесенең котыра, холык-фигыленең үзгәрә башлавы, үзенең үткәнен онытуы турында бәян ителә; матди байлыкка түгел, белемгә, рухи байлыкка омтылу кирәклеге аңлатыла. *Егерме сигезенче* тәрбия аеруча гыйбрәтле булуы белән аерылып тора. Биредә, үзеңне бәхетсез хис итсәң, синнән дә бәхетсезрәкләргә карап гыйбрәт ал һәм булганына шөкер кыл дигән фикер уздырыла, шуны раслау максатыннан бик тә көчле мисал китерелә: Шәех Сәгъди хикаять кыйлмышдыр хис «Замананың үзгәрүеннән һәнүз еглаганым вә шикаять кыйлганым юк иде. Мәгәр бервакытны аягыма кияргә юк иде, аякларым ялангач, Күфә мәсҗеденә килдем. Бер аяксызны күрдем, вә аллаһе тәгаләгә шөкер вә сәна кыйлдым, вә аягым ялангачлыгына сабыр кыйлдым», – диде.

*Балаларга кечкенәдән тәрбия бирү турындагы тәрбияләрне* **жиденче бүлеккә** берләштерергә мөмкин. *Уналтынчы, утыз өченче, утыз җиденче* һ. б. тәрбияләрдән гыйбарәт бу бүлектә балаларга кечкенә вакыттан ук дөрес тәрбия бирү, аларны узындырмау турында, аеруча иректе, мул тормышта рәхәт кенә күреп яшәргә өйрәнгән яшьләрне тормыштагы төрле хәлләр белән таныштыру, әдәпсезләрдән гыйбрәт алып, яхшы гамәлләрне генә үзләштерү кирәклеге, әдәп-әхлак кыйммәтләре турында төшендерелә, шул уңайдан гыйбрәтле хикәятләр китерелә.

**Сигезенче бүлек** *Туганнарга, кунакларга, күршеләргә хөрмәтле мөнәсәбәт турындагы тәрбияләрдән* гыйбарәт. Әлеге бүлеккә караган *илле дүрт, туксан тугыз, йөзенче* тәрбияләрдә күршеләрне хөрмәтләү, карендәшләрнең кадерен белү, саф күңелле булу, күркәм холыклы кешеләрне олылау һәм аларга ихтирам күрсәтү турында бәян ителә. Кунаклар чакырып сыйларга уйлаган очракта, кунакларың азрак булса, алар белән бергә утырып ашарга киңәш ителә, кунакларың күп булса, аларга хезмәт күрсәтү кирәклеге турында әйтелә. Кунакларны ташлап чыгып китмәскә, артык каты кыстамаска, ризыкны алларына ачык чырай белән куярга; кунакларың барында җәмәгатеңә вә хезмәтчеләреңә ачуланмаска, аларны орышмаска; кунаклар белән аралашырга, кара коелып, ят кеше кебек йөрмәскә кушыла. Көтмәгәндә кунаклар җыеп сыйларга уйласаң, бер-берсенә дошман кешеләрне бер мәҗлескә җыймаска, бер табын артына утыртмаска киңәш ителә.

*Дуслык турындагы тәрбияләрдән* гыйбарәт **тугызынчы бүлектә** *кырык ике, кырык өч, сиксән өч, сиксән алтынчы* тәрбияләр карала. Аларда дуслык турында акыллы фикерләр әйтелә. Мәсәлән, *кырык икенче* тәрбиядә: «Һәрбер сереңне дустыңа әйтмә, чөнки кайдан беләсең, бервакытны дошман булып китәр. Дошманыңа, кулыңнан килсә, зарар итмә, бәлки бервакытны, үзеңә дус булыр. Дустыңның дустына да ышаныч юк, аң бул. Әмма ике дошман арасында сүз сөйләсәң, белеп сөйлә: әгәр дуслансалар, үзеңә оят килмәсен», – диелә. *Сиксән өченче* тәрбиядә дошманыңа белгертергә теләмәгән серне дустыңа да сөйләмәскә кушыла, дустыңның да яшерен серне дошманыңа җиткерү очрагы булырга мөмкин, дип искәртелә. *Сиксән алтынчы* тәрбиядә шундый киңәш бирелә: «Әй угыл, тышыннан дуслык күрсәтеп, эчендә дошманлык вә хөсед яшереп йөргән кешедән бик саклан. Бу заманның дусларына да ышанма. Берәү сине алдыңда мактаса, әлбәттә, белгел ки, һичшиксез, сине артыңда яманлый торгандыр. Тәҗрибә кыйлмый торып алданма».

*Хәләл һәм хәрәм маллар әҗере турындагы тәрбияләрне* **унынчы бүлеккә** берләштерергә мөмкин. *Илле тугызынчы, җитмеш бишенче, җитмеш алтынчы, җитмеш җиденче* тәрбияләрдә бары тик хәләл мал гына булдыру, аны саклап тоту, юкка-барга, хәрәм җиргә сарыф итмәү турында бәян ителә. Изге эшләргә генә сарыф ителгән хәләл мал иясе андый малның игелеген күрер, бу байлыгыннан үлгәнче аерылмас; хәрәм мал хәрәмгә генә тотылып бетәр, хәрәм мал иясе аның игелеген һичбервакыт күрә алмас дигән фикер уздырыла (59 нчы тәрбия). *Җитмеш бишенче* тәрбиядә: «Малны саклау – малны табу һәм җыюдан авыррак. Саклап тота белмәгәннәре сәбәпле никадәр байлар малсыз калдылар», – диелә. *Җитмеш алтынчы* тәрбиядә «чыгымнарын үлчәү белән тоткан кеше мохтаҗ булмайдыр» дигән нәтиҗә чыгарыла. *Җитмеш җиденче* тәрбиядә дустың-

ның яки карендәшеңнең сиңа әманәт иткән малын үзеңнеке кебек сакларга, сиңа тапшырган хезмәтен дә үзеңнеке кебек башкарырга киңәш ителәә. Шул очракта Аллаһы Тәгалә синең үз малыңа да бәрәкәт бирер, үзең кеше арасында әманәткә тугры инсан буларак дан алырсың дигән мәгънә ята. Исраф итүчегә, комарбазга, эчкечегә малыңны әманәт итмәскә кушыла. *Сиксән бишенче* һәм *сиксән алтынчы* тәрбияләрне дә шушы бүлеккә кертеп карарга мөмкин. Аларда урлашуның һәм урланган әйбердән файдалануның зур гөнаһ булуы турында хәбәр ителә, нинди генә гамәл кылырга уйласаң да, ахыры ни белән бетәр икән дигән уйны бервакытта да баштан чыгармаска кирәклегенә басым ясала.

**Унберенче бүлек** *Бурычлы булуның, мохтаҗлык кичерүнең авырлыгы турындагы тәрбияләрне* берләштерә. Әлеге бүлеккә караган *егерме өченче, егерме алтынчы, җитмеш сигезенче, сиксән дүртенче, туксан өченче* тәрбияләрдә бурычлы кешенең кол дәрәҗәсендә булуы ассызыклана, аларда шулай ук «кешегә ялынычың төшмәсен» дигән фикер уздырыла. Кешегә бурычка биргәндә, үз файдаңны күреп эш итмәскә, «заклад биреп акча алмаска» киңәш ителә, мондый эшләрнең әдәмне хурлыкка төшерә торган гамәлләр булуына төшендерелә; дуска акча биреп торуның да ярамый торган эш икәнлеге мисал-дәлилләр белән аңлатыла.

**Уникенче бүлек** *Ашау-эчү белән бәйле тәрбияләрне* берләштерә. Әлеге тәрбияләрдә (17, 21, 24, 25, 94–100 нче тәрбияләр) балаларга кечкенә вакыттан ук таныш булган, әби-бабайларыннан, әти-әниләреннән ишетеп үскән әхлак кагыйдәләре урын алган: өстәл артында утырганда сөйләшмәскә, ризыкны иснәмәскә, ашар алдыннан кулларны юарга, ризыкны «бисмилла» әйтеп, аз-аз кабып, ашыкмыйча, яхшы итеп чәйнәп ашарга, ашаганда уңга-сулга каранып утырмыйча, алдыңа гына карап, түкмичә, тамызмыйча ашарга, ашап бетергәч, дога кылырга кирәк һ. б. Бактың исә, ашау-эчү белән бәйле әдәп-әхлак кагыйдәләре Каюм баба заманнарыннан ук килә икән. Китапта бу тәрбияләргә шактый урын бирелгән. Аларда югарыда әйтелгән һәм башка тәртип-кагыйдәләр бик төшемле, үтемле итеп аңлатыла. Мәгълүм булганча, медицинада чамадан тыш ашау тыела, чөнки артык күп ашау сәламәтлеккә гаять зур зыян китерә. К. Насыйри тәрбияләрендә дә бу мәсьәләгә шактый игътибар ителгән. Азрак ашасаң «җисмең сәламәт булыр, зиһенең саф булыр, хәтерең куәтле булыр», – диелә.

Югарыда каралган тәрбияләрдән аңлашылганча, К. Насыйри белемле, һөнәрле, акыллы, тәрбияле, гадел, юмарт, ачык йөзле, аз сүзле, тел белән зина кылмаучы кешеләрне хөрмәт итә, һәркемдә бары яхшы сыйфатлар гына тәрбияләргә омтыла, илтифатка һәм ихтирамга лаек кешеләр белән генә аралашуга өстенлек бирә. Галим-педагог фикеренчә, үзләштерелгән белемнәр дә, байлык та үзеңә һәм башкаларга файда китерерлек булырга тиеш. К. Насыйри фикерләрен хуплап, кешенең матурлыгы аның рухи камил, әхлаклы, күркәм гадәтле, туры сүзле, сүзенә һәм гамәлләренә тугры шәхес булуындадыр дип нәтиҗә ясыйк.

Әлеге хезмәт – балаларга дөрес тәрбия бирү максатында һәр гаиләдә ата-ана өчен, мәктәптә дәрестә һәм тәрбия сәгатьләрендә файдалану өчен алыштыргысыз хәзинә, бүгенге көндә дә актуальлеген һәм кыйммәтен җуймаган рухи мирас.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Вәҗҗиева Җ.* Каюм Насыйри – тәрбияче. URL: https://kazanutlary.ru/j-archive/journal-materials/1945-2/kayum-nasyyritrbiyache?ysclid=m8zxv31cpg262754196 (дата обращения: 26.04.2025).

2. *Җәләлиев Ш.* К. Насыйри иҗатында татар халык тәрбиясе. URL: https://dumrt.ru/articles/mm-islam/mm-islam_5038.html?ysclid=m8zxp1iwcw164412466 (дата обращения: 26.04.2025).

3. Насыйри К. Китаб-әт-тәрбия = Книга о воспитании. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 144 б. (Мисаллар шушы чыганактан алына).

4. *Шәйдуллин Р.В.* Каюм Насыйри: татар мәгърифәтчесе һәм галим-энциклопедист (200 еллык юбилее уңаеннан) // Языки и культуры народов Татарстана. Каюм Насыри: сборник материалов региональных научных форумов, проведенных в рамках мероприятий, приуроченных к 30-летию Института Татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук РТ и 35-летию татарстанской энциклопедистики, г. Казань, 25, 26 апреля 2024 г. / отв. ред. Р.В. Шайдуллин. Казань: Академия наук РТ» «Институт Татарской энциклопедии и регионоведения им. М.Х. Хасанова АН РТ, 2024. Ч. 1–2. С. 5–16.

5. *Шәрифуллина Э.* Каюм коесы // Сөюемнән мин бер чибәр идем..: Шигырьләр, поэмалар. Казан: Рухият, 2005. Б. 497–517.

УДК 821.512.145

# ОСОБЕННОСТИ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ ПАРНЫХ СЛОВ В ХУДОЖЕСТВЕННЫХ ПРОИЗВЕДЕНИЯХ (на материале романа Аяза Гилязева «Балта кем кулында?»)

***З.С. Каримова***
*УУНиТ (Уфа)*

В этой статье рассматриваются особенности использования парных слов в романе известного татарского писателя Аяза Гилязова «Балта кем кулында?». Всего в романе в 981 фрагментах используется 383 парных слова. Каждое из этих слов имеет свою стилистическую функцию в произведении. В статье рассматривались парные слова, созданные самим писателем, ранее не встречавшиеся в словарях и использовавшиеся только в этом романе, определялась их стилистическая роль. Лексемы этого типа оживляют язык романа, повышают возможность художественного описания мыслей, явлений и событий и, наконец, играют большую роль в обогащении нашего литературного языка. А. Гилязов в романе «Балта кем кулында?» использует парные слова достаточно свободно и уместно.
**Ключевые слова:** Стиль, компонент, сюжет, жанр, синонимия, парные слова, антонимы.

This article examines the features of the use of paired words in the novel by the famous Tatar writer Ayaz Gilyazov “Balta kem kulinda?”. In total, 383 paired words are used in 981fragments in the novel. Each of these words has its own stylistic function in the work. The article examined paired words created by the writer himself, which had not previously appeared in dictionaries and were used only in this novel, and their stylistic role was determined. Lexemes of this type enliven the language of the novel, increase the possibility of artistic description of thoughts, phenomena and events, and, finally, play a major role in enriching our literary language. A. Gilyazov uses paired words quite freely and appropriately in the novel “Balta kem kulinda?”.
**Keywords:** Style, component, plot, genre, synonymy, paired words, antonyms.

# ПАРЛЫ СҮЗЛӘРНЕҢ ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРДӘ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
## (Аяз Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?» романы материалында)

***З.С. Кәримова***
*УФһТУ (Уфа)*

«Тел – әдәбиятның беренче элементы» [2: 3]. Тел ярдәмендә әдәби әсәрнең бөтен компонентлары – темасы, образлары, сюжеты, стиле һәм жанры үзара бәйләнешкә керәләр. Парлы сүзләрнең кулланылыш сферасы бик киң, алар матур әдәбиятта да, публицистикада да, хат-истәлекләрдә дә, фән телендә дә, сөйләү телендә дә шактый күп очрый. Парлы сүзләр бигрәк тә матур әдәбият әсәрләрендә күп куллана. Белүебезчә, әдәби телнең үсеше стильләр белән тыгыз бәйләнештә. Ул үзенә күптөрле сөйләм стильләрен берләштерә. Әдәби тел белән матур әдәбият теле арасындагы тыгыз бәйләнештә булып, матур әдәбият стиле әдәби телнең үсешенә зур йогынты ясый. Матур әдәбият стилендә, һәр язучы үзенә генә хас булган тел алымнары һәм сәнгатьчә сурәтләү чараларын кулланып, парлы сүзләр аша да сүз мәгънәсен күпкырлы яклары белән ачып сала. Парлы сүзләр әсәрләрдә сәнгатьчә хис, уй-тойгыларны табигать күренешләрен, сәяси икътисадый хәлләрне, персонажларның эчке дөньясын һәм башка чараларын киңрәк һәм тулырак аңлату, сурәтләү-тасвирлау ысулы булып кулланыла.

Тәкъдим ителгән мәкаләдә Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?» романындагы парлы сүзләрнең стилистик кулланылышы тикшерелә. Романда барлык 981 урында 383 парлы сүз куллана язучы. Бу сүзләрнең һәрберсенең әсәрдә үз стилистик вазифасы бар. Мәсәлән, *Нәҗип «мөдирлек белән яши башлагач, Тимерхан-шадра, Тимерхан- тешсез бик түбәндә, күз күреме җитмәс аста калган иде. Киемсалымы да таланган икән... Тора-бара кулдан мал, беләктән көч, күздән нур качкан, арыбире купнып йөргән Тимерхан бер таңда өтәләтеп-таланып, шыр сөяген селкетеп карчыгы бусагасына кайтып егылган... Карчыгы «Әйдә эт булып өрергә булса да ярар!» – дип аны кабул иткән. Уклау белән аркылысын-буен үлчәп тәүбәгә китергән.*

Бу кыска гына өзектә без парлы сүзләр ярдәмендә Тимерханның бөтен тормыш юлы, портреты күз алдына килеп баса. Парлы сүзләрне геройперсонажларның эчке дөньясын, рухый халәтен чагылдыру өчен дә бик кирәкле тел чарасы буларак куллана А. Гыйләҗев. Мәсәлән, *Кызып-янып барган шәпкә Нәҗипнең күңеленә икеле-микеле уйлар да килеп китколәде.* Үзара якын, синонимик мәгънәле сүзләр парлашып ясалган һәм икенче, компоненты беренчесенең фонетик варианты буларак ясалган парлы сүзләр укучыга Нәҗипнең рухый халәтен аңларга ярдәм итәләр.

Яисә *«Колхоз ничек бара ул чагында?», «Бер кузгатып җибәргәч тауда таш та тәгәри, ава-түнә, туктар-туктамас бара!».* Бу җөмләдәге гади генә халыкта яшәп килгән ике парлы сүзнең никадәр зур мәгънә пространствосы. Димәк, *Колхозның хәле бик начар, ул көчкә-көчкә генә яши.*

Югарыда каралган мисаллардан гына чыгып та, А. Гыйләҗевнең җөмләләрдә парлы сүзләрне төрле стилистик максатына шактый урынлы һәм оста файдалануын әйтә алабыз.

А. Гыйләҗевта бер парлы сүзнең бик еш, хәтта бер биттә берничә тапкыр куллану очраклары да бар. Андыйларга *ир-ат, вак-төяк, хатын-кыз, савыт-саба, ыгы-зыгы, туп-туры, өс-баш, ит-май, күзгә-башка, оҗмах-алан, мал-туар, җил-яңгыр* парлы сүзләрен кертергә була.

*Ит-май бирүләрен белгәч Мәрьямбикә күккә сикерде, киленен ияртеп, иткә-майга төшеп тә китте* [1: 438].

*Каршысында утырган хатын-кыз бер төрле тәэсир итсә, култыгына кергән хатын-кыз Сабитның бөтен күзәнәкләрен уятып, башын зыр-зыр әйләндерә иде* [1: 476].

Ләкин еш кына язучы бер үк сүзне кабатланмаска тырыша. Мәсәлән, кечкенә бер абзацта автор персонажның эшкә мөнәсәбәтен парлы сүзләр белән белдерә. *«...Эшкә килгәч тә бригада бер кавыш эленке-салынкы йөри, тарта, гәп суга»*. Биредә бу парлы сүзне *«ялкау гына йөри»* дип тә язарга мөмкин булыр иде, әмма парлы сүзнең мәгънәсе көчлерәк. Алга та шул ук бригада тырышын эшләүне дә автор парлы сүз ярдәмендә бирә: *«Бүтәннәр филонит итә, мин кызып-кызып эшкә тотынам! Тузаннар оча... Бригада капкага тартыла... Ә мин ярсып-кызып эшкә ябышам. Пыр туздырам»* [1: 349]. Бу очракта парлы сүзләрнең мәгънәләренең икенчесенеке беренчесенекә караганда да көчлерәк. Тагын бер мисал: «*Сүз белән алдыра торган ирләр була, кайберәүләр буй-сын белән хатын-кызын һушсыз итәләр, өченчеләр кылган гамәлләре белән кыз-кыркыпны үзенә тарта, биргән татлы вәгъдәләре белән әсир итә*» [1: 492].

*Вакыт-вакыт авторның җөмләләре гел парлы сүзләрдән генә төзелә. Нәҗип тиз-тиз уңга-сулга карады. Тирә-як, һава-күк тып-тын калган иде. (386). Көндез ашык-пошык ташыганда, нәрсә-караны урнаштырганда, тирә-якта, күрше-күләндә тавыш тауга артык ишетелмәгән иде, хәзер йортның өч каты тиң җанланды, бөтен тарафтан, астан-өстән, яннан-каршыдан төрле төстәге тавышлар агылды.* Бу очракта язучы бер җөмләдә җиде парлы сүз кулланган.

Байтак парлы сүзләрнең лексик мәгънәләрендә бернинди дә эмоциональ-экспрессивлык күзәтелми һәм алар җыймалылыктан башка мәгънәви төсмер белдермиләр. Мәсәлән: *иртә-кич, буй-сын, җәен-кышын, сау-сәламәт, исән-имин, хатын-кыз, кыз-кыркын, бала-чага, ата-анасы, каен-юкәләр, өстәл-урындык, дус-иш, азык-төлек* һ. б.

*«Ата-анаңа терәк булыр идең. Сез сау-сәламәт»* [1: 358].

Икенче төр парлы сүзләр, киресенчә, җыймалылык белән бергә күптөрле эмоциональ төсмерләрне дә чагылдыралар һәм стилистик яктан сөйләмне баеталар. *Этле-мәчеле, керделе-чыктылы, урыс-улак, җен-пәри, эштер-өштер, әйләнә-тулгана, юрый-марый, сукыр-букыр, имгәк-тунеяд, кырлы-мырлы, үпкәчел-көнчел.*

*«Дача шаукымы дөньяга таралганчы, эте-бете уянганчы, Иделнең гүзәл почмагында... бер ел эчендә дача йортларын салырга кирәк!»* [1: 503].

«*...Юдинодан ерак түгел ялгыз башы урыс-улак арасында яшәп ята»* [1: 27].

*Имгәк-тунеядларны шәһәрдән үк сөрәләр түгелме?*

*Мынсыклар, дөрләп кабынучы кинәтләр, үпкәчел-көнчеләр бу дөньядан тизрәк китәләр.*

*Шундый кырлы-мырлы, имансыз дәвергә туры килгән Йосыф белән Мәрьям татар дөньясына уллар да, кызлар да китергәннәр.*

Бу җөмләләрдә сөйләүченең үзе хәбәр иткән кешеләр вакыйгаларга күренешләр, төшенчәләр турында нинди фикердә булуы һәркемгә аңлашылып тора. Мондый парлы сүзләр, һичшиксез, образлылыкны көчәйтәләр, герой-персонажларның эчке дөньясын, табигатен ачыклауга ярдәм итәләр: «*Митя – мондагыларның эчен-тышын белеп бетергән зирәк кеше, ул ташландык карт-корыны кызгана, үзләре дә онытканн туган көннәрен белә, ...бүтәннәр юк санаган кәкре-бөкре корткаларны олылап: «Мария Ефимовна, Дарья Григорьевна» дип эндәшә... карчык-корчыклар юнәлткән ризыкларын юмарт бүлешәләр»* [1: 374].

Стилистик максаттан чыгып, Аяз Гыйләҗев парлы сүз компонентларының урыннарын да алыштырып куя: «Каймак-май күрә алган юк. *Сыер асрар хәлләре булганнар авылда калмады, алар май-каймак ашарга калаларга күченеп бетте»* (408). Яисә язучы татар телендәге «таныш-белеш» дигән парлы сүз урынына «белеш-таныш» парлы сүзен куллана: *«Алай гынамы, никахлашкач бүләк-санак күтәреп килгән белеш-танышларын өерләп куеп чыгарды»* [1: 273].

Ә менә бу җөмләдә А. Гыйләҗев, хатын-кыз парлы сүзендәге «хатын» сүзен «балалар» сүзе белән парлап, яңа эчтәлекле «хатын-балалар» дигән парлы сүз төзи. Әлбәттә, моны «гаиләсен интектерә» дип тә бирергә булыр иде, ләкин парлы сүз ярдәмендә ул башкача яңгырый.

Аяз Гыйләҗев бу романында синоним сүзләрне парлап, аларны субъектив бәяне һәм сөйләмнең эмоциональ характерын белдерү өчен саф стилистик максатта куллана. «*Әмма даруга дигән акчаны көч-хәл белән җыештырган Наиләнең кәнфит-мәнфитләрен алырлык җае юк»* [1: 360].

*«Дүрт таза-таза ир шау-гөр килеп кәрт сугып утыралар»* [1: 364].

*«Аны «җилдә ябышып катасың киләме?» – дип, этеп-төртеп кабинага керттеләр»* [1: 391].

*«Кешеләр авылдагы җәбер-җәфалардан туеп, күпләп-күпләп татар җирен ташлап чыканнар»* [1: 399].

Көч һәм хәл, шау, гөр, этү, төртү, җәбер, җәфа – синоним сүзләр. Шул мәгънәне бирү өчен бу сүзләрнең берсе дә җитәр иде, яисә аларның мәгънәләрен парлы булмаган башка бер сүз белән биреп булыр иде: җәфер-җәфа – авырлык, шау-гөр – тавышлану, этеп-төртеп – мәҗбүри һ. б. Ләкин парлы сүз, аерым сүзгә караган, сөйләмгә стилистик буяу кертә.

Аяз Гыйләҗев компонентлары бер-берсенә капма-каршы булган, антоним булган сүзләрне дә стилистик максатта куллана: *«Чәй кайнап чыкканны көтмәделәр, уяныр-уянмас (уяу) яткан Искәндәрне табынга дәштеләр»* [1: 407]. *Юк-бар адәмнәргә кул биреп чыккансың, идарәдә күренмәдең «Төшәрмен», – диде Нәҗип, алдын-артын уйламыйча.*

Язучы антоним парлы сүзрләрне ике төрле юл белән төзи: бер очракта ул бер үк сүзгә юклык кушымчасы өсти, яисә мәгънәләре капма-каршы булган ике сүзне куллана *(ак-кара, эчен-тышын, юк-бар)* һ. б.

Ике компоненты да аерым мәгънә аңлатмаган парлы сүзләрдә дә эмоциональлек, җанлы картина тудыру мөмкинлеге көчле була. А. Гыйләҗев мондый парлы сүзләрне бигрәк тә яратып куллана: *«...Наиләгә бүтән ым кирәкми иде, ул кабыл-тибел Тимерханнар ягына чыкты һәм акчаны өстәл*

*уртасына ташлады»* [1: 329]. *«Хирург та әлләни тапмады, невропатолог эштер-өштер әйләндергәләде, «годен!» дип егетне чыгарып җибәрделәр»* [1: 319]. *«Элегрәк йомыш-кара төшеп колхоз базарына кагылган мәлләрдә Наилә белән Нәҗип Фәтхулла абзыйлары күзгә чалынганда оялып, шыпан-шыпан читкә таялар иде. Һәркем, эш базар юлында шомарып өлгермәгән сатучылар гына түгел, алып-сатып, эвеш-тәвеш китереп сакалларына кырау төшкән чаллар да урта кул эшем ияләре... бик ерактан иелеп-бөгелеп аңа сәлам бирәләр»* [1: 368].

Мисаллардан күренүенчә, А. Гыйләҗев «Балта кем кулында?» романында парлы сүзләрне шактый иркен һәм урынлы куллана. Автор шулай ук җөмләне кыска һәм җиңел аңлаешлы итеп бирүдә күп сүзләр кулланмыйча, мәгънә бөтенлегенә парлы сүзләр ярдәмендә ирешә:

*«Беренче нәүбәттә хөрмәтле Иван Ивановичны яратып әйләндерә-әйләндерә, миллекләрен алыштыра-алыштыра озаклап чаба.* Мунча керүнең бөтен ләззәтен ачыклый парлы сүзләр. *Энесенең шундый нәзакәтле, гүзәл хатынны ипи-чәйдә, такы-токыда тотуын белсә, эшне бөтенләп кире яктан башлап җидәрер иде»* [1: 510]. Парлы сүзләр ярлылыкны сурәтлиләр.

*«Чыннан да, шәһәрдән мәхшәр, ыгы-зыгылар, сары йорт хәсрәте, буш кесә, кимсенүләр – һәммәсе өелеп тегендә, җәһәннәмдә калыр иде»* [1: 435].

«Ыгы-зыгы» дигән парлы сүз халык күплеген, шау-шуны күз алдына китереп бастыра.

Шулай итеп, башта ук әйтелгәнчә, парлы сүзләрнең кулланылу сферасы гаять киң. Алар бу романда бигрәк тә күп файдаланылып, образларны, вакыйгаларны ачык күзаллауга ярдәм итәләр. Парлы сүзләрнең стилистик кулланылышын күзәтү тагын бер нәтиҗәне ясарга мөмкинлек бирә.

Беренче төркемгә һәркемгә аңлаешлы, сөйләмдә киң кулланылучы, сүзлекләрдә теркәлгән парлы сүзләр: *күз-колак, савыт-саба, эчми-тартмый, бүләк-санак, биш-аяк, алдын-артын, күлмәк-күпчек, шау-шу, дус-иш, кайгы-хәсрәт, гомер-гомергә, күзгә-күз, утка-суга, сукыр-букыр, ак-кара, көч-хәл, ашык-пошык, тирә-як* һ. б.

Икенче зур төркемгә язучы үзе иҗат иткән, элегә сүзлекләрдә булмаган, бары тик бу романда гына кулланылган парлы сүзләр*: комендант-дружинник, ләукә-җәннәт, оҗмах-алан, имгәк-тунеядлар, буйдак-импотент, тол-дүдәк, әче-зәһәр, сансыз-сөмсез, салон-вагон, Мәхмүт-Мудрый, Объ-Енисей* һ. б. Бу төр парлы сүзләр киң кулланылышта йөрмиләр сүзлекләрдә теркәлмәгәннәр һәм конкрет бу роман эчендә генә актуальләр. Хис-тойгыларның тирәнлеген, фантазиянең киңлеген, ассоциацияләрнең иксез-чиксез булуын күз уңында тотканда, мондый парлы берәмлекләр, сүзләрнең эчке мәгънәләре карышмаган очракта, бихисап күп ясалырга мөмкин. Бу типтагы лексемалар, романның телен җанландыралар, уй-тойгыларны, күренеш-вакыйгаларны күпкырлы итеп сәнгатьчә сурәтләү-тасвирлау мөмкинлеген арттыралар һәм, ниһаять, алар әдәби телебезне баетуда зур роль уйныйлар.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Гыйләҗев А.М.* Сайланма әсәрләр: биш томда. Т. 4. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 445 б.

2. *Миргалиев Р.М.* Татар телендә парлы сүзләр. Уфа: РИО БашГУ, 2004. 125 б.

УДК 394.2

# ПРАЗДНИК НАРДУГАН У КРЯШЕН

***З.Н. Кириллова***
*Казанский федеральный университет (Казань)*

Данная статья посвящена исследованию праздника Нардуган у кряшен (крещеных татар), специфике его проведения в условиях поликультурного общества. Нардуган у кряшен считается новогодним праздником, проводится с 1 по 18 января по новому стилю, т. е. между Рождеством и Крещением. Нардуган является языческим праздником, поэтому был запрещен религиозными деятелями. В работе также представлены различные традиции и обычаи проведения похожего праздника у народов Среднего Поволжья. Среди ученых существуют различные взгляды на происхождение слова, которые были исследованы в докладе. Кроме этого, в работе рассмотрены основные этапы празднования и анализированы их названия.
**Ключевые слова:** кряшены, крещеные татары, праздники, Нардуган, традиции, обычаи.

This article is devoted to the study of the holiday of Nardugan at Kryashen (Baptized Tatars), the specifics of its holding in a multicultural society. Nardugan at Kryashen is considered a New Year's holiday, held from January 1 to 18 in a new style, i.e. between Christmas and Epiphany. Nardugan is a pagan festival, so it was banned by religious figures. The work also presents various traditions and customs of holding a similar holiday among the peoples of the Middle Volga region. Among scholars, there are various views on the origin of the word, which were investigated in the report. In addition, the main stages of the celebration were considered in the work and their names were analyzed.
**Keywords:** Kryashen, Baptized Tatars, holidays, Nardugan, traditions, customs.

# КЕРӘШЕННӘРДӘ НАРДУГАН БӘЙРӘМЕ

***З.Н. Кириллова***
*Казан федераль университеты (Казан)*

Керәшеннәрдә Нардуган яңа елны бәйрәм итү йоласы булып санала. Ул иске стиль белән 25 декабрьдән алып 5 гыйнварга кадәр үткәрелгән, ә яңа стиль белән исә 7–18 гыйнвар көннәренә туры килә. Күренгәнчә, Нардуган христиан динендәге Раштуа һәм Кач ману бәйрәмнәре арасында уздырыла һәм славяннарның 12 көнгә сузылган Святки бәйрәмнәренә туры килә.

Славяннарда гына түгел, күп халыкларда кышкы кояш торгынлыгын, ягъни көн белән төн озынлыгы тигезләшкән вакытны (21 декабрь) элек кояшның «үлеп, кабат терелүе» яки «яңадан тууы» рәвешендә күзаллаганнар һәм аны ел саен бик зурлап, тантаналы төстә билгеләп узганнар. Бу йола Урта Идел буендагы халыкларда да билгеле. Мәсәлән, чувашларда – нартӑван, нартукан, удмуртларда – нартуган, мариларда – нардуган, мордваларда – нардван, нардава, нардукан [1: 60–61]. Керәшен татарларында да әлеге бәйрәмнең исеме нардуган буларак сакланып калган. Тикшерүчеләр күрсәткәнчә, әлеге термин кайбер мишәр авылларында да очрый [11: 78]. Төрек диалектларында исә аның мартуфал, мунтувар, мартавал вариантлары бар дип күрсәтелә [14: 61–66; 1: 61].

Нардуган сүзенең килеп чыгышы буенча галимнәр арасында төрле фикер хөкем сөрә. Гадәттә, аны монголча «нар» (кояш) һәм татарча «туу» сүзләреннән ясалган дип аңлаталар. Бу фикер буенча, нардуган сүзе «кояш туган» мәгънәсен белдерә [4: 74]. Татар этимологы Рифкать Әхмәтьянов исә бу сүзнең килеп чыгышын чуваш этимологы В.Г. Егоровча [6] монг. *нар* «кояш *туган* (көн)» дип аңлату дөрес түгел дип билгели һәм аны фарсы сүзе дип тәкъдим итә: «фар. *нард-у-фал* “нәрд уены ысулы белән күрәзәлек итү” (“нәрд һәм фал”) сүзеннән: нәрд уенында уенчы махсус савыттан (чүлмәктән) билгеле чиккә кадәр саннарның берсе язылган шакмак ала һәм нәрд тактасында шул санча йөреш ясый» [1: 61].

Рәүфә Уразман ассызыклаганча, «җентекле анализ нардуган терминының татар сүзе булуын күрсәтә, Урта Идел һәм Урал буе халыкларында ул җирле халык керәшеннәр һәм мишәрләр белән тыгыз элемтәдә яшәгән төбәкләрдә генә, берән-сәрән генә очрый. Чуваш галиме В.Г. Родионов та «“нартухан” сүзе чуваш теленә татар теле аркылы кергән дип саный» [11: 78], ләкин галимнәр терминның нинди сүзләрдән килеп чыгуын аңлатмыйлар.

Нардуган бәйрәме хакында Александр Троянскийның 1835 елда басылып чыккан сүзлегендә дә әйтелә. Автор аны «кояш торгынлыгы» бәйрәме дип атый, кышкы нардуган да, җәйге нардуган да булырга мөмкин дип әйтә [10: 253; 1: 60].

Рифкать Әхмәтьянов күрсәткәнчә, шундый уен әрмәннәрдә дә булган. Русларда ул *куляш* дип аталган. Нардуган җырлары, такмаклары, мәкальләре аерым жанр хасил иткәннәр. Җәйге нардуганда йөзек урынына чүлмәккә чәчәкләр салганнар, һәрбер чәчәк төренең махсус юралышы булган һ. б. Шуны да әйтергә кирәк: *нәрд* сүзе үзе дә – бер чәчәк атамасы [1: 61].

Нардуган үзенең асылы белән аграр йола булган дип санала. Бу бәйрәм игеннәрдән мул уңыш алу хакына, шундый өмет белән уздырылган. «Нардуганга бармасаң, житен булмый» кебек ышанулар яисә нардуган көйләрендә ашлыкка дип атап куркулык коюлар әнә шуңа дәлил булып тора. Әлбәттә, заманалар узган саен, Нардуган, башка йолалар белән катнашып, алардан күп кенә яңа ритуаллар үзләштергән. Атап әйткәндә, Раштуа, Святки бәйрәмнәренең йогынтысы зур булганлыгы күренә.

Элек-электән халык Нардуган бәйрәменә бик җитди караган, бию, җыр әзерләгән. Яшьләр урам буйлап, «Нардуганга!» дип, халыкны җыя торган булган. Нардуганчылар, өйдән өйгә йөреп, җыр һәм такмаклар әйткән, йорт хуҗаларына Яңа елда муллык, иминлек, бәхет теләгән:

Нардуган, Нардуган,
Нардуган, хуҗалар,
Котлы, мөбарәк булсын,
Тормыш түгәрәк булсын,
Мал-туарыгыз артсын,
Колыннарыгыз чапсын,
Игеннәрегез уңсын,
Йомыркадай тук булсын,
Нардуган, Нардуган! [4: 74–75]

Рәүфә Уразман Нардуган бәйрәменең төп мизгелләре дип түбәндәгеләрне билгели: кеше танымаслык булып киенеп, йорттан-йортка йөрү, йөзек салып багу, кызларның язмышы, кияү булачак кеше, киләчәк һ. б. турында төрлечә багу.

Кеше танымаслык булып киенеп йөрү төрле җирдә төрлечә аталган: нардуган булып җөрү, нардуган чабу, нардуган бабалары, бабайлар нардуганы [11: 78], Нардуган уены, киенеп йөрү [9: 27], бабай булып җөрү, бабайчы багыты (вакыты), җәшери (яшеренеп йөрүне аңлата) [3: 59–60] һ. б. Бу чорда кызларның үзара сыйланып йөрүләрен дә кызлар нардуганы дип атаганнар.

Нардуганчылар куркынычрак яки көлкелерәк итеп киенергә тырышканнар. Аю яки кәҗә булып кылану өчен, туннарын, бүрекләрен әйләндереп кигәннәр, хәер эстәүче, карт яки карчык, чегән булып киенү еш очраган. Егетләр – кызлар булып, кызлар – ир-ат булып, картлар исә яшь кәләш булып киенгәннәр. Бу вакытта йөзләрен яшергәннәр, ничек булса да үзләрен танытмаска тырышканнар. Кызлар егетләрдән һәрвакыт аерым йөргән. Өйгә кереп, скрипка, ә соңрак чорда гармун уйнаганга биеп күрсәткәннәр. Үзләре белән гармунчылары булмаса, мич капкачы, таба какканнар, кыңгырау шалтыратканнар. Кайбер өйләрдә шамакайларны сыйлаганнар, ләкин гадәттә алар буш кул белән чыгып китә торган булган. Соңыннан егетләр һәм кызлар, аулак өйгә җыелып, җырлап-биеп күңел ачкан.

Урамда, яшьләрдән тыш, икенче төркем дә йөргән. Анысында кием алыштыручылар аз булган. Берәр карт белән карчык һәм гадәти кием кигән, ләкин битләрен каплаган яки корымга буяган берничә малай төрлечә кыланып, такмаза әйтеп, халыкны көлдереп йөргәннәр. Карт белән карчык ролен авылның мәгълүм шамакайлары уйнаган. Монысының марилардагы яңа ел тамашасын хәтерләтүен әйтергә кирәк [11: 79].

Нардуган бәйрәменең мөһим бер өлеше – йөзек салып багу. Ул гадәттә Яңа елга каршы төндә уздырылган. Бу йола элек күп кенә мишәр авылларында да киң таралган була. Керәшеннәрдә күрәзәлектә егетләр дә, кызлар да актив катнашкан, егетләр еш кына бу эшне башлап йөргәннәр. Алар беркадәр түләү хакына, мәсәлән, йомырка, май һ. б. исәбенә, берәр йортны алып торганнар һәм кызларны шунда чакырганнар. Бәйрәмчә киенгән яшьләр, урамда җырлар җырлап, шул йортка барганнар. Бу көнне өлкән яшьтәгеләр дә яшьләр уенын карарга һәм үзләре дә теләк-өметләренең кабул булу-булмавын белергә дип җыела алган. Кайвакыт йөзек салуны өйдә түгел, берәр мунчада үткәргәннәр. Мишәрләрдә исә багуда фәкать кызлар гына катнаша алган. Аларга күз-колак булу өчен генә берничә өлкән хатын булган. Багучыларны күзләргә килгән әрсез егетләргә кызлар «бәла-каза чакырып китерә алганнар» [11: 80].

Керәшеннәрдә багу йоласының тәртибе серлерәк һәм гаҗәбрәк булганлыгын әйтергә кирәк. Мәсәлән, багу өчен суны бәкедән генә алганнар, төн уртасында су алырга бары тик тулы һәм имин гаиләдән беренче яки төпчек бала исәпләнгән берничә кыз һәм егет барган. Барганда да, кайтканда да, алар бер авыз сүз дә сөйләшмәскә, артка да әйләнеп карамаска тиеш булганнар. Бәке янында бер егет балта белән кояш йөрешенә каршы [9: 44] (Ф. Баязитова хезмәтләрендә – кояш уңаена таба [3: 60; 2: 148]) үзе уртада калырлык итеп сызык сызган. Бер кыз бәкедән су чумырып алган һәм анда

бакыр акча һәм йөзек салган, анысы «патша йөзеге» дип аталган. Чиләкне ак сөлге белән каплаганнар һәм үзләрен көткән өйгә чәнти бармак белән генә күтәреп алып кайтканнар. Өйгә кергәч: «Суга төштек балта алып, судан кайттык мал табып» яки «Суга бардык балдак белән, судан кайттык дәүләт белән», – дигән сүзләр әйткәннәр. Җыелган кешеләрнең һәммәсе, берәр теләк уйлап, йөзекләрен суга салган. Шуннан соң берәр куплет җыр яки такмак башкарылган. Роман Даулей исә 1903 нче елда басылып чыккан мәкаләсендә Казан губернасының Мамадыш һәм Лаеш өязе авылларында «кызлар артында түгәрәккә баскан егетләр көйләмичә генә җыр, мәкальәйтемнәр әйткәннәр. Эчтәлеген һәркем үзенчә аңлаткан [5: 196–203]», – дип яза. Бер кыз савыттагы йөзекләрне болгатып, берсен чәнти бармагы белән алган. Йөзекне алыр алдыннан әйтелгән сүзләрне йөзек хуҗасы үзенә дип кабул иткән. Нардуган такмакларының берничәсен тәкъдим итик:

Нардуганым нарына,
Бакма кеше йарына.
Кеше йары йар булмас,
Үз йарыңа тиң булмас.
Нардуганым нар булсын,
Эче тулы нур булсын.
Нардуган башы кемгә тийәр,
Ул бик бәхетле булсын.
Ак келәтнең ишеге
Таңга таба ачыла.
Талигалы мәндәләргә
Күк кабагы ачыла [2: 145, 147].

Мишәрләрдә дә шуңа охшаш җырлар җырланган. Мәсәлән, Әстерхан мишәрләрендә багу башланыр алдыннан иң кече кыз шундый такмак әйткән:

Нардуганым нард булсын,
Эче тулы нур булсын.
Нардуган кевен кем күләсә,
Шул бәхетле яр булсын! [1: 61]

Йөзек салып багу шул рәвешчә җыр-такмаклар белән дәвам иткән. Гадәттә, балдакны өч тапкыр салганнар. Соңгы тапкыр баккач, суны алып чыгып, кояшка каршы түккәннәр [3: 62]. Бу вакытта суда калган акча һәм «патша йөзеге» ничек төшкәнне караганнар. Әгәр күн төшсә, барлык фаллар рас киләчәк, дип ышанганнар [11: 81].

Йөзек салудан тыш, Яңа ел-Раштуа аулак өйләрендә, кызлар уенында күрәзәлек итүнең башка бик күп юллары да булган. Мәсәлән, Рәүфә Уразман иргә чыгу, булачак киявең турында егермеләп багу ысулы язып алуы турында әйтә. Шулар арасыннан түбәндәгеләре аеруча еш очраган:

▪ Төнлә абзарга (кайчагында башка кеше абзарына) кергәннәр дә дөм караңгыда берәр сарыкның аягыннан тотып алганнар. Әгәр яшь сарык эләксә, ире дә яшь булачак, тәкә туры килгәндә исә, тол калган иргә чыгасыңны бел дә тор, имеш.

▪ Капка аркылы урам якка киез итек ыргытканнар. Итек башы кая карап ятса, кияүгә дә шул якка китәсең, имеш.

▪ Тын тыңлау, тынга бару, ягъни авазларга карап күрәзәлек итү киң таралган була. Мондый багуның бер төрендә берәр йортның тәрәзә төбенә барганнар да ни сөйләшкәннәрен тыңлап торганнар; кызлар, авазларга карап, кодаларның кайсы тарафтан киләсен чамалаганнар. Тынга баруның икенче бер төре буенча, өч юл чатына чыкканнар. Берсе кисәү агачына атланып барган. Шул кисәү агачы белән түгәрәк сызып, түгәрәк уртасына су агызганнар. Гадәттә, ул суны йөзек багудан алып калганнар. Ахырда кызлар түгәрәк эченә ятып тыңлаганнар. Кемгә нәрсә ишетелсә, шуңа карап юраганнннар. Берәү гармун тавышы ишетсә, димәк, ул шәһәр егетенә кияүгә чыгачак. Икенче берәүгә сөйгәненең исеме ишетелгән. Әгәр бу вакытта битеңә кар төшә башласа, тормыш авыр булачак; пычкы белән кискән тавыш ишетелсә, кемдер үләчәк; арба шыгырдаган тавыш килгән якта иген уңачак һ. б.

▪ Өйгә тавык алып кереп, аның үз-үзен тотышына карап та юрау булган. Әгәр тавык орлык чүпли башласа, гаилә кунакчыл булыр; әгәр су эчәргә тотынса, ире эчкече булмас микән, дип юраганнар.

▪ Печән кибәненнән бер башак суырып алганнар. Әгәр башакта орлык күп булса, ишле гаиләле кешегә кияүгә чыгасың, әгәр дә бөртекләр аз булса, ул гаилә ишле булмаячак, имеш.

▪ Әрдәнәдән утын агачы алып кергәннәр. Әгәр ул шома булса, киявең чибәр буласы һ. б.

Хуҗалык елының нинди булачагы турында күрәзәлек итү дә булган. Мәсәлән, кабаны салкынга чыгарып куйганнар. Әгәр дә ул бәс белән капланса, җитен уңачагын хәбәр иткән һ. б. [11: 82–83].

Әгәр дә фал ачу нәтиҗәсе көтелгәнчә чыкмаса, моңа да артык борчылмаганнар, җырда әйтелгәнчә, өметне алга, киләчәккә күчергәннәр:

Нардуганның нары бар,
Кешеләрнең яры бар.
Ходай безне ялгыз итмәс,
Нардуганнар тагы бар [4: 75].

Күренгәнчә, Нардуган мәҗүсилектән калган йола һәм ышанулардан гыйбарәт. Бу бәйрәм христиан дине тарафыннан тыелган була. «Нардуган өе»н – «шайтан өе», «Нардуган уены»н «шайтан уены» дип атаганнар. Мәсәлән, XIX гасырның икенче яртысында яшәгән керәшен шагыйре, дин эшлеклесе, укытучы Яков Емельянов (Җырчы Җәкәү) шигырьләрендә шундый юллар бар:

Җаман эшне – нардуганны
Ич тә искә алмагыз.
Шайтан туйы нардуганга
Кыусалар да бармагыз.
Бармагыз сез нардуганга,
Андый җирне белмәгез,
Азгыннар урыны, шакшы өйгә
Ичбер чакта кермәгез.
Нардуганны кыласыз,
Төне буйы җыйылып.
Нардуганны кылучыга

Шайтан җөрөй сыйынып.
Нардуганда кыланучы
Бик кызганыч тейәдер.
Нардуганда кыланучы
Шайтан кийемен кейәдер [12: 157–159].

Тыюларга да карамастан, Нардуган бәйрәме әле озак вакытлар яшерен рәвештә булса да уздырылып килә, тик шулай да XX гасыр дәвамында аерым йолалары кими бара һәм гасыр азагында бөтенләй диярлек яшәүдән туктый, кайбер өлешләре генә хәзерге керәшеннәр тарафыннан кабат яңартылу омтылышын алды [13: 84–92].

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге. II т. (М–Я). Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. 567 б.

2. *Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. Казан: Матбугат йорты, 1997. 248 б.

3. *Баязитова Ф.С.* Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары: (Рухи мирасыбыз хәзинәсеннән). Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 158 б.

4. Без бер тамырдан: Керәшен татарларының этногенезын һәм этнографиясен өйрәнү буенча урта гомуми белем мәктәпләре өчен уку ярдәмлеге / төз. Н.В. Максимов. Казан: Мәгариф, 2002. 223 б.

5. *Даулей Р.П.* Святки у крещеных татар Мамадышского и Лаишевского уездов Казанской губернии: Доложено в общем собрании Общества археологии, истории и этнографии 25 февраля 1903 г. Казань: Типо-лит. Имп. ун-та, 1903. 8 с.

6. *Егоров В.Г.* Этимологический словарь чувашского языка. Чебоксары: Чуваш. кн. изд-во, 1964. 355 с.

7. *Кириллова З.Н.* Керәшен татарлары сөйләшләре // Занкиевские чтения: Интеграция науки и практики в современном образовательном пространстве: традиции и инновации (5–6 апреля 2024 г.): сб. тезисов докладов VIII Междунар. науч.-практ. конф. Киров: Межрегиональный центр инновационных технологий в образовании, 2024. С. 174–178.

8. *Кириллова З.Н.* Керәшеннәрдә Олы көн бәйрәме // Занкиевские чтения: сб. тезисов докладов IX Междунар. науч.-практ. конф. (3–5 апреля 2025 г., г. Тобольск). Киров: МЦИТО, 2025. [Электронный ресурс].

9. Татары-кряшены в зеркале фольклора и этнографических сочинений слушателей Казанских кряшенских педагогических курсов (педагогического техникума) (1921–1922 гг.): сб. материалов и документов / сост., авт. предисл. и примеч.: Р.Р. Исхаков, Г.А. Николаев. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ; Чебоксары: Чуваш. гос. ин-т гуманит. наук, 2014. 316 с.

10. *Троянский А.* Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских, собранный трудами и тщанием учителя татарского языка в Казанской семинарии, священника Александра Троянского: Т. 1–2. Казань: Унив. тип., 1833–1835. 2 т.; 26. Т. 2 и последний. 1835. 340 с.

11. *Уразман Р.* Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 96 б.

12. Яков Емельянов: тормышы һәм иҗаты = Яков Емельянов: жизнь и творчество: сборник статей и материалов. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2018. 184 с.

13. *Ercan Alkaya, Zoya Kirillova*. Kreşin Tatar Türkçesi (Dil, Tarih, Kültür). İstanbul: Kesit Yay., 2018. 670 s.

14. *Çay A.M.* Türk Ergenekon Bayramı Nevruz. Ankara: Türk Kültürü Araştırma Vakfı Yay., 5. baskı, 1993. 267 s.

УДК 37(092)(470.342)

# ВЯТСКИЙ ПЕРИОД В ЖИЗНИ ПРОСВЕТИТЕЛЯ Н.И. ЗОЛОТНИЦКОГО

***И.Ю. Кириллова***
*Чувашский государственный институт гуманитарных наук (Чебоксары)*

В статье рассмотрен вятский период в жизнедеятельности известного просветителя чувашей, тюрколога-компаративиста, этнографа Николая Ивановича Золотницкого. Именно в годы работы в г. Вятка были сформированы его основные просветительские воззрения, которые были успешно реализованы в Казани в деле просвещения чувашского народа. На формирование его просветительских взглядов повлияли активное участие в общественно-политической жизни города, редакторская деятельность в «Вятских губернских ведомостях», дружба с А.А. Красовским и передовой русской интеллигенцией и др.
**Ключевые слова:** Н.И. Золотницкий, чувашское просветительство, Вятские губернские ведомости.

The article examines the Vyatka period in the life of the famous educator of the Chuvash, comparative turkologist, ethnographer Nikolai Ivanovich Zolotnitsky. It was during the years of his work in Vyatka that his main educational views were formed, which were successfully implemented in Kazan in the enlightenment of the Chuvash people. His active participation in the socio-political life of the city, editorial work in the Vyatka Provincial Gazette, friendship with A.A. Krasovsky and the advanced Russian intelligentsia, etc. influenced the formation of his educational views.
**Keywords:** N.I. Zolotnitsky, Chuvash enlightenment, Vyatka Gubernia Gazette.

Вятский период в жизни ученого-языковеда, тюрколога-компаративиста, этнографа, просветителя чувашского народа Н.И. Золотницкого отметился началом литературной, публицистической и просветительской деятельности. Время его пребывания в г. Вятке – 1855–1865 гг. – были оживленными для провинциального городка. Здесь затевалось его культурное усовершенствование в виде устройства местных выставок, публичных библиотек, открытии воскресных школ, проведения литературно-музыкальных вечеров. На рубеже 1850–1860-х гг. Вятка, насчитывавшая около 15-ти тысяч жителей, имела духовную семинарию, мужскую и женскую гимназии, епархиальное женское училище, две типографии, была налажена книгоиздательская деятельность.

В первые годы пребывания в Вятке в 1855–1859 гг. Н.И. Золотницкий работал канцелярским чиновником в Вятской палате государственных имуществ. Уже тогда энергичный молодой выпускник филологического факультета Казанского университета предпринял попытку издания рукописной газеты «Незваный гость», которая содержала литературные и этнографические материалы, местные новости и сюжеты, «подслушанные разговоры» и пользовалась успехом у читателей [2]. Вышло всего два номера, но «во множестве списков». Знакомство с краем и его населением сыграли свою роль в формировании его мировоззрения. Кроме этого он активно публиковался в «Вятских губернских ведомостях», участвовал

в литературно-общественной жизни города, поддерживал связи с местной интеллигенцией. Его предприимчивая общественная деятельность была замечена, и в начале 1860 г. Н.И. Золотницкому была предложена должность редактора неофициальной части «Вятских губернских ведомостей» (ВГВ).

Оставаясь в целом официальным изданием «Ведомости», прежде всего их неофициальная часть, вели заметную просветительскую деятельность и отличались демократической ориентацией. Это прежде всего проявлялось в том, что в газете старались выражать мнение широких слоев населения и регулярно представляли свои страницы рядовому читателю. В этом была немалая заслуга редакторов, в том числе и Н.И. Золотницкого.

Н.И. Золотницкий работал редактором в эпоху великих реформ и преобразований, происходящих в стране. Оживление общественной жизни в середине XIX в. отразилось и на страницах ВГВ. При возникновении актуального для губернии информационного повода «Ведомости» наполнялись злободневными и содержательными публикациями. Наиболее интересный период газеты приходится на рубеж 1850–1960-х гг., когда в газете начинают появляться относительно смелые публикации. Просветительское движение, усиление которого было вызвано подготовкой «великих реформ», расширило круг тематик и самих авторов из провинциальной интеллигенции. Это множество заметок и статей, рассказывающих об исторических, экономических, общественных, этнографических сторонах тех или иных сел, приходов и уездов. Как литератор, Золотницкий большое внимание уделял в удовлетворении художественных запросов читателей, в формировании в них эстетических вкусов и ценностей. Этому содействовали освещающие культурную и литературную жизнь публикации, затрагивающие вопросы книжной торговли, музыкально-литературных вечеров, театральных постановок, организации школьного и библиотечного дела и т. д. Нашли место в «Ведомостях» и материалы по устной народной словесности и поэтическое творчество читателей. Из воспоминаний Н.И. Золотницкого, многие опубликованные в газете материалы за период его редакторства принадлежат ему, кроме авторских [1].

Одна из главных проблем, волновавших редактора, как видно из опубликованного материала была проблема образования. В статьях об училищах впервые были обозначены идеи начинающегго ученого в области просвещения нерусских народов России [4]. Он высказывает свою неудовлетворенность образовательной программой, пишет о значении христианско-нравственного воспитания в развитии нерусских народов, предлагает свои методы преподавании в сельских школах [5].

В публикациях Н.И. Золотницкого начала 1860-х гг. обозначились важнейшие идеологические посылы, ставшие впоследствии основой его просветительской концепции, – использование начальной школы и родного языка в деле просвещения нерусских народов: «Полагаем, что ученье для инородца тогда только будет полезным, если он начнет и выучится читать, писать, считать и всему прочему на своем природном языке. Конечно, для этого прежде всего нужны учебники и книги на инородческих языках» [6]. И именно ему принадлежит первое учебное пособие «Упрощенный способ обучения чтению» для просвещения вотяков, черемис, мордвы (1862), который впоследствии был распространен в других губерниях и в будущем

лег в основу учебника «Чуваш кнеге» («Чувашская книга», 1867), подготовленного для чувашских обучающихся.

Эпоха реформ вызвала рост общественного сознания вятской интеллигенции, в чем немаловажную роль сыграли революционно-демократические объединения, сформированные в Вятке под влиянием политических ссыльных А.Л. Витберга, А.И. Герцена, М.Е. Салтыкова-Щедрина и др. Огромным авторитетом у интеллигенции пользовался непосредственный сторонник идей А.И. Герцена, радеющий за народное просвещение нерусских народов, преподаватель духовной семинарии А.А. Красовский. В 1859 г. им были открыты частная библиотека и книжный магазин, позже типография. Их деятельность регулярно освещалась в «Вятских ведомостях». Постепенно библиотека сделалась центром распространения оппозиционных идей. В ней действовал нелегальный кружок, в котором изучались и обсуждались «Отечественные записки», «Современник», запрещенный герценовский «Колокол» и другие эмигрантские журналы, участником которых был и Н.И. Золотницкий. «“Колокол” на том берегу бил тревогу, – вспоминал Н.И. Золотницкий, – умы даже и в Вятке волновались» [1].

Н.И. Золотнцикий, наряду с редакторской деятельностью выполнявший надзор за типографиями, литографиями и другими подобными заведениями и книжной торговлей в г. Вятке, был хорошо знаком с А.А. Красовским. Их объединяла идея народного просвещения. В 1861 г. они вместе организовали воскресную школу при уездном училище в Вятке и учили грамоте крестьян. В работе воскресных школ просветители-демократы усматривали прямой путь к образованию народа и возможность его политического воспитания. Об органической связи образования со служением обществу, с пробуждением гражданского сознания поэтически выразил Н.И. Золотницкий в своем стихотворении «1 января 1866 г. в Кукарке»:

Учись затем, чтоб быть полезным
Себе и обществу всему,
Учись быть гражданином честным.

Если в своих ранних стихотворениях начала 1860-х гг. лирический герой Н.И. Золотницкого выступал как чувственный романтик, то со временем он загорается идей просвещения. Будучи редактором неофициальной части «Вятских губернских ведомостей», в 1862 г. он повторно публикует «Речь, сказанная при открытии первой публичной библиотеки в г. Вятке» (1837) А.И. Герцена, что в 1864 г. стало поводом для его увольнения и ссылки в слободу Кукарку [7: 141]. Связь Н.И. Золотницкого с «нигилистами» так же не могла не волновать губернскую власть. После редактора «Ведомостей» он работал инспектором уездных училищ и мировым посредником в Яранском уезде Вятской губернии. В 1866 г. он возвращается в Казань и вместе с Н.И. Ильминским активно включается в дело просвещения нерусских народов, главным образом чувашей.

С уверенностью можем сказать, что именно в годы работы в «Вятских губернских ведомостях» под влиянием передовой русской интеллигенции Н.И. Золотницкий формируется в своих взглядах как просветитель. Об этом свидетельствуют его общественная деятельность и публикации: «В то

время, как в Казани Н.И. Ильминский стал на практике применять выработанную им систему, организуя школьную сеть в крещено-татарских селениях с преподаванием на родном языке, – к такому же выводу о необходимости просвещения чуваш на их родном языке пришел путем собственных наблюдений и выводов Н.И. Золотницкий» [3].


СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1. Автобиография Н.И. Золотницкого // Рукописный отдел Научной библиотеки Казанского университета. Фонд Н.Я. Агафонова. Ф. 216. Л. 1623.

2. *Агафонов Н.Я.* Несколько биографических данных о Н.И. Золотницком // Рукописный отдел Научной библиотеки Казанского университета. Ф. 226. Л. 636.

3. *Афанасьев П.О.* Н.И. Ильминский и его система школьного просвещения инородцев Казанского края // Журнал Министерства народного просвещения. Раздел «Народное образование». Казань, 1914. № 12. Отд. 3. С. 128–129.

4. *Золотницкий Н.И.* Местные известия // Вятские губернские ведомости. 1960. № 9; *Его же.* Несколько слов об Елабуге и Николаевском приходском училище в селе Икском-Устье // Вятские губернские ведомости. 1860. № 48; *Его же.* Несколько слов о вятском женском приходском училище // Вятские губернские ведомости. 1960. № 50.

5. *Золотницкий Н.И.* О состоянии Вятской воскресной школы в первое полугодие ее существования // Вятские губернские ведомости. 1861. № 30 и др.

6. *Золотницкий Н.И.* По поводу открытия частных школ в Вятской губернии // Вятские губернские ведомости. 1861. № 47.

7. *Помелов В.Б.* Деятельность А.И.Герцена по развитию просвещения и культуры в Вятской губернии: к 200-летию со дня рождения // Вестник Вятского государственного университета. 2012. 1 (1). С. 139–145.


УДК 94(575.2)

# ТАТАРСКИЕ ПРОСВЕТИТЕЛИ У ИСТОКОВ МУСУЛЬМАНСКОГО ОБРАЗОВАНИЯ В КЫРГЫЗСТАНЕ В НАЧАЛЕ XX В.

***А.Э. Кубатова***

*Институт истории, археологии и этнологии им. Б. Джамгерчинова Национальной академии наук Кыргызской Республики (Бишкек)*

В статье рассматривается вклад татарских просветителей в становление и развитие системы мусульманского образования на территории Кыргызстана в начале XX века. На основе анализа архивных документов, исследований и воспоминаний современников, позволяющие проследить процессы культурного и образовательного взаимодействия между местным населением Центральной Азии и тюркоязычными народами в условиях Российской империи и накануне советской модернизации. Особое внимание уделяется влиянию джадидизма на модернизации мусульманского образования в целом. Открытие новометодных школ на территории Кыргызстана, а также деятельность татарских, башкирских, узбекских и впоследствии местных просветителей получило поддержку со стороны местной знати (манапов). Они также начали самостоятельно на местах открывать джадидские школы и приглашать учителей (мугалим). Статья подготовлена на основе авторской монографии и включает ранее не введенные в научный оборот архивные материалы, что придает исследованию новизну и актуальность.

**Ключевые слова:** мусульманское образование, джадидизм, татары, Центральная Азия, Кыргызстан, просветительство, архивные материалы, Российская империя.

This article explores the contribution of Tatar enlighteners to the formation and development of the Muslim education system in the territory of Kyrgyzstan in the early 20th century. Based on the analysis of archival documents, scholarly research, and contemporaneous memoirs, the study traces the processes of cultural and educational interaction between the local population of Central Asia and Turkic-speaking peoples under the Russian Empire and on the eve of Soviet modernization. Particular attention is given to the influence of Jadidism on the overall modernization of Muslim education. The establishment of usul-i jadid (new method) schools in Kyrgyzstan, along with the activities of Tatar, Bashkir, Uzbek, and subsequently local enlighteners, received support from the local elite (manaps). They also began to independently open Jadid schools in their communities and invite teachers (mugalim). The article is based on the author's monograph and includes previously unpublished archival materials, which add novelty and relevance to the research.
**Keywords:** Muslim education, Jadidism, Tatar enlighteners, Central Asia, Kyrgyzstan, archival materials, Russian Empire, modernization.

**Введение.** Просветительско-реформаторское движение в мусульманских окраинах Российской империи, как и в самом государстве, сопровождались процессами культурного и политического возрождения. В регионе происходили значительные изменения в общественной и культурной жизни, прежде всего, связанные с трансформацией общественного сознания, формированием национальной интеллигенции и ее деятельности направленной на улучшения положения собственных народов.

Просветители внесли в национальное сознание идеи прогресса, свободы, равенства и социальной справедливости, призывая население стремиться к образованию, считая, что только через знания догнать передовые народы и занять достойное место среди них.

Основатели этого прогрессивного движения – И. Гаспринский, Ш. Маржани, К. Насыри, А. Ибрагимов, М. Абдурашидханов, М. Бехбуди, А. Фитрат и др. были известны и на территории Кыргызстана.

В подготовке статьи были использованы материалы Рукописного фонда Национальной академии наук Кыргызской Республики, Центрального государственного архива КР, Кинофотофонофонда ЦГА КР, Иссык-Кульского областного архива, Государственного архива Казахской Республики, Государственного архива Узбекской Республики, материалы из газет «Туркестанские ведомости», «Шура», «Айкап», воспоминаний просветителей.

Из дореволюционных трудов, посвященных истории просвещения в Туркестане, можно отметить следующие: «Очерк развития народного образования в Туркестанском крае» С.М. Граменицкого (Ташкент, 1896), «Очерки образования в Туркестане (1865–1924)» К.Е. Бендрикова (М., 1960), «Русско-туземные училища, мектебы и медресе в Средней Азии. Путевые заметки» Н.А. Бобровникова (СПб., 1913), «Медресе Туркестанского края» Ф.М. Керенского (СПб., 1898), «Мадрасы в Туркестанском крае» Н.П. Остроумова (СПб., 1907) и др. В этих работах авторы отразили общий

просветительский процесс и дали оценку состоянию мусульманских школ, медресе и русско-туземных школ. К числу значимых источников по данной тематике также относятся исследования первых кыргызских историков – О. Сыдыкова и Б. Солтоноева.

Труды советских исследователей, таких как В.В. Бартольд («Культура мусульманства: общий очерк. – Петроград: Огни, 1918.), А.Э. Измайлов («Очерки по истории советской школы в Киргизии за 40 лет (1917–1957). – Фрунзе, 1957»), Д. Айтмамбетова (Дореволюционные школы в Киргизии. – Фрунзе, 1961) и др., написанных в рамках советской идеологии, требуют повторного изучения изложенных в них сведений и фактов, а также их объективной оценки.

В 90-е годы исследование истории получило новое направление, которое привело к созданию трудов учеными, обладавшими объективным взглядом на изучение истории. Достойны в этом плане труды таких ученых, как: К. Каракеев, Дж. Джунушалиев, А. Джуманалиев, В.М. Плоских, З. Курманов, Э. Маанаев, Г. Курумбаева, Ж. Алымбаев, Н. Курбанова и др.

**Деятельность татарских просветителей на территории Кыргызстана.** Передовая мусульманская интеллигенция, увидев причину безграмотности и невежества народа в социальном и колониальном гнете, в целях ликвидации этих явлений общества стремились объединиться и бороться с невежеством, с помощью просвещения народа. Сторонники нового явления – джадидизма были знакомы со взглядами просветителей и философов Запада и Востока и стремились использовать их достижения во имя развития страны. Их объединяло стремление повысить культурный уровень своих народов, заложить основы формирования национальной самоидентичности, что привело к политическим трансформациям в обществе.

Джадиды довольно деликатно относились к национальным ценностям и патриотизму и призывали к использованию в жизни достижений цивилизации. К примеру, Д.А. Алимова, подчеркивая, что джадиды никогда не ограничивались лишь национальными интересами, так объясняет приверженность джадидов к западной цивилизации: Запад тогда ушел далеко вперед по уровню развития технологии и производства. Государственное устройство будущего они видели в устройстве, основанном на единстве всех национальностей [5: 8].

Известно, что если Ш. Марджани, Х. Файзханов, К. Насыри и др. не просто стремились обновить школы и медресе, но и, осуществляя реформы, они распространяли джадидизм среди мусульманских народов, входящих в состав России, политическим же руководителем движения был Исмаил Гаспринский [6: 12].

И. Гаспринский в целях пропаганды новометодных школ дважды посетил Туркестан (в 1893 и 1906 году), в результате чего им были созданы многочисленные ценные труды об истории, культуре, образовании и т. д.

В основанной им самим газете «Терджиман» он первым поднял проблемы мусульманских женщин и их образования. Повести И. Гаспринского «Кадынлар» («Женщины»), «Арслан кыз», и др. были опубликованы в его журнале «Алем-и- Нисван» («Женский мир»), а в статьях он утверждал, что женщины, как и мужчины, имеют право на образование, участие в общественной жизни. Газета «Терджиман» и вышедший как приложение

к газете журнал для женщин «Алем-и-Нисван», были известны не только в Крыме, но и в Туркестане, Индии, Египте и других мусульманских странах. Основы реформирования школ, разработанные И. Гаспринским, были гораздо выше основ национально-конфессиональных и даже русско-туземных школ.

Численность учителей, приехавших для обучения народа грамоте, только в 1913 году насчитывало около сорока человек. В документах упоминались два имени: Харис, Гады Давыдов. Сообщая эти сведения, власти просили выяснить «кто из татарских учителей приехал к кыргызам для обучения детей и кто из кыргызов поступил в татарские учебные заведения». В ответе из Казани говорилось о том, что в этих целях в Джетысуйскую и другие области прибыли Мавлют Латыпов, Хасан Узбеков, Гатаулла Ахмаров и что о них нет негативных сведений, а что касается Хариса и Гады Давыдова, то их дела в Казанском управлении не рассматривались, однако начальник жандармского управления отметил, что первый из них – Харис Файзи (Файзуллин), возможно, является редактором газеты «Ахбар», выходившей в Казани и закрывшейся пять лет назад. Далее сообщается о том, что Файзи по своим взглядам панисламист и настоящий татарский националист, что им выпущены несколько учебников по татарской грамматике, что он организовал агентуру «Санкт-Петербургского страхового общества», что его брат тоже является агентом этого общества [6: 153].

Несмотря на всяческие гонения, известные татарские и башкирские педагоги Г. Рафики, С. Габдельманов, Н. Мулла-Газин, З. Вагапов, К. Мифтаков, Н. Мамин и др. трудились на кыргызской земле, делая огромный вклад в воспитание молодежи, они познакомили ее творчеством Марджани, Насыри, Тукая, Абая, а также с произведениями русских классиков. Многие просветители продолжили свою педагогическую деятельность после установления советской власти, дали знания тысячам молодым людям.

В 1840 году от Казанского муфтията в город Верный был послан Мухтурулла Баширов. В 1850 году он приехал в город Каракол, где и остался жить. В 1878 году под его руководством в Караколе началось строительство татарской мечети, которое закончилось в 1887 году. При мечети был открыт медресе, в котором начали обучаться городские дети. Из Казани в 90-е годы XIX века сюда приехал со своей семьей и стал муллой мечети Мужабиров Шакир. Ученики Шакира молдо – Иманали Эркебаев, Абдылда Арыстанов, Ыбырай Абдрахманов, Иса Чокморов и многие другие стали известными на территории просветителями.

Исследователь А. П. Ярков представил примерную численность учащихся: в школе (медресе) 31 узбек, 20 дунган, 10 татар. Ученики с любовью называли учителя Мужабирова «Шакир-дамбылда» [14: 35].

Один из них – Алдаш Молдо (Алдаяр Жээнике уулу), известный кыргызский просветитель, посвятивший всю свою жизнь обучению детей. Вместе с ним учился известный фольклорист, собиратель эпоса «Манас» Ыбырай Абдракманов [2: 98]. После окончания медресе Шакира дамбылды, Алдаш Молдо как и другие просветители, вернувшись к своему народу, в 1905–1906 годы организовал на пастбище Сары-Жон Джеты-Огуза передвижную (юрточную) школу и приступил к обучению детей [3: 5–8].

О новометодной школе Алдаша Молдо так писал его сын Абдулхай Алдашев: «Алдаш Молдо пошел по пути своего наставника Шакира дамбылды, в его школе обучались не только религиозным дисциплинам, но и светским, к примеру, он сам обучал четырем действиям арифметики, трем частям географии: физической географии, экономгеографии, политической географии [4].

Кроме того, многие молодые люди учились в школах города Каракола имени И. Гаспринского, Улукбека. Следует отметить то, что имя И. Гаспринского было присвоено в школе в городе Караколе еще при его жизни, говорит о том, что его деятельность оказала сильное влияние на население из отдаленных территорий, в том числе и Кыргызстана. Эта школа продолжила свою работу и после установления советской власти [8: 184–189].

Школа имени И. Гаспринского была открыта по инициативе татарского общества и была оснащена им необходимыми учебными средствами, книгами, партами, досками и т. д. Татарское общество до 1921 года контролировало хозяйственную деятельность школы, имело на руках инвентаризационную книгу. В 1921 году по требованию Отдела народного образования школа была передана под контроль государства. Из постановления экспертной комиссии Каракольского уезда, которая проверяла школьных учителей на предмет из знания, политических взглядов, стало известно следующее. Комиссия, состоящая из 5 человек, провела аттестацию городских учителей. Согласно документу, составленному 3 ноября 1923 года по результатам собрания, из 20 учителей 12 человек получили образование в мусульманских школах, остальные 8 – в российских гимназиях. Если отметить тех, кто окончил мусульманские школы-медресе, то это: 1) Мужазиров Ахметсадык Фатихович – закончил шестилетнюю татарскую школу и в 1898 году учебное заведение (?) имени Колпакова в городе Каракол. Трудовой стаж – 7 лет (следовательно, начал работать с 1917 года); 2) Надыршин Салих Михатхович – в 1898 году окончил мусульманскую семинарию. Трудовой стаж – 24 года (работал с 1899 года); 3) Рахимова Деляфруз Сабировна – окончила татарскую высшую начальную школу и учительскую семинарию в Оренбурге. Трудовой стаж – 6 лет (работала с 1917 года); 4) Джангирова Аимниса Аблайчураевна – в 1920 году окончила татарскую школу в городе Караколе. Трудовой стаж – 1 год; 5) Айтуганов Сыдык Якубович – окончил шестилетнюю татарскую школу в Караколе и один курс Тюркского (?) учительского института. Трудовой стаж – 1 год; 6) Джангиров Мухамеддин Баритонович – окончил городскую мусульманскую школ и шестилетние педагогические курсы в Ташкенте. Трудовой стаж – 2 года и т. д. [8: д. № 42; 21–23].

Следует отметить, что архивные сведения, приведенные выше, наглядно показывают: большинство учителей получили образование в мусульманской татарской школе имени И. Гаспринского и в узбекской мусульманской школе имени Улукбека. В этом контексте заслуживает внимания мнение опытного педагога Салиха Надыршина [14: 56], посвятившего всю свою жизнь преподаванию. Салих Надыршин (родился в 1879 году в селе Жаны Амзи Чистопольского уезда Казанской губернии, дата и место смерти неизвестны) – один из первых просветителей Кыргызстана. После окончания в 1898 году медресе в Казани работал учителем в Тамбовской и Са-

ратовской губерниях. С 1905 года работал в Кыргызстане, в городе Каракол в татарской новометодной школе, затем в русско-туземной школе, а после установления советской власти директором школы имени И. Гаспринского. Кроме татарского владел кыргызским, русским, арабским языками. В постановлении о нем было написано: «Он сказал о слабом развитии тюркского языка и необходимости, поэтому, введения в него персидских, арабских слов и слов из языка Корана и использования его как литературного языка…». Это интересный момент, он, по сути, высказывался за развитие тюркского языка как литературного, предлагая заимствование лексики из других языков, в том числе арабского и персидского – традиционный подход в исламской литературе и культуре. В советской действительности такие высказывания могли восприниматься как отход от идеологической линии, а когда задали вопрос о роли комсомола в школе, Надыршин ответил, что «роль комсомола в развитии социалистического сознания велика». Такой ответ соответствовал официальной линии партии и показывал его лояльность к идеологии, поэтому отметили его хорошую педагогическую и политическую подготовку и присвоили третью категорию» [8: 21–23].

По сведениям еще одного постановления этой же комиссии, Мухамедалиев Мухамед Имин, Абдустураев Иман Тюр (стаж 15 лет, работал

учителем и инспектором мусульманских школ), Ташбаев Абдулла, выпускник мусульманской школы имени И. Гаспринского, Салимбаев Ибрагим, выпускник школы имени Улукбека, Жаксылыков Искак и др. также прошли экспертизу. Мы называем эти имена, поскольку среди выпускников мусульманской школы были представители татарской, узбекской, кыргызской и казахской национальностей. Отмечается, что один из них, Жаксылыков Искак, 9 ноября 1900 года закончил Томский университет по врачебной специальности. На вопрос о том, почему он, будучи врачом, занимается педагогической деятельностью, он ответил, что в связи с состоянием здоровья он перешел на более спокойную работу. Члены комиссии, рассмотрев лишь политическую и педагогическую подготовку И. Жаксылыкова, присвоили ему 2-ю категорию [8: 15]. Следовательно, в среде учителей были и те, кто имел высшее образование.

Учитель каракольского медресе Салих Надыршин обладал большим авторитетом среди местного населения. Он был тесно связан с кыргызскими просветителями и обменивался с ними мнениями. К примеру, известный просветитель Талып Байболот уулу постоянно посещал Надыршина, обменивался с ним мнениями, знакомился с газетами и журналами, выходившими в Казани.

В начале XX века кыргызы начали знакомиться с периодической печатью, выходящей в Казани, и печатать собственные произведения на их страницах. К примеру, Сыдык Карачев свое первое произведение опубликовал в татарском общественно-просветительском и литературно-публицистическом журнале «Шура» («Совет»). Журнал выходил в 1908–1917 годы в Казани на татарском языке, который был основан хозяином золотопромышленного предприятия, известным татарским поэтом Закир Рамиевым, а главным редактором журнала был ученый-журналист Риза Фахрутдинов.

В журнале печатались статьи и о кыргызской земле, о положении ее населения и т. д. К примеру, в одном из его номеров от 1915 года была

опубликована статья узбекского просветителя, джадида Чулпан Абдулхамида Сулейман уулу (1897–1938) о городе Ош. Еще один татарский писатель Наврушан Белешов по совету врачей живший около одного месяца в Арсланбобе в кыргызской семье, под впечатлением от пережитых там событий написал статью, которую опубликовал в номере журнала, вышедшем в 1915 году. В ней описываются красота кыргызской земли и ее природы, развлечения и гостеприимность кыргызского населения, также даются сведения о проживающих там узбеках [1: 71].

Конечно, выход периодической печати в свет и интерес народа к ней не осталось вне поля зрения царской администрации. К примеру, в агентурных сведениях тайного агента под псевдонимом «Красный» от марта 1913 года с тревогой отмечалось, что в «Шура» (приложение «Вакт») пропагандируются идеи о том, что школьное образование объединит мусульман всего мира, поскольку будут разработаны принципы равноправия. Что в этом направлении работают все известные мусульмане, и обучению по единой для всех программе придается большое значение. Что считающихся культурно более развитых татарских учителей посылают не только на территории кыргызов, но даже и в Афганистан… Идея объединения всех мусульман через образование принадлежала Ибрагимову, а Разы Фахретдинов и Гаспринский считались его последователями и пропагандистами этой идеи по всей России [13: 95].

Таким образом, в распространении просветительских реформ и идей среди мусульман роль печати была велика. Вместе с тем, следует отметить, что она информировала о жизни, природе, социальном положении мусульманских народов России и являлась связующим их органом.

Из татарских просветителей, прибывших в Кыргызстан и оставшихся здесь навсегда, можно назвать выдающегося представителя татарского народа, просветителя, писателя Сабира Габдельманова, чья деятельность достойна особого внимания. Габдельманов Сабир (1879–1917) в 1902 году работал учителем в городе Каракол. В его многочисленных опубликованных в печати статьях встречаются упоминания и о городе Токмок. Возможно, вследствие гонений из-за сборника «Фөрьядлар» («Поминальный плач»), он переехал в Токмок, здесь до конца жизни он проработал преподавателем в медресе «Экбалия» («Прогресс»). В 1914 году он был призван на службу в армию, но был освобожден по состоянию здоровья. В 38-летнем возрасте он скончался. Он был активным членом «татарско-кыргызского общества» в Караколе, тесно общался с выпускниками медресе «Галия» Исхаком Канатовым, Эшеналы Арабаевым, Осмоналы Сыдыковым. Можно считать, что он также был знаком с Молдо Кылычем, поскольку часто ездил в гостеприимный аил кыргызского акына.

В произведении «Тянь-Шань тавында бер кечек кэяхет» («Маленькое путешествие в тяньшанских горах»), написанном им в поездке к другу Канату в Кочкор, пишет о полезности кумысолечения, а также, о том, что знакомился с обычаями и традициями, культурой гостеприимного народа, пытался выучить язык [10: 117].

В сведениях о мусульманских школах Джетысуйской области есть информация о том, что в Пишпекском уезде работают две новометодные школы: с 1902 года школа для мальчиков при татарской мечети и открытая

в 1909 году школа для девочек. Указывается, что в этих школах работают учителями крестьянин из Нижнесонской волости, Мамадышского уезда, Казанской губернии, мулла Ахмет Абдулладигин, закончивший в Казани (не в Казани, а в Уфе. – *А.К.*) курсы в медресе «Галия»; выпускник того же учебного заведения житель Кургалиской волости, Чистопольского уезда, Казанской губернии Султан Черкасов; житель Овсяновской волости, Бирского уезда, Уфинской губернии, выпускник медресе в городе Уфа Хосяндзян Баязитов; житель Зендяровской волости, Белебеевского уезда, Уфинской губернии, закончивший то же медресе Ходжа-Галий Рафиков [6: 136].

Из этих же сведений узнаем об учителях, выпускниках медресе «Мухамедие» в Казани, «Галия» в Уфе, «Хусание» в Оренбурге, «Расулие» в городе Троицке. К примеру, мударрисы знаменитого медресе «Экбалия» З. Вагапов и М. Смаков закончили «Расулие» в городе Троицке и «Галия» в Уфе, Нурали Мамин учился в «Мухамедие» в Казани. Их авторитет среди кыргызской молодежи был высок [12: 5–67].

Согласно сведениям из справки инспекции народных учебных заведений Семиреченской области, пишпекской школой (медресе) руководил Фахрул Ислам Гадеевич Рашидов, окончивший учительскую школу в Казани, здесь же работали учителями башкир Мирсаид Рахимов, приехавший из Уфинской губернии, Мирхайдар Диканов, окончивший медресе в Токмоке.

В новометодной школе для девочек в Пржевальске работали в основном женщины, к примеру, дочь Шакира молдо – Зубайда (зять – Хади), Н. Мужавирова [14: 56].

Джадиды не ограничивались образованием, в медресе они организовывали театрально-музыкальные кружки. Например, в Караколе, в доме купца 2-й гильдии Х. Абдувалиева ставились спектакли, а его дочь Нагима (мать Ч. Айтматова) в них исполняла первые роли. Из образованной татарской, башкирской, узбекской и кыргызской молодежи была создана творческая группа, которая осуществила постановку пьесы «Борч» («Долг») С. Карачева и др. спектаклей [14: 79].

Сведения об участии Нагимы Айтматовой (1904–1971) в постановках, нам удалось подтвердить рассказом дочери Торокула Айтматова и Нагимы Айтматовой Роза эже. В ходе встречи задали вопрос, о том, что ей знакомо ли сведения о пьесах с участием ее матери. Она ответила, что случайно узнала об этом в разговоре с ней: «однажды Нагима апа, увидев стебель чеснока, сказала, что если чуть поджигать кончики стебелька, затем сажей можно подкрашивать брови. Я спросила, а зачем? Она ответила, что в молодости она тоже участвовала в постановках в качестве артиста». Ее отец Хамза Абдулвалиев был одним из влиятельных членов татарского общества в городе и активно принимал активное участие в общественно-культурной жизни горожан, в том числе и в финансировании новометодных школ. Он построил большой двухэтажный дом, магазин, торговые ряды, похожие на петербургский Гостиный двор. Нагима Айтматова вспоминала, что в семье всегда отмечали Уразу, Курбан-байрам и Навруз. Рядом с домом был разбит фруктовый сад, который в народе называли «Садом Абдулвалиева» [7].

Календарь, составленный татарским просветителем Каюмом Насыри, напечатанный в Казанской типографии был широко популярен среди народов Средней Азии и Казахстана [9: 8]. О том, что данный календарь был распространен и среди кыргызов, можно узнать из следующих сведений: Урдолетов Жээренбай, получивший образование в каракольском медресе и работавший учителем в аиле Саруу Каракольского уезда, познакомившись через учителя татарской школы в Караколе Салыка (Салих Надыршин. – *А.К.*) с Байтурсыновым Ахметом, проживающим в Оренбурге, переписывался с ним. По просьбе Жээренбая А.Байтурсунов постоянно присылал учебники, газеты и журналы, и другую литературу для распространения по кыргызским школам. По словам Ж. Урдолетова, среди изданий, присланных из Оренбурга, оказался «Заман календари», и он, прочитав информацию о предстоящем затмении Луны, рассказал об этом своим односельчанам. Услышав об этом, муллы начали допрашивать его, мол, откуда он узнал о затмении, и пригрозили убить его, если он еще будет делать предсказания. Однако лунное затмение случилось, как и предсказал Жээренбай, и это спасло его от расправы.

Опираясь на вышеуказанные факты, можно сделать следующий вывод, что просветительские реформы, начавшее свой путь на побережье Волги и в Крыму, постепенно распространилось по Туркестану. Кыргызская молодежь начала получать образование в городах Уфа, Казань, Оренбург. В газетах джадидского толка вместе со статьями, призывающими к грамоте и просвещению, описывающими просветительскую деятельность в Туркестане, начали печататься и материалы, отражающие жизнь кыргызского народа. Просветители и после установления советской власти продолжали свою деятельность в области образования, воспитав и обучив не одно поколение молодых людей.

СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1. Ала Тоо журналынын атайын чыгарылышы. Бишкек: Ош-3000 мамл. дирекциясы, 2000. 247 б.

2. Алдаш Жээнике уулу// КР УИАнын Кол жазмалар фонду. Инв. № 300.

3. Алдаш Молдо // КР УИАнын Кол жазмалар фонду. Инв. № 754.

4. *Алдашев А.* Алдаш Молдо // Ала-Тоо, 1989, №8.

5. *Алимова Д.А.* Джадидизм в Средней Азии. Пути обновления, реформы, борьба за независимость. Ташкент: Узбекистон, 2000.

6. *Аршаруни А., Габидуллин Х.* Очерки панисламизма и пантюркизма в России. М.: Безбожник, 1931. 140 с.

7. Интервью с Р. Айтматовой от 5 ноября 2020 г.

8. Иссык-Кульский областной архив. Ф. 8, оп. 2, д. 42.

9. История литератур народов Средней Азии и Казахстана / под ред. М.И. Богдановой. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1969. 491 с.

10. *Мамытов С.А.* Кыргызско-татарские литературные связи второй половины XIX – начало XX веков. Бишкек: Мурас, 1999. 177 с.

11. Татары в истории Киргизии: прошлое и современность: Материалы Междунар. науч.-практ. конф. (г. Бишкек, 6 июня 2009 г.). Бишкек, 2010. 159 с.

12. *Чукубаев А.* Классовая борьба и общественная мысль Киргизии (1900–1917). Фрунзе: Кыргызстан, 1967. 162 с.

13. ЦГА РУз. Ф. 491, оп.1. д. 1026, л. 95.

14. *Ярков А.П.* Татары и башкиры в Кыргызстане: историко-культурный портрет. Ч. 1. Бишкек, 1996. 117 с.

УДК 81`112

# ВКЛАД КАЮМА НАСЫРИ В РАЗВИТИЕ ТАТАРСКОГО ЛИТЕРАТУРНОГО ЯЗЫКА

***Х.Х. Кузьмина***
*Казанский федеральный университет (Казань)*

Каюм Насыри, выдающийся татарский просветитель XIX века, сыграл ключевую роль в формировании татарского литературного языка. Его деятельность стала основой для развития литературной традиции, способствуя становлению норм и стандартов языка. Насыри активно использовал элементы народной речи, что сделало его произведения доступными для широкой аудитории и способствовало популяризации татарской литературы. Каюм Насыри формирует фундаментальное и прикладное направления науки татарского языкознания, развивает научный стиль татарского литературного языка и закладывает основы публицистического стиля, продвигает языковедческую терминологию. Кроме того, он внедрил в свои работы современные для своего времени темы и жанры, что обогатило татарский литературный язык новыми выразительными средствами.
**Ключевые слова:** татарский литературный язык, общенародный язык, Каюм Насыри.

Kayum Nasyri, an outstanding Tatar educator of the 19th century, played a key role in the formation of the Tatar literary language. His activities laid the foundation for the development of literary tradition, contributing to the establishment of norms and standards of the language. Nasyri actively used elements of folk speech, making his works accessible to a wide audience and promoting the popularization of Tatar literature. Kayum Nasyri established fundamental and applied directions in Tatar linguistics, developed the scientific style of the Tatar literary language, and laid the groundwork for journalistic style, advancing linguistic terminology. In addition, he introduced modern themes and genres into his works, enriching the Tatar literary language with new expressive means.
**Keywords:** Tatar literary language, national language, Kayum Nasyri.

# КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮГӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ

***Х.Х. Кузьмина***
*Казан федераль университеты (Казан)*

Татарның күренекле мәгърифәтчесе Каюм Насыйри яшәгән һәм иҗат иткән XIX гасыр – татар тарихы, татар мәдәнияте өчен генә түгел, гомумән, дөнья халыклары тарихында җуелмас эз калдырган иң катлаулы чорларның берсе. Тел – тарих көзгесе, телдә тарихи вакыйгалар чагылыш таба, шуңа күрә Каюм Насыйри хезмәтләренең әһәмиятен ул яшәгән чорны һәм шул чордагы тел ситуациясен күз алдына китерүдән башка мөмкин түгел.

XIX гасыр – гаять катлаулы чор. Дөнья тарихында Ауропа картасын үзгәрткән Наполеон сугышлары, милли буржуаз революцияләр, Африка, Азия дәүләтләрендә колониаль изүдән котылу өчен барган сугышлар, шулай ук Россиянең үз эчендәге декабристлар күтәрелеше, бәрәңге бунтлары,

Ватан сугышы, Кавказ сугышлары, Идел буенда әледән-әле кабынып торган крестьян хәрәкәтләре – боларның барысы да күпмедер дәрәҗәдә татарның укымышлы халкына да кагылган, аның тарихында, телендә эз калдырган вакыйгалар. Шул ук вакытта XIX гасыр – фәнни ачышлар гасыры. Электромагнит кыры ачылу, эчке янулы двигатель уйлап табу, паровоз төзү, Антарктида ачу, Дарвин теориясе эшләнү, Ауропада фәнни академияләр эше активлашу, этнография фәне алга китү һ. б. Боларның барысы да төрле фәннәрнең, шул исәптән тел гыйлеменең дә алга китүен тәэмин иткән.

Каюм Насыйри яшәгән чор – татар милләте формалаша башлаган чор. Әдәби телләрнең үсеше, гадәттә, милләткәчә чор һәм милләт оешканнан соңгы чорларга бүлеп өйрәнелә. Милләткәчә чорда әдәби тел функциясендә, бигрәк тә аның аерым стильләрендә (рәсми-канцелярия, дипломатия, фәнни, матур әдәбият стилендә) халыкның сөйләм теленнән шактый нык аерылып торган югары әдәби тел шәкеле, элитар яисә доминант чит тел кулланыла. Бу, гомумән, күпчелек әдәби телләргә хас күренеш, мәсәлән, XVII–XVIII гасырларда француз, алман, инглиз телләренең басымы астында яшәгән рус теле өчен «аристократик әдәби тел мәдәнияте» терминын да кулланалар. Ә төрки телләр үсеше өчен шундый ук рольне гарәп, фарсы, соңрак төрек (чагатай) телләре үтәгән; гарәп теле фән теле, фарсы теле шигърият теле буларак аерымланган. Төрки матур әдәбият әсәрләренең теле исә классик формада, берничә вариантта үсеш алган.

XIX гасырның ахырында һәм XX гасыр башында татар язучылары телендә үзенчәлекле агымнар барлыкка килә. Нигездә дүрт агым турында сүз алып барабыз: 1) Классик төрки тел үзенчәлекләрен саклап язу. Нигездә, шигърият әсәрләре телендә көчлерәк сакланган. Биредә бик борынгыдан килгән язма истәлекләрнең теленә якын рәвештә язу күзәтелә. Болгар чорыннан башлап, XX гасырга кадәр язылган әсәрләр әлеге юнәлешкә карый; 2) Гарәпчелек агымы. Элек-электән фән теле функциясен гарәп теле башкарган. Гарәп телендә медицина (тыйб гыйлеме), астрономия, математика фәннәре буенча фәнни хезмәтләр язылганлыгы билгеле. Мәхмүд Кашгариның 1074 елда язылган төрки текстлары булган «Дивану лөгат эт-төрк» хезмәте гарәп телендә язылган. Кашгари шулай ук гарәп телендә төрки грамматикага багышланган «Китаб җәваһир эн-нәхв фи лөгат эт-төрек» («Төрки теләрнең грамматик энҗеләре китабы») дигән хезмәт язганлыгын да искә ала, кызганычка каршы, ул безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән. XIX–XX гасырда да традиция бу дәвам итә, гарәп теле шигърият һәм чәчмә әсәрләр өлкәсендә дә активлаша; 3) Төрекчелек агымы. XVII–XVIII гасырларда татар әдәби теленә чыгътай һәм госманлы төрек теле йогынтысы көчәя. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында исә төрек теле үзенчәлекләре Исмәгыйль Гаспралы чыгарган «Тәрҗеман» газетасы теле аркылы да үтеп керә. Фатих Кәрими, Муса Бигиев, Заһир Бигиевләр бу юнәлеш тарафдарлары булып тора; 4) Халыкның җанлы сөйләм теленә якын рәвештә язу. Габделҗаббар Кандалый, Каюм Насыйри, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай һәм башкалар иҗатларының соңгы этапларында шушы юнәлешне яклап чыкканнар.

Әлеге дүрт агым арасыннан Каюм Насыйри бары тик берсен генә – халыкның җанлы сөйләм телен генә сайлаган дип әйтеп булмый. Ул, чыннан

да, эзләнгән, чөнки аның әйләнә-тирәсендәге чордашлары арасында гомумхалык телен әдәби тел, ягъни элитар тел югарылыгына күтәрүчеләр юк. Шуңа күрә әсәрләре телендә ике төп юнәлеш үзен ачык сиздерә. Аларның берсе – халык сөйләү теленнән, җанлы сөйләмнән файдалану. Каюм Насыйри моңа татар фольклорын, халыкка якын торган әдәбиятны туплау һәм өйрәнү нәтиҗәсендә ирешә. Аның 1884 елда басылып чыккан зур күләмле «Фәвакиһел җөләса фил әдәбият» китабы шул җирлектә барлыкка килә. Монда тагы аның календарьлары телен, балалар өчен төзелгән китапларын («Буш вакыт»), кайбер грамматикаларын кертеп карап була. Шул ук вакытта Каюм Насыйри башка төрки һәм төрки булмаган халыкларның фольклоры, Көнчыгыш әдәбияты үрнәкләрен дә ныклап өйрәнгән һәм аларны үз эшкәртүендә тәрҗемә иткән. Боларга төрекчәдән алынган «Кырык вәзир кыйссасы» (1868), «Әбугалисина кыйссасы» (1881), «Әфсанәи Гөлрәх вә Камәрҗан» (1896), гарәпчәдән тәрҗемә ителгән «Кырык бакча» (1880), «Җәваһирел хикәят» (1884) әсәрләрен кертергә мөмкин. Әлеге әсәрләр саф гарәп телендә булмаса да, гади халыкка авыр аңлашылган гарәп-фарсы сүзләрен күп кулланып язылганнар.

Каюм Насыйрины без, чыннан да, феноменаль шәхес дип атыйбыз, тик аның феномены буш урында барлыкка килмәгән.

Каюм Насыйри иҗат иткән чорга кадәр, XVIII гасырда ук, татар телен фәнни яссылыкта өйрәнү башлана. Моңа, әлбәттә, шул вакытлардагы иҗтимагый-сәяси ситуация дә сәбәпче булган, чөнки Азия, Кавказ илләренә хәрби походлар вакытында татар, гарәп, фарсы, төрек телләрен яхшы белгән татарлар әзер тылмач-тәрҗемәче буларак файданылганнар. Бигрәк тә Әби-патша – Екатерина II идарә иткән чорда (1762–1796 елларда) татар теленә игътибар арта. Татар телен тасвирлаган рус телле грамматикалар дөнья күрә. Каюм Насыйриның элгәргеләре – зыялылар һәм мәгърифәтчеләр – Сәгыйть, Исхак, Ибраһим Хәлфиннәрнең эшчәнлеге; Казан руханилар академиясендә беренче татар теле укытучысы булган Александр Алексеевич Троянский грамматикасы («Краткая татарская грамматика, в пользу учащегося юношества…», 1814); күренекле тарихчы, телләр белгече, педагог, Шиһабетдин Мәрҗани шәкерте Хөсәен Фәезханов («Краткая татарская грамматика», 1862) һәм рәссам-каллиграф, китап миниатюрасы остасы, педагог Мөхәммәдгали Мәхмүдовларның («Практическое руководство къ изученію татарскаго языка», 1855) татар теле өлкәсендәге эшчәнлеге дә XVIII гасыр ахырына – XIX гасыр башына карый. Татар теленең беренче грамматикалары да шушы вакытларда дөнья күрә. Бу грамматикаларда югары элитар тел шәкеле түгел, ә халыкның җанлы сөйләм теле күрсәтелә башлый. Мартениан Ивановның «Татарская грамматика» (1842), «Татарская хрестоматия» (1842, 1896), Салихҗан Кукляшевның «Дивану хикәяти татар» (1859), Габдулла Ваһаповның «Җырлар китабы»нда (1869) халыкның сөйләм теле шәкеле күренә. Әлеге уку басмалары гарәп теленең татарларга яхшы таныш грамматикасы үрнәгендә язылганнар.

Бу зыялылар арасыннан Каюмның чордашы булган Хөсәен Фәезхановны аерып күрсәтергә мөмкин. Ул мөселман мәгарифен реформалау проекты авторы буларак танылa. Хөсәен Фәезханов «Ислах Әл-мәдарис» («Мәктәп реформасы», СПб., 1862) хезмәтендә татар мәгърифәтчеләреннән беренче булып, Аурупа мәгариф методларын татар мәгарифе системасына

күчерү кирәклеге турында сөйли, дини нигезләрне һәм дөньяви фәннәрне укытуны органик рәвештә берләштерергә тәкъдим итә. Хөсәен Фәйзхановның энесе Габделгалләм Фәезхановның 1887 елда дөнья күргән «Татар теленә кыскача гыйлми сарыф» хезмәте билгеле. Шул ук вакытта Каюм Насыйри үзеннән элгәре яисә чордаш булган галимнәрнең китаплары белән таныш булган очракта да, аларның төзелешеннән канәгать булмагандыр дигән фикер кала, чөнки ул 1895 нче елда басылган «Әнмүзәҗ» исемле грамматикасының сүз башында «Утыз-утыз биш еллардан бирле ике тел фәннәрендән, ягъни үз телемездән вә дәхи рус телендән балаларга сабак укытканда, хосусан рус телен укытканда, үз телемезнең кагыйдәсен бәян кыйлгучы бер китапка мохтаҗ буладыр идем. Милләтемез халкындан бер һиммәт иясе зоһур итеп, телемез өчен бер кагыйдә тәртип кыйлмасмы икән дип тәвәкъкогдә идем – берәү дә сикереп чыгучы булмады» дип яза [3: 17].

Каюм Насыйри фәнни эшчәнлеген 34 яшендә, ягъни 1859 елда башлап җибәрә. Бу елны ул үзенең беренче әсәре булган «Мәҗмәгыл әхбар»не яза, әмма аның язма нөсхәсе күп еллар югалып торганга күрә бары 1895 елда гына басылган. «Нәхү китабы (Кыскача татар нәхүе)» (1860), «Буш вакыт» (1860), «Гакаид рисаләсе» (1867), «Кырык вәзир» (1868), «Әбугалисина» (1872), «Хисаплык» (1873), «Татарча-русча лөгать китабы» (1875), «Нәмунә, яки Әнмүзәҗ» (1879) исемле рус теленең грамматикасы язылa.

1871 елда Насыйри календарь чыгара башлый. Шул елдан башлап, 1898 елга кадәр 24 ел дәвамында ул календарь чыгаруын дәвам итә. Бары тик 1886–1887 һәм 1895 елларда гына календарь нәшер ителми кала. Бу календарьларның теле татар әдәби теленең публицистик стилен барлыкка китерүгә башлангыч адым булып торган.

1870 һәм 1871 елларда Насыйриның татар телендә газета чыгару фикере булган. Кызганыч ки, берничә тапкыр, хәтта арадаш галимнәр аша мөрәҗәгать ителсә дә, газета чыгарырга рөхсәт бирелми, ләкин аның еллык каленьдарларын хәзерге айлык журналларга тиңләп булыр иде.

1880 еллардан соң Насыйриның вафатына кадәр диярлек 20 елдан артык дәвам иткән иң актив язучылык дәвере башлана. Бу дәверендә ул бик күп эшли, әсәрләренең иң күп өлешен шушы соңгы 22 еллык гомере эчендә яза. Һәм нәкъ шушы вакытта ул татар әдәби теленең фәнни стилен үстерүгә зур өлеш кертә. Татар теле гыйлемен генә түгел, ә башка фәнни тармакларны да татар телендә эшләп булганлыгын күрсәтә. Бу дәвердә ел саен (календарьларны да кушып санаганда) 5–6 шар китап басыла. 1892 елда «Игъланат» исеме белән үзенең шул елга кадәр басылган һәммә әсәрләренең «Әсами көтеб»ен, ягъни үз хезмәтләренең биобиблиографик күрсәткечен нәшер иткән. 1900 нче елда исә Насыйриның актык басма китабы булган «Сәнаигъ гөлфания» басылып чыга.

Насыйриның иң соңгы әсәре булган гарәп телле «Мифтахел Коръән» (Коръән ачкычы) аның үлеменнән соң 114 ел узгач, XXI гасырда гына басыла. 2016 елда аның тарафыннан «Кәламе Шәриф» нигезендә 1886 елда төзелгән «Мифтах әл-Коръән» дип аталган Коръән конкорданс сүзлеге кульязмасының факсимиль нөсхәсе басыла. Әлифба тәртибендә төзелгән бу сүзлектә 46200 сүз теркәлгән, аларның әлеге «Кәламе Шәриф»тә нинди сүрәдә һәм кайсы биттә урын алганлыгы күрсәтелә. Татар галиме төзегән бу хезмәт ислам дөньясында Коръәннең беренче конкорданс сүзлеге булып тора [5].

Каюм Насыйри яшьрәк вакытында үзе төзегән һәм 1860 елда басылган «Кыскача татар нәхүе» грамматикасын да канәгатьләнерлек бер хезмәт дип танымаган, чөнки «Кыскача нәхү» китабы аерым рәвештә татар теленең үз материаллары, үз спецификасына нигезләнеп кенә язылмаган. Анда татар теле грамматикасы мисалларда гына бирелә, кагыйдәләре сөйләнми. Ул анда татар теленең грамматика кагыйдәләре буенча төзелгән сүзләр, сүз тезмәләре һәм җөмләләр алып, шуларның рус теленә тәрҗемәләрен, рус телендәге кулланышларын өйрәткән. Галим аны «Русча өйрәнүче мөселман егетләре өчен вә һәм татарча өйрәнүче рус егетләре өчен тәснийф кыйлдым», – дигән. Шуңа карамастан, аның «Кыскача татар нәхүе» киң татар җанлы теленнән алынган бай мисаллары йөзендә татар теле грамматикасын шактый тулылыгында чагылдыра. Аның өстенә, ул «Нәмүнә яки әнмүзәҗ» исемендә рус һәм татар телләренең чагыштырмалы грамматикасын төзегән, бу грамматика 1891 нче елда басылган.

К. Насыйриның татар теле грамматикасын аерым рәвештә гыйльми нигездә өйрәнгән иң күренекле әсәре – «Әнмүзәҗ» («Үрнәкләр»). Ул 1895 елда басылган. Бу әсәр үзенең мөстәкыйльлеге, тулы кагыйдәлелеге һәм төзелү методы белән дә алда әйтелгән грамматикаларыннан нык аерыла. К. Насыйри төрле күләмдә һәм тирәнлектә татар теленең фонетик, морфологик һәм синтаксик төзелешләрен күрсәтә, татар теле терминологиясенең беренче үрнәкләрен бирә.

«Әнмүзәҗ» 4 бүлектән тора. 1. Авазлар һәм исемнәр; 2. Фигыльләр; 3. Хәрефләр; 4. Тәркиб вә тәснийф кагыйдәләре. Беренче бүлектә татар теленең фонетикасы буенча беренче тапкыр 10 сузык системасы турында фикерләр әйтелә һәм аларны язуда гарәп әлифбасының 3 кенә хәрефе белән түгел, ә һәрберсенә аерым хәреф кирәклеге әйтелә һәм аларның язма рәвеше тәкъдим ителә. Бу – Каюм Насыйриның графика өлкәсенә керткән яңалыгы һәм соңрак ул унчылык хәрәкәте буларак үсеш ала. Хезмәттә шулай ук тартыклар бүленеше, сингармонизм законы, сүз мәгънәсе турында да әйтелә. Сарыф вә нәхү (Фигыльләр) бабында Насыйри сүз төркемнәрен гарәп грамматикалары мисалында исем, фигыль, хәрефкә бүлә, заман төшенчәсен аера, исем, сыйфат, сан, алмашлык кебек сүз төркемнәрен аера, зат, күрсәтү, сорау алмашлыкларын билгели, 800 гә якын фигыль берәмлекләрен күрсәтә. Хәреф бүлегендә исә исемгә дә, фигыльгә дә карамаган сүзләрне кертә, бирелә бәйлекләр, кушымчалар (мәсәлән, килеш кушымчалары), теркәгечләр, ымлыклар, рәвешләр һ. б. урын ала. Дүртенче бүлектә исә сүзләрне бер-берсенә бәйләү чаралары тикшерелә, изафәгә аерым урын бирелә, сүзтезмәләрне барлый. Бу бүлекнең кыйммәте шунда ки, бирелә халык теленнән күп санлы фразеологик берәмлекләр китерелә.

Әлеге хезмәт татар теле гыйлеме фәнендә фундаменталь хезмәт булып тора, гарәп һәм рус грамматикаларына ияреп язылса да, ул татар телендә һәм татар гомумхалык теле мисалларында төзелгән иң беренче грамматикалардан санала.

Латыйф Җәләй Каюм Насыйри эшчәнлеген югары бәяләп, «Насыйри грамматикасының тарихи әһәмияте шунда ки, ул, беренчедән, турыдан-туры татарларның үзләре өчен төзелгән, икенчедән, авторның үзе тарафыннан дөрес саналган методология (логик-формаль принципка) нигезләнгән, өченчедән, шушы чорның татар теленә, мәсәлән, аның орфографиясенә

кертелергә тиешле яңалык, үзгәрешләрнең фәнни дәлилләрен үз эченә алган була. Татар теле фонетик төзелешендәге үзенчәлекләр, һәм гарәп әлифбасының аларны дөрес тәгъбир итә алмавы мәсьәләсен, беренче башлап, Каюм Насыйри әнә шушы «Әнмүзәҗ»ен дә кузгата» дип яза [2: 38].

1945 нче елда «Совет әдәбияты» журналында басылган мәкаләсендә Латыйф Җәләй галимнең эшчәнлеген һәръяклап ача: «К. Насыйри татар теленең грамматик төзелеше, орфография һәм орфоэпик кануннарына карата шактый зур принципиаль мәсьәләләрле күтәрә, гадәти сөйләм теле белән әдәби тел арасында булырга мөмкин аермаларны ачык бирә һәм әдәби сөйләмне киң катлау тарафыннан үзләштерүнең методик юлларын күрсәтә. Каюм Насыйри коры теоретик, тел төзелешенә караган принципларны санап күрсәтүче генә дә түгел, бәлки, мәгърифәтчеләргә хас рәвештә, әдәби телне татарның үз сөйләү теленә нигезләү эшен практик тормышка уздыручы да була. Ул, мәсәлән, фәнни терминнарны халыкның үз тел чараларыннан алып ясауда бик уңышлы үрнәкләр калдыра. Каюм Насыйри татар теле белеме тарихында үзәк фигура, аңа нигез салучы, бигрәк тә орфография, орфоэпия, терминология һәм лексикология тармаклары буенча яңабаштан тудыручы булып тора» [2: 43].

Шул рәвешле, Каюм Насыйриның татар әдәби телен үстерүгә керткән өлеше нигездә дүрт юнәлештә башкарылган: 1) Татар теле гыйлемен фундаменталь фән югарылыгына күтәрә; 2) Татар теле гыйлеме фәненең гамәли (прикладной) юнәлешен формалаштыра; 3) Татар әдәби теленең төрле өлкәләргә караган фәнни стилен үстерә һәм публицистик стильгә нигез сала, тел белеме терминологиясен, тәрҗемәчелек эшен алга җибәрә; 4) Татар гомумхалык телен әдәби тел югарылыгына күтәрә.

Каюм Насыйриның биографиясе Гали Рәхим тарафыннан шактый тулы яктыртылган [4], әмма аның мирасы җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Галимнең сайланма хезмәтләре басылды, әмма тулы җыентыгы юк. Үзенең хезмәтләре турында ул: «Моннан соңгылар, әлбәттә, файдаланырлар. Халык та күнегер, тыныч булыр. Әмма һәрбер нәрсәнең әүвәл башта ихтираг кылган, вежүдкә чыгарган адәмнәр халыкның мәгънәсеннән башка нәрсә хасил итмиләр. Аларның хасиятләрен соңгы гасырдагы адәмнәр генә белделәр…» дип яза [1: 48]. Чыннан да, Каюм Насыйри мирасы халыкка кайта башлагач, аның бөеклеге еллар аша тагы да ачыграк күренә.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Гайнуллин М.* Каюм Насыйри документларда // Казан утлары. 1945. № 2. Б. 45–52.

2. *Җәләй Л.* Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри // Казан утлары. 1945. № 2. Б. 37–44.

3. *Насыри Каюм.* Энмюзядж / АН СССР. Казан. филиал. Ин-т языка, литературы и истории им. Галимжана Ибрагимова. М-во просвещения РСФСР. Казан. гос. пед. ин-т. Казань, 1975. 207 с.

4. *Рәхим Г.* Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия / редкол.: И.Г. Гомәров (проект җит. һәм җав. мөх.), З.З. Рәмиев, А.М. Ахунов; төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова. Казан: ТӘһСИ, 2020. 9 нче чыг. Б. 42–88.

5. *Хайрутдинов А.Г.* «Мифтах Аль-Кур’ан» Каюма Насыри: первый в мусульманском мире конкорданс корана. Ислам в современном мире. 2016; 12(1). С. 57–76.

УДК 82

# ТЕМА ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ В СОВРЕМЕННОМ ТАТАРСКОМ РАССКАЗЕ

***В.Ф. Макарова***
*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматриваются особенности отражения темы Великой Отечественной войны в рассказах современных татарских писателей. Показана трансформация повествования противоречий времен Великой Отечественной войны, трагических событий, сущности тоталитарной власти, героя войны. Выделены произведения мастеров рассказа, таких как А. Халим, Н. Гиматдинова. Автором отмечается то, что современным татарским рассказам о войне присущи глубокий психологизм, философское осмысление действительности и национальной идентичности.
**Ключевые слова:** современный татарский рассказ, Великая Отечественная война,реалистичное изображение действительности, герой войны.

The article examines the peculiarities of reflecting the theme of the Great Patriotic War in the stories of modern Tatar writers. The transformation of the narrative of the contradictions of the Great Patriotic War, tragic events, the essence of totalitarian power, and the hero of the war is shown. The stories of the masters of storytelling, such as A. Halim, N. Gimatdinova, are highlighted. The author notes that modern Tatar stories about the war are characterized by deep psychologism, philosophical understanding of reality and national identity.
**Keywords:** modern Tatar short story, Great Patriotic War, realistic depiction of reality, war hero.

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ХИКӘЯСЕНДӘ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ТЕМАСЫ

***В.Ф. Макарова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

Сугыш тәмамлануга 80 ел үтсә дә, Бөек Ватан сугышы темасы прозада үзәк темаларның берсе булып кала бирә.

Татар прозасында һәм эчтәлек, һәм форма ягыннан 1960 еллардан башланып киткән, Ә. Еники әйдәп барган үзгәрешләр татар прозасының сурәтләү векторын тышкы тирәлектән кешенең эчке дөньясына, психологиясенә күчерә, шәхесне һәм яшәешне фәлсәфи бәяләүгә алып килә.

Д. Заһидуллина язганча, 1960–1980 елларда «Тарихи шәхесләрнең милли каһарман буларак сурәтләнүе тулы бер әдәби күренеш төсен ала» [4: 15]. Образлылык ягыннан сугыш геройларын сурәтләүгә багышланаган әсәрләрдә иң башта Г. Әпсәләмов иҗатында калкып чыккан милли герой, сугышта җиңүче, романтик образ – татар кешесе хәзерге хикәядә дә төп урынны алып тора. Интернационализм шартларында татар әйдаманын үзәккә куйган Н. Дәүли кебек батыр язучыларның геройлары традиция буларак дәвам итә.

Татар хикәясенең матур үрнәкләрен биргән һәр язучының сугыш темасына кагылган әсәрләрендә (И. Гази, М. Әмир, Ә. Еники, Ф. Хөсни, А. Гыйләҗев, Р. Төхфәтуллин, М. Хуҗин, Ф. Яруллин, А. Хәлим,

Н. Гыйматдинова, Р. Фәизов, К. Кәримов, Ф. Яхин, Р. Габделхакова, Ф. Жамалетдинова, А. Әхмәтгалиева һ. б.) әлеге сыйфатларны күрергә мөмкин.

Совет чоры әсәрләрендә халыкның җиңүгә ышанычы, фашизмның ерткычлыгы, дошман әсирлегендәге хәлләр, фаҗигалы язмышлар, тылдагы авыр хезмәт, фронтка ярдәм итү максаты белән янып яшәү сурәтләнсә, 1980 еллардан хәрби-патриотик теманы үзәккә алган хикәяләрдә традицион планда батырлыкка соклану икенче планга күчеп, алга батырлыкның чыганакларын эзләү, сугышның ачы фаҗигасын реалистик сурәтләрдә бирү күзәтелә. Әйтик, 90 елларда язылган «Бәрәңге чәчәге», «Укалы карлар» (М. Хуҗин) кебек хикәяләрдә сугышның аяныч чынбарылыгы бәян ителә, «Өзелгән өмет» (Ф. Яруллин), «Соңгы һөҗүм» (Р. Габделхакова) хикәяләрендә сугыш чорында хатын-кызларның тетрәндергеч язмышы тергезелә.

XX гасыр ахыры, XXI гасыр башы татар хикәяләренә күзәтү ясаганда, Р. Насибуллова җиңү яулаган ветераннарның бүгенге тормышы сурәтләнгән әсәрләр еш очравына игътибар итә: «Аларда сугышның дәһшәтле елларын искә төшерүләр, фаҗигалы еллар истәлеге булган яраларның яңаруы сурәтләнә. Хикәяләрнең үзәгендә илебез азатлыгы өчен яшьлекләрен биргән, кан койган ветераннар өчен әрнү мотивы үзәккә чыга» [6: 62].

Хәзерге хикәядә дә әлеге тенденцияләр саклана.

Сугыш вакытында тылдагы авыр хезмәтнең сурәтләнеше белән илдә алып барылган сәясәтнең гаделсезлеге дә тасвирланган хикәяләр күп. Фашизмны җиңү көннәрендә рейхстаг түбәсенә беренче булып байрак кадаган милләттәшебез Гази Заһитов турындагы тарихи документаль роман кебек әсәрләр бүләк иткән А. Хәлим хикәяләре игътибарга лаек. Язучының «Трофей ашъяулык» хикәясендә әтиләре сугышта батырларча һәлак булган гаиләнең язмышына битарафлык оста табылган сурәт-детальләр аша ышандырырлык итеп ачыла. Бөек Ватан сугышында Җиңүнең бер еллыгына тол хатынга бүләк ителгән тишек ашъяулык шул чордагы тормышны, дәүләтнең гади кешегә мөнәсәбәтен чагылдыра. Язучы Миңсылу образы аша сугышта һәлак булган ирләренә тугры татар хатын-кызларының кайгы-хәсрәтен, авыр язмышын күрсәтә. А. Хәлимнең «Паравыз кычкыртты» хикәясендә дә әлеге тема дәвам иттерелә. Әсәрдәге туеннан соң икенче көнне сугышка киткән ирен гомере буе көтеп яшәгән Тәнзилә язмышы тетрәндерә.

Хәзерге хикәядә Бөек Ватан сугышы елларының каршылыкларын, фаҗигалые вакыйгаларны, тоталитар хакимиятнең, Сталин режимының асылын күрсәтү яңа чор биеклегеннән бәяләү аша бара (әлеге сыйфатлар татар прозасында иң беренче М. Юныс, Н. Фәттах әсәрләрендә күренгән иде).

И. Иксанованың «Онытылган парад» хикәясе А. Хәлимнең «Трофей ашъяулык» хикәясе белән аваздаш.

«– Анда да тормыш үзгәргәндер инде, үзебез генә дә күпме заводлар җибәрдек бит, – диде Фәйзрахман. Чын күңеленнән ышанып әйтте. Аннан, ничек инде чит туфракта каласың. Илдә аны әнисе көтә. Әнисе 43 тә үк вафат, ә Рәсәй һаман да уфаллалы иде. Берлинда узган Җиңү парадын гына түгел, җиңүчеләрнең үзләрен дә онытткан иде ил» [5]. Әлеге өзектә сугыш ветераннарына мөнәсәбәт ачык күренә. Герой илгә кайткач, парад турында

берничә тапкыр сүз калкытып караса да, аны аңлаучы табылмый, Фәйзрахманны алдакчы дип гаеплиләр. «Берлинда нинди парад булсын, Җиңү парады Мәскәүдә, Кызыл мәйданда узды», – диләр. Хәтта, үз балалары да аңа ышанмый. Улы бер тапкыр әтисенең Берлинда Җиңү парадында катнашуы турында мәктәптә сөйләмәкче була, тарих укытучысы класс каршында оятка калдыра.

«Берлинда эшләгәндә аларга данәләп кенә “Казбек” бирә башладылар. Аны американнар янында бер-ике генә суырып ташларга кирәк иде. Күрсеннәр, янәсе, ничек иркен яши совет солдаты!» [5]. Биредә язучы илдә тамыр җәйгән күз буяу күренешен тәнкыйтьли.

Бөек Ватан сугышы турында булган бүгенге татар хикәясендәге иҗтимагый-сәяси барышка бәя тыл тормышы, сугыштан соңгы еллар, кырым татарлары фаҗигасы, шәхес культы елларының ачы хакыйкате һәм иң әһәмиятлесе – милли яшәеш белән тыгыз бәйләнештә бирелә.

М. Әмирхановның 2020 елда язылган мистик «Алман мордары» бәян-хикәясендә шундый юллар бар: «Тартар илен: Алтын Урда мәмләкәтен, соңыннан Казан, Әстерхан, Касыйм, Себер, Кырым ханлыкларын шул син телгә алган толерантлык харап иткән дә инде. Татар – беркатлы, ышанучан, гадел халык. Ул вакытлы дан белән мавыгып, үзенең үткәндәге җиңүләрен мәңгеләштерү турында уйламаган, толерантлык күрсәткән. Башкалар шуннан бик оста файдаланган <...> Татар дәүләте дигәндә, аның четерекле яклары да шактый, әйтик, немецлар Идел-Урал штатын яклаганнар бит...» [1]. Шул рәвешле, автор азатлык, милләтчелек, фашизм кебек төшенчәләр турында уйлануга чакыра. Вакыйгаларның Германиядә һәм бүгенге Россиядә баруы эчтәлекне бер ил чикләреннән алып чыга, аны кешелек, дөнья тарихы итеп аңлауга юл күрсәтә.

Г. Гыйльмановның «Нихәл, яшьти», И. Иксанованың «Онытылган парад», «Сугыш корбаны», Р.Рахманның «Вәриснең әтисе кайта» хикәяләрендә сугыш темасы күп кенә героик нарративлардан аермалы буларак, пафос белән түгел, ә явызлык-яхшылык, матурлык-ямьсезлек каршылыклары аша лирик, психологик һәм фәлсәфи агымның чиратлашуы формасында ачылган.

Тема яңалыгы җәһәтеннән Р. Латыйповның сугыш чоры атлары хакындагы «Салдат», А. Хәсәновның сугыш вакытында тугры хезмәт иткән этләр турындагы «Өстемдәге затлы җиләнем» хикәяләре дә игътибарга лаек. Ф. Яхинның сугышның кеше үтерү хакындагы ачы хакыйкатен яңача укыган, дөньяда кеше хакы турында хәтта дәһшәтле сугышта да онытырга ярамавы хакында әтисе биргән беренчел дәресне бәян иткән «Әткәй сугышны сөйли» хикәясе, И. Иксанованың геройлары тормышын кешеләрнең иң кадерле нәрсәләрдән баш тарткан корбан китерү тарихы буларак аңлаткан «Сугыш корбаны», Л. Әбүдарованың «Йола» хикәяләре аерылып тора. Аларда сугышның дәхшәтле еллары, гап-гади кешеләрнең батырлыгы героик пафостан башка гына сурәтләнә.

Сугыш турындагы әсәрләр рәтендә сәнгатьчә эшләнеше ягыннан камил әсәр буларак Н. Гыйматдинованың «Шәрифулла» хикәясен билгеләп үтәргә кирәк. Ул Шәрифулланың эчке кичерешләренең төгәл бирелеше, көчле эмоцияләр уята торган психологик тирәнлеге, ышандыру көче белән җәлеп итә.

Әсәрнең төп герое – колхоз рәисе Шәрифулла Фәезхановны, райкомның беренче секретаре сугышка җибәрергә теләми. Әмма, герой фронтка китүгә ирешә. Яшь командир мыскылласа да, Шәрифулла «татар куркак түгел» дип көрәшә. Булдыксыз командир сугышчыларны яр буе миналанган булу ихтималын белә торып, аны үтәргә команда биргәч, Шәрифулла башкаларны коткарыр өчен, беренче булып үзе йөгерә һәм минага эләгә. Үлде дип туганнарына хәбәр итәләр. Сугыш беткәч тә госпитальдә дәваланып, ике аяксыз Шәрифулла гаиләсенә йөк булмас өчен туган ягын күреп кенә китмәкче була... Гарип килеш 5 бала өстенә кайтып төшәргә кыймыйча, «хөкүмәт ятимнәр дип, хет әзме-күпме пенсиясен тамызыр, ачтан үтермәс» дип, читтә яшәргә карар кыла. «Кайда асрар ул җан дигәнең? Вокзаллардамы, чүплектәме, яисә илем дип утка ташланган солдатлар өчен приютлар ачылып, шунда тереклек итәрме?..» [3]. Әмма ул дигәнчә булмый.

Шәрифулла – чын милли образ буларак туган. Ике татар баласы очрашса, туганлаша, ди язучы һәм геройны аңа яшәү көче биргән милләттәше, тырыш медсестра кыз белән очраштыра. Кыз кешелеклелеге белән геройга үлемне җиңәргә ярдәм итә.

Күп кенә татар хикәяләрендә авылдашларына көн күрсәтмәгән, тол хатыннарны җәберләгән колхоз рәисләре образларын очратсак, әлеге әсәрдә Шәрифулла мисалында кешелекле җитәкче образы бирелә. Шәрифулла арыш урлаган авылдашын сатмый, яклап кала. «Иргә колхоз рәисе камытын кигезделәр, мә җигелеп тарт» [3]. Сугышка хәтле армый-талмый колхозны җитәкләгәндә Шәрифулла авыл халкын ачтан үтерми, «әз-мәз печән-саламын, бодай-арышын өләште, кеше хакын ашамады, табын ризыктан сыгылмады».

Хикәядә сугыш, К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасындагы кебек, аждаһа образы аша бирелә. «Баздагы бәрәңге сабагы сыман», «Корыган куакка кунып, телендә сандугач сайраткан шушы карга» кебек чагыштыру, гыйбарәләр, милли димче Сарабикә әби образы, кыз сорарга бару күренеше, һәр авылда була торган Чыпчык Хәмәтша кебек кушаматлар, Мәдинә кебек тормышчан геройлар, Шәрифулланың ретроспекциядә бирелгән авылдашлары образлары аша милли үзаңлы герой күз алдына баса.

М. Мәһдиевнең Вәсфикамалы сыман тырыш, «тиресен дә түгә, бакчасын казый, капчык-капчык бәрәңгене эх тә димичә, күтәреп ташый» торган Мәдинә гамәлләре, сугыштан тагын да холыксызланып кайткан Мыек Сәлминының «Без кем өчен кан койдык?» дип читәнгә менеп кычкыруы ышандыра. «Аптырама, синең алашаң бар ла» дип шаярткан Мәдинә образы белән аты да калмаган колхозда алаша урынына җигелеп тормыш йөген тарткан әниләр, әбиләргә һәйкәл куелган.

Ярты гәүдәле геройның үзен башкалар күтәреп поездга утыртканда кечкенә вакытта авылда «каң-каң» уены вакытында ике кеше култыклап «йөгерткән» чакларын исенә төшерүе, туган туфрагына ятып сагынуын басар өчен җир ашавы тәэсирле бирелә.

Н. Гыйматдинованың «Сатлыкҗан» хикәясенең үзәгендә башкалар качканда яраланган иптәшен алып чыгарга омтылып пленга эләккән Сәлимгәрәй һәм туган илен яратмаган, Германиягә чыгып киткән фронтташы Тарасов каршы куела.

Әсәр башында үз илен чүплек оясы дип атаган, чит илдә яшәргә кызыккан Тарасов әсәр ахырында Германиядә хуҗасы куып чыгаргач, Казанга кайтып чүплектә актарынып яшәргә мәҗбүр була.

Совет концлагерьларын күргән булса да, Сәлимгәрәй иленә ачу сакламый. Ил башта тернәкләнсен» дип, ватанына каршы сүз әйттерми – үз фикерендә нык тора.

Туганы янына чит илгә китәргә кызыккан улына ул һәрвакыт «Туган ил бер генә була», – ди [2]. Язучының башка әсәрләрендәге кебек әлеге хикәядә дә шәхес һәм сайлау иреге үтемле бирелә.

Мондый хикәяләрдә гармун образы кебек милли бизәкләр, милли яшәеш белән бәйле проблемалар, этнографик детальләр аша, системаның, чор-вазгыятьнең милли кыйммәтләрне юк итүе хакындагы фикер тоемлана.

Шул рәвешле, күпчелек әсәрләр ачы хакыйкать рухы белән сугарылган. Романтик һәм реалистик хикәяләрдә язучылар илебездә сугыш барган еллар хакында гына сөйләп калмый, ә халкыбызның бөтен үткәненә дә бәя бирергә, дөньяда барган сугышларның никадәр мәгънәсез, кирәксез икәнлекләрен исбатларга омтыла.

Кайбер әсәрләрдә документаль, публицистик башлангыч әдәбилеккә күпмедер зыян китерә. Әмма бу текстларда тәнкыйди, фәлсәфи, сәяси бәяләрнең автор хикәяләүче мөнәсәбәте белән үрелүен, аерым чорларның мәдәни-этнографик атмосферасы, көнкүреше җентекләп тергезелүне, фактографик материаллар файдаланылуны уңай яктан бәяләргә кирәк.

Вакыт дистанциясе тарихи вакыйгаларны ирекле интерпретацияләргә мөмкинлек бирә, шул ук вакытта, яңа вәзгыять үз коррективаларын кертә. Бөек Ватан сугышы белән бәйләнешгтә бүгенге сугышларны, махсус хәрби операцияне сурәтләгән хикәя-повестьларда бу аеруча сизелә.

Мәйданга сугыш темасына язылган «Күңел нуры» хикәясенең авторы А. Хәбибуллина кебек сәләтле яшь язучылар килү куандыра. Алга таба сугыш вакыйгаларына яңача карарга мөмкинлек бирә торган сәнгатьчә югары кимәлдә язылган хикәяләр әле язылыр дигән өметтә калабыз.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Әмирхан М.* Алман мордары // Казан утлары. 2020. № 2. URL: https://kazanutlary.ru/news/ile-turynda-uyla/alman-mordary-byann (мөрәҗәгать итү вакыты: 25.05.2025).

2. *Гыйматдинова Н.* Сатлыкҗан (хикәя) // Казан утлары. 2022. № 5. URL: https://kazanutlary.ru/j-archive/journal-materials/2022-5/satlykan (мөрәҗәгать итү вакыты: 24.05.2025).

3. Гыйматдинова Н. Шәрифулла (хикәя) // Казан утлары. 2020. № 7. https://kazanutlary.ru/j-archive/journal-materials/2020-7/shrifulla-khikya (мөрәҗәгать итү вакыты: 24.05.2025).

4. *Заһидуллина Д.* Әдәби хәрәкәт.татар әдәбияты тарихы: сигез томда / [төз. Р.Ф. Рахмани]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 11–34.

5. *Иксанова И.* Онытылган парад (хикәя) // Казан утлары. 2017. № 6. URL: https://kazanutlary.ru/news/hikaya/onytylgan-parad-khikya (мөрәҗәгать итү вакыты: 24.05.2025).

6. *Насибуллова Р.Г.* XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар хикәяләрендә әдәби мотивларның чагылышы // Фәнни Татарстан. 2018. № 1. Б. 55–65.

УДК 821.512.145

# «ТРАГЕДИЯ ЛИЧНОСТИ В ПЬЕСАХ А. ГИЛЯЗОВА (на примере произведений «Медные колокольчики», «Три аршина земли»)

***Ф.Х. Миннуллина***

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

*Работа выполнена за счет гранта Академии наук Республики Татарстан, предоставленного молодым кандидатам наук (постдокторантам) с целью защиты докторской диссертации, выполнения научно-исследовательских работ, а также выполнения трудовых функций в научных и образовательных организациях Республики Татарстан в рамках Государственной программы Республики Татарстан «Научно-технологическое развитие Республики Татарстан».*

Статья посвящена анализу драматургии А. Гилязова, в частности пьес «Җиз кыңгырау» («Медные колокольчики») и «Өч аршин җир» («Три аршина земли»), в контексте кризиса соцреализма в 1960–1970-е годы. Рассматривается эволюция жанровых форм, усиление психологизма и условных приёмов, а также критический пафос, направленный на советскую систему и тоталитарный режим. Акцент сделан на трагическом конфликте личности и общества.
**Ключевые слова:** татарская драматургия, соцреализм, трагическое, конфликт личности и общества, коллективизация, символика, историческая память, психологизм, хронотоп.

The article is devoted to the analysis of A. Gilyazov’s dramaturgy, in particular the plays «Copper Bells» and “Three arshins of Zemi”, in the context of the crisis of socialist realism in the 1960s and 1970s. The article examines the evolution of genre forms, the strengthening of psychology and conventional techniques, as well as the critical pathos directed at the Soviet system and the totalitarian regime. The focus is on the tragic conflict between the individual and society.
**Keywords:** Tatar drama, socialist realism, tragic, conflict of personality and society, collectivization, symbolism, historical memory, psychologism, chronotope.

# А. ГЫЙЛӘҖЕВ ПЬЕСАЛАРЫНДА ШӘХЕС ФАҖИГАСЫ («Җиз кыңгырау», «Өч аршин җир» мисалында)

***Ф.Х. Миңнуллина***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

XX гасырның 60–70 нче еллары соцреализмның нигезләре какшау чоры буларак бәяләнә. Язучылар шартлы алымнарга киңрәк мөрәҗәгать итәләр, психологик башлангыч та көчәя. Җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә, язучылар, бер яктан тарихның каршылыклы якларын, шәхеснең фаҗигалы язмышын сурәтләү объекты итеп алалар. Тәнкыйть утын совет системасына, тоталитар режимга таба юнәлтә башлыйлар. Бу уңайдан А. Гыйләҗев пьесалары игътибарга лаек. Сәнгать белгече М.Г. Арсланов фикеренчә, А. Гыйләҗев – «театр сәнгате дөньясына 1960 еллар башында килгән авторлар арасындагы иң сәләтле, иң тирән һәм проблемалы драматургларның берсе. Аның театрга алып килгән дөньяга карашы, дөньяны кабул

итүе болытсыз түгел, бәлки каты, кырыс, кайвакытта давыл алдыннан була торган куркыныч халәт сыман» [1: 39]. А. Гыйләҗев каләме белән кырыктан артык комедия, трагедия һәм драмалар языла. Аларда чынбарлыктагы, милли, тормыштагы каршылыклы мәсьәләләр әхлакый проблемалар белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерелә. Әхлак, намус-вөҗдан каршында җаваплылык, яшәү максаты, кеше күңелендә һәм чынбарлыкта барган мәңгелек көрәше, гыйбрәтле язмышлар, тирән конфликтлы, драматик вакыйгалар аша яктыртыла. Мисал итеп әдипнең «Җиз кыңгырау» (1959) дип аталган драмасын китерергә була. Билгеле булганча, драманың максаты – шәхесне аның башка кешеләр, мохит белән катлаулы мөнәсәбәтләре аша күрсәтү. Геройлар исә әхлакый эзләнүләр һәм рухи үсеш процессында тасвирланалар. Язучының әлеге драмасында совет хакимияте елларындагы кешеләрнең эш-гамәлләре, татар авылында барган үзгәрешләр, шул үзгәрешләрнең кешегә тәэсире, психологик халәте тасвирлана. Хөрмәтулла образында автор совет дәверендә дә үз хуҗалыгын, малын үзенеке итеп санаган кешенең яңа хөкүмәткә ярашмавын, ят итеп каравын күрсәтә. Герой, колхоздан куылу сәбәпле, ике ел читтә яшәргә мәҗбүр була. Вакытлар үтү белән, авылга мулла булу теләге белән авылга кайта. Кызы Разыя әтисен икейөзлелектә, үз асылына хыянәт итүдә гаепли. Пьеса ахырында Хөрмәтулланың җирдә аунап яткан җиз кыңгырауга абынып егылуы, җиргә ятып елавы символик мәгънәгә ия. А. Әхмәдуллин билгеләгәнчә: «...Хөрмәтулла әсәрдә шул дәрәҗәдә оста сурәтләнгән ки, социалистик җәмгыятькә ят карашларны үзендә асраучы кешеләрнең җыелма тибы буларак килеп чыккан» [2: 105]. Кыңгырау үзендә мәңгелек, вакыт, хәтер һәм башка символик мәгънәләрне дә туплый. Гадәттә җиз кыңгыраулар бәйрәм хәбәрчесе, шатлык билгесе булып килгән. А. Гыйләҗев әсәрендә: «Җиз кыңгыраулар – таза тормышлы крестьян Хөрмәтулла өчен гаилә кыйммәте, якты хыяллары турында искә төшереп торучы мирас... «Җиз кыңгырау» әсәрендә автор эчке катлам мөмкинлекләреннән иркен файдалана: җомга, ярминкә хронотоплары, җиз кыңгырау символы «милләтнең бердәмлеген саклаучы» мәгънәсендә килә. Теманың ачылуы, образлар эшләнеше, шартлы алымнар кулланышы җәһәттеннән пьеса татар драматургиясендә яңа сүз булып тора» [7: 177]. Мүкләнеп, пәрвәзгә уралган кыңгырау иске тормышның, Хөрмәтулланың теләк-омтыллышларының җимерелү буларак та күзаллана. Кызы Разиянең: «Син олы юлларда яңгыратып узасы кыңгыраулар амбар почмагында мүкләнеп, пәрәвезгә уралып ятып калганнар! Олы юлларга башка кешеләр чыккан!» [5: 57], шуны раслый. Кызның әсәр ахырында шул кыңгырауларны җиргә ташалап китүе, Хөрмәтулланың шуларга абынуы ата белән кыз арасындагы туганлык мөнәсәбәтләренең өзелүе буларак та абул ителә. Урамннарда бәйрәм төсе биреп чыңлап узасы кыңгыраулар тавышы шул рәвешле тына. Биредә геройның килешә алмаслык тарихи конфликта кереп, шул тигессез көрәштә үз идеаллары өчен авыр газапларга дучар булуы ачыклана. Ләкин ул трагедия геройларына хас булганча, үлемгә дучар булмый. Биредә автор кешенең иҗтимагый фаҗигага юлыгып, тарихи агышны үзгәртә алмыйча җан газаплары кичерүен ассызыклый. Яңа системаның ата белән кызның дошманга әйләндерүен фаҗигалы хәл дәрәҗәсенә күтәрә. Биредә шәхеснең уй-фикере, хис-кичереше, теләк-омтылышлары үзгәреше дә аның эш-гамәлләре сәбәбе итеп карала.

А. Гыйләҗевның «Өч аршин җир» трагедиясендә, повестьларында, драма әсәрләрендә тарихи каршылыклар арасында калган ялгыз кеше язмышы ята. Әсәрне исә фаҗигалылык категориясенә нигезләнеп кару уңышлы булыр.Әлеге категориягә нигезләнгән пьесаларда, кеше яшәешендәге хәл ителә алмаслык каршылык ята. Ю. Борев билгеләгәнчә, трагик герой әсәрләрдә көчле шәхес буларак ачыла, ул тормышта шундый катлаулы шартларга куела ки, бер яктан авырлыкларга баш имәү, икенче яктан, каршылыкларны җиңеп чыгарга көче җитмәү аны зур газаплануларга, үлемгә китерә [4: 261]. Фаҗигалелек категориясен шәхес ялгызлыгында, чынбарлык белән трагик каршылыкта чагылуын А. Гыйләҗевның «Өч аршин җир» трагедиясендә күрергә мөмкин. Трагедиянең сюжеты шәхес фаҗигасы алга куелу белән үзенчәлекле. Тоталитар система корбаннарының җәмгыять тарафыннан кабул ителмәве, сәясәт һәм гаилә каршылыгы, сәяси вакыйгаларның кеше күңелен тупасландыруы, вәхшиләндерүе, кеше язмышын җимерүе кебек бер төркем проблемалар күтәрелә. Әсәрдәге вакыйгалар 30 нчы еллардагы коллективлаштырудан алып 60 нчы елларга кадәрге чорны иңләп ала. Повестьта да һәм сәхнә әсәре өчен иҗат ителгән әсәрдә дә бай гаиләдә бердәнбер бала булып үскән Мирвәлине иң ярлы кеше кызына өйләнүен белгәч, әтисе йортыннан куып чыгара. Әти-әнисе вафат булганнан соң егет байлыкка хуҗа була, шул малны зурайту өчен күп көч сарыф итә. Әмма ил күләмендә башланып киткән колхозлаштыру геройлар язмышына фаҗигалы рәвештә тәэсир итә. Бу үзгәрешләр авыл халкын капма-каршы якка аера. Трагедиянең төп герое Мирвәли шул вакытта трагик хата ясый: йортына ут төртеп, малларын агулап авылдан чыгып кача Үз гаебенең ни дәрәҗәдә булуын ул соңрак, кырык ел үткәч, үлем түшәгендә яткан хатыны Шәмсегаян белән туган авылы Карачурага кайтканда аңлый. Шул юл вакыйгасында Шәмсегаянга китергән җан газапларының ни дәрәҗәдә фаҗигалы булуына төшенә. Шул рәвешле драматург: «Мирвәлинең күңел халәтен, үсеш-үзгәрешен тасвирлаучы чылбыр – аның авылдашларын гаепләвеннән алып үз хатасын тану аша гафу үтенү баскычына кадәрге аралыгын тасвирлый. Мирвәли күңелендә барган эчке каршылык хис һәм акыл, совет җәмгыятендәге яшәү кагыйдәләре һәм үзеңчә яшәргә омтылу арасында төгәлләшә, шушу катлаулы, каршылыклы конфликт әсәрнең буеннан-буена сузыла» [5: 89]. Сагыш, үкенеч, чарасызлык мотивлары Мирвәлинең үткән турында уйланулары белән бәйле.Тарихи урын һәм вакыт колхозлаштыру чоры һәм шуннан соңгы еллар, ә психологик урын һәм вакыт Мирвәлинең яшьлектәнкартлыкка атлаган чоры кебек билгеләнә. Әсәрдә олы юл хронотобы аерым мәгънәгә ия. М. Бахтин юл мотивының әһәмиятен билгеләп, юл контурлары тормыш юлы белән керешеп китә, дигән фикерне әйтә [3: 241]. А. Гыйләҗев пьесасының юл күренешендә Мирвәли белән Шәмсегаянның фаҗигалы тормышы күзаллана. Вакыйгалар бирелешеннән бигрәк, трагедиядә уйланулар, искә төшерүләр, үткән тормышны бәяләү өстенлек итә. Төп герой Мирвәлинең эчке күңел пространствосы белән реаль урын контурлары кисешә. Юл төп геройның ике юл чатында калуын ассызыклый. Күңел тынычлыгын югалткан герой кайту юлын сайлый. Шул рәвешле авыл-юл оппозициясе драматик сюжетны хәрәкәткә китерә. М. Бахтин фикеренчә, олы юл очрашу мотивы белән бәйле [3: 248]. Вакыйгалар катламында геройның туганнары белән

очрашуы геройның язмышында хәлиткеч роль уйный. Туган ягына кайткан Мирвәлине дә авлдашлары үз янына сыйдыралар. Драматургның төп максаты исә – үз җиреннән аерылган кешенең газап чигүен, туган илне ярату хисен раслау, авылдашларына хыянәт иткән геройның фаҗигасын күрсәтү. Аның кылган гамәллләре дә аваылдашларына карата түгел, ә халыкны коллык дәрәҗәсенә төшергән системага каршы юнәлдерелгән. Шулай итеп, үз геройларының психологик халәтләре аша драматург совет хакимиятенә, аның сәясәтенә бәя бирә. Кешенең шәхес буларак, үз милкенә хуҗа булу хисен юкка чыгаруга, битарафлыкка басым ясала. Тоталитар режим шартларында ирекле эш итәргә теләгән шәхеснең фаҗигасын күрсәтә. Бу очракта шәхес язмышы – милләт язмышы, гаилә, ил, Ватан язмышы белән тыгыз бәйләнештә булуын күрәбез. Әсәрләр белән таныша башлауга ук аларның характерлар бәрелешенә генә корылмавын, ә җәмгыятьтәге иң актуаль проблеманы калку итеп күрсәтү максаты куелганлыгы аңлашыла. Югарыда каралган әсәрләрдән аермалы буларак, А. Гыйләҗевнең «Ефәк баулы былбыл кош» драмасы милли сыйфатларны үзендә туплаган, халыкның матур традицияләрен саклаучы Мияссәр карт, балалары ташлаган Рәшидә әби – картлар йортында яшәүчеләр образлары аша автор милләтнең киләчәге, тел язмышы, әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүе, яшь буынның хаксызлыкка ярашып яшәве кебек проблемаларны кискенләштерә. Шулай итеп, заман алып килгән үзгәрешләр алдында кешенең еш кына көчсез булуы, җан тынычлыгы таба алмыйча, үз-үзе һәм әйләнә-тирәсендәгеләр белән каршылыкка керүе дә драматург игътибарыннан читтә калмый.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Арсланов Г.М.* Татарское режиссёрское искусство (1957–1990). Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. С. 39–43.

2. *Әхмәдуллин А.* Күңелләрне уятыр. Казан: Мәгариф, 2007. 223 б.

3. *Бахтин М.* Вопросы литературы и эстетики. М: Художественная литература, 1975. 321с.

4. *Борев Ю.* Эстетика. М.: Высш. шк., 2002. 511с.

5. *Гыйләҗев А.* Җиз кыңгырау. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 302 б.

6. XX гасыр татар әдәбияты тарихы / ф. ред. Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Казан унты нәшр., 2011. Т. 2. 198 б.

7. *Хәбетдинова М.* Аяз Гыйләҗев // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / [төз. Р.Ф. Рахмани]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 6 т.: 1960–1980 еллар / [ф. мөх-р Д.Ф. Заһидуллина]. 2018. Б. 159–180.



УДК 069


# ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ТАТАРСКОГО ПЕДАГОГИЧЕСКОГО ОБЩЕСТВА


***Н.М. Мифтахутдинова***

*Национальный музей Республики Татарстан (Казань)*



В этой статье рассматривается деятельность Татарского педагогического общества в 1920-е годы. Акцент делается на изучение статей, отражающих научную работу Татарского педагогического общества. Нашей целью было исследование обществом направления изучения истории педагогики. В этой области изучалась деятельность Насиха Мухутдинова. В 1928 году находился

в научной командировке в архивах Ленинграда, Москвы. Им были введены в научный оборот многие ранее неизвестные документы.
Также члены педагогического общества выступают с лекциями о выдающихся татарских деятелях. Одно из таких выступлений – доклад Гали Хусни о Каюме Насыри.
**Ключевые слова:** Татарское педагогическое общество, Н. Мухутдинов, К. Насыри, Гали Хусни, Дом татарской культуры.

This article examines the activities of the Tatar Pedagogical Society in the 1920s. The emphasis is on studying articles reflecting the scientific work of the Tatar Pedagogical Society. Our goal was to explore the society's direction of studying the history of pedagogy. The activities of Nasikh Mukhutdinov were studied in this area. In 1928, he was on a scientific trip to the archives of Leningrad and Moscow. He introduced many previously unknown documents into scientific circulation.
Members of the pedagogical society also give lectures on prominent Tatar figures. One of these presentations is Gali Husni's report on Kayum Nasyri.
**Keywords:** Tatar Pedagogical Society, N. Mukhutdinov, K. Nasyri, Gali Husni, House of tatar culture.

## ТАТАР ПЕДАГОГИЯ ҖӘМГЫЯТЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Н.М. Мифтахетдинова***
*Татарстан Республикасы Милли музее (Казан)*

XX гасырың 20 нче елларында ил күләмендә күпсанлы җәмгыятьләр оешу тенденциясе күзәтелә. Әлеге җәмгыятьләрнең максаты – совет хөкүмәте алып барган сәяси-иҗтимагый тенденцияләрне халыкка җиткерү, үтәлешен контрольдә тоту, оешма әгъзаларының бердәм чыгыш ясау мөмкинлеген булдыру, фәнни эзләнүләр юнәлешен алып бару.

ТАССР Халык комиссарлары советы карары белән 1927 елның 4 июнендә Татар мәдәният йорты ачыла. Аның эш бинасы Островский урамы 10 йортта, элекке Дворяннар җыены бинасында урнаша. Татар мәдәнияте йорты – төрле юнәлештә булган җәмгыятьләрнең туплану, юнәлеш бирү, кисешү урыны. Биредә күпсанлы җәмгыятьләр һәм оешмалар эшли: Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте, «Яңалиф» җәмгыяте, Татар пролетар язучылары ассоциациясе, Татарстан Республикасы китап палатасы, Татар педагогия җәмгыяте, Татар совет язучылары оешмасы, Яшь язучылар түгәрәге, Татарстан академия китапханәсе һәм күп кенә башка оешмалар, учреждениеләр эшчәнлегенә җитәкчелек итә, аларның эшчәнлек планнарынраслый, мәнфәгатен дәүләт идарә органнарына җиткерә.

Татар педагогия җәмгыятен оештыру эшләре 1924 елларда ук башлана. Татарлар арасындагы педагогия эшләренең үткәнен өйрәнү һәм агымдагы педагогия эшләрен тикшерү, тиешле юнәлеш биреп баруны күздә тотып, берничә тапкыр җыелышлар уздырыла. Шулай да ул елларда рәсми рәвештә оешма дәрәҗәсенә күтәрелә алмый.

Татарстан Мәгариф халык комиссариатының гыйльми үзәге янында татар педагогия җәмгыятенең 1926 елда гына рәсми эшчәнлеге башлана. Аның Уставы раслана һәм ул «Мәгариф» журналында басылып чыга [4: 162–166]. Татар педагогия җәмгыяте төрле секцияләрне берләштерә.

1926 елның 5 декабрендә җәмгыятьнең беренче оештыру җыелышы була. Г. Сәгъди «Көнчыгыш педагогиясе һәм аны тикшерү юлында

хәрәкәтләр» дигән доклад белән чыгыш ясый. Әдәбиятчы галим Шәрык педагогиясе үзенчәлекләрен барлый, галимнәрнең, фәлсәфәчеләрнең хезмәтләренә туктала. Әлеге теманың күтәрелүе очраклы түгел. Гасырлар дәвамында формалашкан татар педагогия фикере нәкъ менә Шәрык педагогикасы, фәлсәфәсенә таяна һәм инде XIX гасырда Европа педагогиясе идеяләре белән кушылып китә.

Шулай ук әлеге үсеш барышы Г. Сәгъди мәкаләсендә дә чагылыш таба. «XIX нчы йөздә Көнчыгыш педагогиясе урынына ислам шәркы эченә Яурупа педагогиясе килеп керә башлый. Бу хәрәкәт бер яктан госманлы төрекләрдә, мисырлыларда күренсә, икенче яктан татарларда күренә. Идел буе татарларында Яурупа мәгънәсе белән беренче теоретик һәм практик педагог К. Насыйри булды» [4: 108]. Г. Сәгъдинең татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрендә К. Насыйриның эшчәнлеге тагы да тирәнтен ачыла, теоретик һәм практик эшчәнлегендә европа педагогиясен куллануга мисаллар китерә. «...үз фатирына җыйнап мәдрәсә шәкертләрен русча укыта. Менә шулай итеп, Насыйри рус дөньясы аркылы үзе яурупалашу белән бергә, татар балаларына, татар мәдрәсә шәкертләренә дә рус һәм татар теле аркылы Яурупа белемнәрен биреп, аларны Яурупа методы белән тәрбияли башлый» [3: 55].

1926 елның 5 декабрендә уздырылган җыелышта җәмгыятьнең идарә составы да сайлана: 1. М. Корбангалиев (рәис), 2. Хуҗа Рафыйков (рәис урынбасары), 3. Гаяз Максудов, Габдрахман Сәгъди, 5. Нәсыйх Мөхетдинов, 6. Мөхәммәтҗан Фазлуллин, 7. Мирсәет Сафин (гыйльми секретарь).

Җәмгыять эше өч тармак буенча бара:

1. Оештыру эшләре;
2. Гыйльми эшләр;
3. Нәшрият эшләре.

Мәгариф комиссариатында, «Мәгариф» журналы редакциясендә, Көнчыгыш педагогия институтында әгъзалар кабул итү оештырыла. Соңрак ике үзәккә караган педагогия җәмгыяте эшләп килүе дә билгеле: Мәдәният йорты янында Татар педагогия җәмгыяте һәм Шәрык институты янындагы педагогия җәмгыяте) [1: 1].

1928 елда бу җәмгыятьләрне бетереп, алар урынына татар һәм рус педагогларын берләштерерлек уртак бер җәмгыять төзү мәсьәләсе кузгатыла. Өлкә комитет тарафыннан тикшергәннән соң, бу фикерләр кире кагыла, ике җәмгыятьнең дә аерым булуы кирәк табыла [1: 1].

Татар педагогия җәмгыятенең эшчәнлегенең төп мәсьәләләре «Мәгариф», «Татарстан Педагогия җәмгыяте хәбәрләре», «Безнең юл» журналларында, «Кызыл Татарстан» газетасы һәм шулай ук башка вакытлы матбугат битләрендә даими басылып барыла.

Бүгенге көндә вакытлы матбугатта басылган мәкаләләр оешманың эшчәнлеген чагылдыруда төп чыганак булып тора. Мәсәлән, «Татарстан Педагогия җәмгыяте хәбәрләре» журналында даими рәвештә җәмгыятькә кергән әгъзаларның исемлеге, кем булып эшләүләре күрсәтелгән исемлек бирелә.

Татар педагогия җәмгыятенең эшчәнлеге күпкырлы. Беренчедән, әлеге оешма укытучылар белән турыдан-туры эшли, аларның мәнфәгатьләрен кайгырта, һәрдаим «Мәгариф» журналы бүлекчәләрендә укытучылар, уку-укыту процессындагы яңа алымнар, методикалар, яңа китаплар,

әдәбият тарихы, табигать белеме, физика һ. б. фәннәр буенча кулланмалар бастыра. Республика, ил күләмендә укытучылар съездлары, төрле мөһим мәсьәләләрне күтәргән конференцияләр оештыра. Яналифкә күчеш чорында исә, җәмгыять реформаның асылын халыкка аңлату һәм яңа төр язуга өйрәтү эшләрен үз вазыйфасына ала.

Татар педагогия җәмгыяте эшчәнлегенең тагын бер юнәлеше ул – республика, ил күләмендә экспедиция һәм фәнни командировкалар оештыру.

Җәмгыять тарафыннан Казан, Ленинград, Мәскәү архивларындагы татар мәдәниятенә караган документларны һәм китапларны барлау буенча фәнни командировка оештырыла. «Татарстан педагогия хәбәрләре» журналында Нәсыйх Мөхетдиновның «Татар педагогия тарихына караган архив материаллары. (Насыйх Мөхетдинов иптәшнең гыйльми командировкасы турында җәмгыятькә биргән хисаплары» дигән мәкаләсе басыла.

«Казан, Мәскәү, Ленинград архивында эшләгәндә әлегә кадәр һичкем тарафыннан яктыртылмаган бик кыйммәтле материаллар таптык. Алар педагогия тарихын яктырту гына түгел, хәтта бөтен XVIII–XIX йөзләрдә иҗтимагый, сәяси агымнарга да бай материаллар», дип искәртә Н. Мөхетдинов [2: 4].

Архивларда күтәрелгән материаллар тематик яктан бай һәм илнең төрле регионнарында яшәгән мөселманнарга кагыла. Алар – цензура тарафыннан үткәрмәгән китаплар турында, җәдитчелек хәрәкәте, татарлар арасында булып үткән съездлар, Оренбург рухани идарәсе хакындагы документлар һ. б.

Автор фикеренчә, иң мөһим документлар татарлар өчен ачылырга уйланган урта мәктәп проектлары, Касыймия, Мәрҗания, Галия мәдрәсәләре хакындагы материаллар, җәдитчелек хәрәкәте турында рәсми һәм яшерен төстә язылган материаллар. Әлеге документлар буенча «Мәгариф» журналында мәдрәсәләр хакында языла, элекке укытучылар турында белешмәләр биреп барыла.

Насыйх Мөхетдинов Татар педагогия җәмгыяте оешкан көннән үк җәмгыятьнең әгъзасы, 1926 елда ук оешманың беренче идарә составына сайлана.

Ул 1892 елда Чистай өязе Аппак авылында дөньяга килә. Н. Мөхетдинов – 1937 елда репрессиягә дучар булган мәгариф эшлеклесе .

Революциягә кадәр данлыклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, шулай ук 1912 елда Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. Казанда рус-татар башлангыч училищесында һәм «Касыймия» мәдрәсәсе каршындагы рус сыйныфында эшли.

1918 елдан Казан губернасы һәм ТАССР Халык мәгарифе органнарында эшли. Шулай ук ул «Мәгариф» журналына нигез салучыларның берсе. 1922–1924 елларда Кырым АССР мәгариф халык комиссары.

Насыйх Мөхетдинов 1924 елдан Шәрык педагогия институтында, 1926 елдан ТАССР Мәгариф халык комиссариатында, 1929 елдан халык комиссары, 1930 елдан яңадан Шәрык педагогия институтында эшли.

Бер үк вакытта, 1924–1930 елларда, Академүзәк рәисе урынбасары, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр нәшер итү белән җитәкчелек итә. Педагогика һәм педагогика тарихы буенча татар телендә беренче уку ярдәмлекләре төзи.

Татар педагогия җәмгыятенең халык арасында алып барган агарту эшләренең бер формасы – докладлар, лекцияләр белән чыгышлар ясау. Кайбер докладлар «Мәгариф» журналында даими рәвештә басылып та килә.

1928 елдан оешма әгъзасы булган укытучы Гали Хөснинең Г. Шәрәф җитәкчелегендә эшләнгән К. Насыйри хакында докладлы да кызыклы. Әлеге чыгышның төп нөсхәсе Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Мирасханәсендә саклана [5]. Кулъязма 31 биттән тора. Дәфтәргә язылган, авторның үз кулы белән төзәтелгән урыннары да бар. Текстлар астында 18.03.1928 һәм 28.03.28 даталары куелган. Гали Хөсни әлеге темага ике тапкыр чыгыш ясаган дип тә фаразларга мөмкин. Шулай ук дәфтәрдә хезмәте турында Г. Шәрәфкә язган запискасы да бар.

Каюм Насыйриның тормышы һәм аның фәнни эшчәнлеге турында эчтәлекле һәм кызыклы чыгышында Г. Хөсни К. Насыйриның үз әсәрләренә һәм галимнәрнең хезмәтләренә таяна. Доклад тыңлаучыга аңлаешлы, кызыклы формада язылган, бай фактик материал белән баетылган. Файдаланган әдәбиятның, фәнни хезмәтләрнең сноскалары күрсәтелеп барыла.

Шул рәвешле, К. Насыйриның билгеле бер юбилей даталарына бәйсез рәвештә, һәрдаим аның эшчәнлеге халыкка җиткерелеп барылган. Бу эштә Татар педагогия җәмгыятенең дә роле зур.

Гомумән, Татар педагогия җәмгыятенең 20 нче елларда алып барган эшчәнлегенең бер тармагы ул татар педагогиясенең тарихи үткәнен барлау, халыкка күренекле шәхесләр турында мәгълүматлар җиткерү, үткән мирасны популярлаштыру.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Максуд Г.* Татар педагогия җәмгыяте // Кызыл Татарстан. 1928. № 91. Б. 1.

2. *Мөхетдинов Н.* Татар педагогия тарихына караган архив материаллары // Татарстан педагогия хәбәрләре. 1929. № 3. Б. 4–5.

3. *Сәгъди Г.* Сайланма әсәрләр. Т. 2 / төз., текст. иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Р. Надыршина, И.Г. Гомәров; кереш сүз авт. Л.Р. Надыршина. Казан: ТӘһСИ, 2024. 352 б.

4. Татар педагогия җәмгыяте төзелү //Мәгариф. 1926. № 11–12. Б. 162–166.

5. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институның Язма мирас үзәге. Ф. 20, тасв. 3, сакл. бер. 22.

УДК 82.091

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ КАЮМА НАСЫРИ
## (обзор книги «Иршад әл-Әтбиха...»)

***А.Р. Мотигуллина***

*Поволжский государственный университет физической культуры, спорта и туризма (Казань)*

Выдающийся татарский писатель, педагог и общественный деятель Каюм Насыри оставил значительный след в культуре и литературе татарского народа. Важным вкладом является создание кулинарной книги, которая отражает богатство и разнообразие татарской кухни. Книга представляет собой не только

сборник рецептов традиционных татарских блюд, но и служит ценным источником информации о культуре и быте татарского народа. Автор стремился сохранить кулинарные традиции, передавая их будущим поколениям.
Кулинарная книга является важным культурным наследием, способствующим развитию национальной идентичности, гордости за татарские традиции. Тем самым подчеркивает уникальность и самобытность татарской кухни.
**Ключевые слова:** национально-культурная деятельность, публицистика, национальные блюда, общественное значение, традиции, календари.

The outstanding Tatar writer, teacher and public figure Kayum Nasyiri left a significant mark on the culture and literature of the Tatar people. An important contribution is the creation of a cookbook that reflects the richness and diversity of Tatar cuisine. The book is not only a collection of recipes for traditional Tatar dishes, but also serves as a valuable source of information about the culture and life of the Tatar people. The author sought to preserve culinary traditions, passing them on to future generations.
The cookbook is an important cultural heritage that contributes to the development of national identity and pride in Tatar traditions. Thus, it emphasizes the uniqueness and originality of Tatar cuisine.
**Keywords:** national and cultural activities, journalism, national dishes, social significance, traditions, calendars.

# КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ МИЛЛИ-МӘДӘНИ ЮНӘЛЕШТӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ
## («Иршад әл-Әтбиха...» китабына күзәтү)

***Ә.Р. Мотыйгуллина***
*Идел буе дәүләт физик тәрбия, спорт һәм туризм университеты (Казан)*

XIX гасырның икенче яртысында татар җәмәгатьчелегендә иҗтимагый, милли-мәдәни юнәлештә үсеш күзәтелә. Татар дөньясында беренче тапкыр вакытлы матбугат барлыкка килә, мәгърифәтчелек юнәлеше көчәеп китә, җәдитчелек хәрәкәтенә юл ачыла. Әдәби барышның киңәеп китүе, әдәби төрләр һәм жанрларның төрләнүе нәтиҗәсендә аларга бәя бирү, анализлау ихтыяҗы туу публицистиканың көчәеп китүенә сәбәп була. Әмма публицистика жанларының таралуына юл ачкан газета-журналлар булмау сәбәпле, башка төрдәге басмаларны эзләү календарьлар чыгара башлауга сәбәп була.

Шул чор журналистикасын фәнни нигездә өйрәнүче галим Р.Л. Зәйни бу башлангычны татар язучысы, педагог, этнограф К. Насыйри эшчәнлеге белән бәйләп: «К. Насыри первый человек среди татар, кто придал своим календарям основную характеристику газет и журналов – периодичность... В конце XIX века у татар стали появляться настенные календари. В изданиях просветителя-драматурга Ф. Халиди размещались кулинарные рецепты, полезные советы, занимательные рассказы и легенды небольшого объема, приметы, которые он переводил из других изданий на русском и турецком языках» [2: 10–11].

Күргәнебезчә, календарьлар үз эченә төрле мәгълүматны берләштерә: кызыклы һәм файдалы тәрҗемәләр материаллары урнаштырыла. К. Насыйри календарьларында татар халкының этнографик, милли асылын бирергә омтыла, шуңа күрә татар халкының телдән-телгә күчеп йөргән рухи

байлыгын язма рәвештә тәкъдим итә. Аның җыйган мәгълүматлары арасында татар халкының туклану рәвеше, сәламәт яшәү рәвешенә караганнары аерым әһәмияткә ия.

Татарларның аш-су осталыгы белән кызыксыну аны «Иршат әл-Әтбиха илә Истихзар әл-Әтгыймә» (Пешекчегә аш-су әзерләү турында юллама) (1894) китабын язуга этәргән. К. Насыйри анда табында утыру әдәбен, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен, ризыкның кеше организмына йогынтысын һәм төрле ризык рецептларын тәкъдим итә. Китапның 2015 елда басылып чыккан нөсхәсенең кереш сүзендә галим Р.Ф. Шәфигуллина «гомерен татар халкының тормыш-көнкүрешен җентекләп, этнолог буларак өйрәнүгә багышлаган Габделкаюм башына шундый китап язу турындагы фикер килмәсә, бәлки, сәер булыр иде. Шуңа күрә әлеге китапны гамәли кулланма буларак кына түгел, ә галимнең этнографияне һәм милли культураны өйрәнүенең бер өлеше итеп тә танырга була», – дип ассызыклый [3: 7].

Әлеге китапта К. Насыйриның татар халкының этнографик традицияләрен җентекләп өйрәнүе күренә. Әмма аңа кадәр бу башлангычны XIX гасырның уртасында ук татар халкының яшәү рәвешен, этногрфиясен өйрәнгән К. Фукс тәкъдим итә. Үзенең «Казанские татары, в статистическом и этнографическом отношениях» (1844) монографиясендә татар халкының яшәү рәвеше белән беррәттән ашау-эчү культурасына да туктала: «Я всегда усердно делалъ мои наблюдения относительно ихъ нравственности, образа ихъ семейной жизни и домашняго быта. <...> народъ такъ удивительно умелъ сохранить свои обычаи, свои нравы и народную гордость» [5: 34].

Тикшеренүче-галим Н.И. Воробьев К. Насыйриның басылып чыкмаган хезмәтләре арасында (Материалы в его «Неизданных трудах») татар халкының матди мәдәнияты, яшәеше, киенү рәвеше, ашау-эчү үзенчәлекләре бирелүгә басым ясый: «Описание пищи татар местами превращается в книгу кулинарии, он показывает способы приготовления того или иного блюда и дает рецепты» [1: 93]. Аның фикерләре К. Насыйриның «Иршат әл-Әтбиха...» китабын күздә тотып әйтелгән. Аның төзелеше бик гади: ул керештән, аш кабул итү мәдәнияты серләренә нигезләнгән киңәшләрдән һәм җентекләп язылган рецептлар урнаштырылган төп өлештән тора.

Керештә ашау-эчүнең әһәмияте ачыклана, аш-су төрләренә күзәтү ясала. Монда К. Насыйри дүрт юнәлешне аерып чыгара: 1) ризык компонентларына карап асыл һәм мослих тәгамга бүлә, ягъни төп ризык һәм аны тәмләткечләргә бүлү; 2) мослах тәгам компонентлардан тозның әһәмиятен ачыклау; 3) тәгамның ике төре булуы «пешмәк һәм пешермәк», ягъни суда пешерү һәм кыздыру; 4) пешкән һәм кыздырылган ризыкның кеше организмына йогынтысы.

Кереш өлешнең тел-сөйләм үзенчәлеклеге дә аерылып тора. Күп сүзләр гарәп-фарсы алынмалары белән (аеруча төшенчәләр) языла. Ашамлык, ризык, ягъни тәгамнең ике төрле булуы ассызыклана: асыл тәгам һәм мослих (яхшыртучы ягъни тәмләткеч) тәгам. Монда К. Насыйри төп ризык буларак ашны асыл ризык исәбенә кертә, ә мослах исә өстәмә рәвештә кулланыла торган компонентлар.

Шунда ук асыл ризыкның төп компонентлары да санап үтелә: «ит, су, он, ярма, дөге кебек нәрсәләрдер». Күрәбез, ул аш итеп пешерелә торган ризык атамаларын биреп, аларның әһәмиятен ассызыклый. Ярма белән

дөгене аерып күрсәтүе генә бераз аңлашылып җитми. Күрәсең автор Рәсәй эчендәге ярмалар рәтенә дөгене кертмәве аша аның күбрәк чит җирдән кергәнлеген тәгаенләргә теләгәндер.

Мослах тәгам ризыгының вазифалары башкарак. Алар «ләззәт бирүче вә һазым (аш сеңдерү, аш итү) бирүче хуш исле кылучы, мөлаем кылучы әйберләр» дип бирелә. Ягъни мослах тәгам ризыкларына тоз, суган, борыч, лимон, серкә, керән кебек ризык тәмләткеч, өстәмә тәм бирүче компонентларны кертә.

Ашка тәм бирүче матдәләр арасында тоз аерып күрсәтелә. Автор аны ашның тәмен үзгәртүгә мөнәсәбәтен уңай яктан бәяләп, «зарур булганы», – дип язса да, шунда ук аның зарарлы ягына да басым ясый: «...бу ризыкны яхшыртучы матдәләр могтадил (уртача) микътарда булмаса, ихтимал, зарары булмак» [3: 13].

Кереш өлештә, К. Насыйри азык-төлекнең ни рәвешле табынга тәкъдим ителүенә дә тукталып уза: «... тәгам әзерләмәкнең иң олуг гамәле табигыйдер, ягъни пешмәк һәм пешермәк дигән гамәлләрдер ки» [3: 13]. Шул рәвешле, тәгам әзерләүнең ике төрен аерып күрсәтә: беренчесе су белән әзерләп шурпа ясау аша, икенчесе – «корылай таба кебек нәрсәдә кабәб кылынадыр (кыздырыла. – *Ә.М.*)» [3: 13].

Шунда ук автор әзерләнә торган ризыкның сыйфатына да туктала. Аның фикеренчә, азык-төлекне әзерләү, пешерү вакытының да әһәмияте зур. «...Тәгам артык пешеп китсә дә, ләззәте җуеладыр – чи булса да, яки пешәр-пешмәс булса да яхшы булмыйдыр» [3: 13].

Авторның аерым игътибары ашау-эчүнең төрләренә карап кеше организмына йогынтысына юнәлтелә. Пешкән ризыкның ит өлешен яхшы дип күрсәтә, шунда ук «тәнгә тукландыра торганы шурпадыр», – дип билгеләп үтә. Ә кәбаб ризыкларының файдасы күп булу, тукландыру ягыннан яхшы булса да, «ашказаны зәгыйфь кемсәнәгә күп ашарга ярамыйдыр», – дип билгеләп итә. Шул рәвешле, авторның кәбаб, ягъни икенче итеп тәкъдим ителә торган ризыкның аз микъдарда һәм сирәк кулланылуына басым ясап, К. Насыйри бүгенге көн диетологлары дәрәҗәсендә фән нигезләрен белүен дәлилли. Аның кешенең туклану серләрен өйрәнүе, ашау-эчүнең кеше яшәешенең нигезен тәшкил итүен аңлавы үз чорының алдынгы карашлы медицина галиме булуын күрсәтеп тора.

Керештән соң ашау-эчү белән бәйле аерым киңәшләр бирелә. Алар алты өлештән тора һәм керешнең киңәйтелгән дәвамы буларак аңлашыла. «Җиренә вә вакытына карап тәгам»да яшелчә һәм итле ризык ашауны үзенчәлеген автор яшәү урыны, регионнар белән бәйләп аңлата. Салкын якларда ит, җылы якларда яшелчә күбрәк ашауга тәкъдим итә. Ә без яши торган урта климатта исә, икесен куллануны мәгъкуль күрә.

Һәр кешенең организмына бәйле рәвештә ризык микъдары үзгәреш кичерә. «Ризыкның чамасы» өлешендә К. Насыйри кешеләрнең ризыкны кабул итүнең чиген күрсәтергә теләп, «кешеләр комсызлардыр, хәтта ихтыяҗ кадәреннән һәм артык ашыйлар», – дип белдерә. Аның фикеренчә, ашаганнан соң су эчү зарарлы, чөнки аның эшкәртелүен тоткарлый. Шуңа күрә андый кешеләргә бер-ике көн ашамый торырга киңәш итә.

Азык кабул итү арасындагы вакыт та авторны кызыксындырган. «Ике тәгам арасы»н өйрәнеп, К. Насыйри азык эшкәртү өчен 4–5 сәгать вакыт

кирәклеген ассызыклый. Шуннан соң ашказанына ял бирергә кирәклеген дә истә тотсак, 6–7 сәгать аралыгы таләп ителә. Аеруча йоклар алдыннан ашаудан тыелырга тәкъдим итеп, организм өчен авыр булуына басым ясый. Шулай ук гакыл эшчәнлеге белән шөгыльләнгән кешегә «тәгамны аз ашау тиеш» диелә. Бу азык эшкәртелү вакыты белән бәйле булып, эш вакытында «фикергә буталчыклык бирәдер».

«Ашауның вакыты»на бәйле киңәшләр дә әһәмиятле. Монда ризыкның организм тарафыннан үзләштерелүен истә тоту кирәклеге искәртелә. Шуңа күрә ризыкны яхшы итеп чәйнәү кирәклеге әйтелә. Җиңел ризыкны 3–5 минут чәйнәргә, ә авыр үзләштерелә торганнарын бер сәгать дәвамында ашарга киңәш ителә.

Шулай ук азык кабул итү вакытында бөтен игътибар шуңа гына юнәлтелергә тиеш. Әйтик, ашау вакытында китап уку, ашап утырган кешегә борчулы хәбәрләр җиткерү шулай ук зыянлы. Шуңа күрә ашау вакытында барлык эшләрне, гамәлләрне читкә куярга, ризык белән ләззәтләнүгә комачаулаучы якларны читкә куярга киңәш ителә.

Китапның өченче өлеше «Әл-этгамәт әл-мөтәнәүгат» дип атала. Авторның бу рисаләсендә төрле ризыкларны әзерләүнең рецептлары бирелә. Алар арасында аш пешерү серләре дә, төрле кыздырылган ризыклар әзерләү ысуллары да, камыр ризыклары, кайнатма (варенье) әзерләү нечкәлекләре, төрле сироплар, компотлар әзерләү турында да мәгълүмат бирелә. Шуларга нигезләнеп, без моннан бер гасырдан артык элек ата-бабаларыбызның ризык төрлелеге, азык-төлек төрләндерү юллары белән таныша алабыз. Тулы бер энциклопедияне хәтерләткән рецептларны бүгенге көндә файдаланып була.

Гомумән алганда, татар халкының гасырлар дәвамында сакланып килгән милли ризыклары үзләренең уникальлеген югалтмый. Алар халыкның сәламәт яшәү рәвешен саклап, зарарлы гадәтләрдән читләшү, дөрес туклану үрнәге булып торалар [4: 167]. К. Насыйри тарафыннан төзеп калдырылган чыганак та үз чоры өчен генә түгел, бүген дә зур гамәли әһәмияткә ия. Хәзерге чорда бу мәгълүмат татар халкының милли-мәдәни хәзинәсе булып тора. Ул татар халкының яшәеше, көнитеше, рухи нигезе белән кызыксынучы киң катлам кешеләр өчен кыйммәтле чыганак ролен үти.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Воробьев Н.И.* Каюм Насыйри – этнограф // Каюм Насыйри. 1825–1945. Материалы науч. сессии, посвящ. 120-летию. Казань: Таткнигоиздат, 1948. С. 93–96.

2. *Зайни Р.Л.* Татарские печатные календари: становление и развитие (вторая половина XIX – начало XX вв.). Специальность 10.01.10 – Журналистика: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань: 2004. 21 с.

3. *Насыри К.* Иршад әл-әтбиха... / кер. сүз авт. Р.Ф. Шәфигуллина. Казан: Икътисад, идарә һәм хокук институтының «Познание» нәшр., 2015. 48 б. («Татарстан хәзинәсе» сериясе).

4. *Нурмухаметова Р.С.* Влияние внешней среды на формирование и функционирование лексики пищи татарского языка // Филология и культура. Philology and culture. 2014. № 4 (38). С. 164–169.

5. *Фукс К.* Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Казань, 1844; Краткая история города Казани. Казань, 1905 / репринтное воспроизведение с приложением Предисловия Н.Ф. Катанова к изданию 1914 г. Казань, 1991. 210 с.

УДК 811.512.145

# НУМЕРАТИВНЫЕ СЛОВА КАК ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЕ ЕДИНИЦЫ И ВОПРОС ИХ ИЗУЧЕНИЯ В ШКОЛЕ

***Н.А. Мукимова***
*Стерлитамакский филиал УУНиТ (Стерлитамак)*

В языках существуют специальные лексические единицы – нумеративные слова, употребляющиеся при существительных в составе количественной конструкции и имеющие национально-культурологическую нагрузку. Некоторые из них безэквивалентны, у некоторых наблюдается несовпадение семантического поля, поэтому их можно определить лингвокультуремами. Хотя в программы по татарскому языку не включено понятие о нумеративных словах, в учебниках имеются задания и упражнения, которые требуют сравнительного изучения с русским языком. В статье анализируются нумеративные слова, в которых наиболее ярко проявляется культурологическое значение, рассматриваются методическе аспекты их изчения в школе.
**Ключевые слова:** лингвокультурема, нумеративные слова, татарский язык.

Languages contain special lexical units – numeral words – used with nouns in quantitative constructions, carrying national and cultural significance. Some of them lack direct equivalents, while others exhibit discrepancies in semantic fields, allowing them to be classified as linguacultural units. Although the concept of numeral words is not explicitly included in Tatar language curricula, textbooks contain exercises and tasks that require comparative analysis with Russian. This article examines numeral words that most vividly reflect cultural meaning and explores methodological approaches to teaching them in schools.
**Keywords:** linguocultureme, numeral words, Tatar language.

# ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИК БЕРӘМЛЕК БУЛАРАК НУМЕРАТИВ СҮЗЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫ МӘКТӘПТӘ ӨЙРӘТҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

***Н.Ә. Мөкимова***
*УФҺТУның Стәрлетамак филиалы (Стәрлетамак)*

XX гасыр азагында, этнолингвистика, когнитив лингвистика һәм лингвострановедение кебек фәннәрнең дәвамы буларак, мәдәният һәм тел чигендә торган лингвокультурология фәне барлыкка килә. Тел һәм иҗтимагый-мәдәни процессларны комплекслы өйрәнү, тел һәм мәдәниятнең үзара бәйләнешен, тәэсир итешүләрен тел берәмлекләре аша тикшерүгә корылган бу юнәлеш Е.М. Верещагин, В.Г. Костомаров, В.В. Воробьев, В.Н. Телия, В.А. Маслова һ. б. хезмәтләрендә теоретик нигезләмәләр, терминологик тәгъбирләр, гамәли тасвирламалар таба.

Татар телендә чагылыш тапкан төрле этномәдәни берәмлекләрне өйрәнү һәм тасвирлауга багышланган хезмәтләр дә инде шактый. Р.Р. Җамалетдинов, Г.Р. Галиуллина, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, Ф.К. Сәгъдиева, Л.Р. Сәгыйдуллина, Н.Ә. Мөкимова һ. б. тарафыннан

лингвокультурологик тикшеренүләр алып барыла. Аларның хезмәтләрендә төрле мәдәни берәмлекләр каралуга карамастан, күптелле мохиттә яшәп, ана телен өйрәнүче балаларга мәдәни берәмлекләрне өйрәтүгә багышланган методик эшләнмәләр күп түгел дип билгеләргә була.

Кеше яшәешендә иң актив кулланылган сөйләм берәмлекләре – саннар. Әлбәттә, беренче сыйныфтан ук укучыларны санарга өйрәтү, саннарны танып татарча әйтү, ишеткәнен язарга өйрәтү күз уңында тотыла, урта һәм югары сыйныфларда «Морфология» бүлеген өйрәтү барышында сүз төркеме буларак саннарның семантик төркемчәләре, ясалышы, кулланылышы карала.

Саннар универсаль төшенчәләрне белдерсәләр дә, һәр халыкның күзаллавында, гореф-гадәтләре, йолалары, иҗаты һәм сөйләмендә үзенчәлекле чагылыш таба. Безнең карашка, саннар янында актив кулланылган һәм шул ук вакытта пассив лексика рәтенә кереп баручы нумератив сүзләр дип аталган лексик берәмлекләр милли-мәдәни яссылыкта игътибарга лаек. Т.В. Жеребилоның сүзлегендә алар «классификатор» баш сүзе астында бирелә: «Классификаторы (нумеративы, счетные слова) – специальные синтаксические лексемы или морфемы, употребляемые при существительных в составе количественной конструкции. В русском языке им близки лексемы *штука, пара, голова* и др.: *семь штук яблок, две пары брюк*. Свойства типичных классификаторов следующие: 1) их обязательность в нумеративных конструкциях: *пять пар ножниц* (пять ножниц – ненормативное выражение); 2) они не имеют собственной лексической семантики и выполняют грамматическую функцию: передают значение счета; 3) классификаторы образуют систему: разные существительные употребляются с разными классификаторами. Классификаторы принадлежат лексике, а не грамматике» [2: 145].

«Татар грамматикасы»нда нумератив сүзләр (сан ачыклагычлары) термины белән бирелгән тел берәмлекләре үзенчәлекле синтаксик төзелмә дип билгеләнә: «Аергыч ролендә килгән саннарга махсус ачыклагыч сүзләр ияреә. Алар гадәттә аергыч белән аерылмыш (сан белән исем) арасында әйтеләләр. Бу сүзләр саналмыш предметның сыйфаты белән ярашкан булалар һәм, нәтиҗәдә, алар телдә аерым категория сүзләргә генә хас булган нумератив билге булып урынлашканнар» [6: 82].

Бу берәмлекләр мәктәптә татар телен өйрәтү программаларында өйрәнүгә тәкъдим ителми [3; 4]. Безнең күзәтүләребез шуны күрсәтте: дәреслекләрдәге нумератив сүзләрнең бирелеше буенча материал төрлелеге белән аерылып тора [5; 7; 8]. Монда ниндидер система, принцип юк, хәтта материалның кайсыберләрен фактик хата итеп тә билгеләргә мөмкин (километр – чакрым һ. б.). Биремнәр дә укучыларның яшь үзенчәлекләренә, белем дәрәҗәсенә тәңгәл килеп бетми, нумератив сүзләр әле искергән сүзләр, әле интернациональ сүзләр, әле синонимнар буларак тәкъдим ителә. Шул ук вакытта аларның кайсылары исем сүз төркеме итеп билгеләнә (*баш, төп, кәтүк, тартма* һ. б.). Шуны да ассызыклап үтәргә кирәк, бу сүзләр рус телендә кулланылыш белән чагыштырма рәвештә тәкъдим ителергә тиеш, чөнки аларның арасында эквивалентсызлары (*ике кадак май, ике төп чия* һ. б.), милли-мәдәни мәгънә кырлары туры

килмәгәннәре (*ике баш корт* һ. б.), эмоциональ экспрессив мәгънәне белдерүчеләре дә бар (*бер телем икмәк* һ. б.)

*Штук* яки *данә* мәгънәсендәге рус телендәге кулланылыштан аерылып торган, татар телендә иң актив кулланылган сан ачыклагычы – «*баш*». Монда маллар һәм үсемлек исәпләгәндә рус теле белән тәңгәллек күзәтелә (өч *баш* сыер, сарык, суган, сарымсак, кәбестә / три *головы* коровы, овцы, лука, чеснока, әмма три *кочана* капусты), һәм татарда биш *баш* умарта булса, руста – пять *семей* ульев. Шулай ук түгәрәк формага салынган корт та (корот, эремчек) «баш» сан ачыклагычы белән исәпләнергә мөмкин: ике *баш* корт.

*Штук / данә* мәгънәсендәге «*бөртек»* сан ачыклагычының вак, бәләкәй, аз сандагы әйберләрне исәпләүдә актив кулланылуын билгеләргә була: *ике бөртек ярма, ике бөртек бала, ике бөртек чәч, ике бөртек алма.*

Нинди дә булса ризыктан яссы итеп киселгән өлешне белдерү өчен кулланылган «*телем»* сүзе гадәттә аз сандагы өлешне белдерә һәм бер саны ачыклагычы булганда экспрессив мәгънәгә ия:

*Бер телем* икмәкне икегә
Бүлешер дусларың булсын ул.
Кайгылар-шатлыклар килгәндә,
Үз иткән чын дуслар булсын ул.

(«Дусларга». Г. Шакирова сүзләре, И. Гильманшин көе)

Ике яки парлы әйберләрне белдерүдә татар телендә төрлелек күзәтелә: *куш кулы белән исәнләшү, куш учлап бирү, куш каен үсә; бер көянтә су; бер кием итек, ике кием себерке; ике пар бияләй, пар чиләкләр.* Татар теленең этимологик сүзлегендә «куш тамыры төрки телләрдә иң продуктивларның берсе: ул кушма сүзләр ясалуда киң кулланыла (*кушаяк, кушбаш, кушбугаз, кушбуын, кушканат, кушколак, кушкөбәк, кушарлык, куштояк, кушуч, кушъяулык*» дип билгеләнә [1: 478].

*Курыкканга куш күренә, тора-бара буш күренә* кебек әйтемне әдәби әсәрләрдә дә, публицистик мәкаләләрдә дә еш очрый. Башлангыч сыйныфларда уен яки физминутка үткәрү өчен түбәндәге шигъри юлларны тәкъдим итеп, күрсәтеп, татар халкында, мөселманнарда куш куллап исәнләшү гадәтен аңлатырга мөмкин:

Менә сиңа уң кулым,
Менә сиңа сул кулым,
Уң кулым, сул кулым,
Менә сиңа *куш кулым*.

Шулай ук Илдус Гыйләҗевнең «Күрешәм ике куллап» дип аталган шигырен дә өйрәнү урынлы булыр:

Кинә саклый торган халыклар бар,
Тарих белә андый хәлләрне.
Уң кулын ул суза күрешергә,
Сул кулында тота хәнҗәрен.
Бабаларым күрше-күлән белән
Соңгы *кабымлыгын* бүлешкән.

Шикләнергә урын калдырмаган,
Ике кулы белән көрешкән.
Бар дөньяга үрнәк ул гадәтне
Һичвакытта ташлау килешмәс.
Эчкерсезлек нуры сибеп яшәр,
*Сыңар* куллап татар көрешмәс...
Көрешмәс!

Монда автор тарафыннан лингвокультурологик берәмлек итеп билгеләнердәй *«кабымлык», «сыңар»* кебек нумератив сүзләр дә кулланылган. *Бер кабым икмәк, бер кабарлык аш калган* кебек синтаксик төзелмәләр «аз гына» мәгънәсеннән тыш сөйләмгә экспрессив мәгънә төсмере бирәләр. *Куш куллап* һәм *сыңар куллап* берәмлекләрен антонимик мәгънәдәге нумеративлар дип билгеләргә кирәк.

Халыкара классификаторлардан тыш (метр, километр, гектар), рус һәм татар телләрендә озынлык яки мәйдан күләме мәгънәсен белдерә торган уртак, эквивалентлы нумератив сүзләр шактый: *аршын / аршин, сажин / сажень, чакырым / верста*. Шул ук вакытта татар әдәби телендә һәм халык сөйләшләрендә кулланыла торган милли-мәдәни яссылыкта игътибарга лаек булган нумератив сүзләрне билгеләргә кирәк. Мәсәлән, *«илле»* – «6 арпа киңлегенә яки якынча 18 мм туры килгән, бармак киңлегенә тигез озынлыктагы борынгы үлчәү берәмлеге» [9: 181]; *«алым»* – «кыр эшләрендә: бер буйның башыннан алып ахырына кадәр бер яки берничә кеше бергәләп эшкәртә торган кишәрлек» [9: 39]; *«кишәрлек»* – «1) эшкәртү (сөрү, чәчү, уру, утау, чабу һ. б.ш.) өчен бүлеп алынган җир мәйданчыгы; 2) кыр эшләре эшләгәндә, бер кеше алып барырга тиешле җир участогы; алын; 3) ниндидер максат (төзелеш, хуҗалык алып бару һ. б.ш.) өчен билгеләнгән җир мәйданы» [9: 260].

Татар һәм рус телләрендә актив кулланылышта булган *чирек / четверть* сүзенең Башкортстан Республикасы Миякә районы халкында таралган «3 литрлы банка» күләмен белдерү мәгънәсе бар*: Өч чирек бал сатып алдым*. Гомумән, диалектларда, сөйләшләрдә таралган нумератив сүзләрне барлау кирәклеге дә ачык.

Безнең күзәтүләр буенча, милли-мәдәни мәгънәгә ия булган сан ачыклагычлары – гади, көнкүреш сөйләмдә, халык иҗатында, әдәби әсәрләрдә геройның социаль статусын тасвирлауда кулланылган берәмлекләр. Аларны аңлау һәм сөйләмдә файдалану яшь буынга телебезнең байлыгын, халкыбызның акылын, дөньяны танып белүен, җор теллелеген аңларга, белергә ярдәм итәчәк.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I т. (А–Л). Казан: Мәгариф-Вакыт. 2015. 543 с.

2. *Жеребило Т.В.* Словарь лингвистических терминов: Изд. 5-е, испр-е и дополн. Назрань: Изд-во «Пилигрим». 2010. 486 с.

3. Примерная рабочая программа учебного предмета «Родной (татарский) язык» для 1–4 классов начального общего образования / разработчики: М.М. Шакурова, Л.М. Гиниятуллина // Одобрена решением федерального учебно-методического объединения по общему образованию (Протокол № 3/22 от 23.06.2022). Казань, 2022. URL: https://fgosreestr.ru/oop?sub=2&page=4 (дата обращения: 25.03.2025)

4. Примерная рабочая программа учебного предмета «Родной (татарский) язык» для 5–9 классов основного общего образования / разработчики: М.М. Шакурова, Л.М. Гиниятуллина; одобрена решением федерального учебно-методического объединения по общему образованию (Протокол № 3/22 от 23.06.2022). Казань, 2022. URL: https://fgosreestr.ru/oop?sub=2&page=4 (дата обращения: 25.03.2025).

5. *Сәгъдиева Р.К.* Татар теле. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 6 нчы с-ф / Р.К. Сәгъдиева, Р.М. Гарәпшина, Г.И. Хәйруллина. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2017. 191 б.

6. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. Тулыл. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 432 б.

7. Татар теле. 6 нчы сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Ф.Ю. Юсупов, Ч.М. Харисова, Р.Р. Сәйфетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. 175 б.

8. Татар теле: 3 нче сыйныф. Башкортстан Республикасында укыту рус телендә алып барылган гомуми белем бирү оешмаларында татар телен өйрәнү өчен уку кулланмасы / [Н.Ә. Мөкимова, В.Ә. Садыйкова, И.Р. Сәмигуллина, Р.В. Раянова, Р.Т. Галиева]. Уфа: Китап, 2021. 168 б.

9. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты. 2005. 848 б.

УДК 398

# ТАТАРСКИЙ ФОЛЬКЛОР НА СТРАНИЦАХ КАЛЕНДАРЯ К. НАСЫРИ: БАИТ «ИСТОРИЯ КАЗАНИ»

***Л.Х. Мухаметзянова***

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ*
*по Постановлению Кабинета Министров РТ*
*№ от ... ... .2025.*

Основным объектом исследования в данной статье выступает текст «Истории Казани», опубликованный в 1880 году на страницах Календаря, изданного Каюмом Насыри. Дошедший до наших дней в результате деятельности ученого-просветителя в конце XIX века поэтический текст автором статьи подвергается научному анализу. В исследовании подчеркивается, что данный фольклорный текст в жанре баит создан в духе широко распространенных у татар и других тюркских народов историко-героических дастанов о Чура-батыре; проводятся параллели между отраженным в баите образом Чура-батыра и героем тюркского эпоса периода Казанского ханства Чура Нарыком; также отмечается большое сходство между историческими событиями, описанными в «Истории Казани» и тюркских дастанах. Особое внимание автор обращает на поэтику баита. В исследовании дается высокая оценка деятельности Каюма Насыри в деле возвращения народу его ценного фольклорного памятника, выявляется историческая, литературно-культурная значимость текста.

**Ключевые слова:** фольклорный текст, Календарь, образ Чура-батыра, история Казанского ханства, эпическое творчество.

The main object of research in this article is the text of the «History of Kazan», published in 1880 on the pages of the Calendar published by Kayum Nasyri. The poetic text, which has come down to our days as a result of the work of a scientist and educator at the end of the 19th century, is being scientifically analyzed by the author of the article. The study emphasizes that this folklore text in the bait genre was created in the spirit of the historical and heroic dastans about Chura Batyr widely spread among the Tatars and other Turkic peoples; parallels are drawn between the image of Chura Batyr reflected in the bait and the hero of the Turkic epic of the period of the Kazan Khanate Chura Naryk; great similarities are also noted between historical events, described in the «History of Kazan» and the Turkic dastans. The author pays special attention to the poetics of bait. The study highly evaluates the activities of Kayum Nasyri in returning his valuable folklore monument to the people, and reveals the historical, literary and cultural significance of the text.

**Keywords:** folklore text, Calendar, image of Chura-batyr, history of the Kazan Khanate, epic creativity.

# КАЮМ НАСЫЙРИ КАЛЕНДАРЕНДА ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ ҮРНӘКЛӘРЕ: «КАЗАН ТАРИХЫ» БӘЕТЕ

***Л.Х. Мөхәммәтҗанова***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

Танылган татар мәгърифәтчесе, тарихчы, тәрҗемәче, язучы, фольклорчы Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров (Каюм Насыйри, 1825–1902) татар халкын төрле гыйлем нигезләре белән иң беренче таныштырган кеше буларак мәгълүм. К. Насыйри гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләрен, шул исәптән, фольклористиканы үстерүгә үзеннән зур өлеш кертнән. Билгеле булганча, ул 1871–1897 елларда (1886, 1887, 1895 елларда туктатылып тора) «Казан календаре»н төзеп бастыра. Анда, календарьларга хас мәгълүматтан тыш, күп кенә фәнни һәм әдәби материаллар белән бергә татар фольклорына да зур урын бирелә.

1880 елда «Казан календаре»нда К. Насыйри татар тарихында беренче тапкыр «Казан бәете»н бастырып чыгара [2]. Текст халык иҗаты фәнендә «Казан тарихы», «Казан алыну бәете», «Казан алыну турында тарихи җыр» исемнәре белән дә билгеле. Әлеге фольклор ядкяре 1899 елда татар һәм рус телләрендә «Казанская история. Песня о взятии Казани русскими» («Казан тарихы. Урысларның Казанны алуы турында җыр») дигән исемнәр белән Н.Ф. Катановның «Исторические песни казанских татар» исемле китабында да дөнья күрә [4: 5–22]. 1911 елда ул шулай ук «Шура» журналында басылып чыга [3: 525–526]. Безнең чорда бу текст «Татар халык иҗаты» академик басмасының «Бәетләр» томына кертелгән [7: 2], әмма биредә текст кыскартылган формада урын ала, дастанар белән аваздаш Чура турындагы өлеше исә бөтенләй төшереп калдырылган.

Традицион төрки дастаннарның барысы өчен уртак тарихи Чура батыр образының татар халкының бәет жанрында да чагылыш тапкан булуына күзәтү ясау бүгенге көндә гаять кызыклы һәм актуаль. Чура батыр исеме белән бәйле истәлекләр тарихи хәтер буларак безнең көннәргә килеп җитә

алган сирәк фольклор үрнәкләреннән санала. К. Насыйри Календаренда басылган, заманында күренекле галим Н.Ф. Катановның югары бәясен алган текст – Казан ханлыгы чорына караган «Чура батыр» дастаннарына бик якын торуы белән кыйммәтле ядкяр. «Казан тарихы»ның К. Насыйри Календарена нинди чыганактан алынганлыгы билгесез, хәлбуки аны бүген иң беренче дөнья күргән тулы нөсхә буларак танныйбыз. Тикшеренү алып бару өчен К. Насыйри төзеп бастырган Календарьдагы текст текстологик эшкәртелде, алга таба мәкаләдә китерелгән барлык мисаллар әлеге чыганактан [2] алып бирелә.

Заманында Алтын Урда составына кергән төркиләрдән казан, кырым татарлары, нугай, казакъ, кыргыз, башкорт халыкларының эпик иҗатында Чура образы бик популяр. Чура батырга багышланган эпос-дастаннарның һәркайсы тарихта билгеле вакыйганы – Казан алынуны бәян итә. Татар фольклорында исә Чура образы берничә эпик жанрда гәүдәләнгән. Башка төрки халыклар эпосы белән аваздаш күләмле дастан һәм аның вариантлары, тарихи бәет һәм риваятьләр – һәммәсе бу образны халык каһарманы буларак тасвирлый.

Күләме, мотивларының тулылыгы-кимлеге, башкарылу һәм таралу формалары һ. б. яклардан бер-берсеннән аерылып торган төрки дастаннарны һичшиксез берләштерә торган билге – версия-вариантларның сюжеты. Аларның барысын гомумиләштереп бер цикл итеп караганда, Чурага багышланган төрки эпоста төп дүрт зур өлеш аерылып чыга: 1 – Нарәң (Нарык, Наррәң, Нәрек) батырның тормыш көнкүреше; 2 – Чура батырның тууы һәм аның батыр балачагы; 3 – Чура Нарыкның Казан белән бәйле эш-гамәлләре; 4 – Казанның, Хаҗитарханның (Әстерхан) урыслар тарафыннан яулануы турында хәбәр. Дастаннар сюжетында батыр һәм ил язмышы бергә үрелә, Чура тормышындагы трагик вакыйгалар Казан ханлыгының 1552 елгы фаҗигасына барып тоташа. Шуңа күрә бу эпик әсәрнең темасы Чура батыр турында дип тә, Казан ханлыгы җимерелү хакында дип тә билгеләнә [1: 53–57]. «Чура батыр» исеме белән билгеле дастаннарда тасвирланган вакыйгаларның чынбарлыкта булган хәлләргә барып тоташуы, халыкның моңа саллы җавабы рәвешендә, татарларда Чура образының төрле эпик жанрларда эзлекле яктыртылышын һәм популярлашуын тәэмин иткән.

К. Насыйри Календаренда дөнья күргән «Казан тарихы» бәете Чура батырга багышланган төрки халык дастаннары циклында әһәмиятле урын алып тора. Төрки версия сюжетларына гомумән хас булган дүрт зур өлешнең соңгы икесенә – Чура батырның Казан белән бәйле эш-гамәлләре һәм Казанның рус дәүләте тарафыннан яулап алынуы турындагы хәбәрләргә ия булуы дастан жанры чикләреннән чыгып, халык иҗатының башка жанрында үсеш алган һәм таралган «Казан тарихы» бәетен Чурага бәйле эпик иҗат кысаларында карау мөмкинлеген бирә. Календарьда 1880 елда дөнья күргән әлеге фольклор ядкяре Казан ханлыгы алынуга кагылышлы вакыйгаларны яктырта, алай гына да түгел, Чурага багышланган дастаннар циклына өр-яңа мәгълүматлар да өсти.

Бәеттә татар халкының Болгар чорыннан алып Казан алыну вакыйгаларынача тарихы кыскача яктыртылган. «Шура» журналында басылган нөсхәсендә текстны урнаштыручы тарафыннан: «Йыруны (җыру, җыр,

ягъни бәет) Катанов җәнаблары Габделкаюм Насыйри әфәндедән алмыштыр. «Казан бәете»ндә Чура исемле бер батырның исеме зикер ителмештер. Бу кеше үзенең батырлыгы аркасында Казан татарлары вә казакълар арасында ат казанган тарихи бер заттыр», – дигән мәгълүмат китерелә [3: 525].

Текстта иң элек Аксак Тимернең Габдулла хан кулыннан Болгар шәһәрен алуы турында сөйләнә. Шуннан сүз Казан ханлыгына күчә. Биредә бәет сюжетының халык риваятьләрендә сөйләнгән вакыйгалар белән дә гаять дәрәҗәдә аваздаш булуын әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән, нәкъ шушы сюжетка нигезләнгән, Казан салынуга багышланган тарихи риваять мәгълүм [8: 51–53].

Бәет эчтәлегенә кайтсак, 262 ел буе Казанның мөселманнар кулында булып, аннары руслар тарафыннан яулануын хәбәр иткәч, әсәр Казан алынганчы андагы тормыш-көнкүрешне тасвирлый. Тасвир ханнар идарә иткән чорга мөнәсәбәттә хронологик төстә бара.

Газыйлары (*дошман белән сугышучылары*) күп иде, муллалары күп иде,
Галимнәре күп иде заман Ядкарь (*Казанның соңгы ханы*) ирдия
Бу җиһан мөнәүвар (*якты, нурлы*) иде, җәбер вә җәфа юк иде,
Мөрид (*шәкерт*) – мөршид(*туры юл күрсәтүче*) күп иде,
заманы хуп ирдия.

Ядкарь хан бәеттә күккә чөеп мактала. Казан шәһәре урыслар тарафыннан яуланган чорда Касыйм хан углы Ядкарьнең хан булып утыруы мәгълүм. Ул Казанда озак патшалык итмәгән (1552 елның марты – 1552 елның октябре), шулай ук тарихта җитди эз калдырмаган дип санала. Тарихи чыганакларга нигезләнгән фәнни тикшеренүләр күрсәтүенчә [5: 212–228], Иван IV Казанны алган вакытта Ядкарь хан урысларга әсир төшә, үлгән елы билгесез, әмма 1553 елда ул әле исән була. Бәеттә исә Ядкарь ханның «тугыз йөз илле җидедә» дөньядан китүе әйтелә. (Милади белән 1550 елга туры килә). Тарихи вакыйгаларның бу рәвешле фольклорда буталып бирелүе – гадәти хәл. Хронологик тәртипләрне төгәллек белән үтәү, даталарны дөрес бирү халык иҗаты әсәрләренең вазыйфасына кереп бетмәскә дә мөмкин.

Алга таба әсәр Ядкарьнең бик булдыклы бер кызы калуын хәбәр итә. Имеш, атасы аны тәхет варисы итеп калдырган. Әмма атасы үлеп киткәч, ни сәбәпледер, кыз үзен-үзе үтерә. Бәет жанрына игътибарны аянычлы вакыйгаларга күбрәк бирү хас, әлеге мотив әсәргә шушы максатлардан кертелгән булыргамөмкин. Әмма Казан ханының кызы турындагы сюжетка мөрәҗәгать итү ягыннан татар бәете һәм Чура батыр турындагы дастаннарның кисешүен искәртеп үтәргә кирәк. Хан кызы – халык иҗатында популяр, бер жанрдан икенчесенә күчеп яшәүче уртак образ. Шаһгали хан образы бәеттә Шагали дип бирелә:

Нәселендә бер ир бар ирде, исеме аның Шагали
Шифаларга яр ирде, тоткын булмыш ирдия.
Дөнья дигән сарайга җәбер-җафа салдыя.

Бәеттә Казанның урыслар тарафыннан яулануында Шагали гаепләнә, аңа тискәре бәя бирелә. Монда тарихи шәхес Шаһгали ханга гади

халыкның мөнәсәбәте чагылган. Бу урында да ханнарның хронологик тәртибе бераз үзгәртеп бирелгән. Шаһгалинең Казан тәхетендә соңгы тапкыр 1551–1552 елларда, ә Ядкарьнең аннан соң утыруы мәгълүм. Чорның гомуми атмосферасы исә бәеттә дөрес чагылыш тапкан. Монда Казан белән Мәскәү арасында XVI йөз урталарына таба даими булып торган орыш-көрәш картинасын күрергә мөмкин.

Урыслар хәбәрдар ые, мөселманнар бихәбәр ие,
Шәһри Казан җанында орыш-тукыш булдыя.
Ул орыштан булмады, Казан шәһәрен алмады
Ошбу Зөя тавында урыс кала салдыя.

Мөселманнарның Иван IV кылган бу гамәл белән килешмичә, ризасызлык белдереп, урыслар белән сугыша башлавы турында бәетнең алдагы 2 юлы хәбәр итә. Аннан соң текстка Чура батыр исеме килеп керә:

Бар иде бер мәрди (*биредә*: *батыр, кыю*) Хода, исеме аның Чура
Күп урысны кырырга Ходай мәдәд (*ярдәм, булышлык*) бирде йа.

Чура, татар халык иҗатының барлык жанрына хас булганча, ханлыкта атаклы пәһлеван, азатлык өчен көрәшкә күтәрелгән шәхес итеп бирелә. Ул – Казан халкы өчен бердәнбер өмет, шуңа да авыр минутта халык аңа мөрәҗәгать итә:

Диделәр аңар, җә, Чура, булырсың мәрди Хода,
Аллаһның хөкеменә нидер чара? Ибан урысны син тура.

Бу урында бәет дастан жанры хасиятләренә бик нык якыная кебек. Аларның һәр икесендә дә Чура –курку белмәс батыр. Чура образы бәеткә иң киеренке урында килеп керә, аның эш-гамәлләренә дә киң урын бирелә. Дастандагы кебек үк, бәеттә Чура батыр идеаллаштырылган, хәтта Аллаһ бәндәсе итеп күрсәтелгән. Бәет герое дастаннар каһарманы рухына шактый якын тора, хәтта мәгълүм Чура образын тулыландыра. Дини-героик дастаннардагы кебек, биредә Чура батырга дини миссия дә йөкләтелгән. Аны ислам идеяләре белән сугарылганлыгы һәм чорына хас милли-дини азатлык көрәшчесе буларак яңартылганлыгы күпмедер дәрәҗәдә үзенчәлекле итә. Эпоста каһарман илен-җирен дошман явыннан саклап яуга күтәрелсә, биредә ислам дине йогынтысы үзен аеруча нык сиздерә. Татар халык версиясендә Чура Казанга, «Күк чобарына атланып», «урыс гаскәрен куалап», «Күк чыбыгы кара канга батканчы», «Шагали ханның йорты өчен, Сарыканиның күңеле өчен» батырлык кылу нияте белән бергә, ислам җиңүе өчен көрәшергә, «Ак мәсҗедләр салдырырга, Аллаһулап азан әйттерергә» дип тә бара [1: 158]. Дастанда ислам идеяләре төрки эпосы кануннары белән аралашкан булса, бәеттә эпик каһарманлыкның (эпик героика) дини героика белән алмашынуын күрәбез.

Тарихта Казан алынганда Чура Нарыков үтерелгән була [5: 226–227]. Бәеттә тарихи факт исәпкә алынмаган: Чурарус патшасына килеп, аның чатырына үтеп керә, патшаның башын чабып өзә. Бу вакытта дошман патшасы ашап утыра торган була, өзелгән башы ашына килеп төшә:

Акылы җуктыр башында, күп халкы бар кашында
Ник боермады бер башына: ыстрог торың каршымда *(ягъни: сакта тор)*.

А.С. Орлов «Казахский героический эпос» дигән хезмәтендә татар һәм казакъ халкында сакланган 12 строфалы җыруны телгә алып үтә [6: 112]. Бу әсәрдә Аллаһ рәхмәте белән рус гаскәрен кырып, Казанга кергән Чура батыр турында сөйләнә. Халык аннан рус Иванны үтерүен сорый. Чура, Иван кичке ашын ашап утырган җиргә килеп, аның башын чабып өзә. Хезмәтчеләре Иван патшаның өзелгән башын аш тәлинкәсендә табалар. Бу урында әлеге җырның татар халык бәетендә сөйләнгән сюжет белән охшашлыгы күренә.

Бәет – татар халык иҗатының трагик жанры. Иван IV нең Чура тарафыннан үтерелүе бу очракта трагедия булып санала алмый. Ә инде Чура батырның үлеме турында «Казан тарихы» берни дә сөйләми. Чураның батырлыгын, урыс патшасының үлемен тасвир иткәннән соң әсәр Казанны рус явы басып алу вакыйгасына күчә. Биредә иң аянычлы хәл дә әнә шул – Казанның алынуы. Чынлыкта нәкъ менә шушы вакыйга әсәрне бәет жанрына нисбәт итә дә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Чура батыр образының бәет һәм дастан жанрындагы уртаклыгы ил белән кемнәр генә идарә итмәсен, халык арасында Чура кебек каһарманнар булган, дигән идеядә; чит ил баскынчыларына каршы чыккан шәхесләрнең халык тарафыннан хуплануында; вакыйгалар һәм тарихта булган шәхесләр уртаклыгында (Казанның руслар тарафыннан алынуы, Казан ханлыгында яшәгән сәяси эшлекле Чура Нарыков, Казан ханнары, рус патшасы һ. б.) һәм татар эпик фольклорына ислам идеясенең эзлекле үтеп кергән булуында чагылыш тапкан. Милли-азатлык каһарманын халык үзенең шигъри иҗатында горур чагылдырган. Бәетнең тарихи хәтерне безнең көннәргә җиткерүдә, шулай ук әдәби-мәдәни, иҗтимагый әһәмияте чиксез зур. XIX йөз ахырында Каюм Насыйри тарафыннан язмага теркәлгән әлеге фольклор ядкяре рухи мирасыбызны баета, милли тарихыбызны тергезүгә зур йогынты ясый.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Ибраһимова Л.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. 190 б.
2. Казан тарихы // Насыйри К. Календарь 1881 елга. Казан, 1880.
3. Казан татарларының тарихи җырлары // Шура. 1911. № 17. Б. 525–526.
4. Казанская история // Катанов Ф. Исторические песни Казанских татар. Текст, транскр. и пер. Казань: Типо-лит. Имп. ун-та, 1899. С. 5–22.
5. *Мухаметзянова Л.Х.* Чура Нарыков – политический деятель Казанского ханства // Золотоордынское обозрение. 2022. Т. 10. № 1. С. 212–228.
6. *Орлов А.С.* Казахский героический эпос. М.: Изд-во АН СССР, 1945. 148 с.
7. Татар халык иҗаты. Бәетләр / томны төз.: Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова; кереш мәкалә авт.: Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, Р.Ф. Ягъфәров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 352 б.
8. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төз., кереш мәкалә һәм иск. язучы С.М. Гыйләҗетдинов. Казан, 1987. 368 б.

УДК 81’373.2

# ЛИНГВОКУЛЬТУРНЫЕ КОДЫ В ИНДИВИДУАЛЬНО-АВТОРСКОЙ КАРТИНЕ МИРА Г. ГАЛЛЯМОВОЙ

***Г.Р. Насибуллова***
*Казанский федеральный университет (Казань)*

В данной работе исследуется проявление кодов лингвокультуры в современной татарской прозе на материале творчества Гузель Галлямовой. Объектом исследования являются коды лингвокультуры в авторской картине мира Г. Галлямовой, предметом исследования – концептуальные метафоры и сравнения в ее произведениях. Материалом исследования прослужила дилогия «Колокольчики» и «Возвращение», в которой описывается судьба женщины. При помощи семиотического, интерпретативного, концептуального и описательного методов анализируются активные коды культуры в индивидуально-авторской картины мира Г. Галлямовой. Выявлено, что автор обращается к широкому спектру кодов лингвокультуры для описания внутреннего мира своих героинь, среди которых преобладают антропоморфные, растительные и зооморфные.
**Ключевые слова:** индивидуально-авторская картина мира, код лингвокультуры, художественный дискурс, современная проза, концептуальная метафора.

This paper is devoted to examine the manifestation of linguistic culture codes in modern Tatar prose based on the creative work of Guzel Gallyamova. The object of research in this article is the codes of linguistic culture in the author’s worldview of G. Gallyamova, the subject of research is conceptual metaphors and comparisons in her works. The material of the study was the dilogy «Bells» and «Return», which describes the fate of a woman. With the help of interpretive, conceptual and descriptive methods, the active codes of culture in the individual author’s worldview of G. Gallyamova are analyzed. It is revealed that the author refers to a wide range of linguistic cultural codes to describe the inner world of his heroines, among which anthropomorphic, vegetative and zoomorphic predominate.
**Keywords:** individual-author’s worldview, code of linguistic culture, artistic discourse, modern prose, conceptual metaphor.

Семиотический подход к исследованию языка позволяет нам глубоко погрузиться в изучение сложных взаимосвязей между знаками и их значениями, выходя за рамки простого лексического анализа и раскрывая глубинные смыслы, заложенные в культурных феноменах. Культура, с точки зрения семиотики, предстает перед нами не как хаотичное скопление обычаев и традиций, а как тщательно структурированная система знаков, состоящая из множества переплетающихся кодов. Эти коды – своего рода ключи к пониманию культурного контекста – невероятно разнообразны и многогранны. Например, предметный, антропоморфный, пространственный, временной, соматический, растительный, зооморфный, гастрономический и т. д. [1].

Культурные коды представляют собой «вторичные знаковые системы», которые, используя различные средства кодирования, в конечном итоге сводятся к картине мира, свойственной данной культуре. Эта картина мира не является объективной реальностью, а представляет собой своеобразную интерпретацию мира, опосредованную культурными кодами.

Понимание культурных кодов невозможно без учёта исторического, социального и географического контекста. Именно поэтому изучение культурных кодов является необходимым условием для глубокого понимания любой культуры, её ценностей и мировоззрения. Анализ культурных кодов позволяет преодолеть языковой барьер, понять невербальные средства общения и погрузиться в мировосприятие других культурных групп, что особенно актуально в современном глобализированном мире. «Коды культуры – это специфический для каждой культуры набор способов социальной практики, свод ценностей и правил игры коллективного существования, выработанная людьми система нормативных и оценочных критериев, сквозь которые народ постигает мир. Это совокупность реалий, выражающих определенные культурные смыслы и ценности» [2: 3]. Изучение кодов лингвокультуры как в национальной, так и в авторских картинах мира представляется перспективным направлением в современной лингвистике. Коды лингвокультуры в национальной картине мира активно исследуются рядом ученых [5–12], однако работ, посвященных изучению лингвокультурных кодов в авторской картине мира современных татарских поэтов и писателей, практически не представлено.

Данное исследование направлено на выявление активных кодов лингвокультуры в современной татарской прозе на материале творчества Гузель Галлямовой. Объектом исследования являются коды лингвокультуры в авторской картине мира Г. Галлямовой, предметом исследования – концептуальные метафоры и сравнения в ее произведениях. Изучено проявление кодов лингвокультуры в дилогии «Колокольчики» [3] и «Возвращение» [4] при помощи интерпретативного, концептуального и описательного методов. Гузель Галлямова – популярная современная татарская писательница, которая в своих произведениях описывает сокровенные переживания женской души.

В художественном дискурсе Г. Галлямовой коды лингвокультуры можно разделить на коды живой и неживой природы. Разнообразной и разноплановой в романах Г. Галлямовой является группа кодов лингвокультуры неживой природы. Например, «Зөлхәбирәнең яшьлеге таң кебек тыйнак кына чәчәк атты да, саф сөюне тоеп кояш кебек күңел түренә күтәрелде» [3: 17]. Здесь автор сравнивает молодость зарей, солнцем. Заря выражает начало, зарождение молодости героини. «Кояш күтәрелү» – это середина дня, когда солнце освещает все пространство. Молодость героини обретает такую силу из-за любви. Также в этом примере мы видим растительный код лингвокультуры – «чәчәк атты» / расцвел, который экспелицирует молодость; пространственный код культуры выражается в описании внутреннего мира как вместилища – «күңел түре». «Түр» в татарской культуре означает передний угол, почетное место. Таким образом, автор выделяет молодости почетное место.

Рассмотрим еще один интересный пример, где мы видим переплетение различных кодов лингвокультуры: «Кайда гына булса да, айлы кичләр кебек серле итеп, үзенә ымсындырды. Һәм гел шулай күңел җылытасы мәхәббәт, көзге пыскак яңгырлы көннең кояшы сыман, кара болытлар артына посты» [4: 27]. Любовь у Г. Галлямовой наделяется признаками луны, солнца, дождя.

Из стихийных кодов лингвокультуры Г. Галлямова отдает предпочтение огню: «күзләрен очкынландырып», «олы тормышның үзенә беренче учакны ягарга ашыга», «йөзләрендә туктаусыз учак ялкыны уйный», «күңелендә ут кызулыгы бар», «утлы адым», «янып торган күзләр». Огонь выступает как часть природно-стихийного кода культуры, содержит дополнительные культуроносные смыслы и выполняет эталонную и/или символьную функции. В рассматриваемом материале огонь ассоциируется двумя сферами: горе и радость, возрождение и исчезновение. Если горячие глаза, искорка в глазах героини выражают счастье, то огонь в душе – это безысходность, горечь потери кого-то очень близкого. В разных лингвокультурах огонь можно рассматривать как способ обновления и появления новых возможностей или начинаний в жизни, в индивидуально-авторской картине мира Г. Галлямовой огонь является причиной утраты надежды, мечты: «матур хыяллар янып чыкты».

Группу кодов живой природы представляют растительный и зооморфные коды. Герои Г. Галлямовой являются в тесной связи с природой. Большую часть растительных кодов представляют «колокольчики», которые выведены и в сильную позицию – в название первой части дилогии. Они ассоциировались с преданностью и первой любовью. Колокольчики ассоциируются с преданностью, первой любовью и несбыточностью надежд. Растительный мир в произведениях Г. Галлямовой служит для описания внутреннего мира человека, чувств, переживаний. Если сама калина символизирует женскую красоту, молодость и невинность, то автор обращается к кислому вкусу ягод данного кустарника для описания тяжелой судьбы, горя: «байтак кына ачы балан белән сыйладың», «язмышлар балан кебек ачы иде», «тамак төбендә балан ачысын тойды». Такие качества ивы как высота, гибкость используются для описания внешней красоты девушки: «тал чыбыгы кебек зифа буйлы кыз».

Зооморфный код лингвокультуры представлен образом птицей. Концептуальной метафорой вольнолюбивой птицы передается значение желания нового, стремление в будущее: «Суфияның күңеле канатлы – очыпмы оча». Храбрые, сильные мужчины ассоциируются соколом, а предатели стервятником: «минем өчен гап-гади козгын син».

Одним из самых широко представленных в анализируемом материале выступает антропоморфный код лингвокультуры. Автором персонифицируются природа в целом, деревья (калина), эмоции и чувства (печаль, сожаление, мысль, радость), гора, душа. Авторские концептуальные метафоры основаны на следующих признаках: «сон» (Табигатьнең кышкы йокыдан уянуы), «возраст» (ул күпне күргән Баланлы тауның барлык сагышын), «объятия» (тирәкләрнең шомлы шавы кочагында), «эмоции» (бу хәсрәттән Баланлы тау сабырлыгы кирәк), «движение» (йөзеннән елмаю китмәде).

Значительное место в художественном дискурсе Г. Галлямовой занимает «сагыш» / «печаль»: этим признаком наделяются природные явления, существа, внутренний мир героини: «сагышлы җил», «йөрәген сагыш биләп алды», «күңеленә сагыш тулды».

Пространственный лингвокультурный код выражается признаком вместилища, внутренний мир героини описывается местом, а чувства – предметы, которые находятся в нем: «башы тулы әнә шундый уйлар»,

«күңеленә нindidер моңарчы татымаган уй-хис керде һәм бөтен күңелен яулый бара». Внутреннему мира характерна глубина: «хәтер төпкелендә озаграк актарынырга туры килде».

Временной код лингвокультуры реализуется в двух оппозициях: молодость и старость: «яшьлек аланы», «яшьлек таңы», «Баланлы тавы – тоташ яшеллек, яшьлек», «түбәсендәге аксыл ташлар гына тауның карт булуын аңлата».

Соматический код лингвокультуры по сравнению с остальными менее представлен. Автор реализует расстояние при помощи руки и глаз: «кул сузымы ара калган», «күз уңында булган тауга»; слеза реализует чистоту и невинность: «саф күз яшедәй чиста сулы инеш ага», черный цвет актуализируется при помощи глазных зрачков: «күз карасы сыман, гел кара булып, авылдан ук күренеп тора».

Базируясь на проеведенный анализ, можем сказать, что в индивидуально-авторской картине мира Г. Галлямовой в основном актуализируются антропоморфные, растительные и стихийные коды лингвокультуры. Все они направлены на описание внутреннего мира, душевных переживаний героини. Некоторые коды несут оппозиционные характертистики. Например, «огонь» как стихийный код лингвокультуры в произведениях актуализирует зарождение и исчезнование.

## СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ


1. Большой фразеологический словарь русского языка. Значение. Употребление. Культурологический комментарий / отв. ред. В.Н. Телия. М.: АСТ-пресс, 2006.

2. *Пименова Е.Е., Пименова М.В.* Особенности концептуализации неба и объективация его признаков в произведениях С.А. Есенина (лингвокультурологический аспект) // Полит. лингвистика. 2006. № 18. С. 180–190.

3. *Галлямова Г.* Колокольчики. Казань. 2020. 399 с.

4. *Галлямова Г.* Возвращение. Казань. 2023. 256 с.

5. *Маслова В.А., Пименова М.В.* Коды культуры в пространстве языка. СПб., 2015. 152 с.

6. *Мошина Е.А., Бакирова А.А., Бекмурзаева Ф.Ш.* Реализация антропоморфного кода в структурах ландшафтного, анималистического и космического концептов в русской лингвокультуре // Лингвокультурные аспекты концептуальных исследований: сб. науч. ст. к 70-летнему юбилею д-ра филол. наук, проф. В.А. Масловой / отв. ред. М.В. Пименова. СПб.: СПбГЭУ, 2018. С. 64–71.

7. *Башкатова Ю.А.* Соматический код в английской и русской языковой картине мира // Вестн. Кемеров. гос. ун-та. 2013. № 3-2(55). С. 90–94.

8. *Гудков Д.Б., Ковшова М.Л.* Телесный код русской культуры: материалы к словарю. М.: Гнозис, 2007. 288 с.

9. *Ковшова М.Л.* Семантика и прагматика фразеологизмов (лингвокультурологический аспект): дис. … д-ра филол. наук. М., 2009. 654 с.

10. *Ковшова М.Л.* Лингвокультурологический метод во фразеологии: Коды культуры. 3-е изд. М.: URSS, 2016. 456 с.

11. *Красных В.В.* Коды и эталоны культуры (приглашение к разговору) // Язык, сознание, коммуникация: сб. ст. / отв. ред. В.В. Красных, А.И. Изотов. М.: МАКС Пресс, 2001. Вып. 19. С. 5–19.

12. *Красных В.В.* Предметный код культуры в русском культурном пространстве // Русистика на пороге XXI в.: проблемы и перспективы: материалы междунар. науч. конф. (Москва, 8–10 июня 2002 г.) / [сост. Н.К. Онипенко]. М.: ИРЯ РАН, 2003. С. 146–148.

УДК 81.367.7

# ЛЕКСИКО-ГРАММАТИЧЕСКАЯ ТРАНСФОРМАЦИЯ ТАТАРСКИХ ПОСЛОВИЦ

***Г.А. Набиуллина***
*Казанский федеральный университет (Казань)*

В статье рассматриваются основные типы индивидуально-авторских трансформаций пословиц и поговорок в литературных текстах. Подобные трансформации осуществляются авторами с целью актуализации паремий, обеспечения их связи с конкретной ситуацией, повышения их информативности, оценочности, экспрессивности, усиления их воздействие на читателя.
**Ключевые слова:** фразеологические единицы, пословицы и поговорки, лексико-грамматические трансформации.

The article discusses the main types of individual author transformations of proverbs and sayings in literary texts. Such transformations are carried out by the authors in order to actualize paroemias, ensure their connection with a specific situation, increase their informativeness, evaluativeness, expressivity, and enhance their impact on the reader.
**Keywords:** phraseological units, proverbs and sayings, lexico-grammatical transformations.

# ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕНЕҢ ЛЕКСИК-ГРАММАТИК ТРАНСФОРМАЦИЯСЕ

***Г.Ә. Нәбиуллина***
*Казан федераль университеты (Казан)*

Мәкальләр тормышның төрле өлкәләрен чагылдырган үтемле, хикмәтле сүз буларак, прозада, поэзиядә, драматургиядә киң кулланылалар. Төрле чорларда иҗат иткән язучыларыбыз телендә, бигрәк тә Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Г. Әпсәләмов, М. Мәһдиев, Г. Бәширов, Т. Галиуллин, Н. Гыйматдинова әсәрләрендә бу тел җәүһәрләре зур урын алалар. Шулай ук поэзиядә, аерым алганда, С. Сараи, Акмулла, Г. Тукай М. Җәлил, М. Әгъләмов, Ә. Баян иҗатында да мәкальләрнең матур үрнәкләрен очратырга мөмкин. Мәкаль-әйтемнәр куллану, бер яктан, сөйләмне образлы, бизәкле, тәэсирле итсә, икенче яктан, геройларның эчке дөньясын, характерын, хис-кичерешләрен, эш-гамәлләрен тасвирлаганда да мәкальләр ярдәмгә килә.

Матур әдәбиятта мәкальләр сөйләмне сәнгатьле һәм көчле яңгырашлы, самими һәм ышандырырлык итүдә әһәмиятле чара булып торалар. Мәкаль, стилистик бизәк буларак, сөйләмнең эмоциональ-экспрессив яңгырашын көчәйтә. Авторлар, мәкальләрнең мәгънәләрен сакланган хәлдә, аларны билгеле бер стильгә һәм жанрга яраклаштырып бирәләр. Теге яки бу жанрга карап, контекстта мәкальләр җыентыкларда теркәлгән вариантта да, үзгәртелеп тә кулланылырга мөмкин. Гадәттә, чәчмә сөйләмдә мәкальләр зур үзгәрешкә тартылмый, халык телендәге формаларын саклыйлар. Поэзиядә исә мәкальләр шигырь калыбына, ритм-рифма закончалыкларына буйсынып, берникадәр үзгәртелеп кулланылалар.

Мәкальләр сөйләмгә әзер килеш килеп керәләр, яисә лексик-грамматик яктан берникадәр үзгәртелеп кулланылалар, я булмаса сөйләмдә мәкальнең идеясе генә дә файдаланылып, яңадан-яңа канатлы сүзләр, акыллы гыйбарәләр, төртмә сүзләр, афоризмнар барлыкка килә.

Мәкаль текст эчендә генә яши. Текстка килеп кергән мәкальләр, иң беренче чиратта, контекст белән мәгънәви яктан бәйләнә. Мәкальнең текстыннан аңлашыла торган хәбәр итү характеры гомуми мәгънәне белдерү өчен үзенә бер төрле җирлек кенә булып тора. Мәсәлән, ... *бала бит ул сиңа, башка балаларың кебек үк Илморза да синең йөрәгеңә якын. Баш бармагыңның кайсын киссәң дә авырта* (Г. Әпсәләмов). *Сез баш кашып торган арада, Хафиз сыпырып алып куйды шул. Таз таранганчы, уй таралыр, дигәннәр бит* (Ә. Фәйзи).

Бу мәкальләрнең хәбәр итү максаты белән генә кулланылган булулары ачык күренеп тора. Автор әйтергә теләгән фикер тел җәүһәрләре аша җиткерелгән. Бу мәкальләр тормыштан алынган бер канун булып яңгырыйлар; алар сөйләүченең фикерен дәлилләү һәм сүзне куәтләү максаты белән дидактик максаттан чыгып әйтелгәннәр.

1) Конкрет стилистик максатлардан чыгып, мәкальнең текстына гомумиләштерү яки, киресенчә, конкретлаштыру характерындагы сүзләр өстәү контекстта мәгънәнең яңгырашын көчәйтә. Мәсәлән, *Шулай, карчык, бер авызың пешкәч, суык суны да өреп кабарга кирәк* (Г. Ибраһимов); *Бәласы артыннан казасы килә* (М. Мәһдиев). Мондагы мәкальләргә өстәлгән модаль характердагы *«кирәк»* сүзе һәм *«килә»* фигыле катгыйлык төсмере өсти һәм шуның нәтиҗәсендә мәкальләр үтемлерәк яңгырыйлар.

Түбәндәге мәкальләрдә *«синнән» һәм «анадан, туганны»* сүзләре конкретлаштыру мәгънәсе бирә: *Синнән он суы да юк, тоз суы да юк димәкче буласыңмы, – диде Хәлил, шартлар дәрәҗәгә җитеп үпкәләп* (Т. Галиуллин).

Мәкаль текстында төрле ярдәмлекләр һәм модаль сүзләр кушыпкыстырып әйтү – табигый күренеш. Мәкальгә, гадәттә, көчәйтү мәгънәсендәге кисәкчәләр, модаль сүзләр өстәп әйтеләләр. Мәсәлән, *...авыру бит ул казык башында йөрми, кеше башыннан йөри* (И. Гази); *..матурлык ул туйда гына кирәк, акыл көн дә кирәк* (Г. Әпсәләмов). Биредә өстәп әйтелгән сүзләр мәкальнең яңгырашын көчәйтәләр. «Мәкаль текстына бу рәвештә көчәйтү мәгънәсендәге модаль сүзләрнең кыстырып әйтелүе – автор фикере белән мәкальдәге фикернең контекстта бер-берсе белән үрелүеннән килә» [1: 43].

2) Мәкальләр кайбер очракларда структур-грамматик яктан киңәйтеп әйтеләләр. Бу очракта аның семантикасы да үзгәрә. Мәсәлән,

*Шагъбан. Өйләрегезгә таралыгыз... Аталарыгызга кирәк булырсыз. Мәнә мин бәйрәм чәенә картлар алып кердем, Шәйхи юк. үзем чәй ясап эчердем.*

*Заһит. Бик шәп булган. Чиләгенә күрә капкачы, кунагына күрә чәй ясаучысы* (М. Фәйзи).

*– Мәхәббәт ул – тиз ватыла торган бәллүр савыт икән шул, Мисхәт. Ходай тәгалә биргән бүләкне саклый белергә кирәк. Ике көймәнең койрыгын, биш бармак белән биш чебенне тотып булмый диләр түгелме?...* (Т. Галиуллин).

Бу өзекләрдә *чиләгенә күрә капкачы*, *ике көймә койрыгын тотып булмый* мәкальләре киңәйтеп кулланылган.

Мәкальнең текстын югарыда күрсәтелгән рәвешләрдә киңәйтү бигрәк тә шигырьләрдә күзәтелә. Бу күренеш, гадәттә, тезмә сөйләм таләпләреннән чыгып эшләнә. Мәсәлән, С. Сараидан:

*Агач күрке – җимеш булса,*
*Ирнең күрке – игелек,*
*Игелексез ир бар булу –*
*Бөтенләйгә юк кебек* (С. Сараи).

3) Халык телендә куллынылган мәкальнең бер сүзе үзгәртелеп әйтелергә мөмкин. Мәсәлән, түбәндәге мисалда *Бии белмәгән аюга урын тар* мәкале үзгәртелеп кулланылган: *Биисе килмәгән аюга көе килмәгән кебек, башымны катырып утырма әле, минем белән тырт-мырт, ыкы-мыкы сөйләшүеңне ташла. Төрекләрнең яраткан сүзен куллансак, «тәмам»* (Т. Галиуллин).

Алдагы шигырь юлында *«сары»* сүзе «*саф»* сүзе белән үзгәртелгән:

*Сабыр төбе – саф алтын*
*Түзим әле,*
*Дөнья үзе*
*Бер түләр алтын хакын* (Э. Шәрифуллина)

4) Контекстта мәкаль кыскартып–җыйнакландырып әйтелергә дә мөмкин. Мәсәлән,

*Хатын-кызның акылы кыска диеп,*
*Син алдыйсың, егет, үзеңне;*
*Батырлыкка алган орденнары –*
*Сиңа алар шаһит түгелме?* (Н. Баян)

Биредә *Хатын-кызның чәче озын – акылы кыска* мәкаленең *чәче озын* төзелмәсе төшереп калдырылган.

5) Мәкальнең башы гына әйтелергә мөмкин. Мәсәлән, *Кич кайтыр алдыннан чүмәләгә җыя башлагач, уртанчы ул, хахылдап кычкырып җибәрде, ямьсез сүз катнаштырып:*

*– Мактаулы килен... – ди – дип, бавы чишелгән көлтәне Гөлбану өстенә шаяртып ыргытты. һәммәсе кычкырып көлә башладылар* (Г. Ибраһимов).

*Ашыкма... ашка батарсың!* (Н. Исәнбәт). Мәкальне әйтеп бетермәү, яки аның текстындагы берәр сүзне махсус рәвештә төшереп калдыру шулай ук эвфемистик максат белән дә эшләнергә мөмкин.

Контекстуаль кullланылышта мәкальнең лексик составы гына түгел, ә традицион грамматик формасы да үзгәрергә мөмкин.

1) Мәкаль еш кына риторик фигура формасын ала. Мәсәлән:

*– Һавадагы торнаны көтеп, кулындагы чыпчыкны ычкындырасыңмыни?* (Ә. Фәйзи).

*– Укыткан хәлфәләрегез сезгә ни кирәген белмиләрмени? Йомырка тавыкны өйрәтәме? Ахмак булмагыз!* (Г. Ибраһимов).

Риторик сорау формасында әйтелүләре нәтиҗәсендә, *һавадагы торнаны көтеп, кулдагы чыпчыкны ычкындырмыйлар; йомырка тавыкны өйрәтми* мәкальләре бу контекстларда, һичшиксез, көчлерәк яңгырыйлар.

Түбәндәге мисалда *карга сандугач була алмый* мәкале риторик эндәшү формасын алган:

*Сиңа соң сандугачча сайрамак мөмкинме, и карга!* (Г. Тукай)

2) Мәкальләрдә контекстуаль инверсия еш күзәтелә. Инверсиянең иң табигый җирлеге – шигъри сөйләм. Монда ул, гадәттә, ритм-рифма таләпләреннән чыгып кулланыла. Мәсәлән,

*Үз төбенә төшми, ди*
*Шәм-лампаның һичбер нуры.*
*Шул мәкаль монда дөрес шул,*
*Ах, аны җен оргыры!* (Г. Тукай)

3) Сөйләмдә чагыштырмача еш кулланыла торган мәкальләр башка грамматик формада белдереләләр, ягъни үзенең мәкаль калыбын берникадәр үзгәртәләр. Мәсәлән, *Җиде кат үлчә – бер кат кис* мәкале шулай кулланылган: *җиде кат үлчәргә, бер кат кисәргә туры килә* (Г. Әпсәләмов).

Туры мәгънәле һәм чагыштырмача кечкенә булган мәкальнең текстын бу рәвешле әйтү мөмкинлеге чикләнгәнрәк. Төп формадан читләшүнең билгеле бер ноктасында мондый мәкаль үзенең мәкальлеген югалтырга мөмкин, чөнки бу очракта аның мәкаль-җөмләме, ирекле җөмләме икәнлеген аеру кыенлаша.

Мәкаль текстының традицион синтаксик формасын үзгәртеп әйтү кайбер очракларда мәкальгә ироник мәгънә бирә: *Син, Мисхәт, минем өчен казылган базга төштең, рәнҗемә инде. Мин бу дөньяда шактый яшәп, төрле даирәләрнең ничек сулаганын аңлап, бары бер нәрсәдән – кешенең рәнҗүеннән, кемне булса да нахакка үпкәләтүдән генә куркам* (Т. Галиуллин). Бу очракта мәкальләрне контекстка традицион формада, ягъни ничек бар шулай керткәндә, фикер корырак яңгырар иде һәм нәтиҗәдә, сөйләмнең җанлылыгы кимер иде.

4) Мәкаль текстының контекст белән лексик яктан үрелүенең тагын үзенчәлекле ике формасы бар: мәкаль текстының берәр сүзе, мәкальнең бер буыны яки бер кисәге контексттагы сүз яки фраза белән алмаштырылып әйтелә; я мәкальдәге берәр сүз, буын яки кисәк үзенең шушы туры мәгънәле логик эквиваленты белән икесе дә берьюлы – параллель рәвештә әйтеләләр. Бу очракларда, гадәттә, грамматик яктан үрелү күренеше дә күзәтелә. Мәсәлән,

*Бөркетләр*
*Тауда туа,*
*Батырлар*
*Яуда туа!* (Р. Миңнуллин)

*Бүрене аяклар туйдырса, безне көпчәкләр ашата, яшәтә», дип өстәп, үзалдына көлемсерәп куйды. Тәэминат бүлегенннән берәрсен җибәрсәң, бутап кына кайтыр. Арбаның алды кайдан барса, арты шуннан барыр. өч сәгатьтән тиешле мәгълүматлар сезгә килеп җитәр, дип факс белән*

*җавап бирде, йөртүчесенә әзерләнергә кушып, өенә шалтыратты* (Т. Галиуллин).

5) Синоним мәкальләрне тезеп куллану күренеше еш очрый. Мәсәлән, *Агай-энең тату булса ат күп, апа-сеңлең тату булса аш күп* (Г. Бәширов).

*Уе юкның – теле юк,*
*Теле юкның – иле юк* (Н. Арсланов)

6) Текстта тематик яктан якын булган ике мәкальне берләштереп, оештырып әйтү күренеше дә очрый. Фәндә бу күренеш контаминация дип атала. Кайвакыт рухи яки тематик яктан бер-берсенә якын булган берничә мәкальне берләштереп, бер-бер артлы тезеп тә кулланалар. Түбәндәге өзектәге мәкальләр дә кулланылыш максатлары буенча берләшкәннәр – алар бер үк кешене бәяләү өчен кулланылганнар: *– Ике бүлмәле икән фатирыгыз. Иркен. Ленинград проекты. Минем өчен борчылма, кая җәйсәң, шунда эрермен. Йокы ястык теләми. Беген бик арытты да. Юл газабы – гүр газабы дип юкка гына әйтмиләрдер. Миңа менә бу диван да ярар* (Т. Галиуллин).

7) Мәкальнең югарыда күрсәтелгәннән тыш, берникадәр үзенчәлекләрәк булган тагын берничә контекстуаль стилистик мөмкинлеге бар. Язучылар кайбер очракларда еш һәм киң кулланылучы мәкальнең турыдан-туры үзен кулланмыйча, идеясеннән генә файдаланалар. Бу очракта мәкальнең мәгънә ягыннан әһәмиятле бер сүзе, бер буыны яки бер кисәге төшереп калдырыла; шул ук вакытта аның тышкы логик-грамматик структурасы, ягъни җөмлә формасы да югалырга мөмкин. Мәсәлән, *Алар ниндидер зур эш кубарырга йөриләр булса кирәк, – диде Андрей Палыч. – Мин сакалның кылын тартып караган идем дә, коры тотты. Алдан кычкырырга... мин кәккүк түгел дигән була. Башлагач күрерсең ди* (Г. Әпсәләмов).

*Син дә шундый карак һәм алдакчы булып чыктыңмыни, иптәш Симатова? Мин бит сиңа үземә ышангандай ышана, хәтта табына идем. әтинең әйткәне дөрес булган икән: кыен вакытта су белән хатын-кызга таянма дигәне... Суда чайкалган вак йомычка хәленә калдырдың мине* (Т. Галиуллин).

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, мәкальләр сөйләмгә әзер килеш килеп керәләр, яисә лексик-грамматик яктан берникадәр үзгәртелеп кулланылалар. Контекстка җайлаштыру йөзеннән мәкальләр төрле өстәмә сүзләр кушып-кыстырып әйтеләләр, яисә үзләренең традицион лексик составын, яки грамматик формасын үзгәртәләр. Тел-стиль, сурәтләү чараларының иң матур үрнәкләрен үзендә туплаган мәкальләр контекстка төрле стилистик бизәкләр, сүз-сурәт, эвфоник яңгыраш алып керә. Гомумән, мәкальләр фикернең үткенлегенә, сөйләмнең кыскалыгына ирешүдә әһәмиятле стиль чарасы булып торалар, сөйләмдәге башка алымнар белән бергә кушылып, эчтәлекне ачуда зур роль уйныйлар.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Нәбиуллина Г.Ә.* Татар халык мәкальләрендә кушма җөмлә синтаксисы. Казан: Школа, 2004. 208 б.

2. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр / томны төз. кереш мәкалә язучы, иск. әзерләүче Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татгосиздат, 1987. 590 б.

3. Фольклор теле – шигърият теле / төз. И.Н. Надиров. Казан: Фикер, 2001. 223 б.

УДК: 372.881.1

# ОБУЧЕНИЕ САМОСТОЯТЕЛЬНЫМ ЧАСТЯМ РЕЧИ НА УРОКАХ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА С ИСПОЛЬЗОВАНИЕМ ИНФОРМАЦИОННО-КОММУНИКАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ В НАЧАЛЬНЫХ КЛАССАХ

***Ф.Ш. Нуриева***
*Казанский федеральный университет (Казань),*
***Г.Ф. Хасбиуллина***
*МАОУ «Многопрофильный лицей № 11» (Казань)*

В данной работе рассматривается методика преподавания самостоятельных частей речи в начальных классах на уроках татарского языка с использованием информационно-коммуникационных технологий (ИКТ). Основное внимание уделяется важности формирования у младших школьников базовых представлений о частях речи. Использование ИКТ в процессе обучения способствует более глубокому усвоению материала и развитию познавательного интереса у младших школьников. Разработана система упражнений и заданий с применением платформ Google Sites, LearningApps.org, Quizlet, Quizizz и Online Test Pad.
**Ключевые слова:** самостоятельные части речи, татарский язык, урок, ИКТ, сайт.

This paper examines the methodology of teaching independent parts of speech in elementary grades in Tatar language lessons using information and communication technologies (ICT). The main attention is paid to the importance of forming basic ideas about parts of speech among younger schoolchildren. The use of ICT in the learning process contributes to a deeper assimilation of the material and the development of cognitive interest among younger schoolchildren. A system of exercises and tasks has been developed using Google Sites platforms, LearningApps.org , Quizlet, Quizizz and Online Test Pad.
**Keywords:** independent parts of speech, Tatar language, lesson, ICT, website.

# БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФЛАРДА ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МӨСТӘКЫЙЛЬ СҮЗ ТӨРКЕМЕН МӘГЪЛҮМАТИ-АРАЛАШУ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНЫП ӨЙРӘТҮ

***Ф.Ш. Нуриева***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан),*
***Г.Ф. Хәсбиуллина***
*МАОУ «11 нче күппрофильле лицей» (Казан)*

Сүз төркемнәрен мәктәп укучыларына өйрәтүдә төрле сыйныфларга бәйле үзенчәлекләр бар. Башлангыч сыйныфларда татар телен укытуда мөстәкыйль сүз төркемнәрен өйрәнү аеруча әһәмияткә ия. Бу этапта укучылар сүз төркемнәрен дөрес аера белергә, аларның лексик һәм грамматик мәгънәләрен аңларга өйрәнәләр. Шулай итеп, исем, фигыль, сан, сыйфат һәм алмашлыклар турында төп төшенчәләрне үзләштерәләр. Мөстәкыйль

сүз төркемнәренең бирелеше укучыларның телне өйрәнүгә булган кызыксынуын арттыруга ярдәм итә.

Сүз төркемнәре һәм аларның кулланылышы белән таныштырган этапта, иң мөһиме – укучыны гаҗәеп кызыклы татар теле дөньясына җәлеп итү, өйрәнеләсе темага һәм гомумән телгә карата кызыксыну уяту. Укучының туган телгә кызыксынуын арттыру һәм игътибарын җәлеп итәр өчен күнегүләр һәм эш формалары төрлелеге булу шарт. Моны уку-укыту процессында мәгълүмати-аралашу технологияләр куллану тәэмин итәргә мөмкин. Эш формаларының төрлелеге, күргәзмәлек аеруча башлангыч сыйныф укучыларының игътибарын җәлеп итәр өчен мөһим.

Мәкаләбездә башлангыч сыйныф укучыларына мөстәкыйль сүз төркемнәрен өйрәтүдә мәгълүмати-аралашу технологияләрне куллану мөмкинлекләре барланды. Башлангыч сыйныфларда мөстәкыйль сүз төркемнәрен өйрәтү – татар теле дәресләренең төп максатларының берсе. Бу этапта укучылар сүз төркемнәренең нигезен өйрәнә, аларның төрле функцияләрен аңлый башлый һәм практик күнегүләр ярдәмендә белемнәрен ныгыта. Мөстәкыйль сүз төркемнәрен өйрәнү балаларга сүз байлыгын арттырырга, телне аңларга һәм дөрес кулланырга ярдәм итә. Дәресләрдә укучылар сүзләрнең мәгънәсен, аларның җөмләдәге ролен һәм кулланылышын өйрәнәләр. Бу өйрәнү процессында интерактив методлар, уен элементлары, төрле мәгълүмати-аралашу технологияләр кулланыла, шул исәптән, презентацияләр, видео материаллар, интерактив такталар һәм компьютер программалары.

Әлеге хезмәт өчен мәгълүмат туплау барышында күп төрле биремнәр, күнегүләр эшләнде. Алар Google Sites платформасында безнең тарафтан төзелеп, укыту барышында сүз төркемнәрен өйрәтүдә эффектив алым буларак аерым бер сайтта тупланды. Сайтта тасвирланган онлайн биремнәргә сылтамалар урнаштырылды [1].

Сайтның структурасы берничә бүлекне тәшкил итә: «Баш бит», «Исем», «Фигыль», «Сан», «Сыйфат», «Алмашлык», «Рәвеш», «Видео», «Файдалы сылтамалар». Әлеге өлештә үзебез туплаган бирем һәм күнегүләрнең кайбер үрнәкләрен урнаштырдык.

Һәр бүлектә шул сүз төркемен өйрәнүдә ярдәм итә алырлык биремнәргә сылтамалар җыелмасы. Сылтамалар туры LearningApps.org, Quizlet, Quizizz, Online Test Pad, Wizer.me сайтларында эшләнгән биремнәргә илтә.

Түбәндә мәгълүмати-аралашу технологияләр ярдәмендә **исем** сүз төркеменә өйрәтүгә караган күнегүләр тәкъдим ителә. LearningApps.org онлайн платформасында «Парын тап» уены – укучыларга сүзләрне һәм рәсемнәрне туры китерергә кирәк, мәсәлән, «Мәктәп» темасына сүзләр: укытучы, укучы, мәктәп, китап, дәфтәр, акбур, каләм, бетергеч. Шул ук платформада хәрефләрдән сүзләр ясау уены. Шакмакларда хәрефләр тезелгән һәм алар эчендә «Гаилә» темасына караган лексик берәмлекләр яшеренгән. Әлеге сүзләр белән ике уен әзерләнде. Беренчесендә шакмаклар арасыннан табасы сүзләр алдан ук бирелгән, алар кырыйда язылган, ә икенчесендә сүзләр язылмаган. Әлеге тема буенче «Классификация» уены да эшләнде укучыларга тартымлы исемнәр булган сүзтезмәләр һәм җөмләләрне ике якка аерырга тәкъдим ителә, аларны дөрес һәм ялгыш дип язылган ике төркемгә бүлергә кирәк. Мисал өчен, «синең абыем» сүз-

тезмәсен «ялгыш» төркеменә, ә «Синең апаң бармы?» җөмләсен «дөрес»кә урнаштырасы. Шушы ук платформада видео материаллы күнегүләр дә урнаштыру мөмкин. Шундыйларның берсе – текст язуны таләп итә торган викторина. Мәсәлән, YouTube видеохостингында «Салават Күпере» каналының «Бәби сүз» мультфильмының «Һөнәрләр» сериясен куеп, укучыларга әлеге видеода нинди һөнәрләр әйтелде дип сорау бирергә мөмкин, укучыларга шул видео барышында сүзләрне махсус тәрәзәгә язып барырга кирәк була.

«Һөнәрләр» темасына тагын бер видео – «Консуни һәм аның дуслары» мультфильмының әлеге темага караган сериясе. Әлеге серияне Online Test Pad тестлар ясау сервисына кертеп, укучыларга «Консуни нинди эшләр эшли – һөнәрләрне яз» дигән бирем урнаштыру мөмкин. Укучылар җавапны ирекле рәвештә яза. Бу тестлар ясау сервисында диалог рәвешендәге тестлар да ясап була. Мәсәлән, беренче сыйныфта өйрәнелгән исәнләшү, танышу, хәл белешү репликаларына дөрес җавапны табып билгеләргә кирәк,шуннан соң тулы диалог килеп чыгачак. Әлеге диалогта тартымлы исемнәр дә кабатланыла.

Исем+исем конструкциясе белән төзелгән сүзтезмәләрне Quizizz платформасында слайдлар рәвешендә «Кибет атамалары» дәресендә урнаштырдык. Бу платформада шулай ук тестлар эшләү мөмкин. «Урын-вакыт килеше» тестында укучыларга берничә варианттан дөресен сайлап алырга тәкъдим ителә. «Песи, песи, син кайда яшисең? Мин яшим ______, әби белән бабайда». Җыр өзеге бирелгән һәм вариантлар: *авылдә, авылтә, авылда, авылның*. Шунысы уңайлы: Online Test Pad һәм Quizizz сайтларында эшләнгән тестларны онлайн гына түгел, ә эш битләре итеп чыгартып, язмача да эшләтергә була.

Укучыларга исемнәрнең кайсылары кем? ә кайсылары нәрсә? соравына җавап биргәнен өйрәтү дә мөһим. Моның өчен Quizlet сайтында онлайн карточкалар әзерләнде. Карточканың бер ягында кем? яки нәрсә? Соравы язылган, ә икенче ягында шул сорауга җавап бирә торган исем, исем белән ассоциация булдыру өчен янында рәсеме дә бар. Карточкалар белән сүзләрне истә калдырганнан соң, белемнәрне тикшерү өчен LearningAppта «Классификация» уенын уйнатырга була. Монда укучыларга сүзләрне ике якка бүлергә кирәк, бер якка кем? соравына җавап бирә торган исемнәрне, икенчесенә – нәрсә? сайланылган сүзләр*: укытучы, укучы, әни, әти, әби, бабай, сеңел, эне, абый, апа, песи, эт, чәчәк, болыт, ипи, китап, дәфтәр, өстәл, кул, аяк.*

Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр темасын өйрәнгәндә дә күнегүләрне шул ук «Классификация» уены аша тәкъдим итеп була. Укучылар ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне ике якка аерырга тиеш. Алга таба «Парын тап» уенында укучыларга ялгызлык исемнәрне мәгънә ягыннан туры килгән парлар белән тоташтыру биремен урнаштырдык. Мәсәлән, укучыларга Казан һәм шәһәре, Идел һәм елгасы, «Салават күпере» һәм журналы, Сабантуй һәм бәйрәме кебек сүзләрне үзара тоташтырырга кирәк.

Исемнәргә күплек саны кушымчасын дөрес ялгарга өйрәткәндә дә югарыда язылган платформада әзерләнгән уеннар бар. Аларны таблица тутыру форматында эшләдек. Беренче уенда укучыларга исемнәрне *-лар* һәм *-ләр* баганаларына бүлеп урнаштырырга кирәк, ә икенче уенда инде катлаулырак, сүзләрне дүрт баганага урнаштырасы: *-лар, -ләр, -нар, -нәр.*

Килешләрне өйрәткәндә дә Quizlet карточкаларын кулланып була. Бер ягында килеш атамасы язылган, ә икенче ягында аның сораулары. Шулай ук бу очракта да билгеле бер ассоциация тудыру өчен рәсемнәр дә кулланылган, мәсәлән, иялек килешендә этнең иясе – малай, юнәлеш килешендә юнәлешне белдерә торган ук, чыгыш килешендә чыгу юлын күрсәтә торган билгеләмә рәсемнәре куелды. Килешләрне үзләштерү дәрәҗәсен билгеләр өчен Quizlet сайтында тест эшләнде, анда укучылар килешләрнең сорауларын һәм кушымчаларын дөрес билгеләргә тиеш.

Шулай ук Quizlet карточкаларында исемнәр һәм «белән» бәйлеге кулланылышы үрнәкләрен дә урнаштырдык. Бу укучыларга лексиканы ситуациягә мөнәсәбәтле истә калдырырга ярдәм итә ала. Без «Сәлам» дәреслегендә бирелгән диалог репликаларын кулландык [2]. Карточканың бер ягында «Син нәрсә белән уйныйсың?» соравы бирелгән, ә икенче ягында җавап, мәсәлән, «Мин курчак белән уйныйм».

Шулай итеп, исем сүз төркемен башлангыч сыйныфларда өйрәткәндә мәгълүмати-аралашу технологияләр ярдәмендә күп төрле уеннар, тестлар һәм күрсәтмә материаллар әзерләп булганын күрәбез. Башка сүз төркемнәренә дә күнегүләр югарыда санап үтелгн платформаларда эшләнде.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Укытучыга ярдәмлек. URL: https://sites.google.com/view/ukytuchigf/%D0%B1%D0%B0%D1%88-%D0%B1%D0%B8%D1%82

2. УМК «Сәлам». URL: https://selam.tatar/modules


УДК 94

# ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ТАТАРСКИХ ПРОСВЕТИТЕЛЕЙ В ТУРКЕСТАНЕ (конец XIX – первая четверть XX века)


***А.Н. Расулов***

*Наманганский государственный университет (Узбекистан)*


Джадидизм берет свое начало в 80-е годы XIX столетия в Крыму, затем проходит этап своего утверждения, широкого распространения среди казанских татар, а в конце XIX – начале XX века начал широко распространяться в Туркестане, Бухаре, Хиве. С уверенностью можно сказать, что возникшее среди татар джадидское-просветительское движение утверждалось и развивалось сначала в кругу единого татарского народа, затем постепенно приобрело региональный масштаб, распространяясь среди тюрков-мусульман внутренней России. Проблема татарских джадидов по сущности и содержанию, месте, которое она занимал, перспективным планам была присуща всем тюрко-мусульманским народам. В свою очередь, то, что татарский народ с древних времен имел экономические, торговые и духовные связи с другими тюрко-мусульманскими народами, определяло необходимость сотрудничества во взаимоотношениях. Поэтому идеи и инициативы, возникавшие у одного тюрко-мусульманского народа не были чуждыми для других народов, которые воспринимали их с надеждой, что они станут основой развития взаимоотношений. Поскольку отношения, смешанные с передовым просветительством, существовали у тюрко-мусульманских народов и ранее, то это не

явилось новшеством в сотруднических взаимосвязях. В частности, ретроспективный взгляд на историю показывает, что в средние века для территорий Поволжья Бухара, Хива являлись очагами просвещения, а в XIX веке Поволжские татары служили образцом распространения просвещения для туркестанских единоверцев.
**Ключевые слова:** Джадиды, татары, тюрки, Туркестан, мусульмане, просвещение, театр.

Jadidism originated in the 80s of the XIX century in Crimea, then went through the stage of its establishment, wide distribution among Kazan Tatars, and in the late XIX – early XX centuries began to spread widely in Turkestan, Bukhara, Khiva. It can be said with confidence that the Jadid-enlightenment movement that arose among the Tatars was established and developed first in the circle of the united Tatar people, then gradually acquired a regional scale, spreading among the Muslim Turks of inner Russia. The problem of the Tatar Jadids, in essence and content, the place it occupied, and its future plans, was inherent to all Turkic-Muslim peoples. In turn, the fact that the Tatar people have had economic, trade and spiritual ties with other Turkic-Muslim peoples since ancient times determined the need for cooperation in relationships. Therefore, the ideas and initiatives that arose among one Turkic-Muslim people were not alien to other peoples, who perceived them with the hope that they would become the basis for the development of relations. Since relations mixed with advanced enlightenment existed among the Turkic-Muslim peoples before, this was not an innovation in cooperative relations. In particular, a retrospective look at history shows that in the Middle Ages, Bukhara and Khiva were centers of education for the Volga region territories, and in the XIXth century, the Volga Tatars served as a model for the spread of education for Turkestan co-religionists.
**Keywords:** Jadids, Tatars, Turks, Turkestan, Muslims, education, theater.

Уже в начале XIX века, задолго до завоевания края Российской империей, интеллигенция, мыслители осознавали оторванность Туркестана от мирового сообщества, застой в существовавшей системы образования и воспитания.

По мнению У. Долимова, джадидизм распространился в Крыму, Казани, Азербайджане на 15–20 лет раньше, чем в Туркестане, а реформаторы образования – передовые педагоги подверглись притеснению и преследованию в первые годы своей деятельности со стороны фанатичных улемов, сторонников старых методов обучения (усули кадим), были изгнаны из родины [1: 7–8].

Одним из путей избежать противоречивого состояния на местах было найти пристанище в Туркестане, где проживали тюрко-мусульманские народы, близкие друг-другу по языку, религии, обычаям и традициям. К тому же первой причиной такого поведения татарских джадидов-просветителей было то, что проведение реформ среди тюрко-мусульманского населения путем внедрения новометодных школ, выдвижения идеи объединения на национально-религиозной основе администрацией царской России воспринималось как нанесение вреда интересам русской государственности; вторая причина заключалась в том, что по сравнению с национальными школами деятельность школ джадидов подвергалась полицейскому контролю, учебные пособия конфисковались, преподаватели находились под наблюдением, джадидские школы по разным причинам и поводам закрывались.

4. *Исхакый Г.* Габделкаюм ән-Насыйри. Йөз сәнәле дәүриясе мөнәсәбәтилә // ЦПН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф.135. Оп.2. Ед.хр. 74. 14 л.

5. *Исхакый Г.* Габделкаюм ән-Насыйри. Йөзенче сәнәи дәүрияи виладәте мөнәсәбәтилә // Төрек йорды. 1925. № 11. Җилд 2. Агустус 1341. С. 409–413.

6. *Исхакый Г.* Көндәлекләр: 3 китапта. 1 нче китап: 1919–1920 / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Ә.Х. Алиева, Ф.Г. Фәйзуллина, Г.М. Ханнанова; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. Казан: ТӘһСИ, 2023. 300 б.

7. *Исхакый Г.* Милли куәтләр бардыр = Есть сила в нации / Д.Ф. Заһидуллина ред. Казан, 2023. 324 б.: ил.

8. *Миңнегулов Х.* Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 367 б.

9. *Мусин Ф.М.* Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 71 б.

10. *Сахапов М.Ж.* Гаяз Исхаки – возродитель татарской литературы XX века. Казань: Магариф, 2008. 295 с.

11. *Фәйзуллина Ф.Г., Ханнанова Г.М.* Гаяз Исхакый көндәлекләре буйлап мәдәни сәяхәт // Фәнни Татарстан. 2023. № 1(37). Б. 63–73.

12. *Ханнанова Г.М.* Гаяз Исхакый көндәлекләрендә чит ил иҗтимагый-мәдәни тормышы һәм вакытлы матбугаты // Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика: материалы междунар. науч.-практ. семинара, посвящ. 145-летию со дня рождения классика татарской литературы Гаяза Исхаки / сост. Л.Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2023. С. 152–155.

13. *Ханнанова Г.М.* Татарлар турында японнар һәм европалылар (Г. Исхакый көндәлекләре буенча) // Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика: материалы IV Междунар. науч.-практ. семинара, посвящ. 85-летию Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова (9–10 октября 2024 г., Казань) / сост. Л.И. Фахрутдинова. Казань: ИЯЛИ, 2024. С. 343–348.

14. *Ханнанова Г.М., Гарипова Л.Ш.* Гаяз Исхакый Япония турында (1919 елгы көндәлек хатирәләре буенча) // Эхо веков = Гасырлар авазы. 2018. № 3. С. 102–112.

УДК 811.512.145’367

# СЕМАНТИКО-СИНТАКСИЧЕСКИЕ ОТНОШЕНИЯ В ТРУДЕ КАЮМА НАСЫРИ «ӘНМҮЗӘҖ»

***Л.Г. Хабибуллина***

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Исследованию семантико-синтаксических отношений стало уделяться внимание уже в татарских грамматиках XIX века. Несмотря на то, что не были объектом специального лингвистического исследования, в той или иной степени они начали рассматриваться в трудах А. Казем-Бека, К. Насыри и др. Грамматика Каюма Насыри «Әнмүзәҗ» (1895) является первым опытом многоаспектного научного изучения татарского языка. В статье исследуется рассмотрение семантико-синтаксических отношений в данном труде при описании падежей, послелогов, союзов и наречий.

**Ключевые слова:** первые татарские грамматики, Каюм Насыри, семантико-синтаксические отношения, смысловые отношения.

The study of semantic-syntactic relations began to receive attention already in the Tatar grammars of the 19th century. Despite the fact that they were not the object of special linguistic research, to one degree or another they began to be considered in the works of A. Kazem-Bek, K. Nasyri and others. The grammar of Kayum Nasyri is the first experience of a multidimensional scientific study of the Tatar language. The article examines the consideration of semantic-syntactic relations in this work when describing cases, postpositions, conjunctions and adverbs.

**Keywords:** the first Tatar Grammars, Kayum Nasyri, semantic-syntactic relations, semantic relations.

# КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ «ӘНМҮЗӘҖ» ХЕЗМӘТЕНДӘ СЕМАНТИК-СИНТАКСИК МӨНӘСӘБӘТЛӘР БИРЕЛЕШЕ

***Л.Г. Хәбибуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ» грамматикасы 1895 елда басыла. Әлеге хезмәт татар телен комплекслы фәнни тикшерүнең беренче тәҗрибәсе булып тора.

«Әнмүзәҗ» грамматикасында семантик-синтаксик мөнәсәбәтләр махсус анализланмаса да, аларга килеш, бәйлек, теркәгеч һәм рәвешләрне өйрәнгәндә игътибар ителә.

Семантик-синтаксик мөнәсәбәтләр вакыйгаларның эчке логик-мәгънәви бәйләнешләрен белдерәләр. Аларның семантикасы күп очракта җөмләнең яки контекстның гомуми эчтәлеген анализлап ачыклана, чөнки татар телендә еш кына бер үк бәйләүче чаралар төрле мәгънә белдерү өчен хезмәт итә һәм аерым семантика маркеры булып санала алмыйлар. Мәсәлән, татар телендә һәм гомумән төрки телләрдә сәбәп-нәтиҗә һәм максат семантикалары формаль яктан охшаш, чөнки әлеге мөнәсәбәтләрне белдерүче конструкция компонентлары еш кына бер үк чаралар ярдәмендә, әйтик, баш кисәккә *өчен* бәйлеге ярдәмендә ияргән иярчен кисәк / җөмлә белән белдереләләр. Максат һәм сәбәп-нәтиҗә мәгънәләрен аеруда төп күрсәткеч булып контекст – эш-хәлнең махсус эшләнүе яки эшләнмәве санала.

«Әнмүзәҗ» хезмәтендә Каюм Насыйри да сәбәп мәгънәсенең *өчен* бәйлеге ярдәмендә бирелүе турында яза: *«Өчен – тәглил вә сәбәб мәгнәсе өчен мөстәгмәлдер, мәсәлән: Син кичә ни өчен килмәдең»* [1: 60]. Әлеге чара ярдәмендә максат мәгънәсен дә белдерү турында әйтелми.

«Әнмүзәҗ» грамматикасында шарт мөнәсәбәтләрен белдерүче *әгәр, әгәр дә, бәнагяһ* шарт теркәгечләре күрсәтелә: *«шарт хәрфе дигәнемез шундайын хәрефдер ки, бер нәрсәнең үкугына икенче нәрсәне шарт йасыйдыр: Әгәр кич тыныч вә җилсез булса, қойаш йақтырыб чығар; Әгәр шәрикләр арасында мовафәқәт булмаса, аларның эше һич уңға бармас»* [1: 62].

Тел белеме фәнендә кире шарт мәгънәсен белдерүче конструкцияләргә карата галимнәрнең фикерләре бердәй түгел, чөнки алар төзелеше буенча да, мәгънәви эчтәлеге буенча да вакыт, сәбәп-нәтиҗә, шарт мөнәсәбәтләре белән тыгыз бәйләнештә. Тюркологлар В.А. Богородицкий, Н.К. Дмитриев кире шарт мөнәсәбәтләрен шарт мөнәсәбәтенә якынайталар һәм кире шарт җөмләсен иярчен шарт җөмләнең бер төре дип карыйлар.

Каюм Насыйри да «Әнмүзәҗ» грамматикасында шарт һәм кире шарт мәгънәсен аерып карамый. Фигыльнең шарт наклонениесе кулланылган җөмләләр күрсәтелә, әмма китерелгән мисалларның барысы да шарт мәгънәсен белдерми: *Син бойырсаң, мин эшләрмен; Ул чакырса, мин барырмын; Син аны белсәң дә, әйтмәссең; Бу китаб кирәк булмаса, мин аны йазмас идем* [1: 181]. Күргәнебезчә, *Син аны белсәң дә, әйтмәссең* мисалында кире шарт мәгънәсе белдерелә.

Шарт һәм кире шарт мөнәсәбәтләрен аерып карамау моннан соң дөнья күргән Г. Алпаров, В.Н. Хангилдин грамматикаларында да очрый.

Шарт мөнәсәбәтләренең иң төп һәм еш кулланыла торган күрсәткече – шарт фигыль формасы. Иярчен шарт җөмлә иң беренче формалашкан иярчен җөмлә типларыннан санала, чөнки борынгы шарт формасы *-сар/-сӓр* V–VII гасырга караган төрки язма истәлекләрендә очрый [2: 215].

«Әнмүзәҗ»дә дә шарт фигыльнең *-са/-сә* кушымчасы ярдәмендә ясалуы һәм шарт мәгънәсе белдерүе әйтелә: *«Фиғыл шарт ошбу тариқча тәсныйф қыйлынадыр ки, асыл фиғылдән соң -са/-сә хәрфе илхақ қыйлыныб шарт мәғнәсен ифадә қыйлыр: йазсам, йазсаң, йазса...»* [1: 75].

Татар телендә, гомумән төрки телләрдә шарт фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле ярдәмендә ясалган конструкция теләк мәгънәсен белдерә. Әлеге үзенчәлек Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ» грамматикасында да игътибарга алына: *Алсиде җани алсиде, ағызмаған баллар булсиде. Һавадин фәрештә инсиде, инде қаушасыз дисиде* [1: 76].

Хәзерге лингвистика фәнендәге антропоцентризм күренеше белән бәйле рәвештә тел системасында кешегә мөһим урын бирелә. Мәгълүм булганча, вакыйгалар, күренешләр, процесслар һәм кеше үзе дә телдә пространство һәм вакыт яссылыгында күзаллана. Пространство мөнәсәбәте – лексик-синтаксик категория, чөнки еш кына ул лексема буларак аерым сүз белән түгел, ә сүзләрнең синтаксик формалары ярдәмендә белдерелә. Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә пространство семантикасын килеш формасындагы сүзләр (юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килеше), бәйлек сүзле конструкцияләр, рәвешләр, алмашлыклар белдерә ала.

«Әнмүзәҗ» грамматикасында, пространство мәгънәсен белдерү өчен, *-да/-дә* урын-вакыт килеше формасының кулланылуы әйтелә, мисаллар китерелә: *Ул Қазанда тора; Мәсҗеддә намаз уқыйлар* [1: 60]. Моннан тыш, Каюм Насыйри пространство белдерүче *арт, алд, уң, суң (сул), аст, өст, урта, ара* сүзләрен билгели [1: 185].

И. Гигановның «Грамматика татарского языка» (1801), А. Казем-Бекның «Общая грамматика турецко-татарского языка» (1846) грамматикаларында темпораль мәгънә белдерүче вакыт рәвешләре күрсәтелә. Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ»ендә түбәндәге сүзләр вакыт рәвешләре дип карала (барысы да рәвеш булмаса да): *бу көн/бүген, көндез, төнлә, төнәген, әле, байа, иртә, кич, өйләдә, иртә белән, кич белән, кыш көне, йаз көне, җәй көне, көз көне, бу йыл/быйыл, былтыр, ай, йыл, атна, тәүлек* һ. б. Мәсәлән: *Кичә килдем, Көндез йоқладым* [1: 65]

Күргәнебезчә, Каюм Насыйриның татар телен алга таба фәнни өйрәнүгә теоретик нигез булып торган «Әнмүзәҗ» грамматикасында семантик-синтаксик мөнәсәбәтләргә берникадәр урын бирелә: сәбәп-нәтиҗә, шарт, пространство һәм вакыт мөнәсәбәтен белдерүче кайбер чаралар күрсәтелә.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Насыйри К.* Әнмүзәҗ. Казан, 1975. 213 б.

2. Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Ч. III. Синтаксис / под общ. ред. Н.К. Дмитриева, Н.А. Баскакова, Е.И. Убрятовой. М.: Изд-во АН СССР, 1961. 232 с.

УДК 811.512.14

# «ДЖЫК» – ТЮРКСКОЕ СЛОВО ИЛИ ЗАИМСТВОВАНИЕ ИЗ САНСКРИТА?

***А.Г. Хайрутдинов***
*Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ (Казань)*

В статье ставится под сомнение обоснованность утверждения о том, что лексема «джык» (татарск.: җык) было заимствовано языками тюркских племен Сибири из санскрита в процессе проникновения и распространения в их среде манихейской религии в VIII в. Данное слово в его изолированном варианте до сих пор бытует в татарских говорах Заказанья, а составе словосочетаний оно присутствует в лексиконе литературного татарского языка и находит отражение в этимологических словарях. Автор приводит доказательства принадлежности этого слова к корпусу древнетюркской лексики. Об этом свидетельствуют хронологические рамки и динамика переселения тюркских племен-предков современных татар и чувашей из Сибири на территории Причерноморья и Урало-Поволжья. Кроме этого, высказывается предположение о возможности заимствования упомянутой лексемы санскритом из тюркских языков.
**Ключевые слова:** татарский язык, древнетюркский язык, санскрит, булгары, татары, чуваши, этимология.

The article calls into question the validity of the claim that the lexeme "jyk" was borrowed from Sanskrit by the languages of the Turkic tribes of Siberia during the penetration and spread of the Manichaean religion among them in the 8th century. This word in its isolated version still exists in the Tatar dialects of the Qazan Arty region, and as a part of phrases it is present in the lexicon of the literary Tatar language and is reflected in etymological dictionaries. The author provides evidence that this word belongs to the corpus of ancient Turkic vocabulary. This is evidenced by the chronological framework and dynamics of the migration of Turkic tribes, the ancestors of modern Tatars and Chuvash from Siberia to the Black Sea region and the Ural-Volga region. In addition, it is suggested that the mentioned lexeme may be borrowed by Sanskrit from the Turkic languages..
**Keywords:** Tatar language, ancient Turkic language, Sanskrit, Bulgars, Tatars, Chuvash, etymology.

# «ҖЫК» – ТӨРКИ СҮЗМЕ, САНСКРИТТАН АЛЫНМАМЫ?

***А.Г. Хәйретдинов***
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты (Казан)*

Адәм баласының балачак хатирәләре күңеле түрендә җан биргәнгә кадәр саклanaдыр, мөгаен. Миндә дә шулай – хатирәләр күп, шундыйлардан берсе телебез хәзинәсенә кагылышлы. Авылдагы бер балачак дустым берәүгә ачуы чыкса, кашларын җыерып, күзләрен усал итеп кыса төшеп тегене: «Җык!» – дип сүгә иде.

Бу сүзнең мәгънәсе миңа билгесез иде, аның нindидер начар нәрсә булуын гына аңладым. Шул чактан бирле ул сәер *җык* сүзен башка ишеткәнем булмаса да, аның ни белдергәнлеге бер җавапсыз сорау булып

күңелемә сеңеп калган икән. Кайчан да булса әлеге сүз мине кызыклы бер фикергә, гипотезага китерәчәк дип, әлбәттә, уйлап та караганым булмады. Тик, дөнья булгач, ниләр булмас? Һич көтмәгәндә, бу сүз хәтерем төпләреннән калкып чыкты. Эшнең асылы болай булды: көннәрдән бер көнне кулыма мәшһүр төркиятче галим И.Л. Кызласовның «Рунические письмена Сибири. Рассказы археолога» [5] исемле китабы килеп керде. Бу әсәр белән якыннан танышуымның, мавыгып укуымның насыйп сәгатьләре җитте. Китапның эчтәлеге үтә дә кызыклы: моннан мең – ике мең ел элек яшәгән борынгы төрки бабаларыбызның югары мәдәният әһелләре буларак *битик* / *бичик* (хәзерге фәндә *руналар, руник язу*) дип аталган махсус билгеләр уйлап чыгарулары, шул билгеләр, ягъни хәрефләр белән тау кыяларында, тораташ вә балбалларда очлы тимер белән уеп безнең көннәргә кадәр сакланып килгән язмалар калдырулары, ул борынгы ташъязмаларның табылу һәм өйрәнелү тарихы – болар һәммәсе Кызласовның талантлы хикәяләве бәрәкәте белән хыялымда еракта калган дәверләр, гүзәл табигать манзаралары, шунда гомер иткән кавемнәр, кешеләр пәйда булалар, язулары аша миңа кичерешләрен җиткерәләр, уй-хисләре белән уртаклашалар.

Инде *җык* сүзенә әйләнеп кайтыйк.

Башта әлеге сүзнең хәзерге вакытта татар тел белеме күзлегеннән карап, аның нинди мәгънәләргә ия булуын күрсәтәсем килә. Моның өчен Казанда 1981 елда басылып чыккан «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», Р. Әхмәтьянов төзегән «Татар теленең этимологик сүзлеге» (2015) һәм 2016 елда дөнья күргән «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең II томы кебек чыганакларда китерелгән мәгълүматка мөрәҗәгать итик. Боларда әйтелгәннәрне тикшерә башлаганчы игътибар үзәгендәге *җык* сүзенең тискәре мәгънәгә ия булуын да истә тотыйк, чөнки минем югарыда искә алынган балачак дустымның авызында бу сүз тиргәү иде. Шуңа күрә аның фәнни чыганакларда китерелгән мәгънәләренең тискәреләренә игътибар итәчәкмен.

1981 елгы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә караганда, җык сүзенең исем буларак аерым кулланылмавы ачыклана. Ул бары тик сүзтезмәләрдә кулланыла:

*җык булу* сүзтезмәсендә килеп ул «тәмам туеп, арып бетү», «гарык булу» мәгънәләрен белдерә;

*җык кергере (тигере, булгыры)* дигән сүзтезмәдә тиргәү, каргау сүзе буларак килә, һәм, ниһаять,

*җык кебек* дигән сүзтезмәдә «әзмәвердәй», «зур гәүдәле», «таза» мәгънәләренә ия булып чыга.

Моннан тыш *җык* сүзеннән *җыклану* ягъни «җык булу, интегү, җәфалану» мәгънәләренә ия булган исем фигыль дә ясала икән [7: 798].

Р. Әхмәтьяновның «Татар теленең этимологик сүзлеге»н ачып карыйк. Биредә *җык* сүзенең башкортча *йыҡ* буларак «род; отродье», «ыру башы», иске татар телендә, мәсәлән «Нәһҗел фәрадис»тә *йык-йывы* рәвешендә килеп «нәсел-нәсәп, нәселе якын», чуаш телендә *йӑх* «нәсел-ыру, буын, токым, сорт», «аталандыру, үрчетү»; кебек мәгънәләре күрсәтелгән [1: 281].

Әмма шул ук сүзлектә әлеге кәлимә *җик* рәвешендә дә китерелеп «нечто отвратительное, крайне трудное; мерзий», җик булу «омерзеть» ке-

бек мәгънәләрне белдерә. Каракалпак, кыргыз телләрендә *җек*, карачай-балкарларда *җэк*, алтай телендә *дьек, дьеек* рәвешендә язылып ул «әшәкелек, әшәке, кабахәт, явыз рух»ны белдерә. Чуаш телендә *йăх* булып «яман чир; явыз рух», көньяк алтай диалектында *чэк* «җирәнгеч»; коман, уйгыр һәм чыгытайларда *jäk* «җен, хәтәр, явызлык; усал зәгыйфь», борынгы төрки телдә *jäk* «ачлык җене», *jek ičkäk* сүзтезмәсендә «явызлык рухлары». Төркмәннәрдә *йек*, алтайларда *чäк*, хакасларда *чек* булып «әшәке, әшәкелек» мәгънәләрен; чулым татарларында *олуг чäк* «унике башлы шайтан»ны белдерә [1: 268].

2016 елгы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең күрсәтүенә күрә, *җык* атларда була торган авыруны, ә күчерелмә мәгънәдә «авырлык», «газап, иза» мәгънәләрен белдерә [8: 387].

Безнең өчен иң кызыклысы булып ***җык*** сүзенең коман, уйгыр, чыгытай, чулым татарлары телләрендә сакланып калган мәгънәләре тора. Бу телләрдә *jäk* һәм *чäк* булып яңгыраган бу сүз «җен», «хәтәр», «явызлык»; «*усал зәгыйфь*», «*унике башлы шайтан*» булып килә. Чуаш телендә *йăх* дип яңгыраган бу сүз «яман чир; явыз рух» булып килә. Моннан тыш, шул ук телдә бу сүзнең «*йĕк / йĕп*» шәкелендәге әйтелешләре дә күзәтелә: «*Йĕк ура айĕнченех тухать*» (йĕк (җык) аяк астыннан чыга); «*Çĕр çурăлса йĕк тухтăр!*» (Җир ярылып йĕк (җык) чыксын!). Бу очракларда *йĕк* сүзе «*яман ия*» (злой дух), «кабәхәт, җирбит» (гад, гадина) мәгънәләрен белдерә [3]. *Йĕк* сүзе *jэ̆к* (җык) итеп тә укыла ала, мәгънәсе дә баягыча тискәре коннотациядә кала, ягъни кемне дә булса сүгү, ачулану сүзе, «Эт!», дигән кебек [6].

Ягъни, хәзерге вакытта ***җык*** *(җак / җэк / җек / йек / чак / чäк / чик / чык / дьек / йăх / jэ̆к / йĕк / jäk)* рәвешендә яңгыраган бу сүз үзенең иң борынгы семантикасында *җен* (шайтан, демон) мәгънәсенә ия булып, табигать ияләре арасында иң усал, иң явыз булган берсен белдергән.

Хәер, югарыда китерелгән нәрсәләр белән Кызласов китабында язылганнарның нинди бәйләнеше бар, дигән сорау туарга мөмкин. Бәйләнеш бар, һәм аның тәэсирендә барлыкка килгән фикер толымнары кызыклы юнәлештә ишелпе, үрелеп баралар. Искә алынган китапта мондый сүзләр бар: *Күк-кыяда язылган һәм, кызганыч ки, тулысынча аңык булмаган бер битиктә, җен искә алына. Анда кулланылган йәк (хакас телендә чик әйтелеше белән сакланган) сүзе санскриттан алынма буларак, буддачылык язмалары белән таныш булучылыкка ишарә итә һәм төрки телдә язылган манихәй язмалары өчен гадәти күренеш булып тора* [5: 106][1].

Минем мәктәп яшендәге балачак дустым – гади авыл малаеның әлеге сүзне иң борынгы һәм шуңа күрә асыл мәгънәсендә куллануы, ягъни ачуын чыгарган берәүне «Җык!», дип, ягъни, хәзергечә әйткәндә «Җен!», «Шайтан!», дип сүгүе үзенә күрә кызыклы бер күренеш булып тора. Әмма бу сәер сүз тудырган мәсьәләнең икенче бер кызыклы ягы да бар. Идел буе татарларының кан тамырларында мул итеп борынгы болгарларның да каны агуы фәндә күптән мәгълүм булган хакыйкатьтер, шуңа күрә аңа аерым тукталып тормыйм. Кара диңгезнең төньяк ярларыннан алып Идел-

[1] Биредә һәм алга таба Кызласов китабыннан китерелгән өземтәләр татар теленә тәрҗемә ителде.

Чулманга кадәр җәелгән географик җирлектә соңрак дәвердә болгарлар дип аталачак кабиләләр берлеген оештырасы ыругларның археологик эзләре V гасырдан бирле күзәтелә башлый [4: 183–184]. VII–VIII гасырларда әлеге ыруглар Сура, Идел, Чулман, Агыйдел, Җаек елгалары белән Урал таулары арасына барып җитәләр дә, шунда урнашып соңрак, – IX гасырда, – Болгар дәүләтенә нигез салалалар. Алга таба безгә әле генә телгә алынган V–VIII гасырларны истә тотарга кирәк, чөнки Кызласов китергән мәгълүматны, ул атаган даталарны истә тотып бераз фикер йөрткәндә бик кызыклы нәрсәләр килеп чыга.

Кызласов болай дип яза:

*Күпсанлы борынгы тау, елга һәм башка табигый нәрсәләрнең ияләрен үзенең мәһабәт сыны белән алмаштырган, яки, әгәр теләсәгез, буйсындырган бердәнбер Илаһ нәрсә соң ул? Ташъязмаларның эчтәлеге әлеге мәсьәләне дә хәл итәргә мөмкинлек бирә... Бу язмалардан кала тикшерүчеләргә – борынгылык белгечләренә хәзерге көндә билгеле булган һичбер язма чыганак безнең якларда моннан 1200 ел элек булган дөньяга карашның алмашуы турында хәбәр бирә алмаячак* [5: 99].

Кызласовның телгә алынган хезмәте 2021 елда басылган. Шуннан башлап тарих буйлап үткәннәргә таба 1200 ел чигенсәк без VIII йөзьеллыкка барып җитәбез. Ягъни, VIII гасырда Себердә яшәүче борынгы төркиләрнең бер өлеше потларга, ияләргә табынудан арынып тәүхид диннәренең берсе булган мәнихәячелек[1] динен кабул итәләр һәм әлеге тирән рухи үзгәреш ташъязмаларда чагыла башлый: *Анасәйнең тәүхид белән бәйле булган ташъязмалары илаһның исемен атамыйлар, һәм бу, әлбәттә, тиктомалдан түгел. Шулай да, аны белдерү өчен кулланылган сүзләр шактый күрекле. Ташны тырнап язылган берничә юлда ул илаһ чал мәҗүсилеккә барып тоташкан һәм Күкне белдергән борынгы* ***тәңре*** *сүзе белән атала. Безнең язмаларда, Тәңрегә юнәтлелгән догалардан күргәнебезчә, бу сүз белән инде урынлата күкләргә бәйле булса да, шулай ук җир биләмәләрен дә идарә итүче бердәнбер илаһны атыйлар* [5: 100].

Югарыда әйтелгәннәрдән, миңа калса, бик тә кызыклы сорулар туа.

Башта ***тәңре*** сүзен алыйк. XIX гасыр ахыры, XX гасыр башында татарларда нәшер ителгән дини әдәбияттә бу сүз Аллаһны белдерер өчен бик еш кулланылган. Хәтта «Аллаһ Тәгалә» дигән гыйбарә урынына «Тәңре Тәгалә» дигән гыйбарә куллааныла торган булган. Сибириядәге борынгы ташъязмаларда бердәнбер илаһны белдерә башлаган бу борынгы сүзнең ничә гасырлар үткәннән соң да татарларда шул ук мәгънәдә Аллаһка карата кулланылуы гаҗәеп нәрсә. Әйтерсең, дини китаплар язган татар мөселман язучылар һәм дин галимнәре борынгы дәвердә язылган ташъязмалардан үрнәк алганнар. Тугандаш төрки кавемнәрне никадәр ерак аралар, никадәр гасырлар аерып торса да, алар арасындагы рухи бәйланышлар беркайчан

---

[1] Мәнихәячелек – III йөзьеллыкта хәзерге Иран биләмәләрендә барлыкка килеп, үзенә зәрдәшт диненең, гностик христианнарның, буддачыларның карашларын сыйдырган дин. Диннең мәнихәй дигән атамасы аңа нигез салган *Мәни* исемле кешенең исеменә *хәй*, ягъни «терек» сүзен кушылуы белән ясалган. VI гасырда бу диннең үзәге Сәмәрканд шәһәренә күчә, ә VII–VIII гасырларда Чинга (Кытайга) үтеп керә. 762 елда Уйгыр дәүләте башлыгы булган Бөгү Каган мәнихәй динен рәсми рәвештә кабул итә. Моннан соң яңа дин зур тизлек белән Көньяк Сибирия төркиләре арасында да тарала башлый.

да өзелмәгән диярсең. Киресенчә, ул бәйләнешләр һаман тере, һаман исән, һаман җанлы булып торган дигән тәэсир кала.

Әлеге гаҗәеп рухи бердәмлекнең сәбәбе нидә? Аның асылы нидән гыйбарәт? Бу сорауларга җавап бирү йөзеннән түбәндәге уйларым белән уртаклашасым килә.

Сибириядә яшәп калган борынгы төркиләрнең бердәнбер илаһны тәңре дип атаулары, аны шул рәвешле күзаллаулары XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәп иҗат иткән татарларда кисәк кенә кучеп пәйда була алмаган, әлбәттә. Бу сүз болгарларда да, соңрак – татарларда өзлексез рәвештә яшәп килгән, сөйләмдә һәм язмада кулланылган. Димәк, эш әллә кайчан бер-берсеннән аерылган төрки кавемнәрнең һәммәсендә дә буыннан буынга тәңре сүзенең күчеп килүенә генә кайтып калмый. Бердәнбер илаһны күзаллау, аңа ана телләрендә булган сүз белән дөрес исем бирә алу Сибирия төркиләренең дә, Көнбатышка күчеп киткәннәренең дә акылларында, каннарыда, күңелләрендә булган.

Әмма биредә болгарларның V гасырга кадәр үк Сибириядән күчеп киткәннәренә күрә, мәнихәя дине белән танышып өлгәрмәгән булуларын ныклап истә тотарга кирәк. Бердәнбер илаһ турында болгарлар IX гасырда гына, ягъни Сибирия төркиләреннән йөз ел соңга калып белә башлыйлар дип фаразларга мөмкин. Икенче фаразга күрә, алар андый илаһ турында иртәрәк, ягъни VIII гасырда хәбәр алган булырга мөмкиннәр. Кайдан һәм кемнәнме? Кавказны, Мәвараәннәһерне яулап барган гарәплpoints дән, әлбәттә. Тик һич тә Сибириядә калган кардәшләреннән ишетеп түгел. Ничек кенә булмасын, алар ул илаһны, Сибириядә калган кардәшләре белән киңәшләшмичә, шул ук *тәңре* сүзе белән атаганнар һәм бу аңламны XX гасыр башына кадәр саклап калганнар.

Икенче бер сорау баягы *җык* сүзе белән бәйле. Тәңре сүзенең тарихы белән чагыштырганда бу сүзнең маҗаралары күпкә катлаулырак, аның тарихы тудырган сорауларга җавап бирү дә кыенрак.

Кызласовка күрә, тамыры буддачылыкның ана теле булган санскрит теленә тоташкан бу сүзнең VIII гасырда Сибирия төркиләре арасында мәнихәя дине таралган дәвердә телләренә дә үтеп кергән. Бәлки шулайдыр да. Әмма минемчә, бу сүзнең тарихы башка да булырга мөмкин. Аның иң борынгы дәверләрдән үк төрки сүз булуы ихтимал. Чөнки Сибириядән V гасырга кадәр китеп, V–VII гасырларда Кара диңгез буйларында урнашып, соңыннан VIII–IX гасырларда Идел-Чулман-Урал арасында барып җитеп яшәгән болгарлар тәңречелек динен тотканнар. Дини ышануларга бәйле булган терминнар һәм төшенчәләр башка бер халыкның теленә бары тик аларның шул динне кабул итүләре нәтиҗәсендә үтеп керә ала. Шуңа *җык* сүзенең болгар теленә Сибириядә калып манихәя динен кабул иткән төркиләрдән үтеп керә алуы бик шикле.

Югарыда әйтелгәннәрдән нинди нәтиҗәләргә килергә мөмкин? Нәтиҗәләр берничә:

– *Җык* сүзе – төрки сүз.

– *Җык* сүзе төрки телдән бешка телләргә дә үтеп кергән булырга бик мөмкин. Төрки халыкларның борынгылыгын истә тотканда, бу фикер акылга сыймаслык нәрсә булып күренми. Тын океанда сәфәр итеп зур фәнни ачыш ясаган Тур Хейердалны гына искә алыйк: үзенең салына ул

«Кон Тики» дигән исем куша. Бу исем белән Тын океан буйлап сибелгән Полинезия утрауларында яшәүче халыклар үзләре табынган Кояш (Көн) илаһын атаганнар. Тики дигән сүз исә төрки телләрдә Тәкә, яки Теки дип әйтелә һәм ул уңыш, муллык, бәрәкәт кебек төшенчәләрне белдерә, шуңа күрә Көн Теки – чәчрәп торган төрки исем булып чыга. Шул ук Полинезия кабиләләре телендә Күк илаһының исеме *Таңгароа* буларак яңгыравын искә алыйк [2: 26]. Бу күренеш Күк илаһын гомер бакый *Тәңре* дип атаган борынгы төркиләрнең, чыннан да, планетаны, шул исәптән Тын океан утрауларын да ачкан һәм анда яшәгән кавемнәргә нык мәдәни тәэсир ясаган бер халык булуына ишарә генә түгел, хәтта нык дәлил булып тора.

– *Җык* сүзе хәзерге татар телендә кулланыла торган «җен, пәри, дию, иблис, шайтан» кебек алынма сүзләрнең борынгы төрки тиңдәше буларак кабул ителергә һәм телебездә искә алынган сүзләр белән бертигез дәрәҗәдә кулланылырга мөмкин дә, лаек та.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I т. (А–Л). Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. 543 б.

2. *Бакиров М.* Татарский фольклор: многорафия. 2-е доп. изд. Казань: Изд-во Акад. наук РТ, 2018. 406 с.

3. *Ильина Г.Г., Мышкина А.Ф.* Традиционные представления чувашей о фольклорном персонаже инкек. URL: https://www.gramota.net/article/phil20171405/fulltext (09.04.2025 мөрәҗәгать ителде).

4. *Кляшторный С.* Праболгары в евразийских степях // История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. I. Народы степной Евразии в древности. 2-е изд., стер. Казань: РУХИЯТ, 2017. 552 с.

5. *Кызласов И.Л.* Рунические письмена Сибири. Рассказы археолога. М., Абакан: Хакас. кн. изд-во, 2021. 152 с.

6. Словарь чувашского языка. URL: https://ru.samah.chv.su/s/8/йĕк (09.04.2025 мөрәҗәгать ителде).

7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. III т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.

8. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. II т.: Г–Й. Казан: ТӘһСИ, 2016. 748 б.


УДК 82

# ПРИЖИЗНЕННЫЕ ИЗДАНИЯ КАЮМА НАСЫРИ, ХРАНЯЩИЕСЯ В ФОНДЕ НАЦИОНАЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКИ ТАТАРСТАНА

***Л.Г. Халяфутдинова***
*Национальная библиотека Республики Татарстан (Казань)*

В статье представлен обзор прижизненных изданий Каюма Насыри, хранящиеся в фонде отдела рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан. Учёный-энциклопедист, писатель и просветитель К. Насыри – уникальная личность, оставивший после себя богатое научное, литературное и художественное наследие. Его произведения в области литературы, истории и педагогики, вклад в формирование литературно-научных норм татарского языка и достижение своих целей, несмотря на различные

трудности, сделали Каюма Насыри выдающимся учёным-энциклопедистом и просветителем.
**Ключевые слова:** просвещение, письменное наследие, литература, словари, календари.

The article gives an overview of the life editions of Kaium Nasiri, kept in the foundation of the section of manuscripts and rare books of the National Library of the Republic of Tatarstan. Scholar-encyclopaedist, writer and educator K. Nasiri is a unique person who has left behind a rich scientific, literary and artistic heritage. His works in the field of literature, history and pedagogy, his contribution to the formation of literary-scientific norms of the Tatar language and the achievement of his goals, despite various difficulties, made Kaium Nasiri an outstanding encyclopedic scientist and educator.
**Keywords:** education, written heritage, literature, dictionaries, calendars.

## ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ ФОНДЫНДА К. НАСЫЙРИНЫҢ ҮЗЕ ИСӘН ВАКЫТТА ДӨНЬЯ КҮРГӘН БАСМАЛАРЫ

***Л.Г. Хәләфетдинова***
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсе (Казан)*

Үзенең киңкырлы эшчәнлеге белән танылган, бөтен тормышын һәм талантын халыкка хезмәт итүгә багышлаган Каюм Насыйри әдәби мәйданга мәгърифәтчелек хәрәкәте җәелгән чорда килеп керә. Галим-энциклопедист, язучы, мәгърифәтче, педагог, нашир һәм яңа заман татар фәненә нигез салучы буларак Каюм Насыйри – фәнни, әдәби һәм сәнгати характердагы бай мирас калдырган уникаль шәхес.

1879 елдан башлап К. Насыйри үзен язучылык эшенә һәм фәнгә багышлый. Күләмле фәнни хезмәтләре һәм әдәби әсәрләре дә әнә шул елларда туа. Әдип үзенең барлык көчен китаплар, дәреслекләр язуга һәм ул хезмәтләрен бастыруга сарыф итә.

Әлбәттә, әсәрләр язу һәм аларны дөньяга чыгару эшендә К. Насыйри күп каршылыкларга очрый. Аны төрлечә хурлыйлар, куркыталар, ничек булса да бу эшеннән туктатырга телиләр. Ләкин заманының алдынгы кешеләре арасында К. Насыйриның хезмәтләрен танучылар, аның фикерләрен хуплаучылар табыла.

Филология, тарих, этнография һәм башка фәннәр буенча күп әсәрләр авторы буларак, 1885 елда ул Казан университетының Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлана. Шуның белән ул рәсми яктан фән эшлеклесе булып танылa.

Үзе исән чагында ук әдипнең 40 тан артык басмасы дөнья күрә. Шуларның кайберләре төрле елларда берничәшәр мәртәбә басыла. Алар арасында сүзлекләр, мәктәп-мәдрәсәләр өчен төрле уку әсбаплары, татар һәм рус теле, математика, геометрия, география, ботаника һәм башка фәннәр буенча татар телендә дәреслекләр дә бар.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Каюм Насыйриның үзе исән вакытта дөнья күргән 25 китабы, 6 календаре саклана. Алга таба безнең тарафтан кыскача тасвирлана торган китапларның, календарьларның һәммәсе дә Милли

китапханәдә бар, алар 1882–1901 еллар аралыгында Казандагы төрле матбагаларда, әлбәттә инде, гарәп графикасында дөнья күргәннәр. Китапханә фондына килеп керүләре төрле юллар аша булган: кайберләре археографик экспедицияләрдән алып кайтылган, бер өлеше аерым шәхесләр тарафыннан бүләк итеп бирелгән, букинистика кибетләреннән һәм коллекционерлардан сатып алынганнары да юк түгел. Сакланышлары да төрлечә: шактый тузган-таушалганнары, пычранганнары, карандаш һәм каләм белән язу-сызыклар, билгеләр төшерелгәннәре, шулай ук чиста-төзек хәлендә килеп җиткәннәре, соңгырак заманда яңача ысуллар белән каты тышлыкка төпләнгәннәре бар. Әлеге басмалардан кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә килүче галим-голяма, студент-аспирантлар, мәдрәсә шәкертләре, бик еш булмаса да, файдаланалар; хәзерге язуга күчерелгән һәм репринт вариантларын дөньяга чыгару максаты белән наширләр дә кызыксына.

К. Насыйри, беренче чиратта, татар теленең теоретик, грамматик һәм стилистик мәсьәләләрен үзләштергән, укыту методикасын булдырган галим-телче. Телче буларак ул шактый катлаулы, күпьяклы хезмәтләр башкара: татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын исбат итә, тел гыйлеме, сүзлекләр төзү буенча күп хезмәт куя.

Ул татар лексикографиясен югары биеклеккә күтәрә: татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр төзеп бастыра. 1892 елда дөнья күргән русча-татарча сүзлек XIX гасырның икенче яртысы сүзлекләре арасында аеруча әһәмиятле лексикографик хезмәт булып санала. 263 битле бу сүзлектә 18410 сүз теркәлгән. К. Насыйри бу сүзлекне белешмәлек һәм рус телен өйрәнүче татарларга уку ярдәмлеге рәвешендә төзегән. Кереш өлешендә галим бу сүзлекнең 35 еллык фәнни эшчәнлегенең нәтиҗәсе икәнлеген әйтеп үтә. Сүзлекне туплаганда ул тәрҗемә ысулын, параллель материаллар куллану һәм аңлатма бирү ысулын кулланып эш итә.

Сүзлек азагында, «Әлфаз әҗнәбия», ягъни «Чит телдәге сүзләр» дип аталган өлештә, К. Насыйри рус теленә башка теллардән кергән сүзләрне һәм терминнарны урнаштыра.

1895 елда «Ләһҗәи татари» – татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеген төзи. Сүзлекнең I томы (күләме 226 бит) – 1895 елда, II томы (күләме 106 бит) 1896 елда университет типографиясендә басылып чыга. Ул ун меңгә якын сүз, сүзтезмәләр һәм фразеологик әйтелмәләрдән гыйбарәт. Һәр сүз билгеле бер тәртиптә бирелгән. Иң элек татар телендә аңлатмасы, аннан гарәп-фарсы варианты, болардан соң сүзнең кулланышына мисаллар китерелә.

«К. Насыйри – гарәп, фарсы, төрек сүзләре урынына язма телдә татар теленең үз сүзләрен куллану кирәклеген беренче күтәреп чыккан галим. Фән теле – гарәп телендә, шигърият теле фарсы, госманлы төрек телендә булган чорда аның, язма тел татарның үз теленә нигезләнергә тиеш, дигән, заманыннан күпкә алдынгы карашлары замандашлары тарафыннан кискен тәнкыйть ителгән, кире кагылган. К. Насыйри төзегән ике томлы «Ләһҗәи татари» – телебезнең бай, куллану мөмкинлегенең киң булуын беренче дәлилләгән сүзлек. Бу сүзлек татар телендә генә түгел, ә бөтен төрки телләр тарихында беренче аңлатмалы сүзлек булуы белән дә әһәмиятле» [1: 165].

К. Насыйри шулай ук башлангыч белем өчен «Иршад әл әхба әли тәгълим әлифба» дәреслеген, «Кавагыйде китабәт» дип аталган, дөрес һәм матур язу кагыйдәләрен күрсәткән беренче кулланма да әзерли.

Әдип рус телен өйрәнү, рус телендәге китаплардан файдалану өчен кирәк булган уку китапларын төзү өстендә зур эш башкара. 1891 елда «Нәмүнә яки Әнмүзәҗ. Рус теленең уку кагыйдәләре вә дәхи сарыф вә нәхү кагыйдәләрен мөштәмил бер рисаләдер» дип аталган рус теле грамматикасын төзеп бастыра. Ул бер телне икенче тел белән чагыштырып, шул рәвешле рус һәм татар телләренең грамматикаларында булган үзенчәлекләрне өйрәнә.

Алда әйтеп үткәнчә, К. Насыйри төрле дөньяви фәннәрдән татар телендә дәреслекләр төзи. Нәкъ менә ул бу фәннәрнең нигезләре белән татар халкын ана телендә беренче булып таныштыра. Математика фәне буенча «Хисаплык», «Гыйльме һәндәсә» («Геометрия фәне») дип аталган дәреслекләр яза һәм бер үк вакытта татар телендә фәнни математик терминологияне төзи. Шулай ук ул һәр терминның мәктәп яшендәге балалар өчен аңлаешлы булуына игътибар итә. Математикага ул керткән күп сүзләр фәнни телдә нык урнашып, әле дә мәктәп дәреслекләрендә кулланылалар.

География фәне буенча «Истыйляхате җәгърафия» («География терминнары»), «Ысулы җәгърафияи кәбир» («Зур күләмле география») дәреслекләрен төзи. «Җәгърафияи кәбир» үзе өч кисәккә бүленеп бастырыла һәм аларда Африка, Азия кыйтгаларының һәм Гарәп ярымутравының географик үзенчәлекләре тасвирлана.

Аның ботаника һәм фармакология өлкәсенә караган китаплары бик күп файдалы мәгълүматларны үз эченә ала. «Гөлзар вә чәмәнзар» («Үләнлек вә чәчәклек») китабында К. Насыйри үләннәр һәм чәчәкләргә атамалар биреп, татарча исемнәрен булдыруга күп көч куя. Туган илебезнең киң табигать байлыкларыннан файдаланырга чакыра, башкаларлардан өмет итүне урынсыз саный: «Без, Русия халкы, ни өчен башка йорт халкына ялынамыз, ни өчен башка бер йорттан килгән даруларга мохтаҗ буламыз, кайчан ки үз җиребездә дәвага яраклы үсемлекләрнең һәммәсе бардыр. Хәтта мәмләкәтемездәге нәбатат вә дәваларның куәте башка йорттан килгән дәваларның куәтеннән артыграк, имеш, ләбаса! Үз җиребезнең дәвалары һәммәсеннән артык икән ләбаса!» – ди [3: 77].

«Хәвасе нәбатат» («Шифалы үләннәр») дип аталган китапта галим дәвалау үзлегенә ия булган үләннәрне өйрәнеп, һәрберсе хакында тәфсилле аңлатма бирә, алар белән дәвалау ысулларын тасвирлый. Кешедә еш очрый торган авыруларга тукталып, һәр авыруның төп үзенчәлекләрен сөйләп бирә.

Нинди генә фәнгә бәйле китаплар язса да, галим теге яки бу фән хакында мәгълүмат биргәндә, аның тормышта кулланылышына да нык игътибар иткән. Мәсәлән, «Санаигы галфания» китабы татар телендә металл эшкәртү технологиясе буенча беренче дәреслек буларак билгеле. Әдип үзе үк моны искәртеп үтә: «Мондаен мәнфәгатьле яңа фәннәргә каләм таратучы әүвәл мәртәбә мин булам» [3: 92]. Бу китапта К. Насыйри электрдан файдаланып, металлны эшкәртү юлларын өйрәтеп яза.

Моннан тыш, галим авыл хуҗалыгы, игенчелеккә караган «Зирагать гыйлеме», ризык әзерләү һөнәренә бәйле «Иршад әл-әтбиха» («Пешекче

өчен күрсәтмәләр»), анатомия һәм гигиенага караган «Мәнафигъ әгъза вә кануне сыйххәт» («Тән органнары функциясе һәм гигиена кагыйдәләре») кебек дәреслекләр төзеп бастыра.

Аның хезмәтләрендә балалар тәрбиясе, әхлак һәм тәрбия мәсьәләләре аерым урынны алып тора. «Әхлак рисаләсе» китабында әхлак һәм этика мәсьәләләре карала, галимнең педагогик карашлары яктыртыла. Гуманизм, өлкәннәргә хөрмәт, игелеклелек кебек әхлакый сыйфатларны тәрбияләүгә игътибар бирелә.

К. Насыйриның дин өлкәсенә караган хезмәтләре дә бар. «Гәкаид рисаләсе» – татар телендә Ислам тәгълиматы буенча дәреслек төзү өчен тәүге омтылышларның берсе булып тора. Китапның әүвәлге басмасы 1867 елда, ә икенчесе соңрак «Гәкаиде исламия» исеме астында дөнья күрә. Бу – К. Насыйриның дин өлкәсенә караган төп хезмәтләренең берсе. Монда ул Аллаһка ышану, Аллаһының күркәм исемнәре һәм Аның сыйфатлары, пәйгамбәрләргә ышану һәм аларның сыйфатлары, соңгы пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ышану, аның тәрҗемәи хәле һәм шәҗәрәсе кебек сорауларны күтәрә.

Шуны да искәртеп үтәргә кирәк, К. Насыйриның бу хезмәте татар мәдрәсәләрендә киң таралыш алмый. Галимнәр фикеренчә, хезмәт аңлау өчен шактый авыр телдә язылган, шулай ук күпләр галимнең рус телен өйрәнүгә караган эшчәнлегенә тискәре караштa булалар. Моңа бәйле рәвештә, мәгърифәтченең теологик карашлары үз замандашлары арасында яклау тапмый һәм дини уку йортларында да киң таралыш алмый.

К. Насыйриның матур әдәбият өлкәсендә дә әһәмиятле хезмәтләре бар. Бу өлкәдә ул каләмен төрлечә сыный: төрле телләрдән татар теленә тәрҗемә кыла, үзе әдәби әсәрләр яза, халык авыз иҗаты үрнәкләрен җыеп, аларны гыйльми нигездә эшләп бастыра. Язучы төрек, гарәп, фарсы телләрендә басылган әсәрләрне җентекләп сайлый һәм татар теленә тәрҗемә кыла.

«Кырык вәзир кыйссасы» – әдипнең бу өлкәдә беренче хезмәте. Бу әсәр тиз арада укучылар арасында тарала һәм күп тапкырлар кабат басыла. Әсәргә кергән хикәятләрнең күбесендә күркәм әхлакый сыйфатлар мактала. Ялганчылык, мәкерлек кебек тискәре сыйфатлар төрлечә фаш ителә.

«Әбугалисина кыйссасы» – әдипнең иң күренекле һәм киң таралган әсәрләреннән берсе. Ул аны 1872 елда эшләп тәмам итә. Легендар сюжетлы бу әсәр татарлар арасына күптәннән килеп керә. Ләкин гарәп һәм фарсы сүзләре күп булганга, гади халыкка әсәрне уку авырлык тудыра. Шуңа да К. Насыйри үз алдына әсәрнең телен җиңеләйтү максатын куя. Әсәр героеның прототибы – Урта Азиядә яшәгән бөек галим-фәлсәфәче, табиб Ибне-Сина. Төп каһарман үзенең белеме һәм сәләте белән кешеләргә ярдәм итә, шул рәвешле төрле сынауларны җиңә.

Татар телендә газета һәм журналлар бастыру омтылышы XIX гасырның башында ук күренә башлый. К. Насыйри татарлардан бу эшкә беренче булып керешә. Патша хөкүмәтенә ул «Таң йолдызы» исемле газета чыгару үтенече белән мөрәҗәгать итә. Ни кызганыч, аның теләге тормышка ашмый, үтенечен кире кагалар. Ләкин К. Насыйри өметен өзми, китап формасындагы өстәл календаре әзерләү эшенә керешә. «Аның беренче шундый календаре 1870 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыга.

1871 ел өчен календарь итеп чыгарылган бу китап Ибраһим Габдрәшид углы Абдуллин хисабына басыла.

Каюм Насыйри календарьлары шушы басмадан башлап 1898 елга хәтле 24 тапкыр басылып чыга. 1886, 1887, 1895 елларны исәпкә алмаганда, алар һәр елны басылып киләләр. 1883 елгысы – Петров ташбасмаханәсендә, ә калганнары барысы да университет типографиясендә хәреф җыю ысулы белән эшләнеп басылганнар» [2: 13].

Календарьда вакыт берәмлекләре турында белешмәләр китерелә. Кояш чыгу, кояш баю, намаз вакытлары, дини бәйрәмнәр күрсәтелә. Айлар, көннәр белән берrәттән гороскоп формасында белешмәләр дә китерелә.

К. Насыйри асторономия белән дә кызыксына. Бу өлкәдә булган белемнәрен ул календарь битләренә дә урнаштыра. Мәсәлән, 1883 елгы календарьда Кояш системасы, планеталар, Ай, Кояш тотылу турында тулы мәгълүмат бирә, схемаларын китерә.

Календарьларда Каюм Насыйри, Россия белән беррәттән, чит илләр географиясен яктыртуга да шактый зур урын бирә. «Календарьларда шундый тарихи, географик белешмәләр урнаштырып, Каюм Насыйри татар укучыларын җир йөзендәге халыклар, дәүләтләр, бөтен дөнья белән таныштыруны бурыч итеп куйган, аларны үзләренең анда тоткан урынын аңларга чакырган, дөньяга карашларын киңәйткән, киң мәгънәсендә аң-белем, мәгърифәт тараткан» [2: 22], – дип билгеләп үтә Ә. Кәримуллин үзенең бер мәкаләсендә.

Календарь битләрендә К. Насыйри татар халкының тарихы, теле, килеп чыгышына, халык авыз иҗатына бәйле материалларны да урнаштырган. Халык медицинасына караган мәгълүматлар, гигиена, дарулар, үләннәр хакында белешмәләр биргән.

Тәрбия, әхлак темасы да читтә калмаган. Бу өлкәгә караган киңәшләр, гыйбрәтле кыска хикәяләр аша календарь педагогик журнал функциясен башкарган. Ә. Кәримуллин календарьның тагын бер ягын ассызыклап: «Шунысына да игътибар итәргә кирәк: календарьга кергән материалларның күпчелеге халык теленә якын тел белән язылган. Моны да Каюм Насыйри аңлы рәвештә, календарьларының халыкка аңлаешлы булуын тәэмин итү өчен шулай эшләгән» [2: 26], – дип әйтә.

Бөтен гомере буе халкына фидакарьләрчә хезмәт иткән, милләт мәнфәгатен кайгыртуны үзенең яшәү кыйбласы итеп күргән татар галимнәре һәм әдипләре арасында Каюм Насыйри иң мөхтәрәм урыннарның берсен алып тора. Әдәбият, тарих, педагогикага караган әсәрләре, татар халкының телен әдәби-гыйльми калыпларга салуы, русча укытуга керешүе, төрле кыенлыкларга карамый үз максатларына ирешүе К. Насыйрины киңкырлы галим, мәгърифәтче итеп таныта.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Гаффарова Ф.* Татар телендә аңлатмалы сүзлекләр // Казан утлары. 2023. № 11. Б. 164–170.

2. *Кәримуллин Ә.* Каюм Насыйри календарьлары // Әйдә, халыкка хезмәткә! (Күренекле татар публицистлары). Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 200 б.

3. *Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Т. 2. 320 б.

УДК 821.512.145

# ЭВОЛЮЦИЯ ГЕРОЯ В РАССКАЗАХ ДИЛЬБАР БУЛАТОВОЙ

***А.Г. Халиуллина***
*УУНиТ (Уфа)*

В статье проводится анализ эволюции героя рассказов современной татарской писательницы Дильбар Булатовой. Рассматриваются психологические портреты, мотивации и роль героев в художественном мире её произведений, определены типологические черты героев и пути их преобразования. Основное внимание уделяется особенностям авторского подхода к созданию персонажей, их связи с ключевыми темами творчества Д. Булатовой – одиночеством, идентичностью и поиском смысла жизни в условиях современного общества.
**Ключевые слова:** современная татарская литература, проза Д. Булатовой, рассказы, персонаж, образ, герой, тип, характер.

The article analyzes the evolution of the hero of the stories of the modern Tatar writer Dilbar Bulatova. Psychological portraits, motivations and the role of heroes in the artistic world of her works are considered, typological features of heroes and ways of their transformation are determined. The main attention is paid to the peculiarities of the author's approach to creating characters, their connection with the key themes of D. Bulatova's work – loneliness, identity and the search for meaning in modern society.
**Keywords:** modern Tatar literature, prose by D. Bulatova, short stories, character, image, hero, type, character.

# ДИЛБӘР БУЛАТОВА ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ГЕРОЙ ЭВОЛЮЦИЯСЕ

***А.Г. Хәлиуллина***
*УФһТУ (Уфа)*

Язучы Дилбәр Булатованың «Туй», «Лифт», «Кунак мунчасы» кебек хикәяләреннән алып «Әйтмәдең...» һәм башка әсәрләренә кадәр аралыкта балачак хатирәләре дә, яшьлек хисләре дә, киләчәкне якты буяуларда чагылдырган хыяллары да, йөзъяшәр аксакал акылы да, теленең халыкчанлыгы да чагылып, балкып китә. Вакыйгалар тирән драматизм һәм психологик киеренкелек белән тасвирлана. Геройларының романтик характерлы, бай күңелле, ныклы рухлы, иманлы булуы үзәккә алынган конфликтны тагын да кискенләштерә, характерның рухи үсешен тәэмин итә.

Шәхси кичерешләр үзәккә чыгарылган «Бүген бездә коръән ашы» (1993) исемле беренче язмасында ук нәсер жанрының чалымнарын тоеп була. Чәчмә текст юллары арасында тоемланган эчке ритм, сүзләрнең үзара аваздаш (ритмик) яңгырашы композицион бөтенлеккә ирешергә мөмкинлек бирә. Нәсер жанрына хас үзенчәлекләрне авторның башлангыч чорда язылган «Зәңгәр күлдә өч торна», «Күлмәк», соңрак иҗат ителгән «Кунак мунчасы»нда да күрергә мөмкин. Иҗатчының табигать күренешләрен җанлы һәм кабатланмас итеп бирә белү маһирлыгын аерып билгеләми мөмкин түгел. Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Әмир һ. б. татар әдипләре традицияләре

рухында язылган бу әсәрләрдә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачу белән янәшә табигатькә мәдхия укыла, кеше һәм табигать арасындагы берлек, гомумгармония күрсәтелә.

Кызганыч, нәсер жанры үрнәкләрен язучы иҗатында башкача очратмыйбыз. Әмма шунсы кызыклы: югарыда аталган әсәрдә чалымланган мотивлар, дөньяны идеалистик күзаллау юнәлеше Д. Булатова иҗатында тәүдә тоем белән, аннан инде аңлы, субъектив рәвештә өстенлек алачак.

Безнең карашка, тормыш-яшәешне кətелмәгән ягы белән ача белү осталыгы Д. Булатова прозасын башкалардан аерып тора. «Хикәяләренең үзенчәлеге дә шунда – ул кеше тормышында беренче карашка әллә ни катлаулы булмаган вакыйга-күренешләрне тергезә, аларның герой күңелендә нинди нинди эз калдыруына игътибарын юнәлтә. Вакыйгалар экстремаль түгел, һәркем тормышында очрарга мөмкиннәр, әмма алар геройны тетрәндерү көченә ия» [6: 36].

Герой күнегелгән тирәлектән, тормыш агымыннан ят мохиткә, гадәти булмаган тирәлеккә эләгә. Һәм нәкъ шул чакта аның үз-үзен тотышы, уй-хәрәкәтләре аша күңел төбендә йөрткән, үзе дә белмәгән сыйфатлары балкып китә. «Лифт»та, мәсәлән – көндәлек ыгы-зыгы туктала, геройлар мәҗбүри рәвештә «читлек»тә – лифтка бикләнеп калалар һәм шушы шартларда гына горурлык калканнары җимерелеп, бер-берсенә күңелләрен ачалар. Үзара мөнәсәбәтләрдә ниндидер «кат»ка ирешү өчен еллар имтиханын үтәргә, сынау-авырлыклар кичерергә, якыныңны бөтен сыйфатлары белән, ничек бар, шулай кабул итәргә өйрәнергә кирәк икән. Шулай итеп, лифт – күңел баскычларыннан югарыга, яңа этапка күтәрелү мөмкинчелеген символлаштыручы образ ул.

«Күлмәк» хикәясе, авылларга кыргый капитализм мөнәсәбәтләренең үтеп керә башлавын сүрәтләп бирү белән беррәттән, рухи проблематиканы да күз уңында тота. Рәшит сабантуйда, чәмләнеп, талпынып, әлегә беркем дә менә алмаган туры колгага үрләп, мәйдан өстенә караш ташлый. Гади генә, хәтта мескен генә күренгән, яңа елдан соң сабантуй уңаеннан гына күпмедер эш хакы ала алган авыл иренең күңел матурлыгы шушы эпизодта бар тулылыгында ачыла. Ләкин тән дигәнең җиргә мохтаҗ, җирнең үз законнары. Анда төшкәч, Рәшит гүя кечерәеп, югалып кала, бүләккә очсызлы гына бала сандалилары алып, түгәрәктән чыгып китәргә ашыга. Хәзер инде ул гадәти «күлмәген» кия – өйрәнелгән, гадәттәге тормышын дәвам итә. Бу герой да «үсү, балалыктан чыгу» этабын үтә, аның беркатлылык, тиз ышанучанлык «чирен» сыйныфташы – үткен, елгыр Нәҗип бик тиз дәвалый.

«Бию» хикәясендәге Римнең «Күлмәк»тәге Рәшит белән байтак уртаклыклары бар. Төрле буын, иҗтимагый катлам вәкилләре булуларына карамастан, икесе дә, чиста-самими күңелле кешеләргә хас булганча, тиз ышанучаннар – «күлмәкләре бер кат кына», һәм икесе дә бер көн килеп, күңел тетрәнүе кичерәләр. Рим карт та йөрәксенеп Җыен тавына менә, ашкынулы хисләр буранында кала. Бәлки, ул гомер буе шул халәттә яшәгәндер дә. Гомер буе башкалар кубызына биергә дучар Рим картның шигырьләр язуы – тик үзенчә биергә, үз-үзен акларга, якларга омтылышы ул. Әмма чынбарлык нәзберек хыял һәм шигърият дөньясы, татлы истәлекләр белән исәпләшеп тормый. Сәер, әмма замана шаукымына ияреп кендек бию

биеп йөргән кызыкайда ул үзен танып ала. Рәшит («Күлмәк») сабакташыннан алданса, Рим үзен-үзе алдарга омтылып яшәгәнлеген аңлый. Аның шигырьләрен хәтта үз улы, оныклары да укымый бит.

«Кое»дагы геройларның хәрәкәт векторы инде, киресенчә, аска, җиргә таба юнәлгән. Биредәге кое образы, эчәр су чыганагы гына түгел, ул хикмәт, тормыш тәҗрибәсе туплау мәгънәсен дә үз эченә ала. Тереклек итәргә саф суны эзләп табу өчен таш-кырчын катламнарын үтеп, бик тирәнгә төшәргә кирәк булган кебек, иман, мәрхәмәтлелек, аек акыл сыман гүзәл сыйфатларның мәңгелек чыганагы да һәркемнең күңелендә бар. Һәм ул чыганакка һәркем үз юлы, омтылышы белән ирешә (Балбабай, малай), ә кемнеңдер инде, килеп җиттем дигәч тә, сабырлыгы төкәнә (эти образы).

Яңа экономик формация җимешләрен «Сакчы» хикәясендә дә күрәбез. Күләме буенча кечкенә хикәядә, карап торуга гадәти генә яшь егет, поликлиника бусагасын атлап керү белән, үзе дә сизмәстән, битарафлык, ачу, ярышу, тәкәбберлек, үз-үзеңне генә кайгырту кебек тойгыларны татый. Гадәти күренеш буларак кабул ителүче чират психологиясе, әшнәчелек мөнәсәбәтләре, ришвәтчелеккә шаһит булып кына калмый, тормыш дигән театрга үзе дә кушылып китә. Егет каршылыклы хисләр өермәсендә калса, сакчы ир – шартлар тоткыны. Өч тиенлек бахилалар сатып утырырга мәҗбүр гарип кеше белән әреплəшүе өчен оялу егеткә гомерлек сабак бирә, кешеләргә саграк карарга өйрәтә.

«Командировка» хикәясендә Рәсимә шәһәрдән авылга, ун балалы гаиләгә кайтып төшә һәм бөтенләй башка тормыш, омтылышлар, кыйммәтләр белән яшәгән кешеләр тормышына шаһит була. Тәэсирләнеп, ул үзенең тормышына анализ ясый һәм Мәрьям апаның яшәеш кануннары табигыйрәк тә, дөресрәк тә икәнлеген танырга мәҗбүр. Гаилә учагын саклаган, балалары өчен җан аткан, үз йортының патшабикәсе булган Мәрьям һәм каудыр, тынгысыз, эш белән гаилә арасында бәргәләнеп, нииндидер максатларга омтылып, нәрсәдер исбат итәргә азапланган Рәсимә – икесе ике дөнья кешеләре. Әйе, бу ике хатын-кыз үзара конфликтка кермиләр. Конфликт аларның тормышка карашларында, омтылышларында, җәмгыятьтә хатын-кызның тормыштагы урынына карата булган фикер аерымлыкларында. Уйлап карасаң, гасырлардан гасырларга өендә ире, балалары янында аш-су әзерләп, чигү чигеп, тегү тегеп гомер иткән, күп дигәндә, печән әйләндерергә, утауга йөргән татар хатын-кызы соңгы гасырда, «азатлык»ка ирешеп», ниләр генә кичермәде дә, нинди генә фаҗигаларга дучар булмады. Бүген ташландык балалар, исәпсез-сансыз абортлар, хатын-кыз эчкечелеге, ялгызаклар проблемасы, демографик кризис турында сөйлибез икән, бу социаль авыруларның төп тамыры – хатын-кызны гаиләдән аеруда, аны эш атына, ялтыравык реклама, мода колына әверелдерүдә икәнен танырга тиешбез. Бу уңайдан К. Кара әсәрләрендәге тискәре пландагы хатын-кыз образлары да хәтергә килә. Алар бит нәкъ шушы идеология җимешләре. Дөрес, Рәсимә әле яшь, алай ук зәһәрләнеп, җаһилланып өлгермәгән, һәм ул әле башка юлны да сайлый ала. Хикәядәге Алинә образына игътибар итик. Егерме балага бер тәрбияче билгеләнгән казна йортында әрнеп елап торып калган нарасыйның күңелендә «эшем иясе» әнисенә карата нинди тойгылар бөреләнер дә, балигъ булгач, ул үзен тормышта яклаулы тоя

алырмы, гаилә корырга ашыгырмы, корган очракта да сабыеның шундый ук кичерешләргә дучар булуын теләрме? «Онык»та инде шушы ук проблемалар кискенрәк, катлаулырак җирлектә чагылдырыла.

Д. Булатова хикәяләрендә төп герой, шулай итеп, ниндидер бер мизгелдә, башка рухи катламга күчә: ул гаҗәпләнә, газаплана, гарьләнә – көчле хисси тетрәнеш кичерә һәм бу аның арытабангы тормышына, холкына тәэсир ясамый калмый. Хәтта вакыт та гадәти агымын үзгәрткәндәй була. Әсәрнең кульминацион ноктасында аның җаны гүя, канат җилпеп, гадәти тормыш шартларыннан арынып, үткәнгә, хәзергегә, киләчәккә биектәнме, читтәнрәкме караш ташлап ала. Рәһинә («Онык»), Рәшит («Күлмәк»), Зөбәрҗәт («Зәңгәр күлдә өч торна»), Малай («Кое»), Фәрит белән Фәридә («Лифт»), Егет («Сакчы») – алар четерекле тормыш ситуацияләрендә чирканчык, сабак алучылар һәм, мөгаен да, бер ясаган ялгышларын башкача кабатламаслар. Әдәбият галиме Д. Заһидуллина билгеләвенчә, «еш кына язучы тормыш мәрхәмәтсезлеге белән очрашкан геройлар исеменнән хикәяли. Әмма шул мәрхәмәтсезлек калдырган тәэсирне олырак хакыйкать – яшәеш хакыйкате җиңә» [4].

Әйтергә кирәк, бу геройларны, уңай яки тискәре дип атаудан бигрәк, эзләнүче, үзләренең үсеш юлын үтүче геройлар дип билгеләү отышлырак булыр иде. Югарыда телгә алынган образлар, мәсәлән, калыплашкан фикерләүдән азат. Алар дөньяда үз юлын эзләүче, үз карашын формалаштырырга тырышучылар буларак гәүдәләнә. Һәм аларның яшь ягыннан чагыштырмача яшь булулары моны аклый да. Автор аларны кайчак самими, тәҗрибәсез сабыйлар кебек итеп кабул итеп, тасвирлауга юмор хисе дә кушып җибәрә. Үз максатлары, кабатланмас холыклары, үз җитешсезлекләре булган, тормышчан типлар иҗат итәргә омтыла.

Язучының герой идеалына килгәндә инде, алар башкарак «камырдан әвәләнгән». Ана образлары («Командировка»да – Мәрьям, «Кунак мунчасы»нда – картәни), Риза карт («Риза») – озын гомер юлы үтеп, акыл туплаган, тышкы һәм эчке гармониягә ирешкән шәхесләр. Боларның дөньяга карашын үзгәртү инде мөмкин түгел, эзләнүче образлардан аермалы буларак, алар автор тәкъдим иткән четерекле ситуацияне әзерлекле каршылыйлар, аңардан «егетләрчә» чыгалар (әрсез журналист белән очрашу («Командировка», «Риза»), йортны югалту («Кунак мунчасы»). Бу образлардан язучының кеше идеалын чалымларга була, ул – сабыр, шөкерле, тәкәбберлектән, мин-минлектән, гыйсьяный карашлардан азат. Әдәплелек, тышкы йомшаклык артында бернәрсә дә какшата алмаслык ышаныч хисен, иман ныклыгын сизми мөмкин түгел. Биредә авторның ислам карашларында торуының да йогынтысы зурдыр, мөгаен. Бәлки шуңадыр, аның геройлары дуамал романтик каһарманнар сыман, явызлыкның тамырын корытырга алынмыйлар, чөнки, дини ышанулар буенча, фани дөньяда явыз рух, ягъни шайтани көч кешелекнең һәрчак вәсвәсәчесе булачак.

«Риза» хикәясе тагын бер сыйфаты белән игътибарга лаек: XX йөз башы татар хикәяләрендә киң чагылдырылган фәлсәфә – үлем куркынычының яшәү кадерен белергә этәрүе идеясе – биредә яңа материалда чагылыш таба.

Ә инде эзләнүче геройлар әсәрләрдә үз нәфесләре белән көрәшергә мәҗбүр. Көнләшү, мин-минлек («Лифт»), комсызлык («Күлмәк», «Риза»),

тән ләззәте («Оның», «Туй», «Зәңгәр күлдә өч торна»), тәкәбберлек («Сакчы»), хәмер («Кое»), дан өмет итү («Бию») кебек тозакларга дучар булып, алар котылу юлын эзлиләр. Ә инде үз нәфесең белән көрәшү, ислам ышанулары буенча – көрәшнең зурысы.

Бу уңайдан «Ачык ишекләр көне»ндәге Зөбәер аерымлыкта тора кебек. Холык ныклыгын, кешелеклелек сыйфатларын җуймаса да, аның тәкъдирне усал дип кабул итүе, язмышы белән килешә алмавы, гомумән, әсәрнең объектив агымы геройның язмышка каршы көрәшүен сүрәтләү сыман аңлашыла башлый.

Хикәядә герой ут аша үтә. Бу образ хикәяләрдә аерым идея-эстетик вазыйфага ия. «Кунак мунчасы»нда (2009) автор кабаттан янгын образын куллана. Ләкин Зөбәерне ут битарафлык, төшенкелек хәлатенә төшерсә, соңгы хикәядәге карчык янгынны тәкъдиренә язылган сынау буларак кабул итә, гомум тырышлык белән яңа йорт та тергезелә. Ут образы, шулай итеп, шом, юкка чыгу куркынычын, котылгысызлык хисен чагылдыра. Дини мифологиядә дә бит тәмуг ут белән тәңгәлләштерелә. «Кунак мунчасы» хикәясе язучының башлангыч чор иҗатында язылган булса да, авторның кыска чәчмә әсәрләре арасында иң уңышлы һәм камил әсәрләрнең берседер. Бәхетле балачак хәтирәләре авырлыкларга бирешмәгән «нәнәйләр буыны»на соклану, мәдхия булып яңгырый.

Ә менә су образына, киресенчә, күпчелек очракта, чистарыну, котылуга, хикмәткә ирешү мәгънәсе йөкләтелә. Автор бу образның нинди генә чагылышларын бирми! «Зәңгәр күлдә өч торна» һәм «Кое»да, хикәяләрнең исеменнән үк аңлашылуынча, күл һәм кое, «Кунак мунчасы»нда – кар көртләре, «Туй»да – чишмә һ. б. Геройлар өчен дөнья кайчак шаян чишмә сыман көлеп тора, кайчак тыныч күлне, кайчак коенлы дуамал яңгырны хәтерләтә. Карга, бозга, парга әверелгәндә дә су үзенең үзенчәлеген югалтмаган кебек, күпчелек геройлар, нигездә, җан асылларына тугры калалар, аларның киләчәкләре өметле булып күзаллана. Хикәяләрнең исеменә килгәндә, күп очракта алар үз эченә төрле катламдагы мәгънә төсмерләре алган бер сүз белән генә бирелә. Һәм әсәрнең «ачкычы» да шул бер сүз эченә яшерелгән була.

Шактый соңрак язылган «Әйтмәдең…» (2019) хикәясе яшәеш кануннарының катлаулы булуын, чынбарлык белән хыялның капма-каршы килүен күрсәтә. Вакыйгалар ялгыз кеше фаҗигасы тирәсендә тупланып экзистенция ноктасына җиткерелә. Офиста эшләп йөргән хатын Лауранны хезмәттәшләре тормыштан канәгать, балда-майда йөзүче иркә хатын, баласының уңышларына шатланып көн итүче ана дип кабул итәләр. Башкалар көнләшерлек көнитеше белән ул фотосурәтләр аша таныштырып тора. Әмма чынбарлык Лаура якты дөньядан киткәч, аның белән хушлашырга баргач ачыклана: олы яшьтәге әтисе һәм улы белән яшәгән хатынның каты авыру белән көрәшүе, башкаларны борчырга теләмичә тыныч кына сүнә баруы фаҗиганы тирәнәйтә. Чынбарлыкның фотосурәтләрдә ясатып алынган ялтыравыклы тормышка кискен каршы куелуы укучыны уйланырга мәҗбүр итә: без соңгы көнгә кадәр хыяллар белән яшибез икән, күңелебез яхшылыкка, матурлыкка мохтаҗ. Гаҗизләнү һәм үкенү ноктасына җиткерелгән герой кичерешләре тирән психологик яссылыкта тасвирланган. Д. Булатованың күпчелек хикәяләрендә «XX йөз башы татар прозасыннан

килгән яшәү һәм үлем фәлсәфәсе яңа материалда чагылыш табып, җир тормышының фанилыгы хакындагы идея үткәрелә» [7: 654]

Күрүебезчә, Д. Булатова хикәяләрендә геройларның тышкы бәрелеше түгел, эчке конфликт күбрәк урын били, психологизм алымына, эчке сөйләмгә мөрәҗәгать ителә, реалистик сурәтләү ысулы кулланыла. «Кыскаҗыйнак хикәяләр халыкның җанлы сөйләме, персонажларның үз-үзен тотышындгы табигыйлек белән үрелеп» [5: 234] бара. Хисләр гаммасы артык ярсу, шашкын түгел, төсләр кулланылышы да җете, катгый орнаменттан бигрәк, ярымтоннарга, табигый колоритка ия реалистик пейзажны хәтерләтә.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Булатова Д.* Көлдән яралган гөл. Повесть, хикәяләр. Уфа: Китап, 2012. 232 б.

2. *Булатова Д.* Соң түгел… Повестьлар, хикәяләр. Уфа: Китап, 2019. 224 б.

3. *Булатова Д.* Туй: хикәяләр. Уфа: Китап, 2005. 144 б.

4. *Заһидуллина Д.* Чишмәләр – диңгезгә... URL: https://kazanutlary.ru/news/eraktagy-utlar/chishmlr-digezg (дата обращения: 04.05.2025).

5. *Халиуллина А.Г., Сулейманова Д.Д.* Туган як әдипләре. Башкортстанда хәзерге татар прозасы: шәхес, иҗат, тәнкыйть – Уфа: Китап, 2013. 320 б.

6. *Хәлиуллина А.Г.* Чиләккә йолдыз җыеп (Дилбәр Булатова хикәяләрендә герой эволюциясе) // Тулпар». 2011. № 1. Б. 36–37.

7. *Фазлетдинов И.К., Халиуллина А.Г., Сулейманова Д.Б.* Татарстаннан читтә иҗат ителгән әдәбиятта татар мотивлары (Башкортстан һәм Себердәге әдәбият) // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / [төз. Р.Ф. Рахмани]. 8 т.: 2001–2020 еллар / [ф. мөх-рләр: Д.Ф. Заһидуллина, Ә. М. Закирҗанов]. Казан: Фолиант, 2021. Б. 632–665.

УДК 821.512.145

# О 100-ЛЕТНЕМ ЮБИЛЕЕ К. НАСЫРИ

***А.Н. Хасанова***

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье представлен обзор публикаций по случаю 100-летия выдающегося татарского писателя, ученого и общественного деятеля Каюма Насыри из периодической печати начала XX века. Проведен краткий анализ данных статей, в которых освещаются основные события и торжественные акции в честь ученого. Впоследствии все эти публикации были опубликованы в виде отдельного сборника. На основе изученных материалов раскрывается вклад видных деятелей литературы и общественных организаций, таких как Г. Ибрагимов, Ф. Амирхан, Г. Рахим, Г. Баембитов, Х. Габидуллин, Н. Исанбет, М. Курбангалиев, А. Максуди и М. Парсин, а также Ш. Шаймарданова и других представителей татарской интеллигенции в организацию этих мероприятий. В их публикациях подчеркивается значимость широкомасштабной деятельности К. Насыри в контексте истории татарского народа, его вклад в развитие татарской гуманитарной науки как языковеда, литературоведа и ученого-историка.

**Ключевые слова:** К. Насыри, юбилей, мэджлис, Г. Ибрагимов, Г. Рахим, Г. Губайдуллин, 100-летие.

The article presents an overview of publications on the occasion of the 100th anniversary of the outstanding Tatar writer, scientist and public figure Kayum Nasyri from the periodical press of the early 20th century. A brief analysis of these articles is carried out, which highlight the main events and solemn actions in honor of the scientist. Subsequently, all these publications were published as a separate collection. On the basis of the studied materials, the contribution of prominent literary figures and public organizations, such as G. Ibragimov, F. Amirkhan, Gali Rahim, Gilemdar Baimbitov, Haji Gabidullin, Naki Isanbet, Mukhutdin Kurbangaliev, Akhmethadi Maksudi and Mukhammet Parsin, as well as Shaigardan Shaimardanov and other representatives of the Tatar intelligentsia participated in the organization of these events. Their publications emphasize the importance of K. Nasyri's large-scale activities in the context of the history of the Tatar people, his contribution to the development of Tatar humanities as a linguist, literary critic and historian. In addition, the article presents for the first time a handwritten summary of the anniversary, written in Arabic script and stored in the archive of the Lobachevsky Library in the rare Books and Manuscripts sector.
**Keywords:** K. Nasyri, jubilee, Mejlis, G. Ibragimov, G. Rahim, G. Gubaidullin, 100th anniversary.

## К. НАСЫЙРИНЫҢ 100 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ ХАКЫНДА

***А.Н. Хәсәнова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

Күренекле татар галиме, мәгърифәтче, энциклопедист Каюм Насыйриның (1825–1902) тууына быел 200 ел. Ул – XIX йөз татар мәгърифәтчеләре арасында иң алдынгы карашлысы. Кайсы гына өлкәне алма, К. Насыйри беренчеләрдән санала: ул – татар әдәби теленә нигез салучы, татар теле нигезләрен фәнни яктан башлап эшләүче; халкыбызның этнографиясен өйрәнүнең чишмә башында торучы, милли фольклорны туплап бастырып, аны башка халыкларга танытучы, моннан тыш хезмәтләре белән татар тарихы фәне формалашуына һәм үсешенә үзеннән зур өлеш кертеп, бай мирас калдырган галим.

К. Насыйри үзе исән чакта аның иҗатын фәнни яктан бәяләүчеләр бик аз була, аларның да күпчелеген шул чор рус шәркыятьче галимнәре тәшкил итә. 1902 елда «Тәрҗеман» газетасында басылган «Габделкаюм әфәнденең вафаты» исемле некрологын исә без шул юнәлештә татар фикер ияләре тарафыннан язылган беренче язма дип билгели алабыз. Анда мәгърифәтченең тәрҗәмәи хәле һәм гыйльми эшчәнлеге кыскача гына яктыртыла, аның чирек гасыр дәвамында татар телендә календарь бастыруы махсус билгеләп үтелә [10: 6–7].

К. Насыйри үлгәннән соң ун ел үткәч, күренекле тарихчы, филолог, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Габделбари Баттал беренчеләрдән булып көндәлек матбугатта Каюм Насыйри эшчәнлеге турында язып чыга. «Йолдыз» газетасының 1912 елгы 11 октябрь санында «Телемез» исемле күләмле мәкаләсендә К. Насыйрины «үз арабыздан чыгып, үз телебезне тергезү нияте белән кулына каләм тоткан затларның ин олугысы» дип күрсәтә. Аны «телебезгә иткән хезмәтләре ягыннан әдәбият тарихыбызда иң беренче урынны тотарга лаеклы бер зат» дип атый [5: 111–112]. Автор галимне русларның Дале белән бер баскычка куя. К. Насыйриның исеме

онытылып барганлыгына борчылуын белдереп, аның тормыш юлын һәм хезмәтләрен өйрәнергә кирәклеген ассызыклый. Татарлар арасыннан чыккан мондый «тырыш вә эш сөюче кеше булган бу затны, ни өчендер, халкыбыз тәкъдир итә алмый» дип ачынып яза. «Шура» журналының баш сәхифәләрендә төрле гарәп, фарсы галимнәренең биографиясенә һәм эшчәнлегенә багышланган мәкаләләрнең күп булып та, шул ук вакытта К. Насыйри кебек олуг затка матбугат битләрендә игътибарның булмавына, татар милләте арасында исеменең онытыла баруына ризасызлык белдерә. Ш. Мәрҗанигә багышлап быстырылган мәҗмуга бөек шәхеснең исемен тергезгән кебек, әлеге олуг галимнең исеме дә тергезелер, аңа багышлап хезмәтләр язылыр дигән өметтә кала. Моңа җавап буларак «Шура» журналы мөхәррире Ризаэтдин Фәхретдин мәгърифәтче турында бастырырга материал юклыгын белдерә һәм галим турында мәгълүматлы кешеләрдән журналга материал җибәрүләрен үтенә. Нәтиҗәдә, «Шура»ның 1912–1913 елгы саннарында мәгърифәтче галим турында замандашлары, татар укымышлылары, дин эшлеклеләре Ризаэтдин Фәхретдин [27], Нуретдин Ишаев[12], Галимҗан Акчурин [1], Гарифулла әл-Чокрый [30], Мөхәммәтнәҗип Түнтәри [25], Мөхәммәтхәнәфи [20] һәм Мөхәммәткамал [21] Мозаффаровлар, Габдулла бине Таҗетдин әл-Кәчимири [15], Насретдин әл-Хуҗаши [28], Миргазиз Укмаси һәм Һади Таһириның [25] истәлек-хатирәләре дөнья күрә. Замандашлары К. Насыйри үзе исән чакта, аның татар фәненә һәм мәдәниятына керткән өлеше тиешенчә бәяләнмәве, вакытлар үткәч кенә, аның мирасының нинди зур әһәмияткә ия булуы ачыклануын билгеләп үтәләр.

Сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы Шәйхулла Алкин 1912 елда «Аң» журналы битләрендә К. Насыйриның этисе Габденнасыйрга, туганнарына һәм төрле кешеләргә юлланган хатларын бастырып чыгарган була [2: 14–15]. Автор әлеге хатларны бер авылда чормада табып алуы, алар бик күп булып һәм эчтәлекләре бер төрле булу сәбәпле, шуларның сигезен генә укучылар игътибарына тәкъдим итүе турында язып куя, аларның галим биографиясе белән кызыксынучы укучыларга кызыклы булачагын искәртә.

К. Насыйри иҗатын профессиональ тикшерүнең яңа омтылышы 1917 елда күзәтелә. Гыйзетдин Сәйфелмөлеков җитәкчелегендә бер төркем милли зыялылар галимнең туган авылы Югары Шырданнан Казанга аның архивын алып кайта. Бу материаллар К. Насыйриның энесе – мәрхүм имам Габделкавиның тол җәмәгатен кияүгә алган авыл мулласы Нургалидә саклнган. Насыйри биографиясен язуны әлеге иҗат төркеме Җамал Вәлидигә йөкли. Мәгърифәтченең биографиясен язу өчен, архивны үзенең туган авылы Апазга алып кайтса да, Октябрь инкыйлабыннан соң төбәктә барган вакыйгалар, Гражданнар сугышы һәм башка хәлләр аркасында Җ. Вәлиди иптәшләре кушкан йөкләмәне башкарып чыга алмый [7: 14].

Татарстан Җөмһүрияте төзелгәч, 1920 елларда К. Насыйрины өйрәнүнең яңа дулкыны күтәрелә. Совет идиологиясе нигезендә К. Насыйрины галим һәм календарь төзүче буларак кына күрсәтеп, аның дини хезмәтләре онытыла, яшерелә һәм фәнни тикшерүләр мәйданнынан төшереп калдырыла. Шул чорда галим һәм аның эшчәнлеген мәңгеләштерүгә багышланган төп эшләрнең берсе булып аның тууына – 100 һәм вафатына 20 ел тулу уңаеннан чаралар үткәрү тора.

XX йөздә К. Насыйрины кадимчеләр һәм җәдитчеләр арасында калган мәгърифәтче галим буларак өйрәнгәннәр. Аның Казан дини семинариясендә татар теле укытучысы булып эшләве, XIX йөзнең икенче яртысында гыльми хезмәтләр язуы һәм календарьлар бастыруы аерым билгеләнә. К. Насыйри җәдитчелек идеяләренә идеаль туры килгән, чөнки аның рус телен, дөньяви фәннәрне белүне алга сөрүе, аларның гамәли кулланылышын пропагандалавы, Совет хакимияте өчен кулай булган. Шуңа күрә дә галимнең эшчәнлеген өйрәнү, шул чорның башка күренеклеләре белән чагыштырганда, алгырак планга чыгарыла, аның туган һәм үлгән елларын бәйрәм итү традициясе башлана. Бу чаралар татар милләтенең үзбилгеләнүе, тарихи хәтерне саклап калу ягыннан да кыйммәтле була.

Совет чорына кадәр мөселманнар арасында үлем көнен генә билгеләп үтү булган. Шуңа нисбәтле совет властенең беренче елында да башта К. Насыйриның вафатына 20 ел тулу датасы уздырыла. Юбилей чараларына бәйләп, концерт, фәнни конференция, күргәзмә кебек чаралар үткәрү традициясе барлыкка килә.

1922 елда Галимҗан Ибраһимов галимнең мирасын барлау һәм саклау эшенә керешә. 1922 елны «Татарстан» газетасының 19 май санында галимнең «Каюм Насыйриның вафатына егерме ел тула» исемле мәкаләсендә галимне «үлгәннән соң да, үзе хаклы булган дәрәҗәдә әһәмият бирелгәне – әсәрләре, хезмәтләре, тәрҗемәи хәлләре гыйльми рәвештә тикшерелеп, гомумнең файдалануы өчен мәйданга куелганы юк әле», дип язылa [8: 133–140]. Г. Ибраһимов 1922 елның 13 июнендә Татарстан Мәгариф халык комиссарияты каршындагы Гыйльми Үзәк утырышында доклад белән чыгыш ясый, һәм шуның нигезендә 1922 елда К. Насыйриның вафатына 20 ел тулуны 2 сентябрьдә искә алу кичәсе итеп уздыру турында карар кабул ителә. Әлеге кичәне оештыруны өч кешедән торган комиссиягә йөкләлиләр. 1922 елның маенда комиссия рәисе итеп – Г. Ибраһимов, әгъзалары итеп Сәлах Атнагулов һәм Газиз Гобәйдуллин билгеләнә [10: 727–728]. Аларга галим хакында җыентык әзерләү эше йөкләнә. Иң җаваплы эшне – галимнең тулы тәрҗемәи хәлен язуны – комиссия Гали Рәхимгә тапшыра. Шулкадәр кыска вакыт эчендә Каюм Насыйри кебек киң кырлы эшчәнлек алып барган шәхеснең тулы биографиясен эшләү җиңелдән булмый. Г. Рәхим фикеренчә, моңарчы өйрәнелмәгән, таркау материалларны бергә җыю, эшкәртү, җитмәгән фактларны барлау әлеге эшне катлауландыра [29: 288]. Әле Җ.Вәлиди һәм Г.Сәйфелмөлеков тарафыннан 1920 елларда ук җыелган материаллар нигезендә, шулай ук галимнең туган авылы Югары Шырданга булып, аның туганнары, кардәшләре белән очрашу нәтиҗәсендә бай фактик материал тупланып, галимнең тәрҗемәи хәле беренче тапкыр юбилей уңаеннан нәшер ителгән «Каюм Насыйри мәҗмугасы» исемле җыентыкта урын ала [23: 42–81]. Ләкин әлеге җыентыкта китерелгән текст комиссия рәисе Г. Ибраһимов тарафыннан шактый кыскартылып бирелү сәбәпле, галим шул ук елны «Безнең юл» журналында К. Насыйриның тәрҗемәи хәлен, җыентыкта төшереп калдырылган мөһим урыннарны өстәп, яңадан бастыра [22: 56–62].

Җыентыкта шулай ук К. Насыйриның рәссам Госман Арсланов тарафыннан 1920 елларда ясалган беренче портреты урын ала. Соңрак галимнең йөз еллык юбилеен бәйрәм итү кичәсендә күренекле татар язучысы

Фатих Әмирхан әлеге портретның оригиналга охшамаганлыгын билгеләп үтә, шул сәбәпле җыелыш вакытында галимнең яңа портретын ясау турында карар кабул ителә. К. Насыйриның тууына 120 ел тулуны билгеләп үтүгә әзерлек вакытында рәссам Байназар Әлминов тарафыннан чордашлары истәлеге нигезендә яңа портрет иҗат ителә.

Юбилей җыентыгында Г.Ибраһимовның ике мәкаләсе урнаштырыла: Каюм Насыйриның татар халкы тарихындагы урыны турында «Каюм Насыйриларның тарихи урыннары» [9: 138] һәм яңа татар әдәби теленең формалашуы хакында «Яңа әдәби татар теленең беренче баскычларында» мәкаләләре. Шулай ук Әхәт Гаффарның «Рус матбугатында Каюм Насыйри», Газиз Гобәйдуллинның «Каюм Насыйриның гыйльми-тәгълими хезмәтләре» һәм «Насыйри чын гыйльми-фән бабында» мәкаләләре, Хуҗа Бәдигыйның «Каюм Насыйриның халык әдәбиятын җыю һәм тикшерү юлында хезмәтләре» һәм Җамал Вәлидинең «Каюм Насыйрида татар теле» дигән мәкаләләре урын ала, Каюм Насыйриның «Казан татарларының ышанулары һәм ырымнары (борынгы шаманизм калдыклары)» исемле хезмәте рус телендәге басмасыннан тәрҗемә ителеп бастырыла [13].

К. Насыйриның тууына йөз ел тулу уңаеннан юбилейга әзерлек эшләре алда әйтелгәнчә, инде 1920 еллар да ук башлана. Галимнәрдән, мәдәният, мәгариф вәкилләреннән һәм җәмәгать эшлеклеләреннән торган инициатив төркемнәр бәйрәм планнары турында актив фикер алыша. Юбилей чараларының төп бурычлар булып: 1) Каюм Насыйриның шәхесен мәңгеләштерү; 2) фәнни тикшеренүләр үткәрү, аның мирасын барлау һәм системага салу, тормышы һәм эшчәнлеге турында хезмәтләр һәм материаллар бастырып чыгару; 3) мәдәни чаралар: юбилейга багышланган күргәзмәләр оештыру тора.

Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми Үзәкнең татар редакциясе коллегиясе тарафыннан 1925 елның 10 феврале утырышында, Каюм Насыйриның тууына йөз ел тулуны билгеләп үтү мәсьәләсе тикшерелеп, түбәндәге карарлар кабул ителә: «1) Йөз ел тулган көнне Каюм Насыйриның шәхесе белән киң катлауны таныштыру, аның ролен ачыклау һәм хезмәтләрен барлау максатында зур ачык җыелыш уздырырга. 2) Журналистика институтында Каюм Насыйри исемендәге стипендия булдыру хакында ТАССР Мәгариф халык комиссариаты коллегиясенә юллама белән мөрәҗәгать итәргә. 3) 4 нче Евангелистлар урамы аталышын Каюм Насыйри исеменә алыштырырга. Бу көнне билгеләп үтү өчен тиешле оешмаларга мөрәҗәгать итәргә. Йөз ел тулу көнен билгеләп үтү өчен комиссия төзүне Академүзәккә йөкләргә. Программаны нигездә кабул итәргә, аны детальләштерүне һәм үткәрүне шул ук комиссиягә тапшырырга»[10: 727–728].

Юбилейга әзерлек вакытында комиссия алдына галимнең төгәл туган елын ачыклау мәсьәләсе куела. Моңа нисбәтле, гыйльми Үзәк секретаре Заһид Нуркин «Кызыл Татарстан» газетасының 8 февраль санында татар җәмәгатьчелегенә мөрәҗәгать бастыра: юбилейга багышлап чыгасы мәҗмугага һәм гомумән вакытлы матбугатка галим турында булган яңа материалларны бирүләрен үтенә. Әлеге мөрәҗәгатькә җавап рәвешендә «Безнең юл» журналының 1925 елгы 3 номер март санында Зөя кантоны Насыйри исемендәге II баскыч мәктәпнең бер укытучысы яңа мәгълүмат җиткерә.

«Борынгы заманның галимнәре үз йортларында булган зур вакыйгаларны китап читләренә язып баралар, туган-үлгәннәрне дә шунда теркиләр иде. Каюмның әтисе Габденнасыйр да "Әмин тәзәк" дигән кульязма әсәренең тышына 1813 тән 1866 гача шулай язып барган». Гыйльми үзәккә җыбәрелгән әлеге хатта: «... Габденнасыйрның 1823 нче елда Габделкаюм исемле улы дөньяга килеп, 1824 нче ел февраль 5 ндә үлә. 1825 нче ел февраль 2 ндә Габделкаюм сани (Насыйри) дөньяга килә. Димәк, Каюм бабаның туганына 100 ел 1924 нчедә булмыйча, 1925 нче елда икән», – дигән җөмләләр китерелә [14: 112]. Хатның язылу датасы итеп 1925 елның 23 гыйнвары күрсәтелгән. Туган елына карата булган буталчыклык та 100 еллыгына әзерләнү процессында шул рәвешле ачыклана.

1925 елның 15 февралендә К. Насыйриның тууына 100 ел тулу мөнәсәбәтле Татарстан Җөмһүрияте җитәкчелеге һәм Гыйльми Үзәк тарафыннан Татар дәүләт театры бинасында зур җыелыш уздырыла. Театр залы халык белән шыгырым тулган була. Театрның бер залында К. Насыйриның басылган китапларыннан тыш кульязма хезмәтләре дә, шул исәптән аның үз кулы белән төзелеп, Суфия Таһирия кулында сакланган шәҗәрәнең күчермәсе һәм аның турында вакытлы матбугат битләрендә чыккан мәкаләләр дә күрсәтелә. Бу күргәзмә аның татар халкының тарихына, әдәбияты һәм теле үсешенә керткән өлешен ачык күзалларга мөмкинлек бирә. Сәхнәнең уртасына галимнең рәссам-графист Госман Арысланов ясаган портреты эленә.

Җыелышны Гыйльми Үзәк рәисе Галимҗан Ибраһимов «Каюм Насыйриның тарихи роле» докладлы белән ача. Татарларның мәдәни күтәрелешендә К. Насыйриның чиктән тыш зур роль уйнавы, татарның беренче реформаторы булуы турында сөйли. Шул сәбәпле Татарстан Җөмһүрияте аңа тиешле кыйммәтен куеп мондый төр юбилейларның әле революциядән соң беренче тапкыр уздырылуы хакында әйтеп уза.

ТАССР мәгариф халык комиссары Шәһит Әхмәдиев Татарстан Җөмһүрияте Үзәк Башкарма Комитеты рәисе Шәйгәрдан Шәймәрданов һәм Халык Комиссарлары Советы рәисе Хаҗи Габидуллин имзалаган котлау хатын укый. Каюм Насыйри исемен мәңгеләштерү юнәлешендә түбәндәге эшләрне башкарырга карар кылыну хакында хәбәр итә: «1) Мәскәүдә Журналистлар институтында Насыйри исемендәге стипендия билгеләргә; 2) Татар тәгълим-тәрбия техникумын Насыйри исеме белән атарга; 3) Казанда Евангелистовский һәм Яңа Бистәдә Большой Симбирский урамнарын Насыйри урамы дип атарга [30: 128]; Насыйри әсәрләрен сайлап бастырырга». ТАССР Мәгариф халык комиссариатының 1925 ел 24 февраль карары нигезендә Татар педагогия техникумына Каюм Насыйри исеме бирелә [10: 728–729].

Мөхәммәт Парсин «Насыйриның биографиясе» исемле докладында галимнең тормыш юлына һәм эшчәнлегенә кыскача тукталып үтәм [21: 129–130]. Гали Рәхим «Насыйриның гыйльми-фәнни хезмәтләре» дигән докладында галимнең фән-гыйлемне халыклаштыру юлындаы эшчәнлегенә туктала һәм тарих, еорафия, хисап, һәндәсә, табигать, үсемлек, космография, агрономия һәм техника фәннәре турында язан китапларын саный. Аның язганнарыннан шул чор шәркыятьче рус галимнәренең дә файдаланганлыгын ассыклый [24: 82–84].

Мөхетдин Корбангалиев «Насыйриның имля, әдәби тел турында хезмәтләре» докладында галимнең хәзерге татар әдәби телен формалаштыруда эшләгән эшләре турында чыгыш ясыйлар һәм, Насыйри укучысы буларак, аның педагогик традицияләрен дәвам итүенә басым ясый [16: 119–122].

Әхмәтһади Максуди, К. Насыйри турында истә калганнарын сөйләгәндә, аның биографиясен язарга җыенган вакытта аннан түбәндәге сүзләрен ишетүне сөйли: «Мине ач вакытта карамадыгыз. Инде яшем җитмешкә җиткәч, миңа аның нинди әһәмияте бар?» Чыгышын: «Әгәр дә Насыйри булмаган булса, Татарстан Җөмһүрияте хәзерге шикелле булмас, бәлки мәдәняттә артта калган бер өлкә генә булыр иде», – дип тәмамлый [18: 131].

Әлеге җыелышта Фатих Әмирхан Заһид Нуркин, Хәйретдин Вәлиев, Нәкый Исәнбәт һәм башка күренекле фән, мәдәният һәм җәмәгать эшлекләренең чыгышлары да тыңлана. Җыелышка килгән халыкның сыймавы, мәҗлес чиктәш тыш җанлы һәм күңелле үтүе турында Г. Латыйф үзенең «Насыйри турында истә калганнар» исемле мәкаләсендә язып калдыра.

Мондый юбилей җыелышлары Казанда гына түгел, шулай ук Мәскәү һәм Уфада да уздырыла [4: 133].

Гыйльми үзәк коллегиясенең 1925 ел 26 март утырышы карары белән ТАССР Халык Комиссарлары Советы күрсәтмәсе буенча К. Насыйриның тууына 100 ел тулу уңаеннан аның мәҗмугасын төзү эше Г. Ибраһимовка йөкләнә. Аңа юбилярның тууына 100 ел тулуга багышланган материаллар, галимнең нәшер ителмәгән хезмәтләре, Г. Гобәйдуллинның әлеге басылмаган хемәтләре турында мәкаләсе керергә тиеш була [10: 734–735]. «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм йөз еллык бәйрәм материаллары» дип аталган мәҗмуга 1926 елда дөнья күрә.

Җыентыкта Г. Ибраһимовның «Башлангыч», «Каюм бабаның йөз еллыгы», Газиз Гобәйдуллинның «Насыйри кулъязмаларының гыйльми кыйммәтләре турында», Мөхетдин Корбангалиевнең «Каюм Насыйри турында истәлекләр», Гыйлемдар Баембитовның «Каюм Насыйрига 100 ел тулу белән», Фатих Әмирханның «Бу рухта беренче...», Гариф Латыйфның «Насыйри турында истә калганнар» исемле мәкаләләре һәм мәгърифәтчене искә алу чаралары турында көндәлек матбугатта басылган материаллар урнаштырылган. Бу җыентыкта галимнең кулъязма хәлендә калган берникадәр хезмәтләре дә кертелә, аларны Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллин кебек галимнәр өйрәнеп, эшкәртеп җыентыкта бастырырга әзерли. Г. Гобәйдуллин тарафыннан галимнең Казан университеты китапханәсендә саклануы 4 кулъязма әсәре барланып, «Насыйри кулъязмаларының гыйльми кыйммәтләре турында» исемле мәкаләсе дә урын ала [6: 60–80]. Г. Рәхим тарафыннан галимнең Казан татарлары хакында этнографик мәгълүматлар туплаган кулъязмасы тикшерелеп, рәткә китерелеп «Татар этнографиясе материаллары» исеме астында басыла. Шулай ук җыентыкта югары фәнни камиллектә әзерләнгән, иске әдәбиятыбызның кулъязма хәлендә калган ядкәрләре булган, Каюм Насыйриның 1880 елларда язылган һәм моңарчы басылмаган «Казан тарихы турында (Халык сөйләве буенча)», «Аксак Кара тун, Пугачев һәм Ишбулат мул ла хакында риваятьләр», «Археология материаллары (Зөя өязе авыллары буенча)», «Татар этнографиясе материаллары» дигән хезмәтләре кертелә.

1925 елда Каюм Насыйриның 100 еллык юбилеен билгеләп үтү, шул чорда татар җәмәгатьчелеген мәдәни мираска һәм аны саклауга хөрмәт тирәсенә берләштерүче мөһим вакыйгага әверелә. Юбилей уңаеннан уздырылган чаралар күренекле татар галимнең истәлеген мәңгеләштереп кенә калмыйча, аның мирасын өйрәнү өчен яңа офыклар да ача. Бүгенге көндә дә Каюм Насыйри һәм аның хезмәтләре киләчәк буыннарны илһамландыруын дәвам итә, һәм аның идеяләре хәзерге җәмгыятьтә дә актуаль булып кала бирә.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Акчурин Г.К.* Насыйриның тәрҗемәи хәле хакында кайбер мәгълүматлар // Шура. 1912. № 23. Б. 3.

2. *Алкин Ш.* Каюм Насыйри хатлары // Аң. 1912. № 1. Б. 14–15.

3. *Әмирхан Ф.* Бу рухта беренче... // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926. Б. 124–126.

4. *Баимбетов Г.* Мәскәүдә Насыйри кичәсе // Эшче. 1925. 15 февр.; *Баимбетов Г.* Мәскәүдә Насыйри кичәсе // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926. Б. 133.

5. *Баттал Г.* Телемез // Йолдыз. 1912. 23 сент. № 884; 11 окт. (№ 892); *Баттал Г.* Телемез // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Габделбари Баттал. Сайланма әсәрләр. Т. 1. / [төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Ш. Гарипова, А.Н. Хәсәнова, Г.М. Ханнанова; кереш сүз авт. А.Н. Хәсәнова]. Казан, 2023. Б. 111–112.

6. *Гобәйдуллин Г.* Насыйри кулъязмаларының гыйльми кыйммәте // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926. Б. 60–80.

7. *Заһидуллин И.* Великий татарский просветитель Каюм Насыри. Казан: Татар. кн. изд-во, 2024. С. 14.

8. *Ибраһимов Г.Г.* Каюм Насыйриның вафатына егерме ел тула // Ибраһимов Г.Г. Әсәрләр: 15 томда. 10 т.: Татар тел белеменә һәм телне укыту методикасына караган хезмәтләре / [төз. текст., иск. һәм аңлат. әзерл.: Э.М. Галимҗанова, Ф.Г. Фәйзуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. Б. 6-7.

9. Ибраһимов Г.Г. Каюм Насыйриның тарихи урыннары // Ибраһимов Г.Г. Әсәрләр: 15 томда. 12 т.: тарих һәм иҗтимагый фикергә караган мәкаләләр, хезмәтләр (1922-1932) / [төз.: Г.М. Ханнанова, Г.А. Хөснетдинова; текст. әзерл.: Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова, Э.М. Галимҗанова; иск. һәм аңлат. әзерл.: Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова, К.Г. Ахсанов; кереш сүз авт. К.Г. Ахсанов]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. Б. 138.

10. *Исламов Р.* Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / төз. Р.Ф. Исламов. Казан: Җыен, 2017. Б. 727–728.

11. *Исхакый Г.* Габделкаюм әфәнденең вафаты // Тәрҗеман. 1902. 15 сентябрь; *Исхаков М.Г.* Габделкаюм әфәнденең вафаты // Исхаков М.Г. Әсәрләр: 15 томда. 6 т.: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре / [төз.: З. Рәмиев, Ф. Ибраһимова; текст. әзерл. Ф. Ибраһимова; иск. һәм аңлат. язучы З. Рәмиев]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 6–7.

12. *Ишаев Нуретдин*. Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр // Шура. 1912. № 22. Б. 694.

13. Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга / ред. Һәйят. Казан: Т.С.С.Җ. дәүләт нәшр., 1922. Б. 160.

14. Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926. Б. 135.

15. *Кәчимири Габдулла Таҗетдин*. Габделкаюм ән-Насыйри // Шура. 1913. № 10. Б. 292–293.

16. *Корбангалиев М.* Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926. Б. 119–122.

17. *Кустрамавый М.-Нәҗип*. Габделкаюм ән-Насыйри хәзрәтләре тәрҗемәи хәленә гаид // Шура. 1913. № 8. Б. 233–237.
18. *Латыйф Г.* Насыйри турындаистә калганнар // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926. Б. 131.
19. *Мозаффар Мөхәмммәткамал.* Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр // Шура. 1912. № 23. Б. 719–720.
20. *Мозаффар Мөхәммәтхәнәфи*. Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында // Шура. 1913. № 6. Б. 172–175.
21. *Парсин М.* Насыйриның биографиясе // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926. Б. 129–130.
22. *Рәхим Г.* Насыйриның тәрҗемәи хәленә гыйлавә // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия / редкол.: И.Г. Гомәров (проект җит. һәм җав. мөх-р), З.З. Рәмиев, А.М. Ахунов; төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова. Казан: ТӘһСИ, 2020. Б. 81–88.
23. Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия / редкол.: И.Г. Гомәров (проект җит. һәм җав. мөх-р), З.З. Рәмиев, А.М. Ахунов; төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова. Казан: ТӘһСИ, 2020. Б. 42–81.
24. *Рәхим Г.* Татар этнографиясе материаллары // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926. Б. 82–84.
25.*Таһири Һади.* Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр // Шура. 1912. № 23. Б. 719.
26. *Түнтәри Мөхәммәтнәҗип.* Габделкаюм Насыйри хакында хатиратым // Шура. 1913. № 3. Б. 72.
27. *Фәхретдин Ризаэтдин.* Габделкаюм Насыйри. («Асар»дан күчерелде). (Мәшһүр адәмнәр вә олуг хадисәләр) // Шура. 1912. № 21. Б. 641–645.
28. *Хуҗҗаши Насретдин.* Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри илә мөсахәбә (хатирә дәфтәремнән) // Шура. 1912. № 24. Б. 745–748.
29. Хуснутдинова Г.А. Фәнгә хезмәт итеп... // Актуальные проблемы тюркологии: Россия и тюрко-мусульманский мир: X Междунар. тюркол. конф. (г. Елабуга, 25 декабря 2020 г.) / отв. ред. А.З. Нигамаев. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2021. С. 287–289.
30. *Чокрый угылы Гарифулла.* Габделкаюм ән-Насыйри // Шура. 1913. № 5. Б. 141–142.
31. *Шәймәрданов Ш., Габидуллин Х.* Татарстан хөкүмәте хаты // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926. Б. 128.

УДК: 894.343:398.22

# ОТРАЖЕНИЕ И РАЗВИТИЕ ФОЛЬКЛОРНЫХ ТРАДИЦИЙ В ТВОРЧЕСТВЕ БАШКИРСКОГО ПОЭТА И ПРОСВЕТИТЕЛЯ МУХАМЕТСАЛИМА УМЕТБАЕВА

***Н.А. Хуббитдинова***
*БГПУ им. М. Акмуллы (Уфа)*

Статья посвящена рассмотрению особенностей отражения фольклорных традиций в творчестве поэт-просветителя, общественного и государственного деятеля Мухаметсалима Уметбаева.

Течение Просвещения или просветительства, как известно, возникло в XVIII–XIX вв. в Европе. Затем оно получило активное развитие в России и стало на повестке дня также и в деятельности прогрессивной части национальной интеллигенции, башкир и татар в том числе. В этот период в национальном образовании начинается активное движение. Оно ратовало за

обновление и прогрессивное развитие образования. В творчестве поэтов начинают все активнее звучать просветительские ноты, призывающие население к знанию и образованию. В этот период на ниве татарского просветительского поля активно работали Курсави, Ш. Марджани, Х. Фаизханов, К. Насыри и др. Среди башкирских просветителей в этом активность проявляли Мифтахитдин Акмулла, М. Уметбаев, Ш. Бабич, Ф. Туйкин, Р. Фахретдинов и др., которые своим творчеством и общественной деятельностью внесли весомый вклад в джадидтское обновление в программае образовании, в дело развития среди населения культуры и просвещения.
М. Уметбаев в своих поэтических произведениях – «Как в старину провожали башкирских девушек», «Хикая о трубе, ковере и яблоке» – мастерски использовал образцы башкирского народного творчества.
**Ключевые слова:** М. Уметбаев, фольклорные традиции, просветительство, творчество, стихи, поэма, сказки, обряды.

The article is devoted to the consideration of the features of the reflection of folklore traditions in the works of the poet-educator, public and state figure Mukhametsalim Umetbaev.
The Enlightenment movement, as is known, arose in the 18th–19th centuries in Europe. Then it was actively developed in Russia and became on the agenda of the progressive part of the national intelligentsia, including the Bashkirs and Tatars. During this period, an active movement began in national education. It advocated for the renewal and progressive development of education. In the works of poets, educational notes began to sound more and more actively, calling the population to knowledge and education. During this period, Kursavi, Sh. Marjani, H. Faizkhanov, K. Nasyri and others were active in the field of Tatar education. Among the Bashkir educators, Miftakhitdin Akmulla, M. Umetbaev, Sh. Babich, F. Tuykin, R. Fakhretdinov and others were active in this field. With their creativity and social activities, they made a significant contribution to the Jadid renewal in the educational program, to the development of culture and education among the population.
M. Umetbaev in his poetic works – "How Bashkir girls were seen off in the old days", "Hikaya about the pipe, carpet and apple" – masterfully used examples of Bashkir folk art.
**Keywords:** M. Umetbaev, folklore traditions, education, creativity, poems, poem, fairy tales, joys.

## БАШҠОРТ ӘҘИБЕ ҺӘМ МӘҒРИФӘТСЕҺЕ МӨХӘММӘТСӘЛИМ ӨМӨТБАЕВТЫҢ ИЖАДЫНДА ФОЛЬКЛОР ТРАДИЦИЯЛАРЫНЫҢ ХУДОЖЕСТВОЛЫ САҒЫЛЫШЫ ҺӘМ ҮҪТЕРЕЛЕШЕ

***Н.Ә. Хөббитдинова***
*М. Аҡмулла исем. БДПУ (Өфө)*

Мәғрифәтселек хәрәкәте XVIII–XIX бб. Европа һәм Рәсәй халыҡтары тарихында, уларҙың милли-мәҙәни тормошонда тәрән эҙ ҡалдырған прогрессив күренештәрҙең береһе булып тора. Ул билдәле бер яңы фәлсәфә, ҡараштар менән әҙәбиәтте хасил итте. Тормош күрһәтеүенсә, феодал ҡалдыҡтары, абсолют монархия нормалары һәм дини догмаларына ҡаршы хәрәкәтте сағылдырҙы. Европа илдәренән сыҡҡан был ағым рус әҙиптәре

һәм йәмәғәт эшмәкәрҙәре тараынан эләктерелеп алына. «Идеи революционно-демократического крыла русского просветительства находят свое выражение в разных вариациях и в разное время в пропагандистской деятельности народников, в творчестве Н.Г. Чернышевского, А.И. Герцена, Н.А. Добролюбова и др. Мотивы просветительства продолжали оказывать влияние на произведения таких видных писателей, как М.Е. Салтыков-Щедрин, И.С. Тургенев, Н. Островский, Ф.М. Достоевский и др.» [1: 65].

Башҡорт һәм татар кеүек халыҡтарҙың рухи тормошона ла мәғрифәтселек хәрәкәте оло бер яңылыҡ булып килеп инде. Бәлки, тәү осорҙа революцион күтәрелеше идеяларынан бигерәк ана шул демократик яңылыҡты тойған, мәҙрәсә, мәктәптә ҡәҙимселектән йәҙитселеккә ынтылыуҙы, рус, европа телдәренә, тәбиғи фәндәренә мөрәжәғәт итеүҙе хуп күргән башҡорт һәм татар мәғрифәтселәре эшмәкәрлегә әүҙемләште. Заманында Татарстанда Ҡурсауи, Ш. Мәржәни, Ҡаюм Насыри ише һәм башҡа милләт зыялыйҙары замандаштары булған башҡорт әҙиптәре лә тәүгеләрҙән булып мәғрифәтселек юлына баҫты. Шулар араһында Мөхәммәтсәлим Өмөтбаевтың ижады һәм эшмәкәрлеге был йәһәттән тәрән эҙ ҡалдырҙы. Башҡорт теле таҙалығын, сафлығын ҡайғыртҡан әҙиптәребеҙ кеүек ул да халҡыбыҙҙың бай телле һәм зиһенле ауыҙ-тел ижадына мөрәжәғәт итте.

Мөхәммәтсәлим Өмөтбаевтың (1841–1907) ижадында, ысынлап та, фольклор традициялары, жанрҙары үҙенсәлекле сағылыш тапҡан. Унда халҡыбыҙҙың туй йолаһы, иҫтәлек өсөн шиғри хат, йәдкәр яҙыу ғөрөф-ғәҙәттәре кеүек һәм башҡа фольклор традицияларының художестволы ҡулланылыуы күҙәтелә. Мәҫәлән, үҙенең «Үткән заманда башҡорт ҡыҙҙарының оҙатылыуы» тигән ҙур ғына күләмле поэмаһында ул башҡорттоң туй йолаһы күренештәрен поэтиклаштырып сағылдыра.

Халҡыбыҙҙың туй йолаһынан билдәле булыуынса, кейәү кеше ҡайныһы йортона килгәс, ҡыҙҙы йәшерәләр. Егете дуҫ-иштәре ярҙамында йәш ҡыҙҙар, еңгәләрҙең уйын «ҡаршылыҡтарынан» аҡса таратып ҡотолорға тырыша. Ҡыҙ кеше ҡаса икән, кейәүе иптәштәре менән уны тотоп, күтәреп алып китергә тейеш.

Туйҙың ошо эпизоды М. Өмөтбаевтың әлеге поэмаһында шулай һүрәтләнә:

...Элегерәк ҡыҙҙы алып йәшерәләр,
Йә сәхрәлә, йә өйҙә бикләнәләр.
Юҡ, булмай ярҙам итеп кейәүгә,
Елә торғас, ҡала эҙләп йәйәүгә...
Ана-тора, бына ята, тиешәләр,
Тауыш-ғауға күтәреп, һай, тиәләр.
...Егет туҡтамай ҡыҙҙы тотмайынса...
Көсө етмәһә күтәреп илтергә,
Берәүҙе аранан һайлай илтергә һ. б. [2: 43].

Халҡыбыҙҙың театрлаштырылған массалы йолаларының береһе һаналған туйҙың был етеҙ үҫешкән, динамикалы күренеше шағир тарафынан үҙенсәлекле поэтиклаштырылған.

Йола булараҡ кейәүгә сыҡҡан ҡыҙ башындағы таҡыяһын һалып, ике толомон һүтеп, бер толом үрә һәм башына ҡашмау ябына:

Ата-инәң йортонда
Һинең ҡолонсаҡ сағың.
Ҡашмауыңды кейерһең,
Килен булып йөрөрһөң, –

тип, һамаҡлап төрлө теләктәр әйтә-әйтә ҡыҙҙың өҫ-башын алмаштырып кейендергәндәр.

М. Өмөтбаев туйҙың был ритуалын да оҫта тотоп алған:

...Егет килһә, алам тип, ҡыҙҙы илгә,
Бер ай яталыр, үтәлер ғүмере елгә.
Килен булған кеше сафтыр гөнаһтан,
Кейенәлер ирәүән баш-аяҡтан...
Һаҡал, таҡыя кейер – йәш ҡыҙ балалыр,
Тубый ҡашмау кейгән – ҡатын булалыр, –

тип, поэтик формала дөйөмләштереп ҡуя шағир [2: 43].

Ҡыҙҙы ата йортонан оҙатҡансы, байтаҡ йолалар атҡарыла. Мәҫәлән, шул арала ҡыҙ саҡ менән хушлашыуҙы ойошторалар: оҙатыла торған көндө ҡыҙҙың башына бөркәнсек ҡаплап, әхирәттәре менән йөрөп килергә ҡырға сығарып ебәрәләр. Шунда йәш ҡыҙҙарҙың береһе әлеге таҡыяны ырғыта. Ҡалғандары артынан йүгерә. «Таҡыяны алып, тағы ырғыталар, тағы ла йүгерешеп ҡыуышалар. Шулай йүгерешеп дүрт-биш саҡрым ергә китәләр. Таҡыяға болашып йүгергән ҡыҙҙар артынан еңгәләре сыға. Арбала кейәү килә. Ҡыҙҙарҙы ҡыуып етеп, еңгәләр улар менән болашып, көрмәкләшеп, таҡыяны тартып ала» , һуңынан берәй ағас ботаҡтарын суҡлап («Кем бәйләгән суҡ тиҙ уңа – шул ҡыҙ тәү башлап кейәүгә сыға», тип уйлағандар), ҡыҙҙың таҡыяһын элеп:

Таҡыяларын талға элеп,
Талпынып-талпынып илай ҡыҙ бала.
Китәр ҙә юлын ҡарай-ҡарай,
Ҡайырылып-ҡайырылып илай ҡыҙ бала, –

тип, ағасты уратып йөрөп сеңләгәндәр [3: 407].

Туйҙың ошо һуңғы күренеше М. Өмөтбаевтың шиғырында шулай уҡ поэтик сағылыш тапҡан:

...Тубый ҡашмау теҙелде, еңгәһе, бир,
Ҡыҙым, уға ҡарышма таҡыяң бир...
Ҡыҙы таҡыяны бирмәйҙер был эштә,
Йолалап ултыра шаҡшы мөйөштә.
Баяғы ҡатын-ҡыҙ бик кинәнәлер,
Бере – бир, бере – бирмә, тип киләләр.
Ҡатындар унда айырылып сығалар,
Ҡыҙый яҡлы булып ҡыҙҙар торалар...
...Бара торғас, ҡатын-ҡыҙҙарҙы еңә,
Баҫып барып ала таҡыяны еңгә...», –

ише экспрессив теҙмә формала күҙ алдына килтерерлек итеп, йола күренеше тасуирлана [2: 45].

Башҡорт халҡының тылсымлы йәки батырҙар тураһындағы әкиәттәрендә герой, ғәҙәттә, төрлө тылсымлы әйберҙәр ярҙамында үҙенең маҡсатына ирешә («Таҙҙың төшө», «Осар кейеҙ», «Ғабдрахман» һ. б.).

«Тылсымлы әйберҙәр ярҙамында маҡсатҡа ирешеү» мотивына ҡоролған сюжет «Мең дә бер кисә» көнсығыш әкиәттәрендә йыш ҡулланылған. М. Өмөтбаевтың башҡорт халҡының ижады менән көнсығыш һүҙ сәнғәте традицияларының бәйләнеше юҫығында башҡарған тәржемәләрендә лә ошо мотивты осратырға мөмкин. 1873 йылда әлеге «Мең дә бер кисә»гә ингән «Торба, балаҫ һәм алма хикәйәте»н татар теленә тәржемә итә. Тәржемәнең нигеҙендә көнсығыш хикәйәте сюжеты ятһа ла, унда башҡорт фольклоры һыҙаттарын да һиҙемләргә була.

АТ551 («Молодильные яблоки») тибындағы мотивҡа ҡоролған тылсымлы әкиәттәрҙә үлгән йәки ҡаты сирләгән геройҙы йә икенсе бер персонажды берәй тылсымлы дарыуҙы, алманы еҫкәтеп йә иһә битенә һирпеп (йәки егет үлгән ҡыҙҙың маңлайынан үбеп ала) терелтәләр. «Дарыу эҙләүселәр» тигән башҡорт халҡының батырҙар тураһындағы әкиәтендә ҡыҙ егеттең өҙөлгән башын кәүҙәһенә бер тылсымлы дарыу менән йәбештереп, икенсеһен еҫкәтеүе була, герой шунда уҡ иҫенә килә, терелә. Һуҡырайған аталарының күҙенә шул уҡ дарыуҙы һөртһәләр, уның күҙе киренән күрә башлай, имеш. Был мотивтың тамырҙары «Мең дә бер кисә» көнсығыш әкиәттәр сюжетына барып тоташа. Уны шулай уҡ халҡыбыҙҙың «Алтын ҡош» тигән тылсымлы героик әкиәтендә лә осратырға мөмкин [4: 326; 5: 347].

М. Өмөтбаевтың «Торба, балаҫ һәм алма хикәйәте»ндә фольклорҙың был үҙенсәлектәре, мотивтары, шулай уҡ сағылыш алған: бында ла сирләп ятҡан ҡыҙға тылсымлы шифалы алма еҫкәтеүҙәре була, унығы шунда уҡ һауығып китә. Һуңынан ағай-энеләрҙең береһенә кейәүгә сыға.

Фольклорҙа мөхәббәт сюжетына ҡоролған мотивты шағирҙың әлеге хикәйәтендә лә күҙәтергә була: батшаның бер улы торба аша күрше батшалыҡтағы һылыу ҡыҙҙың ҡаты сирләүен күреп белә, үҙе уға үлеп ғашиҡ була, уртансыһының осар балаҫына ултырып, шунда осоп барып етәләр, кеселәренең тылсымлы алмаһын еҫкәтеп, ҡыҙҙы аяҡҡа баҫтыралар. Һауыҡтырып алғас, ғашиҡ булған ағалары уға өйләнә.

Яҙыусының «Торба, балаҫ һәм алма хикәйәте» халыҡ ижады һәм көнсығыш әҙәбиәтенең популяр мотивтарына ҡоролоп, әҫәрҙең романтик сюжетын мауыҡтырғыс үҫешеүенә булышлыҡ иткән.

М. Өмөтбаевтың шиғырҙары менән тәржемәләренән башҡа, халҡыбыҙҙың фольклоры, теле, тарихы һәм этнографияһы өлкәһендәге күҙәтеүҙәре, тикшеренеүҙәре ҡулъяҙма көйөнсә лә, баҫтырылған килеш тә һаҡланыуы билдәле («Өфө губернаһы мосолмандарының ырымдары, хөрәфәттәре, мәҡәл, тапҡыр һүҙдәре һәм хикмәтле һүҙҙәре», «Риүәйәттәр, легендалар», «Боронғо башҡорттарҙың еләндәре», «Башҡорттар» һ. б.). Шулар араһында башҡорттарға ҡағылышлы тарихи-этнографик тикшеренеүҙәре ҡыҙыҡлы.

Билдәле булыуынса, башҡорт этнонимының аталышына бәйле риүәйәттәр байтаҡ. «Башҡорт ҡайҙан килеп сыҡҡан», тигәнендә, мәҫәлән, Урал буйҙарына баш бүре – ҡорт артынан эйәреп килеп сыҡҡандан һуң үҙен «башҡорт», тип атай башлай: «баш»+«ҡорт». Икенсе бер риүәйәттән билдәле булыуынса, халҡыбыҙҙың аталышы Ҡорҡот ата тигән башлыҡтарының исеменән килеп сыҡҡан, имеш һ. б.

М. Өмөтбаевтың «Өфөнөң тарихына ҡағылышлы материалдар» тигән мәҡәләһендә лә ошо этимологик риүәйәттәргә хас элементты күҙәтергә мөмкин. Йәғни шағир ошо риүәйәттәрҙәгесә халҡыбыҙҙың килеп сығышы тарихы хаҡында һүҙ йөрөтә, әммә ул тарих «башҡорт» этнонимының барлыҡҡа килеүенең бер варианты кеүек ҡабул ителә. «Болғар дәүләте аҫтында булған саҡтарында уҡ, үҙҙәрен баш унғар, йәғни баш юғур һәм, аҙаҡ килеп, башғур, һуңғараҡ башҡурт тип йөрөтә башлағандар, һуңғы атамала «Ғ» хәрефе «Ҡ» менән сиратлашҡан һәм «Т» хәрефе өҫтәлгән», тип белгән тикшеренеүсе [1: 196].

Авторҙың был мәҡәләһендә шулай уҡ төрлө төбәктәрҙең ер-һыу, ҡалалар атамаларының килеп сығышы тураһында бәйән иткән риүәйәт һәм легендалар ҙа килтерелә (мәҫәлән, рәсми аталған Верхний Уралдың халыҡта ни өсөн – Тал ҡала, ә Өфө Имән ҡала тип йөрөтөлөүен аңлата һ. б.).

Әлеге күҙәтеүҙәрендә М. Өмөтбаев Урал-Волга буйында билдәле булған «Сыңғыҙнамә» хикәйәтенә ингән Аҡһаҡ Тимер хаҡындағы ҡисса менән ауаздаш эпизодты килтерә. Унда ла фольклорға хас «бойомға ашаҫаҡ төш күреү», «изге ярҙамсы Хызыр Ильяс» кеүек мотивтарҙы ла осратырға момкин. Улар шулай уҡ билдәле сюжеттың йылдам үҫешенә хәл иткес этәргес көс бирә.

Билдәле булыуынса, М. Өмөтбаев 1887 й. башында хеҙмәт эштәре буйынса Санкт-Петербурга эшкә саҡырыла. Тик, был эште үҙәктән тороп башҡарыуы ҡыйын булғанлыҡтан, ул март айында Ҡырымға Симферополь тарафтарына китергә мәжбүр була һәм унда ғүмеренең ике йылын ваҡеф эштәрен рәткә һалыу буйынса ҙур эш башҡара [6: 233]. Шул осорҙа шағирҙың тыуған ерендә ҡалған ғаиләһенә, бала-сағаһына, дуҫиштәренә байтаҡ шиғри хаттар яҙа. Шағирҙың ошо осорҙа ижад иткән шиғри һәм ҡәҙимге хаттары өҫтөндә текстологик эште ғалим М. Нәҙерғолов башҡарғайны. Әлеге хеҙмәтебеҙҙә беҙ шул хаттарҙың текстарына мөрәжәғәт иттек һәм проблемаға ярашлы анализ үткәрҙек [7: 70–87]. Уларҙың күбеһе юғарыла телгә алынған шиғри хат, йәдкәр яҙыу кеүек йола фольклоры традицияларында ижад ителгәнгә оҡшай («Дуҫҡа», «Кемгә хәлем һөйләйем», «һағыныу», «һағыныу хаты», «Остаҙ Мирсалих Биксуринға» һ. б.)[1].

Килде беҙгә айырылыу көндәре, әй, дуҫҡайым,
Бер аҙ шулай һөйләшеп ҡалмаҡ кәрәк.
Йылдар тотон, күҙҙәр күреп, һүҙ бөтмәҫ,
Һүҙ табалмай әл-фираҡ нитмәк кәрәк [2: 73].

Халҡыбыҙҙың был йола күренешенән билдәле булыуынса, бындай иҫтәлек өсөн яҙылған шиғри хаттарҙа яҙыусының туғандарын, дуҫ-иштәрен һағыныуын, улар менән тиҙерәк осрашырға теләүен, шул нигеҙҙә тыуған хис-тойғолары йылы поэтиклаштырыла. Бындай шиғырҙарҙың тәүге ике строфаһында, ғәҙәттә, тәбиғәт күренештәре, тыуған ер-һыу атамалары, гөл сәскәләр телгә алынып поэтиклаштырыла. Өсөнсө һәм дүртенсе юлдарҙа

[1] М. Өмөтбаевтың ошо йола күренешен үтә лә үҙһенеүе күренә, сөнки уның мәҡәләләр, материалдар,ижадынан торған йыйынтыҡ та «Йәдкәр» тип аталған (Казан, 1897). – *Н.Х.*

иһә иҫтәлек яҙыусының әйтергә теләгәне, уның хис-тойғолары, теләк-өгөттәре белдерелә.

Баҡсаларҙа үҫкән гөлдәр
Ниңә башҡынайын эйәләр?
Шуны күрһәң, бергә мәлдәр
Иҫтәреңә һинең төшөрҙәр...

Йәки

...Ағиҙелдең аръяғында
Бейек тауҙар бармы икән?
Һине күреп ҡул бирешеп
Һөйләшер көн бармы икән?
Һыҙылып алһыу таңдар атҡан саҡта
Һандуғастар тауышын тыңларһың.
Тыңларһың да, бәғерем, бер уйларһың,
Мине иҫкә алып йырларһың[1].

Ошондайыраҡ традициялыҡты М. Өмөтбаевтың телгә алынған шиғри сәләм-хаттарында ла күҙәтергә мөмкин.

Яҙ көнөндә кәкүк саҡыра микән
Ағиҙел буйы бейек тирәктә.
Бер күрергә һеҙҙе мең зар булдым
Мәхрүм, мәхзүн (ҡайғылы, моңло) булып йыраҡта, –

тип башланып китә лә:

Яҙ көнөндә сәсәк бик шат саҡта
Гөл йығасы ниңә бөгөлгән.
Һеҙҙең өсөн, дуҫҡай, йығлай-йығлай,
Япраҡтарым бәнем өҙөлгән, –

тигән юлдар менән тамамлана [7: 70]. Тимәк, М. Өмөтбаев халыҡ йырының формаһын, поэтик үҙенсәлектәрен иҫтә тотоп, хат-шиғырҙарында уны оҫта файҙаланған.

Шағир хатының сәсмә өлөшөнән һуң яҙған быңдай шиғри сәләмдәре араһында балаларына төбәп әйткәне лә бар. Уларҙа күберәк өгөт-нәсихәттәр, теләк-ниәттәр яңғыраусан. 1888 йылдың 1 февралендә яҙған бер хатының ахырында ул түбәндәгеләрҙе яҙып киткән:

...Ғалим булмаҫ күрмәгән нәхү вә ҡәләм[2]
Ғамил[3] булмаҫ сикмәгән жоур-әләм[4]
Аҡыллылар күп белеп аҙ һөйләгән
Белекһеҙҙәр аҙ белеп суҡ һөйләгән.
......................................................
Бына минең һабағым
Шуны белә алмайым... [2: 43]

---

[1] Учалы районы Сәфәр ауылы Шәүкәт Ғариповтан Н. Шоңҡаров яҙып алды, 1965 й.
[2] Грамматика и синтаксис.
[3] Егәрле, булдыҡлы.
[4] Ауырлыҡ, михнәт.

Шулай итеп, М. Өмөтбаевтың ижадында фольклор традициялары ҙур ғына урын алған. Айырым ижади үрнәктәрендә, хаттарында, тарихи, этнографик материалдарында халҡыбыҙҙың йола поэзияһы күренештәре, ауыҙ-тел ижады мотивтары, тотош легенда сюжеты, йырҙары сағылыш тапҡан. Мөхәмәтсәлим Өмөтбаев шағир, мәғрифәтсе генә түгел, шулай уҡ тарихсы, этнограф, фольклорсы булараҡ та күҙаллана. Был йәһәттән уның поэзияһы ла, ғилми хеҙмәттәре лә, хатта хатлашыуы ла мөһим әһәмиәткә эйә. Мәғрифәтселек идеяларына ярашлы булған шағир һәм мәғрифәтсеһенең быңдай алдынғы эшмәкәрлеге башҡорт ҡына түгел, тотош төрки халыҡтары мәҙәниәтен яңыртып, байытып, күтәреп торҙо, тиһәк тә яңылышмабыҙ.

ӘҘӘБИӘТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Панеш У.М., Ашинова Ю.А.* Эволюция просветительства и особенности формирования его революционной модели в национальной литературе // Ежеквартальный рецензируемый, реферируемый научный журнал «Вестник АГУ». Вып. 4 (307). 2022. С. 63–70.

2. *Өмөтбаев М.* Йәдкәр / төҙ., баш һүҙ, аңлатм. авт. Ғ.С. Ҡунафин. Өфө: Башкорт. кит. нәшр., 1984. 196 б.

3. Башҡорт халыҡ ижады: Йола фольклоры / төҙ., баш һүҙ, аңлатм. авт. Ә.М. Сөләймәнов, Р.А. Солтангәрәева. Өфө: Китап, 1995. Т. 1. 560 б.

4. Башҡорт халыҡ ижады: Тылсымлы героик әкиәттәр / Төҙ., баш һүҙ авт., ком. М. Минһажитдинов, Ә. Харисов. Өфө: Башҡорт. кит. нәшр., 1976. 1-се кит. 374 б.

5. Башҡорт халыҡ ижады: Батырҙар тураһында әкиәттәр / төҙ. Н. Зарипов, М. Минһажитдинов, ком. Л. Бараг, Н. Зарипов. Өфө: Башҡорт. кит. нәшр., 1978. 3-сө кит. 357 б.

6. Башҡорт әҙәбиәте тарихы. Өфө, 1990. Т. 2. 582 б.

7. XIX б. аҙағы – XX б. башы башҡорт прозаһы үрнәктәре. Хрестоматия. Өфө, 2006. 180 б.

УДК 821.512.145; 392

# «ПИОНЕР ТАТАРСКОЙ ЭТНОГРАФИИ»
## *(Об одном этнографическом труде Каюма Насыри)*

***Г.А. Хуснутдинова***
*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В данной статье рассматривается труд К. Насыри «Татар этнографиясе материаллары», опубликованный в 1926 году в сборнике, подготовленному к 100-летию ученого. Работа ученого была обнаружена и опубликована благодаря научным изысканиям известного ученого-литературоведа Гали Рахима. По мнению Г. Рахима, К. Насыри является пионером татарской этнографии, а его научный труд – первым исследованием по татарской этнографии. В работе К. Насыри освещаются материальные и духовные особенности татарского народа.
**Ключевые слова:** Каюм Насыри, Гали Рахим, этнография, история, татарская литература, научная деятельность.

This article examines the work of K. Nasyri “Tatar ethnography and the material of the Tatars”, published in 1926 in a collection prepared for the 100th anniversary of the scientist. The scientist’s work was discovered and published thanks to the

scientific research of the famous literary scholar Gali Rahim. According to G. Rahim, K. Nasyri is a pioneer of Tatar ethnography, and his scientific work is the first study on Tatar ethnography. In the work of K. Nasyri highlights the material and spiritual characteristics of the Tatar people.
**Keywords:** Kayum Nasyri, Gali Rahim, ethnography, history, Tatar literature, scientific activity.

## «ЭТНОГРАФИЯ БАБЫНДА ҮЗ АРАБЫЗДАН ЧЫККАН БЕРЕНЧЕ ПИОНЕР»

### *(Каюм Насыйриның бер этнографик хезмәте турында)*

***Г.А. Хөснетдинова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

Татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле Каюм Насыйри бөтен тормышын һәм талантын халыкка хезмәт итүгә багышлаган, татар халкының аң-белемен күтәрүгә хезмәт иткән бөек шәхесләрнең берсе. Аның мирасы хәзерге көндә дә фән һәм мәдәни дөньябызның үзәгендә тора.

К. Насыйри эшләгән чор, ягъни XIX йөзнең икенче яртысы Россиядә мәдәниятның көчле үсү чоры. Бу чорда халык көнкүрешенә, халыкның мәдәни үсешенә зур кызыксыну туа. Төрле этнографик бүлекләр оештырыла, алар үз чиратларында әлеге теманы яктырта торган журналлар чыгара башлый. Казан да бу эштән читтә калмый. Казан университеты каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте төзелә, аның «Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете» дигән журналы басыла; җәмгыятьнең утырышларында галимнәрнең шул исәптән Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Әхмәров һ. б. докладлары тыңлана. К. Насыйри 1895 елда шул җәмгыятьнең хакыйкый әгъзасы булып сайлана.

К. Насыйриның этнография буенча язылган хезмәтләре башка өлкәдәге фәнни хезмәтләре белән чагыштырганда әллә ни күп түгел. Аның рус телендә «Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства» (Петербург, 1880), «Образцы народной литературы казанских татар» (Казан, 1896) дигән хезмәтләре басылуы билгеле. Беренчесендә татар халкы арасында ислам динен кабул иткәнгә кадәр булган борынгы ышанулары, ырымнар, им-томнар хакында мәгълүмат бирелсә, икенчесендә – табышмаклар, мәкальләр, җырлар тупланып бирелгән. Әлбәттә, болар турыдан-туры этнографиягә карамаса да, алар халыкның көнкүрешен өйрәнгәндә кыйммәтле материал булып торалар.

К. Насыйриның зур гыйльми әһәмияткә ия булган этнография буенча хезмәте 1926 елда «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм йөзьеллык бәйрәм материаллары» дигән җыентыкта дөнья күрә.

1925 елның 15 февралендә Татар дәүләт театры бинасында Каюм Насыйриның тууына 100 ел тулу уңае белән Гыйльми үзәк тарафыннан тантаналы зур гыйльми җыелыш ясала. Анда «Каюм Насыйриның тарихи йөзе» (Галимҗан Ибраһимов), «Каюм Насыйриның тормышы» (Мөхәммәт Парсин), «Насыйриның гыйльми хезмәтләре» (Гали Рәхим), «Каюм Насыйриның татар теленә хезмәте» (Мөхетдин Корбангалиев) дигән темага докладлар укыла. Юбилейга йомгак итеп: «1) Мәскәүдәге Журналистлар

институтында Каюм Насыйри исеменә стипендия билгеләргә; 2) Казандагы Евангелистовская (*хәзер Татарстан урамы*) һәм Яңа Бистәдә Большая Симбирская (*хәзер Меховщиклар урамы*) урамнарны Каюм Насыйри исеме белән атарга; 3) Казан татар педтехникумын «Насыйри педтехникумы» дип атарга; 4) Насыйри әсәрләрен сайлап бастырырга һәм аның турында мәҗмуга чыгарырга» [1: 172–173] дигән карар кабул ителә.

Җыентыкны төзү эше Г. Рәхимгә тапшырыла. Чөнки, беренчедән, Гали Рәхим татар язучыларының һәм сәнгать әһелләренең иҗат биографиясен өйрәнүдә, аерым чыганакларны барлау юлында ару-талуны белмәс галим була. Аның Каюм Насыйри, Галиасгар Камал, Мөхетдин Корбангалиевләр хакында язылган бай эчтәлекле мәкаләләре, фәнни эзләнүләре шуның ачык бер дәлиле. Икенчедән, Гали Рәхим бу теманы яхшы өйрәнгән галимнәрнең берсе. Ул 1922 елда К. Насыйри вафатына егерме ел тулу уңае белән Халык мәгариф комиссариаты карары белән әзерләнгән «Каюм Насыйри мәҗмугасы»ның мөхәрир-төзүчесе дә, төрле газета-журналларда галимнең шәхесен һәм иҗатын яктырткан күп санлы мәкаләләр авторы да [4].

«Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм йөзьеллык бәйрәм материаллары» исеме белән нәшер ителгән җыентык Г. Ибраһимовның кереш сүзе белән ачыла. Сүз башы рәвешендә язылган «Башлангыч»та галим юбилейның татар дөньясында зур бәйрәм булуын билгеләп болай ди: «...бер яктан, бабаның әсәрләрен, хезмәтләрен тикшерүгә сәбәп булса, икенче яктан, аның хакында яңа материаллар табылуга, аның китапларын, язганнарын җыюга зур ярдәм итте. Менә шул соңгылар эчендә гыйльми кыйммәте иң зур булганнары, <...> моңарчы басылмаган, тик әле яңа дөньяга чыгарылган кулъязмаларыдыр» [2: 255]. Галим Насыйриның мирасы моның белән генә тәмам булмавын, эзләнүләр дәвам ителергә тиешлеген ассызыклап, киләчәккә өметләр баглый. Юбилей уңае белән басылган мәҗмугада К. Насыйриның Казан тарихына багышланган материаллары, риваятьләр, археология, татар этнографиясе һәм К. Насыйриның йөзьеллык бәйрәме уңаеннан басылган мәкаләләр урын алган.

Каюм Насыйриның этнография өлкәсенә караган язмасы якын кардәше Габдрахман Хөсәенов тарафыннан Гыйльми үзәккә тапшырылган кулъязма материаллар арасыннан табыла. Җыентыкны төзүче-автор Гали Рәхим әлеге кулъязмаларны эшкәртеп, тәртипкә сала, төрле редакцияләр арасыннан тулырак булганнарын сайлап ала һәм «Татар этнографиясе материаллары» дигән шартлы исем белән мәҗмугада бастыра. 28 биттән гыйбарәт әлеге хезмәтнең «Башлангыч»ында автор Каюм Насыйриның эшчәнлегенә югары бәя бирә, аны «этнография бабында үз арабыздан чыккан беренче пионерлардан» дип саный. Фикерен дәвам итеп кулъязманың «...татарга һичбер изахсыз (*аңлатмасыз)* мәгълүм әйберләрне озаклап, бәгъзан урыс мисаллары белән аңлатуы урыс гыйлем һәм этнография әһелләре өчен язылганын белдереп тора. Ихтимал, ул Насыйриның “Урыс җәгърафия җәмгыяте”нең журналында басылган татар хорафаты турындагы әсәре шикелле урысчага тәрҗемә кылынып бастырылырга уйланылгандыр, шуңар күрә дә татарчасында тел ягына артык әһәмият бирелмәгәндер» [3: 83], дип белдерә.

Галим хезмәтнең кыйммәте итеп «Бер яктан татар этнографиясе бабында иске заманда татарлар тарафыннан язылган бердән бер әйбер, икен-

че яктан XIX йөзнең татар тарихы этнографиясе өчен байтак чи материал бирә торган бер документ» [3: 84] булуын күрсәтә.

Хезмәтнең структурасына килгәндә ул Европа этнография гыйлемендә кабул ителгән тәртип белән тезелгән. К. Насыйри материаль мәдәният – торак, кием-салым, аш-су мәсьәләләренә дә, мәгънәви мәдәният – бала туу, өйләнү, үлек күмү белән бәйле гадәт һәм йолаларга да кагылган.

Беренче «Йорт-җир» дигән бүлектә галим җентекле итеп татарларның тораклары, көнкүреш әйберләре турында сөйли. Мисал: «диварга аскан сурәтләр һичбер өйдә юк; моның урынына истигъмаль кылалар (*кулланалар*), мәсәлән, бик бизәкләп шамаил, һәйбәт рамкага куялар, башка догалар, аятелкөрси кебек һәм Мәккә-Мәдинә сурәте, яки гөл сурәтләрен кәгазьгә язып, бик яхшы бизәкләп диварга ислам һәм диварны бизәкләр өчен һәйбәт сөлгеләр эләләр» [3: 86]. Кайбер очракта К. Насыйри аларның килеп чыгыш тарихларына да туктала. Мисал итеп өйдә кош асрау хакында бер өземтә китерү урынсыз булмас. Мәсәлән: «өй кошларын асраучы бик аз, мәсәлән, кәнәри, сандугач кебек сайрый торган кошларны асраштыргалыйлар. Шәригать буенча кошны читлеккә ябып асрамак мәкруһтыр (*начар күренештер*). Шуның өчен кош асрамакны бик хуш күрмиләр. Әмма бәгъзы түбәнрәк дәрәҗәдәге халык Мисыр күгәрчене (*күгәрчен кошлар семьялыгының яшел күгәрченнәр ыругына караган яшькелт сары төстәге кечкенә кош*) асрыйлар. Гүя аны асраган кеше саваплы була, имеш, дип, бер-бер карчыктан ишеткәннәре бардыр; ул күгәрченне тәбәррекән (*мөбарәк эш дип*) асрый торганнардыр ахрысы, шулай гөман итәмен (*уйлыймын*)», ди дә, шуны дәлилләп мисал китерә: Мөхәммәд пәйгамбәр гам Әбүбәкер белән Мәккәдән Мәдинәгә барганда бер тау тишегенә кергәннәр. Артларыннан куа килеп Әбүҗәһилләр бу гарга (*мәгарәгә, тау куышлыгына*) җиткәннәр; ул арада гарның тишегенә күгәрченнәр оя ясаганнар, үрмәкүчләр пәрәвез корганнар, аннан Әбүҗәһилләр кайтып киткәннәр, монда кеше юк, күгәрченнәр оялаган җирдә кеше тормас диеп. Шуның өчен бәгъзы татарлар бу күгәрченне асрыйлар [3: 86–87].

Икенче – «Кием-салым» дигән бүлектә Каюм Насыйри кием-салым турында сөйләп кенә калмый, ул аның материалына, тегелешенә, төсенә, хәтта нинди вакыйга уңае белән кулланылуына да әһәмият бирә. «Татарда бар кием: күлмәк, ыштан, камзул, казаки, җилән, чапан, чикмән, кыска тун, өчбилле, тун, толып, чалбар, бишмәт, читек, кәвеш, башмак, бүрек, такыя, кәләпүш. Бу киемнәрнең бәгъзысы бар. Башка халыкта һичберәүдә күрмәй, һичбер халыкның киеменә охшамый» [3: 88]. Татарлар, галим фикеренчә, киемнәренең күп һәм матур булуын яраталар, шул сәбәпле аларны матурлап, бизәкләп эшлиләр. «(Дәхи бәгъзы хатыннар күп вакытны калфак кияләр, җефәк калфак була. Гадәттә фабрик эше, бәрхетле калфак диелә. Биш тәнкә, алты тәнкә була простое. Шул калфакны янә тезетәләр энҗеләр, тапаслар белән; кыйммәт төшә. Ул калфакка ука чачак һәм ука чук тагалар. Бик арзан тормый. Дәхи ул калфакны ясыйлар кыйммәтле бәрхеттән. Кыз-хатын бар бик осталар калфак ясарга. Бик кыйммәтле калфак эшлиләр Казан кызлары, энҗе белән кыйммәтле ташлар утыртып» [3: 92].

Каюм Насыйриның аш-су турында язганнары (хезмәтнең өченче бүлеге) урыны-урыны белән аш пешерергә өйрәтү китабына әверелеп китә, ул теге я бу ашны хәзерләү юлларын өйрәтә һәм рецептлар бирә. Мәсәлән,

бәлеш белән гөбәдия әзерләү бик тәфтишле итеп аңлатыла. «Бәлеш һәм гөбәдия карап торырга бертөрле формада. Әмма бәлешне хәзерлиләр бөккән кебек, ләкин түгәрәк була. Әүвәл камырны җәяләр, камыр өстенә дөге салалар, чи ит турап салалар, тоз, борыч азрак салалар да шул җәелгән камыр белән төреп [бөккән] кебек итеп ясыйлар. Табага куеп мичтә пешерәләр. Әмма гөбәдия дигәне һәм бәлеш кебек түгәрәк буладыр. Ләкин гөбәдиягә итне турап салмыйлар, чавып салалар бик вак итеп астка, аның өстенә корт салалар, аның өстенә йомырканы пешереп, төеп салалар, май салалар. Бәлеш кебек итеп камыр белән төрәләр; зиядә хуп (*бик яхшы*) нигъмәт була» [3: 95]. Шулай ук К Насыйриның кульязмасында төрле ашлар, пылау, бөккән һәм кактөш (чәк-чәк) кебек азыклар турында да мәгълүмат бирелгән.

Дүртенче – «Гадәтләр» бүлегендә галим татар кешесенең туганнан алып үлгәнгә кадәр булган тормыш йолалары турында яза. Ул бала туган вакыттагы гореф-гадәтләргә, баланы карауга, туйга һәм мәет күмү мәсьәләсенә җентекле рәвештә кагыла. Кунакларны кабул итү, аларны сыйлау гадәтләре кебек вак детальләр дә галим игътибарыннан читтә калмый.

Галим тарафыннан китерелгән көнкүреш үзенчәлекләре арасында бүгенге көндә инде онытылган, югалганнары да бар. Мәсәлән, «Бишек туе», «Бүләк багу» бәйрәмнәрен шундыйлар рәттеннән санап үтәргә мөмкин.

К. Насыйри этнографик материалларны Казан шәһәре һәм Казан тирәсе татарлары тормышыннан алган (кайвакыт ул аларны үзе күрсәтеп тә китә), этнография фәнендә кабул ителгән системага салган. Халыкта алар ничек булган булса, шул рәвешчә язган. Яхшы якларын да, начар якларын да бертигез күрсәткән.

К. Насыйриның татар этнографиясе турында язган тагын берничә язмасы-мәкаләсе булуы ихтимал. Бу хакта автор үзе хезмәтендә искәртеп бара. Мәсәлән, эшләпә, ак ишаннар, ботка хакында ул «минем байтак зур рисаләм бар, яисә бәяны түбәндә килер» дип язып китә. Ни кызганыч, галимнең мондый хезмәтләре әлегә табылганы юк.

Сүзне йомгаклап, шуны әйтәсе килә: Каюм Насыйриның татар этнографиясе турында язылган әлеге хезмәтен, иҗат мирасын бүгенге хәлдә күрүебез белән без иң элек Гали Рәхимгә бурычлы. Тик ни сәбәпледер К. Насыйриның «Сайланма әсәрләре»ндә дә, фәнни мәкаләләрдә дә галимнәр бу хакта дәшми киләләр. Әлбәттә, узган гасырның 60 нчы елларына кадәр Г. Рәхим исемен искә алырга ярамый иде, әмма инде XXI гасырда басылган хезмәтләрдә дә мондый фактларны инкяр итү мөмкин дә, дөрес тә түгел.


ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Гыйльми үзәк язмалары // Магариф. 1925. № 1–2. Б. 172–173.

2. *Ибраһимов Г.* Башлангыч // Ибраһимов Г.Г. Әсәрләр: 15 томда. Академик басма. 8 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933) / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Г.А. Хөснетдинова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. Б. 255–258.

3. Татар этнографиясе материаллары // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм йөзьеллык бәйрәм материаллары. Гали Рәхим карамагында. Казан: ТССҖ дәүләт нәшр., 1926. Б. 83–107.

4. *Хуснутдинова Г.А.* На службе науки... // Актуальные проблемы тюркологии: Россия и тюрко-мусульманский мир: X Междунар. тюркологическая конф. (г. Елабуга, 25 декабря 2020 г.) / отв. ред. А.З. Нигамаев. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2021. С. 287–289.

УДК 351.853.1

# ИСТОРИЯ ЗДАНИЯ МУЗЕЯ КАЮМА НАСЫРИ В КОНТЕКСТЕ СОВРЕМЕННЫХ ИССЛЕДОВАНИЙ

***Э.И. Хузиева***
*Музей Каюма Насыри – отдел ГБУК Национальный музей Республики Татарстан (Казань)*

Научно-просветительская деятельность К. Насыри тесно переплетена с людьми его эпохи. В статье описана история мест длительного проживания К. Насыри. Так же переданы воспоминания современников о некоторых близких по духу ученому людях, их взаимоотношениях с ним.
В статье история строительства музея К. Насыри включила этапы: до начала строительства и до момента открытия музея. Впервые в нее влючено описание история дома М. Хусаинова, на месте которого после реконструкции был открыт музей.
В даной статье помимо воспоминаний родственников, хозяина дома Мухамедбадыга Хусаинова, включены архивные материалы, сведения из технической документации на дом (1961–1969). Уточнены годы проживания К. Насыри в доме М. Хусаинова.
**Ключевые слова:** Каюм Насыри, музей им. Каюма Насыри, Мухамедбадыгъ Хусаинов, ученый, просветитель.

Scientific and educational activities of K. Nasyri is closely intertwined with the people of his era. The article describes the history of K. Nasyri’s long-term residence. The memoirs of contemporaries about some people close to the scientist and their relationship with him are also transmitted. In the article, the history of the museum’s construction by K. Nasyri included all the stages: before the start of construction and before the opening of the museum. For the first time, it contains a description of the history of M. Khusainov’s house, on the site of which a museum was opened after reconstruction. In addition to the memoirs of relatives, the owner of the house, Mukhamedbadyg Khusainov, this article includes archival materials, information from the technical documentation for the house (1961–1969). The years of K. Nasyri's residence in M. Khusainov's house have been clarified.
**Keywords:** Kayum Nasyri, museum named after Kayuma Nasyri, Mukhamedbadig Khusainov, scientist, educator.

# КАЮМ НАСЫЙРИ МУЗЕЕ БИНАСЫНЫҢ ТАРИХЫ – ЗАМАНЧА ТИКШЕРЕНҮЛӘР АША

***Э.И. Хуҗиева***
*Дәүләт мәдәният учреждениесе Татарстан Республикасы Милли музееның структур бүлекчәсе – Каюм Насыйри музее (Казан)*

К. Насыйриның фәнни-агарту эшчәнлеге үз чоры кешеләре белән тыгыз бәйләнгән. Мәгърифәтче аларның эшлекле мөнәсәбәтләре даирәсенә кергән, алар белән тыгыз туганлык бәйләнешләре булган, хәтта алар йортында яшәгән. Һәм бу, турыдан-туры, аның фәндәге карашларына эз калдырды һәм аның чорының тарихи-мәдәни контекстында чагылыш тапты. Совет чоры дәвамында аларның кайберләре ниндидер сәбәпләр аркасында тарих тарафыннан «онытыла».

Шундый кешеләрнең берсе дип Мөхәммәтбәдигъ (кыскача Бәдигъ) Хөсәеновны (1853–1929) санарга була.

Бәдигъ Хусаинов исеме «Совет әдәбияте» (Казан Утлары) битләрендә 1944 елда Мөхәммәд Гайнуллинның (1903–1985) «Атаклы галим һәм язучы Каюм Насыйри» дип исемләнгән мәкаләсендә искә алына. Фәнни журнал мәкаләнең дәвамын берничә санда җинтекләп, нечкәлекләр белән бастыра. Әдәбиятченең ул публицистик иҗатында шундый юллар бар: «1893 нче елның көзеннән башлап Насыйри хәзерге Тукай урамына, Сөләйман Аитов (1862–1922) дигән кешенең карамагында булган агач йортка күчеп тора башлый. Квартирда торганы өчен Сөләйман Аитовның улы Исмәгыйлне һәм аның кардәшләреннән Яушевның улын укытып гимназиягә хәзерләргә тиеш була. Насыйри анда берничә ел тора. Бай малайлары янына кушып берничә фәкыйрь баланы да укыта. Ләкин соңрак Аитов элекке фикереннән кайта. Шуннан инде Насыйриның аның йортында квартира хакы түләми торуы да артык санала. 75 яшьлек карт язучыга тагын да квартира алыштырырга туры килә. 1899 нчы елда Бәдигъ мөәзиннең түбәнге өенә күчә, үлгәнче шунда тора» [2: 71].

1948 елда К. Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган фәнни сессия материаллары да татар һәм рус телләрендә чыга. Татарча вариантка М.Х. Гайнуллинның «Каюм Насыйриның гыйльме юлы» мәкаләсе керә. Әммә, анда 1899 ел урынына 1889 ел язылa.

Мәгърифәтченең сәүдәр һәм хәйриятче С.М. Аитов карамагында булган йортына күчеп торганы турында замандашлары истәлекләре сакланган. Насретдин әл-Хуҗаши Гаяз Исхакый белән 9 гыйнварның 1902 елында К. Насыйрига барганын болай язып калдырган: «Гаяз әфәнде илә икәүләп урамнан узганда, Әби чиркәвеннән барып, Екатерининский урамга (хәзерге Г. Тукай урамы, 46 йорт урыны) кергәндә, сул чаттагы бер йортка ишарә кылып: «Мона шул йортта безнең милли мөхәрриремез Каюм Насыйри тора», – дигән иде. Замандашы, Нуреддин Ишаев да, Шура журналында (1912) 1898 елда Каюм Насыйри янына Екатеринский урамындагы йорттка кергәнен яза. Бу Ф. Аитованың кызлар мәктәбе ишек алдындагы агач йорт дип исәпләнә. Бу хакта С.М. Аитов үзенең истәлегендә дә язып калдыра.

Сөләйман Аитов дүрт тапкыр өйләнгән, аның Фатиха (Яушева) исемле хатыныннан Исмәгыйл улы туа. Кияүгә чыгуын Фатиха болай дип искә төшерә: «1887 елда мин Казанда туып үскән Сөләйман Аитовка кияүгә чыктым һәм Казанга күчендем...». Фатиха Габделвали кызы Казанда беренче кызлар мәктәбен ача, ире белән мәгърифәтчелек юллында тирән эз калдыручыларның берәүләре булалар. Мәгърифәтчелек юлынынан баручы Каюм Насыйри үзенә охшаш, күренекле заман кешеләре белән аралашкан.

Каюм Насыйри музееның беренче мөдире Р. Хөснетдинова «Андыйлар табигатьтә сирәк очрый» дигән мәкаләсе дә укучыны музей төзелеше тарихы, мәгърифәтченең туганнары белән дә таныштыра [7: 144]. Мөхәммәтбәдигъ турында мәкаләдә аерым сүз юк; исеме әйтелеп кенә уза. Барлык бастырылган мәгълүмәтләрне чагыштырып, аның турында яңа материалны барлап, ачыклау кирәклеге күренде.

Мөхәммәтбәдигъ Казанның икенче частендагы өченче участогына караган бишенче мәхәллә мәчете мөәзине Мөхәммәтгалим Хөсәенов гаиләсендә 1853 елда туган. 1874 елның март аенда ике мөәзиннең (азанчының) берсе Фәхретдин Габдессаттаров, ә сентябрьдә этисе Мөхәммәтгалим вафат булгач, мәхәллә халкы бушап калган урынга улы Мөхәммәтбәдигъны сайлый һәм раслауны сорап Казан губернә идарәсенә мөрәҗәгать юллый. Документта аның рекрут чиратында тормавы, мәхкәмәгә тартылмавы, штрафник булмавы, егерме бер яшьтә икәнлеге һәм даими яшәү урыны барлыгы, тиешле дини белем алганлыгы күрсәтелә.

Ул 1874 елның 30 сентябрендә Уфадагы Диния нәзарәтенә барып, тиешле сынау үтә һәм бу хакта 2966 санлы таныклык алып кайта.

1875 елның гыйнвар аенда Мөхәммәтбәдигъның документлары Губернә идарәсендә тикшерелеп, Тихвин урамындагы 5 нче таш мәчеткә рәсми рәвештә азанчы, ягъни мөәзин вазифасына билгеләнә [5: 2].

Мөхәммәтбәдигъ шул заман өчен алдынгы фикерле, киң карашлы, шигъри күңелле кеше булган. Моңа аның «Бәгъзе вакыйгате тарихи» дигән елъязмасы гына да ачык дәлил булып тора. Ул хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университетның Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана. Әлеге ядкярне тикшереп, әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдинов (1929–2016) «Гасырлар авазы=Эхо веков» журналының 2006 елгы 1 нче санында «Бәдигъ мәзин елъязмасы» дигән этрафлы мәкалә бастырды. «Бәгъзе вакыйгате тарихи»дан күренгәнчә, ул шәһадәтнамә, васыятьнамә, талак кылу, гариза, төрле прошение формаларын төзегән, үзе укый торган хөтбәләр язган. Бу аның мөселман хокукыннан шактый хәбәрдар булганлыгы турында сөйли.

Вакыйгалар язмаларында Бадыгъ Казанда булган төрле мөхим хәлләрне хәбәр итә; 1888 елда муллаларга рус теле белүне кертмән хокук та, 1887 елда Вятка өязенә Казан университетыннан йокле таш карарга экспедициясе китүне дә, хава торышларын да тапшыра. Казан Дәүләт Университетының сирәк кулъязма бүлегендә ул экспедициядә төшкән фотосүрәт саклана. Шулар арасында, 1887 елның 7 августында кояш батылып, мәчеттәге галимнәр (муллалар) бу могҗизаны караганнын яза. Әлбәттә, мөәзин Мөхәммәдбадыгъ алдынгы галимнәрдән карашлары белән калышмаган.

Без белгәнчә, М. Хөсәенов этисеннән мирас булып калган йорттында яшәгән. К. Насыйри 1859 елның 21 сентябрендә Мәскәүгә абзыйсы Габделхәйгә язган хатында «Галим абзый яңа өйгә кергән» дип хәбәр итә [4: 559]. Әмма, мөәзиннең әйтелгән елъязмасында «1888 сәнәдә яңа йорт салып чыктык» дигән юллар бар. Йортның 1969 елгы сызымы буенча да, аның төзелеше 1880 еллар дип күрсәтелгән.

Ләкин оклад кенәгәсенең Казанның 2 нче өлеше буенча күчемсез милек өчен шәһәр взносы турында кызыклы язмалар саклана.

ТР Милли архивы фондында 1869 елдан башлап агач йорт өчен җыем исәпләнгән оклад кенәгәсе язмалары сакланган. Йорт исә Мөхәммәдгалим Хөсәеновныкы булган.

Алар нигезендә, Хөсәенов Мөхәммәдгалимның 1869 елда агач йорт өчен җыем исәпләнә. Хөсәенов Мөхәммәтбәдигъка исә, 63 кв. сажин

мәйданлы агач йорт өчен 112 сум 50 тиен күләмендә җыем каралган. 1902 елга кадәр Хөсәеновларның йортлар өчен түләүләре теркәлеп бара. Мәсәлән Бәдигъ Хөсәенов, 1894 елдан 1902 елга кадәр ай саен 400 сум тәнкә түләп барган [6: 304–305].

Мөхәммәдбәдигъның килене Хәдичә (Бурганова) хәтерендә йорт турында сакланган истәлекләр буенча ишекнең уң ягында кухня, сул ягында галимнең остаханәсе урнаша. Беренче катның Көнчыгыш яртысында кызы (Фәкиһә) яшәгән, ә йортның икенче катында йорт хуҗасының гаиләсе яшәгән. Янкорманың көнчыгыш яктан чыгып торган фасадының төньяк-көнчыгыш ягында беренче катта К. Насыйри файдалана торган кечкенә генә эш бүлмәсе бар, аңа урамнан аерым керү урыны да бар. Йорт сазлыклы урынга салынганга, өй базында һәрвакыт су булган; йортның фасадлары майлы буяу белән тышланган, аксыл-соры төскә буялган. Өй эчендә исә стеналарга обойлар ябыштырылган. Йортның уң ягында капка һәм флигель, янында җиләк-җимеш бакчасы, чатыр, сарайлар була. Бүгенге көндә, күбесенчә бакча урыны «К. Насыйри исемендәге аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 80 нче номерлы татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе» җирлегенә кергән.

Мөхәммәтбәдигъ берничә тапкыр өйләнә. Беренче хатыннан Кәрим исемле уллары туа. Хатыны Гайнелхәят Шәриф кызы 1877 елда вафат була. Шул ук елда Казанның Яңа бистәсендәге Мостафа исемле кешенең Бибизөһрә исемле кызына никахлаша һәм 1880 елда уллары Рафыйк туа. Мөәзиннең бу җәмәгате дә 1882 елда 23 яшендә бакыйлыкка күчә.

Өченче хатынынннан (исеме әлегә мәгълүм түгел) кызы Факиһа (1890–1959), улы Әхмәт (1895–1944) туа. Бу балаллар да анасыз калып, үги ана белән үсәләр.

Мөхәммәтбәдигъның Бибимәрьям (1871–1894) һәм Җәмилә (?–1891) исемле сеңелләре булганлыгы мәгълүм. Алар икесе дә яшьли вафат була. Беренчесенең Әминә исемле 4 яшьлек кызы, икенчесенең Габдулла исемле 3 яшьлек улы кала.

1932 елда йортны саталар һәм хуҗалар флигельгә күчәләр һәм 1935 елга кадәр шунда яшиләр. Флигель сүтелеп, йорт хуҗалары Казанда хөкүмәт фатирына күчә. Шул елны Рөстәм Хусаинов (Хәдичә улы) сөйләү буенча, йортны Мөхәммәдбәдигъ улы Әхмәт, ат караучы Галигә сата.

Әхмәт ага белән хатыны Хәдичә К. Насыйриның паспортын үзләрендә саклаганнар һәм соңыннан аны шул вакыттагы СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшырганнар.

К. Насыйри үзенең соңгы сыену урынын туганы гаиләсендә таба. Мөхәммәдбәдигъ йортында 1899 елдан башлап, 1902 елның 21 агустына (яңа стиль белән 3 сентябренә) вафатына кадәр яши.

ТР Милли музей фондында бу йортның 1960 елларда төшерелгән һәм 1979 елда эскиз проект төзү нигезендә төшерелгән фотолар сакланган.

Тарихи йортның бу фотосурәтләрендә аерманы күрергә мөмкин. 1979–1980 елларда, йорның агач тәрәзә йөзлекләре алмаштырылган, урамга карап торган тәрәзәләр киңрәк һәм түбәнрәк. 1960 елда тәрәзә йөзлекләре

озын булганлыгы күренә. Гадәти милли стильдә төзелгән тәрәзә йөзекләре үзләре аерым үзенчәлекле бер бизәк булып тора.

Фотографияләр нигезендә, йортның утынлыкка 1955 елларда җайлаштырылган, аның өчен аерым керү һәм баскыч янкарма барлыгы күренә [1: 5].

Каюм Насыйри яшәгән соңгы йортны саклау кирәклеге турында сүзләр 1922 елда ук яңгырап ала. Бу мәсьәлә Бөек Ватан сугышы елларында да күтәрелә, 1945 елда ТАССР Дәүләт музеенда К. Насыйрига багышланган почмак оештырыла.

1979 елда Париж Коммунасы урамын төзекләндерү уңае белән Мөхәммәтбәдигъ йортын К. Насыйри һәм Ф. Кәрим урамнары чатына күчерү мәсьәләсе калка. Моның өчен проект төзелә, фотосурәтләр, эскизлар әзерләнә.

1981 елның 1 апрелендә фәнни-төзекләндерү Советында йортны үзенең тарихи урынында калдыру турында карар кабул ителә. Архитектор Рәфыйк Билалов тарафыннан янгынга каршы саклык чаралары күрелә, барлык агач конструкция тиешле матдә белән эшкәртелә. Булачак музейның бинасына рәсми «Каюм Насыйри исемендәге мемориаль музей» статусы бирү карала. Шул ук елда Татарстан АССР Министрлар Советының 601 нче карары нигезендә йорт дәүләт тарафыннан саклануга алына. Бу вакытка ул инде шактый таушалган була. Шул вакытта алдырылган фотода аның җиргә шактый иңгәнлеге күренә.

Йортның соңгы фотосурәте К. Насыйри кардәшләренең берсе, рәссам Рушан Шәмсетдинов тарафыннан 1983 елда алдырыла. Бичара йорт, янгынга дучар булып, күмергә кала. Ләкин, беренче музей мөдире Р. Хөснетдинова язганча, М. Хусаинов йорты сүтелә, 1981 елдан алып иске йортның, алдан төзелгән проект нигезендә тугәл күчермәсе торгызыла [8].

1986 елда бу реконструкцияләнгән бинада фольклор үзәге ачыла [3: 4]. Ләкин бина 1989 елда яна һәм кабат торгызыла.

Инде 2002 елда, монда Каюм Насыйри мемориаль музее ишекләрен ача (Париж Коммунасы урамы, 35 йорт). Бу вакыттан алып, Каюм Насыйри исемендәге музее тарихы башлана.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. АО «Техническое бюро инвентаризации». Д. 3135. Л. 5, 28.

2. *Гайнуллин М.* Атаклы галим һәм язучы Каюм Насыйри // Совет әдәбияты. 1944. № 1. Б. 71–78; № 2–3. Б. 87–93.

3. *Зиганшина А.* К юбилею без музея // Вечерняя Казань. 2000. № 21. С. 4.

4. *Исламов Р.Ф.* Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-библиографик җыентык. Казан: Җыен, 2017. 559 б.

5. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 2. Оп. 2. Д. 2. Л. 2.

6. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 98. Оп. 6. Ед. хр. 451. Л. 304–305.

7. *Хөснетдинова Р.* Андыйлар табигатьтә сирәк очрый // Казан утлары. 1998. № 4. Б. 144–148.

8. *Хөснетдинова Р.* Насыйри мирасын мәңгеләштерү мәсьәләләре // Шәһри Казан. 2000. 4 апр.

УДК 821.161.1

# РЕЦЕПЦИЯ ПРОСВЕТИТЕЛЬСКИХ ИДЕЙ КАЮМА НАСЫРИ В ТВОРЧЕСТВЕ АЙГУЛЬ АХМЕТГАЛИЕВОЙ

***Р.Р. Хусаенова***

*Казанский федеральный университет (Казань)*

*Статья написана и опубликована при финансовой поддержке РНФ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта «Проведение фундаментальных научных исследований и поисковых научных исследований малыми отдельными научными группами» (региональный конкурс)» № 24-28-20211*

В статье рассматривается влияние просветительских идей выдающегося татарского просветителя Каюма Насыри на творчество современной татарской писательницы Айгуль Ахметгалиевой. Проводится анализ произведений А. Ахметгалиевой с целью выявления отголосков просветительских взглядов К. Насыри на образование, религиозную концепцию, науку, культуру и национальную идентичность. Подчеркивается актуальность наследия К. Насыри для современного татарского общества и его отражение в художественном мире А. Ахметгалиевой.
**Ключевые слова:** Каюм Насыри, Айгуль Ахметгалиева, татарская литература, просветительство, рецепция, религиозная концепция, национальная идентичность, образование, культура.

The article examines the influence of the educational ideas of the outstanding Tatar enlightener Kayum Nasyri on the work of the modern Tatar writer Aigul Akhmetgalieva. An analysis of the works of A. Akhmetgalieva is being carried out in order to identify echoes of K. Nasyri's educational views on education, religious concept, science, culture and national identity. The relevance of K. Nasyri's heritage for modern Tatar society and its reflection in the art world of A. Akhmetgaliyeva is emphasized.
**Keywords:** Kayum Nasyri, Aigul Akhmetgalieva, Tatar literature, enlightenment, reception, religious concept, national identity, education, culture.

Творчество Каюма Насыри (1825–1902) занимает особое место в истории татарской культуры и просвещения. Его многогранная деятельность, охватывающая вопросы образования, науки, языка и культуры, оказала огромное влияние на формирование татарской национальной идентичности. Актуальность изучения наследия К. Насыри не утрачена и в современном татарском обществе, стремящемся к сохранению и развитию своей культуры и языка. В этом контексте особый интерес представляет рецепция просветительских идей К. Насыри в творчестве современных татарских писателей, в частности, Айгуль Ахметгалиевой.

Айгуль Ахметгалиева – современная татарская писательница, чьи произведения отличаются глубоким анализом социальных и культурных проблем, тонким психологизмом и ярким национальным колоритом. В её творчестве прослеживается стремление к осмыслению прошлого и настоящего татарского народа, к поиску путей сохранения национальной идентичности в условиях глобализации. Целью данной статьи является выявление

и анализ рецепции просветительских идей К. Насыри в художественном мире А. Ахметгалиевой.

Просветительские идеи Каюма Насыри, направленные на развитие образования и науки среди татарского народа, находят свое отражение в творчестве Айгуль Ахметгалиевой. К. Насыри придавал огромное значение изучению родного языка, считая его основой национальной культуры и идентичности. В своих произведениях А. Ахметгалиева часто поднимает вопросы сохранения и развития татарского языка, его роли в жизни современного татарского общества, а также вопросы религии. Она показывает, как знание родного языка помогает сохранить связь с историей и культурой народа, укрепляет национальное самосознание.

К. Насыри активно пропагандировал научные знания, стремясь к расширению кругозора татарского народа, к приобщению его к достижениям мировой цивилизации. В произведениях А. Ахметгалиевой также прослеживается интерес к науке, к новым технологиям, к роли образования в формировании личности. Она показывает, как образование помогает человеку стать более свободным и независимым, как оно способствует его духовному и интеллектуальному развитию.

К. Насыри был убежден в необходимости сохранения и развития татарской культуры, в ее уникальности и самобытности. В своих произведениях А. Ахметгалиева также уделяет большое внимание вопросам культуры, традиций, обычаев татарского народа, религиозной концепции. Она показывает, как культура помогает сохранить связь с прошлым, как она формирует национальную идентичность, как она обогащает духовный мир человека.

Одним из важных аспектов просветительской деятельности К. Насыри было формирование национального самосознания татарского народа. Он призывал татар к осознанию своей истории, культуры, языка, к гордости за свое происхождение. В произведениях А. Ахметгалиевой также прослеживается стремление к укреплению национального самосознания татарского народа. Она показывает, как важно знать свою историю, помнить о своих корнях, чтобы не потерять свою национальную идентичность в условиях глобализации. Это мы видим в произведении «Таллыкүлдә былбыл бар» («Соловей озера Таллыкуль»).

Главный герой Шамиль, не приезжавший в деревню 25 лет после смерти бабушки, поражен состоянием Таллыкуль: *«Зариф янына сугылганчы ук, күкрәгендә актарылган дулкын шавын тыя алмыйча, аскы урамнардан, Таллыкүл буйларыннан урап килгән һәм аптыраудан шаккаткан иде. Авыл урамыннан үләт чире кырып үткәнмени: хәлле генә күренгән йортлар янәшәсендә капка буен бил тиңентен кычыткан баскан, тормыш гаме сүнгән, хуҗасыз калган байтак өйләр күзгә ташлана. Чокырланып беткән юллардан бүгенгедәй коры көнне дә рәтләп йөрерлек түгел. Яңгыр-мазар яуса, җиңел машина белән авылга бөтенләй керешле-чыгышлы булмыйдыр, мөгаен. Ә Таллыкүл?.. Ул юк, бөтенләй булмаган кебек юкка чыккан; иелә-бөгелә елаган таллар гына кемнәндер ярдәм сорап сыкрана шикелле. Шул тирәгә өелгән чүплек тавы гына бирегә адәм балаларының сукмагы өзелмәгәнен сөйли иде. Шамил күзе күргәннәргә ышанмыйча, машинасыннан төшеп, таллар янына якынрак килде. Борынына бәрелгән әшәке истән күңеле болганса да, кире борылырга ашыкмады. Кайчандыр ай нурында*

*шадраланып торган тымызык күл өсте урынында төзелеш калдыклары, иске машина кабинасы, капчык-капчык әллә тавык, әллә үрдәк йоннары, бәдрәф кәгазьләре, күгәреп бер-берсенә ябышкан кием-салым, хәтта сарык үләксәләренә хәтле аунап ята иде»* [1: 11–12] («Еще не доехав до Зарифа, не в силах сдержать шум волнения, что поднимался в его груди, он объехал окольными путями по нижним улицам, по берегам Таллыкуль, и от изумления застыл. Словно чума прошла по деревенской улице: рядом с домами, которые выглядят вполне благополучными, у калитки по пояс выросла крапива, угас жизненный интерес, в глаза бросается много бесхозных домов. По изрытым дорогам даже в такой сухой день нормально не проехать. Если пойдет дождь, то на легковой машине в деревню, наверное, совсем не въехать и не выехать. А Таллыкуль?.. Его нет, словно его и не было вовсе; только склонившиеся в плаче ивы стонут, словно просят у кого-то помощи. Только гора мусора, наваленная в том месте, говорила о том, что дорога сюда не заросла. Шамиль, не веря своим глазам, вышел из машины и подошел к ивам поближе. От отвратительного запаха, ударившего в нос, его замутило, но он не спешил повернуться назад. На месте когда-то рябившей в лунном свете тихой глади озера лежали строительные отходы, старая кабина машины, мешки то ли с куриными, то ли с утиными перьями, туалетная бумага, позеленевшие и слипшиеся тряпки, даже трупы овец» – подстрочный перевод. – *Р.Х.*). В этом произведении также особое место занимает религиозная концепция. Путь выхода из проблем, которые есть в этом произведении, автор передает через героя Рифата. Рифат видит успехи хозяйства, в котором работает, в сильной руке хозяина и в его религиозности: *«Безнең хуҗа барысын да кулда тота белгәнгә. Үзе дә җир җимертеп эшли, кешедән дә таләп итә белә. ...Ничава, бер ел эчендә барыбыздан да майланган коймак ясады: әлифне таяк дип тә белми идек, мәчеткә барып вәгазьләр тыңлый торгач, намазга да өйрәндек, тормышка бүтән күз белән карый башладык. Дин белән алдырды – нигә яшереп торырга. Урлашу юк, эчү юк, аның каравы халыкка эш бар, акча бар»* [1: 47–48] («У нас хозяин все умеет держать в руках. Сам тоже работает, как вол, и с людей умеет требовать. ... Ничего, за год из всех нас сделал масляные блины: мы и букву алиф как палочку не знали, а теперь, слушая проповеди в мечети, научились и намаз читать, и на жизнь стали смотреть другими глазами. Религией взял – чего уж скрывать. Воровства нет, пьянства нет, зато у людей есть работа, есть деньги»).

Шамиль и сам видит правду в этих словах, потому что с похожим явлением столкнулся в селе Аккуль-Азюрка в Мордовии. Там удивительно налаженная мирская жизнь переплетается с религиозной: *«Басудагы халык бил турайтып күтәрелеп басты, барысы берьюлы эш ташлап, азан тыңлап хозурландылар, аннан кайсы кая намазлык җәеп, сәҗдәгә иелделәр. ...Шул мәлдә ул үзе өчен гаҗәеп тоелган ачыш ясады: күкрәп яшәгән авылның төп көче сәүдәгәрлектә түгел, гасырлар буе сакланып калган диндә, иман ныклыгында иде»* [1: 46–47] («Люди в поле выпрямились и застыли, все разом бросили работу и наслаждались, слушая азан, затем кто где расстелил намазлык и склонились в земном поклоне. ...В тот момент он сделал для себя удивительное открытие: главная сила процветающего села не в торговле, а в религии, сохраненной веками, в крепости веры»). Знание

о том, что в Аккуль-Азюрке семь мечетей и все они посещаются, только укрепляет его эти мысли. Но в то же время Шамиль понимает, что религия не в мечети, а в душе человека.

Также в произведении приводится риторический вопрос *«Шулай да нинди генә затлы киемгә төренеп, нинди генә югары урында эшләмәсеннәр, аларның тамырлары монда бит! Тамырларыннан йөз чөергәнне кем генә ярлыкар»* [1: 85] («В какие бы роскошные одежды они ни были одеты и на каких бы высоких постах ни работали, их корни все равно здесь! Кто благословит того, кто отвернулся от своих корней?») – горесть родной земли воспринимается автором как риторический вопрос, выражающий тоску по родной земле.

Подводя итоги, можно сказать, что в произведении Айгуль Ахметгалиевой «Таллыкүлдә былбыл бар» («Соловей озера Таллыкуль») очень хорошо изображены явные примеры безбожия и аморальности. Автор мастерски подчеркивает эти проблемы, что делает произведение актуальным и важным для обсуждения и в современном обществе.

Еще одна повесть Айгуль Ахметгалиевой «Кичке таң» (рус. «Вечерняя заря») занимает особое место в современной татарской литературе, отличаясь лиризмом, психологической глубиной и вниманием к вопросам национальной идентичности. Повесть о великодушных врачах в белых халатах, а также об искренности, душевности, красоте и милосердии. Писательница повествует и заставляет задуматься о судьбах, балансирующих на волоске, о вере и надежде, любви, потере, обретении и печали.

# ПРАКТИЧЕСКОЕ ЗНАЧЕНИЕ СОПОСТАВИТЕЛЬНОГО МЕТОДА ПРИ ОБУЧЕНИИ РУССКОМУ ЯЗЫКУ ТАТАР
## (на примере деятельности ученого-педагога Каюма Насыри)

***М.М. Шакурова***
*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Данная статья посвящена исследованию научного наследия по обучению детей русскому и татарскому языкам в XIX–XX вв. Этот период характеризуется активным поиском новых теоретически обоснованных методов, приемов и форм обучения языку. Методическое наследие Каюма Насыри имело большое теоретическое значение, определило собой практическую деятельность школы на многие десятилетия и до сих пор не потеряло своей актуальности для современной школы. Особое место в области методики изучения языка в русско-татарской школе этого периода занимают азбуки, грамматики, учебники и словари Каюма Насыри. В статье рассматриваются его работы в историко-методическом плане.
**Ключевые слова:** татарский язык, русско-татарская школа, Каюм Насыйри, двуязычие, сопоставительный метод.

This article is devoted to the study of the scientific heritage of teaching children Russian and Tatar languages in the 19th–20th centuries. This period is characterized by an active search for new theoretically sound methods, techniques and forms of language teaching. The methodological heritage of Kayum Nasyri was of great theoretical importance, determined the practical activities of the school for many decades and has not lost its relevance for the modern school to this day. A special place in the field of language teaching methods in the Russian-Tatar school of this period is occupied by the alphabets, grammars, textbooks and dictionaries of Kayum Nasyri. The article examines his works in historical and methodological terms.
**Keywords:** Tatar language, Russian-Tatar school, Kayum Nasyri, bilingualism, comparative method.

# ТАТАРЛАРГА РУС ТЕЛЕН ӨЙРӘТҮДӘ ЧАГЫШТЫРМА ЫСУЛНЫҢ ГАМӘЛИ ӘҺӘМИЯТЕ
## (галим-педагог Каюм Насыйриның эшчәнлеге мисалында)

***М.М. Шәкурова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

XIX гасырда күпләп басылып чыккан сөйләүлекләр, үзөйрәткечләр, грамматика китаплары, сүзлекләр татар телен укыту методикасы өлкәсендә яңа фикерләр уятты, укытуның эчтәлеген ачыкларга, эш алымнарын эзләргә мөмкинлек бирде. Үзләренең бөтен гомерләрен, белемнәрен татар һәм рус халкының телен, тарихын өйрәнүгә, татар мәгарифен үстерүгә, татар балаларына рус телен укытуга багышлаган бер төркем галимнәр, укытучы-методистлар бар: В.В. Радлов, Каюм Насыйри, И.А. Бодуэн де Куртенэ, В.А. Богородицкий, Н.А. Бобровников һ. б. Бу чорда аларны татар әдәби теленең фонетикасын, морфологиясен чагыштырма планда аңлатып, укучыны

сөйләшергә, аралашырга, укырга һәм язарга өйрәтү, педагогика һәм методика фәнен эшләү, укыту ысулларын ачыклау мәсьәләләре борчый.

XIX гасырның 60 нчы елларында бер төркем рус педагоглары (П.Г. Редкин, К.Д. Ушинский, А.С. Воронов, Д.Д. Семенов, В.Я. Стоюнин һ. б.) С.-Петербургта Педагогик җәмгыять төзиләр: искечә укыту алымнарын, тәрбия чараларын, дәреслекләрне тәнкыйтьлиләр, Россиядә грамоталылык дәрәҗәсе түбән булуны ассызыклыйлар, бигрәк тә авыл җирләре өчен белемле укытучылар әзерләү, алар өчен китапханәләр ачу турында фикерләшәләр. «Педагогик елъязмалар» дигән журнал да чыгаралар [1: 7]. Кызганычка каршы, 1879 елда патша хөкүмәте бу Педагогик җәмгыятьне яба.

XIX гасырның икенче яртысында рус-татар мәктәпләре күпләп ачыла башлый. Р.Р. Фәхретдинов рус-татар (миссионерлар) мәктәпләренең санын 1870 елларда 70 кә җитүен әйтә [4: 37]. Ләкин «Кое-что о казанском мусульманстве» (1893) дигән китапның авторы («некий мусульманин» – Шахбазгәрәй Исмәгыйль улы Әхмәров) татарларга русларның телен, аның культурасын, гореф-гадәтләрен, әдәбиятын өйрәнергә, рус халкы белән аралашырга, рус-татар мәктәпләренә балаларны курыкмыйча бирергә чакыра: «Министерство же Народного Просвещения, по инициативе которого открывались русско-татарские школы, видя несочувствие населения, перестало открывать их вновь, предоставив татарам самим заботиться о средствах к умственному просвещению и приобретению знания русского языка» [2: 14].

Телләрне чагыштырып, татарча уку-язуга өйрәтү методикасын үстерүдә Каюм Насыйри хезмәтләренең гыйльми һәм гамәли әһәмияте гаять зур. Татар һәм рус телләрендәге авазлар системасы, басым, интонация, орфография, орфоэпия өлкәсендәге кайбер үзгәрешләр сөйләмне аңлауда, телне өйрәнүдә авырлыклар тудыра. Шул сәбәпле татар яки рус телен җентекләп өйрәтүгә керешкәнче, иң элек аның структурасына, бигрәк тә фонетик, лексик һәм грамматик төзелешенә хас булган үзенчәлекләрне, төп кагыйдәләрне үзләштерү бик мөһим. Чынлап та, әлфбадан башлап авазларны татар һәм рус телләрендә чагыштырып өйрәтәбез, аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәләрен бирәбез, тәрҗемә итәбез, ул сүзләр белән җөмләләр төзибез: Татар һәм рус телләрендә о һәм ы сузыкларын әйткәндә аерма бармы? *Савыт – авыл, ваза – вагон* сүзләрен бер-берегезгә әйтеп карагыз. В тартыгын татар һәм рус телләрендә әйткәндә аерма бармы? һ. б. [7: 66–72].

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров татар телен фән буларак мәктәпләрдә өйрәнергә кирәклеккә әйтә. Ул 1825 елның 14 (2) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында укымышлы гаиләдә туган. К. Насыйри – тәрҗемәче, тарихчы, эпиграфист, тел галиме, лексикограф, педагог. Аның гыйльми-мәгърифәтчелек эшчәнлеге XIX гасыр урталарыннан башлана. Ул төрле уку китаплары һәм дәреслекләр яза башлый: «Нәху» (Рус телендә язылган һәм «Краткая татарская грамматика» дип атала): Русча өйрәнүче мөселман егетләре вә татарча өйрәнүче рус егетләре өчен тәсниф кыйлынды (1860). Мәгърифәтче-укытучы буларак, татар һәм рус телләренең грамматикасын яхшы белә, чагыштырма методикага нигезләп аңлата: *«...Ләкин гайре телне өйрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кавагыйдатен белмәк зарурдыр»* («Фәвакиһел җөләса»). Әлеге дөньякүләм танылган хезмәт бүген дә әһәмиятен югалтмаган. Ул – XIX гасырның икенче яртысында татар лингвистикасының үсешенә үзеннән зур

өлеш керткән галим. Профессор Л.З. Шакирова XX гасыр башларында татарларга рус телен өйрәтү барышында файдаланылган табигый, тәрҗемәи (чагыштырма), катнаш һ. б. ысулларга тирән анализ ясады, үзенең тасвирый бәяләмәсен бирде. Ул чагыштырма ысулның нәкъ менә Каюм Насыйрилар заманында ук кулланылышка керүен, алар тарафыннан тәкъдим ителүен искәртә [5: 5–6].

XIX гасырның икенче яртысында рус-татар мәктәпләренең күпләп ачыла башлавында бөек педагогның да роле бик зур. Бу чорда Каюм Насыйриның татар һәм рус телләрен укытуга керткән өлешен дә ассызыклап үтәргә кирәк [6: 208]. «Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы» дигән хезмәтендә 1871 елда педагог Каюм Насыйриның күргән кыенлыклары, яшәү шартлары, ачлы-туклы яшәүгә дә карамастан, укучыларны берәмләп эзләп табып, ихлас татар телен өйрәтүе, татар һәм рус мәдрәсәләрендә телгә өйрәтү вакыты, баланы русчага укытуда министрлык, инспектор хәзрәтләре, әти-әниләрнең фикерләре зур ихтирамга лаек: «*Бөтен кыш буенча утыз биш малайдан ким булмады, һәм укырга-язарга вә һәм гыйльме хисапка яхшы төшенүчеләр булды*» («Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы»). Духовная семинариядә татар телен укыту белән берлектә рус телен дә яхшылап өйрәнә, соңыннан булачак галим Казан университетына ирекле тыңлаучы булып керә.

1889 елда татарларны русча укырга-язарга өйрәтү өчен, Каюм Насыйри «Кавагыйд кыйраәт русия» («Русская азбука») дигән китап яза. 24 битле бу әлифба, 50 дәрескә бүлеп, рус һәм татар хәрефләрен, сүзләрен чагыштырып, җентекләп эшләнгән. Телгә өйрәтүдә татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләре дә (1878, 1892) мөһим роль уйный: *«Сүзләрне берәм-берәм ятлап, һәрбер ишеткән сүзне исеңдә тотып, берәм-берәм зиһен тубалына тутырырга кирәк. Моның мисалы менә шундый: берәү, бер чиләк алып, урманга җиләк җыярга бара. Иң элек, урман авызына кергәч, чиләгенә бер җиләк өзеп сала. Шулай кичкә чаклы йөреп, чиләген тутыра»* («Русча-татарча лөгать»тән) [6: 36].

Каюм Насыйри әхлак, тәрбия, уку-укыту мәсьәләләрен бергә үреп бирә: «Гыйлемлек вә наданлык», «Ата-ана хакы», «Хәйләкәрлек», «Әдәп» һ. б. Педагог баланы яшьтән үк акны карадан, яхшыны яманнан аера белергә өйрәтсәк, үсеп җиткәч аңа күпкә җиңел булачагын, тормышта ориентлашып, үз урынын, үз юлын дөрес табачагын әйтә, *«...балалар яшь агач кебектер, яшь агач һәрникадәр кәкре булса да, төзәтмәк асандыр»* («Әхлак рисаләсе» (1890)) [3: 38].

1892 елда аның «Кавагыйде китабәт» (Язу кагыйдәләре) дигән кулланмасы басылып чыга. Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ» дигән хезмәтен (1895) шул чорның беренче гыйльми тулы грамматикасы дип атыйлар [3: 57]: *«Утыз-утыз биш елдан бирле ике тел фәннәреннән, ягъни үз телебездән вә дәхи рус теленнән балаларга сабак укытканда, хосусан рус телен укытканда үз телебезнең кагыйдәсен бәян кылгучы бер китапка мохтаҗ буладыр идем»*. Шул уңайдан татар телен гыйльми өйрәнүгә, татар телен укыту методикасын үстерүгә зур өлеш керткән Казан тюркология мәктәбенең роле дә, һичшиксез, зур (В. Радлов, Н. Катанов, И.А. Бодуэн де Куртенэ, В.А. Богородицкий һ. б.).

Россиядә XIX гасыр ахырына кадәр уку-укыту һәм тәрбия мәсьәләләре буенча күпме проектлар эшләнсә дә, 1917 елга кадәр аларны тормышка ашыра алмыйлар. Балаларын үстерү, аларны укыту, югары тәрбия бирү, ир балалар белән бергә кызларны да мәктәпкә тарту, мәктәпләр төзү, аларны ашату-эчертү – рус һәм татар педагог-галимнәренең уртак проблемаларына әйләнә (С.А. Рачинский. «Заметки о сельских школах», 1883; Н.И. Ильминский. «Казанская центральная крещено-татарская школа: Материалы для истории христианского просвещения крещеных татар», 1887; В.Д. Сиповский. «Чего недостает современной школе», «Чему и как учить», 1895 һ. б.). Болар арасында *«аягыма кияргә юк дип укырга йөрмәүче балага кәвеш алып биргән»,* ач-ялангач шартларда, фатир эзли-эзли, шунда дәресләр үткәргән олы җанлы, белемле Каюм Насыйри да бар [3: 39].

Каюм Насыйриның педагогик һәм методик характердагы мәкаләләрен һәм китапларын тикшереп чыккач, шуны әйтәсе килә: Каюм Насыйри – телне өйрәтү методикасының нигезен эшләгән, рус һәм татар халкына армый-талмый хезмәт иткән тәҗрибәле галим-педагог. Ул шәкертләрнең психологиясен яхшы белгән, уку-укыту һәм тәрбиягә караган мәсьәләләр белән бик теләп шөгыльләнгән. Аның лингвистика, методика өлкәсенә караган хезмәтләренең гамәли әһәмияте туган (татар) теленә игътибар бермәбер арткан заманда тагын да ачыграк күренә.

Шулай итеп, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы – телгә өйрәтү методикасының нигезе эшләнгән чор. Бу чорда рус-татар мәктәпләре күпләп ачыла, укытуның эчтәлеге ачыклана, иң уңышлы ысуллар һәм алымнар тәкъдим ителә, әлифбалар, грамматика китаплары, дәреслекләр, сүзлекләр бастырыла. Бигрәк тә рус һәм татар телләрен чагыштырып өйрәтүдә Каюм Насыйриның роле зур була. Бүгенге көндә туган тел (татар теле) дәресләрендә укучыны чагыштырма грамматика, тәрҗемәи сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табарга, җөмлә һәм текстның тәрҗемәсен белеп, сүзләрнең лексик һәм грамматик мәгънәләрен аңлап үзләштерергә, тел берәмлекләрен гамәли яктан кулланып, алга таба синтаксик һәм грамматик конструкцияләр белән иркен эш итәргә, аңлап сөйләшергә, аралашырга өйрәтергә тулы мөмкинлекләр бар.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Антология педагогической мысли России второй половины XIX – начала XX в. / сост. П.А. Лебедев. М.: Педагогика, 1990. 560 с.

2. Кое-что о казанском мусульманстве. Казань: Тип. и литогр. В.М. Ключникова, 1893.

3. *Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: ике томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 320 б.

4. *Фахрутдинов Р.Р.* Татарское либерально-демократическое движение в конце XIX – начале XX вв.: идеология и политическая программа: дис. ... канд. ист. наук. Казань, 1996. 214 с.

5. *Шакирова Л.З.* Обучение русскому языку в татарской школе: теория и практика. Казань: Магариф, 2002. 191 с.

6. *Шакурова М.М.* Становление и развитие методики преподавания татарского языка в иноязычной аудитории // Научный Татарстан. 2010. № 3. С. 207–214.

7. *Шәкүрова М.М.* Туган тел (татар теле). Әлифба. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен / М.М. Шәкурова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов; [рәссамы Л.С. Золондинова]. Казан: ТР ФА нәшр., 2023. 128 б.: рәс. б-н.

УДК 821.512.145

# ТЕМАТИЧЕСКОЕ МНОГООБРАЗИЕ В СОВРЕМЕННЫХ РАССКАЗАХ

***Ч.Р. Шарипова***
*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Жанр рассказа, занимающий важное место в современном татарском литературном процессе, ориентирован на тематическое разнообразие. Наиболее широко и полно отражены вечные, национальные, социально-общественные темы, отражающие изменения времени и особенности личного творчества писателя. Через них авторы ставят в центр повествования вопросы смысла жизни, человеческого счастья, взаимоотношений родителей и детей, сохранения нравственных качеств, любви и ненависти, добра и зла и т. д. С этой целью часто обращаются к метафорам, символам, литературным деталям, а также к мотивам сна, памяти, воспоминаний.
**Ключевые слова:** татарская литература, литературный процесс, рассказ, тема, эпоха, герой, средства изображения.

The genre of the short story, which occupies an important place in the modern Tatar literary process, is focused on thematic diversity. Eternal, national, socio-social themes reflecting the changes of time and the peculiarities of the writer's personal work are most widely and fully reflected. Through them, the authors place at the center of the narrative the issues of the meaning of life, human happiness, the relationship between parents and children, the preservation of moral qualities, love and hate, good and evil, etc. For this purpose, they often turn to metaphors, symbols, literary details, as well as motives for dreams, memories, and memories.
**Keywords:** Tatar literature, literary process, story, theme, epoch, hero, means of representation.

# ХӘЗЕРГЕ ХИКӘЯЛӘРДӘ ТЕМАТИК ТӨРЛЕЛЕК

***Ч.Р. Шәрипова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (Казан)*

Хәзерге татар әдәбиятында кече жанрлар, шул исәптән хикәя заман үзгәрешләрен үзендә шактый тулы чагылдыра. Моңа эстетик кыйммәтләрнең үзгәрүен, язучыларның заман таләпләренә тугры калып, укучы кызыксынуларына бәйле алып барылган эзләнүләрне, яңалык формасында кертелгән жанр үзенчәлекләрен кертеп карарга мөмкин. Чынбарлыктагы авырлык-каршылыклар әдәби әсәрләргә дә үтеп керә. Шуңа да заман геройлары тормышта үз урыннарын табу өчен җитди көрәш алып бара. Болар барысы да проблемалар төрлелегенә, тематик киңлелеккә китерә. Заман хикәяләренең тематик киңлелеген тикшерү хәзерге әдәби процесс үзенчәлекләрен, аерым авторларның сәнгати эзләнүләре киңлеген тулырак аңларга, бәяләргә мөмкинлек бирә. Хезмәтнең актуальлеге әнә шулар белән билгеләнә.

Хәзерге әдәби процесста хикәя иң актив жанр булып кала, шуңа да ул даими тәнкыйтьчеләр һәм әдипләрнең игътибар үзәгендә тора (Л. Әбүдәрова [1], Г. Гайнуллина [2; 3], Г. Гайфиева [4], Ә. Закирҗанов [6], Р. Зәйдулла [9], Д. Заһидуллина [5; 7; 8] һ. б. хезмәтләрендә әлеге жанрга хас үзенчәлекләр, аның төзелеш-композициясе, герой бирелеше, әдипләр

мөрәҗәгать иткән сурәт чаралары төрле яктан тикшерелә. Г. Гайфиева хикәя жанрына караган әсәрләрнең поэтикасыу макчатчан өйрәнеп, эчтәлек һәм форма, тематика, геройлар системасыу, сәнгати чараларның әдәби функциясен аерып чыгара [4]. Заман хикәяләрен эзлекле тикшергән Д. Заһидуллина: «Хикәя прозадагы үзгәрешләргә сизгер, яңарыш һәм үсеш кичерүче жанр булып кала. Заман хикәясендә татар әдәбияты өчен традицион алымнарның – психологизм, фәлсәфи гомумиләштерүләргә алып килү, эмоциональлек, символлар теле белән эшләүнең – яңа мөмкинлекләре барлана» [8: 157], – дип яза. Галимә әлеге жанрга хас җитди үзенчәлекләрнең берсе буларак, башка жанрга хас сыйфатлар белән баюын, аның синтетизм күренеше тәшкил итүен һәм шуның белән чынбарлык вакыйгаларын тулырак ачуга ирешүен күрсәтә [5: 471]. Әдәби процесска күзәтү ясап, Р. Зәйдулла болай дип яза: «Гасырдан артык хикәя татар укучысының әдәбиятта иң яраткан жанр булып тора. Аның кыскалыгы, фикергә, сурәтләргә бай булуы иң беренче шарт. Кинаяләр, шигърияткә хас алымнар, интрига булганда хикәянең әһәмияте, мавыктыргыч көче тагын да арта. XXI гасыр хикәясенә күптөрлелек хас» [9: 144]. Болар барысы да хикәя жанрына булган кызыксынуның зур булуын күрсәтә.

Хәзерге хикәяләрдә мәңгелек, милли, соиаль-иҗтимагый һ. б. темалардан яшәеш мәгънәсе, мәхәббәт һәм нәфрәт, ата-ана каршындагы изге бурыч һ. б., шулай ук дуслык-тугрылык, гаилә, ата-ана һәм бала, хезмәткә караш, әхлакый кыйммәтләрне саклап яшәү һ. б. еш очрый. Иң актив хикәячеләрнең берсе булган Г. Гыйльманов әсәрләрендә дөньяда мәгънәле, язмыш каршылыкларыннан курыкмыйча яшәү фәлсәфәсе чагылыш таба. Аның геройлары – тормышта чыныккан, гел алга таба атларга гадәтләнгән һәм шуңа омтылучы шәхесләр. Әдипнең үтә дә үзенчәлекле геройлары хыял белән чынбарлык чигендә яшиләр, шул ук вакытта алар тетрәндергеч язмышлы, әмма үз идеалларына, рухи кыйблаларына тугры калалар. Язучының «Йодрык» әсәрендә хикәяләүче чечен сугышындагы мәхшәр эчендә булып, үзләре дә вәхшилек кылган, кешелек әсәре дә калмаган яшьләрдән куркып кала, ул гына түгел, алар утырган вагон да алар керү белән ыңгырашкан кебек була. Автор вагон эчендә сугыш вакыйгаларын сөйләп баручы егетләрнең күргәннәрен хикәяләүче авызыннан җиткерә, моның өчен ул бożралы композиция алымын куллана. Вакыйга эчендәге вакыйгада Чечняда булган хәлләр, егетләрнең Йодрык-тау исемле тау янында сугышулары, әлеге тауның «җанлы» булуы, шушы тау янында егерме җиде көрәштәшләрен югалтуларын, Рамазан исемле яшь егетне сатлыкҗанга санап, җәзалап үтерүләре турында сөйләнә. Ул үзендә курку һәм җирәнү уяткан егетләргә каршы тору көчен тоймый, аларга курку катыш нәфрәт белән карый, гомумән, транспорттагы халыкның да алардан куркуы бөтен җәмгыятькә бәя буларак яңгырый.

Г. Гыйльманов әсәрләрендә мәхәббәт темасы яктыртылышы да кызыклы һәм үзенчәлекле. «Саташу» хикәясенең төп герое Искәндәр чибәр кыз Лилиана корган тозакка төшә. Кыз аны тән мәхәббәте белән ләззәт «диңгезенә» алып керә. Әмма автор ассызыклавынча, мондый мәхәббәттән салкынлык бөркелә, ул чын түгел. Искәндәр образын автор төш белән янәшә куя. Хикәядә вакыйгалар хыял-чынбарлык белән үреп бирелә. Тормышта үз-үзен таба алмаган, «җиңел» мәхәббәттән тәм тапкан, наз эзләп йөргән Лилиана

язмышы белән төшендә күргән мәхәббәтен бик озак эзләп тә, аны бер минутлык ләззәткә алыштырган Искәндәрнең язмышы чагыштырып бирелә.

А. Әхмәтгалиева хикәяләрендә яшәеш фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итә. Автор күп санлы гаилә-мәхәббәт темасы чагылган, көнкүреш проблемаларын үзәккә алган әсәрләр иҗат итә. Шулар аша милләт темасына да «күпер» суза. Әсәрләрендә гаилә-мәхәббәт темасының милләт язмышын кайгыртучы алтын багана икәнен кат-кат исбатлый ул. Авторның «Җиде ят» хикәясе бу яктан шактый ук кызыклы һәм игътибарга лаек. Автор биредә капма-каршы кую алымын куллана: ике килен образы сурәтләнешендә геройларның эш-гамәлләренә бәя бирә. Курчак кебек килен каенанага карата битараф, дорфалыгы белән аерылып тора, арадагы салкынлык та арта гына бара. Ул шул дәрәҗәгә җитә, киленнең дә, аның белән бергә Рәшитнең дә авылга кайтулары сирәкләнә. Ә күрше килене Рауза исә игътибары, ярдәмчеллеге белән барысының да күңелен яулап ала.

Бүгенге чор герое яңа шартларда яши, сугыш, ачлык, репрессия эзәрлекләүләреннән ерак, әмма ул да чор белән каршылык эчендә, хәтта аерым әсәрләрдә чорның, туган иленең артык баласы сыйфатында яши, ләкин үз туган иленең патриоты булып кала бирә. Р. Габделхакова еш кына тормыш авырлыгын ялгызы үтәргә мәҗбүр булган, көчле рухлы, чыдам холыклы кешеләр язмышын үзәккә куйган, шәхес һәм аның җәмгыятьтәге роле, шәхес һәм туган җиргә тугрылык темаларын чагылдырган хикәяләр авторы буларак билгеле. Шундыйларның берсе булган «Кышлары салкын булса да...» хикәясе героинясы бик авыр тормыш юлын үтә. Көчле хатын-кыз образы үзәккә куелган әлеге хикәясе белән автор хатын-кызларның түземлеге, «салкын»га да, язмыш давылларына да бирешми торган шәхесләр язмышы турында гына түгел, ә җәмгыятьнең кеше тормышында тоткан урыны, хакимиятнең гади халыкны авырлыкларга түзә алырдай итеп «тәрбияләве» турында уйланырга чакыра.

Хикәяләрдә яшәеш фәлсәфәсе гыйбрәтле вакыйгаларда ачыла. Авторлар язмышка артык ышану, берни дә үзгәртергә теләмәү кебек карашларны кире кагалар. Алгы планга үз язмышыңа үзең хуҗа булу, тормышың өчен җаваплылык тоеп яшәү идеясе куела. Замандаш тормышы, аның җәмгыятьтәге урыны турында уйланган әдипләр еш кына үзгә шартларга куелган геройлар язмышына килеп чыгалар. Алар арасында хәрбиләр тормышы, армия хәлләре, шулай ук төрле сәбәпләр аркасында төрмәгә эләккән гыйбрәтле язмышлар бар. Бу темаларга Г. Гыйльманов, Р. Зәйдулла хикәяләрендә шактый киң урын бирелә (Г. Гыйльмановның «Йодрык», Р. Зәйдулланың «Тәре» хикәяләре). Авторлар хикәяләвендә армиядә гаделлек һәм рухи бөтенлек юк, ә физик көч үзеңнән көчсезләрне мыскыллау, җәберләүгә генә сарыф ителә дигәнгә кайтып кала. Шул исәптән рус булмаган милләт вәкилләре дә мыскыллау объектына әверелә. Болар бигрәк тә «Тәре» хикәясендәге Хәйрүшнең фаҗигалы язмышы аркылы күрсәтелә. Шуларда җәмгыятьнең авыру нокталары барлана, укучыга сайлау, нәтиҗә ясау мөмкинлеге булдырыла.

Бүгенге көндә язылган күп кенә хикәяләрнең үзәгенә милләт язмышы темасы алына. Кайберләрендә милли вазгыять кеше язмышы контекстында, шуңа параллель рәвештә сурәтләнә. Катнаш никахлар милләтләрнең берсенә фаҗига китерә, дигән фикер Ф. Җамалетдинованың «Васыять» хикәясендә

үткәрелә. Әлеге проблема татар әдәбиятында инде шактый тирән өйрәнелгән булса да, язучының әлеге хикәясе мисалында аның һаман да актуаль булуы, әлеге проблемага элекке дәверләрдәге кебек артык әһәмият бирелмәве, гадәти хәл итеп кенә кабул ителүе ассызыклана. Әсәрдә авылның элекке әхлакый кануннар, иман сакчысы вазифасыннан читләшүе дә ачык күренә. Авыл яшәешенә күпмедер дәрәҗәдә үзгәреш кертерлек, уйланырлык, нәтиҗә ясарлык хәлләр дәвам итәчәк дигән фикерне автор үзе дә укучыга тапшыра.

Татар әдәбиятында авыллар халыкның, милләтнең йолаларын, гореф-гадәтен, традицияләрен саклап калган, шуларны яшәтүче бер изге урын буларак сурәтләнсә, хәзерге заман әсәрләрендә авылның әхлак сакчысы буларак вазифасын башкармау, артка тәгәрәү мисаллары да еш кына үзәк проблема буларак яңгырый. А. Әхмәтгалиеваның «Дөнья матур, дөнья киң» хикәясе гади татар авылында яшәүче гаиләләрнең көнкүреше, борчу-мәшәкатьләре турында. Биредә нинди генә «замана җилләре» килеп кагылмасын, авыл халкы алар алдында көчсез булып тасвирлана. Шуңа ул, язучының җан авазы буларак, битарафлыкны, башбаштаклыкны җиңүдә, авыл халкын «йокыдан уятуда» үгет-нәсыйхәт кебек яңгырый.

Хәзерге татар хикәяләрендә авторлар авыр хәлләргә, кайбер очракларда хәтта үлемгә дучар булган геройлар тормышы аркылы татар кешесенә милләтне саклап калу юлларын да күрсәтәләр. А. Әхмәтгалиеваның «Яулык» хикәясендә тасвирланган вакыйгалар – Мәдинәнең төрле вакытлардагы хис-кичереш халәте. Автор аларның үсеп-үзгәреп торуын күрсәтүгә бәжралы композиция алымын куллану аша ирешә. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте барлык кешегә дә җитүен үз мисалында аңлата Мәдинә. Кеше тормышында диннең роленә бәя бирүче, укучыны уйланырга мәҗбүр итүче әлеге хикәя барлык кешелек дөньясына сөрән булып яңгырый.

Шулай итеп, заман хикәяләрендә яшәешнең төрле якларына нисбәтле тематик төрлелек белән очрашабыз. Арада көнкүрешнең аеруча актуаль мәсьәләләре белән бәйле яшәеш фәлсәфәсе, милләт язмышы, гаилә бәхете, мәхәббәт һәм нәфрәт, армия хезмәте, катнаш никах, әдәп-әхлак кыйммәтләрен саклау һ. б. темалар чагылыш таба.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Әбүдарова Л.* Яңа заманның бәхет өчен көрәшүче каһарманнары // Казан утлары. 2017. № 4. Б. 156–160.

2. *Гайнуллина Г.* «Чыбыркы тәртипкә чакыра...» // Казан утлары. 2021. № 7. Б. 148–151.

3. *Гайнуллина Г.Р.* Хәзерге татар прозасы: жанрлык хасиятләре, әдәби алымнар // Tatarica: literature. 2018. Вып. 10. Б. 61–75.

4. *Гайфиева Г.Р.* Поэтика жанра рассказа в татарской прозе конца XX – начала XXI веков: дис. … канд. филол. наук. Казань, 2010. 171 с.

5. *Загидуллина Д.Ф.* Синтетизм в современной татарской прозе // Полилингвиальность и транскультурные практики. 2024. Т. 21. № 3. С. 470-480.

6. *Закирҗанов Ә.М.* Өмет хисе сүнмәсен // Мәйдан. 2013. № 5. Б. 90–96.

7. *Загидуллина Д.Ф.* Татарский рассказ в XXI веке: две тенденции развития // Национальные литературы Поволжья и Приуралья: исследовательские парадигмы и практики: материалы Всероссийского научно-практического семинара / сост.: Л.Ш. Галиева, Ф.Х. Миннуллина. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2024. С. 84–91.

8. *Заһидуллина Д.* Заман прозасында – чор сулышы // Казан утлары. 2015. № 3. Б. 157–161.

9. *Зәйдулла Р.* Хикәянең дәвамы бар // Казан утлары. 2022. № 10. Б. 167–168.

УДК 82.09:821.511.152

# ОБРАЗЫ ПТИЦ В ЛИРИКЕ МОРДОВСКОЙ ПОЭТЕССЫ АЛИНЫ ПОДГОРНОВОЙ

***С.В. Шеянова, А.О. Муромцева***
*Национальный исследовательский Мордовский государственный университет им. Н.П. Огарёва (Саранск)*

*Исследование выполнено за счет гранта Российского научного фонда № 24-28-00098 «Мордовская женская литература: специфика репрезентации гендерной картины мира, национально-художественное своеобразие», https://rscf.ru/project/24-28-00098/.*

В современном отечественном литературоведении изучение способов репрезентации образов птиц в художественном, в частности лирическом тексте, является одной из актуальных задач, поскольку расширяет представление о творческой индивидуальности поэта, особенностях образного строя его лирики, механизмах его моделирования, интерпретации традиционных поэтических образов и их трансформации в поэтическом сознании автора, развитии системы мотивов и символов. В статье исследуются функционально-семантические особенности образов птиц в лирике мордовской поэтессы Алины Подгорновой. Цель исследования – определить функции, специфику репрезентации и индивидуально-творческой интерпретации орнитологических образов в стихотворениях автора. Научная новизна исследования состоит в том, что в аспекте орнитологической образности лирика А. Подгорновой анализируется впервые. Утверждается, что образы птиц наделяются различными содержательными коннотациями, символической нагрузкой. Они способствуют трансляции постмодернистского сознания автора, раскрытию эмоционально-психологического состояния лирического субъекта, вызывают разноплановые ассоциации.
**Ключевые слова:** мордовская женская литература, женская лирика, А. Подгорнова, орнитологическая образность.

In modern Russian literary criticism, the study of the methods of representing images of birds in artistic, in particular lyrical texts, is one of the urgent tasks, since it expands the understanding of the creative individuality of the poet, the features of the figurative structure of his lyrics, the mechanisms of its modeling, the interpretation of traditional poetic images and their transformation in the poetic consciousness of the author, the development of a system of motives and symbols. The article examines the functional and semantic features of bird images in the lyrics of the Mordovian poetess Alina Podgornova. The purpose of the study is to determine the functions, specificity of representation and individual creative interpretation of ornithological images in the author's poems. The scientific novelty of the study is that A. Podgornova's lyrics are analyzed for the first time in terms of ornithological imagery. It is claimed that images of birds are endowed with various meaningful connotations, symbolic load. They contribute to the transmission of the author's postmodern consciousness, the disclosure of the emotional and psychological state of the lyrical subject, and evoke diverse associations..
**Keywords:** Mordovian women's literature, women's lyrics, A. Podgornova, ornithological imagery.

Орнитологические образы относятся к числу универсалий, сквозных образов-символов, полифункциональных элементов художественного текста, отражающих символический, мифопоэтический, онтологический смысл, создающих подтекстовое пространство. Они выступают средством выражения авторской концепции, отражают взаимосвязи поэта с миром природы, социумом. Это обстоятельство вызывает большой интерес к орнитологическим образам со стороны исследователей. В рецепции литературоведов орнитологические образы воспринимаются «устойчивыми структурно-семантическими комплексами, вбирающими широкий спектр значений: творческое вдохновение, любовный порыв, осознание собственной исключительности, попытки преодолеть несовершенство земной жизни, поэтизация лирического «я», метафоризация предметно-образного мира, одухотворение и эстетизация жизненных реалий. Выступая как традиционные символы и образы-концепты, они отсылают к определенной поэтической традиции и выступают в качестве «маркеров национальной идентичности текстов» [5: 148]. Кроме традиционных дефиниций, связанных с данной научной проблемой, сегодня прочно укрепилось понятие «орнитологическое пространство», определяемое как «тип пространства, обусловленный обращением к образам птиц и обладающий устойчивыми особенностями, детерминированными орнитологической семантикой» [6: 208].

В мордовской поэзии образы птиц становятся не только средствами символизации, создания экспрессивности текста, но и наделяются концептуальной нагрузкой, отражают авторский мирообраз, а также национальную картину мира, о чем свидетельствуют произведения А. Доронина, И. Ишуткина, А. Арапова, Н. Циликина, В. Нестерова, Р. Орловой, Л. Рябовой, М. Слугиной и др. Несмотря на семантическую многоплановость, функциональную значимость образов птиц в произведениях национальных писателей, вопросы орнитологической образности оказывается на периферии научных интересов исследователей. Мордовская женская поэзия начала XXI века в аспекте заявленной проблемы частично рассмотрена в статье С.В. Шеяновой [8], в которой предметом исследования является «комплекс флористических и фаунистических образов в женском поэтическом дискурсе, их семантико-структурные особенности, эстетические функции» [8: 128]. На наш взгляд, изучение орнитологического пространства мордовской женской лирики научно значимо как для выявления специфики творческой мирореальности авторов-женщин, так и определения стратегии эволюционирования национальной литературы в целом.

В стихотворениях эрзянского автора Алины Подгорновой мы обнаружили образы птенца, ласточки, воробья, вороны, поползня, соловья, королька, голубя, грифа, разноплановых функционально и семантически. В данной статье рассмотрим специфику репрезентации образа птенца, ласточки, соловья, голубя.

В стихотворении «Я птенец, родившийся вне гнезда» изображен аллегорический образ вылупившегося из скорлупы птенца, воспринимаемого символом беззащитности человека в современном мире. По утверждению исследователей, «одна из существенных граней орнитологического топоса связана с тем, что в самой его структуре заложена антиномия дома / без-

домья» [6: 208]. В произведении А. Подгорновой реализован мотив бездомья: птенец не имеет своего дома: «Я птенец, родившийся вне гнезда. / Надо мной не горит ни одна звезда. / Подо мной в руинах лежит мой дом, / Не успел я согреться его теплом» [4: 9]. Эти обстоятельства усугубляют драматизм ситуации, который в последующих строфах лишь усиливается: «Я птенец, родившийся вне гнезда. / Надо мной нарезает круги беда. / Подо мною осью скрипит Земля. / Как незавидна птичья судьба моя!» [4: 9]. Образ птенца символически соотносится с современным поколением молодых людей, которые также родились «вне гнезда» (не имеют своего дома), часто оказываются в суровых обстоятельствах действительности («я родился – рассыпалась скорлупа»), не имеют возможности самореализации («моя жизнь бессмысленна и глупа»), вынуждены бороться с внешними противоречиями, разрушительными проявлениями сегодняшнего дня («мир мой рухнул. Ужасен он был в конце»). Лирический субъект, как представитель этого поколения, осознает ответственность, возложенную на него временем: «И еще итог, что как в страшном сне / Все из пепла поднять выпадает мне» [4: 9]. Он готов выполнить свою миссию, стремится «окрепнуть», «набраться сил». Образ беззащитного птенца, на наш взгляд, соотносится с поколением Z, имплицирует мысль о жестокости и противоречивости окружающего мира, одновременно утверждает сильные стороны личности – умение возрождаться, брать ответственность на себя, осознавать свое истинное предназначение.

В стихотворении «Ласточки в небе устроили демонстрацию…» орнитологический образ, на наш взгляд, «играет роль медиатора, посредника между высоким и низким, между историческим и антропологическим временем, между географическим и метафизическим пространством» [7: 391]. Лирическая героиня наблюдает за беспорядочными движениями птиц, ей нравится этот гвалт, она испытывает «скорость полета, рискованные сближения». Ощущение высоты, легкости, парения, размаха крыльев, безграничности пространства, отсутствие границ соотносимы с метафизическим состоянием. Посредством «устроивших демонстрацию» ласточек в произведении реанимируется общественно-исторический контекст: «Вижу я, как разбросает картечным / Выстрелом / Тех, чьим единственным выходом было – / Выстоять, / Тех, кто шагал среди загнанных и / Отринутых, / Тех, чью судьбу на себя примерять / Не принято» [4: 23]. В настоящее время героиня наблюдает, «как мир обрастает минами. / Не говорите, что небо над нами / Мирное. / Ласточки в небе, как в запертой клетке / Мечутся» [4: 24]. Маркеры прошлого расширяют хронотоп текста, имплицируют трагическое прошлое страны. Настоящее также противоречивое, сложное, тревожное. Ласточки выступают носителями «вещей правды», пророчествуют о нелегкой судьбе России: «Правда ли, что не бывать ничему хорошему? / Все, что нас слепит, рассыплется черным крошевом, / Снова разделимся, снова сыграем в салочки» [4: 24]. Постепенно свободный полет ласточек сменяется состоянием «запертой клетки», а «птичий гомон» – чем-то грозным, «не праздничным», «голодным», их крыльями «исполосовано небо», они напоминают «острые шашки», которыми облака лишаются голов. Создается устрашающая картина, которая в последующих строках лишь усугубляется: «Но ласточки, стоит к небу поднять мне / Голову, / Требуют

хлеба, а может, дождя / Свинцового. / И крики их так // Пронзительно-устрашающи, // Что начинаем от мира тянуть пожарищем» [4: 23]. Негативный эмоциональный фон передается цветовыми маркерами – серый, свинцовый, черный. Как известно, «в мифологии многих народов мира ласточка – это положительный образ, символизирующий весну, возрождение, обновление жизни, счастливое и многообещающее будущее, плодородие, восход солнца, утро, домашний уют» [2: 257]. В анализируемом стихотворении этот образ «претерпевает трансформацию в соответствии с постмодернистской концепцией поэта, ее восприятием действительности как хаоса, трагедии, безнадёжности» [8: 133].

В стихотворении «Мистический» изображен образ соловья, который традиционно наделяется положительными коннотациями, ассоциируется с весной, отражает духовную жизнь человека, его эмоциональную составляющую. К примеру, в поэзии А. Фета «соловей выступает как средство раскрытия авторского мировосприятия, представлений поэта о назначении искусства», «символ прекрасного, как способ эстетического переживания природы» [1]. У А. Подгорновой образ соловья несколько расходится с архетипическими представлениями о данной птице. Героиня восхищается его голосовыми способностями: «Как поет! Ну как он заливается!» [4: 34]. Однако его песня – пугающие, неопределенные «предсказания»: «Он поет про ничего и нечего, / А в припеве – что-то там про зря. / И его бесхитростная песенка / Ребусу коварному сродни: / То ли призывает он повеситься, / То ли за бессилие бранит. Но чего, чего он добивается? / Чтобы в петлю или чтобы в бой?» [4: 34]. Финальные строки стихотворения построены на сарказме: «Соловей в оракульской агонии / Прикрывает бисеринки глаз / И, не объясняя антиномии, / С тонкой ветки падает в экстаз. / вслед за этим, как ни поразительно, / Прямо надо мною, на суку, / Кто-то изрекает и презрительно / И многозначительно: «Ку-ку» [4: 34]. «Традиционный символ прекрасного» в анализируемом тексте трансформируется, сопоставляется с кукушкой, птицей с негативной коннотацией, что обусловлено мироощущением автора, его экспериментаторством, оригинальной интерпретацией классических образов.

В стихотворениях А. Подгорновой «Как ни крути», «В тот день дул норд, хозяин здешних мест…» архетипическое представление о соловье не трансформировано, автор придерживается восприятия соловья как «божьей, святой, чистой птицы» [2: 260]. В стихотворении «В тот день дул норд, хозяин здешних мест…» этот образ связан с приходом весны, символизирует обновление души и зарождение любви: «И будто по команде соловьи, / Что раньше голосов подать не смели, / Мне «Варшавянку» в песню о любви, / Срываясь, на высоких, перепели…» [4: 51]. Птицы заставили лирическую героиню встрепенуться, вновь испытать давно забытое чувство. В стихотворении «Как ни крути» соловей становится аллегорией любящего сердца, что соотносится с фетовской метафорой, в которой соловей выступает «символом любви, универсализации любовного чувства» [1].

В стихотворении «Голубь» изображается образ птицы, которая «до настоящего времени является главным символом христианства, …символом Святого Духа и Крещения в христианстве» [2: 422]. Из-за скорбного

воркующего звука, который издают голуби, они воспринимаются символами скорби. У А. Подгорновой с голубем сопоставляется мужчина, с которым у героини, очевидно, сложились противоречивые отношения, в связи с чем он наделяется разнородной коннотацией. Первые строки стихотворения отражают презрительное, уничижительное восприятие героиней мужчины, что передается посредством индивидуально-авторского неологизма («Голубя недоголубленного взгляд / У тебя. Вряд / Ли станешь с другими в ряд» [3: 125]). В тексте стихотворения не эксплицированы обстоятельства, в которых оказались герои, не воссоздана поведенческая модель мужчины. Сложно понять, почему героиня так негативно настроена по отношению к нему, что призывает его к самоубийству: «Дли момент прозрения и – / Пли!» [3: 125]. В финальных строках стихотворения образ птицы обрастает традиционным мотивом скорби («Стань голубем голубей – / Птицей скорби моей / С будущего и до сей» [3: 125]). Только с уходом из жизни мужчина завоюет уважение героини. Тогда «рвань» (в нашей интерпретации, негативные проявления) будет нивелирована чувством скорби, утраты, которые героине переносит легче, чем отношения с живым мужчиной.

Образы птиц в творчестве эрзянского поэта Алины Подгорновой становятся одной из важнейших составляющих образного строя ее лирики, существенной частью индивидуально-творческой картины мира. Посредством орнитологических образов раскрывается эмоционально-психологическое состояние лирической героини, отражаются реалии современной действительности в авторском восприятии. Специфика моделирования и интерпретации образов птиц у А. Подгорновой, их наращивание символическим смыслом обусловлены авторским мироощущением, постмодернистским сознанием поэта.

## СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1. *Азбукина А.В.* Образ-символ «соловей» в русской поэзии XIX в.: дис. … канд. филол. наук. Казань. 2001. 259 с.

2. Птица как образ, символ, концепт в литературе, культуре и языке: коллективная монография / отв. ред. А.И. Смирнова; МГПУ. М.: Книгодел, 2019. 504 с.

3. *Подгорнова А.* Марямга (Вслух). Саранск, 2013. 160 с.

4. *Подгорнова А.* Мель (Мысль). Саранск, 2021. 112 с.

5. *Сафина Г.Ф., Идиатуллина Л.Т.* Образы-символы «крылья», «птица» в татарской женской поэзии 1980–2010-х гг. (на примере лирики Л. Шагирзян) // Казанский лингвистический журнал. 2022. Т. 5. № 2. С. 147–157. URL: http://kaz-linguo-journal.ru/index.php/linguo/article/view/253/227 (дата обращения: 30.04.2025).

6. *Тропкина Н.Е.* Художественная семантика орнитологического пространства в русской поэзии XX века // Современное педагогическое образование. 2019. № 12. С. 208–210. URL: https://spo-magazine.ru/upload/iblock/c39/СПО%20№12%202019.pdf (дата обращения: 30.04.2025).

7. *Цзин Цзинши.* Художественная семантика орнитологических образов в лирике Арсения Тарковского: образ ласточки // Мир науки, культуры, образования. 2021. № 4 (89). С. 389–392.

8. *Шеянова С.В.* Природная образность в эрзянской женской лирике // Вестник угроведения. 2024. Т. 14. № 1 (56). С. 128–136.

УДК 81’42:811.512.1

# ДУХОВНЫЕ ЦЕННОСТИ И НРАВСТВЕННЫЕ ПРИНЦИПЫ ХУДОЖЕСТВЕННОЙ ПРОЗЫ И. ГАСПРИНСКОГО

***З.Ш. Шукурджиева***
*ГБОУВО РК КИПУ им. Ф. Якубова (Симферополь)*

В статье рассматривается творчество известного просветителя тюркского мира конца XIX – начала XX в. Исмаила Гаспринского, выявляется идейно-эстетический замысел литературных произведений писателя. Автор акцентирует внимание на художественной прозе И. Гаспринского – цикле романов под общим названием «Молла Аббас» («Мулла Аббас»), рассказе «Арслан къыз» («Девушка-львица»). В статье дается анализ некоторых литературных произведений писателя через призму духовных ценностей и нравственных принципов автора, отражающих его мировоззренческую позицию, ориентированную на просветительство, культурное возрождение тюрко-мусульманского общества современной ему эпохи.
**Ключевые слова:** Гаспринский, писатель, литература, нравственные принципы, духовные ценности.

The article examines the work of the famous educator of the Turkic world of the late 19th – early 20th centuries, Ismail Gasprinsky, and reveals the ideological and aesthetic concept of the writer’s literary works. The author focuses on the fiction of I. Gasprinsky – a series of novels under the general title «Molla Abbas» («Mulla Abbas»), the story «Arslan kyz» («Lion Girl»).The article provides an analysis of some literary works by I. Gasprinsky through the prism of the spiritual values and moral principles of the author, reflecting his ideological position, oriented towards enlightenment, the cultural revival of the Turkic-Muslim society of his contemporary era.
**Keywords:** Gasprinsky, literature, novel, moral principles, spiritual values.

Будучи духовым лидером и одним из ярчайших представителей интеллигенции тюркских народов конца XIX – начала XX в., И. Гаспринский внес огромный вклад в их развитие, тем самым способствуя просвещению и духовному возрождению целых народов. Автор оставил после себя богатое литературное и публицистическое наследие, в котором нашли отражение многие социальные, общественные процессы, проблемы тюркского мира и мусульманских народов того времени.

Посредством литературных произведений И. Гаспринский распространял и тем самым популяризировал свои просветительские идеи, это было главной целью его жизни – обогащать общество новыми знаниями, мотивируя людей учиться, получать новые знания, просвещаться, улучшать свою жизнь. Реформировать жизнь мусульманского сообщества Российской империи с разных сторон, привнося в нее цивилизационные достижения западной и русской культур – такой была основная задача И. Гаспринского как просветителя, писателя и публициста.

Литературные труды автора, написанные в различных жанрах, во многом позволяют понять жизнь тюркоязычных и мусульманских наро-

дов на рубеже XIX–XX вв. в различных ее проявлениях, а также увидеть социальную неоднородность общества того периода. В своих сочинениях И. Гаспринский преимущественно описывает сюжеты, основанные на реальных событиях, однако часть его литературных произведений, как, например, роман «Дар-ур рахат мусульманлары» («Мусульмане страны Благоденствия»), содержит фантастические сюжеты. В романе большое внимание уделяется проблеме воспитания образованного общества, теме любви к знаниям, труду. Главный герой Молла Аббас, путешествующий по Испании, неоднократно обращает свое внимание на то, как жители Страны Спокойствия стремятся к получению знаний и как это культивируется в обществе: «Жители Рахата знали, а тут еще лучше поняли, что сила жизни в разносторонних знаниях и что обеспечение хорошей жизни в умелом труде. Этим сознанием проникнуты старый и молодой, мужи и жены. Поэтому среди них были позабыты слова "невежа" и "лентяй". Всеобщий труд и всеобщее обучение легли в основание жизни этой маленькой страны» [2: 220].

Приведем еще один фрагмент из данного романа, в котором дается описание мектеба при мечети, где учатся дети 8–12 лет, постигая различные науки. В нем также видим подтверждение того, насколько серьезно относились в Стране Спокойствия к образованию, в частности к обучению и воспитанию детей. Шейх Джелял, устроивший для Моллы Аббаса прогулку по мектебу, так повествует об учебном заведении: «Тут обучаются все дети деревни без исключения – как мальчики, так и девочки. Учение длится четыре года. Мальчики обучаются письму, чтению, вере, счету, сельскому хозяйству с начальной химией и физикой, а также и ремеслам. Девочки, кроме наук, обучаются домашнему хозяйству, рукоделию и домашней медицине, необходимой для будущей хозяйки и матери» [2: 198].

Все это вызывает удивление у главного героя Моллы Аббаса, приехавшего из Ташкента, где обучение в медресе, по его словам, подразумевает лишь изучение богословия и духовного законодательства, поскольку считается, что «все науки, кроме духовной, смущают мысли и веру мусульманина». Аббас задумывается над тем, как можно совместить высокий уровень цивилизации с духовным совершенством общества, и после путешествия по Стране Спокойствия и знакомства с жизнью местных людей приходит к мысли о том, что это возможно, если повышать интерес общества к образованию, способствовать развитию науки, культуры, цивилизации. Путем эволюции и прогресса мусульманское общество имеет все шансы на лучшую жизнь, заключает И. Гаспринский устами Моллы Аббаса.

Художественные достоинства романов И. Гаспринского оценены многими исследователями. Так, в работах И.А. Керимова отмечается, что в «Молла Аббас» (1887), «Солнце взошло» (1905) и «Сто лет спустя» (1906), раскрывается природа мастерства художественного слова, талант Гаспринского-писателя. Исследователь считает, что роман «Молла Аббас», публиковавшийся фрагментами в «Терджимане» на протяжении всего 1887 г., был первым тюркоязычным романом на территории Российской империи. В то же время он упоминает, что некоторые литературоведы

относят к данной категории произведение казанского писателя Мусы Акджигитова «Муса Хисамутдин», изданное годом ранее (1886) [5].

В исследованиях А.Т. Сибгатуллиной отмечается, что, выделяя успехи в экономике и социальной жизни европейцев, западной системе образования, культуре, правовой системе, писатель обращает внимание своих соплеменников на то, что научно-технический прогресс не должен ни в коей мере отрицательно сказаться на духовности и вере. Автор подчеркивает, что художественная проза И. Гаспринского целиком находится в рамках его программы модернизации тюрко-исламского мира и служит продвижению прогрессивных идей в эстетической форме [7].

Склонность к образному мышлению и в то же время реалистичное описание событий автором особенно отчетливо проявляются в романе «Молла Аббас». Невзирая на то, что в основе произведения лежит романтический сюжет, многие образы, сюжетные перипетии в произведении правдивы, словно взяты из жизни и диалоги, картины, характеры. Легкий, ровный стиль изложения, повествовательный тон автора увлекают читателя и способствуют экспрессивному восприятию описываемых в романе событий. Это в свою очередь свидетельствует о том, что И. Гаспринский нашел свой стиль повествования и отошел от манеры изложения многих тюркских авторов современной ему эпохи, зачастую прибегавших, с целью усиления воздействия на читателя, к использованию в своих произведениях фольклорных мотивов, образов и сюжетов. Этим во многом объясняется то, что читатель воспринимает близкий к жизни роман в изложении И. Гаспринского как естественную, реальную историю, а не как, скажем, сказку или вымышленный сюжет.

Роман «Молла Аббас» представляет собой цикл из нескольких произведений: «Французские письма», «Африканские письма», «Страна Амазонок», «Таинственная страна». Главный герой романа – уроженец города Ташкента Молла Аббас Франсеви, от его имени ведется повествование, он же является основным действующим лицом всех перечисленных выше произведений. Будучи связующим элементом всех сочинений цикла, он вызывает к себе пристальное внимание читателя, которого интересует его судьба и дальнейшие приключения.

Принято считать, что этот образ И. Гаспринский во многом списал с себя, поскольку в романе можно провести немало параллелей между судьбами героя и самого автора. Например, тот факт, что И. Гаспринский немало путешествовал в своей жизни, посетил ряд западных и восточных стран, отражен в путешествиях Моллы Аббаса, который, как известно, также посещает страны Запада и Востока. Из биографии И. Гаспринского известно, что его поездки в Европу приходятся на 1870-е гг. Судя по событиям, описанным в романе, Молла Аббас также путешествует именно в это время. Кроме того, герой романа представлен писателем воспитанным, культурным, имеющим широкий кругозор молодым человеком, окончившим медресе и получившим светское образование. Здесь также просматриваются аналогия героя с личностью автора произведения.

Таким образом, мы можем констатировать, что данное произведение во многом автобиографично и переживания, выпавшие на долю главного героя романа, – это во многом чувства и эмоции, пережитые самим

И. Гаспринским. Именно поэтому автор мастерски описывает в «Молле Аббасе» многие эпизоды, картины, детали и характеры, что подчеркивает его наблюдательность, проницательность, внимательность, умение видеть и анализировать события разного уровня – от политических до бытовых.

Вот пример детализированного описания писателем Кордуанской мечети в романе «Дар-ур рахат мусульманлары»: «Эта грандиозная молельня сооружена из дорогого мрамора с куполом, покоящимся на восьмидесяти колоннах. Вид мечети грандиознее, внутренняя отделка великолепнее стамбульской Айя-Софии, большой каирской мечети и других сооружений подобного рода. Освещение храма так рассчитано, что производит на зрителя глубокое впечатление. Строгая симметрия всех частей, красота и величие общего вида, воздушные арки, соединяющие колоннаду храма, непритворно и беспристрастно говорят нам о духе народа-строителя, духе великом, красивом и жизнетворном, каковым представляется кордуанская мечеть – воплощение духа и вкуса арабов» [2: 176].

Интересен образ главного героя, тонко и тщательно выписанный И. Гаспринским в цикле романов. Через характер Моллы Аббаса автором передан его современник – молодой человек, безгранично любящий свою родину и стремящийся принести пользу обществу. Обладающий пытливым умом и горячим сердцем, жаждущий новых знаний, любитель странствий и приключений, Молла Аббас является образцом прогрессивно мыслящего молодого поколения конца XIX в., представителем восточной культуры и цивилизации. Он предстает перед читателем положительным героем, наделенным способностью логически мыслить, любить, сочувствовать, имеющим индивидуальный характер и свойственные ему черты [4].

Вот как говорит о себе Аббас в романе «Дар-ур рахат мусульманлары» «Я оставил Ташкент в возрасте 22 лет, окончив, как мог, курс всех наук. Богатство, оставленное мне отцом (мир праху его!), и одиночество давали мне право и возможность довершить мое учение и воспитание путешествиями по благословенным мусульманским землям. Через Оренбург и Москву я попал в Одессу. Пребывание в России, расспросы у казанцев значительно расширили мои знания, и Западные страны все более и более начали меня интересовать» [2: 171].

Также через образ главного героя писателем ярко переданы темы ценности общечеловеческих нравственных принципов, религиозности, духовного развития личности и общества. Это особенно очевидно прослеживается в романе «Дар-ур рахат мусульманлары», в котором описываются путешествие и пребывание Моллы Аббаса в Испании. 27-летний молодой человек приезжает в Андалусию, где впервые видит памятники мусульманской культуры периода Арабского халифата. Так, во время почти месячного пребывания в городе Гранада он изучает дворец Эль-Хамра. Словом, все вокруг привлекает внимание наблюдательного Аббаса, вдали от своей родины столкнувшегося с исламской цивилизацией. Но больше всего его поражает удивительная страна Рахат, в которой живут люди с высокими нравственными устоями, исповедующие ислам и регулярно выполняющие предписания этой религии. Уровень их жизни достаточно высок, они даже пользуются благами техники, различными приспособлениями, не свойственными той эпохе. Здесь следует отметить, что при описании

действительности, картин быта жителей страны Рахат писатель прибегает к некоторой гиперболизации, использованию гротескных форм (насколько позволяет воображение автора), поэтому ряд литературоведов относят данный роман к разряду утопических, содержащих элементы фантастики.

Внимательно разглядывая образцы мавританской архитектуры, Молла Аббас понимает, что единство культур разных народов, которое стало возможным благодаря синтезу различных цивилизаций, в основе которых лежат духовные, нравственные принципы, общечеловеческие ценностные ориентиры, уничтожают губительные войны. Это, естественно, негативно отражается на жизни людей, государств, их дальнейшем развитии и сосуществовании. Описанием в романе кровавого противостояния католиков и мавританских мусульман автор подчеркивает и усиливает эту мысль, показывает, насколько разрушительными могут быть религиозные войны [1].

Социальной роли женщины в художественном творчестве И. Гаспринского отведено значительное место. Созданный автором в литературных произведениях образ современной женщины дает общее представление о жизни мусульманки в конце XIX – начале XX в. Так, судьба мусульманской женщины занимает одно из центральных мест в творчестве И. Гаспринского. Женщина-мусульманка в произведениях писателя становится отражением социальных изменений в обществе, символом преобразований.

Самобытные и яркие женские образы несут идеологическую, социальную нагрузку. Транслируя данную проблему в общество через литературные произведения, И. Гаспринский демонстрирует прямой интерес к женской тематике, стремление подчеркнуть равенство в правах мужчин и женщин, указывая пути к культурной эмансипации.

Показывая читателю пример разносторонне развитой девушки, писатель ставил своей целью побудить общество иначе посмотреть на женщину, переосмыслить ее роль в социуме. Рассказ «Арслан къыз» («Девушка-львица») стал своего рода символом стремления к независимости тюркских народов, а образ Гульджемаль Бикеч – олицетворением женского идеала в крымскотатарской и тюркской литературах конца XIX – начала XX в. В рассказе находим такое описание героини: «Красавица была смелой наездницей, отличным стрелком, обладала маленькой, но крепкой рукой, способной до крови натянуть уздечку непокорного коня. Гульджемаль совсем не походила на тех наших слабоногих девушек, которые едва носят собственное тело и боятся муравья и воробья» [2: 273].

Таким образом, общечеловеческие ценности и духовно-нравственные принципы лежат в основе идейно-эстетического замысла литературных произведений И. Гаспринского и являются основополагающими элементами многих его романов и рассказов. В них отражена система принципов культурного возрождения тюрко-мусульманского общества конца XIX – начала XX в. в интерпретации автора. Это дает нам более полное представление о философии писателя-публициста И. Гаспринского и отражает его мировоззренческую позицию, ориентированную на просветительство.

СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1. *Ганкевич В.Ю.* Жизнь и педагогическая деятельность И. Гаспринского: дис. … канд. ист. наук: 07.00.01. Симферополь, 1995. 238 с.

2. *Гаспринский И.* Полное собрание сочинений. Т. 1. Литературные произведения / гл. ред. Р.С. Хакимов; сост. С.А. Сеитмеметова, Г.Ю. Сеитваниева. 2-е изд., испр. и доп. ГАУ РК «Медиацентр им. И. Гаспринского». Симферополь, 2021. 510 с.

3. *Гаспринский И.* Кадынлар. Проблески культурного движения татар: очерки / пер. Э.Э. Абибуллаева, сост., авт. примеч. С.А. Сеитмеметова. Симферополь: Форма, 2016. 61 с.

4. *Гаспринский Исмаил.* Молла Аббас (роман). Эки томлукъ. Бириндӂи том. Симферополь: Къырым девлет окъув-педагогика нешрияты, 2001. 400 с.

5. *Керимов И.А.* Гаспринскийнинъ «джанлы» тарихи. 1883–1914. Симферополь: Тарпан, 1999. 407 с.

6. *Сибгатуллина А.Т.* Гаспринский как писатель и литературный критик // М.: Медина, 2011 [Электронный ресурс] // URL: https://idmedina.ru/books/islamic/?2579 (дата обращения: 15.01.2025).

7. *Сибгатуллина А.Т.* Цельность литературного творчества Исмаила Гаспринского // Тезисы науч. конф. «Исмаил Гаспринский – идеолог, реформатор, просветитель. На переломе эпох» (16–17 октября 2014 г., г. Москва). М., 2014. С. 28.

УДК 81-112.2, 811.512.145΄0

# ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ К. НАСЫРИ В РАЗВИТИИ ЛИТЕРАТУРНОЙ НОРМЫ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА II ПОЛОВИНЫ XIX ВЕКА

***А.Ф. Юсупов, Н.М. Юсупова, А.Л. Зиганшина***
*Казанский федеральный университет (Казань)*

Статья посвящена изучению деятельности ученого-энциклопедиста, педагога и просветителя Каюма Насыри в области татарского языкознания, в частности татарской стилистики и татарской разговорной речи. Как известно, что одно из развитых научных направлений в татарском языкознании, основной задачей которой является изучение живого разговорного языка коренных народов, исследование явлений народной речи. В ходе исследования дается краткий историографический обзор трудов ученого, посвященных изучению данной проблемы, определяется вклад и значение его трудов для развития литературной нормы татарского языка во II половине XIX века.
**Ключевые слова:** К. Насыри, история языкознания, стилистика, языковая норма, разговорная речь.

The article is devoted to the study of the activity of the scientist-encyclopaedist, educator and enlightener Kayum Nasyri in the field of Tatar linguistics, in particular Tatar stylistics and Tatar colloquial speech. As it is known that one of the developed scientific directions in Tatar linguistics, the main task of which is the study of the living spoken language of indigenous peoples, the study of the phenomena of folk speech. The study gives a brief historiographical review of the works of the scientist devoted to the study of this problem, determines the contribution and importance of his works for the development of the literary norm of the Tatar language in the second half of the XIX century.
**Keywords:** K. Nasyri, history of linguistics, stylistics, language norm, colloquial speech. speech.

# XIX ГАСЫРНЫҢ II ЯРТЫСЫ ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ӘДӘБИ НОРМАСЫ ҮСЕШЕНДӘ К. НАСЫЙРИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***А.Ф. Юсупов, Н.М. Юсупова, А.Л. Зиганшина***
*Казан федераль университеты (Казан)*

Билгеле булганча, татар стилистикасы тел белеменең аерым фәнни тармагы буларак XX гасыр урталарында формалашып җитә. Әмма стилистиканың төп термин-категорияләре XIX гасыр урталарында ук тикшерелә, фәнни әйләнешкә кертелә башлый. Ул вакытта *сөйләм, стиль* дигән терминнар файдаланылмый, әмма бер гасырдан соң шушы терминнар белән исемләнәчәк күренешләр билгеләнә [6: 10]. Фәнни әдәбиятта, нигездә, татар теленең ике төрле формада кулланылышына игътибар ителә: телдән сөйләм формасы һәм язма сөйләм формасы (китаби тел).

Тел берәмлекләренең кулланылу функциясенә мөнәсәбәттә, татар телен *сөйләм теле* һәм *язу* яки *китап теле* дигән ике төргә бүлеп карарга мөмкин икәнлеге турында әйтелә. Мәсәлән, М. Иванов «Татарская хрестоматия» (1842) хезмәтенең кереш өлешендә: «мин хрестоматияне ике өлештән төзәргә кирәк дип таптым: 1) сөйләм теле үрнәкләре, 2) китап теле», – дип яза [1: 3]. М. Иванов сөйләм теле белән китап теле арасындагы аерманы билгели, моңа дәлил итеп кайбер үрнәкләр дә китерә. Ул Оренбург төбәгендәге татар теленең кулланылышын ике төргә бүлеп караган вакытта теоретик яктан нигезле фикер әйтә алган, ләкин әлегә үз карашын гамәли яктан нәтиҗәле итеп раслап бетерә алмый. Әмма шунысы бәхәссез: галим язма текстларның халык сөйләменә якынрак яисә ераграк булып язылуына игътибар иткән.

С. Кукляшев әлеге мәсьәләгә ачыклык кертә: ул үзенең «Татар хрестоматиясе» (1859) дигән хезмәтенең кереш өлешендә татарлар сөйләшә торган тел – *төрки тел* дип ассызыклый. Хезмәттә язма татар теле, текстта сүзләрнең куллануына һәм җөмләләрнең ничек төзелүенә карап, өч төргә яки категориягә бүленә: *гади тел, эш теле, гыйльми тел* [2: 3]. Аның фикеренчә, гади тел бөтен татар халкының сөйләү теленә якын булуы белән аерылып тора. С. Кукляшев билгеләп үткәнчә, эш теле гади сөйләм һәм гыйльми тел арасында тора, анда татар сүзләре белән беррәттән гарәп һәм фарсы сүзләре дә шактый кулланыла. Гыйльми тел гарәп телен яхшы белүчеләргә генә аңлашыла, биредә күптөрле гарәп алынмалары, тәгъбирләре, гыйбарәләре һәм грамматик тезмәләре өстенлек итә. Тел белгече кайбер китапларның татарча булуын җөмлә ахырында татар теленә хас ярдәмче фигыльләр кулланылуыннан чыгып кына белергә мөмкин икәнлеген күрсәтә.

С. Кукляшев, татар тел белемендә беренче булып, татарча текстларны өч төрле телгә бүлеп карарга мөмкин булуын теоретик яктан нигезли, хезмәттә *стиль* төшенчәсе *тел* дигән атама белән бирелә. Автор бу өч төрле телгә мисал итеп мәкальләрне, дастаннарны, хикәяләрне, эш кәгазьләрен үрнәк китерә. Хезмәтнең гамәли ягында, текстларны сайлау һәм урнаштыруда төгәл тәртип сакланмый. Бу турыда ул үзе болай яза: «хрестоматиянең башында үзем җыйган мәкаль-әйтемнәрне урнаштырдым, аннан хикәяләр, кайберләрен кульязма китаплардан алдым, кайберләрен

көнчыгыш телләреннән тәрҗемә иттем. Аннан соң үрнәк буларак үзем язган хатлар бирелде, эш кәгазьләре, распискалар, кечкенә шигырьләр, “Искәндәрнамә”дән өзекләр бирдем» [2: 3].

Татар тел гыйлемен үстерүдә үзенең күренекле хезмәтләре белән зур урын тоткан К. Насыйри (1825–1902) да, чордашлары фикерләрен дәвам итеп, стиль мәсьәләләренә кагылышлы аерым мәсьәләләргә тукталa. Ул *сөйләм теле* һәм *язу теле* дигән төшенчәләрне аерып билгели, язма һәм сөйләмә тел арасындагы аермалык турында фикерләр әйтеп, аңа ачыклык кертә; язма әдәби телнең халыкның сөйләм теленнән читләшкән булуын, анда алынма сүзләрнең күп кулланылуын күрсәтә. К. Насыйри *сөйләм теле* дигәндә табигый җанлы сөйләшүне күз алдында тота. Мәсәлән, 1859 елда язылган «Мәҗмәгыл әхбар» исемле әсәре турында ул болай дип яза: «Авылга кайтканда, мин ул китапны үзем белән алып кайткан идем. Бәгъзе мужикларга укып күрсәттем, мин укыганда үзара сөйләшәләр: “Кара, сөйләшкән кебек укый” – диләр. Хасил һәркем аңларлык...».

К. Насыйри язма әсәрләр теле халыкка аңлаешлы булырга тиеш дигән караштa тора, әлеге фикерне эзлекле үстерә, теоретик нигезли. Галим халык сөйләшкәнчә, аңлаешлы итеп язуны үзенең төп максаты итеп күрә, аны фәнни принцип итеп ала. Мәсәлән, ул «Әбүгалисина» кыйссасын (1889) гарәп теленнән тәрҗемә итә. К. Насыйри аңлы рәвештә халык өчен иҗат ителгән матур әдәбият әсәрләренең шул халыкның җанлы сөйләм теленә нигезләнеп язылырга тиешлеген белеп эш итә.

Күп фәннәрне (тел, әдәбият, тарих, этнография, математика, география, геометрия, ботаника, медицина, календарьлар һ. б.) өйрәнеп хезмәтләр язган галим һәр *фәннең үз теле, терминнары* булырга тиеш дигән нәтиҗәгә килә: «...Һәрбер фәннең үзенә махсус истыйляхы (термины) бардыр вә үзенә махсус теле бардыр. Безнең телемездә кадимнән бу фәнләр язылa килмәгәнлек сәбәбле, урынына муафикъ вә килешә торган сүзләрне табуы читен, ...лөгать белән истыйлях арасында, әлбәттә, бер галәкә (бәйләнеш) кирәкдер, һичбер мөнәсәбәтсез бер сүзне истыйлях ясап булмыйдыр...» [3].

К. Насыйри, үзенең «Кавагыйде китабәт...» (1892) әсәрендә стилистика мәсьәләләренә дә тукталып, татар теленең төрле стилистик төсмерләргә, сурәтләү чараларына бик бай икәнлеген дәлилли. Ул киң тармаклы теоретик һәм гамәли эшчәнлеккә нигезләнеп, *сөйләм теле, язу теле, әдәби әсәрләр теле, фәнни хезмәтләр теле* турында беренче башлап яңа фикерләр әйтә, җанлы сөйләмә тел белән язма китаби тел арасындагы аерманы гади итеп аңлатып бирә: «мәдәниятле һәрбер адәмнең ике төрле теле булып, берсе анасыннан сөт имгән мөдәттә үгрәнгән теледер, икенчесе дәхи остазга тәгълимгә бирелгәч, гыйлем вә фән лөгатьләре белән ачылган телдер» [4: 5].

Язу һәм стиль кагыйдәләренә багышланган хезмәттә шулай ук аерым сүзләрнең язылыш нормаларына игътибар ителә, мәсәлән: *улды – булды, улыр – булыр, вар – бар, кәлде – килде, вирде – бирде, кәтде – китте, кәрәк – кирәк*. Әлеге вариантлар арасыннан галим сөйләмә телдә кулланылышта булган формаларга өстенлек бирә.

Язма әдәби телнең орфографик нормаларына караган карашлары галимнең «Әнмүзәҗ» (1895) грамматикасында да урын ала. Биредә әдип татар сөйләм теле кагыйдәләрен турында сүз алып бара һәм аларны язма

әдәби тел нормалары буларак тәкъдим итә. *Казандан, күбдән, акдан* кебек искергән формалар урынына *Казаннан, күптән, актан* язылыш формаларын кертеп җибәрә, ягъни татар теленең сөйләмә формалары үрнәк итеп алына [5: 46].

Шул рәвешле, К. Насыйри, үзенең чордашлары һәм Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкилләре И.А. Бодуэн де Куртенэ (1845–1929), Н.В. Крушевский (1851–1887), В.А. Богородицкий (1857–1941) белән бер үк вакытта диярлек, җанлы сөйләмә телнең язуда чагылыш тапкан язма тел белән бер үк күренеш түгеллеген фәнни нигездә аңлата башлый.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Иванов М.И.* Татарская хрестоматия, составленная Мартинианом Ивановым. Ч. 1–2. Казань: Типолитогр. ун-та, 1842. 196 с.
2. *Кукляшев С.* Татарская хрестоматия, составленная Салих Джаном Кукляшевым, коллежским советником, старшим учителем арабского и персидского языков при Оренбургском Неплюевском кадетском корпусе. Казань: Ун-т тип., 1859. 126 с.
3. *Насыйри К.* Истыйляхте җәгърафия. Казан: Ун-т тип., 1890. 74 б.
4. *Насыйри К.* Кавагыйде китабәт, ягъни тасниф вә имла кагыйдәләрен бәян кылучы бер яңа фәнде. Казан: Ун-т тип., 1892. 32 б.
5. *Насыйри К.* Әнмүзәҗ. Лисанымызның сарыф вә нәхү кагыйдәләре. Казан: Ун-т тип., 1895. 86 б.
6. *Юсупов А.Ф.* Татар теленең стилистикасы һәм сөйләм культурасы: югары уку йортлары студентлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2024. 160 б.


УДК 81

# ДВУЯЗЫЧНЫЕ СЛОВАРИ КАЮМА НАСЫРИ

**_А.Ш. Юсупова_**
*Казанский федеральный университет (Казань)*

Одним из основных источников при изучении тех или иных языков, а также показателем их места и роли в истории культуры являются филологические словари. Современный татарский язык также формировался в историческом контексте становления татарского народа как нации. Особенно ценным источником для историко-лингвистических исследований являются двуязычные словари. Взятые в совокупности, они позволяют документально подтвердить роль и место тех или иных языков в истории культуры в определённые исторические периоды, взаимоотношения данных языков, в том числе их связи с третьими языками. Причем при исследовании таких словарей можно без ущерба для требований научной объективности сосредоточиться на лингвистическом материале одного из двух языков. Словари К. Насыри, изданные в XIX веке выделялись качеством и количеством, видами включённых в них слов, методами перевода лексических едениц. Они служили важным подспорьем в изучении татарского и русского языков, являлись образцом для составления одно и двуязычных словарей тюркских народов.
**Ключевые слова**: Каюм Насыри, словарь, двуязычный, татарская лексикография.

Philological dictionaries are one of the main sources for studying various languages, as well as an indicator of their place and role in the history of culture. The lexical composition of each language reflects different aspects of the life of a particu-

lar people throughout its history. The modern Tatar language was also formed in the historical context of the formation of the Tatar people as a nation. Bilingual dictionaries are a particularly valuable source for historical and linguistic research. Taken together, they allow us to document the role and place of certain languages in the history of culture in certain historical periods, the relationship of these languages, including their relationship with third languages. Moreover, when studying such dictionaries, you can focus on the linguistic material of one of the two languages without compromising the requirements of scientific objectivity. Dictionaries of K.Nasyri published in the XIX century were distinguished by the quality and quantity, types of words included in them, and methods of lexical translation. They served as an important aid in the study of Tatar and Russian languages by contemporaries, and were and are a model for compiling single-and bilingual dictionaries of modern Turkic languages.
**Keywords**: Kayum Nasyri, Dictionary, bilingual, Tatar lexicography.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ИКЕ ТЕЛЛЕ СҮЗЛЕКЛӘРЕ

***Ә.Ш. Юсупова***
*Казан федераль университеты (Казан)*

Татар фәнендә кабатланмас эз калдырган, киңкырлы эшчәнлеге зур игътибарга лаек булган олы галим Каюм Насыйри татар теле, әдәбият һәм мәдәният, тарих, этнография, археология милли тәрбия һәм җәмгыять фәннәре өлкәләрендә эшли. Ул гына да түгел, төгәл фәннәр, аерым алганда, география, математика, ботаника, игенчелек буенча татар телендә китаплар язып, беренчеләрдән булып, аларның гыйльми нигезләре белән татар халкын таныштыра.

Галим эшчәнлегенең энциклопедик характеры, фәнара бәйләнешләрне эчке тоемлап, аларны отышлы куллану осталыгы ул эшләгән һәр өлкәдә чагылыш таба.

Каюм Насыйриның тел белеменә караган киң һәм универсаль эшчәнлегенең һәр тармагы аерым монографик эзләнүләргә лаек. Бүген без аның сүзлекчелек өлкәсендәге эшчәнлегенә тукталырга уйладык.

Каюм Насыйри лексикография сүзен «лөгать китабы тасниф кыйлу» дип тәрҗемә иткән. Бу – дөрес тәрҗемә. Сүзлек китаплары төзү – телләрнең суз байлыгын җыю, тикшеру һәм аларны системалаштыру кебек зур һәм катлаулы мәсьәләләрне үз эченә ала.

XIX йөзнең соңгы яртысында, татар лексикографиясен үстерү юлындагы хезмәтләрнең иң күренеклеләре һәм яңа төрләре К. Насыйри тарафыннан языла. Әлбәттә, XIX гасырда Каюм Насыйрига кадәр дә сүзлекләр төзелә, бастырыла һәм К. Насыйри үзенең хезмәтләрендә ул сүзлекләрдән, һичшиксез, файдалана. Ләкин татарларга рус теле, русларга татар теле өйрәтү теләге белән янган К. Насыйриның ул сүзлекләр белән генә чикләнеп каласы килми. Ул татар лексикографиясе өлкәсендә еллар буе киң һәм тирән фәнии эзләнү-тикшеренү эшләре башкарып, шул чор татар дөньясын яңа һәм гаять әһәмиятле сүзлек китаплары белән баета.

К. Насыйри үзенең лексикографик хезмәтләрен төп өч максатка нигезләп башкара. Русларга татар теле һәм татарларга рус теле өйрәтү максатын куеп, ул, беренче чиратта, 1878 елда үзенең «Татарча-русча лөгать» исемле сүзлегенең беренче басмасын, 1892 елда «Полный русско-татарский

словарь» ның беренче басмасын чыгарган; 2) татарларга һәм башка кызыксынучыларга шул чор татар әдәби телен өйрәтү һәм татар әдәби телен стилистик баету теләгеннән «Ләһҗәи татари» дигән татар теленең анлатмалы сүзлеген төзи һам аны 1895–1896 елларда аны бастырып чыгара. Бу сүзлекләрнең һәрберсе үз чорында татар һәм рус телләрен өйрәнү һәм шул телләрдәге әдәбият белән файдалану юлында, татар һам рус халкы өчен популяр белешмәләр булып хезмәт иткәннәр. Русча татарча һәм татарча-русча сүзлекләрнең икешәр тапкыр басылуы да шуны раслый; 3) Татар әдәби телен лексик яктан нормалаштыру максатын куеп, К. Насыйри берничә төрдә терминологик сүзлекләр төзегән.

КФУ китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә, ТР Милли Китапханәсе фондларында, ТР Дәүләт архивында саклана торган кулъязмалары арасында төрле фәннәр буенча төзелгән терминологик сүзлекләре бар:

а) Латинча-гарәпча биология терминнары сүзлеге.

б) Татарча-латинча-русча ботаника терминнары сүзлеге,

в) Татарча биология терминнары сүзлеге

г) Русча-латинча-татарча ботаника терминнары сүзлеге,

д) Гарәпчә-татарча-латинча гомуми терминнар сүзлегенең башлангычы.

Бу хезматләрнең бер өлеше К Насыйриның басылып чыккан кайбер аерым әсәрләренә кертелгән. Мәсәлән, «Гөлзар вә Чәмәнзар» (Хавассы набатать), «Буш вакыт» исемле хезмәтләрендә һәм календарьларының аерым саннарында басылган термин сүзлекчәләре шул кулъязмалардан алынган. Ләкин күпчелеге басылмыйча калган. Бу хезмәтләре К. Насыйриның лексикография өлкәсендәге эш күләменең моңа чаклы билгеле булганнан күпкә күбрәк һәм тагын да катлаулырак булуы турында сөйли. Ул, бу өлкәдә үзенең колачын бөтен киңлегендә җәеп, шул чор татар халкына кирәкле лексикографик белешмәләрнең һәртөрлесен төзеп бастырмакчы булган, шундый максатлар белән яшәгән һәм эшләгән.

Шул ук кулъязмалар арасында К. Насыйри тарафыннан төзелгән русча-татарча кечкенә сүзлек өчен словник һәм эшләнеп тәмамланган татарча-русча кечкенә сүзлек тә бар. Болар, эчтәлекләренә һәм төзелү характерлдарына караганда, башлангыч практика өчен яки мәктәпләр өчен хәзерләнгән булганга тиеш.

Каюм Насыйри – татар лексикографиясенә, бигрәк тә аның академик сүзлекчелегенә нигез салган галим.

К. Насыйриның «Татарча-русча лөгать китабы» 1859 елда ук төзелә башласа да, бик соң басылып чыга [5: 80]. 2923 сүзне үз эченә алган 120 битлек сүзлек татарларга рус теле, русларга татар телен өйрәтү максаты белән төзелә.

«Татарча-русча лөгать»нең керешендә К. Насыйри татар һәм рус телләре фонетикасы турында кыскача мәгълүмат бирә. Рус телендә хәрефләрнең ике төрле, ягъни баш (зур) һәм юл (вак) хәрефләре булуын, сулдан-уңга язылуын да искәртеп үтә. Бу ике телдә иҗек һәм басымның уртак һәм үзенчәлекле якларын билгели. Басымның татар телендә, гадәттә, сүз ахырында, ә рус телендә исә төрле иҗектә килә алуын һәм басымга карап мәгънә үзгәрүен ассызыклый.

Бу сүзлек үзенең төзелеш принциплары белән дә хәзерге сүзлекләргә бик якын. Анда сүзләр алфавит тәртибендә, әлеге тәртип сүзнең беренче хәрефенә генә түгел, аннан соң килгәннәренә дә карый. Сүзләр дүрт баганага бүленеп бирелә: беренче баганада гарәп алфавиты тәртибендә, гарәп графикасында татарча сүз урнаштырыла; икенчесендә – сүзнең рус хәрефләре белән транслитерациясе; өченче баганада – сүзнең русчага тәрҗемәсе; дүртенче баганада рус сүзе гарәп хәрефләре белән китерелә. Галимнәр тел өйрәнүчеләр өчен ике телнең фонетик мөмкинлекләрен, әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләрен шулай чагылдырырга тырышканнар. Әлбәттә, бу алым телне җиңелрәк үзләштерергә ярдәм иткән.

К. Насыйри үзенең бу сүзлегенә гарәп, фарсы сүзләрен аз керткән. Ул сөйләм телендә һәм әдәби телдә кулланыла торган алынмаларны гына алган. Монда (күп булмаса да) диалекталь һәм архаик сүзләр дә урын тапкан. Татар сүзләре каршысына рус телендә сүзгә-сүз эквивалент тәрҗемә бирелгән. Тәрҗемәләр җыйнак һәм аңлаешлы. Иллюстрация материаллары, лингвистик аңлатмалар очрамый диярлек.

Гомумән алганда, бу сүзлек үзенең күләме белән да, эчтәлеге белән да татар һәм рус теле өйрәнүчеләр өчен иң кирәкле белешмәләрне генә эченә алган практик кулланма булып тора. Басылмас борын ук аның белән кызыксынган кешеләр булганлыгы шуны тагын да раслый. К. Насыйри үзенең басылган һәм басылмаган әсәрләрен күрсәтеп язган исемлегендә, басылмаган әсәрләре арасына кертелгән «Татарча-русча лөгать китабы» турына «Радлов гасбән (хуплау) алды» дип язып куйган.

К. Насыйриның «Русча-татарча сүзлеге» (1892) XIX гасырның икенче яртысында төзелгән сүзлекләр арасында аеруча күренекле лексикографик хезмәтләрдән санала. 264 битлек иң күләмле сүзлекнең тулы атамасы – «Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как термины». К. Насыйриның бу хезмәте ике тапкыр басылган. Беренче тапкыр 1892 елда, икенче тапкыр 1904 елда дөнья күргән. «К. Насыйри бу сүзлекне турыдан-туры татарларга рус теле өйрәтү өчен белешмә-кулланма итеп төзегән. Автор бу хезмәтенең 35 еллык эш тәҗрибәсе икәнлеген ассызыклап, «бу вакытка кадәр бездә тел өйрәнү юк иде» дигән фикере белән уртаклаша» [4: 4].

Русча өйрәнүчеләргә бераз нәсыйхәт дигән сүз башында К. Насыйри рус теле өйрәнүгә карата байтак киңәшләр биреп үтә һәм дүрт таләпне шарт итеп куя: 1. Аерым сүзләрне белү. Аларны, җиләк җыйганда үзең дә сизмәстән чиләк тутырган шикелле, әкрен-әкрен үзләштерү. 2. Авазларның әйтелеше белән танышлык. 3. Өйрәнелә торган телнең морфология һәм синтаксисын белү. К. Насыйри карашынча, телне конвертларда адрес язу өчен генә өйрәнергә ярамый, чөнки мондый максаттан чыгып өйрәнүчеләр бервакытта да теләкләренә ирешә алмыйлар» һәм ул тел өйрәнү чагыштырма методка нигезләнгән булуын яклый. 4. Рус префиксларының үзенчәлекләрен исәпкә алу [3: 5].

Үзләштерелергә тиешле рус сүзләренең санын билгеләп, Каюм Насыйри болай ди: «Бас, рус телен өйрәнмәкче булсаң, экальле (иң аз) 10–15 мең сүзне ядыңнан белмәк лазимдер» һәм шул таләптән чыгып, үзенең бу сүзлегенә 20 мең чамасында рус сүзе керткәнлеген әйтә, ягъни «Русча-татарча сүзлек» 20 мең чамасы берәмлекне үз эченә алагн. Лөгатьлектә сүзләр

рус алфавиты тәртибендә урнаштырылган, шул чор орфографиясе кагыйдәләрен саклап язылган. Тәрҗемә өлешендәге сүзләр гарәп графикасында бирелгән. Китапның соңгы битендә һәр хәреф башланган бит санын күрсәткән таблица урын алган. Шулай итеп, Каюм Насыйри сүзлекнең техник төзелешен дә заманының алдынгы рус сүзлекләре нигезендә формалаштырган.

Сүзлеккә кертелгән рус теле сүзләренең татар теленә тәрҗемәләрен һәм иллюстрацияләрен күздән кичергәч, К. Насыйриның рус һәм татар телләренең сүз байлыгын гаять яхшы белгән, аларны оста файдаланган тел галиме булуы тагын да ныграк ачыла. Ул рус сүзләрен тәрҗемә иткәндә үз чорындагы татар әдәби телендә булган татар лексикасын киң файдалану белән бергә, шундагы гарәп, фарсы һәм төрек сүзләр һәм тәгъбирләрнең барысын да иркен кулланган. Без анда, саф татарча сүзләрдән торган тәрҗемәләр белән беррәттән, татарча, гарәпчә, фарсыча сүзлар аралаш тәрҗемәләрне да шактый күп табабыз Мәсәлән, *артиллерист* – тупчы, *баллотировать* – сайламак, *баллотировка* – сайлау, *вести* – илтмәк, *жаба* – бака, *вещь* – нәрсә, *акушерка* – эби, мөвәллидаә, *алфавит* – алифба, *алчность* – ач күзлелек, хирыс, *бабочка* – күбәләк, парвана һ. б. Рус теле сүзләрен шундый катнаш лексика белән тәрҗемә итүе аркасында, К. Насыйри үзенең сүзлеген ул чор татар халкының шактый киң катламнары файдалана алырлык кулланма итеп чыгарган.

Рус сүзләренең тәрҗемәсе итеп бирелгән гарәп, фарсы сүзләре янына куярлык, аларга туры килерлек татарча сүзләр булмау очракларында, К. Насыйри җәяләр эчендә аларның татарча аңлатмаларын биргән. Мәсәлән, *благодарность* – шөкер, тәшәккер (изгелек кадерен белүчелек), *благодарный* – хакшенас (изгелек кадерен белүче). Алай гына да түгел, биргән тәрҗемәләре бик ук төгәл булмаган урыннарда, тагын да ачыклау соралган җирләрдә, ул, гомумән, җәяләр эчендә аңлатмалар, ачыклаулар, аныклаулар биреп барган. Мәсәлән, *вдохновление* – җанландырмак (ягъни гайрәтләндермәк), *вдыхать* – тәнәффес кыйлмак, суламак (сулышны эчкә таба тартмак), *вена* – тамыр (бәдәндәге тамыр), *мыс* – борын (җәгърафия истилахы). Бер үк сүзнең сөйләмдә төрле мәгънә һәм төсмерләр белән кулланылуын аныклап күрсәтергә кирәк булганда, К. Насыйри, аның төп мәгънәләрен тәрҗемә белән аңлатканнан соң, өстәмә мәгънәләрен аерым мисалларда күрсәтә барган. Мәсәлән, *обращать* (внимание) – зиһенгә алмак (дикъкать кыйлмак), *он обратил землю в сад* – ул җирне бакча итте; *он обратился ко мне с просьбой* – ул миңа гозер итеп килгән иде; *я обратился к нему с речью* – мин аңа хитап итеп әйттем; *он обратился в бегство* – ул качарга йөз тотты; *земля обращается вокруг солнца* – җир кояш тирәсендә әйләнәдер; *обращаться с людьми* – могашәрә кыйлышмак, халык белән аралашмак; *вода обращалась в лед* – су бозга әверелде һ. б. Шул юл белән К. Насыйри рус телендәге предлогларның, приставкаларның семантик кулланышларын шактый тулылыгында Һәм төгәллегендә аңлатуга ирешкән.

«Русча-татарча сүзлек»нең ахырында К. Насыйри «Әлфаз әҗнәбия», ягъни «Чит сүзләр» дигән баш астында рус теленә башка телләрдән кергән сүзләр һәм терминнар сүзлекчәсе урнаштыра. Биредә *артиллерия, антропология, барометр, бисквит, вентилятор, дидактика, консул, ланцет, манускрипт, ландшафт, микрография, неврология, орфография, плане-*

*та, рейд, реформа, риторика, система, текст, темперамент, хронография, фотография, эксперт, этикет, эфир, цилиндр, юбиляр* кебек 1700 гә якын иҗтимагый-сәяси, фәнни-техник терминнар урын ала. Рус телендәге бу алынмаларга татар телендә аңлатмалар бирү, тәрҗемә итү сүзлекнең кыйммәтен тагын да арттыра һәм бу күренеш үз чоры өчен зур яңалык булып тора.

К. Насыйриның бу сүзлеге бүгенге көндә дә үзенең практик әһәмиятен саклый. Анда бик күп рус сүзләренең мәгънәләре турында кирәкле һәм дөрес белешмәләр табарга мөмкин. Шуның белән бергә, бүгенге көндә аның гаять зур тарихи кыйммәте бар. Бу хезмәт мондый тип сүзлекләр арасында иң күренеклесе һәм унышлыларыннан беренчесе булып тора. Икенче яктан, аның тәрҗемә өлеше безнең күз алдыбызда шул чор татар әдәби теле лексикасының тулы һәм чуар картинасын гәүдәләндерә.


ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Закиев М.З.* К. Насыри и формирование современного национального языка // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976. С. 79–86.

2. *Насыри К.* Татарско-русский словарь. Казань, 1878. 120 с.

3. *Насыри К.* Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины. Казань, 1892. 263 с.

4. *Хангилдин В.Н.* Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе // Каюм Насыйри: 1825–1845: Тууына 120 ел тууга багышланган гыйльми сессия материаллары: Мәҗмуга. Казан: Татгосиздат, 1948. Б. 78–91.

5. *Юсупова А.Ш.* Двуязычная лексикография татарского языка. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. 410 с.



УДК 398


# КАЮМ НАСЫРИ И ТАТАРСКАЯ ФОЛЬКЛОРИСТИКА СЕРЕДИНЫ XIX – НАЧАЛА XX ВЕКА


***И.И. Ямалтдинов***

*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*



В статье рассматривается процесс становления и развития татарской фольклористики как науки. С середины XIX века становление и дальнейшее ее развитие тесно связано с именами ученого-энциклопедиста К. Насыри, классиков национальной литературы поэта Г. Тукая и писателя Г. Ибрагимова, фольклористов Х. Бадиги, Ф. Туйкина, Г. Рашиди, а также ученых-литературоведов Г. Баттала и Г. Рахима. Особое внимание уделяется вкладу К. Насыри как одного из основоположников татарской фольклористики. В заключении автор делает вывод, что в середине XIX – в начале XX в., наряду сбором и публикацией произведений татарского фольклора, были созданы и первые теоретические работы.



**Ключевые слова:** татарская фольклористика, середина XIX – начало XX века, становление и развитие, Каюм Насыри.



The article examines the process of formation and development of Tatar folklore studies as a science. Since the middle of the 19th century, its formation and further development have been closely linked with the names of the encyclopedic scholar K. Nasyri, the classics of national literature poet G. Tukai and writer G. Ibragimov,

and the folklorists H. Badigi, F. Tuikina, G. Rashidi, as well as literary scholars G. Battala and G. Rahim. Special attention is paid to the contribution of K. Nasyri as one of the founders of Tatar folklore studies. In conclusion, the author concludes that in the middle of the 19th – early 20th century, along with the collection and publication of works of Tatar folklore, the first theoretical works were created.
**Keywords:** Tatar folklore studies, middle 19th – early 20th century, formation and development, Kayum Nasyri.

К середине XIX века в русской и зарубежной фольклористике начинает формироваться целое исследовательское направление, в сферу внимания которого попадает и татарский фольклор. На первом этапе своего развития это направление все свои усилия концентрировало на собирании, переводе, первичном анализе и публикации жемчужин национального фольклора. В работах А. Риттиха «Материалы для этнографии России: Казанская губерния» (1870), В. Витевского «Сказки, загадки и песни нагайбеков Верхнеуральского уезда Оренбургской губернии» (1891), С. Рыбакова «Музыка и песни уральских мусульман с очерком их быта» (1897), Н. Катанова «Материалы к изучению казанско-татарского наречия» (1898), «Исторические песни казанских татар» (1899) татарское народное творчество становится объектом целенаправленного научного изучения.

Во второй половине XIX века в дело собирания, изучения и издания татарского фольклора вносят свой вклад Г. Фаезханов, М. Салихов, Т. Яхин, Ф. Халиди и др. Ежегодно отдельными книгами печатаются «Сказание о Сейфульмулюке» («Сәйфелмөлек кыйссасы»), «Сказание о Юсуфе» («Йосыф кыйссасы»), анекдоты Ходжи Насретдина, «Сказание о Сулеймане» («Сөләйман кыйссасы»). В 1852 году выходит в свет «Русча-татарча әлифба» («Русско-татарская азбука») Г. Вагапова. Позже этот труд издается под названием «Үзи-үзидән өйрәткеч» («Самоучитель») и выдерживает более 20-и изданий. В нем приводятся татарские народные песни, мэзэки (анекдоты), сказки, пословицы-поговорки и др. В 1869 году Г. Вагапов издает первый сборник татарских народных песен под названием «Җырулар» («Песни»). Широко используют фольклорные произведения в своих учебниках и хрестоматиях по татарскому языку Г. Махмудов, С. Кукляшев, М. Бикчурин. Начиная с 1870-х годов издаются десятки фольклорных сборников без указания составителей и собирателей. Все большее внимание начинает уделяться переводам на татарский язык произведений фольклора народов Востока.

Вместе с тем, получает определенный размах также работа по переводу образцов татарского фольклора на другие языки с целью ознакомления ими иные народы. Непосредственная запись из уст народа, издание, перевод на другие языки произведений народного творчества берут свое начало с 70-х гг. XIX века. В эти годы академик В.В. Радлов, венгерский ученый Г. Балинт, финский ученый Х. Паасонен, венгерский тюрколог Г. Вамбери, профессор Казанского университета Н.Ф. Катанов выпускают свои значимые научные труды. В частности, в трудах В. Радлова «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в южной Сибири и Дзунгарской степи. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар» (1872), «Das turkische Sprachmaterial des Codex Cumanicus»

(1887), Г.Балинта «Kazani-Tatar Nyelvtonulmanyok» (1875–1876), Г. Вамбери «Das Turkenvolk in seinen Ethnographisen beziehungen» (1885), Х. Паасонена «Tatarische Lieder» (1901) в переводе на русские и немецкие языки приводятся образцы народного творчества. Эти ученые, наряду с подачей произведений татарского фольклора на языке оригинала, переводили их на немецкий (Х. Паасонен) и венгерский (Г. Балинт) языки в целях оказания помощи европейским ученым, изучающим тюркские языки. Н.Ф. Катанов – помимо публикации образцов татарского народного творчества в арабской графике и в академической транскрипции – сопровождал их точными переводами на русском языке, отдельные слова снабжал комментариями. Его «Материалы к изучению казанско-татарского наречия» (1898) стали одним из первых трудов, благодаря которому русский читатель мог ознакомиться с некоторыми образцами татарских народных сказок. В XIII томе «Известий Общества археологии, истории и этнографии» (1896) выходят собранные К. Насыри «Образцы народной литературы казанских татар», а в XVI томе выходят 11 сказок на русском и татарском языках. Он, наряду с популиризацией фольклора с целью просвещения своего народа, развития его культуры и науки, придавал большое значение ознакомлению и русского народа с духовным богатством татар. Как считает фольклорист Э. Касыймов, совместный труд К. Насыри и П.А. Полякова «Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов» был подготовлен именно с этой целью. П.А. Поляков перевел сказки, собранные К. Насыри, в качестве источника для изучения татарского языка. Также в конце книги он поместил статью, в которой рассмотрел татарские народные сказки в сравнительном аспекте со сказками других народов. Все это свидетельствовало о высокой научной значимости этого сборника. После него вплоть до начала 1920-х гг. больше не выходило специального подобного сборника татарских народных сказок на русском языке.

Особый интерес вызывают замечания Э. Касыймова, касающиеся этих изданий, так как они в определенной степени характерны и другим трудам того же периода. Он, в частности, отмечает, что часть таких изданий выпускалась как лингвистический материал, фольклорная составляющая была вспомогательной. Поэтому среди них встречаются произведения, по сути не являющиеся образцами народного творчества. Вместе с тем, не указывается, где, когда, от кого и кем были записаны сказки (не паспортизируются). Перевод ограничен академическим принципом. Точная подача текстов на другом языке и отсутствие комментарий – все это, а также использование дополнительных слов, не имеющихся в оригинале, искажают подлинный текст и художественность сказок. Кроме того эти сборники издавались малым тиражом в сугубо научных целях и не доходили до широкого читателя [2: 111].

Известный просветитель, ученый-энциклопедист К. Насыри нас интересует как один из основоположников татарской фольклористики. Его работа в этой области в основном велась в трех направлениях. В первую очередь он собирал и записывал татарский фольклор непосредственно из уст народа, придавая большое значение популяризации его наилучших образцов. В своих трудах «Казан календарьләре» («Казанские календари»), «Кырык бакча» («Сорок садов»), «Фәвәкиһел-җөләсә фил әдәбият» («Пло-

